# КАЗАН УТЛАРЫ

8.1990



## ЖУРНАЛ АЛДЫРУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Журналның брак саны килгән очракта аны газета-журналлар нәшриятының техник контроль бүлегенә җибәрүегезне үтенәбез. Адресы: *420066, Казань, ул. Декабристов, 2, Типография ГЖИ, ОТК.*

Редакция журнал җибәрү белән шөгыльләнми.

Әгәр журналның теге яки бу саны килми калса, «Союзпечать»нең җирле бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу мәсьәлә редакция вәкаләтенә керми.

Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1990

8

(814)

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ә. БАЯН. Төрле еллардан. *Шигырьләр* . . . 3
Х. ӘЮП. Су хәтере. *Шигырьләр* . . . . . . 7
А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Балта кем кулында? *Роман* 11
С. ГӘРӘЕВА. Авылым. *Шигырьләр* . . . . 110
Б. РӘФЫЙКОВ. Нишләттең син, замана... *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . 113
Н. АКМАЛ. Күгәрчен сөте. *Повесть* . . . . 114

МӘҖИТ ГАФУРИНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

З. РӘМИЕВ. Әдипнең аз билгеле шигырьләре 155
М. ГАФУРИ. «Милләт мәхәббәте» китабындагы шигырьләрдән . . . . . . . . . . . 156

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тукайлар рухы *(күренекле әдип, сугыш һәм хезмәт ветераны Салих Баттал белән әңгәмә)* 158
Әдип турында каләмдәшләре *(Н. Арслан, А. Гыйләҗев, Р. Батулла)* . . . . . . . . 163

Л. ХӘМИДУЛЛИН. Киңәшле эш таркалмас 168

КИТАП КҮЗӘТҮ

В. ХАКОВ. Хәзинәләр ачкычы . . . . . . 171

МӘДӘНИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Г. САТТАРОВ. Исемнәр йолдызлыгы . . . . 173

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Халикъ Садриның тууына 100 ел . . . . . 172

Бер сорауга — бер җавап 109

УКУЧЫ СҮЗЕ

Ф. ГАНИЕВ. Әдипне хуплыйм . . . . . . 179
Г. ӘДҺӘМОВА. Өметләр өзелмәгән . . . . . 180
Р. СӨЛӘЙМАНОВ. Моңа без хуҗа . . . . . 182

Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре . . . . . . . . . 183

*Баш мөхәррир*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙФИ
*(җаваплы сәркәтип)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш мөхәррир урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек мөхәррире)*
МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек мөхәррире)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркәтип — 53-07-09,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

ЮМОР-САТИРА

**Х. ХӨСНУЛЛИН.** **«Саратти агентлыгы».** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . 185
**НИЗАМИ.** **Тәүбә.** *Шигырь* . . . . . . . . 186
**КӘШФЕЛЗАДӘ.** **Һаман «күтәрелүче» бер дуска.** *Шигырь* . . . . . . . . . . . . 186

**Журналыбызны кайда күпме алдыралар** . . 187
**Мәдәният тормышы көндәлеге** . . . . . . 189
**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа А. ГИЛЯЗОВА «В чьих руках топор?»; начало повести Н. АКМАЛОВА «Птичье молоко». Стихи А. БАЯНА, Х. АЮПА, С. ГАРАЕВОЙ, Б. РАФИКОВА;
«Литературная критика»: беседа Г. Муратова с писателем, ветераном войны и труда С. БАТТАЛОМ о проблемах современности и литературы; статья Л. ХАМИДУЛЛИНА.
«Книжное обозрение»: В. ХАКОВ рецензирует книгу Дж. Зайнуллина «Татарская азбука на основе арабской графики».
«К истории культуры»: статья Г. САТТАРОВА «Созвездие имен».
«Юмор и сатира»: стихи Х. ХУСНУЛЛИНА, НИЗАМИ и КАШФЕЛЬЗАДЭ.
Строки из писем.
В номере отмечается 110-летие классика татарской литературы М. Гафури и 100-летие писателя Х. Садри.
Сведения о распространении журнала «Казан утлары» и о татарской периодической печати.
Хроника культурной жизни.
На наших обложках — «Казанский кремль». Портрет известного драматурга, народного депутата СССР Туфана Миннуллина.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Р. Вафина, Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина.

Производствога бирелде 6.06.1990 ел. Басарга кул куелды 31.07.1990 ел. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 83044. Заказ Д-287. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1990 ел.

# ШИГЪРИЯТ

## Әхсән Баян

## ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

### Илгә кайтсам

Күп юллар узгач, талчыгыр булсам,
Туган туфракка кайтып егылсам,
Сез күкрәгемә куегыз, зинһар,
Кыр бизәп үскән арыш чәчәген.
Өстәлсен аңа еракта калган,
Яшьлектә тамган керсез яшьләрем.

Кызлар, киленнәр учак якканда,
Тузан кузгатып көтү кайтканда,
Күк чәчәк белән куегыз бергә
Кичке кырларның алтынсу төсен.
Өстәгез аңа изге сөт исен,
Ак бәхет сирпеп йолдызлар көлсен.

Манчыгыз яулык чишмә суында,
Күрше-тирәнең сабыр моңында.
Йөрәк яңадан талпынмый калмас,
Битемдә җирем сулышын тойгач.
Сагышлар узып, күзем ачылгач,
Сезгә яктырак елмаер кояш.

1988.

### Әни сагышы

Үскән чакта ашыктыра идек
Вакытны без, Җирне, Кояшны:
«Их, шуларның әйләнешен ничек
Тиз йөрешкә күчереп куясы!»

Күчереп булмаганга, көннәр — озын,
Әни кайта кырдан артык соң.
Үсү кирәк иде безгә тизрәк,
Тарту өчен йөкнең яртысын.

---

*Әхсән БАЯН (1927) — шагыйрь, прозаик, драматург, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән утызга якын шигырь, проза китаплары авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Үстек бугай, гәрчә бик акыртын,
Һәм ачылды бугай күз кинәт:
Без үскәнбез, ә анинең буен
Кичерәйткән Вакыт әкренләп...

Усаллашты Вакыт, күрдек тагын:
Ул әнинең соңрак төсләрен, —
Һәм хисләрен бәлки, — китте урлап,
Йолкый торды чәчен, тешләрен.

Салкын күздә... алып китте үзен...
Ашыкты ла Вакыт артыграк.

Җир һәм Кояш зырлап әйләнә дип,
Уйлап торам хәзер аптырап.

Әллә, димен, ташларгамы таяк
Көпчәгенә Җирнең, Кояшның?
Моңа ләкин әни каршы иде,
Оныклар бит юкса тумас дип.

Шуңадыр да элеккечә кала,
Үз урнында кала барысы:
Көлеп каршы ала оныклары,
Озата бара ана сагышы.

1985

## Тәңре төяге

Сугыш, имеш, җиргә иңгән күктән,
Күккә, имеш, ызгыш — тамаша:
Күк әмере белән
Адәм селти кылыч,
Илләр белән илләр талаша.

Тәңре җиңгән вак пот-санамнарны,
Алла җиңгән олуг Тәңрене.
Шаулап тора яулар ут-төтенле,
Ава байрак — этле, тәреле.

Кара таңда пәйгамбәрләр калка,
Аллаларны яклап, коеп кан.
Безнең пәйгамбәр юк, ил Тәңрене
Яклау кирәклеген оныткан.

Пәйгамбәрләр, Идел күрмәгәнгә,
Җәннәт эзләп тапкан чүлләрдән.
Оҗмах өчен кулай инеш-дәрья
Хыял-бакча белән бизәлгән.

Чүл-сахрада шуңар аллалар күп,
Кул изиләр «заман ахыр»дан.

Тәңре улы, ят кыйблага барып,
Шулар шөһрәтенә баш орган.

Ятим калгач, Титан булалмаган,
Зевс булалмаган Алпамыш.
Раббы, Яхве, Хода якташлары
Безне соңрак таный башламыш.

Инде алар, кыйбла дигән ерак
Төякләрдән килә-килешкә:
«Су — изге!» — дип, иеләләр җәһәт
Безнең чишмә, безнең инешкә.

Аллаларга, күккә игелек бара,
Димәк, минем җирем, суымнан.
Яңа көчләр эзләп салынган юл
Иделемә таба сузылган.

Табына торган кодрәт, кыйблабыз
Якындадыр күптән — Иделдер.
Оҗмах та шул... Сакламасак аны,
Яшәү безгә хәләл түгелдер.

1983

## Муса Җәлилгә

Синең гомер легендага тартым,
Тик бәхәсле булды кай ара.
Безне әйтү кая, дөнья хәтта
Каһарманнар белән шаяра.

Шаярдылар үчле һәм үчсезләр,
Шаярдылар тешле, тешсезләр.
Һәйкәл ташын кимерделәр кайчак
Кешеләрдән күреп күселәр.

Таш катысы торды мантыйк белән:
«Шулкадәр үк дошман исәрме —
Үзенә дус, ялчы, кол булганның
Башларын ул әллә кисәрме?»

Балта сыман синең өстә торган
Катылыкны без дә татыдык.
Әмма күптән гильотина белән
Хәл ителгән иде батырлык.

Шуннан китте жырлы соклanулар,
Сырышулар данлы форсатка:
«Булыр идек без дә аның кебек,
Шундый хәлдә калган очракта!»

Күкрәк сукмыйк — бәлки, булыр
идек...
Ак кар яугач... кызыл кар яугач...
Актык, мәрмәр сүзне әйтербез — тик
Башыбызны кисеп карагач.

1983

## Кичке фаҗига

Ышыкланып эңгер төсләренә,
Мыштым гына килде ябалак.
Торды тыңлап. Абзар кыекларын
Кагып узгач, торды сагалап.

Чыпчык — башы житсә — көтә
белсә,
Куркаклыгын бераз тыебрак,
Булмас иде берни. Коты очып,
Оядан ул чыкты пырылдап.

Чырылдап та ләкин өлгермәде.
Сукты төссез яшен-ябалак.
Эләктереп тиз үк качты карак.
Һәм чыпчыктан калды пар канат.

Ә табигать, булмагандай берни,
Мәңге килгән гадәт буенча,
Иркәләвен белде жирне сөеп,
Бөек серен үзенең жуймыйча.

1987

*

Шигырьле ак кәгазь белән
Каплап тордым кояшны.
Эссе кабудан шигырем
Саклады шулай башны.

Тырышырга бурычлымын
Инде мин онытмаска:
Башны шигырь саклый кайчак
Һәм шигырь... житә башка.

1988

## Син һәм яшел кыр

Мин күргәннең чиге — зәңгәр томан,
Белгәннәрем чиге — шул уктыр.
Барачагым чиге — күк офыктыр,
Аръягында син бар, мин юктыр.

Без очрашкан чактагыдай, һаман
Чакыра безне урман, болын, кыр.
Житәкләшеп күпме еллар уздык —
Алда мондый озын юл юктыр.

Газабына юлның без күнеккән,
Әй, булмаса икән азагы.

Мин калсам да, син кит ары — сиңа
Мин китергән шатлык аз әле.

Булганнары калсын минем белән...
Офык дигән зәңгәр ызаннан, —
Минсез сине бәхет көткән хәлдә, —
Мин узалмам инде, узалмам.

Без очрашкан чактагыдай, алда
Чакыра сине болын, яшел кыр...
Хушлашабыз ләкин — мин кул
болгап
Калам инде: «Син бар, атлый тор!»

1987

*

Булды, житте! Таштан каерып юкә,
Уздыргандыз күпме гомер бушка.
Булганына шөкер кыл да уйла
Һәм башкача карый төш тормышка.

Хыял белән саләт бер-берсенә
Охшаш түгел икән бөтенләй үк.
Яшь чактагы теләкләрең белән
Ирешкәнең синең — жир белән күк!

Лэкин кара: кояш — исән, шул ук.
Бичәң яшьлегедәй ай елмая.
Барча хаталарны ташлап җилгә,
Кычкырып бер көл дә — чык
дөньяга.

Дөнья кичә юеш, пычрак иде,
Бүген исә җир — нык, тыныч һава.
Ничек безне җил яратып исә,
Нинди әнә назлы яшь кар ява.

Кем өчендер бу да хыялдыр бит?
Кыюсыздыр өмет... Әйдә, чыгыйк.
Аргы урамда бигрәк матур тормыш —
Атлап узыйк шунда шыгырт-шыгырт.

Өреп, сикереп маэмай каршылады.
Бичарага безне күрү — сөенеч...
Яшәп тыгыз һәм тиз, елларны без
Сәгатьләргә сыйдырырга тиеш.

1987

## Авылдашым монологы

Яшел җәйгә яшьлек яме өстәп,
Әйтте чибәр миңа һәм дустыма:
— Сабантуйда кем тәкәне алса,
Бирәчәкмен йөрәгемне шуңа.

Күктән төшкән фәрештәмнең сүзе
Әйтелсә дә тик шаярып, уйнап,
Көч сынарга мин ризалык биргәч,
Көндәш дустым канатланды чынлап:

— Сабан туе тәкәсеме? Бик шәп.
Алайса, бел, быел ул — минеке!
— Шаярсаң да сүзне сөйлә уйлап.
— Егет кеше сүзне әйтмәс ике.

Вәгъдә — иман, атылган ук сыман.
Һәм егетне булмый артык хурлап:
Сүзендә ул торган — атна буе
Симертелгән малны... чыккан урлап.

Ә мин мескен, әй, көрәшкән булам,
Егылсам да тагын сикереп торам.
Очрашканда кыз күзләре белән
Гарьлегемнән башны читкә борам.

Гарьлегемне җиңеп, тагын чыгып,
Тагын җиңелеп, тагын алгач сөлге,
Соңгы кабат арка тойгач җирне,
Күкрәгемдә — җиңүченең тезе...

Күкрәгемне учлап, алпан-тилпән
Атлыйм — гүя мин хәмердән гарык.
Җиңүченең шатлыгымы бөтен?
Җилкәсендә аның — арык сарык.

Ә карак дус? Менә ул ичмасам
Бәйрәм итте, шайтан! Унбиш көнлек
Җәзага да тармас җайны табып,
Көнендә үк кайткан, мыек бөтереп.

Җитмәсә бит, минем хакта ялган
Сүз тараткан: мин, янәсе, чаккан.
«Доносчы!» — дип яман ярлык таккан.
Ә ул, имеш, корбан чат нахактан.

Тәкә суеп, бар авылны җыеп,
Корды мәҗлес — бию, җыр, тантана.
Шау-шу аша ишетәм: һәм фәрештәм
Тавышы килә — көлә, әй шатлана!

Минем генә яшьлек юләрлегем
Җырлар, биер хәлне калдырмады.
Җәрәхәтен ялагандай җәнлек,
Яттым сыйпап сынган кабыргамны.

1989

# Харрас Әюп

## Су хәтере

*Суның да хәтере бар...*

Картлар сүзе

Ышкылгандай шәһәр диварына,
Ни гомерләр ага Казан-су! —
Магнитофон тасмасыдай,
Безнең
Язмышларны «язып» алган су.

Вакыт чорный барган...
Болганса да,
Җуелмыйдыр сулар хәтере;
Кырылышып бетсә-бетә халык —
Су бетмидер... Мәңге ул тере!

Дошман сөенмәсен — манкортларга
Әйләнде дип, халык уллары,
Киләчәккә ага Казан-елга —
Онытмагыз әле ул барын...

❋

Күрәчәгең булгач, күрми хәл юк —
Елга ничек йөзен капласын?
Хәтерләүләре дә — авыр газап
Ул көннәрне...
Алла сакласын!

...Ничәнче көн камалышта шәһәр,
Кальга өсләрендә ак төтен...
Сиңа шатлык каян килсен, Казан,
Сатлыклардан булгач бәхетең?!

Исәнгерәп кинәт, чайкалды көз,
Тыныч елга тетрәп аһ орды:
Сатлыкларның шакшы кулы белән
Шартлаттылар ничә гасырны!

Адәм әүлиясе Колшәрифнең
Су өстендә ап-ак шәүләсе:
Шагыйрьләрнең өлеше — халык өчен
Шәһит китү микән әллә соң?!

Ходай кушмагандыр бу язмышны,
Башкисәрләр безгә кушкандыр —
Илдән иман, ахры, Колшәрифләр
Җаны белән бергә очкандыр...

Урамнардан кызыл гөрләвекләр
Кушылдылар төшеп суларга:
Сулар хәтерендә Казан-елга
Канлы тасма булып чорналган...

---

Харрас ӘЮП *(1946) — шагыйрь, «Ышаныч», «Таң суы», «Төнге кояшлар» һәм башка китаплар авторы. Казанда яши.*

*

Белеп торам: «Язганыңда
Су күп»,— диячәкләрен...
Нишлисең инде — сулардан
Булгач күрәчәкләрең?

Узган гомерләр — суларда,
Алар шаһит барына:
Качып китә Шаһгалиләр,
Сулар салып дарыңа.

Шәһәрне ничек саклыйсың
Чыланган дары белән?
Ул суларны кая куйыйм,
Язмыйча бары белән?!

Белгәннәр суның куәтен,
Су белән булашканнар —
Казанны бер йотым сусыз
Итәргә тырышканнар.

Капма-каршы ике көчтер:
Берсе — су, берсе — дары, —
Чишмәне шартлаткан чакта
Очрашкан алар тагы.

Бәхет дип сөйләнеп, бүген
Кемнәр дуамалланган? —
Халыкның гомер чишмәсе
Шул чактук томаланган...

Язарга кызык булганнан
Су кушып язмыйсың ла! —
Нишлисең, сулар күп булгач
Халкыңның язмышында?!

Шаһгалиләрнең гасырлар
Узып та беткәне юк:
Бар бездә дары... Тик аның
Әле дә кипкәне юк!..

*

Кеше түгел бит ул онытырга —
Хәтере бар суның, хәтере бар,
Безнең ише хәтерсезләр өчен
Кире кайта-кайта әйтере бар.

Муеныннан бүрәнәгә бәйләп
Агызылган ирләр сүземе әллә?
Сабыйларның елашуы микән —
И бу елга сабыр, түзем әл дә!

Бөтенесе инде кырылып беткәч,
Әче күз яшьләрен эчкә йотып,
Ахыр чиктә чыга хатын-кызлар
Илбасарга каршы хәнҗәр тотып...

Ела, Казан! Ятим урамнарың
Ул чагында елый алмагандыр —
Сабыйларга хәтле каны аккач,
Яшен түгәр кеше калмагандыр.

Кырык җирдә кырылышып яткан
Татарларга кемнәр ясин чыксын? —
Мөселманнар килеп дога кыла
Менә бүген — ничә гасырдан соң!

Аккан сулар оныта ала диме
Ул суешны газиз каласында?
Ела, Казан! Таман бу кайгыңа —
Ничә гасыр әле еласаң да!..

*

Ышкылгандай шәһәр диварына
Сулар аккан —
Сора сулардан:
Мәчет хәтле мәчетләрне тиран
Урыныннан нигә кубарган?

Йөрәгеңә чиркәү салып куйган,
Сызламасын нигә йөрәгең?!
Болгарында чиркәү — бабайларның
Кабер ташы белән түләдең...

Талап җыйган алтын-көмеш җитми,
Кирәк аңа синең Иманың —
Канлы кулын Иманыңа сузган,
Хөкемдары булып дөньяның.

Иван белән ярашмыйдыр Иман,
Хак Иманга барыбер кер кунмый...
Каеннарга кушып карый исемен —
Ә каеннар һаман чукынмый!..

...Үз юлыннан сулар ага торган,
Ә суларга бар да язылган:
Бу халкының рухын сындырырга
Теләүчеләр әллә аз булган?!

Җимерелми калган Сөембикә
Манарасы кыяфәтендә
Ул бүген дә басып тора әле,
Яңа эзләр уя хәтергә.

Манараның үткен очы ерта
Кемнәрнеңдер мин-минлекләрен —
Шәҗәрәле була явызлык та...
Инде күпме авыз иткәнең!

Түкми-чәчми барсын салып бара
Агышына: сулар — хәтерле.
Аккан судай нигә озын булды
Безнең кимлек? Сулар әйтерме?

*

Уйланабыз суга карап,
Үткәнне сагынабыз,
Туры килдек лә суларның
Айкалган чагына без.

Актарылган чакларына...
Бөтереп ала дулкын.
Чыгырдан чыккан суларның
Белә идек тә холкын,

Белгән көенчә һаман да
Саламга ябышабыз —
Заманга ябышыр чакта...
Ялгышсыз ялгышабыз!

Кая карасаң да — сулар,
Биш диңгез порты — Казан.
Агасы икән лә безгә
Кайсы диңгезгә табан?!

*

Кемнәр генә җырламады
Бу бәхетсез нигездә:
«Минем дә кайгыларымны
Илтеп сал, дип, диңгезгә...»

Агызып алып киттеләр,
Авырсынмады сулар —
Халыкның кайгы-сагышын
Көн вә төн ташыдылар.

Ташыдылар... Әллә нигә
Бетмәде кайгы гына —
Әнә тагын кемнәреңдер
Иленнән аерыла:

Суларга төшә шәүләсе
Кремль төрмәсенең...
Хәлеңнән килсә, и елгам,
Язмышка бирмәс идең.

Асыл егетләрен илнең —
Туфанын, Кәримнәрен...
Кемнәр белсен нидән болай
Ярларга бәрелгәнең!

Су буйларында — авыллар...
Сулар ник ашыктылар? —
Корбанлы еллар кайгыны
Көн вә төн ташыттылар...

*

Идел... Кама... — сулар тоташ.
Беләсең, су, беләсең:
Туган авылын эзләп бирәү —
Кая борсын көймәсен?

Тирәндәме өй урыны —
Ташлансынмы ташкынга?
Ата-баба сөякләре
Кайсы дулкын астында?

Әллә чынлап та аларның
Җаннары тере микән —
Акчарлак булып, суларга
Сугылып йөри микән?

Ник болай хөкем иттеләр
Үзеңнән башка гына? —
Куялмыйсың башкаеңны
Нигезең ташларына...

Ничек хәтерләмәсен дә
Сулар, ничек белмәсен:
Кеше дип йөртәләр иде —
Әверелдең кемгә син?!

Чакырган җиргә барасың,
Куган җирдән китәсең...
Куган җирләр — Туган җирең
Булса, ни хәл итәсең?

*

Сулар белән гел янәшә бит без,
Чагылабыз гүя көзгедә.
Бер сорарлар әле, таптырырлар —
Хәтерләп кал, дулкын, безне дә!

Ком кудыра иде земснаряд,
Камышлары Казан-елганың
Тирбәлделәр җилдә...—
И газиз су!
Яулыгыңны кемгә болгадың?

Дәшми-тынмый гына сулар ага,
Ага хәтер сулар эзеннән.
Кадер беткән чакта хәтерләр дә
Кала икән чыпчык тезеннән...

Кемлегебез — чишмәләргә язган...
Суга салдык күпме байлыкны!
Эремәде суда ул гөнаһлар —
Үлгән
Балык булып өскә калыкты.

Саекса да хәтер, еллар тирән —
Үзебезгә чоңгыл казылган.
Хәтерләп кал, дулкын: килер язмыш
Сәнәк белән суга язылган.

Кеше күзе үтерүчесе йөзен
Алып кала, диләр, үзендә.
Китеп бара сулар — безнең шәүлә,
Безнең сурәт сулар күзендә...

*

Гасырлар икән бит синдә...
Аңладым, су, аңладым:
Безнең болай булуларда
Гаебе юк алланың!

Мулла да, кулак та түгел
Кешеләрнең дошманы,
Хак дошманың — үткәнеңне
Онытырга кушканы.

...Су буйларына төшәсең,
И, Сулар бар әле дә! —
Кемнәр кергән булыр иде
Бу халыкның хәленә?

Иделеңнән аермасын! —
Шуны телә иң элек,
Болай да бит бар дөньяга
Бетә яздык сибелеп...

Җирдәге бар сулар тоташ,
Аксалар да кай таба.
Аккан сулар кире кайтмый,
Диләр дә бит... Кайтала!

Явызлыкта чама беткәч,
Сулар да бер кайтачак:
Су хәтере — безнең хәтер! —
Туфан булып калкачак...

1989

## Чәчмә әсәрләр

**Аяз Гыйләҗев**

# БАЛТА КЕМ КУЛЫНДА?

РОМАН



Кояш офыктан аерылып шактый күтәрелде, көн әз генә җылынгандай булды; мунчаны кабызып җибәрергә бик вакыт иде. «Суны каян ташыйсыз соң? Көмешкүлгә үк йөрмисездер бит?» — дип сорады Нәҗип аптырашка калып. Бу юлы Нәҗип әнисеннән күңелле, шат җавап көткән иде. Югары Авыл халкы өчен изге саналган Көмешкүл Мәрьямбикәгә дә туган ягының иң матур, иң хатирәле төбәге иде. Көмешкүл ярларыннан башланган Аклан чирәмендә Сабан туйлары уза, көзге муллык җыеннарында да тирә-як халкы шунда җыела...

«Күл юк, улым.ул да әллә кайчан кипте», — диде Мәрьямбикә исе китмәгән кыяфәт белән. Күл юклыгына ул әллә кайчан күнегеп беткән иде инде. Нәҗип тоткан пар чиләк шылтырады. Ахырзаман диләр, шул килеп җиттеме әллә? «Кипте шул, — диде карчык, күлне әзрәк җәлләгән сыман. — Анау елны дөнья корыды, яңгыр яумады, күлгә әллә ничә басудан торбалар тыгып, җәй буе суын суырттылар. Көзгә тиклем күл төбендә ындыр табагы хәтле генә су калды дип сөйләделәр. Үзем бармадым, барганым да юк. Аяк тартмый. Җитмәсә, күл ягына нефтьчеләр өч тишек тишкәннәр. Әллә шунда качты су, әллә кысыр җәйдә үлде. Хәзер, әнә, язгы сулар әз-мәз җыелып ала да, кояш ялый башлагач, бетә дә китә икән. Адәм буе сырганак, чатлы-ботлы әрекмән үсә ди ярларында. Суны, онытмаган булсаң, Галләм абыеңнар коесыннан алабыз. Аларның коесының суы каты, кая барасың, күпчелек коелардан су качты, Түбән оч чишмәсе корыды... Кое суының ни чәе чыкмый, ни керне агартып булмый, эчәргә дә тозлы. Әткәң яңгыр сулары җыештырып йөри. Яңгыр суы да хәзер селтеләнә бара».

Алар сөйләшә-сөйләшә тыкрыктан кайттылар, кеше-кара күренмәде, көтү куган чак, мәгәр бу очта мал тавышлары юк иде.

Ул чиләкләрен шылтыратмаска тырышты. Урамга чыкты.

Югары Авыл урамы. Аның гомер юлының башы. Балачакта бу урам хәтфә чирәм белән, янбакча киртәсе буйлары песи борчагы, карга борыны кебек үләннәр белән каплана иде. Боларның берсе дә калмаган, урам Әзи юлы шикелле үк изелеп, җебеп, чокырланып беткән. Күз ял итәрлек янбакчалар да, миләш, шомырт, сәрви куаклары ара-

Ахыры. Башы 7 нче санда

сында балкып утырган умарталар да юк. Тракторлар — урамның, замана — янбакчаларның, агу таратучы сәмәлүтләр — бал кортларының, төклетураларның, зәңгәрсу быжаннарның башына җиткән...

Ул ике чиләген бер кулына алып, авам-авам дип утырган читәнкиртәләргәябыша-ябыша, Галләмнәр коесына барып җитте. Чыгырлы иске кое янына баскач, жилкапка һәм тәбәнәк утыртма читән аркылы хуҗаларның ишегалдына карады. Заманында карчыгы Хәдичә белән сигез бала үстергән Галләмнәр йортында хәрәкәт сизелмәде, ак колаклы арык эт, суга килүченең ят икәнен абайлапмы, болай, олы дөреслек өчен генәме, иренеп бер-ике тапкыр авызын ачып алды. «Тавышымны ишеттегезме?» — дигәндәй, кешесез ишеккә бер карады да өй нигезе җылысына сузылып ятты, күзен йомды. Шәп-шәрә ботакларын тибрәндереп утырган, шәрә сөякле корыган карама агачында ике арык чыпчык, нидер бүлешә алмыйча тарткалаштылар да, икесе ике якка очып югалдылар. Кое чыгырының имән багана төпләре муртайган, чергән иде. Ул чыгыр бавына бәйләп, багананы кулы белән тотып, чиләкне кара кое авызына төшерде. Урам сәерлеге, бушлыгы, тынлыгы белән аны тәмам йоткан иде, якынаеп килгән аяк тавышын ул әллә нинди бер могҗизадай кабул итте, ялт итеп борылып карады. Сыңар чиләген беләгенә элеп, болай таба Гөлгенә килә икән. Ул җиңел, юка күлмәк кигән, тезе ачык, изүенең пыртлые ычкынган, авызында кәгазьгә урап төргән беләк буе тәмәке. Яланаякларына үкчәләре кыршылып, ямьшәеп беткән резин итекләр элдергән. Килеп тә җитте, тәмәкесен төкереп тә очырды. Төпчек кое яны дымына төшеп, байтак выкыт чыжлап, зәһәр ис таратып ятты. «Исәнме, Нәҗип, — диде Гөлгенә, чиләген сул беләгеннән уңына күчереп. — Кайтып җиттек, диген».

Нәҗип аның яшерен ымнар тулган, төртмә сәламен алмады, җавапсыз калдырырга да яхшысынмады, тонык кына: «Күрәсең бит, кайттык», — диде.

Гөлгенә, соң дәрәҗәдә кызыксынып, аулакта күршесенең эч серләрен алып калырга дип, сорауларга тулып-ташып килгән иде, Нәҗипнең тонык җавабына аның исе китмәде, өйдән әзерләп чыккан беренче соравын бирде: «Хатыныңны да алып кайттыңмы?» «Балаларны да», — диде Нәҗип. Гөлгенә кинәт уйчанланды, бу халәтен Нәҗипкә сиздерәсе килмәде, юри наян, ясалма тавыш белән: «Мунчаң эссе булсын, утыныңны җәлләмә! Иптәш хатын белән мин дә юынып чыгармын», — диде. Нәҗип аңа күтәрелеп карады: «Ник үзегез якмыйсыз?» «Баш авырта. Кичә иптәш кызымның туган көне иде. Кичен юынасы идек, салынган, махмырга иртән юыныйк дип төшсәк, кемдер суны бетереп куйган. Кунакка буш кул белән кайтмагансыңдыр, яртың булса, безгә дә өлеш чыгар. Сызгыр гына, кереп җитәрбез». «Мин эчмим бит», — диде Нәҗип коры гына. Гөлгенәгә бу сүз җитә калды, куе кашлары очып китәргә җыенгандай хәрәкәтләнде: «Ә син хәсрәтеңне ничек юасың алайса? Әллә син хәсрәтсез яшәүчеләр арасына мендеңме? Кеше хакы ашап яшәп ятасыңмы?»

Нәҗип бер мәлгә Гөлгенәнең чая кыз чакларын хәтерләде...

Ул бер чиләк су меңгезде, икенчесен. «Бусы миңа!» — диде Гөлгенә төчеләнеп. Нәҗип чиләге судан бушап, өченчесенә шалтыр-шолтыр килеп кое авызына кереп югалды. «Хәзер кайгы-хәсрәтсез кеше бармыни ул? Нигә эчәләр дип уйлыйсың син? Хәсрәткә даруны академиклар да таба алмый. Эчмим дип йә син алдашасың, йә син просто дурак». «Каты әйтәсең», — диде Нәҗип ачыктан-ачык җәберсенеп. «Председатель утыртты мине. Мир үгезе! Авылда аның кулы аша үтмәгән хатын-кыз калмады. Дөрес, печән урлап кайттым. Урламасам, соңгы кәҗәне — Сталин сыерын сатарга туры килә иде. Рәис тотты, сагалап йөргән икән, шпион. Колхоз байлыгын кайгыртып йөрүедер, дисеңме, тот пычагым, мине каптырырга теләгән ул, сасы көзән. Ау-

лак әрәмәдә каршыма ук килеп чыкты. «Әгәр шушы хуш исле печәндә кочагыңа алсаң, берни булмас», — ди. Кочагыма да алыр идем, жәл түгел, чибәр ул сатана, тәне шома, тәмәкенең дә хуш ислесен тарта, куллары мамык кебек йомшак, мәгәр бирелмәдем, күпме хатын-кызның күз яшен түктергәнен уйладым да күкрәгенә төрттем! Кыяфәт күркәнеке булса да, көче этәчнеке икән! Чалкан барып төште. Бүртендә, ә мин шарык-шарык көләм. «Печән урлап кайтканда тоткан колхоз рәисен кыйнаган өчен» җиде ел ямадылар».

Өченче чиләк миндә, су күтәреп, кайтыр юлга чыктылар. Юл янәшә иде, сүз өзелмәде. «Хәсрәтем юк дисең, алайса?» Нәҗип эндәшмәде. «Алайса шул: әллә кем булгансың икән, начальник! Әйтәм җирле әнкәң очраган саен мактана иде. «Һай минем Нәҗибем, вай минем Нәҗибем! Мәскәүдә, Брежнев патша янында укый. Чакырып алганнар. Мавзолей янындагы йортта яши, ди, бер үзенә болын хәтле бүлмә биргәннәр. Уртада трактор дәүмәлеге өстәл. Өстәлендә өч төймә. Берсенә баса — чәй китерәләр. Шикәрлене! Икенчесенә баса, пумушнигы атылып керә: «Ни боерасыз да ни кушасыз?!» Өченчесенә баса, машинасы килеп җитә...»

Гөлгенәне тыңлау кызык иде, ул бер халәттән икенчесенә җиңел сикерә, әле карчык булып сокланып сөйли дә, үз фикерен ялгап, Нәҗиптән мыскыллап көлә дә иде сыман. «Заводка директор булып кайта икән. Ә заводында халык!.. Кара болыт белән бер икән! Әнкәң шулай сөйләгән иде, дөрес сөйләгәнме?»

Нәҗип сүз әйтмәде, әче көлемсерәп Гөлгенәгә карады.

«Әйдә, яшәп кал, без беткән кешеләр. Дөнья йөзендә орлыкка һәйбәтләр калсын. Син әйбәт кеше. Әнә минем иптәш хатын. Заводта эшләгән, цех парторгыннан биш корсак төшергән. «Урлады!» — дип өтерменгә тыгып котылган теге кара йөз. Менә безне «эчәләр» дип район гәҗитенә яздылар. Гәҗитәдән пирчәткә бармакчасы хәтле генә апа килгән иде. Әй чәтерди бу, әй шыбырдый, — коелмый гына. Ну, мәйтәм, лагерьда очраган булсаң, сидереп сидегеңә утырта идем мин сине! Күрер иде гадел яшәүнең нәрсә икәнен! Әчмәсәк, без нишләргә тиеш! Мине утырткан рәискә кол булыргамы? Колхозчы кол лабаса ул! Бер сүз әйтә алмый ул, бичара. Ә мин кол түгел, тотсын кәҗәнең койрык астын. Тотсын да бөти итеп таксын. Мин кайтыр дип көтмәгән икән, ә мин, ныграк булыр өчен, иптәш кызны да ияртеп кайттым. Яртыны кыстырып кергән теге, йөрмә, дидем, икене алып кер! Икене тыгып килгән. «Кичер», — ди.

Гөлгенә мәзәк кенә көлеп куйды, чиләге чайкалып суы түгелде. Нәҗип капка төбеннән китәргә ашыкмаган Гөлгенәгә карап: «Сау бул!» — дигән сүзне әйтте дә кабаланып мунчага төшеп китте. Гөлгенәнең әрсезлегеннән котылдым дисә дә, тагын ике-өч тапкыр очраштылар алар. Нәҗип юл дәвамында бер-ике сүз әйтеп туктаса, Гөлгенә, сагынган кешесен көтеп алган гашыйк шикелле, туктаусыз сайрады.

«Тутаң лагерьда ялгыз булган дип беләсеңме? Төрмәдә дә хокукы юк чибәр хатынның! Аны теләсә кем тотып ала! Конвой ялгыз калдырамы чибәр хатынны? Мин күргәнне эт тә күрмәс! Югарыдан берәр начальство килдеме — мине дәшеп кертәләр. Генерал белән кунган бар! Шампан белән аягымны юдырттым... Хак, алдасам күзем чәчрәп чыксын! Җәһәннәм кисәвенә әйләнгән инде без. Бер мин генәме? Крестьянның яшәр чуты калмаган, әллә кая китеп олага идем, шул председательнең күзенә кадалган кылчык булыйм дип кенә монда ятам. Мине күргән саен ыштаны юешләнә тегенең! Ух, күзен чукып чыгарыр идем!..»

«Нигә боларны миңа сөйлисең, Гөлгенә?» «Сиңа сөйләмичә кемгә сөйлим? Син бәхетле җан, директор, янында хатының, балаларың... Әй, Нәҗип, ал син безне эшкә! Әгәр эш әз генә бәхет китерә икән, мин җир җимерергә әзер! Иптәш кызым минем сүздән чыкмый...

Нәҗип суын түгә-түгә мунчага ашыкты. Йә, ни әйтсен дә нинди киңәш бирсен инде бу бичара җанга?! Энисе дә инде Наилә язган хатны түкми-чәчми, нык кына купайтып авыл арасында сөйләп йөргән икән!..

Кырык ямаулы җиз тас, баусыз чиләкләр, агач чапчаклар су белән тулгач, Нәҗип мунча мичен кабызып җибәрде...

## 19

Юка көрән чалбар, зәңгәр җирлеккә ак буй-буй төшкән сатин күлмәк киеп, шома таягын арык тез араларына кыстырып, әтисе өстәл янында утыра. Наилә балаларның күлмәк-чалбарларын юып көнгә элгән, малайларны уяткан, юындырган. Искәндәр белән Рөстәм, әбиләренең йон кабасын ат итеп, идән уртасында чабыш оештырганнар. «Булышырга чыга идем, миннән башка да ярдәмчеләр табылган икән сиңа!» — дип Наилә хәтәр генә кадап алды. Ул Гөлгенәнең арыбире иренә тагылып су ташыганын күзәткәләгән икән. «Су ташыр хәлем юк иде шул, бөтен буыннарым сызлый, юл изгән», — диде Наилә, кайнанасына карап. Мәрьямбикәгә шул гына кирәк тә, аның үз гомерендә бер булса да килененә зарланып, бушанасы килә: «И килен, шуны әйтәсеңме авызыңны кыеш-мыеш китереп, көн буе мыштырдап инә буе җир китәм, ә кичкә гәүдәм ындыр табагында чабагач астында калган көлтәгә әйләнә, сызламаган буын, шыгырдамаган сөяк юк. Ах-ух килеп урынга аугач, исәпләп карыйсың: эшләгән эшең бармак башы шае булган!»

Наилә, тәртибен белеп, һәр нәрсәне зур итеп күрсәтеп, күчтәнәчләрен чыгарды. Искерә төшсә дә, балкып торган ак калач янына алка-алка итеп колбаса турады. Мәк сибелгән вак клиндерләрне ашъяулыкка аудардылар. Мәк хәлвәсе белән аллы-кызыллы манпаси ясмыкларын күргәч, карчыкның дымлы күзләре яшьләнде: ничә бала үстереп, аның шушы кадәр күчтәнәчне күргәне юк иде. Ул дулкынланып, уфылдап кече якка керде дә чүпләм башлы тастымал белән төрелгән агач табактагы бәрәңгене алып чыкты. «Бәрәңгебез вак, кәҗә белән сарыкларга дип, өй базында тотканы гына калды. Эресен көзен тышкы базга күмгән идек, язын ачып җибәрсәк, җылашып үлә яздык, базы белән тоташтан кисәүләнгән. Тазартырга көчебез җитмәс, дип базы-ние белән күмдек. Күзгә сай гына итеп булса да баз казымыйча ярамас. Кайтасыгызны белмәдек шул, сыек май алган булыр идек. Сыек май сибеп тә җибәрсәң, вак булса да, бәрәңгебез тәмле, ярмаланып тора. Йә, кунаклар, житешегез. Хәзинәдә бары белән».

Табакка иң әүвәл малайларның кулы кереп китте, алар ак күмәчне тиз-тиз чәйнәп, арага бәрәңге кыстыра башладылар. Йосыф карт та җанлангандай булды, ул пычак очына бер алка колбасаны эләктереп алды да томанлы күзе алдына китереп озак кына әйләндерде, шуннан соң гына капты, чәйнәп йоткач: «Колбаса да бар икән әле дөньяда, и агай!» — дип иренен чәпелдәтте.

Борынгыдан килгән гадәт буенча, бу йортта аш-су янында сөйләшү юк иде, кечеләр үз бурычларын сабый чактан ук үзләштергәннәр, олылар дәшмәсәләр дә, бу кагыйдәләрнең үтәлешен бөркет булып күзәтәләр, түргә әллә нинди кадерле кунак утырса да, кыстамыйча сыйлыйлар, кысташмыйча тамак туйдыралар иде. Бүген иртәнге чәй тиз тәмамланды, самавыр суынырга да өлгермәде. Нәҗип яшерен өмет белән кече якка карашын ташласа да, чаршау-пәрдә селкенмәде, чәй янына май-шикәр чыкмады, күпереп торган авыл ипие дә, корт та, төче катлама да, бүтән төрле сагынылган сыйлар да юк иде. Тузаны очып торган такта чәйне әнисе саран гына, бал калагы очына эләктереп кенә салды. Чәйне бик зурлап, берәр манпаси кабып, мактый-

мактый эчтеләр. Мактау да бу йортның гадәте түгел иде...

«Мунчаны карап кайтыйм әле», — дигән сылтау белән Нәҗип мунчага китте. Мәрьямбикә оныкларына чыпчык оясы күрсәтергә булды. Наилә өйдә бер ялгызы калды. Йосыф карт мече як сәкесенә җәелгән урынына кереп ятты.

Никадәрле арган булса да, Наиләнең йокысы сак иде. Ул иренең торып чыгып киткәнен дә, кайнанасының озак күрешми торган улы белән кыска-кыска сөйләшкәнен дә аермачык ишетеп ятты. Торып чыгасы, иренә күренәсе килмәде. Монда бөтен нәрсә, тирә-як, мөнәсәбәтләр үзенчә иде. Ул моны сизде. Юл газаплары исенә төшкән саен аның җаны икегә бүленеп өзгәләнде. Гомерлек юлдашына, ике улының әтисенә, туган төягенә кайтып барганда, чарасыз, ярдәмсез калып интеккәндә ул ничаклы авыр сүз яудырды. Гафу ителерлек хәлме бу? Йә, тормышны бүгенгәчә көйли алмаганнар икән, монда бер Нәҗип кенә гаепләме?.. Әгәр Мәскәүгә укырга китмәгән булса... Анда барып артыгын көчәнмәсә... Күтәрә алмастайны югары чөяргә тырышмаса... Гади генә, кешечә генә яшәп китәчәкләр иде бит. Эшкә ашмас хыяллар үтәр иде. Әле менә күз алдында адәм уллары чамасыз кыен шартларда яшәп яталар. Кичә мунчада кайнанасы Йосыф карт турында аңа бик күп нәрсәләр сөйләде. Асылда сүз әнә шул карт, Нәҗипнең әтисе хакында гына барды да бугай...

«Басымчак иттеләр Йосыфымны, яз-җәй генә түгел, көзен-кышын да ял күрмәде... Калхузның иң кара, иң пычрак эшенә җиктеләр. Сарык карады, дуңгыз көтте, ат сарайларыннан тирес түкте, урман кисеп кабык төшерде, кабыкны күлдә җебетеп, мунчала каезлады. Киндер басасын күлгә чумдырды, аны чыгарды. Баса көлтәсен күлдән чыгарудан да авыры юк, үзе авыр, үзе кара көзгә кала, үзе сасы... Мунчада өч чабынгач кына тәннән исе китә. Барды Йосыфым, ың-шың чыгармады, эшләгәнгә бер тиен түләмәсәләр дә, бастырып сүз әйтә алмады. Калхузның колы булды инде, колы. Ташлы-комлы авыш басуларны ул сөрде, күмер яндырды, таш яндырып таш катыгы ясады, кәнсәләр бәдрәфен дә аннан тазарттырдылар. Гаилә ишле иде, кая барсын? Фермаларны таш катыгына тончыга-тончыга ул агартты... Мине дә җиктеләр, ире басымчак катыннарга да калхузда пачут юк, камыт кигертәләр дә куалар... Бозауларның эче китә башласа, «Мәрьямбикә, бар!», атлар күтәрәмгә калса, «Мәрьямбикә, йөгер!» «Кәбестәгә ак корт төшкән, яшелчәдә куна-төнә ят!» Балалар үсте, мәктәпкә йөрделәр, без малайларны да, кызларны да күрмәдек. Иртән ач карынга чыгып чаптык, кичен, ашарлык хәл дә калмаганда, кайтып егылдык. Мәгәр сүзебез бер иде: «Балалар, без күргәнне күрмәгез, коты калмаган бу яклардан чыгып качыгыз», — дип тәрбияләдек. Калада анда бүтәнчәдер, фатирыгыз юк икән — булыр. Ходайдан күркәм сабырлык һәм татулык сорагыз». Бу сүзләр Наиләнең күңеленә кереп оялады...

Элек тә сантый түгел иде Наилә, бер төн эчендә ул илдәге хаксызлыкны, гаделсезлекне, халыкларның аслы-өсле сыйныфларга нык аерылганын күрде. Бер якта балга манчылып мунча керүче Гөлнаралар. Әле хатыннары шулай азына, ирләре ниләр кыланмый икән аларның?! Аерым кунакханәләрдә, ял йортларында ярты гомерләрен үткәрүче лауреатлар, депутатлар, пленум әгъзалары ниләр күрми дә, ниләр күрсәтми икән?! Ә монда гомере буе буразнадан чыкмаган, тормышның иң авыр эшләрен үтәгән карт хәзер беркемгә дә кирәк түгел. «Кибеткә сирәк кенә тәм-том, сыек май кайта, безне бар дип тә белмиләр, төрткәләп чыгаралар. Ил белән азынды халык, ил белән!»

Кайчандыр тормыш терәге булган, илне ашаткан, киендергән кеше хәзер әнә мече як сәкесендә ара-тирә ыңгырашып, тавыш биреп ята. Төшендә һаман котырган төлке белән сугышамы? Әллә төшендә гайрәтләнеп, үзен изгән председательләргә әр сүзе әйтә аламы?

Кайчандыр алар да кешеләр булганнар ич, хәзер кисеп ташланган тырнакка да тормыйлар. Ник без үзебездән түбәннәрдән гыйбрәт алмыйбыз икән дә гел-гел югарыга үрләгәннәргә карыйбыз икән?! Югарыга карарга аны Нәҗибә өйрәтте. Ә аны югарыга карарга тормыш мәҗбүр итмәгәнмени? Ни өчен аның авылга, ата-анасы катына кайтмавының сәбәбе шушымы әллә? Нужадагы әтисенә ярдәм итә алмавы аның горурлыгын басып торганмы? Алай булуы да ихтимал. «Без барыбыз да заманча бозылган буын. Без үзебездән алда килгән, сугышны кичергән, бер чакта да тамагы туймаган, өсте юньле кием күрмәгән буынны кадерләмәдек. Киресенчә, алар яши белми, дип алардан көлдек, мыскылладык. Ул Йосыф картның боек кыяфәтен, тонык-яшьле күзләрен һәм аның, таш кубарып, котырган төлкегә каршы чыккан мизгелләрен күз алдына китерде... Күңеле тулды Наиләнең, күңеле нечкәрде, ул үзен, ирен, балаларын, кайнатасы белән кайнанасын, төрмәдә кешелеген җуйган Гөлгенәне, аның адашкан юлдашы якут кызын, тагын бик күпләрне жәлләп, әрнеп, кайнар яшьләренә чыланды.

Нәҗип мунча мичен томалап, салкын-кайнар суларны әвеш-тәвеш китереп көйләп чыккач, күңеле борлыгып, инеш буйларын тагын бер урады. Эш юктан эш тапкан булып, тыкрык башында йөрде. Наилә янына кайтып керәсе килми иде аның.

Шактый торып, эч пошуларын баса алмыйча ишегалдына кайтып керсә, әнисе өч литрлы бидон тотып каударланып йөренә. «И, улым! — диде ул.— Әле ярый кайттың. Кибеткә сыек май кайткан, әле сата башламаганнар. Фәрәхетдин хатыны: «Картларга бирмиләр!» — дип әйтеп үтте. Улым, бар, иренмә, төшеп кара. Кунакны, олы кешене кире бормас Зәйнәп. Күпме бирсә дә, ал!» Шулай әйтеп, Мәрьямбикә улының учына кулдан-кулга йөреп, мең хәсрәткә шаһит булып, изелеп, таушалып беткән өчлек белән берлекне китереп салды. Нәҗип, күзен түбән төшереп: «Барам, әни, барам!» — дип күнде. Искәндәр әтисенә тагылырга теләсә дә: «Өс-башың ару түгел, тегеләре кипмәгән, урам бик пычрак!» — дип, аны ияртмәделәр. Әбисе малайларга чормадагы күгәрчен оясын күрсәтергә булды, болдыр баскычына чыгып өлгергән Наилә иренең җилкәсен генә күреп калды. Эндәшми китүенә ачуы килмәде, ул Нәҗипнең җанында ниләр кайнаганлыгын аңлады.

Югары очтан Түбән очка лай изеп, Нәҗип барып кергәндә кибет эче кеше белән туп-тулы иде. «Картларга бирмим дигән... монда яшь кеше бармыни?» Аның беренче уе шул булды. Гел хатын-кыздан гына торган чуар төркемгә ул уртак сәлам бирде. Алдарак, кибетчегә якынрак тартылган иң тыгыз төркем аның сәламен ишетмәде. Ишек катындагы тарау хатыннар: «Бу нинди артык тамак тагын?» — дип, Нәҗип кулындагы өч литрлы бидонга карадылар. Мөнир хатыны Хәлисә дә шунда икән, ул, Нәҗипне таныса да, бүтәннәр аның сәламенә игътибар итмәгәч, сәламне алмады. Җыелганнар арасында чыш-чыш китте, хатыннар колактан-колакка Нәҗипнең кем булуын ирештерделәр. Картаеп чуттан чыккан Йосыф белән Мәрьямбикә баласына «Коммунизм юлы» колхозының кысан кибетендә чиратта ярсыган хатын-кызларының исе китмәде. Кемдер: «Һе, алай икән!» — дип куйды, кемдер: «Каладан кайтып, май теләнергә төшкән!» — дип җибәрде, бөтен күзләр сагышлы өмет белән кибетчегә төбәлгән иде. Ялыну-ялвару, инәлү, табыну, ярарга тырышу, тәлинкә тоту, ясалма төчелек һәм түбәнлек бар иде бу арган күз карашларында. Һәр күз: «Зәйнәп миңа мәрхәмәтлерәк караса ярар иде!» — дип ялвара, ягымлырак, гөнаһсызрак күренергә тырыша иде. «Сата башла инде, Зәйнәп!» — диде хатыннарның чаярагы. «Ходайдан фәрман көтмисеңдер ласа?» «Тинтерәтмә инде», — диеште бүтәннәр. Каләмен колак артына кыстырган, мул майланган коймак төсле елтыр, бүлтәеп торган битенә сыткы сибелгән Зәйнәп, җеп иреннәрен кысып чут салган жи-

реннән күтәрелеп карады да: «Сыер савучылар кайтмыйча сатмыйм!» — дип кычкырды. Батыраеп алгарак чыккан хатыннар бу тавышка шунда ук сеңделәр, тавышлар арттагы рәтләрдән, куелыктан гына чыккалады: «Күпме басып торабыз инде? Без эшләмибезме! Аяклар авырта, чыдайт нельзя!» — дип басынкы гына бер гөрләп алдылар да, Зәйнәп челәеп, кибеттәгеләрне берәм-берәм аралый башлауга, шым булдылар. Ул арада, кибетнең арт ишегеннән кемнеңдер чуар шәлле баш түбәсе күренде, күз алдында түш киереп торган Зәйнәп «ә» дигәнче юк булды. Ул югында хатыннар кыюланды: «Булса да булыр икән мөртәт!» — диде зарланып берәү. «Шушы кыланчыкны башыбызга бәла итеп китерделәр бит!» — дип кушылды аңа бүтәннәр. Зәйнәп ак камыр кебек кыска буынлы, юантык кулларын шактый каралган чүпрәккә сөртә-сөртә килеп чыккач, күз карашлары җылынды, тавышлар тынды. Үтенү, үгетләү сүзләре шактый көткәч кенә яңгырады: «Сата башла инде, апаем,— диде өлкән яшьтәге, өстендәге ирләр пиджаген бау белән кысып буган озынча, арык хатын, — балам чирле!»

Нәҗип кибеткә кайтып җиткән сыек майның сатылмау сәбәбен аңламады, үзенең юк эш артыннан йөрүен чамалап, ул ишек катынарак тартылды. Каранды: кибет киштәләренең яртысын төрле-төрле эчемлек шешәләре биләгән иде. Аракының ниндие генә юк монда, коньяклар бар! Бик кыйбатлылары бар! Кайтаралар икән, кемдер сатып ала, эчә дигән сүз. Кинәт көн ачылып киттеме, рәшәткәле тар тәрәзәгә яктылык бөркелде, киштәләрнең шешәләр тезелгән яртысы нурланып балкып, икенче яртысы фәкыйрьлеге, өметсез ярлылыгы белән күзне кисте. Кәгазьләре күгәреп беткән тоз каплары, шырпы, ике-өч балта сабы, ята-ята ала-кола тапланган радиоалгычлар... Алар артында тышлыклары дымнан кабарган китаплар күренде. Иң өстә «Микрохирургия» дәреслеге ята... Ул арада шым гына арт ишек ачылды, Зәйнәп йомылып юк булды, тынчу кибетне ризасызлык авазлары күмде. Наразыйлыкны Зәйнәп тавышы каплады: «Сез! Әллә бригадир хатынын да чиратта тотар идегезме, оятсызлар!»

Тавышлар басылды, киресенчә, мактау, хуплау сүзләре ишетелгәләде: «Ә, ул икән! Алсын, алсын! Аңа ярый! Төс!» — диештеләр хатыннар. Кеше һаман өстәлә торды, төркем тыгызланды, инде Нәҗип уртада кысылып калды. Яктылык арткач, ул бер нәрсәгә — хатыннарның тешләре юклыкка игътибар итте. Күпчелекнең теше сынып, коелып беткән, теш казналары суланып, ирекнәре бөрешеп бөтенләй югалган, яңаклар суырылып эчкә кергән, сөйләшкәндә авазлар йотылып, имгәнеп чыга... «Ни булды сезгә, авылдашлар?» — дип чак сорамады ул. Һава кызды, хатыннарның да температурасы арта бара иде, кызган халыкка ялгыш бер очкын төшсә дә, әллә ни булуы ихтимал, дәшмәвең алтын.

Беркем аны аралап эндәшмәде, сорашмады, гомумән, монда гадәттәге сәлам алышулар, кочаклашып күрешүләр, сөенешеп хәл-әхвәл белешүләр, ара-тирә көлеп куюлар беткән икән. Сытык чырай, җимерелгән кашлар, таушалган кием-салымнар, өметсезлек чокырына тирәнгә баткан күзләр. Кергән бер кеше артка баса да, кәҗә имчәге хәтле түшен бүтәннәрнең очлаеп торган калак сөякләренә терәп, Зәйнәпкә карап тора башлый. «Читлеккә ябылган җәнлекләр кебек»,— дип уйланды Нәҗип үз алдына. Арт ишек сирәк-мирәк ачыла, кайчагында баш күренә, ара-тирә аннан кул гына изиләр. Зәйнәп терсәкләрен җитез йөртеп югалып тора. Җыелганнар: «Инженер хатыны килгән», «Бухгалтер алып китте», «Завхоз кызы күршеләренә дә алган»,— дигән соңгы хәбәрләрне тыңлап, ләкин берсенә дә ачык мөнәсәбәт белдермичә, аякны аякка алмаштырып басып торалар. Ниһаять, Нәҗипнең түземе бетте, һавасызлыктан йөрәге, башы авырта

башлады. Ул югарыдан, хатыннар башы өстеннән ирләрчә нык итеп: «Сата башлыйсызмы сез, юкмы?» — дип кычкырды. Зәйнәп дәшмәде. Нәҗип соравын кабатлады, тавышы тагын да көрәеп, усалланып чыкты. Бүтәннәр кысылышып юл сапты. Нәҗип Зәйнәпне ачыграк күрерлек итеп алгарак үтте. Зәйнәп аны танымый, ул чит авылдан китертелгән сатучы иде. «Син! — диде ул бәбәген Нәҗипкә терәп бетереп, — кычкырма! Май авыл хезмәт ияләренә сатыла. Идарәнең карары бар. Мин аны уза алмыйм». Мөнир хатыны Халисә телгә килде: «Ул Йосыф абзый малае ич!» — «Җәллисеңме?» — диде Зәйнәп. «Җәллим»,— диде Халисә, аны-моны уйламыйча. «Җәлләсәң кочаклап ят, минем эшкә тылкышма!» Әле генә Зәйнәпне сүгеп, каһәрләп торган хатыннар аның ягына күчеп, хихылдарга, Халисәне үртәргә тотындылар, бичара хатын чиратын ташлап чыгып ук китте. Нәҗип телен тешләде. Арт ишек тагын ике тапкыр ачылып-ябылды, ниһаять, төрле зурлыктагы бидоннар, шешәләр, пыяла банкалар тотып, биш-алты хатын килеп керде. Җыелганнар атынып, дулкынланып алды, соңгы кергәннәр иртәнге савымны тәмамлап кайтучылар иде. Юл ярып аларны алга үткәрделәр, Нәҗип тагын артта калды. Кергән хатыннардан борынны ярып силос, авырсы сенаж исе килә, сырма өстеннән кигән кап-кара халатларына коймак-коймак сыер тизәге, салам-солам һәм бүтән чүп кисәкләре ябышкан иде.

Сыек майлы авыр бидонны Зәйнәп сыңар кулы белән генә очыртып чыгарды да озын саплы чүмеченә тотынды. Күзләр шул чүмечкә төбәлделәр. Ул сыер савучыларга май тутырды, үзе, күзен шакмакландырып һаман Нәҗипне күзәтте. «Күрсәтәм әле мин сиңа! Май түгел, бүтән нәрсәңне тотарсың!»

Сыер савучыларның соңгысы, иң иске, таланган, җиң очлары чачакланган халат кигәне, озак мыштырдады. Ул озаклап Зәйнәпнең колагына нидер пышылдады, сатучының авызы ерылды. Ул, хатынның култык астыннан иске букча алып, аңа бер-бер артлы өч шешә аракы шудырды. Нәҗип яныннан үткәндә бу хатынның авызыннан көйгән самогон исе бөркелде. Җыелганнар аны да якладылар: «Аларгә ярый! Төс! Эчмәсәң, фермада ярты елда кәкрәеп катарсың!»

Озын саплы «алдыр чүмеч» флягага чумып югала да чупырдап килеп чыга, өлгер Зәйнәп бер тамчысын әрәм итми, читкә тамызмый, чүмеч күз ачып йомганчы бушый. Сәгать ярым басып торгач, Нәҗипнең дә чираты җитте. Шактый җылынган (чакыручы юкта да ике тапкыр арт ишектән чыгып керде!) Зәйнәп чыгынкы маңгаен сарган матур чәчләрен кул аркасы белән артка сыпырды да Нәҗипнең бидонын кире этәреп: «Документың бармы?» — дип сорады. «Нинди документ?» «Шушы авыл гражданины булуың турында». «Мин Казанда яшим». «Яшәгән җиреңдә аша да инде син, абзыкаем. Авыллар өлешенә кермә. Хезмәт ияләренә, совет гражданнарына болай да май җитми. Син анда балда-майда йөзәсең диләр... Имеш, бер үзең бер кантурда баш булып утырасың икән. Начальник анда син. Ә монда мин начальник. Белмәсәң, белеп кит, яме».

Сүз башында Нәҗипкә якын теләктәшлек белдереп торган хатыннар бер авыздан Зәйнәпне якларга, алай гына түгел: «Хак әйтәсең!», «Ай, безнең Зәйнәп туры сүзле дә!» — дип мактарга тотындылар. Эш кая барып җитәр иде, ишек төбеннән ачулы бер тавыш яңгырады: «А ну, сука!» Хатыннар шым гына тавышка борылдылар. Зәйнәпнең кырган кашлары дерелдәде. Ишек катына тәмәке суырып Гөлгенә белән аның ахирәте кереп басканнар иде. «Син, уйнашчы!» — Гөлгенә, терсәге белән чиратны нык ерып, Зәйнәп каршысына килеп басты, ике кулы белән прилавкага таянды. «Син, тишек иләк!» Зәйнәп авызын бәлшәйтеп көлде, аңа ияреп бүтәннәр дә хихылдады. «Кил, кил, Гөлгенә аппагым, сиңа чиратсыз да бирәм», — диде Зәйнәп юхаланып. «Син миңа бирмә, аңа бир! Предсе-

дательгә бирәсең, парторгка бирәсең, аңа да бир!» Хатыннар Гөлгенәнең кай якка суктырганын чамалап, почмакларга сеңделәр: ай-һай, тел! Парторгка гаеп ташлый... Председательгә кизәнә! Яшәтмәсләр бу тиле башны! Тфү, тфү, бәласе йокмасын! Кайберәүләр май аласыларын да онытып, кибеттән чыгып ук шылды. «Анда иденме, нигә Гөлгенәнең авызын томаламадың?» — дип идарәгә чакырып арт сабагыңны укытырлар. Күрмәвең — көмеш, ишетмәвең — алтын!

Зәйнәп бушлык уртасында бидонын кочаклаган Нәҗипкә эче елмайды: «Йөрисең баш бутап, абый кеше. Мин Гөлгенә кешесе дисәң, әллә кайчан бирә идем». Тынлыкта май аккан тавыш кына калды. Хатыннар инде Гөлгенәне кыстарга керештеләр: «Син дә ал, читенсенмә, күпме теләсәң дә ал!» Аракыдан бушаган ярты литрлы шешәгә күздән тутыргач, Гөлгенә акча чыгарып тормады. Нәҗипкә кыю күз кысып, артларыннан чыгарга ымлады да юк булды. Алар артыннан ишек ябылуга, Зәйнәп: «Май бетте. Таралыгыз, тарал. Әле рәискә кертеп чыгарасы бар, парторг, ревкомиссия рәисе алмаган. Ни көтәсез тагын? Күтәрегез үкчәләрегезне!» — дип, кашын-күзен җимереп чинады. Тешсез авызлардан сүз чыкмады, хатыннар иртәгә тагын Зәйнәп катына баш орып киләселәрен чамалап, тындылар, шым гына таралдылар. Югары Авыл урамында саз чапылдаганы шактый вакыт ишетелеп торды. Нәҗип үзе күргән тамашадан тәмам югалып калган иде, хатыннар артыннан чыгарга атлаганда, аны кибет эченә ыргылган икенче дулкын — ирләр ташкыны өерләп кире алып кереп китте. Ирләр бер-берсенә төртеп, киштәләрдәге шешәләрне күрсәтешеп, Зәйнәп каршысына ябырылдылар. Кибет эче күтәренке, күңелле тавышлар белән тулды. Зәйнәп сандугач булып сайрады, тургай булып канат какты, карлыгач булып очты.

Нәҗип, мөлдерәмә тулы бидонын чайпалтмаска тырышып, аяк астын күзе белән капшый-капшый, шактый озак кайтты, хәзинәсен исән-аман әнисе кулына тапшыргач, бичара карчык түзмәде, бөгелеп төште. «Менә бит,— дип такмаклады ул.— Ир-ат төшкәч тутырып биргән. Мае өресез, чеп-чиста, исе лә исе! Без ни, исәпкә бар, санга юк дигәндәй, төшсәк, үртәлеп кайтып китәбез. Бирсә әйрән тутыра, аның да яртысын үзенә апкала. Әтиең теләсә ни дисен, берәр балаң янында булса, ни әйтер идең кана?!»

Авыл кешесенең шул инде: шатлыгын уртаклаша башласа да, авызы кара кан белән тула. Һич уйламаганда, теләгән фикерен әйтеп, күңелен бушатты Мәрьямбикә. «Нигә кумыйсыз андый кибетчене?» — дип сорады Наилә. Ире артыннан ук төшеп киткән Гөлгенәләрне ул бик җентекләп карап калган иде.

Карчык, куркып-каушап, бидонын чак аударып җибәрмәде. «Әстәгъфирулла, килен, тәүбә диген. Ничек телең әйләнә? Зәйнәпне рәис ияртеп килде, килүенә партиягә алдылар үзен, авыл арасында ялгыш сүз ычкындыра күрмә, берүк. Рәискә кардәш тиешлеме шунда, бүтән якынлыгы бармы, Зәйнәпне бик якын итә, диләр. Авылда бүген кибетче баш! Рәис үчегешеп, ваксынып йөрми, Зәйнәпкә карап ярты сүз генә әйтә. Парторгы да Зәйнәпне өстерә».

Яхшыга авыз ачып, соңра, искәрмәстән рәис, парторгларга тел тидерүен абайлаган карчык тәүбәгә килде, белгән догаларын ашык-пошык укый башлады.

Аның ихлас хөрмәтен, олылавын, гаҗәпле шатлыгын күргәч, кунаклар сыек майның бу йортка байтактан кермәгәнен төшенделәр.

## 20

Кунакларны көн аралаш мунча ягып, вак бәрәңге һәм каты-коты ипи белән генә үткәреп җибәрергә ярамаганын Мәрьямбикә дә, дөнья-

да ваемы калмаган Йосыф карт та бик яхшы аңлый. Ил-күз алдында хурлык: кайтканнарына кайчан, йорттан таба исе чыкканы юк, коймак, бәлеш пешми. Гөлгенә белән аның ахирәте генә түгел, Фәрәхетдиннең паралич суккан чалыш карчыгы да, чапырыштагы Минәч карт белән аның шикәр авырулы Бәдриҗамалы да Йосыф ихатасыннан, олы кунак төшкән йорттан, тәмле исләр таралганны көтәләр. Чөнки бәлеш-мазар пешергәндә Мәрьямбикә карчыкның ятим-ялпыны, күрше-каршыны өлешсез калдырганы юк иде. Ит пешмәсә — бит пешә. Нәҗип белән Наилә, балаларны ияртеп, кипкән Көмешкүлне тамаша итәргә чыгып киткән арада, Йосыф карт, дуңгызлар янынннан кайтып килүче, шактый кәефләнгән Сөнгать арбасына утырып, идарәгә кадәр төште. Язгы чәчү барган көннәрдә колхоз, кысыр сыер йә булмаса кышлау үгез суеп, ир-ат механизаторларны җыеп, шәп кенә мәҗлес үткәреп ала торган иде. Быел да шул тантана якынлашуы Йосыфның мүкләнгән колагына керде. Ул рәис Ихлас янына барырга тәвәккәлләде. Кая барасын карчыгына әйтеп тормады. Гәрчә картының күңелендә ниндиерәк иләс-миләс уйлар кайнаганын ул болай да сизә иде.

Ихлас идарәдә булып чыкты, көттереп кенә ул картны үз янына дәште, сорау белән аңа күтәрелеп карады. «Ихлас туган, синең хозурыңа ифрат зур гозер белән төштем әле». «Йә, шуннан?» — диде коры гына Ихлас. «Тамак ягы начарайды. Быелтыр, беләсең, хәл юк дип тормадык, икебез дә эшкә чыккаладык. Бәрәңгебезне тышкы базга салырга соңардык, ул лапас астында көшелдә, суыкта ятты. Шуңа язга кисәүләнде дә...» «Йә, йә»,— дип ашыктырды аны Ихлас. Йосыф сүз эзләп, фикер җыеп торды. Кыска һәм үтемле итеп әйтәсе килде аның! Ишетсен әле Ихлас та Йосыфның тавышын! Тик... гозерне, ялынычны көчле, саллы сүзләр белән ничек оештырып әйтә аласың? Хәерчедән бер чакта да тук тавыш чыкмый шул... «Эз-мәз он язып бирмәссеңме диган идем. Аннары ит... Хет ике-өч кило! Тана чалгансыз икән дип ишеттем». Ихлас, җавап биргән чакта, тоткарланып, уйлап тормый иде. «Ит — механизаторларга. Буленеп куелган. Бүтәннәргә граммын да бирмибез. Сиңа бирсәк — ярты авыл төшәчәк. Он... кибеткә ипи кайтып тора, макарон да күренгәли. Син пенсионер, сине колхоз түгел, хөкүмәт кайгыртырга тиеш». «Бирмисең, алайса?» «Үземнән булса, рәхәтләнеп бирер идем, үзем мал асрамыйм, Йосыф агай. Түзәргә туры килә. Менә тормыш яхшырып, колхоз тагын да ныгып китсә, карарбыз». Йосыф кыза төште: «Күпме көтәргә була? — диде ул әрнеп. — Миңа бүген кирәк. Бүген!» Ихлас аңа гаҗәпләнеп карады: акылыннан шашканмы әллә бу тишек галуш? Даулап төшкәнме? «Юк!» — диде Ихлас өзеп һәм җитәкләп картны ишеккә кадәр китерде...

Нәҗипләр Көмешкүл ягасыннан сүзгә саранланып кайттылар. Малайлар гына: «Әби, без кыр үрдәге күрдек!» — дип шыбырдаштылар. Картының Түбән очтан, идарә ягыннан үлек төсенә кереп кайтуын Мәрьямбикә аруга юрамады. Йосыф Казан кунакларына ачылмады, кайтты да урынына ауды, улы хөрмәтенә генә сорашып төшкәнен ул Ихласка әйтүне кирәк санамады.

Мәрьямбикә «Йосыф бик нык чирли башласа» дип, күз карасыдай саклап тоткан, бала йодырыгы хәтле сары мае бар иде, шуны чыгарды. Бер көн бәрәңге дурычмагы пешерде — майлап ашадылар. Икенче көнне кыстыбый бөкте — аны ашарга да җитте сары май. Карты белән чышын-пышын киңәшкәннән соң, алар бердәнбер бәрәннәре Бүркәне суярга карар бирделәр. Дөрес, әле ел иртә, май башы гына, бәрән арык, ите ике учка сыеп бетәчәк, көтүдә йөртеп, йортта ашлы сулар белән сыйлаштырсаң, көзгә аннан илле кадак ит чыгачак! Ләкин... йорт тулы кунак! Үзләре ничек тә җан асрарлар, ничә елга бер күрешкән балаларына яңа суйган ит тә ашатмагач, дөньясы корысын!

Көтелмәгән яктан тагын җайсызлык килеп чыкты.

Көмешкүл кипкән. Олы суда балык заты калмаган, инеш ярларына, болыннарга чыгарлык түгел. Велосипедны, аяк арасында уралмасын дип, чоланга ук чыгарып ташладылар. Нәҗип-Наилә балалары белән күбрәк өй арасында, сарык-кәҗә тирәсендә уралдылар. Ничарадан бичара, сугыш коралларын шәбәйтергә тиешле Нәҗип, малтуар белгече булып китте. «Менә кәҗә, — диде ул, ике сырлы мөгезне тотып. — Сөт бирә, мамык. Сөте шифалы, файдалы». Кәҗә белән дуслашмады малайлар: әтисе ычкындырып җибәрүгә, ул Искәндәрне сөзәргә килә башлады.

Сарыклар да кырагай булып чыкты, малайларга баш иеп дуслашырга теләмәделәр, тояклары белән пычрак чәчрәтеп, капкадан лапас астына кадәр чаптылар да чаптылар. «Тавык аңгыра кош,— диде әтиләре,— күкәе тәмле булса да, үзе аңгыра, кеше белән сирәк дуслаша».

Малайлар замат арасында сарык бәрәне Бүркә белән аралашып, аны яратып өлгерделәр. Бәрән ифрат акыллы иде, мәхәббәткә мәхәббәт белән җавап бирде. Малайлар чакырса килде, колак артын кашытты, ипи кыерчыгы бирсәләр, кыстатып тормады, бармакларны рәхәт кытыклый-кытыклый ризыкны кулдан алды.

Бүркәнең көтүдән калганын олы малай тиз аңлады, пес итәргә чыккан җиреннән йөгереп керде дә: «Әни, Бүркәне бикләгәннәр!»— дип кычкырып җибәрде. Бәрән дә үзенең тоткынга эләккәнен сизенеп, сузып-сузып мәәлди иде. Наилә ни диярга аптырап торганда, авыл карчыгы телгә килде: «Бүркәне суябыз, улым, аш салырбыз, пилмән бөгәрбез, бәлеш ясарбыз, сыйланырбыз!» Олы малайның күзе шар булды, керфекләре леп-леп бәргәләнде: «Ничек суясыз?» «Муенына пычак салабыз да кых итәбез. Әтиең белән бабаң суяр, сез карап торырсыз, өйрәнерсез, егет кеше сугым суярга өйрәнергә тиеш». Әбисе сүзен бетергәндә Искәндәр идәндә тәгәри-тәгәри елый иде: «Суймагыз Бүркәне, суймагыз! Кисмәгез аның муенын!» Әллә нинди дәлилләр кушып малайны үгетләсәләр дә, ярсыган малайны җайга китерә алмадылар, ул такмаклап, һаман елады, елый-елый шешенеп бетте. Абыйсының ник елаганын аңлап бетермәгән Рөстәм, балалык теләктәшлеге белән аңа ияреп акырырга тотынды. Нәҗипнең йөрәге урыныннан купты, Наилә ярсыды, ниһаять, пычакка ял, бәрәнгә гомер бирделәр.

Малайлар җиңде, гауга бетте, ә табында пилмән юк, итле шулпа бу атып пешми. Бит пешә, бит! Бит пешкәннән тамак туймый, киресенчә, эч чурлый, ашказаны кычкырып тәмле ризык сорый...

Нәҗип белән Наилә арасындагы кискенлек, йорттагы киеренке шартларда кичерәеп калды, алар сүзсез генә бер-берсен аңлап, артык сүзләр сөйләшмичә генә гафу итештеләр. Карт белән карчыкның авыр тормышы, хәерчелеге аларның зар-моңнарын онытырды, ике арадагы каршылыклар чүп-чар, су өстендәге күбек булып калдылар. «Илдә яхшы кеше калмады инде!— диде бер чакны Йосыф.— Ил белән бозылдык».

Нәҗип белән Наилә балаларга сыек май болгаткан вак бәрәңгене ашаталар да йокларга яткыралар, үзләре чолан идәнендә, толып астына кереп, колактан-колакка сөйләшәләр: «Нишлибез? Нишләргә? Кая барып бәрелергә? Яшелчә, һич югында суган кыягы өлгерер дип көтәр идең, әле җиргә җылы керми». «Җир җылына алмыйча интегә хәзер»,— диде бер мәлне Мәрьямбикә. Яши-яши бу фикернең олылыгын да аңладылар. Юл буйларында, кашлак урыннарда үлән баш төртте, тау битләре хәйран яшелләнде, әле кузгалак-кукы ише нәрсәләр күренмәде.

Җомга көнне Яңа урам очында яшәүче Камалиларның сыеры күпер чыкканда такта арасына кыстырып аягын сындырган да суйганнар, ит арттырырга чамалары бар икән, диган хәбәрне бу араларда өеннән чыгыбрак йөрергә ярата башлаган Мәрьямбикә ишетеп кайтты. Нәҗип

соңгы акчасын йомарлап шунда торып чапты. Килосы җиде сумнан! Камали көч-хәл белән йөри икән, сугыштан кырык яра, кырык ямау алып кайткан кеше, карчыгы кемне күрсә дә, үкереп елый. «Кайчан сыер малына тиенәбез дә, гарип картыма ни ашатырмын? Сөт, катык ашап кына исәнлеген иплән бара иде бит! Тәңрем, ник каргадың безне? Сыерыбыз сыер гына түгел иде, хәзинә иде!» Сатулашмады Нәҗип, җидешәр сум түләп, өч кило ит алды. Кичкә ит шулпасы пешерделәр.

Нәҗип, әдәп саклап, әнисенең киңәшләрен тотып, исән калган, сирәгәйгән күрше-каршыларга, чыбык очы агайнеләргә тиз-тиз кереп, сәлам алышып чыккалаган иде. Күңеле күтәрелмәгәч, авыл советы, колхоз идарәсе кебек урыннарга кереп, күрешеп чыгу турында уена да китермәде. Бүген, ясканып, ипине дә эре-эре кабып токмач ашарга утырганнар иде, нык итеп ишек кактылар. Ит алып кайткач чәк кенә ачылып киткән Нәҗип тиз-тиз барып ишекне этеп җибәрде, теге якта басып торучының иңенә бәрде. «Кунакны шәп каршылыйлар икән монда!» — диде кеше, юриме, чынмы иңбашларын уып. Нәҗип кызарынды: «Гафу итегез!» Мәрьямбикә очып кына ишек катына килде: «Әйдүк, әйдүк, мактап йөрисез икән, табынга рәхим итегез, хуш килдегез!» Йосыф кузгалмаса да, әнисенең очынуына карап керүченең эре балык икәнен искәрде. Мәрьямбикә, «ай билем, һай гәүдәм!» — дип өзмәс зарланган карчык, керүченең бер алдына, биш артына төшеп, бөгеләсыгыла сәламләде, шуннан соң гына кунак белән таныштырырга булды: «Рәисебез бу, көтелмәгән кадерле кунак, юрасаң да болай мач килмәс. Ихлас улым, уз түрдән!» Гаҗәп, рәис Мәрьямбикәне күрмәде дә бугай, Йосыфка да карамады, кумәк кыстаган хуҗаларга рәхмәт әйтмәде, өстәл белән урындык арасына баскан Нәҗипкә текәлде. «Минем Нәҗип иптәш янына кагылуым иде», — диде ул. Нәҗип, аңа ияреп, болдыр баскычына чыкты, алар шунда янәшә бастылар. Ихлас Нәҗипнең буй-сынын, кием-салымын, тәҗрибәле җөйче күзе белән үлчәп-сынап чыкканда, Нәҗип аны тагын бер тапкыр табынга чакырды: «Картлар рәнҗер», — диде. «Рәнҗемәсләр! Алар өйрәтелгән. Председательгә рәнҗемәскә кирәген беләләр булыр. Председательне яратырга гына ярый». «Алай да... картлар күңеле уалырга гына тора», —диде Нәҗип, тавышы йомшарып, юашланып чыкты. «Менә нәрсә, Нәҗип иптәш,— диде Ихлас кинәт кырысланып.—Юк-бар адәмнәргә кул биреп чыккансың, идарәдә күренмәдең. Ярый. Бар, син кер, тамагыңны туйдыр. Аннан туры идарәгә төш. Мин анда». «Төшәрмен», — диде Нәҗип, алдын-артын уйламыйча. Кул кысыштылар.

Нәҗипнең ашавы ашау булмады, рәискә ашыгыч ризалык бирүенә борчылды. Ихласның көтмәгәндә ишек кагуы, йомышын әйтмичә кырт борылып чыгып китүе дә, орчык булып бөтерелгән әнисенә күз салмавы да, әтисенә ләм-мим эндәшмәве дә аңа авыр тәэсир итте. Һич югында Наиләсенә сәлам бирергә кирәк иде. Кунак ич! Йомышы бар икән, әйтсен иде монда гына!

Картлар рәиснең килүенә дә, чыгып китүенә дә сөенделәр. «Табын ярлы, табын!— дип уфтанды Мәрьямбикә.— Теге шайтан суы булса, чыгармый идем аны. Иң кирәге юк! Олы кешегә бөгелмәгәннәр дә шешә каршында сыгылып төшә!» Картлар рәиснең улларын үз катына өндәвен белгәч, чиксез шатландылар, чакыруны яхшыга юрадылар. «Авыл арасында дәрәҗәң артыр! Теләсә кемне чакырмый ул безнең рәис! Аңа, улым, ярты чакрымнан бөгелеп сәлам бирәләр, анда да күп сөйләшеп тормый! Персидәтел авылда алла, районда мулла, Казанда да мәзин әле ул! Кулы әллә кайларга үрелә! Утыр дисә, утка утырасың, суга ташланасың. Теләсә, чилләдә бәке чаптыра безнең Ихлас!»

Председатель кабинетының ишеге ачык иде, ул туп-туры шунда барып керде. Ихлас ялгыз, түрдә берүзе. Баш очында калынкаш бабайның дәү рәсеме, ярты стенаны тутырып тора. Күкрәк бүлтәеп чыккан, алтын-көмешкә манылган орденнар, чәңгелдәргә әзерләнеп, сафсаф

эленгәннәр. Бая кул кысышканнар иде, бу юлы күз очлары аша сәламләштеләр. Ихлас Нәҗипнең баш өстендәге рәсем белән кызыксынуын төкәндерде: «Районда беркемдә юк мондый затлы портрет!— диде.— Художнигын Ленинградтан китерттек. Ипи калагы хәтле генә җәбрәй, рәвешен китереп койды да куйды. Шуны әйтмәкчемен, Сабит абыең кызыгып йөргән иде, бер заманны бездән биш арттырып җибәрде!» «Сез Сабит абыйны беләсезмени?» «Белмичә! Дуслар! Ул минем туган авылда председатель бит. Әйтмәделәрмени?» «Әйткәннәр дә кебек»,— диде Нәҗип томанлы гына.

Бүлмәдә бүтән мактанырлык нәрсә табылмады. Ләкин Ихлас, җитәкче булarак, замана нечкәлекләренең җелегенә төшкән зат, бүген мактанырлык нәрсә табылмаганда, Нәҗипне кулыннан тотып киләчәккә алып кереп китте. Менә киләчәктә! Менә анда күрерсез! Анда инде болай гына булмас! Алга, киләчәккә кыю карарга кирәк! Анда безне җиңүләрдән ары җиңүләр көтә! Американы куып узабызмы? Тефү! Ул безгә бер тиен тормый. Дөрес, ул бу сүзләрне әйтмәде, ләкин сүз сөрешеннән Ихласның якты киләчәккә юл тотканын аңлады. Һәм хуплады да, дип ышанды Ихлас. Хупламаска, атаклы Сабитның энесе лә ул, алма агачыннан ерак тәгәрәмәс!

«Бу авылдан китәм, китәм диебрәк йөрдем. Шаккатырырлык идарә йортын әллә кайчан балкытып куя идем. Сызымнарын Казанда эшләттем. Егерме биш меңгә төште». Ихлас почмакта посып утырган саргылт шкафны ачып, аннан кәгазь төргәк суырып чыгарды һәм сызымнарны өстәлгә җәеп таратты. «Сез аңлыйсыз! Карагыз: индивидуаль проект!»

Алар янәшә басып кәгазь өстенә иелделәр, бераздан калкындылар. «Әй,— диде Ихлас, гадәттән тыш күтәренке тавыш белән.— Син Сабит абый белән нәкъ бер буйда икәнсең!» «Буйлар сезнең белән дә бер икән!» — диде Нәҗип, аны куәтләп. «Минем белән дә!— диде Ихлас, ни өчендер мактанып.— Безнең беренчене беләсең дә беләсең инде?! «Ишеткәнем бар!» «Районда председательләрнең, парторгларның гел бер буйда булуына иреште бит! Бездә хәзер җитәкче кадрлар, Кремльне саклаучы солдатлар төсле, бөтенесе бер буйда. Кстати, беренчебез Харис Вәгыйзович шул командада хезмәт иткән!» «Бер буйда булуның ни хаҗәте бар?»— дип сорады Нәҗип гаҗәпләнеп. «Бар аның хикмәте, бар. Утыр син, утырып тыңла. Берзаман Казаннан, югары йорттан беренче килеп төшә. Иярткән үзе белән бер көтү кеше. Самолеттан агылып чыгалар болар. Кайсы юан, кайсы нәзек, арада бүтәкәләр бар, кәтәнәләр, колгалар! Ә без торабыз монда крепость стенасы кебек, гвардиннар! Бөтенебез бер буйда — метр да сиксән җиде! Обком секретарьларының күзе яна!» Ихлас күңелле мизгелне кабат исенә төшереп, рәхәтләнеп көлеп алды. «Шуннан?»— дип кызыксынды Нәҗип. «Уйлап эшләсәң һәр нәрсәдән мәгънә чыга! Безнең первый шундый. Ел авыр иде, сөт кими, ит планы тулмаган, кай яктан карасаң да, эш сөрлеккән. Первый Казаннан безнең хуҗаны сугансыз-борычсыз ашарга дип усалланып чыккан. Харап! Безнең ныклы сафны күргәч, йомшады егет, дусларча гына орышкандай да итте. Йөри-йөри дә: «Яле, гвардиннарны тез әле!»— ди. Безгә нәрсә! Команда гына булсын! Тезеләбез! Шундый бердәм рәткә тезелеп озаттык тегене! Көзен хуҗага орден! Без дә коры калмадык! Вәт».

Сызымнарга күз ташлап, идарә проекты турында өстән-өстән сөйләшкәч, Ихлас Нәҗипкә йөзен якынайтты: «Кал районда! Сине бик хәтәр заводта эшли диләр... Атом бомбалары ясыйсың икән!» Нәҗип көлгән булды: «Андый завод Казанда бармыни?»— дип сорады. «Буең шәп!— диде сокланып Ихлас.— Хуҗага күрсәтсәң, сине җибәрми дә җибәрми инде ул. Күркәм буй!»— «Гел-гел буйга аркаланып яшәргәме исәп?» Ихлас Сабитның бертуган энесеннән ирония көтмәде, сорауны чынга алды. «О-о, безнең Харис Вәгыйзовичның башы түгәрәк, маңгае текә! Яңадан яңаны уйлап таба торган хуҗа. Утыр син, утыр. Утырып

тыңла. Шулай берзаман Казаннан бик хәтәр вәкилләр иртәп тагын кунак килеп төште. Мәскәүдән, министрлыктан кешеләр бар. Район өчен дәрәҗә, почет! Бер үк вакытта чиксез җаваплылык та! Әзерләндек, дөнья купты. Мәскәүлеләрне буй белән генә алдыра алмыйсың. Ризык та күргән алар, хөрмәтен дә. Тоттык та бөтен район мәктәпләреннән пионерларны җыйдык. Аэропорттан Сабит абый колхозына кадәр юлның ике ягына нәни әләмнәр тоткан пионерларны бастырдык! Кыз белән малай алмаш-тилмәш. Көтәбез, борчылабыз, пионерлар көтә. Кыймшанмыйлар да, керфек тә какмыйлар. Аларга шулай кушылган! Боевое задание! Самолет төшәм дигәндә генә төрекмән бүреге хәтле генә болыт килде дә Әзи өстенә эленмәсенме?! Коеп яварга тотынмасынмы? Ишә генә! Балалар тора, аларга шулай кушылган! Өч мең ярым баланы җыям дисәң дә... Салкын тимәсме дигән шик-шөбһә әйтүчеләр булды булуын, совет баласына пычак булсынмы, нык ич аның нигезе! Корыч! Соңыннан яңгырга куанышып бетә алмадык. Пионерларның шәбәреп, әләмнәрен болгап, коеп яуган карлы-бозлы яңгыр астында каршылаулары казанлыларга гына түгел, мәскәүлеләргә дә ошады. «Мондый бөек патриотизмны очратканыбыз юк иде!» — диештеләр тегеләр.— «Менә шушы булыр ул чын интернационализм!» — дип мактыйлар. Ул елны уҗымнар начар кышлаган иде, басулар ала-кола, ит планы үтәлмәгән, сөт тапшыру — утырып җыларлык, дуңгыз балалары кырылган, үрдәк бибиләре үлеп беткән. Пионерлар сафы артыннан җитешсезлекләрнең берсе дә күренмәде, кунаклар безне мактап киттеләр, ә көзен — хуҗага орден! Аңа әләккәндә без буш калабызмы? Яши белергә генә кирәк. Бер нәрсә кызганыч, буйлы егетләр авылда калмый! Офицер погоннары тарта яшьләрне! Парадны карыйлар да хәрби мәктәпләргә ычкыналар! «Балалар чирләшмәдеме соң?» — дип сорады Нәҗип, Искәндәре белән Рөстәмен уйлап. «Һәй,— дип кул селкеде Ихлас.— Авыл баласына пычак булсынмы аңа?!»

Казан хәлләрен сораштырганда Нәҗипнең югары сыйныф вәкилләрен, затлы җитәкчеләрне белмәвенә гаҗәпләнеп, хәбәрдарсызлыгына исе китеп утырган Ихлас, сүз җебен үз кулына алып, Америкадагы кабахәт, канга туймас сенаторларны, конгрессменнарны, халыкны таларга яраткан Пентагонны сүгеп, чирек сәгатьлек кайнар нотык сөйләп ташлады. Кинәт башлаган сүзен капылт туктатып, Нәҗипнең иңенә кулын салды. Әңгәмә кызгач, алар диванга күчеп, янәшә утырганнар иде. «Кайтасыңмы районга? Кайт, җүләр! Мондый буй белән... Яшим дисәң — дворец салдырасың. Теләсәң, хуҗалык — алпавыт утары торгыз. Нигә үз авылыгызга кайтмаска? Ата-анаңа терәк булыр идең. Иң мөһиме — абыең, Сабит Йосыпович монда. Үзара гына әйткәндә, аны быелгы конференциядә беренче итмәкче булалар. Харис Вәгыйзовичны Казанга алалар». «Сез сөйләгән хезмәтләре өченме?» Әле Ихлас бу юлы да Сабит энесеннән, Нәҗиптән, Казанда бомбалар ясый торган завод инженерыннан ирония, этлек көтмәгән иде, кунакның шырпысы барып ук җитмәде. Ихлас үз сүзен сөрде: «Җүләр булма, уйла! Риза икәнсең, хәзер хуҗага шалтыратам да, янына алып барам». «Ә сез Сабит абый урынына бармакчымы?» — диде Нәҗип. Ихлас маңгаен җыерды: «Андый перспектива да юк түгел!» — диде.

Нәҗип өзеп сүз әйтмәде: күңелендә икеләнү корты кыймылдады. Икеләнү минуты белән арта торды. Төрле уйлар килеп-китте егет башына!

Чыннан да, шәһәрдәге мәхшәр, ыгы-зыгылар, сары йорт хәсрәте, буш кесә, кимсенүләр — һәммәсе өелеп тегендә, җәһәннәмдә калыр иде. Чиренең төп сәбәбе — эшкә ашмаган теләкләренең күплеге, өмет юлының кинәт киселүе, дип уйлый ич Фаина Марковна. Фәридун Фазлыев та шуны куәтли. Картлар авылда җ а й л а ш а алмый икән, аларның заманы, чоры узган. Алпавыт утары кебек мәһабәт сарайда яшәп, тавык бавыры белән каз боты ашый башласаң, Наиләнең дә теле тые-

лыр иде. Аңа да рәхәт күрергә бик вакыт! Ә малайлар... малайлар! Чемкара «Волга» машинасында черт-черт көнбагыш чиртеп Эзи мәктәбенә укырга йөрерләр. Укытучылар аларның кем баласы икәнен белеп игътибарларын арттырырлар... Колхоз бүгенгә артта икән. Сабит абыйсының ярдәме белән Нәҗип Йосыпович хуҗалыкны күтәрә алмасмы? Ихлас та читкә какмас! Болар районның баганалары икән ич!

Чирләп ауганнан бирле һәр нәрсәгә шик белән карарга, берәүгә дә ышанмаска күнегеп баручы Нәҗипнең шикчеллеге өскә чыкты: «Тукта, постой, татарин,— диде ул үз-үзенә.— Шушы этәм-сәтәм хуҗалыкны сиңа сылап, Ихлас Сабит абый авылына китеп барачакмы?! Шәһәр кунакларын, Мәскәү вәкилләрен ташыйлар икән, Сабит абыйсы эшне тәгәрәтеп алып бара торгандыр! Нигә миңа Сабит абый хуҗалыгын алып калмаска!? Нигә аны Ихласка бирергә?!»

Нигә ва-банк бармаска?! Ул шиген Ихластан яшермәде. «Тәҗрибәсез килеш бу авылга кайтырга кыймыйм. Сабит абый урынына дигәндә... уйлап карарга ярый!» Яшелле-күкле булды Ихлас, тамагына коры ризык торган үрдәк сыман, су эзләп, як-ягына каранды... «Син, син!— диде ул тотлыгып.— Үзеңне Сабит абыйны алыштырырлык зат дип саныйсыңмы? Син аның кем икәнен беләсеңме? Алла ич ул, пигамбәр!» «Ә сез, Ихлас иптәш,— диде юри сүзләрен сузып әйтә-әйтә Нәҗип.— алланы алыштыра алыр идегезме? Андый көчегез бар икән, нигә безнең авыл шулай тезләнгән?!

«Мәсәлән?»— дип сорады Ихлас, дерт итеп китеп. «Нигә шул бакыр бугазлы кибетчене тотасыз?» Баярак, Нәҗипнең уенын-чынын бергә бутап ычкындырган чәнечкеле сүзләрен дөрес аңлаган икән Ихлас, бу кеше, Сабитның кан кардәше, Казан заводларының берсендә хезмәт итүче инженер, Ихлас күнеккән әңгәмәдәшләрнең берсенә дә охшамаган иде. Юк-бар кешеләргә кергәләп, идарәгә төшмәвеннән үк күңеле бизгән иде аның Нәҗиптән. «Аның авызы тулы гайбәт! Бер дә юньле сүзе юк!»— дип Зәйнәп килеп шикаять кылгач, ышанып та бетмәгән иде Ихлас... Ләкин Нәҗипне күрми булдыра алмады. Беренчедән, Гөлгенә явыз кайтып төшкән чак. Ул аларның парлап урамнан су ташыганнарын да, кибет сукмагында очрашуларын да ишетеп өлгергән иде инде. Ниләр сөйләштеләр икән? Теге алап авыз авыл тормышыннан нинди гаепләр табып Нәҗипкә өйдә икән?.. Сагаерга, серен алырга, моның өчен Нәҗипкә якынаерга кирәк иде. Күр менә, яхшылыгыңның әҗерен ал, син аңа мактаулы эш тәкъдим итеп, аның дәрәҗәсен күтәреп утырасың, ә ул кулы белән тизәк изә... Ихлас алай тиз бирешә торганнардан түгел, әлегә ул монда хуҗа! «Әле синең шулай быткычланып, күзәтеп һәм донос ясап йөри торган гадәтең дә бармыни?»— дигәнен Ихлас сизми дә калды.

Нәҗип дәшмәде, ике тезенә ике кулы белән шап итеп сукты да аягына басты, идарә проекты сызымнарына күз ташлап, әче көлемсерәде, ишеккә атлады. Ихлас аны озатмады, киресенчә, китәргә дип ишеккә юнәлгән кунакны онытып, кукыраеп өстәле артына кереп урнашты, чыраена гадәттәге кырыслык, корылык чыкты. Ни беләндер Нәҗипне таптыйсы, түбәнәйтәсе килде. Башына яңа уй килде! Бусага аша атлаган Нәҗипне аның суык, битараф тавышы туктатты. «Мин анда завхозга әйткән идем, бер кило акмай, биш кило ит төшеп алыгыз». «Күпме түләргә?»— диде Нәҗип һәм ваксынуын аңлап, телен тешләде. «Нинди түләү?! Сабит абый хөрмәтенә күчтәнәч».

Беркен Сабитның әтисе, Йосыф карт ит сорап ялварып төшкәч, тупас кына борып чыгаруына Ихласның кәефе кырылып йөри иде. Тупасрак кыланды шул... Карт кайтып өйдәгеләргә сөйләгән булса? Казаннан кайткан кошлар Ихлас турындагы кара сүзне башкалага ияртеп кайтып китсәләр? Йомшарырга, Сабит алдында да яхшы атлы булып, боларның күңелен дә җебетергә кирәк иде. Ул чакта кызмыйча да булмады шул! Карттан алдарак кына Гөлгенә төшеп, түргә үк кереп уты-

рып, шук күзләрен уйнатып, ит сораган иде. Соравы сорау гына булса икән, хакы бар кеше сыман, даулап төшкән төрмә кошы! «Синнән алачакларым минем бик күп әле! Өч-дүрт кило ит биреп кенә котылырмын дип уйлама!» дип Ихласның күзен ачырмыйча тә-тә килеп утыра сасык!..

Нәҗип чыгып китте. Ихлас идарә дежурныен завхоз янына йөгертте. «Йосыфка ит... май бирсен!»— дип боерды.

Исемен атап кычкыргач, ул туктап борылды. Гөлгенә дәшә икән, кулындагы зәңгәр кыйгачын болгый-болгый арттан килә. «Син кулыңны картлар кебек артка куеп йөрисең икән!» «Бардыр инде, Гөлгенә». «Теге иблис ник чакырткан?» «Кайсы иблис?» «Беләсең ич, кыланма. Авылда әллә ничә иблис булмый». «Ник дип, гәпләшеп утырдык». «Син аның бер сүзенә дә ышанма. Сыңар сүзенә дә! Хәйлә капчыгы ул, алдар таз, көнче күбәләк, аның юньле кеше юлына тәбе куюдан башка шөгыле юк». «Колхоз ничек бара ул чакта?» «Аннан башка да бара ул. Бер кузгатып җибәргәч таудан таш та тәгәри, ава-түнә, туктар-туктамас бара». «Туктап та кала!» «Туктады дигәндә кемдер көч куеп кузгата аны!»

Гөлгенә белән иңгә-иң терәп Түбән очтан менгәнне Наиләсе күрсә, ни уйламас? Бу арада мөнәсәбәтләр чак кына җылынып, һәйбәтләнеп килгәндә тагын ызгыш-талаш килеп чыкмасмы? Ул, адымнарын акрынайтып, Гөлгенәгә сорау белән карады. Гөлгенә сизгер, шып туктады, кыйгачын ачык муенына урады. «Ярый, бар, кайт. Иблис корган тозакка төшкәч, Гөлгенә тутаңны искә алырсың, янында мин булмам. Әсинең бикәчең... булышчы түгел ул сиңа! Сиңа кыен килгәндә кулын сузмас. Юртак ул! Табан астында ут яна аның! Күпләрне күрдем мин, җаным, бик күпләрнең языгын үземә алдым. Гаепләмә!»

Гөлгенәнең таушала башлаган чибәр йөзенә акыл чаткылары, тирәнлек, олылык һәм горурлык йөгерде. Нәҗипнең нигәдер аннан аерылып китәсе килмәде. Ләкин калырлык сәбәп юк иде. Утырып торыр урын да юк ичмасам! Өйдә дә көтәләр булыр.

Ит-май бирүләрен белгәч, Мәрьямбикә күккә сикерде: «Безне дә кешегә санап, якты чырай күрсәтер икән, ходаем!»— дип такмакларга керешә. Нәҗип, картларны узындырып: «Колхозның батыр ветераннарына күчтәнәч итеп бирә»,— дигән иде, өйдә хис өермәсе купты! И, адәм баласына күпме кирәк, бер кило май, биш кило ит өстенә әйтелгән бер җылы сүз кәүсәр чишмәсеннән су эчү белән тәңгәл булды. Мәрьямбикә өзмәде-куймады, киленен ияртеп, иткә-майга төшеп тә китте.

Авыл, авыл! Синең чыбыксыз телефоннарың! Юрган астыннан йөргән борчаның да эзен беләсең син! «Йосыфның Казанда министрлар белән аралашып йөри торган Нәҗибе кайткан... Моннан болай Йосыф белән Мәрьямбикәгә ит тә, май да чыгачак икән»,— дигән хәбәр Югары очка Мәрьямбикәнең үзеннән алда менеп җитте.

Көннәр җылына төште, тук карынлы кичләр күңеллерәк үтте, майлы бәрәңге ашыйлар, төшлеккә итле шулпа пешә, бер көнне, тәвәккәлләп пилмән дә бөгеп ташладылар. Мәрьямбикә карчык баш өянәген онытты, көндезләрен мендәргә баш куеп хәл җыеп тормый, тыр-тыр чаба. Ике көннән Гөлгенә Нәҗипкә нәни генә язу кисәге алып кайтып тоттырды: «Теге иблис тагын сине чакырган!»— диде ул, Наиләне күзе белән ашап-ботарлап.

Бу юлы Ихлас ялгыз түгел иде, тирәсендәге кешеләргә кырлы-мырлы бер-ике сүз әйтеп озаткач, ул Нәҗипкә ят итеп беравык карап торды да: «Иртәгә пленумга барам. Сезне Сабит абый чакырткан. Утыртып барырмын. Иртән алтыда төшеп җитегез»,—диде.

Нәҗип: «Җәй буенча торырга кайттык!» — дип әтисенә ялгыш кына ычкындырса да, алар Наилә белән икәүләп тизрәк моннан китү ягын карарга кирәклеген толып асты аулагында сөйләшә башлаганнар иде инде. Сабит абыйларының чакыруын «котылу!» дип кабул иттеләр.

«Ник чакыртты икән?» — дигән шик күңелләргә килеп карамады. «Сабитыбыз Нәҗипләрне кунакка чакырган!» — дип, өй борынча мактанып йөрде иртән майлы ипи, көндез итле шулпа ашаган, күңеле бөтәйгән Мәрьямбикә карчык. Кунакка тек кунакка! Сабит турында сүз куергач, әнисе белән икәү генә калган аулакта, Нәҗип әнисеннән: «Сабит абый сезгә бер дә ярдәм күрсәтмимени соң? Әз-мәз ит, он, май ише нәрсәләр кайтарып ташларга кулыннан киләдер ич?» — дип сорады. Мәрьямбикәнең иреннәре җебеде, күзеннән яшь коелды. «И улым,— диде ул,— Сабитыбыз алай ук кансыз түгел, бик кайтарыр иде, атаң риза түгел. Элгәре елларны түшкәсе белән ит, капчыгы белән ак он кайтаргалады. Дөге, тары ярмасы ише вак-төякне әйткән дә юк иде, әтиең борчылды. Авылда карт-коры ачыккан чакта ничек итеп урлап китергән ризыкларны ашап ятыйм, диде...» «Урлаганны кайтармагандыр ич? Сатып алгандыр?!»— диде Нәҗип шактый аптырап. «Ничек булса да әтиең риза түгел. Кеше белән тигез яшисем килә, ди... Сабитка да шуны җиткерде». «Сабит абый ни диде?» «Ни дисен... авызын кыйгайтып көлде дә күзгә күренмәс булды. Шул».

## 21

Наилә — килен, соңгы тапкыр өй җыештырып, идән-сайгак юып, балаларның кием-салымын ямаштырып өйдә калды. Искәндәрне әбисе янбакчага суган утыртырга алып чыкты. «Җир исен иснәрсең, эшкә өйрәнерсең, әйдә, балам!» Йосыф карт бер якта, Рөстәм бәләкәч икенче якта, аштан соңгы рәхәт йокыга талдылар. Татар тук корсак белән йокларга ярата. Нәҗип: «Өй арасында уралып, комачаулап йөрмим»,— дип ындыр артларын әйләнеп кайтырга булган иде, бара-бара юлы Көмешкүлгә үк алып килде.

Юл белән бармады ул, ындыр артыннан башланып күлне каймалаган чирәмлеккә килеп җиткән сыза буйлап менде. Сыза кипшергән, чит-читләренә котырып үлән калыккан, уентык-уентык булып кузгалак тишелеп чыккан, таш чәчелгән җылы яр ярыкларыннан шыштырдап кәлтә еланнар йөгереп чыга.

Иртәгә кузгалырга туры килә, сәгать сукты, алда ни көткәнен әйтеп булмаса да, монда ни калачагы сукыр күзгә дә күренеп тора: әле кайчан Югары Авыл сыеры күпергә чабып кереп аягын сындыра да председатель Ихлас, кәефе килеп, бәлтерәгән карт-корыга ит-май язуы тоттыра. Болары экият итеп сөйләргә генә калыр, ә ата-ана ничек яшәр? Бәрәңгеләре яңага чаклы да җитәрлек түгел. Яңа урамда бәрәңге саталар ди сатуын... Ә акча?! Яхшы бала булса, акчаны хәзер Нәҗип калдырырга, нужарган ата-анасын ул коткарырга тиеш. Эх, чыгарып саласы иде мең тәңкәне! «Мең тәңкә, мең тәңкә!»— дип радиодан җырлау ансат ул... Мең, мең... Фәтхулла абзасына мең сум бирәсе бар аның... Наилә алганнарны исәпләсәң мең ярымга җитә. Артып та китәдер әле. Мудрый-Мәхмүткә шуннан ким түгел. Тагын кемнәргә бурычлы соң әле ул?! Саный башласаң, баксаң, тирәнтен уйласаң, аның зур, ашыгыч түләнәсе бурычы ата-анасына икән! Читтән караганда акланырлык сәбәпләр җыела, ә кайгы-хәсрәтнең уртасына килеп кергәч, кот очарлык хәлләргә тап буласың!.. Әйе, Нәҗип Йосыф улы Нургалиевкә кайгы-хәсрәт капкасы һәрвакыт ачык. Киң. «Кер, кер!»— дип кара канатлы фәрештәләр күмәк чакырып торалар.

«Ни эшләргә? Ни кылырга?»— дигән сораулар белән баш ватмады Нәҗип, өметсезлеккә бирелгән егет бу баткактан чыгу юлы юклыгын шәйли башлаган иде инде. Хәзер башны җүләргә салып, койрыкны бот арасына кыстырып, телне аркылы тешләп, Сабит абыйларына барып керүдән бүтән чара калмады. Әллә Ихласның сүзен тотып, муенга камыт киеп, районда калыргамы? Камыт артык зур булып муенны

чиләндерсә?! Нигә рәис, авылда бүтән эш беткәнмени? Механик булыр, инженер... Ә хыяллар? Максатлар?! Көнчелек? «Көнчелек ояладымы әллә синең йөрәгеңдә?» — диде бит Фәридун Фазлыев... Җөмләдән, кайда икән ул хәзер? Күреп сөйләшәсе иде. Фәридун Фазлыев исенә төшкәч, Нәҗип бу дөньяда сөйләшер, аңлашыр кешеләре калмавын, дуслары юклыгын ап-ачык аңлады.

Элек күл булган шактый киң чокыр шәйләнә башлагач, ул шул тарафта ниндидер томанлы шәүлә абайлаган иде, бара-бара шәүлә кеше кыяфәтенә керде. Җир буе ара калгач, шәүләнең киселгән тирәк төбендә утырган Гөлгенә икәнен таныды. Кире борылып китмәде Нәҗип, юк, киресенчә, адымнарын ешайтты. Гөлгенәнең нәкъ шушы сихерле аулакта, кипкән бәхетсез күл ярында, әрсез әрәмтамаклар кисеп, төяп алып киткән тирәк төбендә очратуына сөенде. Гөлгенә аның яшьлегенең шаһиты ич! «Илдә яхшы кеше калмады!» — дип еш тәкърарлый эти белән әнисе. Бәлки, Гөлгенә дә яхшы кешеләргә зарыккандыр?!

Гөлгенә ул килгән якка карап, шатлыгыннан балкып, тагын да чибәрләнеп утыра икән, очып урыныннан купты да Нәҗипнең каршысына килеп басты. «Мин чакырып китердем сине, Нәҗип»,— диде. «Нигә?» — диде Нәҗип, гаҗәпләнгән булып. «Нигәме? Белерсең. Янымa утыр әле». «Сыярбызмы соң?» «Мин синең кочагыңа керермен». Күлнең ашъяулык кадәр генә калган күзгесенә чулт итеп пар кыр үрдәге килеп кунды. Гөлгенә кулын чәбәкләде: «Кайттылар! Миннән куркып очып киткәннәр иде, хәзер әнә кайттылар!»

Алар кысылышып янәшә утырдылар. «Бик теләгәндә мин әллә нинди хикмәтләр эшли алам. Тылсымын беләм, сүзләрен. Төз атлап барган кешене керфегем тирбәтеп аяктан ега алам». Нәҗип көрсенде: «Егучылар күп...» «Екмадым әле сине, дәшеп китердем, яныма утырттым». Гөлгенә уң кулы белән аны кысып кочып алды да бүтән ычкындырмады. «Син бер нәрсәгә игътибар иттеңме, авылда яшьтәшләр, безнең чордашлар калмаган. Син кайтып кергәч, кара бүкәй булып йөрсәң дә, эчем җылынды... Иртәгә китәбез без моннан! Булды, кайттык. Ихлас дигән бәндәнең канына тоз салдык. Мине очраткан саен кара коелды, мөртәт. Авыл, тирә-як аннан кан калтырап торганда, мин аның чыраен ертып кем икәнен йөзенә бәреп әйттем! Авыл ишетте, белеп калалар. Мин үлгәч, сагынып сөйләрләр! «Бар иде бер Гөлгенә, берәүдән курыкмас иде! Алла булып кыланган Ихласка да башын бирмәде!» — диячәкләр... «Минем хакта ни әйтәчәкләр?» «Синең хактамы?» Гөлгенә аны үзенә якынрак тартты, күзенә карады: «Синең хакта, аппагым, сөйли алмаслар! Чөнки син оборонный заводның почта тартмасына кереп оялаган корт!» Нәҗип куырылды: «Нигә андый аяусыз хөкем чыгарасың?» «Болай гына,— диде Гөлгенә Нәҗипнең тәнен көйдереп,— күрәсеңме үрдәкләрне! Оя ясарбыз дип килгәннәр, бичаралар, ясамасыннар! Мин хәзер аларны куып җибәрәм!» Гөлгенә сикереп тә торды, җирдән таш алып күлгә тондырды. Үрдәкләр таш төшеп җиткәнче үк фыр итеп очтылар. «Хәзер Галинаның туган ягына, Ижауга кайтабыз. Аны хур итеп, сөяркә итеп тоткан, соңыннан өтермәнгә тыгып котылган цех начальнигының күршесеннән фатир алып, ай буе аның канына тоз салып яшәргә исәп!... Безне күргәч, тез буыннары калтырап тегенең!» Гөлгенә, цех начальнигының кыяфәтен күргән кебек, рәхәтләнеп көлде.

Нәҗип муенына сарылган кулларны кагып җибәрде. «Җирәнәсеңме, җирәнәсеңме?» — дип пышылдады Гөлгенә җәберсенеп. Ул шашып-шашып Нәҗипне суырып үпте, Нәҗип аның ихтыярына бирелде. «Монда түгел, монда түгел! — дип Гөлгенә күзләре белән тирәяктан нидер эзләде. — Адресыңны бир, Казанга барырмын, мин сине әллә кайдан да эзләп табармын». «Яңа квартирага күчәргә җыенабыз, адресым үзгәрә... Мин сиңа Ижауга, главпочтамтка хәбәр салырмын... Килерсең! Көтәрмен!»

Гөлгенәнең тойгылары аңа күчте, алар икесе бер җан, бер тән булып шактый озак аерыла алмыйча басып тордылар. Куркып очкан үрдәкләр яңадан кайтты. «Җәй уртасында күлнең кибәсен белмиләрме әллә бу сантыйлар?!» — диде Гөлгенә күз яшенә буылып. «Кайтабызмы?» — дип сорады Нәҗип. Үрдәкләр аны сихри төшләр дөньясыннан чынлыкка кайтарганнар иде. «Син атлый тор, мин әз генә утырам әле!» — диде Гөлгенә читкә карап. «Кыр үрдәге булып очып китмәссеңме?» — диде Нәҗип, аерылышу мизгеленә җылылык өстәргә теләп. «Нәҗип, күрәм, аңлыйм, син бәхетле түгел. Монда кайтып килүеңнән бәхетең ишаер дип уйлама. Хатының яратмый сине. Бәрәүне дә яратмый ул. Күрүгә мине дошман итте. Нигә? Кемгә явызлык кылганым бар минем? Беркемгә дә. Сиңа да кылмам. Син — яшьлегемнең хатирәсе. Бердәнбер тере кеше. Мин белгәннәрдән. Таралды яшьтәшләр! Күчендe чордашлар. Хәбәр ит, сагынсаң чакыр. Мин почтага көн саен ике тапкыр барып йөрермен, ярыймы?» Ул кайнар куллары белән Нәҗипнең муенына сарылды, кайнар хисләренә буылып-тулышып, шашып-шашып иреннән, муеннан үпте, аннан җиңел генә иң башына кагылды: «Бар, кит. Туктама, зинһар, борылып карама. Тәки капка төбегезгә хәтле ияреп барырмын да хатының алдында суырып үбәрмен!»

«Булыр бу башсыздан!» — диде Нәҗип, адымнарын ешайтып.

«Заманалар нык үзгәрде, — дип уйлады ул бара-бара. — Гөлгенә ни ди: «Председательдән дә курыкмый иде дип искә алачаклар!» диме? Әйе, авыл кешесен әүвәлдә уңганлыгы, булганлыгы өчен мактап телдән төшермиләр иде. Чигүчеләр, җөйчеләр, биючеләр, Сабан туе пәһлеваннары теллләрдән-телләргә күчеп ныгый иде, хәзер әнә... кайнар хисле зимагур Гөлгенә «председатель иблистән курыкмавы белән» телгә кереп калачак...

* * *

Сабитның Казан кунакларын чакыруын ата белән ана яхшыга юрадылар, сөенечләрен яшермәделәр, яңадан монда кайту, җәй буе яшәү хакында сүз бөтенләй кузгалмады, әбиләре балаларның велосипедын тотып: «Чормага меңгереп куярмын, яренгә кайткач рәхәтләнеп уйнарлар. Ел да болай тормас әле», — дигәч, үзеннән-үзе аңлашылды: Нәҗипләр борылып кайтмаячак.

Өй арасындагы эшләр тәмамлана төшкәч, Наилә тирәсендә икеөч тапкыр сәер генә уралып-чуралып йөргән карчык, авызын учы белән каплап аңа дәште: «Килен, монда кереп чыкчы!» Алар кече якка керделәр. «Бик бай йортка барасыз, килен, буш кул белән йөрү килешмәс. Сабит абыеңнарны күргәнең юк, алар... без түгел! Ул җыйналышта чакта Эзидә вакытыгыз булыр, кибетләренә кагыл, син — кала кызы, затлы бирәр бүләк табарсың. — Карчык, як-ягына каранакарана, иртәдән бирле учында йөртеп, тирдән җебетеп бетергән бер төргәк акчаны килененә сонды. — Берүк, әтиең сизмәсен. Нәҗибеңә дә әйтмә». «Алсам оят ич, әни!» Наилә янды-көйде. «Ал, ал. Ирең төпченсә: «Хатын-кызның ахыр чиктә генә чыгара торган маясы була аның!» — диярсең дә көлеп җибәрерсең. Минем улым — йомшак күңелле бала, читне уйламас. Йомшак күңеле аркасында замана тормышына көйләнә алмыйдыр дип беләм». Наилә сүзсез генә әнисен кочаклады. «Безгә ни кирәк? — дип дәвам итте Мәрьямбикә. — Әтиең чирдән арынмый, чынкый тереләсе юк. Безнең гомер узган. Кайтырыгызны белмәдек, кайтырыгызны, чүтеки аяк киенеп торыр идек. Икенче кайтыр булсагыз, штубыты хәбәрләшеп торыйк. Ике сүздән хат язып салу читен түгелдер бит?»

Наилә шунда гына Нәҗипнең укырга киткән җирдән чирләп кай-

туын, эшендә ямьсез чатак чыгуын, булды дигәндә квартираларын тартып алуларын бәйнә-бәйнә сөйләп ташлады. Икәүләшеп туйганчы елаштылар.

Моңа кадәр басынкы йөргән малайлар, китәселәрен белгәч, кинәт дуладылар: «Нигә Кызыл тауга менмәдек? Әти төлке күрсәтәм дигән иде!» «Кызыл тау кипмәгән, ә төлке тилергән», — диде Наилә, ахыр чиктә кызып китеп. Искәндәрнең ике күзе дүрт булды: «Минем тиле төлкене күрәсем килә!» — дип киреләнде. Төлке күрә алмаслыгын белгәч: «Балык тотасым килә, эти кармак салырбыз диде!» — дип еламсырады. Әбисе аны юатты: «И балам, балык имгә дә калмады шул, юк», — диде. Кичкә кадәр турсаеп йөргән балаларны төрткәләп йокларга яткырдылар. Йокларга яткыргач та Искәндәр тынычланмады, йөгереп кенә абзарга чыгып, Бүркәнең муеныннан кочып саубуллашып керде.

Нәҗипнең әтисе белән мөнәсәбәте берчакта да төче булмады, ул «әти!» дип өзелмәде, ата да аны кырыс яратты, улын кочакламады, үпкәне булмады, аркасыннан да бик сирәк кенә кага торган иде. Бу юлы Нәҗип түзмәде, башын читкә борып, күзен яшереп, әткәсенең шыр сөяк җилкәсенә кулын салды. «Сау яшә, әти. Инде болай озак аерым тормабыз, кайтырбыз!» — диде.

Идарә каршысында яшел түбәле «Уазик» һәм Нәҗипләргә таныш трактор парлап гөрләшәләр иде. Тракторы таныш, рульдә утырган кешесе бүтән иде. «Мөнир ял итәме?» дип сорады Нәҗип, сәлам алышкач. Моңарчы Мөнирләргә кагылмавына үкенде, әгәр ул шәфкатьле җан очрамаса, суыкта катып юлда кунасылар икән! Ят тракторчы очлаеп торган ияген селкетеп, тәмәкесен иренендә шудыртып йөртте дә, Нәҗипкә бик өстән генә карап: «Андыйларга ял эләкми, андыйларның үз урыны бар!» — дип чәрелдәде. Нәҗип белән Наилә сагайдылар: «Чирләгәнме әллә?» «Беркөн Әзигә барганда арбасын аударган, көнлек савымны түккән! Тракторын алдылар да үзен чучка койрыгы юарга җибәрделәр. Бездә закон каты». «Аның ни гаебе бар? — диде Нәҗип борчылып. — Юллар өчен ул җаваплымы әллә?» «Сөт түккән өчен кумадылар, аны списать иттеләр. Рәис абый белән әрепләшкән өчен алды ул җәзасын... Соң чүп башы белән Ихлас абыйдан: «Ник ул юлларны әзрәк рәтләмисез?» — дип дупрус алып ята икән! Күрәктән сәнәк булган!» Әллә кайчан тракторга кызыгып йөргән бур Мәҗит малае Марс, Мөнирнең дуңгыз койрыгы борырга эләгүенә ифрат шат иде, шатлыгын Казан кунакларыннан да яшереп тормады. Дөньяда Ихлас абыйсын хөрмәт итүче Марс барлыгын казанлылар белеп китсен!

«Уазик» шоферын ияртеп, идарәдән Ихлас чыкты, бер оя булып бөялеп торган казанлыларга каш сикертеп сәлам юллады да: «Сыешыгыз!» — дип боерды. «Син бездән калма! — диде ул тракторчыга. — Бата калсак, җәлт килеп җит». «Мин Мөнир түгел лә!» — диде Марс авызын ерып.

Урта урамдагы идарәне үтеп, Түбән очка кергәндә нәни генә, тар күпер бар. Машиналар кара-каршы очрашканда, алданрак килүчене үткәреп, күпер башында туктап көтәләр иде. Бүген «Уазик» күпергә кердем дигәндә, теге яктан каршыга, пычрак чәчә-чәчә, авыр КРАЗ килеп туктады һәм юл таләп итеп кычкыртты. Ихласка бу бер дә ошамады, каршысында кем машинасы икәнен аңышмыймы әллә бу йолкыш?! Ихлас шоферы ишекне ачып кычкырган иде, КРАЗ шоферы аңа йодрык күрсәтте. Ихлас белән шофер икесе ике яктан машинадан төштеләр. Монда юл начар, Ихласның чалбар балагына сыек ләпек чәчрәде. «Каршыңа кем килгәнне күрмисеңме?» — дип җикеренде шоферы, Ихласка ярарга тырышып. Ихлас та: «Кая ашыгасың? Җәһәннәмдә көтеп торырлар, кабаланма!» — дип аны куәтләде. КРАЗ шоферы, аю кебек дәү, тупас гәүдәле ир, машинасы-

ның эрҗәсенә ишарәләде. «Мин ашыкмас идем, ул ашыктыра». Анда ап-ак такталы табутның ике ягына җиде-сигез кеше тезелешеп утырган икән, тавышка алар да калкынып, нидер мыдыр-мыдыр сүзләшеп алдылар. «Кем ул?» — дип сорады Ихласның шоферы, бердән юашланып. «Авылдашыгыз Хәнифә булыр бу, бәбәйдән вафат. Туганнары монда алып кайтып күмәргә булганнар. Үзе дә шуны үтенгән». «А ну, кире борылыгыз!» — дип кычкырды Ихлас шашынып. Эрҗәдән мәетне озата кайтучы туганнар коелды. Алар Ихласны танымасалар да, тавышы көрлегеннән бу якның хуҗасы икәнен чамаладылар. «Ник борылыйк без?» — диештеләр алар аптырап. «Эштән качалар да үлгәч туган авылларны искә төшә! Эшләгән, яшәгән җирендә җирләсеннәр. Борылыгыз, борыл!» «Апаем, — диде арадан иң өлкән кеше, — син әкәмәт кеше икәнсең! Хәнифәбез: «Туган төягемә алып кайтып җирләгез», — дигән икән, без мәрхүмәнең сүзен боза да, үзгәртә дә алмыйбыз. «Тоталар да күмәргә монда кайтаралар, Чаллыдан да мәет килә, Иҗаудан да. Свердловскидан да алып кайттылар. Юк бит, шунда гына җирләсәләр, мәшәкате, чыгымы аз була!» — диде Ихлас һаман киреләнеп. «Хәнифәбезнең актыккы үтенече бит, туган, соңгысы. Җирдән дә, күктән дә бүтән нәрсә сорары юк». «Ярар, берлеккә рөхсәт. Моннан ары махсус приказ белән беркетермен: качканнарны монда кайтару юк!» «Качканнарны» дигәнне ишеткәч, озата кайтучылар нидер шаулаша башлаган иде, өлкән ир кырыс күз карасы белән аларны тиз тыйды. КРАЗ артка, бер кырыйгарак чигенеп, «Уазик»ка юл сапты, Эзигә сәфәр чыгучылар мәет салган мәтәм машинасын үтеп киттеләр...

Хәнифә Нәҗипнең классташы иде, Гөлгенәнең балачак дусты. Иртәнге мәшәкатьләр белән ул Гөлгенәне онытып торган иде, хәзер борыла-борыла артына карады: алар да китәбез дигәннәр иде ич... Әллә Ихлас болай иртәләп, ашыктырып алардан качып чыгып барамы? Нәҗипләр барында очрашудан курыктымы?

Шулай иде, бүген мәетне зиратка үткәрергә Ихлас рөхсәт бирәчәк түгел иде, даулашып-сүгешеп булса да ул КРАЗны кире борачак иде, әмма кичә янап чыгып киткән Гөлгенә исеннән чыкмаганга, ул ризалыгын бирде. «Киткәнче күзеңә кылчык булып кадалам әле мин!» — дигән иде Гөлгенә... Милиция чакыртып, сансыз-сөмсез хатынны этап белән озаттырырга да җыенды, Казан кунакларыннан бераз шигәйде. «Кунак — Сабит энесе! Аның кем икәнен кем белгән?!»

Авыл артта калды, әлегә хәвеф-хәтәрсез бардылар, юл да беркөнгегә караганда шактый кипшегән, машина да егәрле иде, трактор күз күремендә артта калды. Үз алдына уйланып барган Нәҗип тиктомалдан: «Үлгәч кайтып монда ятарга телиләр икән, алар моннан үз ихтыярлары белән китмәгән булып чыга!» — дип сүз әйтеп алды. Ихлас ни әйтер дип көтсә дә, рәис дәшмәде, аның ап-ак якасы кисеп кергән таза, тук муены гына ныграк кызарды.

Юл кашлакта гына бераз җилләгән икән, иңкүлеккә, үзәнгә төшүгә, тәгәрмәчләр саз ярып, юлны капшап бардылар. Әгәр тәгәрмәчләр зыр-зыр әйләнеп лай тугылап тормасалар, Нәҗип Наилә белән парма-пәр килеп талашкан эскерт төбе янына килеп җитүләрен сизмәс тә иде, «Уазик» та бу төшне үтә алмады. Шофер чыгып, әллә кайда ташбака кебек сөйрәлгән тракторга кул болгады. Үзе, тәмәкесен кабызып, тышта калды. Берәү дә сөйләшмәде, иртә уянган малайлар йокымсырап эти-әниләренең алларына аудылар. Шофер тросын эзләп алды, трактор килеп җитеп, алга узуга, җәһәт-җәһәт машинаны такты. Трактор бер талпынуда гына машинаны кара лайдан сөйрәп чыгара алмады, фыр-фыр көчәнде, торбасыннан куе төтен бөркелде, бер уңгарак, бер сулга каерылды, ниһаять, машинаны

тагып, бер-ике җир буе баргач, туктады. Күз күреме кадәр җир шактый коры, тигез һәм хәвефсез күренде. Тракторны көтеп, урта юл күперендә машинаны әз-мәз юып, Ихласның чалбар балагын рәткә китереп шактый юандылар, бер кузгалгач, Ихлас шоферга сәгатен күрсәтте. Шофер рульгә ябышты һәм барып җиткәнче башын күтәреп тә карамады... Алар ике катлы, кызыл калай белән ябылган бина янына килеп туктадылар, райком элек тә шунда иде, хәзер дә монда икән... Ихлас машинадан төшкәч, күзе белән як-ягын капшады да: «Сабит абый сезне үзе эзләп табар, ерак китеп йөрмәгез», — диде. «Аның машинасы әнә теге, номеры 33—38», — дип, шофер да сүз кыстырды һәм елкылдап торган, бер тамчы лай чәчрәмәгән «Волга»ны күрсәтте.

Машиналар килә торды, алардан нәкъ бер буйдагы, бер төслерәк киенгән, сәламәт, тап-таза, тук кыяфәтле ирләр төшә торды, алар бер-берсе белән бик дус, якын иде, ахрысы, күрүгә кочаклашалар, аннары эре-эре адымнар белән райкомның биек һәм авыр ишегенә кереп югалалар иде. Сабит иртәрәк килгән булып чыкты. «Ул — бюро члены!» — диде Ихласның шоферы хөрмәт белән авызын чапылдатып.

Шоферның да, форсаттан файдаланып, Әзидәге баҗасына кереп чыгасы бар икән, ул китәргә җыенгач, «Әйбер караларны алып калыйк, бер-беребезгә бәйле булмыйк», — диде Наилә. Әйберләрне күтәреп, райком алды мәйданыннан читкәрәк китеп, аулак ындыр киртәсе янына бөялделәр. Бөтене белән ипи тотып, алап авызы белән почмагыннан умырып тешли-тешли, бер ир үтеп китте, ипинең исе таралып калды. Искәндәр белән Рөстәм әниләренең Югары Авылда кимәгән, күз карасыдай саклап тоткан күлмәгенең итәгеннән тарткаладылар: «Әни, карыным ачты!» Иртән тамагына ризык үтмәгән Нәҗипнең дә бурасы буш иде, ул да Наиләгә карап: «Әллә тамак ялгап алабызмы?» — диде. Ашханәне тиз таптылар, анда иске селедка кисәкләре, пешкән күкәй һәм авылча калын-калын киселгән ипи телемнәрен алдылар.

Балалары авызына ризык кергәндә сөенмәгән ана буламы?! Искәндәр белән Рөстәмнең йоп-йомшак ухый телемнәрен төенә-төенә ашаганын күреп, Наиләнең күзенә яшь килде, бер-ике телемне юлга төреп тә алдылар. Чәй үтә күренмәле сыек булса да, кап-кайнар иде.

Наилә чиста кулъяулыгы белән иренең ирен читләрен сөрткәләде һәм төче, яшь тавыш белән аңа эндәште: «Син хаклы булып чыктың, Нәҗип. Авылга кайтып йөрисе дә калмаган». «Нигә? — дип сорады көтмәгәндә кикереп Нәҗип. — Бер күреп килүдән ни зыян?» «Күреп кенә булсачы!.. Күрсәтеп тә китәбез бит. Менә хәзер дә бай йортка барабыз...» «Бай булсалар ни, туган абыем лабаса ул!» «Туган абыйларга коры кул белән, күчтәнәчсез баралармы?» — диде Наилә тиз-тиз.

Нәҗип бик аптырап хатынына карады, тел шартлатып башын чайкады.

«Нәҗип! — диде Наилә кыз чагындагы көмеш, иркә тавышы белән. — Болыт юк, җил юк, билетлык акчабыз бар, әллә Казанга кайтып кына китәбезме? Нигә Сабит абыйларга күренеп адәм көлкесенә калырга? Минем бер дә аягым тартмый!» «Качыйк дисеңме?» «Берәр заман кайтырбыз әле, гафу үтенербез, балалар чирләде диярбез!» «Юк инде, — дип карулашты Нәҗип. — Бүген качабыз икән, яңадан күзләренә күренә алмабыз». «Йә инде, Нәҗип, — дип сузды Наилә. — Тормышыбыз үзгәрер, сихәтләнеп эшли башларсың, баербыз, балалар исәер, шундый чакта кайтсаң да күңелле ичмасам. Иеме?» «Этинең хәле авыр... Эти турында киңәшергә кирәк».

Нәҗипнең ныклыгын тикшергәч, Наиләгә кыюлык керде, ул уң кулы белән кадак суккан сыман, һаваны кисә-кисә: «Болай итәбез

ул чагында. Сез шушы тирәдә ураласыз, ә мин кибетләрен әйләнгәләп чыгыйм. Абый йортына буш кул белән бару килешмәс», — диде. Нәҗипнең тамак туйгач йомылыр-йомылмас күзе шардай ачылды: «Ә акча? Юкка күз кыздырып, җаныңны үртәп йөрмә, Наилә». «Хатын-кызның... — диде Наилә бөгелә-сыгыла. — Күзгә кырып салырлык актыккы маясы — запасы була аның!» Наилә ясалма чыркылдап, сикергәләп кибет эзләп чапты, малайлар шау-гөр килеп аңа ияpделәр. Нәҗип киртә баганасына терәлеп иссез-өнсез карап калды.

Нәрсә алырга? Ни алып барсаң, хуҗалар күңеленә хуш килер? Наилә җаны-тәне белән Нәҗипнең Сабит абыйсы белән якынаюын тели иде. «Кермичә генә китик!» — дип ул ирен кызганып, юри үгетләп маташкан иде. Аның моңарчы Сабит абыйсын да, килендәшеҗиңгәсе Сөмбеләне дә күргәне юк. Иренең туганнары белән арасы кырку икәнне белә Наилә, тартышның сәбәбен сорап, төпченгәне генә булмады. Гомумән, Нургалиевләр затында сүз йөртү юк та бугай, әнә Югары Авылда тордылар, Мәрьямбикә карчык ул-киленнәре, кыз-кияүләре хакында авыз ачып берни сөйләмәде. Сабитлар гаиләсе, Казанда чактагы кебек, бүген дә табышмак иде. Сабит белән Нәҗип татулашсалар, алда ни эшләргә кирәклеген Наилә белер иде!

Универмаг яңа ачылып маташа икән. Наилә кибетчеләргә ияреп диярлек эчкә керде. Кибетне бай дип тә, ярлы дип тә әйтеп булмас иде, эчемлек тезгән киштәләр сыгылган, шешәләр күз явын алып «гаскәри Чыңгыз кеби» тезелешеп торалар. Наилә бу почмактан ятрәк китәргә тырышты. Оекбашлар, кызыллы-зәңгәрле яулык-кыйгачлар, бармакчалары ләпшердек пирчәткәләр, тузанлы киштәләрдә озак аунап төс җуйган чүпрәк-чапрак рәтендә дә озак юанмады. Савыт-сабалар тезелгән киштәләрдә дә күз төшерерлек нәрсә-кара күренмәде. Кием-салым бүлегендә карачкы иңеннән төшкән кыешмыеш чабулы иләмсез плащлардан, якаларына көя төшкән пальтолардан гайре әйбер юк та иде шикелле. Танышкан саен аның өмете киселә барды, ул, үзе дә сизмәстән, беренче кергән эчемлекләр почмагына борылып кайтты. Берәр шешә кыйбатлы коньяк алыргамы әллә?... Ярамас, Сабит абыйсы капмый торган тәкъвә ир булса, оятын кая куярсың? Балалар ияртеп, шешә тотып барып керү килешмәс тә...

Бая шушы почмакка савылып керүче ирләр арасында аңа бер таныш йөз чалынган иде, шулай булып чыкты. Өс-башлары таланган, калтыравык куллы, җиту сакаллы дистә ярым ир, күбекләрен өрә-өрә, баш төзәтәләр иде. Сырмасын җилбәгәй җибәргән, яңакларын бөдрә төк баскан Мөнир янындагы ике сукбайны һәм шөкәтсез бер марҗаны кыстый-кыстый сыра белән сыйлый икән. Янына барасы итте Наилә, тракторчының чалбар кесәсеннән бер шешә аракы тартып чыгаруын күргәч, яхшысынмады, тыелып калды. Мөнирнең исерек тавышы колакны ярып керде. Шактый нык салган, ахрысы, егет. «Китәм! — диде ул сыра кружкасын һавада йөртеп. — Түзәрем калмады... Сөйгәнемне мәсхәрә итте, түздем... Әтинең мунчасы янды — бүрәнә бирмәде. Урманнан урладым, эләкләделәр. Шуның белән ничә ел бугазыма пычак терәп торды! Чак кына авызың ачылса да: «Утыртам мин сине, рәшәткә артына тыгам!» — дип янады. Утыртыр да! Закон үзенеке! Нинди кыз иде Югары өч Гөлгенә! Төрмәдә биләнке ясап кайтардылар. Кем гаепле икәнен эзләп кара! Бугазыңны ботарлар! Китәм! Яшьтәшләрдән беркем калмады. Соңгысы — мин. Әлерәк кенә Хәнифә апаны алып кайтып киттеләр. Үлгән бичара! Тездән суык саз ерып, көн-төн тирес ташып ферма җилендә салкын тидерде бит ул. Врачлар бала тапмаска киңәш иткәннәр Хәнифәгә. Утызны узганчы түзгән, бичара. Үзе вафат, баласы калган. Ире — алкаш. Тагын бер ятим артты дигән сүз! Ул иблис минем Халисәмнең кызлыгын алды, җәлләп кенә аңа өйләндем! Китәм!»

Наилә күз яшьләренә тончыгып, универмагтан чыгып китте. Малайлар тыр-тыр аңа иярделәр.

Күрмәгән-белмәгән кешегә бүләк алудан да кыены юк, бүләксанак өлкәсендә тәҗрибәсез, үзе берчакта да бүләк алмаган Наилә кара тиргә төште. Ишек катында һава сулап торгач, кередән универмагка керде, икенче катка күтәрелеп, товар залларын ике-өч кат урады.

Ул Сабит Нургалиевләрнең тормышын күз алдына китереп карады. Җыйнак кына алты почмаклы өйдә торалардыр... Чиста-пөхтә җыештырылган. Йорт тирәли чәчәкләр. Бик күп чәчәкләр! Өйдә китап киштәләре, пластинкалар. Илһам Шакировны яраталардыр, Әлфия Афзалованы, Рәшит Ваһаповны. Әлфиянең тәлинкәсе бар икән — икенче катта тәвәккәлләп шуны алды. Җырлары нинди бит әле тагын: «Кәккүк», «Болын»! Кайсы татарның бу моңнарны тыңлаганда йөрәге кайнарланмас?! Тәлинкә биреп кенә хуҗа олылыгын бәяләп булмас шул, туганнарның очрашканнары юк, дүртәүләшеп кайтып керәләр.

Универмагның өлкәнрәк бер сатучысы баядан бирле аларга игътибар иткән иде инде, түм-түгәрәк, буйга тигез дип әйтерлек ике малайны күргән саен, аның йөз җыерчыклары куанычтан балкып китә иде, гаҗизлектән исергән Наиләне ул дәшеп туктатты. «Җаным, сез бу якныкы түгел шикелле, кайтышмы, китешме?» — дип сорады. «И апа, — диде Наилә, җылы сүздән балавыздай эреп. — Шәһәрдән кайткан идек, хәзер бер авылга кунакка китеп барышыбыз. Буш кул йөзне ертыр, бирәр бүләк эзлим дә ни алырга белмим. Башым катты. Колхоз рәисләренә барабыз. Нинди бүләк килешер дә, нәрсә кулай булыр?» — диде Наилә һәм барасы авылның исемен атады. Апаны алыштырып куйдылармыни!? Әлек тә ягымлы караган иде, хәзер тулган айдай балкып Наилә янына чыкты, иелеп малайларның битләрен чупылдатты. «Шулаймыни, акыллым? Сабитларга барасызмыни? Ай, бик затлы кешеләр чакыра икән. Аларга лаек бүләк монда булмас, әйдәгез әле, үзем сайлашыйм». Наилә бераз шигаебрәк хатын артыннан иярде, идәннән түшәмгәчә картон тартмалар, төргәкләр, төеннәр шыплап тутырылган киштәләр арасыннан үтеп, кечкенә бер бүлмәгә барып керде. Тәрәзәсе юк бүлмәнең ишеге өстендә якты лампочка яна иде. «Бик һәйбәт бүрекләр бар, биш йөзлеге бар, алты йөзлеге. Сабит абыегыз аннан арзанлыны кими». Наилә коелып иңде, кулына йомарлаган ике егерме бишлеге тирдән дымланды. Аның икеләнгәнен күреп, сатучы хатын — кеше холкының иң югары дәрәҗәсендәге белгече — планканы шундук түбәнгәрәк төшерде: «Исемә төште! Бүрекләре бар аның, бар. Беркөн япон зонтигы сораткан иде, ул чакта бездә юк иде, хәзер бик затлылары кайтты. Бәясе дә җүн — илле тәңкә. Әлфия Мортазина табарга булышты», — дип әйтсәгез, миңа бик җиткән. Юк, юк, акча кирәкми. Әлфия Мортазина дип әйтергә генә онытмагыз. Сез бүләкне аңа тапшырырсыз, зонтик миннән сезгә бүләк! Улларыгызны бик-бик ошаттым. Ялгыз мин, бала-чагам юк. Сайлашты диегез дә, гаиләсенә бик күп, бик күп сәлам тапшырыгыз. Сөмбелә керсен, сез дә кайткан-киткән чакларда читләтеп үтмәгез, керегез!»

Наилә ялынса да, Әлфия Мортазина акча алмады, киресенчә, кергәннәре өчен рәхмәт әйтеп, телефон номерын язып бирде. Малайларга бирәр кап печенье, ике шоколад һәм ике шешә баллы су эләкте. Аларга да акчаны алмады.

Егерме бишлекләрен эчкәрәк яшереп, аптыраган-йөдәгән Наилә ирен эзләп китте.

«Хатыныңның кем икәнен беләсең килсә, сәфәргә алып чык», — дигән борынгылар. Наилә ирен әллә ничә мәртәбә шаккатырды бүген. Көткән арада әйбер-караларын сөйрәп китап кибетенә кергән иде

Нәҗип. Бакса, артыннан хатыны да бастырып кереп җиткән. Нәҗип кулына алган китапларын куям дигәндә, аларны Наилә тартып алды. «Ядерная физика, — диде Нәҗип, — Америкада язылып басылган, Мәскәүдә тәрҗемә ителгән, җәһәннәмдәге Эзигә килеп череп ятачак. Башкалада бу китапны ике шәм яндырып эзләсәң дә табачак түгелсең! Монда ике томы утыз сум! Анда берсе-берсенә йөзне сорыйлар!» «Әйдә, алабыз!» — диде Наилә кинәт. «Нәрсәгә ул?» «Миннән сиңа бүләк!» Наилә сатучы алдына баягы җебеп беткән егерме бишлекләрне чыгарып салды. «Сабит абыеңнар китапны күрсен... Кайчагында кулдагы китап кешенең абруен нык күтәрә!» — диде хатын, сөенеченнән кабынып. Алар мәсьәләне ачыклаган арада сатучы китапларны һәйбәтләп төреп, бәйләп, каршыларына китереп куйды.

Кибеттән чыктылар. Китап алу белән мавыккан Нәҗип, әгәр Наиләсе зонтик сабы белән кабыргасына төртмәсә, берни күрәчәк түгел икән. «Ни бу? Тагын миңа бүләкме?» «Бусы Сабит абыйга!» «Ә бусы?» «Бусы Әлфия Афзалова, үземә бүләк!» Юк, чыннан да, монда Нәҗип аңлап бетермәгән сер бар иде: малайлар әниләренең сумкасына тыгылып печенье кимерәләр, шешә ачып баллы су эчәләр... Каян? Ничек? «Зәйдә ханым-әфәндегә кредит ачканнармы?» — диде ул, хатынын беренче тапкыр ханым-әфәнде дип атап. Өйләнгән чактагы: «Мин сине ханым-әфәнде дип кенә йөртермен», — дигән вәгъдәсе әллә кайчан онытылган иде. Ире чирләгәннән бирле Наиләнең чыраеннан сөенү качкан иде, аның чибәрлеген өзмәс нужа, туя ашамау, курку, икеләнүләр, шик-шөбһәләр йоткан иде. Бүген һич уйламаганда ул сабырланып, тынычланып калды, гәүдәсенә кыз чагы җиңеллеге, күңеленә тигезлек кайтты. Иренең култыгы астында — «Ядерная физика» китабы, күреп егылсыннар. Япон зонтигын ачып-ябып карадылар, тавыш-тынсыз, шоп-шома эшли! «Кредит ачарлар да! — диде ул җиңелчә яңгыравык тавыш белән. — Нургалиевләр фамилиясе шактый югары дәрәҗәдә йөри икән монда!»

Хатынының күңеле күтәрелгәнен сизми калган ир буламы? Бер мәлгә Нәҗип тә үзгәрде, холкын-фигылен алмаштырдылармыни: «Әллә чыннан да шушы төбәктә, туган җирдә, Нургалиевләрнең акцияләре югары чакта калыргамы? Чукынып китсен фән, чәнчелеп китсен завод, челпәрәмә килсен эшкә ашмас хыяллар! Калырга председатель булып и вәссәлам!»

Мөгаен, Сабит белән алар бу турыда гәпләшерләр. Ихлас аңа идарәдә сөйләшкәннәрне җиткерми калмагандыр. Районның ике ягында ике Нургалиев эшләп ятыр! Нәҗип абыйсыннан өйрәнер, аннан өлге алыр, бер заман икесе дә халыкара данлы рәисләр булып китәрләр... Уртак әкияти мизгелнең шифасы балаларга да тиде, алар чыркылдашып, бер-берсен куып уйнадылар. Бакчага, яфраклары күңелле ачылып килгән агачлар астына кереп утырсалар да, көн җылытты, эссе була башлады, алар төенчекләре белән куерак күләгә эзләп күченделәр.

Кәнфит суырып, прәннек кештердәтеп, куе баллы су чөмергән малайларның тамагы кипте. «Су эчәм!» — диде кече малай. «Минем дә тамагым кипте!» — диде Искәндәр. Наилә малайларны баягы ашханәгә алып барып кайтты. Аннары алар алмаш-тилмәш кысталдылар. Бәдрәфкә этиләре алып барды. «Кунакка ач бармыйк!» — дип, ашханәгә әүвәл Наилә кереп чыкты, Нәҗипнең дә эче чурлады, ашык-пошык ул да тамагын ялгады. Инде әйберләрен төйнәштереп, бәйләштереп райком ягына ашыкканнар иде. Рөстәмнең сандалие төшеп калган. Нәҗип аны эзләп кире чапты. Сандали йон йомгагы хәтле генә эт авызында булып чыкты, этне куып тотканчы, авызыннан сандалины алганчы, Нәҗип шыбыр тиргә батты.

Ахылдап-ухылдап райком янына барып җитсәләр, пленум беткән, машиналар таралган, кап-кара «Волга» янында кара көеп Сабит

абыйлары басып тора. Җиңелчә кул кысышып, уртача җылылыкта күрештеләр. Нәҗип Наилә һәм уллары белән бертуган абыйсын таныштырды.

Бүтән чакта Сабит Нургалиевнең көяз машинасы райком алды мәйданыннан иң беренче булып кузгала иде, председательләр шаугөр килеп аны озаталар, кулын кысып калырга чират торалар, ыгызыгы арасында хаҗәт-йомышларын әйтергә дә өлгерәләр иде. Еш кына аны озатырга секретарьлар чыга, райбашкарма рәисе, урынбасарлар, вак-төяк, ыбыр-чыбыр мөдирләр тантаналы озатудан читтә калмыйлар. Бүген тәртип бозылды, инде иң арттагы колхозларны тагын да арткарак сөйрәгән булыр-булмас рәисләр дә таралды, бүлек мөдирләре бил бөгеп, баш ия-ия аның яныннан әллә ничә үттеләр, ул шоферына «Кузгалдык» дип авыз ачканда энесен күреп алды. Ояндагы бүтәннәргә ул сыңар күзен дә төшермәде: Сабит үзенә кирәкмәгән кешеләрне күрмәскә күптән гадәтләнгән иде. Энесенең хатынына кул сузганда ул аның кайнар, хисле бармакларына чак кына кагылды, алай да эчке бер тетрәнү белән сискәнеп китте, ачуы кабарган чак иде, ачуы кабарганда ул аяусыз, хис-тойгыларына бәя биреп өлгерә алмый, язгы ташкын кебек вата, җимерә, кыра... Сөйләшмәде, «Утырыгыз!» — дип приказ бирде дә шоферы Әхмәтзыя янына кереп чумды. Наилә белән Нәҗип очрашуның корылыгыннан каушадылар, букчәләрен кая урнаштырырга белмичә, малайларны урыннан-урынга күчерделәр. Ашыгу кешене кечерәйтә, түбәнсетә. Сабит аларның вакланып, бик бәләкәй калып каударланып маташуларын күз керфеге белән күзәтеп торды.

Ниһаять, урнаштылар, ишекләр ябылды. Әзине чыгып уңга борылдылар, алар борылып кергән юл тигез, гаҗәеп матур һәм күптән түгел генә асфальтланган иде. Монда язгы пычракның әзе дә юк, юлның ике ягына рәт-рәт итеп пөхтәләп, ныклы күз астында утыртылган яшьтәш каеннар бөреләрен ачып, дөньяга мең-миллионлаган күз белән карап, тирә-яннарына сокланып чайкалалар иде. Хуҗа сүзсез баргач, кунаклар да авыз ачарга кыймадылар. Иртә торган малайлар, тирбәлеп барсалар да, бүген йокыга баш бирмәделәр, алар да яктагы тәртипкә, камиллеккә сабыйларча сокланып, онытылып утыралар иде. Бара-бара Рөстәмнең түземе төкәнде, кыйгаеп әнисенең алдына ятты, башы итәкне күтәреп, күлмәкне сөзеп керде. Төп-төз утырып барган Сабитның күзе ялгыш кына каршыдагы көзгегә төште: Наиләнең йоп-йомры тез башлары, матур коелган тулы балтырлары күзен кисеп алды. Энекәшнең хатынына алай карау язык иде, ул моны искәреп читкә борылды, аңын томалаган вәсвәсәгә баш бирергә теләмәде. Түзмәде, көзгегә тагын бер карап алды, күрер өчен аскарак шуышып, җайлабрак утырды. Аның ач күзе кая төбәлгәнен Наилә тиз абайлады, аякларын күчерергә, читкә тартылырга әмәлен генә табалмады. Сул кулы белән тез башын томалап карады, итәкне тартып төшерергә тырышты, барыбер тезләр ачылып калды. «Күр син аны, энекәшне йолкыш кына дип йөрсәм, хатынның асылын эләктергән икән ләбаса!» Шушы уй күңеленә килгәч, Сабит көлемсерәде. Бу нәтиҗәсе ул моңарчы әзерләп куйган планны баш-аягы белән әйләндереп ташлады...

Гөлгенә тормәдән кайтып бавырына таш булып утыргач, Ихласның берәр тыныч көне булдымы икән? Нәҗип кереп, булыр-булмас сүзләре белән канын кайнаткач, ул көне-сәгате белән ишеткәннәрен Сабитка җиткерде. Энесенең кем икәнен, теленә ни килсә шуны теләсә кайда лыгырдап йөргәнен ишетсен Сабит, белсен! Кибетче Зәйнәп, берне биш, койрыгы белән куш итеп кибеттә очрашуларын үтә ямьсез итеп Ихласка әләкләгән иде инде. «Халыкны котыртты! Май да сатмагач, нигә эшкә чыгасыз сез, ди!» Мөнирне чәнчелдереп төшерергә әллә кайчаннан кыҗрап йөргән бур Мәҗит малае Марс та нәтиҗәне

үз файдасына борган иде: «Һәй, Ихлас абый! Мөнирне Казан кунаклары котырткан. Гел шулай ул, теләсә кем сүзенә ышана! Ул бит, теге, Югары очның зыяндаш Йосыф малаен утыртып кайткан. Мөнир буынсызга шулар сүзе җитә калган!» «Дыр», «бугай»лар Ихлас авызында көчәйтелгәннән соң, Сабитка үтә ямьсез булып барып җиттеләр. Ул энекәшен элек тә сөйми иде, хәзер җене котырды: гомер эченә бер авылга кайтып монда үз тәртипләрен урнаштырырга маташамы, бушбугаз! Без урнаштырган тәртип ошамыймы аңа?!» Шул минутта ук Сабит уенда камил план туып өлгерде. Ә аның планнарын тормышка ашырмаган чагы юк!.. «Пленумнан соң, энекәшне, ыбыр-чыбырлары белән төяп алып кайтырга да, кара-каршы утырып йонын туздырырга кирәк юньсезнең!» Бу булды бер, икенчедән, бертуган энең районга кайтып сиңа керми китә икән, күңелле хәл түгел. «Кунакка энесен дәшеп алган!» — дигән хәбәр аның абруен гына күтәрәчәк. Энесе авызын тыя алмыйча дөньяны тәмам сасытканчы алып кайтырга аны! Пеше чыбык белән сыртын каезларга! Телен тешләтергә һәм артына тибеп Казанына озатырга! Авыл хуҗалыгын белмәгән башы белән Ихласка нинди провокацион сораулар биреп маташкан бит! Имеш, колхоз-совхозлар үз-үзләрен дә туйдыра алмаганда ни дип аларны асрап ятасыз да нишләп таратмыйсыз?! (Нәҗипнең күңеленә дә, теленә дә андый сорауның килгәне юк!) Утыз өч ел яшәп тел тыярлык та акыл җыя алмаган икән ишәк! Ә еллары нинди, еллары! Яшәгән кешегә яшәрлек кенә, бәхетле еллар, рәхәт еллар! Бөке генә түгел, таш та өскә калка торган еллар!

Әллә этиләргә кайтып, шунда чәкәләшеп алыргамы дип уйлады Сабит, эти-энисеннән яхшысынмады. Җәзага тартыр өчен кунакка алып кайтырга туры килде һәм, кайтыр юлның яртысына җиткәч, кинәт кенә планнар үзгәрде. Алда ни көткәнен дә, ни кичерәсен дә тәгаен генә белмәсә дә, ул кунакларны алай тиз озатмаска карар кылды. Зурайды аның планы, тармакланды, энекәшкә акыл бирергә кирәк анысы, шиксез, әмма мондый сылу киленне кунак итмичә дә ярамый бит! Нәҗипне эт итеп, хатынын ничек юмаларга, күңелен күрергә — анысын уйлап бетерергә тәҗрибәле Сабитның акылы җитмәде. Чөнки Наилә энесенең хатыны иде...

Юллар, кырлар монда бүтәнчә иде, сөрелгән, чәчелгән җирләр күз явын алып пар бөркеп яталар. Ерганак-чокыр тирәләрен хәстәрләп караганнар, ярларда вак-вак чаукалыклар калкынган. Урман авызлары, юл читләре чүп-чардан арындырылган. Язгы гөрләвекләр тирәнәйткән су эзләре дә күздән читтә калмаган, тал чыбыктан тәбәнәк киртә-тоткарлагыччылар үреп, суның юлын бикләгәннәр. Асфальтка аркылы чыккан юлларга бөтен җирдә дә «Тракторларга керергә ярамый!» — дигән кисәтүләр эленгән. Бөтен юл дәвамында коммунизмга ашыктырып өндәмәләр кычкырып утыралар. Ниһаять, Нәҗип түзмәде: «Сез башка мәмләкәттә яшисез икән!» — дип ычкындырды. Сабитның куе, тыгыз һәм коры керфекләре дерелдәп китте. Наиләсе алдында мактаганы өчен энесенә эченнән рәхмәт укыды. «Юлны әйтәсеңме?» — дип сорады ул, Нәҗиптән тагын да ныграк соклану көтеп. «Аны да!» — диде Нәҗип, башын уңга-сулга боргалап. «Юл шәп! — диде Сабит. — Татарстанда бер! Нефтьчеләр салып бирде. Округтан генеральный директорны депутат итеп мин сайлаттым. Карыйм: Мәскәүдән булыр-булмас берәүне сыларга маташалар. Стоп, мәйтәм! Директор депутат булды, мин — юллы. Яхшы юлың бар икән, бәхет үзеннән-үзе авызга тәгәрәп кереп тора. Аңларга гына кирәк. Ул депутат, ә мин ни кушсам, шуны эшли. Элек сессиягә икра ашап, ял итәргә йөргәннәр, ә минем депутат министрдан министрга чаба! Имә белсәң, җир астын таларга гына өйрәнгән нефтьчеләрдән ун имчәк таба аласың!»

Берчакта, беркем алдында серен чишкәне юк иде Сабитның

Бигрәк тә Ихлас: «Гафу итегез, Сабит абый, энегезнең иләге тишек икән!» — дип кисәткәч, телдә сагаерга кирәклеген күңеленә беркетеп куйган иде... Машинада Нәҗип белән икәүдән-икәү барсалар, ул, әлбәттә, авыз ачып сүз әйтмәс иде. Асылда хәзер дә ул энесе өчен сөйләми. Нәҗип — нүл, адәм тәганәсе, хәзер аның һәр сүзе, тырышып матурлаган һәр җөмләсе Наиләгә, аның шашарлык дәрәҗәдәге матур аякларына юнәлтелгән. Оят, үз-үзен каһәрли Сабит, күзен аска төшерә, кул аркасын, беләкләрен чеметеп карый, нишләсен, күзе тагын көзгегә борылып кайта... Ул тыңласын, ул ишетсен, ул таң калсын! Сылу хатыннарны кулга ияләштерергә дигәндә Сабитның мең ысулы бар барын, тик әлгәрге, сыналган ысуллар ярамый бүген, ярамый, беренчедән, Наилә — энесенең хатыны, икенчедән очрашулар озынга тартыла алмый, ара кыска. Чибәр хатыннарны йә байлыгың, йә чибәрлегең, йә ирлегең белән бөгә аласың. Өчесе дә бар Сабитта, өчесен дә биргән ходай, йа раббым, нигә бу хатынны энесенең бичәсе итеп яраттың?! Тирә-яктагы юллар, тиешле рәвешен китереп эшкәртелгән кырлар, юл читләрендә ләпердәп утырган яз киленнәре — яшь каеннар — һәммәсе бүген Сабит Йосыф улы Нургалиев файдасына хезмәт итәләр! Хәзер Нәҗип сүзне өзмәсен, сораштырсын, кат-кат кызыксынып төпченсен, аның һәр соравына җавап бары тик Сабитның дәрәҗәсен күтәрәчәк, абруен ныгытачак.

Нәҗип абыйсының мактанырга атлыгып торуын аңлады, максатын гына башына китерә алмады. Сабит көче-егәре, башкарган зур эшләре белән аны аста калдырырга тели, дип уйлады.

«Кайтып җитәбез!» — диде Сабит күңелсезләнеп, юл, көзгедәге манзара аңа нык охшаган иде... Юлдашлар, иелә төшеп, алга, сузылып яткан буш, туры юлга карадылар. Күз күреме җирдә авыл шәйләнде, шифер түбәләр, түбәләрне каймалаган уйдык-уйдык биек агачлар күренде. Түбәләрдән һәм агачлардан биек-биек булып авыл өстендә сәер бер канат оча иде. «Нәрсә бу?» — дип сорады Нәҗип көлемсерәп. «Ашыкма!» — диде Сабит, күкрәген алгарак чыгарып. Теле ачылган Сабитның бу юлы өзеп җавап бирмәве, «күк әкәмәтенең» болытларга тия язып тирбәлүе кунакларның һушын алды. «Әллә күктә җилкән йөзә инде?» — дип сорады Наилә. Юл буе шым утырган, барлыгы да беленмәгән Әхмәтзыя бу юлы чыдамады: «Әләлә!» — дип куанып ычкындырды. Аның хикмәтле җилкәнгә башаягы белән табынуы шушы бер ымыннан мәгълүм булды.

Моңарчы үзләрен гашыйк иткән каеннар онытылды, уңга, ябык, киң ындыр табагына, йөзләрчә машиналар саф-саф тезелгән асфальтлы мәйданчыкка кунаклар әйләнеп тә карамадылар, күзләр, бер булып, каядыр омтылган сихри җилкәнгә текәлгәннәр иде. Җилкән очып та, йөзеп тә китмәде, юлаучыларны мәрхәмәтле канаты астына алырга җыенгандай, һаман якынлашты. «Рәсем ич бу, гап-гади сурәт!» — диде үткен күзле Наилә. «Рәсемен рәсем, әмма гади түгел! — диде тирән ышаныч белән Сабит. — Күрерсез! Карагыз!»

Нәҗип тә аермачык күрде, тирә-юньнең иң биек байрагы булып аларга каршы Леонид Брежневның портреты йөзә иде. «Нинди зур!» — диде сокланып Наилә. «Биеклеге төгәл утыз биш метр!» — диде куанып Сабит. «Ничек җил бәреп төшерми аны!» — дип сорады шаккаткан Нәҗип. «Йөз дә кырык ике мең сумга төшкән очкычпортрет җилгә баш бирәме? Белгечләр исәпләп чыгарды, иң каты давылларда, штормнарда да исән-аман калачак. Ә штормнар безнең якта булмый да булмый. Тыныч якта яшибез, шөкер! Әле иң гаҗәбе анда түгел, алда — чак кына сабыр итеп торыгыз!»

Хикмәтле рәсемгә якынлашкан саен машина акрынайды һәм, ни гәҗәптер, якынайгач та, янынннан узып барганда да Брежнев калын кашларын күтәреп, аларга туп-туры карап тора иде. Инде үтеп тә киттеләр, чаттан борылыр вакыт җитте. Сабит серле кыяфәт белән:

«Борылып карагыз тизрәк!» дип ашыктырды. Борылсалар, Брежнев һаман аларга йөз белән тора иде. «Ни бу? Нурларны кисештердегезме?» — дип кызыксынды Нәҗип. «Сихер!» — дип куанды Наилә. «Юк ла! — дип тантана итте Сабит. — Хикмәт шунда: рәсем үз күчәрендә йөз сиксән градуска борыла торган итеп эшләнгән! Менә сере кайда! Аны мин уйлап таптым. Ярата безнең хуҗа монда килергә! Аны рәсем янынннан дүрт-биш тапкыр үткәрәбез. Кая барса да артыннан ил хуҗасы, партия юлбашчысы күз атып, дәртләндереп кала. Шәп уйланганмы? Рәссамны дәүләт бүләгенә тәкъдим итәргә җыенабыз. Казаннан худфондтан белгечләр чакырып китердек, бер атна ял итеп, фикер алышып яттылар. Премиясез калмабыз дип ышанам. Игеннәрнең торышы, күрдегез, һәйбәт, көзгә, боерган булса, Леонид Ильичның үзенә чакыру җибәрәбез. Күрсен татар халкының мәхәббәтен!»

Наилә эчкерсез аһ итте, ул беренче ишарәләреннән үк Сабитны нык куллы хуҗа, киң колачлы лидер, сүзен кайда да сүз итә алырлык гайрәтле олпат ир дип таныды. Соклануын һич яшереп тормады, Сабитның әйткән һәр фикеренә йә кашын уйнатып, йә көлеп, кул чабып, һич югында күз нурларын мул түгеп, соклануын, хуплавын һәм бәхетле булуын белдерде. Сабитка әнә шул гына кирәк тә! Ул тигез, кирәк чагында мамыктай йомшак тавышы белән һаман Наиләне сихерли, яшь хатынның туймас күзе кай ноктага төшсә дә, үзен югары күтәрерлек дәлилләр таба, хатынны үзенә таба тарта иде. Абыйсын күптәннән күргәне булмаса да, Сабитның яшь чактан ук һавалы, комсыз һәм әрсез икәнен онытмаган Нәҗипнең күргәннәренә әллә ни исе китмәсә дә, алдагы вакыйгалар аны да иләс-миләс ясады.

Машина сигнал бирә-бирә урам буйлап рәхәтләнеп тәгәри, тыкрык башы тутырып утырган ишле бәбкәле казлар каңгылдашып аңа юл бирделәр, тамак төбе белән эндәшеп, бәбкәләрен читкә чакырдылар. Чаттан борылгач, уң якта балкып күренгән, зур кызыл кирпеч бина универмаг икән, аның ишек катында тәмәке пыскытып торган милиционер, төпчеген ыргытып, үрә катып машинага честь бирде. Машина күренгәч, кибет эчендәгеләр дә этешеп-төртешеп урамга чыгып сибелделәр, бөгелә-сыгыла машинаны озатып калдылар. Мондый олы хөрмәт Наиләнең күңелен нечкәртте, күңелле каршылаудан аның күзендә яшь күренде. Ә машина Кызыл мәйданда парад кабул итәргә чыкканмыни, урамның нәкъ урта сызыгыннан тавышсыз гына тәгәрәде. Ишегалларында, капка төпләрендә нидер эшләп йөргән кешеләр, йөз белән борылып, Сабитка бил бөктеләр, кулларын күкрәктә кушырып рәисләрен сәламләделәр.

Сабитның шушы хәрәкәткә исе китмәве, кырын күзен дә салмыйча төп-төз утырып баруы Наиләнең күңелен аерата нечкәртте. Ул, ихтыярсыз хәлдә, каршылаучыларга кул болгап, рәхмәт укып барды. Аның үзенең бер чакта да игътибар үзәгендә булганы, шундый татлы бәхетне татыганы юк иде.

Урамның ике ягыннан җитешлек белән салынган зур-зур өйләр, төзек каралтылар, төрле шәкелдәге янкормалар, өйалларын, верандалар озата барды. Кыйшайган капка да, купкан койма тактасы да юк, һәр тарафта ныклы хуҗа кулы, хуҗа барлыгы сизелә иде. Капка түбәләренә ал байраклар кадалган, стеналарга, коймаларга аллы-чуарлы өндәмәләр ябыштырылган иде. «Сездә бер-бер бәйрәмме әллә?» — диде Нәҗип аптырап. «Бездә һәр көн бәйрәм, — диде горурланып Сабит. — Сез, хөрмәтле кунаклар, коммунистик татар авылына килдегез!»

Тирә-яктагы бөтенлекне, төзеклекне тамаша кылып килә-килә, Нәҗип як-ягын үз авылларындагы ташландык урам-тыкрыклар, керсәң чыга алмаслык юллар, бетәшкән өйләр, адәм тәганәсенә әйләнгән чирле эти-әнисе белән янәшә куеп карады.

Ул арада машина җиз кадак түбәләре белән мул бизәлгән биек һәм киң капка каршысына килеп җитте, тукталмады, капка үзеннән-үзе ачылды, алар Олы көн сагасы тәгәрәтеп уйнарлык тип-тигез, йоп-йомшак чирәм калкынган киң ишегалдына килеп керделәр. Эчтә, капканың ике ягына, ике кеше баскан иде. Берсе, агач аяклысы, капка ябарга тотынды, икенчесе, озын итәкле халат кигәне, какчарак, зифа буйлы хатын, машинага таба бер-ике адым атлады. Дүрт ишектән дә җиргә төштеләр. Хатын Наиләгә якын ук килеп, күгелҗем вак җыерчыклар белән мул каймаланган күзләрен зур ачып, дога укыгандай җитдиләнеп карап торды да озынча, ябык бармакларын җилпәзәдәй таратып кулын сузды. «Сез, мөгаен, минем килендәшем буласыздыр инде?» — диде. Наиләнең юл буе исертеп килгән тойгылары сүрелмәгән, мәхәббәт балкышы кимемәгән иде, ул, килендәшенең кулын әләктереп алып, аны күкрәгенә кысты. «Менә дөнья, килендәшләр үзебез, ә күрешә алганыбыз юк», — диде ул кайнарланып. «Сөмбелә минем исемем!» — диде хуҗа хатын. «Миңа Наилә дигән исем кушканнар, исемемне яратам», — дип көтмәгәндә чытлыкланды Нәҗип хатыны.

«Рәхим итегез, кадерле кунаклар,— диде Сөмбелә.— Юынып алырсыз, аннан тамак ялгарбыз, ачыккансыздыр. Чәем әзер».

Алар өр-яңа диярлек чуар палас җәелгән болдырга менеп, кырып ясалган баганалы култыксаларга ябыша-ябыша текә баскычтан икенче катка күтәрелделәр. Йорт эчендәге калын-калын затлы келәмнәрдән, хуш истән Наиләнең җиңелчә башы әйләнде, киленен күзеннән ычкындырмаган Сабит шундук аның беләгеннән әләктерде, кулы Наиләнең янар таудай ут атып торган күкрәгенә тиеп китте. Аларның йөзләре якынлашты. Сабит белән Нәҗипнең йөз сызыкларында охшашлык шактый булса да, туганнарның күз карашы бөтенләй үзгә, бүтәнчә икән. Сабитның күзләре утлы күмер булып яналар, аларның тирәнлегеннән әллә нинди куркыныч, шомлы нурлар агыла иде. Көтмәгәндә, Сабитның калынча, нык уелган иреннәре: «Мин сине ашарга телим!» — дип пышылдады.

Әллә өнендә ишетте моны Наилә, әллә бер мәлгә саташуы булдымы, сизми калды...

## 22

Нәҗип белән Наиләне гаҗәпләнергә мәҗбүр иткән ике нәни генә вакыйга булып алды. Иртәнге чәйдән соң хуҗалар, Сабит белән Сөмбелә, «Сезне әзгә генә ялгыз калдырырга туры килә, авыл кешесенең шул, бетмәс эш инде...» — дип, икесе ике якка бер-бер артлы чыгып киткәч, ике малай, Искәндәр белән Рөстәм, әниләренә килеп асылындылар. «Кайчан китәбез инде?» — диде Рөстәм шыңшып. «Кайтыйк бабайларга!» — дип кат-кат инәлде Искәндәр. Ата белән ана ни уйларга белмичә югалып калдылар. Хуҗалар шундый бай, юмарт, киң һәм ачык күңелле, алып килгән күчтәнәчләрне әз булса да зур итеп кабул кылдылар, кат-кат рәхмәт укыдылар. Йоклаган урыннары ханнарныкы кебек, ашаган ризыкларын сөйләп, мактап бетерермен димә, ә алар, маңка сарыклар... «Кайчан моннан китәбез?!» имеш...

Дөрес, кичә дә бер вакыйга аларны сискәндергән иде. Кичке мул чәйдән соң, күп санлы утлар яктырткан ишегалдында аш сеңдереп йөргәндә, капкадан йомры бер хатын-кыз килеп керде дә: «Сабит Йосыпович, иртәгәге көндезге рейска алдым. Икесе зурларныкы, икесе балаларга!»,— дип, председатель кулына самолет билетлары китереп тоттырды. Моңарчы бер дә читенсенмәгән, кыенсынмаган, кай тарафка сүзе керсә дә, кыюлык, белем, фикер күрсәтә алган мәгърур хуҗа бер мизгелгә югалып калгандай булды. Сабитны аңларга бик

теләгән Наилә генә түгел, Нәҗип тә моны сизде. Сабит хатынга күзен алартып карады да, билетларны вак-вак кисәкләргә ерткалап, почмактагы чиләккә илтеп сипте. Хатын баскан җиреннән юк булды, аны күрми дә калдылар.

Бу хәлне йомшак караватта юка мамык юрган астында йокларга әзерләнгән Нәҗип хатыны белән уртаклашмакчы иде, әллә ничек онытты, кичке аш алдыннан эчелгән кыйммәтле француз коньякларының тәэсире булдымы, кәеф шәп иде, күңелсезлекләрне искә аласы килмәде.

Хәзер, хуҗаларсыз аулакта, ике малай ике яктан бабайларга кайтуны дауларга тотынгач, алар йомры хатынны, ертык билетларны, билетларның бүгенгә икенче рейска алынган булуын да хәтергә төшерделәр.

Наиләнең тагын бер җитди шиге бар иде, ул аны, кәефен бозмас өчен, иренә әйтмәскә уйлаган иде, хәзер, шик төшкәч, анысын да ачып салды. «Иртән, хуҗалар йоклаган бүлмә кырыннан үтеп барам, ишек ярым ачык, эчтә сөйләшәләр... «Тагын урман азгынлыгын оештырасыңмы? — диде Сөмбелә.— Тагын котырасыңмы?» Ә Сабит абый бер генә җикерде: «Молчи, дура!»

Кунакларны шиккә салган вакыйгалар өзек-өзек һәм бик нәни иде, алай да, иш янына куш өстәлгәч, алар бер булып җепкә тезеләләр һәм бай хуҗаларга килгән ярлы кунакларның кәефен кырдылар.

Малайлар, әти-әниләрен хафага салуларын уйламыйча, һаман: «Бабайларга кайтыйк!» — дип кабатлыйлар иде. Тавышлары өйгә сыймый башлагач, текә баскычтан җитәкләп төшеп, аларны иркенлеккә — ишегалдына алып чыктылар. Наилә йортның арт ягыннан, эчкәргедән чыгып килүче хатынны абайлады. Ул, кунаклар белән ашыгыч кына исәнләште дә, бигенә ачык йозак эленгән таш амбарга кереп китте. Нидер ниятләп Наилә аңа иярде, артыннан керде. Хатын каушаган кыяфәт белән сүзсез басып торып аны каршылады. «Сез бу йортның кеме буласыз?» — дип сорады Наилә турыдан-туры. Хатын тиз җавап бирмәде, уйланып торды. «Ашчы булам мин»,— диде ул ишетелер-ишетелмәс кенә. «Ашчы? — диде гаҗәпләнеп Наилә.— Ике балалары тиң Зәйдә укый, монда ике җанга махсус ашчы тоталармы?» Ашчы хатын кунакның исемен белә икән. «Ай, Наилә җаным, Сөмбелә апаның түре буш торамы? Көн аралаш кунак ич алар-да!» Наилә җайлап кына кунакларның каян килүен, кемнәр булуын сораштырса да, ашчы башын чайкады. «Минем эшем учак янында. Бүтәнен белмим»,— диде. Әңгәмәне өзеп, ишек тоткасына ябышты, алъяпкыч астына кыстырган нәрсәсен (шешә булды, ахрысы) яшереп, шәүлә кебек, өй артына кереп югалды. Каяндыр, лапас астыннан кичәге агач аяк күренде, иске малахаен салып сәлам бирде. Уң як чигәсендәге тирән җәрәхәт эзен томалар өчен бүрек кигәндер, ахрысы... Сәлам биргәннән соң, сөйләшмәде, кунакларны күздән дә югалтмады, ары-бире йөреп, әле аннан, әле моннан килеп чыга торды. «Әллә күзәтә инде?» — диде Наилә шигәеп. «Шикле шикләнер, чикмәнен бөркәнер»,— диде Нәҗип аны котыртып.

Хуҗалар кайтмады. Нәҗип Наиләгә, Наилә Нәҗипкә аптырап караштылар, балалар юк-бар уен табып, әз-мәз мавыгып киттеләр, бабайларга өндәү онытылып торды. Ул арада болдыр башына чыгып ашчы хатын аларны чәйгә чакырды. Чәйне теләр-теләмәсрәк эчтеләр, эчләре нык ук поша иде. Чәйдән соң диваннарга таралып кырынярын ятып алдылар, йокы килмәде. Йокы һәм тынычлык качкан иде. Ярый, язгы чәчү бетмәгән, Сабитның вакыты да булмасын, ди. Сөмбелә нигә юк? Нигә күзгә-башка күренми? Иртән дә юньле-башлы сөйләшмәде, тырт та пырт, койрыгын чәнчеп чыгып югалды. Аның «Тагы урман азгынлыгы оештырасыңмы?» — дигән сүзе ни аңлата?

Ашчы да, агач аяк та бүтән күренмәделәр. Нәҗип икенче кат ишекләренең бикле булуына игътибар итте, тартып-тартып карады, ишекләр нык һәм тыгыз бикләнгән иде. «Әйдә, урамга чыгабыз!» — диде ул кинәт. «Дөрес! — дип сикереп торды Наилә.— Инеш буена төшәбез, зиратларын әйләнеп чыксак та ярар». «Нигә зират?» — диде җәберсенеп Нәҗип. «Зират урманы дөньяда иң моңсу урман, ә хәзер минем күңелем моңсу».

Менә, аңла син хатыннарны! Ишегалдына чыгып капкага таба баралар иде, лапастан баягы төксе карт — агач аяк килеп чыкты. Ул кулын артка куеп сүзсез генә аларга текәлде. Капка бикле иде, алар сорау белән аңа карадылар. «Өйдә генә торыгыз, — диде карт, шактый нык тавыш белән.— Көтегез!»

Берни эшләр хәл юк, кунаклар тагын икенче катка менделәр, газета караштырган булып беркавым утырдылар. Астан яңгыравык аяк тавышлары ишетелде, хуҗа кайтып килә, ахрысы, бүтәннәр текә баскычтан алай шак-шок менә алмас... Чыннан да, ишектән шат чырайлы, өр-яңа костюм кигән, ап-ак күлмәген килешле галстук белән бизәгән хуҗа килеп керде. Киң тәрәзәдән төшкән кояш нурында ул башка бер дөньядан килгән сихерле зат сыман күренде. «Җыеныгыз!» — диде ул кыска гына.

Чакыру идеме бу, катгый боерык булдымы, кунаклар аңышмадылар. Нәҗип кыяр-кыймасрак: «Кая барабыз?» — дип сорады, Наилә бөтенләй коелып инде. Сабитның каралҗым сөрмә белән каймаланган ач күзләре аны үтәли тишеп-тишеп тикшерәләр иде. «Урманга!» — диде ул, кунакларны ашыктырып. Нәҗип кабыл-тибел балаларны киендерергә кереште, моны күргән Сабитның чырае сытылды. «Балалар кала,— диде ул һәм тамак төбе белән: — Бәдәр!» — дип кычкырды. Баягы хатын юк җирдән бар булды, кушканны көтмәде, балаларны җитәкләде, колак авырттыра торган ямьсез тавыш белән боргаланырга, юхаланырга тотынды. «Әйдәгезче, былбылларым... Мин сезне бер җиргә алып барыйммы, алтын алмаларыма керпе күрсәтимче... Бакчада аларның оясы! Керпе белән тәмле кәнфитләр ашарсыз!»

Еларга ачылган авызлар җыелды, төчеләп-юмалап Бәдәр малайларны ияртеп чыгып китте. Нәҗип белән Наилә сүз катарга да өлгермәделәр. «Безгә уникедә анда булырга кирәк! — диде Сабит, кунакларның ыкы-мыкы торуларын өзеп. — Ашыгыйк!»

«Волга» бүген ишегалдына кермәгән, ул капка баганасына бәйләнгән ялкау ат сыман, тын гына аларны көтә иде. Биргән сәламнәренә Әхмәтзыя җавап кайтармады, ул алга карап, еракка текәлгәндәй нидер уйлый иде. Җаваплы кешеләрнең шоферы ни уйлаганны кем белгән? Утырыштылар, ишекләр ябылды. «Ә Сөмбелә?» — диде Наилә, тез астына итәген җыештырып. Сабит: «Узышлый кереп алырбыз,— дияргә уйлаган җиреннән.— Ул бүген бара алмый»,— дип ычкындырды.

Наилә ике ут эчендә калды, Сабитның: «Мин сине ашарга телим!» дигән сүзе шаяру булмыйча, шушы көтелмәгән сәяхәткә барып тоташса, ни кылырсың? Ул машинадан атылып чыкканын сизми дә калды, иренең таләпчән, чәнечкеле күз карашы гына кире борылырга мәҗбүр итте. Абый белән эненең татулашуын Наилә үзе тели түгелме? Хәзер киреләнеп, ике араны бозып ташласа? «Сөмбелә дә барса икән!» — диде ул көч-хәл белән машинага утырып. «Безне көтәләр!» — диде Сабит. Наиләнең кирегә суктырып маташуы аңа бер дә ошамады. «Тәртә арасына кергәне юкмы әллә бу кырыкмыш тайның?» — диде ул күңеленнән, җене котырып.

Әле кичен генә Сабит Йосыф улы Нургалиев бөтенләй бүтән кеше иде. Сөмбеләнең Нәҗип белән Наиләне әчкерсез, чын күңеленнән каршылавы аның да йөрәген җылытып җибәрде. Өй арасы эшлә-

реннән күптәннән аерылган хатынының гади, әмма акыллы аңгәмәсе, туганнары алдында Сабитны олылавы, этле-мәчеле яшәүләрен бер ым белән дә сиздермәве онытылып беткән хисләрне яңарткандай булды. «Күр син аны! — дип уйлады Сабит. — Без юньләп аралашмый торган арада бу хатын нык ук үзгәргән ләбаса! Сүзләрен тыңла — акыллы сукалый! Игътибарлы, тыңлый белә, алга чәчрәп чыкмый — тыйнак. Бер үк вакытта үз дәрәҗәсен төшерми, вакланмый, тормышның чүп-чарын теленә кертми, күбрәк дөнья иминлеге, балалар, аларның киләчәге турында сүз алып бара!»

Эзи белән авыл юлында күңеленә хуҗа булып өлгерә язган вәсвәсәләреннән Сабит оялып ятты, салган баштан, йокылы-уяулы хәлдә Сөмбеләсенә җылы сүзләр ычкындырды бугай...

Килгән олы, затлы кунакларны өй сые белән генә сыйлый торган кеше түгел Сабит, ул еш кына аларны аулак урман аланына алып менә, мәҗлеснең шәбе, кәттәсе әнә шунда кеше күзеннән читтә уза. Моңарчы Сөмбеләнең урман аланын күргәне дә, учак күмерендә пешкән куырдыклардан, кош итләреннән, билдәмәләрдән авыз иткәне юк. Нәҗипне урман аланына өндәр, дип Сөмбеләнең башына да килмәде, Сабитыннан күргән саран җылылыктан эреп, онытылып йоклап китте. Төн уртасында ул йокы бүлмәсенә янәшә кабинеттан килгән тавышка уянды. Сабиты телефоннан кемгәдер эш куша иде. Ишекләр кысып ябылган булса да, иренең тавышыннан, ярым-йорты ишетелгән сүзләрдән Сөмбелә аңлап алды: Сабит Нәҗип белән Наиләне югары дәрәҗәдә кабул итәргә җыена икән!.. Инде бу юлы да Сөмбеләне нәүмиз итеп калдырса... Ул аяк очларына гына басып килгән иреннән: «Мин дә бараммы анда?» — дип сорады. Сабитның сүзсез килеп ятуыннан Сөмбелә барысын да аңлады. Тик бер нәрсә караңгы иде: якын туганнарыннан да хатынын яшерә икән, ни уйлый бу Сабит? Сөмбеләне калдырып ниләр майтармакчы була? Гайбәт йөри, Сабит хатын-кызларны шунда чеметкәли икән, дигән хәбәрләр килеп ирешә... Ярый, шулай да булсын ди, азынсын да ди... Нәҗип-Наилә янына нигә сыйдырмый ул Сөмбеләне?.. Таңга кадәр тырпылдап ятты хатын, таң алдыннан соравын тагын кабатлады, ире: «Молчи, дура!» — дип мыгырдагач, өмете өзелеп, сөмсере коелып икенче бүлмәгә, аулакка чыгып китте.

Сабит туктаусыз икеләнә иде әле, иртәсе дә килә Сөмбеләне, күңеленең төпкелен ниндидер корт та кимерә... Эзи юлында уйлаган вәсвәсәле уйлары кайта-кайта хәтергә иңәләр дә аның туймас җанын котырталар, моңарчы татымаган рәхәтлекләр вәгъдә итә иде. Иртәнгә кадәр ул төпле генә карарга килә алмады, идарәгә баргач кына, төнлә йокылы-уяулы биргән боерыгының үтәлә башлавын хәбәр иттеләр. Сугымчылар пычакларын үткенләп, бүгенге тантанага багышланган малларны машинага салып урманга киткәннәр булып чыкты. «Иртәләгәннәр! — дип сукранды ул үз-үзенә. — Андый эштә иртәләмичә дә ярамый бит», — дип өстәде.

Асфальт көндәм чыжтырдады, мәһабәт җилкән яныннан үткәндә йөреш тагын тыйлыкты, болытларга үрелгән Брежнев сәяхәтчеләрнең оешып бетмәгән төркемен калын кашлары белән хуплап, түшендәге алтын йолдызлары белән яктыртып озатты...

Эзи юлына чыкмадылар, машина кинәт кенә сулга каерылды, челтәрле тимер култыксалар белән бизәлгән таш күперне кичтеләр. «Колхозның утыз биш еллыгына салдык. Рим легионнарын, Гудериан танкларын чыдата торган күпер. Илдә бер, ачылышына Казаннан, Чабаксардан вәкилләр килде».

Моннан соң очраган һәр корылма, һәр бина нинди дә булса юбилей шәрәфенә җиткерелгән булып чыкты. Машина авылны, Брежневка «Җиңү» ордены тапшырылу уңаеннан төзелгән таза ферма

каралтыларын, акташ икмәк амбарларын артта калдырып, тауга үрләде. Сабит галстугын чишеп, күлмәк сәдәфен ычкындырып җилләде, Наиләгә борылып карады — аның күз карашы таркау һәм шактый мәгънәсез иде... Күңеленә шик-шөбһәләр килә-китә башлаганда Сабит машинаның кош булып очуын ярата иде, бүген дә Әхмәтзыяга ым какты, машина әкияттәге тулпар булып алга ыргылды, әһ дигәнче куе, нәфис яшеллеккә төренгән урманга барып керделәр. Урман авызында, дәү төп өстенә утырган милиционер сикереп торып честь биреп калды.

Машина язгы дым таралып өлгермәгән юлга төште, монда асфальт җәелмәгән, уңда, авыл өе сыярлык чокырда эрер-эремәс ала сыер тиресе булып кар ята, борыннарга әчкелтем яфрак исе, язгы яңарыш, тереклек исе килеп бөркелде. «Кошлар кайтты,— диде Сабит җанланып,— кошлар көньяк белән төньякны ялгадылар. Кош кунгач, корыган агачка да җан керә!» Шулай диде дә тагын Наиләгә сөзеп карады.

Моңарчы Нәҗипнең көнләшкәне дә, Наиләнең көнләшерлек сәбәп чыгарганы да юк иде, бүген, абыйсының Наилә белән гадәттән тыш мавыгуын абайлап, йөрәге сызланып алды.

Озак бармадылар, машина түгәрәк дип әйтерлек аланга барып кереп туктады. Алан тирәли яшь каеннарга аралаштырып чыршы утырткаННар. Каеннарның бәбкә йоны кебек йомшак, хуш исле, балавызлы яфраклары чыршыларның серле куелыгы белән аралашып, һәр күңелгә барып җитә торган илаһи матурлык хасил иткән иде. Машинадан төшкән кунаклар бу юлы хуҗаның өндәвен көтмәделәр, «Бар шул дөньяның гаҗәп почмаклары!» — дип, беравыздан аһ иттеләр. Нәҗип белән Наилә урманда кунаклар күп булыр дип көткәннәр иде, алай булмады, аланның бу башында кеше-мазар күренмәде. Бераз күз ияләшкәч, алар аргы башта иелеп нидер эшләгән ике кешене, алар янәшәсендә кабыныр-кабынмас төтәгән учакны абайладылар. Ике ирнең берсе, эшен ташлап, җитез генә юртып Сабит янына килеп җитте һәм гаепле кыяфәт белән: «Һәммәсе дә әзер булыр, Сабит Юсупович, килерегезне тәгаен белмәдек шул!» — дип, хуҗага күтәрелеп багарга кыймыйча әмер көтеп калды. «Киләсебезне үзем дә тәгаен генә белмәдем шул!» — дип уйлады Сабит, ниятен бер сүз белән беркетте: «Ашыгыгыз!» Килүче ирмән егете елдам китеп барды, аның җиленнәнме — учак дөрләп яна башлады, яз исенә кушылып, алан читләренә каен тузы исе таралды.

Сабит егетләрчә җитез кыланып пиджагын салды, аны ботакка элде, галстугын чишеп кесәсенә тыкты, җиңнәрен сызганды. Аның күңелендә өлгереп җиткән бер уе да юк иде, сүз юктан сүз булсын өченгә, аланны мактарга тотынды. «Да-а, аланыбыз дөньясында бер! — диде ул. — Килер заман, алан уртасына мәрмәр багана бастырып, монда булып киткән бик күп мәшһүр затларның исемнәрен язарлар!» «Кызганыч, — диде Наилә чытлыкланып.— Алар арасында без булмабыз шул!» «Сез, Наилә килен, исемлекнең башында торырсыз!» «Минем хатынның дәрәҗәсе арта!» — диде Нәҗип көлемсерәп. «Чөнки, — дип аңлатты Сабит,— бу аланда синең кебек чибәр хатынның булганы юк иде». Наилә кызарып пешеп чыкты, артык төче бәйдән Нәҗип тә уңайсызланды. Сабит үзе дә бер ара сүзсез калды: «Нишлим мин? — дип әченнән сүгенеп алды.— Нигә кычкырып мактарга иде? Энекәшнең хатыны лабаса ул! Хатыны!»

Шулай уйласа да, күзе чалмабаш чәчәге өзәргә иелгән Наиләнең түшенә, күлмәк ерыгына төште. Ашыгып читкә борылды Сабит, нидер исенә төшкәндәй маңгаена учы белән сукты, башын кагып кунакларга үз артыннан барырга боерды. Алар дөрләп, әссе бәреп торган учакны, түбәләмә ит тутырган табаклар, эреле-ваклы казаннар янында тыз-быз килгән ике ирмән егетен үтеп, арырак киттеләр һәм көмеш су тулган түгәрәк күл янында телсез калдылар. «Коръәндә

адәм улларының иң зур хыялы — су! — дип кычкырды Сабит.— «Түбәндә, елгалар шаулап аккан үзәндә», диелә анда. Ә без фәкыйрьләргә алан читендәге шушы түгәрәк күл дә җитеп ашкан!» Иелде дә кулы белән күл суын уятып, дулкыннар чупылдатты.

Аланда төрле шөгыль, төрле һөнәр ияләре булып китеп, аларның һәрберсе Сабитның яшәешенә, теленә, кыланышларына нидер өсти иде, рәиснең хәтере шәп, сеңдереп, отып алырга гына тора. Беренче күргәннәр, әз-мәз аның репертуары белән танышкач, Сабитның белеменә, теле җорлыгына, фикер кыюлыгына хәйран калгалыйлар иде. Бүген ул гадәттәгедән дә хәтәррәк сөйләшә, сүзе белән кунакларын күмеп ташлап, әкрен-әкрен үз ихтыярына буйсындыра бара иде. Сылу килене генә түгел, бала чактан абыйсына баш бирмәскә гадәтләнгән энесе дә аның кемлеген, агачында өлгергән җимешләрне күрсен!

Ул әрмән егетләренә тагын бер күз салып алды, ул яктан ымшым булмагач, тагын сүз йомгагын сүтәргә тотынды.

«Кабатласам, кичерерсез! Районның гына түгел, Татарстанның оҗмахы монда! Оҗмахның мөдире каршыгызда. Оҗмахта кыска арада булган бәхетләләр яшәүнең рәхәтлек мәгънәсен монда аңлап китәләр. Мондагы минутлар аерата хатын-кызлар өчен истәлекле була. Ни әйтсәң дә, тормышның бихисап мәшәкатьләре, очсыз-кырыйсыз ыгы-зыгысы аларның асыл иңнәренә төшә. Батыр ирләрнең куллары гына ятырга тиешле кайнар иңбашларында нужа арбасының эзләре ята. Тормыш хатын-кызларыбыз өчен әлегә бик авыр. Шуңа күрә форсаттан файдаланыгыз: оҗмах монда, монда! Бутәненә өметләнмәгез! Тагын бер мәртәбә кисәтәм: мин сезгә оҗмах ишеген ачам!»

Сабит басып торып, ике кулын чайкый-чайкый сөйләде. Нәҗип белән Наилә йомшак кабарган үләнгә утырып аны тыңладылар. Ике сүз генә әйтергә җыенган Сабит, өйрәнелгән гадәте буенча, тыела алмыйча шактый кайнар нотык сөйләп ташлады.

«Ничек бу дәрәҗәгә ирештең? Илнең хәле мөшкел чакта оҗмах төзер өчен бик зур көч-куәткә ия булырга кирәк ич! Колхозларның язмышы мәгълүм — таралырга тора алар! Ә син оҗмах дисең!»

Нәҗиптән шул сорауны көткән Сабит, сорауга сорау белән җавап бирде: «Кайсы мәгънәдә сорыйсың? Матди якны күз алдында тотасыңмы, әллә мораль як кызыксындырамы?» «Ике як та!» — диде өзеп Нәҗип.

Сабитның күләгәсе су өстендә тирбәлде. «Матди якка килсәк... Берегез минем кан кардәшем, икенчегез сылу киленем, кадерле кунагым. Монда сөйләшкәннәр монда калыр, дип ышанам. Эзләгән егет кулына мал төшмиме, Нәҗип туганым?! Нефтьчеләр белән арадашлыкны көйләп җибәрдек дигән идемме? Шул! Күр инде, Татарстан илгә миллионарча тонна нефть бирә. Нефть ведомстволар, министрлыклар, кыскасы — Мәскәү абзаң кулында. Ә алар... безнең җирне көпә-көндез кычкыртып талый! Татнефтьтә курчаклар утыра, рәттән! Татарстанга ни кала? Безгә? Шушы җирдә яшәүчеләргә? Белмәсең, башың чайкама! Беләбез! Нефть безнең басу түрендә табылгач, мәсьәләне кабыргасы белән куйдым мин. Генеральный директор белән шушы аланда икәүдән-икәү сөйләштек. Һәм безнең җирдәге скважиналарны, минем үтенечне тыңлап, консервацияләделәр. Тыңламый карасын: кем депутат итте генеральныйны?! Кем? Мин! Хәзер хәзинә безнең кулда. Татарстан файдасына хезмәт итүче җир тишеге миндә! Кирәк чакта ачабыз без аны, җир маен алабыз. Кирәк кадәр генә чыгарабыз. Бездән тыш тирә-күрше хуҗалыклар, район үзәге, больница, мәктәпләр, фермалар — һәммәбез бушлай нефть ягабыз. Бөтен котельнялар шуңа күчте. Нужара идек ягулык эзләп, тирәякның урманын кисеп бетерә яздык, хәзер рәхәтләнәбез. Ачкыч бездә, сәрмая да безгә ага... «Ә тотылсагыз?» — диде беркатлы Нәҗип.

«Энекәш, энекәш! — дип аланны яңгыратты Сабит. — Син дөньяның ничек һәм кая тәгәрәгәнен һаман белмисең икән! Бабаңнар аны биш былтырдан, хан заманыннан ук аңлаган. «Кул кулны, ике кул битне юа!» — дип васыять әйтеп калдырган. Тукта, мин сиңа тагын бер хикмәт күрсәтим. Күр, тыңла, өйрән, колагыңа киртлә: оҗмахка үтү юлларын абзаңнан отып кал!»

Ул үкчәсе белән кара җир чыгарып кырт борылды, алан аша үтеп, кунакларын урман авызына алып китте. Кергән җирдән түгел, бөтенләй башка юлдан, тар сукмак аша урман кырына чыктылар. «Күрәсезме моны?» — дип сорады Сабит, сөрелмәгән киң генә басу өстенә кулын изәп. Нәҗип белән Наилә, ялгыш сүз ычкындырудан куркып, иңнәрен уйнаттылар. Нәҗип иелеп, яфраксыз шәрә сабакларны учына җыйды, иснәп карады. «Урылмаган карабодай басуы дисәм, сиңа төрттерү буламы?» Сабит көлеп җибәрде: «Өстенә бастың, сыер икәнсең! Инде ник урылмыйча калганын да әйтә алсаң... миннән сиңа бер бүләк!» «Бүләге нәрсә, бүләге?» — дип сикергәләде Наилә, тагын могҗиза көтеп. «Уң колагы үзенә! — диде Сабит, кыяфәтендәге серлелекне арттырып. — Әйтә аласыңмы?» «Юк»,— диде башын кашып Нәҗип. «Белә алмыйсың да! Чөнки без гади кешеләргә хас законнар тоткынлыгында яшәмибез. Сез, кадерле кунаклар, безне коммунизмга чыгарган иң ышанычлы юл чатында басып торасыз...» «Карабодай игүчеләрнең даны таралган бугай... Азнакай тирәсендә игәләрме әле аны?» Сабит тыела алмыйча, бөгелә-сыгыла, күзеннән яшь атылып чыкканчы көлде. Көлеп бетергәч: «Калдау җирнең урманга һәм безнең оҗмах аланына янәшә булуы да сиңа берни сөйләмиме? Юкмы? Алайса әйт, чын ир-атлар бу дөньяда барыннан да бигрәк ни ярата?» Табышмаклардан башы каткан Нәҗип, абыйсының сүз сөрешен, фикеренең очын югалтканга, тәмам исәнгерәде. «Белмим», — диде. «Синең иң яраткан нәрсәң бармы бу тормышта?» «Хатын, балалар, гаилә»... Сары йортның әсире Нәҗип тагын тотлыкты. «Шөгылең бармы синең? Яраткан эшең? Хоббиең? Онытылып, кинәнеп яшәгән мизгелләрең кай чагыңда була?» «Доктор Фаина Марковна биргән сораулар ич!» — дип уйлады таң калган Нәҗип. Каян абыйсының башына килгән болар?

«Балык тотармын дип кайткан идем — күл кипкән. Инеш саеккан, быкырдык сазлыкка әйләнгән». Сабит бу гаепләү сүзләрен бөтенләй ишетмәде, ул урылмаган кыр өстендә тирбәлгән серле рәшәне, җылы дулкыннарда тибрәлгән тургайларны күзәткән булып читкәрәк китте. Нәҗипнең түгел, Наиләнең кызыксынуы шартлар дәрәҗәгә җиткәнен күреп, аңлатып бирде. «Бу карабодай басуын урдырмыйча юри калдырам мин, махсус. Көзлектә беренче яшь кар артыннан ук бу кырларга урман тавыклары, көртлекләр кереп тула. Ә без аяз таңнарда агач ышыгына посабыз да менә чүплибез тегеләрне! Көзен кыр тавыклары, көртлекләр аерата тәмле, ләззәтле була. Миңа ауга Казаннан гына түгел, Мәскәү, Ленинградтан кайталар. Бездәге кебек сусыл итле, хуш исле көртлекләр беркайда юк икән! Хәтта Европада да!

Берзаман нефтьчеләрнең генеральный директоры Кувейт принцын ауга алып килде... Ну, кеше! Кыяфәт — во! Байлык — во! Шулай да кырны күргәч шаккатты! Аудан соң миңа саф алтыннан сәгать, Сөмбеләгә энҗе муенса биреп китте. Миндә, Сөмбелә янында, бер врач эшли, Әсфәндияров аның фамилиясе. Бәлки, колагыңа чалынгандыр, былтыр мин аңа Ленин ордены тактым, Татарстанга депутат иттем. Язып та чыктылар! Әнә шул врач куыра инде көртлекләрне! Телеңне йотасың, валлаһи! Былтыр бездә корылык иде, миндә түгел, районда! Мин сусыз каламмы? Җәһәннәм тишегеннән «фрегат»лар кайтарып, болын-кырларны суга күмдем. Кругка утыз центнер алдык... Бәла килгән хуҗалыкларны карарга Сафуан Саби-

рович килеп төшмәсенме? Уен-муен кеше түгел — чуен муен! Татар-башкорттан хөкүмәт составына кергән беренче кеше! Районның бик күп кырларын списать иттек. Әсфәндияров куырган чучка балаларын, ул ыслаган балыкларны хәзер дә сагынып искә ала икән Сафуан Сабирович! Дөрес, ул чакта көртлек, кыр тавыгы юк иде, әгәр алар да булса, дөньясын умыра идек! Басуларны списать итеп, районны налогтан тәмам коткара идек!» «Ә нәрсә ашарбыз? — дигән шик булмадымы?» Наиләсенең көтмәгәндә кыстырган сүзеннән Нәҗип уңайсызланды. Сабитның бәхәсне, төпченүне һәм каршы килгәнне яратмавын ул төшенгән иде инде. Сабитның гына исе китмәде, ул: «Фи-и, ә Америка нигә яши? Канада? Алар тук чакта без дә ачтан үлмибез!» — дия-дия, кипшергән үлән сабакларын кыштырдатып кыр өстенә кереп китте, балагына ябышкан сырганакларны күргәч, тиз-тиз кире чыкты. Наилә, үзе дә көтмәгәндә, иелеп кайнагасына чалбарын чистартырга булышты. Сабит тагын да ныграк очынды. «Дөньяда иң авыр фән — яши белү фәне. Төрле-төрле кешеләрнең күңелен күреп, күпмесенә сыенып, күпмеләрен сыендырып яшәү, уяулык, осталык, зирәклек сорый. Океаннарда адашу бер нәрсә, кешелек диңгезендә адашмыйча йөзеп кара! Үзең яшәгән җәмгыятьтә дилбегәне кулыңа алырга теләсәң, тәвәккәллек кирәк. Сездән серем юк, сорасам — гаҗәпләнмәгез! Менә син, туганым, калынкаш бабайны яратасыңмы?» Нәҗип мыек астыннан көлемсерәде. «Ул хакта уйлаганым юк!» — диде ул бераздан. «Ник уйламыйсың, уйла! Аның чабата кашын ратканга рәсемен күккә элделәр дип беләсеңме әллә? Түгел! Үз урыным, дәрәҗәм, байлыгым, киләчәгем өчен тырышам! Бары шул гына. Брежнев миңа тими, теләгәнчә яшәргә, хыялларымны эшкә ашырырга җай бирә! Ходай аның гомерен озын итсен. Рәчәйдә бер чакта да мондый иркенлек, рәхәт тормыш булганы юк иде, диләр белгән кешеләр. Заманча яшим дисең икән, туганым, аягыңда сапоги-скороходы, башыңда шапка-нивидимка булырга тиеш. Алары бар икән, табыныңда скатерть-самобранка булыр! Әкиятне чынга әйләндергән заманда яшибез. Һәм аның шулай икәнен хәзер үз күзегез белән күрәсез!»

Алар чыккан сукмакта бая күзгә чалынып калган милиционер күренеп китте. Күренде дә юк булды. «Ягез, туганнар,— диде Сабит,— тиз йөрешле итекләрне киик! Гурген белән Самвел зарыккannардыр!»

Сабит иркәләп кенә Наиләне култыклады. Нәҗип арттан иярде, оҗмах-аланга юлдашларны ашыктырып, борынга куырдык исе килеп җитте...

Кысан, җитешсез тормыштан кинәт иреккә чыккан хатын-кызның күңеле әйле-шәйле яңа фикерләр белән тула, җаны очар кошка әверелә, ул нужа басып торган кара язмышыннан ычкынып күккә күтәрелә, үзен моңарчы изеп, кимсетеп килгән мәшәкатьләргә күктән торып, җирәнеп карый. Наиләнең шундый иләс-миләс чагы иде. Ул бер минутка гына үз ярын — Нәҗибен шушы уңдырышлы һәм тарихи карабодай басуында, ауда дип күз алдына китереп карады. Тарихи китапларда патшаларның, түрәләрнең ау мажаралары хакында укыганы бар иде аның... Иренә тугры яшь хатынның ялгызы гына күккә ашасы килми иде. Ул монда да иптәшлеккә әле ирен сайлады...

Иртә. Таң сызылган. Кырпак төшкән. Дөнья көмештән коелган! Нәҗипнең өстендә кыска кайры тун, аягында җылы, җиңел ботинкалар. Кулында куш көпшәле мылтык, билен гармун күрегедәй патронтаж бизәгән. Иртәнге яраура тезелешеп, ак кар өстенә имза салып сунарчылар бара. Зирәк хатын-кыз аяк киеменнән төшкән эзгә карап та кайсы ирнең кем икәнен белә ала. Бөтенесе бер буйда! Гвар-

диннар! Симез, саллы тәнле көртлекләр йокыдан айнымасалар да, рәхәтләнеп карабодай чүпли! Кыр иркен, урын аулак, хәвеф-хәтәр юк — ак кар өстендә ят эзләр шәйләнми. Аучылар, тыннарын эчкә тартып, кошларга якынлашалар. Ваемсыз көртлекләр ризык җыя, үлем якынлашканын уйламыйлар да!.. Аучыларның күзләрендәге ут таң сызыгы белән кушылып мавыккан кошларга күренми диярлек...

Шушы урында Наиләнең кайнар сулышы бүленде, ул ирен, байтак еллардан холкын, гадәтләрен белгәнгәме, кош аулаучы итеп күз алдына китерә алмады. Юк, юк, мылтык тотса да, кош ата алмас аның Нәҗибе! Ә Наиләнең күктән тиз генә төшәсе килми, фәрештәләр янында ул анда, аллалар тирәсендә! Аның хыялы күкләргә сыя алмыйча тыпрылдый, һәм аның күз алдындагы Нәҗип шәүләсен көтмәгәндә Сабит абыйсы алыштыра. Аны асыл тунлы итеп тә, мылтык аскан итеп тә, бөртеккә алданган кошкайларны берәм-берәм чүкеп торучы итеп тә күз алдына китереп була иде... Бөркет күзләре кысылган, нык бармаклар мылтык чакмасына сытардай сеңгәннәр; гамьсез кошлар, вак кургаш ядрәләрдән түгел, аның күз карашыннан берәм-берәм ак карга тәгәриләр, карабодай сабакларын акка төргән кырпак өсләрендә алсу кан тамчылары чәчрәп кала. Нәҗиптән аермалы буларак, Сабит абыйсының ияге чыгынкырак икән, икегә ярылып тора. Борын да зур һәм саллырак. Иң гаҗәбе: каннан, вак-төяк җәрәхәтләрдән курка торган Наилә бүген чәчрәп-чәчрәп сибелгән кош канын сокланып, сөенеп күзәтә ала, чөнки аларны шушы илнең хуҗасы, азамат ир, көчле, бөркет карашлы, бай күңелле, мул табынлы Сабит Йосыф улы Нургалиев аткан! «Нәҗип Йосыф улы...» — дип бик әйтәсе килә Наиләнең, ләкин иренең исеме бая әйткән мактау сүзләренә ябышмый, хатынның тавышы юк, теле әйләнми, чуалчык, мактаган уйлары тагын Сабит шәүләсенә барып урала. Дөньядагы бөтен мактау, соклану сүзләре килешә Сабит абыйсына!

Аланга кайтканчы Сабитның яхшы корычтан коелган тыгыз иңбашлары әллә ничә тапкыр аңа кагылып алды, ләкин Наилә бу мизгелдә чирканмады, мәсхәрәләнеп читкә тайпылмады, чөнки бу иңнәр аныкы — Татарстанның атаклы депутаты, олпат бер ир Сабит абыйсыныкы. Нигә аның Нәҗибе бәхеттән мәхрүм икән? Ходай туганнарны да тигез яратмаган! Әгәр Нәҗип урынында Сабит булса, кесәсендә диплом йөртеп шәһәрдә торса, ни-нәрсәләргә ирешер иде икән?.. Ә Наилә Сөмбелә белән урынын алышып авылда яшәсә... Сөмбелә кайда икән хәзер? Ни хәлдә?..

Көфер уйлар һәрчак татлы була. Ул уйлар яшь хатынның канатланган гөнаһлы күңелен кайсы упкыннарга илтеп ташлар иде икән — әйтүе кыен, чөнки йөгәнен салган хатын-кызның хыялы чиксез, аның чиген һәм төрлелеген бүгенге көнгә кадәр бер фән дә ачыклап, бер тәгълимат та нигезләп бетерә алмаган.

Алар тәмле исләргә күмелгән сихри аланга кайтып керделәр, Наилә, нурлы күзләрен зур итеп ачып, «аһ!» дип ыңгырашып алды, бу аның гүзәллеккә гыйшкы да, бәхетеннән шашынуы да иде. Сабит туганнарча кайгыртып: «Армадыгызмы?» — дип сорады, Наилә, тигез, энҗе тешләрен кояшта җемелдәтеп аңа карады.

Кичәге гөнаһлы кызыгулар, төнге вәсвәсәләр күңелдән кичкәч Сабит җиңеләеп, чистарып калган иде. Ул Нәҗипкә дә, Наиләсенә дә ачык күз, яхшы теләкләр белән карап, үзеннән дә, оештырган сәяхәтеннән дә бик канәгать иде. Табын әзер, авызга су китереп ахак күмерләр өстендә шашлык кәчәннәре аллана, өстәлгә ниндиен генә оҗмах нигъмәтләре таратылмаган! Кыр тавыклары юк-югын, мәгәр йорт тавыклары ботларын күккә чөеп, авызга кертем, керәм дигәндәй кызыктырып чалкан яталар. «Нигә шушы кадәр ризык? Тагын кем-

нәр киләсе икән? Мондаен рәхәтлекне бозмасалар ярый ла...» — дип хафаланды, сүзсезлекнең рәхәтен тоя барган Наилә. Үтә күренмәле юка телемнәргә туралган каклаган каз. Яшел суган кыякларында чык елтырый. Укроп, петрушка яфраклары арасында алтын беләзекләр булып казылык телемнәре яткан. Эре-эре сөякле дәү-дәү ит калҗаларында пар бии. Сарык кабыргалары алтынсу сихри төсләргә манылган. Наилә түзмәде: «Нигә кунаклар килеп җитми соң?» — дип шыбырдады. Сабит, шонкар кош булып, табын өстеннән күз йөртеп чыкты: «Кунаклар монда, кунаклар без инде. Наилә килен!» — дип көлеп җибәрде. Оҗмах аланга менгән чакларда болай да кәефе җиңел күтәрелә торган Сабит бүген аерата рәхәт хисләргә уралып калган иде. Аерып берәүнең дә хәтерен саклыйсы юк, эш, мәшәкатьләр турында уйлап, кемнедер югары чөеп интегәсе юк, бурычлар, йөкләмәләр, гамь-ваемнар бүгенгә оҗмах-аланнан читтә калган. Үз кәефеңне күреп, үз кадереңне белеп, туганнарыңны сыйлап утыр әйдә бер!

Көяз, кыска мыеклы әрмән егетләренең берсе Наилә алдына мае чыжлап торган шашлык-куырдыкны китереп куйды. Наилә чак төчкереп җибәрмәде, кульяулыгы белән нәфис борынын кысып артына борылды һәм төчкерәсе килүен онытты: күздән калган пәҗегән яфракларны тишеп көнгә үрелгән яшел үлән кылычлары арасында испан ханымнарының җилпәзәсе булып шешәләр тезелеп яткан иде. Коньяклар, аракылар, көмеш башлы шампаннар, шәрапләр. Наиләнең күзе күрмәгән, колагы ишетмәгән дүрткел, озынча, юан бүксәле тәбәнәк шешәләр дә бар иде арада. «Өч кешегә?.. Күбрәк түгелме?» — дип уйлады ул сөенечене шик катыштырып.

Сабит шашлык китергән егеткә каш сикертте, егет күл буена таба кайтты да, алар «ә» дигәнче гаип булдылар. «Әллә сихерле көмеш күлгә чумдымы алар?» — дип сорады Наилә, әгәр шул мизгелдә Сабит абыйсы, Татарстанның тылсымчысы: «Чумдылар шул, төпкә киттеләр!» — дисә, ул аңа да ышаныр иде. Бер тынга аптырашта калган кунакларга Сабит озак уйларга ирек бирмәде, ялт кына шешә ачып, коньякны кинчә төпле, зур бокалларга мул итеп койды да чәкешергә үрелде. «Ягез, туганнар!» Алар киң, озынча өстәлнең ике ягына бүленеп утырганнар иде, Сабит бер яктан, кунаклары аның каршысында. Кыстата-кыстата Наилә чәркәне яртылады, ә Нәҗипкә тамчысын калдырырга да рөхсәт бирмәде Сабит, чәнечке җәпләренә казылык эләктереп икесенә дә кабымлык сонды. Чәркәләр мөлдерәмә тулды. «Беренчесе күрешү шәрәфенә иде, бусы туганлык өчен!» Бу юлы Сабит Наиләне дә өзми-куймый кыстады, чәркәнең төбе ачылганчы, «Бетереп, бетереп! Туганлык җебен ныгыткан-да тамчысын да калдырырга ярамый!» — дип күңелле такмаклап торды. Беренче йотымнардан ук тәненә ут йөгергән Нәҗип икенчесен эчеп куйганын абайламады да...

Бер тын сөйләшмичә ашадылар, тамак кырган, ирен чәпелдәгән тавышлар оҗмах-аланда хуҗа булып торды. Казылыктан ерак далалар, кылган исләре килә иде. Тавыклар мәмрәп пешкән, аның вак-төяк сөякләрен теш арасына кыстырып бер-ике әйләндергәч тә йотып җибәрделәр. Сабит җәдәч сөяген кульяулыгына төреп чалбар кесәсенә шудырды. Нәҗибенең өченчесен дә түңкәйтеп куйганын күргәч, Наилә ымы белән аңа тыелырга боерып карады. Мәҗлес кызды, чәркәләр бер орбита белән күтәрелеп-төшеп йөрделәр, моңарчы боегыбрак утырган Нәҗип майлы иреннәрен йонлач кул аркасы белән кат-кат сөртеп ямьсез хихылдады, чайкалып урыныннан купты һәм ялагай, мескен тавыш белән: «Матурлык өчен! Муллык өчен! Иминлек өчен! Дан өчен! Шуларның барысына да хуҗа булып өлгергән Сабит абый өчен!» — дип кычкырды.

Йә, үзең тост тәкъдим иткәч, ничек эчеп бетермисең ди?..

Наиләнең күзеннән яшь атылып чыкты.

Китте, чәркәнең төбе ачылды, Нәҗипнең башы әйләнде, ашказаны сулыгып ризык сорады. Ул суына төшкән шашлык калҗаларын чәйнәми-нитми генә тамагына шудырды. Мәҗлескә ут капты, түгәрәк алан өчен, көмеш тулган күл өчен, аланны каймалаган чыршы-каеннар өчен, рәхәт дөньяга чыгарган тиңдәшсез юмарт Совет власте өчен, Наиләнең матурлыгы, Сабит белән Нәҗипнең батырлыгы өчен дә йотып куйдылар. Брежнев исеме әйтелгәч, Сабит урыныннан сикереп торды, үрә катты һәм «Юлбашчыбыз, Ленин бабабызның иң ышанычлы шәкерте Леонид Ильичны хөрмәт итмәгән кешеләр чәркәләрендә бер тамчы булса да калдыралар!» — дип кисәткәч, Нәҗип, бер булса да юлбашчыга хөрмәтен белдерергә форсат чыгуыннан файдаланып, чәркәне бер тында йотып бетерде.

Наиләнең күзе маңгаена менде, бер йотты да чәчәде...

Ә Сабит? Аны һич танырлык түгел иде, олысымаклык, тәкәбберләнү, һавалану әллә кая китте, ул яшел үлән кыякларын сытасыта биеде, учларын, шап-шап чәбәкләп, чүгәли-чүгәли аланны йөз әйләнде. Наиләне биленнән кысып зыр-зыр әйләндерде, маңгаен тотып, аһылдап егыла язган хатынны сак җитәкләп кенә күләгәгә, урындыкка илтеп утыртты. Әз-мәз хәлләнгәч Наилә күл тирәсенә атлады, кызуы сүрелә төшкән учакка карап торды, тая язып ярдан суга иелде, ботакка ябышып, кулъяулыгын суга манчып, маңгаен чылатты, биек муенын юды, рәхәт булып китте.

Ул табын янына борылып кайтканда, Сабит белән Нәҗип, кочаклашып, бер-берсенә мәхәббәт сүзләре юллыйлар иде. Нәҗип, кулындагы мөлдерәмә тулы чәркәне болгап тост әйтергә маташты, сүзенең энә-тотанагы булмады, уйлары төрле якка чәчелгән, теле көрмәкләнгән, күзе, тиле кешенеке сыман, тонган иде. Наиләнең борчулы күз карашы белән очрашкач, аның түнгән миендә нәни генә аң чаткысы кабынды, ул яртылаш түгелгән чәркәсен өстәлгә куеп: «Мин әз генә ял итеп алыйм», — диде.

Табыннан ерак та түгел, куе чыршы ботаклары астында одеал җәелгән киң сәке бар икән, Сабит, Нәҗипнең уң кулын иңенә салып, ярым сөйрәп аны шунда илтеп яткырды. Әйләнеп килгәндә аларның күзләре кисештеләр, Наилә Сабитның ап-аек, нык һәм кискен карашыннан берьюлы куырылып китте.

«Йокласын бераз, — диде Сабит, — ял итсен».

Моңарчы алар **өчәү** иде, өч арасында бер төрле булган Сабит, икәүдән-икәү калып, өстәл янында кара-каршы утыргач әкрен генә кыяфәтен, тотышын, күз карашын һәм уйларын үзгәртә башлады. «Нигә без бу исерекбашның гырлаганын сагалап утырабыз? — дип ашыктырды ул уен.— Нигә иркенләп урманда йөреп килмибез?!»

Аның тәкъдименә Наилә карышмады, ул, шуны гына көткәндәй, кабаланып урыныннан купты, ике куллап кайнагасының беләгенә сарылды һәм алар шул хәлдә, бер-берсенә ябышып, күл тирәли атладылар.

Каршыда утырган хатын-кыз бер төрле тәэсир итсә, култыклаган хатын-кыз Сабитның иманын әйләндереп сала иде. Ул, тәүлек чамасы үзен авызлыклап тотты-тотуын, әмма хәзер, берни уйламаган тугры Наилә үзенең хәвефле, куркынычлы сукмакка төшүен чамаламый иде әле.

Тирә-юньдә кошлар чыр-чуы, яңарып яткан җир исен талгын ташыган җил онытылды, күк гөмбәзе астында дөнья буп-буш калды, шушы бушлыкны бер мәлдә алар икәү тутырып торалар иде бугай... Бая, карабодай басуыннан, көртлекләр һәм экиятләр патшалыгыннан кайтканда уена килгән сәер фикерләрен хәтерләп, Наилә көлемсерәде. Аннан бер секундка да күзен алмаган, һәр адымына, хәрәкәтенә үзенчә бәя биреп барган Сабит: «Ник көлдең, килен?» — дип төпчендә. «Болай гына!» — диде кызарынып Наилә һәм шул кызыллыгы белән җавабы-

ның дөрес түгеллеген расладьт. Аның тик тора алмас хәлгә килгән күңелендә гаҗәбрәк бер теләк уянды: «Сабит абыйның тыгыз, таләпчән иреннәрен бер үбеп алсаң... Гөлнарага сөйләр сүзләр булыр иде булуын!» Гөлнараның чуар тормышы, балга манчылып ятулары, сауналары искә төшкәч, Сабитның иреннәрен сынап карау теләге бермә бер артты. «Иреннәре Нәҗипнеке төслеме икән? Бер кан ич аларда!»

Бу сәер теләк сагаю, курку белән тиз-тиз алышынса да, күңелгә оялап өлгергән вәсвәсә, шайтан аны котыртып, икеләндереп барды.

Күңелгә иңгән вәсвәсә хатын-кызның күз карашын, тән температурасын гына үзгәртеп калмый, аның адымнары алмашынып, әүлиядәй хатын-кызлар да иблис токымы вәкиленә әверелә ләр. Наиләдәге үзгәрешне Сабит сизмәде түгел, сизде, аның нык ук уянган күңеле: «Туганымның хатыны ич... энекәшнең хәләле!» — дип сыкрады.

Күлнең аргы ягында, өч-дүрт җир буе ара киткәч, бирелән күренми торган ышыкта, нәни генә, пөхтә генә йорт та бар иде, такта түбәле, бер генә тәрәзәле. Бу йортның барлыгын, аның ни-нәрсәгә хезмәт иткәнен күбесенчә хатын-кызлар белә иде. Бүген ул йортка якынаю хакында Сабит уйлап та карамаган иде, аяклар ничектер шушы тирәгә китереп җиткерделәр. Ул ишекне тезе белән төртеп ачты, алар эчкә, күңелне били торган рәхәт караңгылыкка барып керделәр. Айның төшеп, акылга килгән Наилә бер дә аны-моны уйламады. Сабит та сабырлыгын җыеп өлгерде.

Идән уртасындагы камыш өстәлдә ике тустаган, шешәләр, капкач та йотарлык итеп вак-вак туралган ит кисәкләре, тавык бавыры, аерым тәлинкәдә симез сарык коерыгы күренде. Сабит тавышсыз гына Самвел белән Гургенны каргарга керешге: «Юньсезләр... Әйтмәгән килеш монда да табын хәстәрләгәннәр. Кеше котыртып... Күңелне аздырып! Кунак ханымның килен икәнен беләләр ич, ахмаклар!»

Сабит Наиләнең ике иңеннән йомшак кына басып аны камыш көрсигә утыртты, үзе басып калды...

Нәҗип йокыга китә алмаган иде әле, ул сәкене каплап җәелгән йомшак одеалын җыерып уң ягына борылып ятты, һәм йокы белән уяулык арасында туа торган сәер халәте аны төрледән-төрле уй дәрьясына алып кереп китте. Ул сүнәр-сүнмәс яктырган офык уртасында үзен күрде, үз-үзенә ерактан, бөтенләй чит кеше булып карады.

Хыялларында ул үзе дә шундый иркенлекне, татлы тормышны күздә тотып яшәмәдемени? Кызганыч ки, сукмагын дөрес сайламады, хыял-омтылышларының берсе дә тормышка ашмады. Бәс, шулай икән, нигә ул Сабит абыйсын дошман күрде? Нигә ул сайлаган юлдан җирәнде? Югыйсә, ни аермалары бар аларның? Хак, бервесе кул җитмәс биеклеккә үрелгән, ат казанган, икенчесе танавын канатып канауда аунап ята. Рухи игезәкләр ич алар асылда, бердәйләр! Ата-ананы икесе дә санга сукмадылар. Кардәш-ырулардан йөз чөерделәр. Аерма тик шунда гына—Сабитның кемлеге хәзер ачык мәгълүм. Нәҗип омтылыш-тартышларын әлегәчә хатынынннан да яшереп килде. Хыяллары тормышка ашмаганга рухи имгәнеп егылганын ул өлешчә Фәридун Фазлыев белән Фаина Марковнага гына ачып салды.

Ике туганның кайсысы гөнаһлырак: Сабитмы, Нәҗипме? Утыз өч ел яшәп гөнаһсыз берәр бәндәне очраттымы ул?! Юк ич!.. Тукта, бар икән, бар! Эти-әнисе, яхшылыктан бүтәнне кылмаган изге җаннар!.. Сабит китергән ит-майлардан баш тарткан әтисе авылдашларына язган уртак язмыштан тайпылырга теләмәгән. Ул кеше булып калырга омтылган, шуңа ирешкән дә! Бер гаепсезгә читлеккә ябылган Фәридун Фазлыев... Башы нужадан чыкмаган Ираида Никифоровна... Җылы җанлы Фаина Марковна... Илнең гөнаһсыз бәндәләләре җирдә-илдә Сабит ишеләр яшәгәнен тулаем белмиләр дә булыр, утыз өч ел яшәп Нәҗип үзенең кая, нинди тормышка омтылганын, чын итеп шушы

оҗмах-аланда гына күрде ләбаса! Илдә тигезсезлекнең елдан-ел көчәя баруын Нәҗип элегрәк тә сизенә иде... Хәзер уйлады: бәлки, шул тигезсезлек аркасында адашкан адәм уллары башларын аракыга ыргыталардыр да?! Аракы бер мәлгә кешеләрне тигезли, туганлыкның тишек-тошыгын ямаштыра. Абыйсы белән Нәҗипне дә бүген аракы тигезләде. Абыйсы аркылы тулы бер сыйныф—бер буйдагы рәисләр, парторглар, профсоюз куштаннары, активистлар, тагын күптин-күп әрәмтамаклар белән бер рәткә бастырды. Сары йорт әсире, Ионыч колы, симез көртлек атарга, чучка куырдыгы белән хушланырга ярат-кан партия вәкилләре белән дә тигезләнде ул. Нәҗип тә алар кебек, бер генә көнгә булса да, Маркс хыялланган коммунизмга чыкты. Сөен, Энгельс! Бар икән, дөнья читендә коммунизм аланнары да бар икән! Ни теләсә шуны ашый Нәҗип, машинада түш киереп йөри, шофер аңа «ләббәйкә!» дип баш ора, теленә ни килсә дә, аны дурдомга япмаслар, чөнки ул—тирә-якның ханы-солтаны Сабит Нургалиевнең кунагы! Хуш, хуш!.. Шулай да булсын, ди... Ә нәтиҗә? Нәтиҗә шул: үзе моңарчы сүгеп, нәфрәтләнеп, җирәнеп йөргән партия, хуҗалык бюро-кратларыннан Нәҗип бер ягы белән дә аерылмый икән! Җай булса, ул шушы ялган коммунизмда гомерлеккә калыр иде! Бәс, алай икән, нигә ул этиләре авылында гаделлек хаклап йөргән булды? Кибеттә нәни генә булса да бунт күтәрде? Очраган кешеләрне: «Нигә бу хәлләргә түзеп яшисез?!» — дип котыртты.

Ул калкынырга теләде, гәүдәсе буйсынмады. Хәзерге мизгелдә җа-нына ия түгел иде Нәҗип. Җаны, күбәләк булып, оҗмах-алан өстендә-ге зәңгәр төтен алкаларына утырып тирбәлә иде. Кинәт җил учакны тергезде, җаны —сары күбәләк —канатлары көеп, агач ешлыгына мә-тәлеп төште, тузанга әйләнде... Капылт айныды, «Кем акчасына һәм ни өчен шулкадәр юмарт сыйлыйсың мине?» — дип абыйсыннан сорыйсы килде. Сорарга кирәк! Кемдер сорау белән генә булса да аларны сискән-дерергә тиеш ләбаса! Нәҗип Йосыф улы Нургалиев абыйлары өчен корылган коммунизмда яшәргә теләми. Юк—и все!

Атаклы профессорның кияүдән кайткан кобра-кызына өйләнсә, ул бүтәнчә яшәр иде. Декан булып озак яшәмәде Захарчук, күксәү чиренә юлыгып, ай ярым дигәндә дүрт бүлмәле фатирын (Ульяновлар ура-мында!), дача, саклык кенәгәсендәге өч йөз меңгә якын акчасын калды-рып, Арча кырына мәңгелеккә сәфәр кылды.

«Һәркем үзенчә бәхетле була!»—дип шукланып яшәгән нык куллы Фәтхулла абзасын алыштырып, промбазага кереп оялаһа, Нәҗип оста-рып җитмәс идеме?

Бирнәле толга кол булып ялланмады Нәҗип, базага да күсе булып ояламады, нәтиҗәдә, трактор арбасына утырып, кылдый-былдый юл-ларда шакшы сөт бидоннары белән бергә тәгәрәп туган йортына кайт-ты. Кысыр сыер җилене тикле күчтәнәч кыстырып, җәй буе атасы хи-сабына тамак үткәрергә кайтып төште. Хәзер китәргә дә акчасы юк... Булган, Нәҗипнең дә мөмкинлекләре булмаган түгел, ләкин аларның берсе дә аның табигатенә ярашмаган, ул сагайган, саф килеш диярлек, чиста хәлдә кала алган.

Коньяк һәм аракы парлары, ниһаять, үзенекен итте, ул хәтерен җуеп, авыр гәүдәсенә кара канат куеп, төпсез упкынга очты...

Әле баярак Наиләне сокландырган көчле куллар ике имиен умы-рып тоткач, ул айныды, уң кулы белән кайнагасының күкрәгенә ките-реп төртте: «Нишлисез сез?!» Күзен кан баскан, акылын җуйган Сабит җавап кайтармады, хатынның дерелдәгән сылу гәүдәсен почмакка кысрыклады. Шапылдап урындык ауды, аңа игътибар итмәделәр. «Наилә, сылуым, курыкмагыз! Наять булыр, аулакта ич без!» — дип, Сабит хатынны үгетләде, үзен дәртләндерде. Ләкин Наилә акылын җыеп өлгерде, котырган үгез сыман янында торган Сабитның култык

астыннан шамбы балыгы сыман шуып чыкты, ул «тоттым!» дигәндә, яңагына берне чалтыратты. Сабитка бу бөтенләй ошамады, бер минут-та нәфесен тыеп, омтылышын уенга алып, гафу үтенергә торганда яңактан чәчрәп чыккан ут аны тәмам тилертте. Ул: «Ник тыпырчына-сың? Ул кадәр кем булдың?» — дип кычкырды. Наилә—үзенең к е м-л е г е н әзгә генә исеннән чыгарып ялгышкан, чит биләмәләргә кереп адаша язган кеше—күз ачып йомганчы чын халәтенә, сары йорт кеше-сенә, чирле, әшсез ирнең хатынына, каргалган язмыш иясенә әйләнде. Хәзер Сабит шашынган мир үгезе булса, Наилә—кулына үткен хәнҗәр тоткан, иңенә ук-җәя аскан горур болгар хатыны иде. Ире—Нәҗибе исенә төште, аның шушы кискен тартыш барганда сәкедә җәйрәп, гыр-лап ятуын уйлап әрнегән хатын Сабитның икенче яңагына берне тон-дырды. Сабит тактикасын үзгәртте, кул хәрәкәтеннән әлгәре сүзләр, кыланулар, ялган вәгъдәләр зарурлыгын аңлады, әш телгә күчте. «Ирең татлы йокыда, алтыным. Алан аулак. Без икәүдән-икәү. Алан сакта. Кошлар күрсә дә, аларның сайравын кем аңлар?! Татар хатыны булып кыланма. Син миңа бик ошадың. Караган саен сиңа мәхәббәтем арта бара. Читкә какма, киреләнмә, бул минеке! Мин сине бәхет диңге-зендә йөздерермен!» «Кагылмагыз!—диде Наилә,—китегез, зинһар!»

Шактый хатыннарны моннан кимрәк әзерлек белән дә кулыннан үткәргән Сабитның мондый кыргый каршылыкны очратканы юк иде. Әйе, хатыннар карышкалап та маташалар, ялындыралар да иде, идән-гә, үләнгә тезләнеп, ятып аунаган чаклары да бар иде аның, күкрәгән йодрыгы белән төеп, ялган антлар әчкәне күпме, ә бу Наилә кыланмый да, шаяртып та маташмый—тәрткән урыны күкрәктә сызлап тора! Үз гомерендә беренче тапкыр мондый хәлгә очрады. Ялындырганда, кы-ланганда, юри-марый буй бирми маташканда, хатын-кызны бөгәргә, сындырырга Сабит арсеналында йөзләгән ысул бар иде, ул хатын-кыз-ларның күңелендә һәм тәнендә ходай тарафыннан бүләк ителгән мең-нәрчә хиссиятле нокталарны таба иде. Баш бирми торган югаларны, аргамакларны бер үзе станга керт̆еп, тавышсыз-гаугасыз дагалый тор-ган тимерче тирә-якта бер булса, Сабит Йосыф улы шундыйларның берсе, атаклысы иде. Хәзер исә сынатты, ялынуы ялган, үгетләре буш, вәгъдәләре күз буяу булып чыкты. Дагалыйм дигәндә, чүкече ут уйнатканда гына аргамагың стан араталарын ватып-җимереп чыгып китсен әле.

Бер ярсыды Сабит, бер уенга кайтарып калдырырга теләде. Хак, карышкан саен Наилә Сабитка ныграк ошады, туймас каны котырды, нәфесе җиде башлы дию булып аның назлы тәнен теләде. Ут булып ян-ган яңагы сак булырга кирәклеген искәртте. Бу хатын көч белән алына торган затлардан түгел иде! Ашыкты Сабит, иртә котырды. Хәзер менә сүз белән җайга салып, ипкә китереп булырмы, юкмы?!

Тыелгысыз сүзләр яңа суырткан бал булып акты...

«Наиләкәй, карышуның мәгънәсез икәнен аңлыйсың. Гашыйк бу-луым хак. Син минем йокымсырарга мәҗбүр ителгән хисләремне уят-тың. Сөмбеләне күрдең, чирле ул, иргә күптәннән хезмәткә ярамый. Синең гүзәллегең шаштырды, кызып китеп, ипсез кыланганмын икән, кичер. Ләкин карышуың юкка! Монда мин хуҗа, кулымда көч, власть. Бел—мин монда теләсә ни эшли алам!!»

Тартышны ничектер көйле генә тәмамларга кирәк иде. Наиләнең күңеленә шаярту уе иңде, ул: «Ни теләсәм дә, үти аласызмы?» — дип сорады. «Күктән йолдыз чүпли алмам,— диде күкрәгән төя-төя Са-бит.— Лувр музееннан Джоконда рәсемен чәлдереп үк булмас. Бүтән-чә — ни сорасаң, шуны үтим! Урман шаһит: куш, боер. Күл суы белән ант итәм: үтим!» Ул тагын күкрәгенә сукты, күкрәгенең корыч калкан-дай киң, маймыл сырты сыман йонлач икәнен хатын-кызга белдерергә үлеп ярата ул. Оттырмый, җилбәзәк хатыннар шунда ук йомшак бар-маклары белән аның түшен сыйпарга тотыналар. «Безгә Казанда өч

бүлмәле квартира алып бирегез!» Сабит, мамонт ауларга җыенган кыргый булып, кулын бутап күккә сикерде. «Шәһәрнең кайсы төбәгеннән кирәк? Ничәнче кат? Кояшлы якмы? Наилә җанкисәгем, квартир ачкычы кулыңда дип бел!»

Биеп туктагач ул сынын турайтты, сак, песи адымнары белән Наиләгә тартылды. Наилә, ул онытылып биегән арада, түрдән ишек катына күчеп өлгергән иде. «Бер генә үбәм... бер генә! Вәгъдәгә бер үптер инде! Үпкән-кочкан җилгә очкан! Суырып кына бер үбимче, җаным!»

Аркасы ишек тактасына тигәч, Наиләнең көче артты. Ул «Нәҗип уянмадымы?» — дип тыңланып торды, ләкин тирә-як тын, якында гына бер кош сайрый иде. Аның күңеленә сәер уй килде: «Кошлар сайраша, без аларны куанычка гына сайрый дип беләбез. Аның бутәнчә чарасы юк лабаса, елавы да, көлүе дә бер төсле үк! Баласын җуйган сандугач бер чакта да карга булып каркылдый алмый инде! Бәлки, ул Наиләнең җәтмәгә эләгә язып тырпылдавын күзәтеп торып сайрыйелыйдыр? Аңламассың кош-кортны!»

Сабит «эш җайланды!» дип Наиләгә үрелгән иде, Наилә ике йодрыгын кушлап кайнагасының күкрәгенә китереп орды. Аны-моны көтмәгән Сабит чайкалды, ныклыгын югалтты һәм бар авырлыгы белән гөрселдәп идәнгә ауды. Наилә читлектән ычкынган кош булып тышка атылды. Туп-туры Нәҗип янына чабып барды, дөньядан ваз кичеп, тәмам җебеп-мәлҗереп яткан иренең манма су булган чәчен тартты. Нәҗип иреннәрен кыймылдатып нидер мырылдады, мышнап борылып ятты. Хатын аннан рәт чыкмаслыгына ышангач, җилкәсенә берне кундырды да, кояшка карап алып, кайтыр юлга төште. Бая карабодай басуыннан үткәндә килгән юлны бераз чамалаган иде, күңеле сизенгән икән!

Башта ул исереп ауган иренә рәнҗеде. Исереп, мәлҗерәп аунаган ирләр шундый мизгелләрдә хатыннарының каргышын, зарын бер булса да ишетсәләр икән! «Йолкыш!—диде Наилә,— мәлҗерәгән! Сасы йомырка сарысы, төртенмеш, ачкак! Аракы күрмәгән бирән! Күзе тонганчы чөмерде! Йомыкый! Бәрәңге кәлҗемәсе! Сыек сыер тәбикмәге! Ачкүз! Маймыл!» Иренә багышланган «сәламнәре» шунда тәмам булып, ул каргышларын Сабитка яудырырга тотынды. «Муены астына килгере! Бозык! Чукынгыры! Күрексез гармун! Тамагына таш торгыры!»

Коммунист, депутат, бюро члены, пленум әгъзасы Сабит Йосыф улы Нургалиев тагын бик күп мактаулы, шәрәфле исемнәргә лаек булыр иде, Наилә урман авызына чыгып җитте. Телендә каргау сүзләренең барын белми иде әле ул моңарчы, кайбер бәндәләр белән күчәр башлары орынганда алар, ходай кодрәте беләнме, үзләреннән-үзләре телгә киләләр икән...

Әхмәтзыя янына бу рәвештә, күз акайтып, чәчне-башны туздырып, күбенгән сыер кебек мышнап барырга ярамый иде. Наилә шып туктады, күлмәк итәген төкереклап сыпырды, тезе канаган икән, аны төкереклап сыйпаштырды, тамагын кырды: шөкер, тавыш бар икән, тавышы булгач, Әхмәтзыяны көйләрлек сүзләрен табар.

Руль артында йокымсыраган Әхмәтзыя башта берни дә аңламады, аңлый алмады. «Мине авылга төшереп куегыз!—диде Наилә кат-кат.— Баш әйнәгем кузгалды, миңа врач, Сөмбелә апа кирәк»,— дип өстәде. Әхмәтзыя, көнгә чыккан ябалак сыман, күзен мелт-мелт йомып: — «Ә Сабит Йосыпович?!» — дип карышты. Әллә ялварып, әллә боерып, Наилә: «Кайтырга Сабит абый кушты да!» — диде, тавышы ямьсезләнде.

Якында аяк тавышы ишетелде. Наилә коты чыгып шул якка карады: фуражкасын тезенә суга-суга, милиционер монда таба килә икән, ул Наиләне күреп шып туктады, дымлы маңгаен картуз түбәсе белән сөртергә тотынды. Наилә: «Үләм!» — дип ыңгырашты да машинага

кереп чумды. Әхмәтзыя педальгә басты, башын чайкады. Ул бик нык икеләнә, курка иде. Әгәр бер-бер ялгыш җибәрсәң, Сабит Йосыпович аны тереләй тотып ашаячак... Үзеннән алда эшләгән шоферның бер кыек сүз ычкындырганы өчен дүрт ел ярымга төрмәгә тыгуларын ул бик еш исенә төшерә! Сабак! Юаш, җиде балалы Әхмәтзыя үзенең авылга түгел, җәһәннәмгә таба ашкынуын тиз аңлады; Сабит абыйсы хатын-кызны алай ансат ычкындыра торган ир түгел! Беткән баш беткән!

Сабит гөрселдәп идәнгә барып төшкәч, беравык исен җуеп, шаккатып: «Минме бу? Шушы ямьсез хәлгә мин төштемме?» — дип җәберсенеп ятты. Ни булганын аңласа да, моннан ары ни булырга тиешлеген,ниләр күрәчәген күз алдына да китерә алмады. Ярый, торыр, аягына басар, ишектән көнгә чыгар... Берәрсе аның күтәрәм сыер сыман егылып ятканын күреп калмадымы? Хуш, аны күрмәделәр, ди... Ә Наиләнең аткан уктай атылып чыгуын, ире янына барып капланып, дөнья сасытып акыруын күрмәскә сукырмы әллә алар?.. Наиләнең ире янына чабуында аның шиге юк иде. Форсат чыкканда һәр хатын-кыз тугрылыгын җанлы мисаллар белән ныгытырга ярата! Ул, Наилә каядыр еракка чабар, машинага утырып авылга элдерер, дип уйлый алмады...

Әрмән егетләре дәшмәс... Милиционер Вәлиәхмәт тә үз кеше... Ә Нәҗип? Дөньяда Наиләнең ире дә бар лабаса! Наилә шул боламыкка ниләр дип лыгырдар икән? Ничек итеп? Туганнарны пычакка-пычак китерергә теләмәсә, берни сөйләмәс, алай да монда озак ятырга ярамый.

Сабит торды, төзәтенде. Иң мөһиме хәзер шул: Наиләне күзәтергә! Артыгын тугарылып китмәсен!

Хәзер үк барып җитәргәме? Әллә Наиләнең әз генә суынганын көтәргәме? Һәр очракта Нәҗип ни уйлар?

Ул сабыр итәргә булды, җан азыгы санап бер-бер артлы ике чәркә коньяк эчте, шешәне почмакка ыргытты, аунаган урындыкны аякландырды. Фикерен бер ноктага юнәлтергә тырышып, тәрәзә каршысында басып торды. Күңеле болгана, мие кайный иде.

Әзерләнеп, гадәти битлеге белән йөзен каплап, күкрәкне бүлтәйтеп табын тирәсенә барып җитсә, беркем юк, сәкедә бөгәрләнгән әнесенең өне ишетелми, көл сыман иреннәреннән сүз түгел, куе селәгәй ага. Ул күзе белән әрмән егетләрен эзләп, алардан сорашырга теләде, ләкин «күзгә чалынып йөрмәскә!» дигән боерык алган тыңлаучан егетләр каядыр сеңгәннәр, күренмәделәр.

Сискәндереп күңеленә бер шик килде, ул да, Наилә сымаграк карганып, машина янына чапты. «Ах, явыз! Ах, ыштансыз марҗа! Ирдәүкә! Әләкче! Саескан!» Сабитның егәрле, нык аяклары велосипед кигиләре кебек ялтырадылар...

Ул урман авызына чыгып җиткәндә машина калдырган ис таралган, тәгәрмәч астында сытылган үлән сабаклары әкрен-әкрен калкыналар иде. Якында гына күке кычкырды. Сабит аны ишетмәде, ачудан аның колагы тонган, ияге белән иреннәре калтырыйлар иде. Чыршы белән каен арасында милиционерның картузы күренде. Сабит, ыжгырып, ике сикерүдә шунда барып җитте. «Кайда ул?» — дип үкерде. Рәиснең төрле рәвешләрен күреп күнеккән Вәлиәхмәт, шыр җибәреп: «Кем?» — дип сорады. «Минем акылдан шашкан килен!» «Киттеләр», — диде тилемсә елмаеп, аны-моны чамаламыйча Вәлиәхмәт. «Кая киттеләр?» «Киленегезнең утырганын гына күрдем, кая баруларын сорамадым!»

Сабит шулай кинәт орды, Вәлиәхмәт авыр көлтәдәй ауды, дөнья зыр-зыр әйләнде, күзеннән ут чәчрәде...

Колхоз председателе, КПСС члены Сабит Йосыф улы Нургалиевнең характеристикасы Советлар иленең байтак почмакларында саклана. Орден тапшырганда да язалар аны, депутат итеп сайлаганда әллә ничә җиргә җибәрәләр, әзмени лаеклы кешеләргә характеристика саклана торган оешмалар киң советлар илендә?! «Алдынгы фикерле чын коммунист», «партиягә тайпылмас хезмәт итүче», «тугры», «принципиаль», «эшлекле», «тыйнак большевик», «тотнаклы ленинчы», «үрнәк эшләр иясе» һ. б. һ. б.

Якыннан белгән, аралашкан, ризык бүлешкән, балыкка барган, сунарга йөргән юлдаш-иптәшләре, сердәш-көрәштәшләре, мөгаен, аның бу мактаулы сыйфатларына тагын ни дә булса өсти алырлар.

Сабит җитәкләгән мактаулы «Коммунизм юлы« кешеләре исә, рәисләре турында байтак нәрсәләр белсәләр дә, дәшмәсләр иде, чөнки ерак тарих дәвамында татар крестьянының авызы шулкадәр еш һәм нык пешкән ки, ул дәшмәскә өйрәнгән, зарланса, мич арасына кергән, йодрыгын йомарласа, җиң эченә яшергән.

Нәҗип, кайтырга җыенып, авыл турында хатынына мәгълүматлар биргәндә, абыйсы турында болайрак дигән иде: «Чибәр... Яшь чагында кызлар камалышында үсте. Иркәләнде. Эшем иясе булып күренергә ярата. Ата ялкау булса да, кеше җилкәсенә ансат менеп кунаклый. Әкиятләрдә бер зат бар ич, укыгансыңдыр: буе бер карыш, сакалы биш карыш затны онытмасаң, әнә шул бәндәгә алдар тазны да ялгасаң, Сабит Нургалиев килә дә чыга!»

Тәүлек эчендә Наилә дә Сабитны үзенчә бәяләргә өлгерде. Сабитның бозык, фәхеш зат икәнен дә белде. Аның мондый затсыз кешене күрү түгел, ишеткәне дә юк иде. Бәйләнчек Изил Латыйпов моның янәшәсендә гөнаһсыз бер фәрештә икән! Бер карында яралып, бер әнкәне имеп үскән туганының хатынына кул сузып маташсын инде, ахмак! Оятына ничек көч килми дә, шундый бәдбәхетне ничек җир йотмый?!

Әгәр, ходай язганнар тормышка ашып, Газраил, Нәнкир белән Мөнкир, өчәүләшеп, каршыларына үрә бастырып Сабитның үзеннән: «Кем син? Яшермә бөртеген дә, и адәм угылы, ачыл?!» — дип боерсалар, Сабит үзе дә аптырап калыр, тинтерәп, җавап таба алмас иде.

Мисалга шуны әйтеп китик: Сабитның гомерендә дә төш күргәне юк, ята, мендәргә башы тиюгә йоклап китә, кай ягына ятса, шул хәлдә уяна, селкенми дә, кыймшанмый да! Арган чагы була, борчулы чаклары, мәгәр аның йокысыз интегеп, түшәм санап, көндәлек уңышларына яки хаталарына анализ ясап ятканы юк. Байтак квартирда, казна йортларында яшәделәр, яшьтән үк матурлыкны, гөл-чәчәкләрне үлеп яраткан Сөмбелә, яңа урынга күчкән саен, гөлләр утыртып карады. Сабит яшәгән йортта гөлләр үсәргә теләмиләр иде.

Болынга, чәчәк-ганҗәләр арасына барып керсә, ул таптап үткән үләннәр бер чакта да калкынмыйлар, терелмиләр, аның аягы тигән печәнне мал ашамый, ул моны белә һәм шуның өчен, намын, исемен саклап, әзер сукмаклардан йөрергә тырыша. Явыз ата казлар аңа ысылдап килми, усал этләр өреп бер чакта да аңа аркылы чыкмый, машина урамнан үткәндә үк койрыкларын бот арасына кыстырып, кая туры килсә шунда, аулакка посалар. Бәбиләрне кулына алса, алар күз-кашларын җимереп үкерәләр, төн ката бимазаланалар. Юкә балы чорында чүниккә кунаклар алып барып, кызыксынып иелсә, бал кортлары очудан туктый, умарта авызына кизүгә куелган кортлар дәррәү эчкә кереп яшеренәләр. Корт чакканы юк аны, кара еланнар очраса, тәгәрмәчкә әйләнеп әллә кая ыргылалар, ул чишмә авызыннан эчәргә теләп иелсә, аның сулышы тиюгә су тибеше әкренли, юынырга керешсә, тына, туктала.

Кыскасы, үз асылын, ниләр кылырга маһир икәнлеген Сабит үзе дә белеп бетерми иде...

Сабит, шулай итеп, чарасыз калып, сорауларның берсенә җавап таба алмыйча, муртайган имән төбенә барып утырды, кояшта җылынып йөгерешкән кызыл тараканнар, кырмыскалар төрле якка таралдылар, тычкан тишеге тирәсендә быжлаган төклетура, аллә кая. Карама куыш тирәсенә очып китте. Сабит кайнап бәргәләшкән уйлары белән япа-ялгызы калды.

Нәҗип Казанда чакта Наиләсенә: «Бригадирга булышып йөргәндә боздылар малайны, бакча сукаларга ат кирәк икән—аңа килделәр. Печән-салам алып кайтырга дигәндә йомышлары аңа төште. Тол дүдәк, ятим-ялпы хатыннар, ирләре бәхет эзләп читкә тайпылган киленчәкләр гел аңа ялынды. Яшьли аракыга ирене тиде малайның. Авыл бозды Сабит абыйны!»— дип аңлаткан иде...

Җиңел һәм беркатлы аңлату! Кемнең кайчан һәм ничек бозылганын белеп булса икән!..

Ярдәмчедән бригадир иттеләр Сабитны, тора-бара күрше колхозга рәис итеп җибәрделәр. Районда гына түгел, республикада иң яшь председатель иде ул! Дан алган егетне Саратовка, өлкәара партия мәктәбенә укырга озаттылар. Курсларда да иң яшь ул иде. Буй озын, кыяфәт килгән, хәтере шәп, сүз өчен бурычка кереп тормый, русчаны тиз элдерде, теттерә генә — җыеп әйткәндә, Сабит курсларның күз өстендәге кашы булды. Комиссия, тикшерү, кунаклар килгәндә аны иң алга чыгардылар, ипи-тозны аңа тоттырдылар.

Ике елдан укып кайтты, Сабитны район үзәгеннән ерак түгел Ирнә үзәненә таралып урнашкан мал-туар симертү совхозына директор итеп җибәрделәр. Элеккеге директор, чакрым баганасыдай биек буйлы, мишәр Хәлиуллин эшен тапшыргач, вәкилләр сыйланып киткәч, егетне үз янына, кабинетының аулак чоланына дәшеп кертте. «Мин сине белмим, мәгәр, энем, бер күрүдә ошаттым. Шылай, кәбәм, олы эшкә алынасың. Бел һәм онытма, борының райком ягына борылган булсын! Шуннан нинди җил исә, белеп ала торган бул. Мин сиңа, кәбәм, учетка кермәгән унҗиде баш сыер, илле данә тана һәм дә йөз илле каты борынны калдырам. Баш саннарын өлкән зоотехник белән бухгалтер Нәҗибә генә белә. Дәрәҗәләрен, хаҗәтләрен һәм үзләренә ни бата икәнен белә торган зирәк балалар. Аларга ышан, тик күзеңнән ычкындырма! Куелыкта чакта нәзек агачны да җил сындыра алмый. Сине нык куллы, каты кеше дип танысыннар. Эшкә өйрәнгәч тә узынма. Чамасын онытмасаң, Совет власте юмарт ул, кәбәм! Кешене кешедән аера бел, мине онытма! Мине Башкортстандагы дуслар чакыра, райисполком итмәкчеләр!»

Мишәр Хәлиуллинга Сабит гомере буе рәхмәт укыды. Нинди юмарт куллы, затлы кеше! Һич нәрсәне яшермәде, бер күрүдә аңа ышанды, күпме байлык, акыл калдырып китте. Әле Хәлиуллин заманында прокурордан шикләнәләр, райком секретарьларыннан, милициядән куркалар иде. Сабит заманында һәр тарафка яңа буын кешеләре килде, алар яшәеш законнарын да, властька элегрәк килеп, үзләренчәрәк яшәп ятканнарны да тиз-тиз үзгәрттеләр, үзгәрмәстәйләрдән ансат котылдылар. Районда Сабит курка торган зат калмады: симез сарык түшкәләре, таналарның ал һәм арт ботлары, бавырлары, тез башлары прокурорга да, райком әһелләренә дә, Казан кунакларына да аның кулы аша үтә торды. Рәхмәт тиңсез акыллы мишәр Хәлиуллинга! Ул биргән акылны Сабит ныгытты, маясын ишәйтте. Аның тагарагыннан ашаучылар ел саен арта бара иде.

Мал-туар хуҗалыгында күрсәткән хезмәтләре өчен ике ел рәттән орден алды, Мәскәүгә, авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә чакырып, «Москвич» машинасы биреп кайтардылар. «Бигеш» аэропорты эшли башлауга шактый яшьләре шунда киткәч, уртачалардан саналган

«Коммунизм юлы» кохозына рәис итеп аны җибәрделәр. Сабит бер мәлгә шүрләбрәк калды. Райком секретаре: «Колхозыңны үрнәк ит. Алга чыгар. Дан яула. Өмет синдә!»—диде. Куркуы юкка булды, мал-туар симертү совхозында шәбәйгән танышлык, арадашлыкның файдасы тия башлады. Кодрәтле куллар аңа төрле яктан ярдәм яудырды. Бәйрәм алларыннан телевидениедән, радиодан, газета-журналлардан иң житез, елгыр егетләр килеп, атна буе сыйланып кунак булдылар.

Сабитның кулы юмарт, хуҗалыгы нык, кадрлары ышанычлы иде. Колхозның даны күзгә күренеп артты: орденнар, бүләкләр, мактаулар чоры башланды. Баштарак бер нәрсә бимазалады: әти-әнисе, туганнары белән ара ераклашты. Яшәү дәрәҗәсе, аралашкан кешеләренең абруе туганнарны, теләсәң-теләмәсәң дә, читкә кагарга мәҗбүр итә иде. Тора-бара Сабит анысына күнекте.

Түрен туганнардан яшерде. «Вакыт юк, эш күп!», — дип, чакырган җирләргә бармады, агай-энеләр дә аны аңлаган кебек булдылар.

Үсте Сабит, делегация составында Америка, Голландиягә барып фермерлар белән очрашты. Самолетта шыр җибәрә торган кеше, очсыз-кырыйсыз океан өстеннән очканда: «Исән-аман кайтып элгәшсәм, әти-әнине күреп чыгармын!» — дип нәзер әйтте. Кайткач, әүвәлгечә вакыт җиткезмәде, партактивтан пленумга, пленумнан активка чапты. Америка коммунистларын, эшсезләрне,бер хокуксыз негрларны «җәлләп» нотыклар тотты, ашкынып коралланучы, Совет илен хәрби базалар белән чолгаган дошманга нәгърә орды...

Кунакта симез итне хәтсез күп ашап, эче борып-борып авыртып уянгач, Сөмбелә биргән дарулар да ярдәм итмәгәч, шигәеп, «нәзерем тотты» дип, бик ашыгыч кына авылына кагылды. Америка,Голландиядә халыкларның, шул җөмләдән крестьяннарның да ничек яшәгәнен күреп шаккаткан Сабит этисенең турыдан суктырган соравына нинди җавап биреп котылырга белмәде. Әтисе болай диде: «Улым, син йөргән якларда ярлы һаман ярлымы, әллә аларда ярлылык бетәнчәрәкме?»

Сабит боргаланды, әтисенең юаш, басынкы гына, бөкресен күтәрә алмыйча иелеп, күзгә карап торганын күргәч, алдарга базмады, күнегелгән ялганны сиптерергә көче җитмәде. Әтисе Сабитны зарыгып көткән иде, имтихан алучы кырыс профессордай, өстәмә соравын да биреп өлгерде: «Мәзәк бит тормыш, улым. Ярый, сугыш, дидек. Сугыштан алда кулаклар илгә зыян салган, диделәр. Алардан соң корткычлар, троцкийчылар илнең тамырын кимергән, дип аңлаттылар. Кулакларны сөрдек, корткычларны кырдык; сугыш беткәнгә биш былтыр... Крестьянның тамагын туйдырырлык хәләл закон чыгамы бер, юкмы? Яши башлаганнан бирле крестьянның ипекәйгә туенганы юк лабаса. Син йөргән җирләрдә хөкүмәтләр буржуйский... Алар инде крестьянга бер бөртек калдырмыйча алып бетерәләрдер. Безнең, ичмасам, юанычыбыз бар: эш башында үзебезнекеләр утыра. Эшче дә крестьян... Андадыр инде ул хәлләр! Негрлар ачлыктан бер-берсен ашыйлар, дип яза гәҗитләр. Шуларны күрә алдыңмы, юкмы?» Сабит мондый туры сорауларны беренче тапкыр ишетте. Бүтәннәр сораса, ул андый пырдымсызларны тамак тавышы белән ялт тыяр иде. Әтисенә каршы төшәргә йөрәге җитмәде, иле белән әллә кайчан коммунизм шартларында яшәп ятучы Голландия крестьяннары хакында дөреслекне дә ачмады. Авыл агайлары бер-берсенә хәбәрләрне җиткерергә яраталар, әтисе кемгәдер ул күргәннәрне сөйләсә... бәладән башаяк! Әнә күп сөйләгән Шаранскийны Чистай төрмәсенә тыгып куйганнар...

Туган йортыннан әтисе әзерләп куйган сорауларга җавап бирмәс өчен дә читләште ул. Тик бусы юкка иде, буыны ару-талуны белмәс Йосыф карт инде бетәште, биле бөкерәйгән саен күз күреме тарайды, иелгән башы җирне һәм шул җирдә тырманган кешенең хәлсез аякла-

рын гына күрде. Күңеле гамен, улына юнәлткән сорауларын ул әллә кайчан онытты, җиңеләйде. Элек сөзәк тау битенә чәчелгән кабер ташларын белми дә идек кебек, хәзер, көн туса, баш шул хәсрәтле якка каерыла: «Кара канатлы Газраил очып килмиме?!»

Бәхете юк икән—юк инде ул, аны булыр димә, крестьянга бер заман камыт кигергәннәр икән, кайсы патша яки юлбашчы салдырсын аны? Ат белән крестьян камытын ташласа, илне кем туендырыр? Ризабәхил, ходаем, Йосыф белән Мәрьямбикәнең тамагы туймаса да, балалары балда-майда йөзә, ипине күкрәккә терәп кисәләр. Үз вакытында авылдан чыгып ычкындылар. Әнә хәзер китеп кара, паспорт сорап йөз ертып барсаң, кәҗә билеты тоттыралар, абзар артына барсаң барырсың, аннан ары юл киселгән.

Авылда хәзер урындагылар яшәсә яши, әнә Сабит кебек уңганнар дөньяны уч төбендә биетә. Вәт аны яши диләр! Дөрес, Йосыф картның улын барып күргәне юк, кеше сөйләгәннән чыгып кына чамалый. Татарның шул инде язмышы: «Ай-һай, ак калач тәмле икән!» «Ашап карадыңмы?» «Юк ла, әти Эзи базарында бер марҗаның ашаганын күргән!»

Котырган төлке белән алышканнан соң этисен больницага нинди хәлдә салуларын баш врач аңа көне-сәгате белән житкерде. Яше олы кеше чирләмичә тормас, була торган хәл, әмма этисенең котыру чире йоктыру ихтималы аны нык борчыды. «Әтисе котырып үлде»,—дигән хәбәр калкып чыкса, бер дә Сабит файдасына түгел иде. Тәжел эшләрен кичектереп, киләсе кунакларына отказ биреп, больницага ашыкты. Картның һушсыз яткан чагы иде, аның катына Сабитны да кертмәделәр. Өч көннән соң тагын барды. Бу юлы баш врач аны Йосыф карт янына ияртеп керде. Килеп кергәч тә Сабит этисен күрмәде, күргәч танымады. Югарып, арыкланып калган Йосыф караватка сеңгән, аяккуллары хәрәкәтсез таралган иде. Юрган калынлыгы җансыз гәүдәнең этисе икәнен белгәч, Сабитның күңеле тулып, күз төпләре дымлангандай булды. «Эти,—диде ул, җебеп, балалыкка кайткан тавыш белән,— хәлең ничек?» Карт үз хәлен әйтеп бирә алмады, баш врач әйтеп аңлатырга курыкты...

Эзи белән авылы арасын Сабит капма-каршы уйларга уралып үтте. «Исән-аман котылып чыкса, берәр яры дәваланырга җибәрәсе булыр... Әнә Казан янында гына Васильево бар, терәлеп тора, ашау-эчү дә ару гына диләр, ятсын шунда ай буе!.. Йорт-җирләрен әз-мәз караштырасы иде... Ит-ашлары да әлләкем түгелдер, Әхмәтзыя берәр симез түшкә илтеп ташласа да чит булмас...»

Эзи артта калып, ятагына тормастай сеңгән хәлсез карт ераклашкан саен, Сабит бүтәнчәрәк уй йөртте: «Үлсә ни әйтерсең? Мондый яман чирдән әллә кеше булып чыга ул, әллә гомергә имгәк, күз күеге хаста булып кала. Кем карар аны? Үлүе—котылу, исән калганнарны коткару!»

Әйтергә кирәк, авылга кергәндә ул эткәсенең җайлы гына үлүен теләде, аның әҗәлен «ансат котылу» дип атады.

Казан табиблары, җирле врачлар Сабитның бу уйларын белми калдылар. Алар, киресенчә, республикадагы иң гайрәтле кешенең эткәсен коткарыр өчен көне-төне тырыштылар, йокламадылар. Котыру чиреннән билгеләнгән дару-дәрманның ни өчен файдага китмәвен кат-кат анализлардан соң белделәр. Аның кан косып әлерәк кенә больницага кереп чыгуы күп нәрсәне ачыклады. Еллар буе ашлык агулауда катнашып, яшелчә бакчасында эшләгәндә түтәлләргә дустны учы-учы белән сипкән, язын самолетларга гербицидлар, төрле көчтәге пестицидлар тояшкан, ни кылганын, ни сулаганын уйламаган Йосыфның организмы агудан тәмам йончыган, үпкәләре эштән чыккан, бронхларына куркыныч матдәләр кереп тулган булып чыкты.

Соңгы диагноз Сабитны аерата хафага салды. Бүтән берәү мондый

чир элэктерсэ, аның исе китмэс иде, авыру йэ үлэр, йэ терелеп чыгар иде. Һэммэсе хода кулында. Э монда... «председатель Нургалиевнең атасы төрледэн-төрле агулы матдэлэр арасында уралып, минераль ашламалар чыгарып чир йоктырган, үпкэсе череп-теткэлэнеп беткэн!» — дигэн яман хэбэр халык арасында таралса?..

Сабит Нургалиев хагы-нахагы белэн бергэ районда минераль ашламаны кырга иң юмарт кертүче иде. Район өлешен генэ түгел, уртак тимер юл станциясеннэн күршелэргэ дигэнне дэ ул үзенэ ташытып куйгалый иде. Машиналары күп, шоферлары—ул тэрбиялэгэн, җитез, урлашырга күнеккэн, яңа ел киче дип тормыйлар, Октябрь бэйрэме дэ аларга песи төчкерүе белэн бер, чыгалар да китэлэр, бүтэннэр аяк киенгэнче ташып, тутырып та куялар. Агу юмарт сибелгэн кырларда чүп үлэне үсми, аның серлэрен Сабит эллэ кайчан белеп оныткан! Аның колхозында төзек бер эгъзасы да калмаган кешелэр бар, лэкин эле алар яшь, тазалар, аларга акыл бирүче: «Нишлисез сез? Нигэ, һич югы, агу арасында уралганда халат, пирчэткэлэр, респираторлар кимисез?» — диюче юк, киресенчэ, сөенэлэр, уч тутырып акчасын, машина эрҗэлэрен түбэлэмэ тутырып ашлык алалар, аларның агудан челтэрлэнэ башлаган үпкэлэрен элегэ яшергэн күкрэклэренэ күзлэрен орденны депутат Сабит Нургалиев кадый...

Сөмбелэ генэ шиккэ төшэ башлады, авыл арасында моңарчы күрелмэгэн хэллэр ешайды. Яңа өйлэнешкэннэрдэн берэү гарип бала алып кайтты, сабыйның аяк-кул бармаклары укмашып каткан иде. Мэк чэчэгедэй ике киленнең бэбилэре үле туды. Ашлама склады мөдире Фэезханның колагы ишетмэс, күзе күрмэс булды. Кырык яше яңа тулган иде Фэезханның! Сөмбелэ шиклэрен Сабитка эйтеп карады. Сабит аңа бер генэ кычкырды: «Тавышың чыкмасын!»

Ул этисенең чирен, кан косуының сэбэплэрен беркемгэ чыгармаска кушты. Казан белгечлэре китте дэ югалды, җирле табиблар тел тешлэделэр.

Шулай итеп, Йосыфның чир тамырлары сер булып калды, фаш ителмэде, тавыш-гауга чыкмады, бар да улы Сабит талэп иткэнчэ көйлэнде. Бераз вакыттан соң картның хэле тигезлэште, ул энэ шундый буынсыз, чирлэшкэ, хэтерсез хода бэндэсенэ эйлэнеп калды.

Э Сабит, изге ниятлэрен, назерлэрен тиз онытты, яңандан-яңа мэшэкатьлэр туа торды, кемдер килде, кемдер кагылып чыкты, утырышлар, пленумнар, киңэшмэлэр, симпозиумнар, тэҗрибэ уртаклашулар, эле Казан, эле Мэскэү юллары. Унөч кешелек делегациягэ җитэкче итеп аны ун көнгэ Японияга җибэрделэр. Болар янында эткэсенең чире бик бэлэкэй, вак-төяк булып кына калды.

## 24

Кунаклар: «Иртэн Сөмбелэ кабыл-тибел чыгып югалды, юньлэп эндэшмэде»,— дип үпкэлэделэр, асылда ул беркая китмэде, өйдэ калды, барлыгын кунаклар белеп өлгермэгэн иң эчкэрге, аулак бүлмэгэ кереп биклэнде. Сөмбелэнең кайдалыгын Сабит бик яхшы белэ иде, ызгыш-талашлардан соң хатыны ара-тирэ шул бүлмэгэ кереп кача, ишекне эчтэн элеп, мендэр почмагын тешли-тешли кайгысын таратка-лый иде. Дөрес, соңгы дэвердэ ул иренең хикмэтлэренэ күнекте, исе китми башлады, чит хатыннар белэн юргалавына бармак аша карады, «бөкрене кабер генэ төзэтер», дигэн иманга килде.

Өйлэнешкэннэренэ ел дигэндэ, юк өчен үзара низаг чыгып, кара мунча өйалдына кереп биклэнгэн хатынын Сабит чабаклап алып кайткан иде. Һай, гомерлэр—телэгэндэ качар урыны да булмаган Сөмбелэнең ул чакларда! Хэзер табып кара, аулак бүлмэнең ишеге имэн тактадан, эчтэн тимерлэнгэн, ачкычы үзендэ генэ, өй тирэсендэ уралучы Бэ-

дәр дә керми анда, бу бүлмә Сөмбеләнең хөҗрәсе, аның зонасы, бүлмәдәге һәр почмак аның бик күп күз яшьләренә шаһит. Сабит та канәгать — Сөмбеләнең алмаз яшьләре шунда эзсез сеңеп бара...

Сүз белән алдыра торган ирләр була, кайберәүләр буй-сын белән хатын-кызны һушсыз итәләр, өченчеләр кылган гамәлләре белән кызкыркынны үзенә тарта, биргән татлы вәгъдәләре белән исәр итә. Болар өстенә Сабитның күз белән алдыра торган сихри көче дә бар иде.

Сөмбелә өтек кенә бу колхозда өченче елын врач булып эшли иде инде. Көзге пычракларда председатель итеп яшь-яшь егетне китерделәр. Райкомның авыл хуҗалыгы мөдире җыелышта аны күкләргә чөйде: «Колхозның киләчәге — газиз илебезнең киләчәге ул, ә илнең киләчәге Сабит Нургалиев кебек уңганнар кулында»,— дип мактады. Ходайның әмере шул булгандыр, җыелыштан соң кичке чәйгә яңа рәисне, аны озата килгән вәкилне, авыл куштаннарыннан берничә кешене Сөмбелә яшәгән квартирга алып кайттылар. Сөмбеләнең кызларча пөхтә җыештырылган дивары әти-әнисенең, туганнарының фотоӘсемнәре белән чуарланган, киштәсендә китап-журналлар тезелеп яткан җыйнак кына почмагы бар иде. Чаршау-пәрдә белән бүленгән олы якта хуҗалар — әби-бабай гомер кичәләр. Сөмбеләнең уңганлыгыннан хәйран калганнар, «үзе чиста, эше пөхтә, өйне гөлдәй итеп тота, аш-суга осталыгына исең китәрлек; теле ягымлы, үзе чибәр, буе зифа...» Бабай очынып мактаганда әби тешсез авызын мыймылдатып, күзенең агы белән генә карап куйгалый, имеш...

Юкарак озынча гәүдәле, күлмәге аша төртеп торган беленер-беленмәс күкрәкләре кебек кыюсыз иде Сөмбелә. Әз сүзле, ягымлы ихлас врачны әби-бабай гына түгел, бөтен авыл үз итте, яратып өлгерде. Уймак авызының тулышкан иреннәре сафьян кебек йоп-йомшак, чәчләре колак тирәсендә бөдрәләнеп киткән, кашлары җемелдәп торган кап-кара иде кызның.

Сабитның өйләнмәгән егет икәнен клубта чакта ук кызларның чаяраклары колактан-колакка сөйләгәннәр иде инде. Сөмбелә—институт тәмамлаган дипломлы врач, унбиш кешелек кенә больницасы бар, инде өченче елын эшли, кияүгә чыгу өмете сүнеп-сүрелеп куйган мизгелләре булгалый, бердән — кызның буе озын, икенчедән — врач, өченчедән — чибәр дә, ул төпләнгән авылда, күрше-тирәдә аңа тиң булырлык, тиң санап сүз катарлык егет-җилән юк иде. Сабитка күз атып чышынпышын сөйләшкән кызлар арасында ул тып-тын утырды. Җыелышны ташлап чыгып, тиз-тиз өс-баш алыштырып килүчеләргә дә игътибар бирмәде. Сабитның үз-үзен тотышындагы тыйнаклык, теленең матурлыгы, тавышының горур көрлеге аны беразга җәлеп итсә дә, Сөмбелә бүтәнне уйларга өлгермәде. Аны җәлт кенә партоешма секретаре чакырып алды һәм өенә ашыгырга кушты. «Сынатма, сеңел!» — диде.

Андый «кичке чәйләр» үткәргәне булмаса да, Сөмбелә каушап төшмәде, бик ашыгыч кына пилмән бөкте, мич ягып вак бәлеш утыртты, тозлы кыяр турады, башлы суганга көнбагыш мае сибеп салат ясады, ризыкларының һәммәсен өлешләргә бүлеп, бар булганын матурлап өстәлгә тезде. Кәрәзле балны әллә ничек тылсымлап кисеп торганда лапыр-лопыр атлап, күн итекләренә балчык төяп, ир-атлар кайтып керде. Алар күңелле гөрләшеп мич арасында бит-кулларын юып, чәчләрен ыспайлап тарап, туп-туры табын тирәсенә сырыштылар. Аш өлгергәнне көтеп тозлы кыяр, салкын ит калҗалары капкалап, тустаганнарын еш-еш күтәрә башладылар. Пилмән чыкканда йөзләре килгән иде аларның. Яңа рәиснең тустаганга бик чамалы кагылуын, өлкәннәр сөйләгәндә алга чыкмавын, берәүне дә бүлдермичә ихлас тыңлавын өй белән чолан, чолан белән келәт арасында тыз-быз йөргән Сөмбелә күрми калмады, әлбәттә. Гаҗәпләнде, аның гел чоланга, келәткә чыгасы гына килеп торды. Келәт, чолланнарга кагылганнан соң табын тирәсенә ни булса да китерергә җай чыга иде. Яңа рәис тә әле тоз сорап

алды — тозга кагылмады. «агач кашык бирегезче!»—диде—үзе калай кашык белән ашады. Ирләр ачыкканар икән, пилмәнне өстәтә-өстәтә состылар, ак серкә китерткән Сабит аңа да үрелмәде. Инде бүтән ризыкка урын да юктыр дип чыгарган вак бәлешнең йогы калмады, комагайланып, табында ни бар, бөтенесен ашап бетерделәр.

Тамагына берни капмаган, арган, маңгаена бөрчек-бөрчек тир сибелгән Сөмбеләне иң актыкта, китәргә дип җыенганда кунаклар үз яннарына чакырдылар. Үзенең арзанлы ситса күлмәге, йомшак-ягымлы карашы, татар кызларына хас мөлаем-сабыр тыйнаклыгы белән ул Сабитның күнелен җилкетеп алды. Җанының болай да язгы сулардай ташыган чагы иде, председатель булып киләсең икән, өйләнмичә ярамый, тәрҗемәи хәлләрне кәгазьгә тутырганда «өйләнгән, өйләнмәгән» дип теркиләр икән, бу инде бер дә юкка түгел, өйләнмәгән кадр — басудагы җил ул, әле генә монда, кул арасында иде, күз ачып йомганчы Карама куышка барып җиткән.

Сабитның күнел ачардай таныш-белеш кызлары шактый булса да, «Өйләнәм!» — дип күз тоткан кешесе юк иде. Сөмбеләнең дүрт яшькә олырак булуы аны бер мәлгә икеләндерде дә онытылды. Күз төшеп, күңелгә дәрт ояласа, яшькә карап торалармы?

Сабит төпсез күзе һәм утлы карашы белән алдыра иде. Сихерле, тирән иде аның карашы, кеше җанын үтәли тишә ала торган сөрмәле күз бүләк иткән иде юмарт табигать бу егеткә.

Кичлекләре калмаган хуҗалар, әтәч белән тити, әллә кайчан йоклаган булганга, кунакларны барлап озату да Сөмбеләгә йөкләнгән иде. Соңгы кеше булып ишеккә яңа председатель килде, чыгарга ашыкмады, сүз дә әйтмәде, кызның калтыранган кулларын кысып, һич көтмәгәндә аның татлы иреннәреннән үбеп алды. Иреннәрнең кызыктыргыч матурлыгына керүгә сокланган иде, аларның сусыл йомшаклыгы, кызның татлы сулышы, тыны егетнең башын әйләндерде. Ул тагын бер үбим дип үрелгән иде, сагайган кыз, юк, ачуланмады, кәҗәләнмәде, айдай балкып башын читкә какты, бөдрәләре колак тирәсендә уйнадылар. Авызга үрелгән Сабитның иреннәре кызның юка иңбашына кагылды, йомшак икән аның тәне, канны кайната, дәртне уята торган тән икән!

Председатель булып килгәч, ул эшне тиз тотты, ике ай дигәндә алты почмаклы якты йорт җиткезделәр, морҗадан беренче төтен ургылып чыкканда, яңа йортка авылның яңа хуҗасы килен төшерде. Яңа нигездә яңа тормыш башланды, уллары туды. Малай көткән Сабит Сөмбеләсенә тагын да ныграк якынайды. Сабит Саратовка укырга киткәнче алар хәйран матур яшәделәр. Өйләнешкән елдагы гаугалар, юк-бар арасында килеп чыккан низаглар кими төште.

Ике ел эчендә Саратовтан Сабитны алмаштырып кайтардылар. Кыяфәте, төсе-бите генә түгел, исе, кыланышлары, кешеләргә мөгамәләсе, сөйләү рәвеше, килеш-килбәте үзгәргән иде аның. Төнлә кайтып керде, бәләкәй караватта авызын чәпелдәтеп яткан йомры улына сыңар күзен төшергәч, сөенеченнән балкыган хатынына бер сүз генә әйтте: «Чишен!» Тәне куырылып, җаны өшеп киткән хатын нишләргә белмичә арлы-бирле талпынган арада тагын бер хөкемен игълан итеп өлгерде: «Моннан ары, мин көннең-төннең кай вакытында кайтып керсәм дә, иңеңдә юка халат кына булыр. Бүтән берни юк!» Сөмбелә кызмача ирнең мондый шартын көлкегә алды: «Син кайтканны хәбәр итеп торырга капка төбенә сакчы куй алайса!» — диде. «Куярмын да!» — диде Сабит һәм һаман аңына килә алмаган хатынының өстеннән чүпрәкчапракларны умырып, йолыккалап теләсә кая ыргыта башлады. Аның корыч бармаклары Сөмбеләнең йомшак тәненә умырып, ертып керде, Сабит тыелгысыз, ач хис белән ими башларын тешләп, чәйнәп бетерде.

Шуннан террор башланды. Төн ката ризасызлык, зар сүзләре, чиксез оятсыз таләпләр... Ә көндезләр—төннең дәвамы: «Нигә тәлинкәңне

тутырасың, бирән түгел ич мин!». «Ике көн рәттән токмач та кашык чумары! Миңа тау бүксә тагарга телисеңме?» «Вак бәлеш» — «тавык җимеше» булды, өчпочмак—«искелек калдыгы». Сөмбелә яратып пешергән кәбестә ашы «юынтык су»га әйләнде. Гауга кухнядан караваткка, караваттан аш-су тирәсенә ялгана торды, өзелмәде. Сабит хатынынннан чыкылдап торган бозыклык таләп итте. «Тәнем тартыша, Сабит, кыймыйм»,— дип аңлашырга омтылган тыйнак хатынын Сабит караваттан төртеп төшерде. Нык кына салып кайткан иде...

«Яраббым!—дип ялварды, бала чагында догалы йортта әби-баба тәрбиясе күргән, кукрәгендә ходасына, тәңрегә ышанычы бетмәгән хатын.— Ике еллык уку кешене танымаслык үзгәртә алыр икән! Шул партшкола бозды Сабитымны! Нигә адәм балалары бер дә уңай якка үзгәрми дип йөрсәм, укуларының кире якка бора торган хасияте көчлерәк икән!»

Иренең аяусыз коллыгына төшкән мизгелләрдә курка-курка гына әнә шулай карганды Сөмбелә. Икенче бәбәйләре кыз булды. «Син ник бу дөньга кыз китердең?Дөнья алардан ни файда күргән? Анабыз һава ахмаклыгы аркасында без оҗмахтан куылган!»

Аның мондый өйрәтүләренә исе китми башлаган Сөмбелә иренең кайбер фикерләренә һаман шакката иде. «Әүвәлдә «кара халык—кара сарык» дигәннәр. Халыкның карасын сарыкка әйләндерү читенме? Тефү! И все! Хәзер менә мин, Сабит Нургалиев, «ак халык—кара сарык!» — дип игълан итәм. Халык — тоташтан сарык көтүе ул, аның агартылган, белем алганы да «кара сарык». «Бусы да Маркстан отып алган фикерме?» — диде аптыраган Сөмбелә. Ире, гадәтенчә, аны мыскыллап, өстән аска карады. «Маркс тарихның бүгенге көннәрен күз алдына да китерә алмаган. Идеалист булган ул, наив, беркатлы. Мәсәлән, кем уйлаган Маркс-Ленин тәгълиматы белән туган дәүләтләр, кызыл әләм болгап, бер-берсенә каршы сугышка чыгар дип? Бармы андый шик Маркста? Маркс түгел, Ленин да андый каршылыкларны күз алдына куя алмаган. Ал социалистик илләрне! Югославлар Ленинны үзенчә укый, ә албаннар үзләренчә тукый! Кытай белән Вьетнам кан коеп сугыша: ике гаскәрнең дә кулында кызыл әләм! Чехлар бер якка карый, мадъярлар бөтенләй икенче якка. Чыгарып кара немецлардан безнең армияне, кая карап чукыныр лар икән! Дөньяда буталыш, тәгълиматлар очып-очып төшәләр. Иртәгә кем тәгълиматы өстен чыгасын, ни буласын чамалап кына әйтә алучы да юк. Шундый чакта бер төркемгә тупланган асыл ирләр сарыкларның агы, карасы өстеннән идарә итеп оҗмахка чыккан икән, минем урыным кайда булырга тиеш? Яшәп калыйк әле! Яшәп! Әйе, халыкны агартырга кирәк. Ак халык та Ленинга табынсын. Маркс-сакалбайны пәйгамбәр дип санасын. Һәр тәгълимат иртәнге күе томан, томанда нәрсәләрнең шәкеле үзгәрә, төз агач та кәкрегә әверелә. Әнә шул томан таралмасын дип телә! Бичара син, надан!»

«Бичара», «надан», «аңгыра», «томана» — Сөмбеләнең иреннән ишеткән сүзләре гел шул булды. «Бала бага белмисең, чөнки син надан, томана!» — дип ул балаларны Әзигә илтеп ташлады. «Татарча белү абзар артына барырга гына ярый, урысча өйрәнсеннәр!» «Аш-суыңның рәте-тәме юк!» — дип ул йорт карауны толымын көнгә биш сүтеп, биш үрә торган, кияүгә чыкмаган юха Бәдәргә тапшырды.

Ир хатынының мәшәкате кырыкка төрләнгән. Гаиләдә беренче булып таңнан ул сикереп тора, көн туса утыз-кырык чакрым җир үтеп, кулы аша тонна-тонна авырлык үткәрә, кичне каршылый һәм, өй эшләрен йомгаклап, иң соңгы кеше булып караватка ава. Ләкин хатын-кыз үзенә язган мәшәкатьләр гадел булганда, җиңел үткәрә, арса да зарланмый, ирен бага, бала-чагаларын сөенә-сөенә карый. Әле төп эшенә барырга да өлгерә. Һәм көннәрдән бер көнне шушы рәхәт мәшәкатьләр Сөмбелә кулыннан китте. «Үтүкләнгән кереңнән селте исе килә»,— ди-

де Сабит. Пешергән коймагын: «Төерле!» — дип юынтык су чиләгенә илтеп аударды. «Син мине агуларга телисең!»—дип җикеренеп, аш-су тирәсенә яңадан җибәрмәде. Больницасыннан чыгарырга да омтылды, ләкин бу юлы Сөмбеләне җиңә алмады.

Эш табалмаган хатын биләмгә чыга, өй серләрен читкә чәчә, ирен көн саен таптый-таптый кумә. Сөмбелә андыйлардан түгел иде: түзде, чыдады, дәрәҗәсе һаман диярлек үсә барган коммунист ирен җәлләде, балаларының әтисен кызганды. «Әзрәк сабырланмасмы, җайга төшмәсме?» — дип кич-иртәләрен тәңрегә ялварды. Сабиты Казанга киткәнне көтеп алып, авылда мулла вазифасын башкаручы аксак Гыйльметдин абзыйны чакырып, Коръән укытты. «Ни теләкләрең бар, килен?» — диде Гыйльметдин ахырда. «Сабитымның гомере озын булсын, аны әдәп-тәүфикъ ташламасын!» — диде күзен качырып Сөмбелә. Изге Коръән аятьләре дә ипкә китерә алмады Сабитны. Инде балаларыннан да коры калгач, Сөмбелә биреште, ике бите ике карындык булып саргайды, кигән күлмәкләре чөйгә элгәндәй асылынды, күзенең нуры түгелде, кыз чагында буш вакытында мандолина чиртә иде, ул сердәшен дә чормага менгереп ыргытты, бердәнбер юанычы китаплар һәм әнә шул почмактан-почмакка өч адымлы аулак бүлмәсе калды. «Килгән-киткән кешегә булыр»,— дип эшләткән иде аны Сабит, Сөмбелә бәхетсезлегенә булган икән. Хәл эчендәге авырулар барында больницада, врач бүлмәсендә кунарга калгалады, Сабит монысын катгый тыйды, өзмәс шалтыратып, хатынына тынгы бирмәде.

Хатын-кыз ничарадан-бичара иренең азгынлыгына күнегә, иләшә, йөрәк маен сыза-сыза, күз яшенә манчылып, кара кайгыга сабышса да түзә. Аны өмет яшәтә. Күшеккән җанын өмет җылыта. Кайгысын өмет җиңәләйтә. «Менә балалар исәйсен, ныгысын, акылга утырсын... Алар, мөгаен, Саратовка партшколага тап булмаслар, Маркс-Энгельсларны укып һаваланмаслар, гади — татарча әдәп-тәртипкә өйрәнерләр. Дөнья танырлык күзләре ачылгач, Сөмбелә гомер юлында татыганнарын аларга сөйләр, күңелен бушатыр, газаплардан котылыр. Яши-яши, бәлки, Сабит та тәүбәгә килер!»

Авыл арасында «брач апаның» ничек яшәгәнен, ниләр кичергәнен беләләр идеме, юкмы — аны Сөмбеләгә килеп әйткән кеше табылмады, ул үзе аксак Гыйльметдин белән очрашканда кызарынып, күзен аска яшерә торган булып китте, биргән сәламенә җавап көтеп тормады. Зирәк карт, Сөмбелә үтеп киткәч, борылып карый да тирән итеп көрсенә иде.

Балалары хакына түзде Сөмбелә, «Әгәр алар әтиләре белән генә калсалар, канечкеч ерткыч-җанварларга әйләнерләр!»,— дип курыкты. Халыкның агы да, карасы да кара сарык көтүенә әверелә барганны Сөмбелә куркынып, күзен ачып күзәтә иде...

«Казаннан хатыны белән энекәш кайтып төшкән, ярты көнгә генә аларны чакырып алмый булмас»,— дигәч, Сөмбелә югалып калды. Ул хәзер нишләргә тиеш? Кунаклар алдында ире аңа нинди урын бирә? Түрнеме, ишек катынмы? Әгәр Сабит, Сөмбелә бөгелеп-сыгылып кунак каршылар, дип көтә икән, анысы булмас! Өйдә нинди тәртип яшәсә, энекәше түгел, чурт килсә дә, шул тәртип калыр. Аш-суны Бәдәр әзерләсен, кунаклар җаеннан да ул торсын, бер самавыр чәй куеп та эчертәчәк түгел Сөмбелә чакырылмаган кунакларга!

Бүлмәсенә кереп утыргач, уена бүтәнчәрәк фикерләр килде. «Әгәр дә мәгәр,— диде ул,— бертуган энесенең кайтуыннан файдаланып, өебез эчендәге шомлы хәлләрне, Сабитның явызлыгын, кансызлыгын, азгынлыгын, хатынын терәләй ләхеткә тыгуын түкми-чәчми ачып салсам?.. Ялган-яла катыштырмыйча бары тик дөресен генә сөйләп бирсәм!!? Кемдер белергә, мин исән чакта белеп калырга тиештер ич аны? Ичмасам, бертуган энесе белән аның хатыны дөнья йөзендәге биш миллиард кеше арасыннан Сабит Йосыф улы Нургалиевнең тамырын,

үзэген белеп торсыннар! Аның сәяси карашлары белән танышсыннар, иманын ачыкласыннар. Сабит Нургалиев фәрештә булып яшәмәс моннан болай! Хак тәгалә күрәдер, сул иңендәге фәрештәләр, алмаш-тилмәш өч сменалап эшләсәләр дә, ул кылган гөнаһларны теркәргә пергамент җиткезә алмыйча интегәләрдер, языклары өчен адәм угыллары дөньялыкта да җавап бирергә тиеш, дигән акыл бар микән Маркс томнарында?! Саратовта эзрәк шул сүзләрен дә укытмадылар микәнни? Дөньяны бутап бетергән, ил башына һәрчак канәчкеч тиран менеп утырырлык сукмак, мөмкинлекләр калдырган, илләрне илләргә өстерүгә корылган бу тәгълиматта кешелек сыйфатлары, шәфкать, мәрхәмәт дигән заруриятләр бер дә юктыр шул! Миллионлаган ахмаклар, шуңа таянып, егерменче гасыр дәвамында миллионлаган адәмнәрнең башын кыймаслар иде югыйсә!»

Шулай уйлады Сөмбелә. Уй-фикерләренең дөреслегенә ышанып ук бетмәсә дә, шулай фикер йөртте. Ул кунакларны капка төбенә чыгып каршылады. Каен энесе белән килендәшенең кемнәр булуын үз күзе белән күрәсе килде. Юк, Сабит кисәткәнчә хәтәр кешеләр түгел иде кунаклар, икесе дә басынкы, тыйнак, барыннан да бигрәк үзара тату, дус күренделәр. Моңарчы алар бусагасын таптаган һавалы, тәкәббер кешеләрдән нык аерыла иде болар. Игътибарлы кешеләр, табын янына бер вакытта утырдылар, бергә калкындылар, балалары да тәртипле икән, аш тирәсендә әрсезләнмәделәр, әниләренең күзенә багып кына ашадылар.

Өс-башлары да уртача, алып килгән бүләкләре арзанлы, әмма зәвыклы иде. Зонтик әйбәт бүләк, аннан бигрәк Әлфия Афзалова җырлары Сөмбеләгә көтелмәгән бүләк иде. Ул җырлар тәлинкәсен күкрәгенә куеп торды да, тиз үк уйната да башлады.

Бу кунаклар белән мөнәсәбәт үзгә иде, аларның ят-ябага шомарткан бусагасы аша туганнары, к а н  к а р д ә ш л ә р е кергән иде бүген. Сөмбелә гадәтләрне үзгәртте, аш-суны да Бәдәр түгел, бүген Сөмбелә үзе чыгарды. Кичке аш күңелле үтте, табынга эчемлек куймады, татарча, бер-берсенең күңелен табып, җай гына әңгәмә куертып чәйләделәр. Иртәнге чәй алай була алмады. Сабит кырыс иде, кара бүкәй, ашыкты, кабаланды, чәен ашъяулыкка түкте. Сөмбелә дә тиз-тиз юкка чыкты, кунакларның олысы гына түгел, кечеләр дә борлыгып калдылар, «Бабайларга кайтыйк!» — дип дауладылар.

Сабитның көн уртасында кайтканын, кунакларны дөбердәтеп, ашыктырып кая алып киткәнен Сөмбелә ишетеп утырды. Мисыр күгәрченене кебек гөрләп, Бәдәр балаларны янбакчага алып чыкты, һаман бер сүзне тугылады: «Монда керпе оялый торган иде, кая китте икән ул? Әллә быел ояламаганмы мәхлук? Әйдәгез, балалар, эзлик». Ары бара — шул ук сүз, бире килә — телендә һаман керпе! Фу, бу нинди бетмәгән керпе инде?..

Нигә бу малай актыклары: «Бабайларга кайтыйк!» — дип үкерәләр?

Ул бүлмәсеннән чыкты, төрледән-төрле назлы сүзләр әйтеп, малайларны дәртсендереп аш өенә алып керде, өстәл янына кара-каршы утыртты һәм бик юка телемнәргә турап бәрәңге куырырга куйды, җәһәт кенә төче коймак изде. Малайларга коймак та, майлы бәрәңге телемнәре дә, Сөмбелә апаларының җылы карашы,татлы теле дә ифрат ошады, алар, әвен сугып кайткан егетләрдәй, ризыкларны сыпырып куйдылар. Сөмбелә кат-кат сорады: «Тәмлеме? Төерле түгелме? Агу тәме килмиме? Әче түгелме? Йомшакмы?»

Авыз тулы коймак, чәйнәгән саен тәмләнә, малайлар Сөмбелә апаларына күз уйнатып кына җавап бирделәр, аның мазасын аңлап бетермәделәр. Керәп, ишек катында нидер мыгырдап басып торган Бәдәр, чәч толымнарын җилфердәтеп, йомылып кына чыгып тайды...

Коймакка ялгап чәй эчәргә тотынганнар иде, капка төбенә машина килеп туктады. Сөмбелә куркынып тәрәзәгә ябырылды. Капка ачыл-

ды, озак та үтмәде, аш өенә тыны-өне бетеп Наилә килеп керде. Сөмбеләнең бу хәлгә акылы җитмәде. «Ничек алай бик тиз кайтасы иткән?!»— дип эченнән кабатлый-кабатлый, үз килендәшенә текәп карады. Теле: «Ник бәйрәмне ташлап кайттың?»— дип сорады. «Сезне алырга, сине, балаларны!»— диде Наилә, авызын учы белән каплаштырып. Коньяк исен килендәшенә бер дә белдертәсе килми иде аның. «Мине алыргамы? Балаларны?» «Әйе, сине алырга. Күңелле икән анда! Рәхәтләнеп ирек ачып, йөреп кайтыйк». Сөмбеләнең икеләнеп, ышанмыйчарак торуын күргәч, Наилә ашыктырды. «Көттермик! Сабит абый: «Җәһәт килеп җитегез!»— дип кычкырып калды!»

Ни булган Сабитка? Тагын алыштырганнармы? Бу юлы сабакны кем бирде икән? Энесеме? Оҗмах аланына ничә ел рәттән кунакташып, бер тапкыр да хатынын чакырганы юк иде. Туганы белән күрешкәч, әз генә күңел бозы эреп киттеме әллә?!

«Ярабби, тәңрем! Шулай булсын кана! Языклы бәндәләреңнең күңеленә дә шәфкать чаткысы, миһербанлык иңдер!»— дип кабатлады Сөмбеләнең шиңгән чәчкә төсле иреннәре.

Малайлар әниләренең кочагына атылдылар.

## 25

Тимер юллар министры уттан котылса да, алар утырган затлы вагон сасы көлгә, кәкрәеп беткән тимер-томырга әйләнгән иде. Янгынның сәбәбен, нәтиҗәсен тикшерер өчен Мәскәүдән өч кешелек комиссия килеп төште. Казаннан да берәү өстәлгәч, бу гадәттән тыш төркем дүрт почмаклы булды һәм хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевичны хафага салды. Мондый төр комиссия белән эш йөрткәннәре юк иде әле аларның! Тикшерүчеләр саны арткан саен эш зурга китә, аларның күңелен табу кыйммәткәрәк төшә бара иде. Җирле кешенең комиссия составына керүе дә хәвефле, мәскәүлеләр «печән хакын» белә, алар түтәленә күпме сипсәң дә, сеңәчәк вә онытылачак.

Дөньяның бүтән тармакларыннан да салкын җилләр искәләде, тимерьюлчылар, ваемсызланып, рәттән өч квартал планын үтәмәделәр, пассажирлардан шикаятьләр арта торды, үзәк газеталарның берсендә Басыйр Бариевичның хуҗалыгын аркылыга-буйга теткән мәкалә басылып чыкты. Газета корреспондентын кабул итеп, эш белән таныштырып йөргән Исламнурга хуҗасыннан шактый авыр шелтә эләкте. Исламнур акланырга теләп болай диде: «Заман борылыш ясый, Басыйр Бариевич, кайбер кешеләрне аңлап булмый! Килде корреспондент, Зимин урамындагы иң затлы кунакханәгә, футбол кыры хәтле люкска урнаштырдык. Аш ташырга, кәефен күзәтергә иң гүзәл официанткабыз Оляны куйдык. Озатканда сумкасына ысланган чехонь, симез-симез сазаннарны үзем тутырдым. Рәхмәт әйтәсе урында, күрдегез, ниләр казып чыгарган. Заман үзгәрә дип беләм».

Акылга һич сыймый торган шөбһәле уйлар Басыйр Бариевичның үзенә дә килгәли иде. Тикшерергә килүчеләр бу юлы бер дә бил бирмәстәй маташалар! Биргән бүләкләрне чырай сытып кына алалар! Соң, паровоз бүләк итә алмый ич инде ул аларга! Ярамаганмы затлы бүрек, тун ише нәрсәләр?! Ә берсе, ә берсе... «Эшне Иван Ивановичка визит ясаудан башлыйбыздыр?»— дигәч, «Соңыннан, соңыннан!»— дип карышып катты. Хатынына бушлай путевка тоттыргач та йомшамады. Аңла син замана кешеләрен!

Җыелышларда, пленумнарда, хәтта бюроларда да гел макталып килгән Басыйр Бариевичның эче китә башлады. Хурлык, әдәм көлкесе, билләһи! Иван Иванович белән очрашып «хәлне бераз төзәтер идең», ул үзе сырхау, кан басымы уйный, әле аска төшә, әле

сикерә. Берәр атна ятып торырга, җаваплы эшләрдән читтәрәк булырга иде дә, кая ул, шәһәр советының сессиясе якынлаша, Мәскәү вәкилләренең соравы буенча анда тимер юлдагы житешсезлекләр дә карала-чак. Ах, бик тә вакытсыз килеп төште бу Мәскәү әрләннәре! Каян шундый кылчык бәндәләр табыла диген! Ходаем, кил, кара, тикшер — тап! Чокчып чыгар баскычның түбәнге аратасына кунган бер мәхлукның ялгыш-хаталарын! Һәйбәтләп шелтә белдерербез, бүтәннәргә сабак булсын өчен бүтән эшкә күчерербез, акчасын әз алганы өчен хатыны сыртын каезласын тегенең! Юк бит, туймыйлар ачарбаклар, югарыга үреләләр! Кемгә дигән әле!.. Басыйр Бариевичка! Хөрмәтле Иван Ивановичның ахирәт дустына! Җиде орденлы җәмәгать эшлеклесенә! Ходавәндә, чокчынырга керешсәң, хан кызында да кечтеки генә гаеп табыла диләр түгелме?

Ашыгыч чараларын күрергә, судан коры чыгарга, утка салсалар да, янмаска кирәк. Судан коры чыгаручы, яман уттан йолып алучы бер нәрсә бар — акча! Иван Иванович алдына барып тезләнергә дә өч бүлмәле берәр квартира алырга. Ионыч кулына андый мал төшсә, нишләтергә белер! Кертсен Урта Азия, Кавказ ягы базарчыларын! Алар... акчаны суга! «Волга» машинасына күз йоммыйчы кырык меңне чыгарып салалар икән. Әллә тимер юлчылар фондына кайткан ике-өч машинаны шуларга бөдәргәме?.. Ник үзгәрде бу мәскәүләләр?! Бөтенләй каефне бозалар, кара йөзләр... Мондый стратегик мөһим мәсьәләләр, әлбәттә, кабинетларда хәл ителми, мондый житди мәсьәләне аулакта, кеше күзеннән читтә үткәрергә мөмкин. Иван Ивановичның да Басыйр Бариевичта тәҗел йомышы бар иде: соңгы вакытта ил буенча яңа бер дулкын кузгалды — кешеләр дәүләттән җир алалар да дача җиткереп керәләр. Дөрес, әлегә Иван Ивановичның да, Басыйр Бариевичның да ул җәһәттән зар-моңнары юк, теләгән чакларында югары катлау вәкилләренә аталган затлы дачаларга, Боровое Матюшино тирәсенә баралар да төшәләр. Тимер капкалар ачыла, караучылар үрә катып честь бирәләр: «Ләббәйкә, Иван Иванович!» «Рәхим итегез! Басыйр Бариевич!» Аяк табаның кычытса, әйдә Кырымга кит, Кавказ тауларына мен, нарзан ванналарында кайна. Өлгер секретарьлар, урынбасарлар әмереңне көтеп кенә тора, путевканы күз ачып йомганчы китереп житкерәләр. Шулаен шулай да, ярый ла эшең китсә гел уңайга! Әнә бит күз алдында дөнья кайный! Үзәк газетаның өтек бер хәбәрчесе шәһре Казанның гына түгел, Татарстан җөмһүриятенең алтын баганаларына кизәнә. Иртәгә кизәнеп кенә калмас, муеныңны кыеп төшерергә дә чирканмас! Балта бүгенгә алар кулында, иртәгә йә берсекөнгә аның кулдан ычкынуы ихтимал. Кем кулына барып керә ул, балтаны кайсы якка карап селтәрләр, аны берәү дә белми. Калынкаш бабайның да сәламәтлеге начар диләр... Имеш, дару урынына әрмән коньягын эчеп кенә тора икән...

Ике акыл — олы акыл. Иван Иванович өстенрәк торып, Басыйр Бариевич аның авызына карап, икесе ныклы уйга килделәр: дача шаукымы дөньяга таралганчы, әте-бете уянганчы, Иделнең гүзәл почмагында, Әнисә абыстайлардан ерак түгел бушлыкта җир алырга, җәй башыннан калдырмыйча эшкә тотынырга һәм бер ел эчендә дача йортларын салырга кирәк!

Май урталары! Иң гүзәл ай! Юкка гына алма, чия агачлары шушы айда чәчәк атмый! Тургайлар шашына, күке егетләре тыела алмыйча кычкырып күке кызларын эзлиләр, меңнәрчә сайрар кошлар, барлыкларын белдереп, төрле тавышларга чыркылдашалар, оя тибәләр, бер-берсен эзләп табалар, бала чыгарырга утыралар. Мондый вакытта кавышкан Иван Иванович белән Басыйр Бариевичның тантанасының тагы инде мунча түгел. Дөрес, мунча керәләр алар, чәркәләр дә бушап тормый, әмма бүген максат бүтән! Тимер юл белән Әнисә абыстайның каз көтүләрен аерып торган ямь-яшел

урман кырындагы коры, тар сукмактан арлы-бирле йөрергә яраталар алар. Алдан, ике җилпуч кулын Везувий вулканы хәтле корсагы өстендә ял иттереп, вәкарь белән тамак кыргалап, Иван Иванович атлый. Аның артыннан арба кучәреннән төшеп калган чәкүшкә Басыйр Бариевич теркелди. Теркелди Басыйр Бариевич, үзеннән алда теле бара Тел төбендә Иван Ивановичны мактау! Урысны мактап кына балта сабына ия булырга мөмкин икәнен татарларга моннан күп гасырлар элек Иван патша сеңдергән. Татарның бер гореф-гадәтен дә белмәгән Басыйр Бариевичлар каян шулкадәр нык үзләштергәннәр аны? Бара Басыйр Бариевич, елан угы төсле теленнән бал тама... «Бездә, татарда дим, хөрмәтле Иван Иванович...— Шулай башлый да Басыйр Бариевич сагаеп: — Хәер, минем татарлыгым да инде!.. Ә мин малайларны рус дип яздырдым, әйе, рус дип!» «Син нидер бүтән сүз башлаган идең»,— дип гөрселди Иван Иванович. «Ә, исемдә, исемдә. Имән кебек ирләр, диләр... Әллә сезнең кыяфәтне, сезнең мәгърур гәүдәне күреп шулай әйткәннәрме дип уйлыйм... Хак! Имән дә имән, сез дә имән!» Иван Иванович чак кына адымнарын акрынайта, әкренрәк баса, аның Басыйр Бариевичның һәр сүзен ишетеп каласы килә. Янына ук кысылыр иде Басыйр Бариевич, нәләт суккан сукмак тар, тавышын көрәйтер иде — чыкмый, кычкырса, саескан сыман чәтерди башлый. Ул бик озаклап тимер юл буйларына утырткан агачлар хакында белешмәләр бирә, кемнәрнеңдер чүп агач — америка өрәңгесе утыртып, хәзер шул агачның, азынып, урманнарга үтеп керә башлавын каһәрли (Мәскәүдән килгән корреспондент шәхси әңгәмәдә әйткән сүзләр!). «Ә без, күрәсезме, юл тирәләрен тутырып имән утырттык. Имән! Үзебезгә үзебез һәйкәл салдык, хөрмәтле Иван Иванович! Алдагы буыннар безне гел мактап искә алсыннар. Шулай түгелмени?»

Бу әңгәмә архирәтләрнең исендә калып, алар еш-еш юл буе имәннәрен үзләренә тиң агачларны хәтергә төшерәләр иде. Инде шушы тирәдә җир алып куйсалар, имәннәргә карап, горурланып яшәячәкләр бит! Хак! Иван Иванович имән хакында сүз чыкканда Басыйр Бариевичның күңелен бераз кырды, инде онытылып беткән татарлык хисләренә кагылды... «Руста да бар андыйрак атама,— дип җөпләде Иван Иванович,— элеккеге заманда, рус гаскәрләре татарларны кырган чакта, гаскәриләрне «дубы — могучие великаны» дип йөрткәннәр».

Бүгенге май кичендә мунча искиткеч шәп буласы иде, Мәскәүдән килгән корреспондент белән чатак чыккач, үз-үзен битәрләп йөргән Исламнур бүген үзен күрсәтеп, яхшы атын кире кайтарырга тиеш иде. Акча, җир мәсьәләләре хәл кылынып, алдагы көнгә матур планнар сызылачак иде... Үткәнендә Басыйр Бариевич Иван Ивановичны «имән» дип мактаганда үз адресына дан сүзе чыкмагач, чак кына рәнҗеп тә йөри иде. Яшермик, Иван Иванович та Басыйр Бариевичны берәр затлы агач белән тиңләргә теләп, аңа борылып-борылып карады. Фантазиясе бай түгел шул, чагыштыру таба алмады. Басыйр Бариевич үзе дә... Иван Ивановичка якынаям дип, сукмактан читкә, әрекмән арасына кергән... Юк, Басыйр Бариевичны бик яратса да, мактарлык сүз тапмады ул чакны Иван Иванович. Ә бүгенге очрашуда аны тамырлары тирән киткән агач белән тиңләргә әзерләнде...

Бүгенге очрашу мәҗлесе гаҗәеп шәп, нәтиҗәле һәм бәрәкәтле булырга тиеш иде.

Эңгер-меңгер тәмам куерып, этәч белән тавыклар куначаларга менгән мәлдә, тимер юл белән параллель барган таш юлдан Әнисәләр ихатасына таба бер-ике артлы ике машина борылды. Кыр буш, кыр өстендәге һава хуш исләр белән генә тыгызлап тутырылган иде. Ләкин хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Барие-

вич берни күрмәделәр, ис тә сизмәделәр, алар, берсе ишелеп, берсе очып машиналарыннан төштеләр. «Нәрсә бу?» — диде Иван Иванович, Американың явыз полицияләре йөртә торган күсәк юанлыгы бармагы белән кыр өстенә күрсәтеп. «Белмим»,— диде куркудан ыңгырчак биеклеге генә калган Басыйр Бариевич. Әнисә абыстайның көтүлекләре шакмакларга бүленгән һәм шакмак читләрендә лилипут гаскәрләре булып ап-ак, өр-яңа чөйләр җемелди иде. «Бала-чага уйнаган дисәң»...Басыйр Бариевичның авызы ачылды да ябылды. «Нинди бала-чага?!— дип күк күкрәтте Иван Иванович. — Ызаннар тигез, чөйләр күп, имәнлектән авылга кадәр иңләгәннәр! Дачалар! дачалар! Җирне бүлгәннәр! Кайсы явызы безнең өлешкә кергән?!» «Булмас,— диде акланырга бик теләп Басыйр Бариевич.— Сез шәһәр башлыгы, сездән башка ерып керергә кем җөрьәт иткән?»

Сүзен эш белән беркетергә яраткан Басыйр Бариевич, туфляларына туфрак тулуына карамастан, кыр өстенә кереп китте һәм «мисле Чыңгыз гаскәре» кебек тезелгән агач чөйләрне батырларча йолкып ыргытырга тотынды. «Бу бәладән чөй чыгарып кына котылып булмас,— диде шунда ук эшлекле кыяфәткә кергән Иван Иванович.— Бу зур мәсьәлә! Кемдер безнең юлга агач аударган дигән сүз. Кем?!» «Кем генә булмасын, чарасын күрергә! Танавын канга батырырга кирәк аның!» — дип чырылдады саескан Басыйр Бариевич. «Канатырбыз да, кирәк икән — төрмәгә тыгарбыз! Илдән кудырырбыз!» — дип җитди йомгак ясады Иван Иванович.

Ике дус ай нурына чумган кыр өстендә кылыч уйнаттылар, йодрыклар йомарланды, үкчәләр җирне төйде, тигез рәтләр булып шым утырган агач чөйләр дер-дер калтыранды. Мондый хәлдә мунчаның тәме буламы? Ризыкның ләззәте каламы? Хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич ашык-пошык чабындылар, коньякны кырлы стакан белән голт-голт эчтеләр. Коньякны, унбиш ел буена таш мәгарәдә өлгереп яткан затлы эчемлекне кырлы стакан белән?! Бусы Исламнурның акылына сыймады, ул өнсез калды, аны очкылык тотты, ямьсез очкылык тавышына куначаның иң биегенә менеп йокымсыраган әтәч җиргә егылып төште. Айлы төндә кара болыттай каралган кунакларны машиналар шым гына алып киттеләр. Иван Иванович кайтып керүгә телефонга ябышты, көтеп зарыккан хәләлен шик-шөбһәгә төшерде: мунчадан соң һәрчак ул хатынын куенына ала торган иде. Әллә чит итәк яныннан кайтканмы бүген ире?! Хатын төн ката йокламады.

## 26

Брежневның югары сыйныфларга үтә мәхәббәтле күренгән, түбән катлау вәкилләре арасында меңнәрчә мәзәккә сәбәп булган калын кашлары яныннан үткәндә машина, өйрәтелгән гадәте буенча, йөрешен әкренәйтте. Ул ара да булмады, рәсем-җилкән каршындагы капка ачылды, аннан «ур-ра!» кычкырып эреле-ваклы җиде малай атылып чыкты. Әхмәтзыя, уңайсызланып һәм бераз горурланып, Наиләгә баш какты: «Минем ташбашлар!» «Әйдәгез, аларны да аппарабыз!» — диде Наилә кинәт. Сөмбелә эндәшмәде. Әхмәтзыя аяк терәп каршы килде. Наилә сүзен сүз итте, малайлар машинага кереп тулдылар. Тугыз малай бергә килгәндә тынычлык каламы? Китте үчекләшү, танышу, урын өчен кычкырышу, чыр-чу... «Бу машина этинеке!» — дип мактанды малайларның берсе. Искәндәр уйлап-уйлап торды да: «Ә минем эти атом бомбасы ясый!» — диде. Авыл малайлары тактиканы шундук үзгәрттеләр. Искәндәргә ярарга тырыштылар. «Безгә бер бәләкәйрәкне ясап бирсен инде, ә?» — дип ялындылар. Машина урманга якынлашты.

* * *

Нәҗипнең күптәннән болай үлеп йоклаганы юк иде, ниһаять, уянды, чак кына айнып, исенә килсә... Ул шыр ялангач килеш күл ярындагы юан чыршыга ябышып тора, чалбар балакларын, җиңнәрен сызганган әрмән егетләре сыңарышар чиләк тотканнар да, күлдән су чумырып алып, алмаш-тилмәш аның өстенә коялар иде. Шактыйдан маташалар, ахрысы. Нәҗипнең аяк астында күлдәвек ясалган, ярга якын су болганган, җир җебегән. Ә тәне күгәрчен тәпиедәй күгәргән иде.

Ул иң әүвәл әрмәннәрнең нәфрәт тулы күзләрен күрде. Исерекбаш иргә алар шундый җирәнү, кимсетү белән карыйлар иде ки, бу суык караш сап-салкын судан ныграк тәэсир итте, ул дер-дер калтырап, күзен уып: «Җитәр, егетләр», — диде. Әрмәннәр, чиләкләрен атып бәреп, икесе ике якка киттеләр, берсе учакны тергезергә тотынды, икенчесе табынны калдык-постыклардан чистарта башлады.

Чиләкләрнең берсе Нәҗип аяк очыннан тәгәрәп күлгә барып төште, ул иелеп чиләкне алам дигәндә, сынын тота алмады, чулт итеп күлгә капланды. Егетләрнең берсе йөгереп килеп быкырдап яткан Нәҗипкә кулын бирде. Җебегән тавык, күшеккән күркә, диләр. Нәҗип нәкъ шул хәлдә иде хәзер. Кабаклары салынган, чит-читләре шешенгән күз ярыклары әз-мәз ачылгач, ул урман юлыннын тиз-тиз монда таба атлап килүче Сабитны күрде. Ул кулындагы ботаклы таяк белән юлындагы куакларны аяусыз кыйный иде. Нәҗип як-якка карангалап ыштанын эзләде, бәхете, тиз тапты, Сабит кулындагы таякның кайсы төшне яратканын ул балачактан ук бик яхшы белә иде. Яра иде аны Сабит малай чагында, «ике»ле алса да, кайтып тукмый иде, кызларның берәрсе кырын караса да, Нәҗипне җәзалый иде. Суык мунча миченә энекәшен башы белән тыгып торганы да бар иде явызның...

Сабит бу төбәктә власть иде. Тирә-якны дерелдәтеп торкан Исмәгыйль соңгы кичтә Хәлил белән ничегрәк очрашкан булса, Сабит Исмәгыйльдән мең тапкыр артыграк котырынган иде. Мин-минлеге, Сабитлыгы изелгән иде аның. Хәзер юлында кем очраса, ул аны таптап, сытып китәчәк иде. Таудан тәгәрәп төшүче биниһая авыр таш иде ул. Власть кешесенең ачуы берчакта да үзеннән-үзе сүрелми, аны җәза, кан, җәберләү тәме аша гына төкәндереп була. Әгәр әүвәл башлап аңа әрмән егетләре очраса, ул аларны изеп ташлаячак иде.

Вәлиәхмәт вак җанвар иде, кол, билендә наганы атынса да, шөһрәтле колхоз рәисе, депутат, бюро, пленум әгъзасы булган атаклы ир алдында ул — көя күбәләге, вак черки иде. Хәзер Сабит-сунарчыга эре җәнлек кирәк, кыр тавыгы, көртлек каны гына аның ачуын юып ала торган түгел, әгәр юлында бүре очраса, ике дә уйлап тормастан аңа ташланачак Сабит, юлбарыс читлегенә коры кулдан барып керәчәк.

Юеш тәненә трусигын кия алмыйча азапланган энекәшен күз карашы аша үткәргәч, ул, йодрыкларын йомарлап, нигәдер янтая төшеп, аңа якынлашты. Сугарга күтәрелгән кул һавада калды. Нәҗип күрелмәгән җитезлек белән читкә тайпыды. Туганнарның күз карашлары кисештеләр, корыч чыңлаган тавыш чыкты, һавада яшеннән соң була торган ис таралды. «Син, йолкыш! — диде Сабит авыр тавыш белән.— Урам себерүче! Түш киереп, оборонныйда эшлим дип йөрисең, бозау! Син бит гап-гади җүләр баш».

Нәҗип тә Йосыф Нургалиев малае, анда да власть уянды, теләгенә ирешә алмаса да, анда да шул властька омтылыш бар иде ич. Әнә шул Нәҗип, Наилә яраткан, омтылышлы, кырыс Нәҗип уянды Сабит бәхете өчен казыткан көмеш күл янында. «Йолкыш булсам

да, мин ирекле җан. Ә син Брежнев һәм аның яраннарының колы. Алар синең эше ялагайларга таянып тора. Синең ишеләр крестьянны бөлгенлеккә төшерде, аны җирдән качарга мәҗбүр итте. Сез — бер буйдагы читән казыклары... Дөрес, син — өстә, мин — аста. Дөньяның асты өскә килүе бар. Онытма шуны, депутат!»

Сабитның сүзе бетте. Уйлау сәләте баш миеннән йодрыгына күчте. Ул, үзен-үзе белештермичә, алагаемга киерелеп энекәшенең ипи шүрлегенә менәм дигәндә... күзеннән утлар күренде, ул чәчрәп җиргә барып төште, бер түгел, биш әйләнде. Күзен кан басты, кан тамырларына ут ачысы кушылды, ул читкә чәчрәгән таягын алып бер селтәнгәндә, юлда бала-чага чыркылдашкан тавышлар ишетелде. Грузчик булып йөргәндә буш араларда шадра Вафа бокс серләрен өйрәткәләгән иде Нәҗипкә, шул ярап куйды: ул, үкчәсен җиргә терәп, астан ап睿кот белән җан көченә бәргән иде. Балалар тавышы аның колагына да керде, аягына баскан Сабитка тагын берне өстәргә йомылган йодрыгы язылды, күзе ныграк ачылды.

Юлда әүвәл башлап милиционер Вәлиәхмәт күренде. Ул нигәдер абына-сөртенә арты белән килә, бала-чага урап алган Наилә белән Сөмбеләгә нидер аңлатырга тырыша иде. «Сөмбеләгә монда ни калган? — дип уйлады Сабит, таягын читкә атып бәреп.— Ни кирәк аңа? Аны кем чакырган? Кайтып бөтенесен чишеп ташлаганмы әллә теге пырдымсыз зат?!» Сөмбеләнең елмаюын очраткач кына, ул Наиләнең тапкырлыгына, үткенлегенә хәйран калды, аңлады. Юк, утыз өч яшькәчә тормышын көйли алмаган Нәҗипкә әрәм мондый затлы мал! Чибәрлеге өстенә тапкырлыгы, зирәклеге дә җитәрлек икән. Карасына коелган Сөмбелә бала-чага төяп, тыелган аланга менгән икән, бу инде Наиләнең көче, аның хикмәте дигән сүз. Бүтәнчә түгел.

Вәлиәхмәт, хуҗасы адаштырып калдырган эттәй, Сабитка карады. «Сабит Йосыпович!— дип елмасырады ул.— Бу тирәгә бала-чага китерергә ярамый, дип мең кабатладым». Наилә үтә мөлаем, игелекле тавыш белән аны бүлдерде: «Нигә ярамасын ди? Алан киң, ризык мул, вакыт иркен. Рәхәтләнеп ял итик!» — диде.

Сабит, күз карашына җылылык өстәп, аның ягына карады. «Котылдым! Коткарды бу чәчби мине!» Наилә таң йолдызы кебек балкып иренә карады: «Син йоклаган арада мин балаларны төшеп алдым!» — диде ул мактанган тавыш белән. «Ничек оста итеп ирен коткарды!» — дип уйлап өлгерде Сабит, сокланып.

Сөмбелә кыюланды, үзенә моңарчы сер булып килгән аланны тиз-тиз караштырып, табындагы артыкларны — буш һәм тулы шешәләрне җыеп алды, кай арада ут тергезеп, шашлык куырып өлгергән егетләр өстәлгә итле сыйны китереп өйделәр. Малайлар, аларга ияреп олылар да корсаклары кап булганчы сыйландылар.

Көн шулай, һич көтмәгәнчә, берсе дә күз алдына китерә алмаганча татулык белән үтте. Урманнан кайтышлый Сабит: «Эш тә бар ич әле дөньяда!» — диештереп төшеп калды. Алар, Наилә белән Нәҗип, Сөмбелә җитәкчелегендә кичке чәй янына җыелдылар, йөзләр яктырды, телләр ачылды. Кунаклар якты күңелле Сөмбеләгә бар булган хәсрәтләрен һич яшермичә, арттырмыйча, киметмичә сөйләп бирделәр. Сөмбелә һәр хәсрәтне үзенеке итеп тыңлады, балаларның сары йортта нинди шартларда яшәвен белгәч, кызганып ихлас яшьләрен түкте. «Малайларны җәйгә бездә калдырыгыз, июнь башында ялга чыгам, минем беркая барганым юк. Әзидән Марат белән Гөлбостан кайта, туганнар ич алар, очрашсыннар, белешсеннәр, һич иренмәм, карармын»,— дип кат-кат үтенде. Наилә белән Нәҗип ризалаша язганнар иде инде. Сабитның корылыгын, кискен холкын уйлап, бала-чаганың җайсыз якларын исәпләп, уйларыннан кире кайттылар.

Балаларны йоклаттылар, табак-савытларны җыештыргач, өч-дүрт кат рәттән Әлфия Афзалованы җырлаттылар. Нәҗип читкә борылып еш-еш иснәштерде. Ятарга вакыт булса да, Сөмбеләнең аларны тиз генә кулдан ычкындырырга исәбе юк иде шикелле. Сабит соң кайтты, ашамады, бер тустаган катык сорап алды, эчәргә ашыкмады, уртлап куйгач, кунаклардан бигрәк Сөмбеләсенә карады. «Сабит,— диде Сөмбелә шактый көр тавыш белән,— заманы шулдыр, туганнар белән аралашу кимеде. Сине дә, үземне дә гаепләргә җыенмыйм. Ходаның рәхмәте төшеп, энекәшең кайтты, хатынын күрдек, балаларын. Мәскәүдә укыганда Нәҗип чирләп егылган икән! Чирле кешене эштә яраталармы? Мин моны врач буларак әйтәм, беләм, яратмыйлар!» Сабит тустаганын иренենә тидереп алды, катыгын йотмады. Аңа шөгыль, әңгәмәдән читкә каерылырлык бер-бер эш кирәк иде. «Фатирга чиратлары җиткән, бирмәгәннәр. Ахыр чиктә, эшеннән үк чыгарганнар». Баштарак ул хатынын юньләп тыңламады, сөйләгән сүзләре аңына авырлык белән барып җитте. Әле ул Нәҗипне урам себерүче дип кенә ишеткән икән, баксаң, менә кая таба киткән эшләр!.. Көндезге вакыйганы көлкегә калу дип исәпләгән Сабитның эче яктырды: «Димәк ки, Наиләнең эшләре кәкәй?! Ир аста, нужада икән, аның хатыны да шунда барып төшкән була түгелме?» Нәҗипнең нужаруына ул, яшермик, сөенде.

Ирләре бәла-казага юлыккан, нужарган хатыннарны аерата ярата Сабит, аларга мөнәсәбәттә аның сыналган ысуллары, ышанычлы әмәлләре бар. Ирен саздан тартып торгызасың икән, хатыны синең кочагыңа керде дигән сүз. Ул, урман маҗарасын хәтерләп, тагын бер ачынып алды. Ах, бу хәлләрне анда барганчы ишеткән булса! Энесенең шундый нәзакәтле, гүзәл хатынны ипи-чәйдә, такытокыда тотуын белсә, эшне бөтенләй кире яктан башлап җибәрер иде. Әле дә соң түгел, ул йокымсырапмы, йокыга салышыпмы утырган Нәҗипне кабинетына чакырып кертте: «Нигә син боларны элегрәк хәбәр итмәдең?» — дип ырлап ябышты. «Шуннан ни үзгәрер иде?» — диде сүрән генә Нәҗип. Ул Наиләсенең ачылып китүен дә, Сөмбеләнең сүзне шул якка алып керүен дә өнәмәгән иде. Нәҗип саклыгын онытты, чире исенә төшеп тә карамады. Сабит болай да аны исерек чучка хәлендә күрде. Әле моннан соң да тормыш итәсе бар. Наиләнең Югары Авыл юлында тел тозагыннан ычкынган сүзләре кайчан исә бер калкып чыгачак. Нәҗипнең моңарчы шундый шәп, затлы, дәрәҗәле Сабит белән аралашмавы, инде аралашам дигәндә мәлҗерәп аунап ятуы да телгә керәчәк. Нигә һаман-һаман Сабит өскә чыга соң әле?!

Нәҗип гарьлегеннән әрнеп ишек тоткасына ябышты. «Туктап тор,— диде Сабит.— Тотканы каерып чыгарма! — аннары, өч телефонның берсенә — зәңгәренә төртеп күрсәтте.— Казанны мин турыдан-туры җыям. Көт бераз!»

Нәҗип тирләгән ишек тоткасын ычкындырып тыелып калды, сөйләшмәде. Сабит сул кулы белән маңгаен кашый-кашый номер җыйды, менә аның кырыслыгын елмаю алыштырды, ул ниндидер Иван Иванович белән якын туганнарча хәбәр бүлешергә тотынды. Мондый тавышы да бар икән Сабит Нургалиевнең, болай да сөйләшә ала икән ул! Ятрәк чыгып югаласы килә Нәҗипнең, ишек нәни генә шыгырдауга, Сабит күзен-кашын сытып аңа туктарга куша. Тагын тавышы үзгәрә, кенәри булып сайрый, тук песи булып мырлый, ара-тирә күркә сыман кабарынып та ала. Бүлмәне тутырып көлеп тә җибәрә! Теге якта язып алырга ниятләделәр бугай, ул иҗекләп әйтеп тора башлады. Нәҗипнең исем-фамилиясен атады, холкын мактады, «эшлекле, ышанычлы!» дип, күкләргә чөйде. Трубкасын куйгач, әле генә мактап бетергән Нәҗипкә сыңар күз дә салмыйча,

аны бетереп, үз өстенлеген раслап тәрәзә аша төнгә карап утырды. «Ну, кыланчык!»— дип уйлады Нәҗип, абыйсын үтереп ташларга теләп.

Хатыннар янына чыксалар, алар белән нидер сөйләшеп, урындыкны ишек катынарык тартып китереп, җирән кыска чәчле, киң калын җилкәле, ныкча кыска муенлы бер кеше утыра иде. Сабит Сөмбеләгә карады, кашлары җыерылды: «Бу бәндә минем рөхсәттән башка түремә кереп утырган! Ни хәл бу? Йомышы ни?» Тегенең йомыш юллап йөрүе кыяфәтенә чыккан, иңбашлары салынган, күлмәгенең сул якасы бөкләнеп муенына кергән, галстугы бозау чәйнәгәндәй таушалган иде. Карый торгач Сабитның исенә төште: «Ба-а, бу бит, бу... Хәлиуллин! Баганадай мишәр нигә болай таушалган икән? Исеме Әхсән бит әле, әйе, Әхсән Сәхәпович бугай. Әйе, әйе, мал-туар симертү совхозын Сабит аның кулыннан алып калган иде. Рәхмәт төшкере, әллә аның да әвене янганмы?!» Күрештеләр. Сабит хәзер күтәренке, наян авазлар белән сөйләшергә кереште: «Йә-йә, Әхсән Сәхәпович, ни хәлләр!? Чәй белән сыйлыйкмы, әллә мәе дә батамы?» «Юк, юк! — диде ике кулы белән битен каплап, артка тайчынып Хәлиуллин.— Ир башына шул шайтан... җитә! Тамчысын да капмыйм. Чәйләп торырга да соң. Минем, Сабит Йосыпович, сиңа тәҗел йомышым бар. Рәхмәт, кәбәм. Әйдә, бер сүләшикче. Төн ката йөрүемә рәнҗемә. Син кунак-төшемсез яшәмисең, беләм. Кичерерсең».

Сабит төсен үзгәртте, теләр-теләмәс кабинетына керде, ишекне ачык тотып Хәлиуллинны үткәрде, ачык ишектән Нәҗип тә аларга иярде. Хәлиуллин күзе белән урындык эзләп табып, авыр гына килеп утырды, Сабитны якыны санап, йомышын сөйләргә дә тотынды.

«Совхозда синең жылы кулыңны кысып аерылганнан соң, кәбәм, Башкортстанга барып чыктым мин. Райбашкарма рәисе итеп якташлар чакырып алган иде. Эшләдем. Бер-бер чатак чыкты димим, чыкмады. Чыгып өлгермәде! Әмма-ләкин чыгу ихтималы бар иде. Әүвәлдә башкорт кем иде? Иркен дала улы иде! Баймакта яши иде ул, Урал буйларында. Хәзер башкортның яңа буыны калага тартылды. Туйды даладан башкорт баласы, аңа шәһәр кирәк, шәһәрдә жылы урын кирәк. Урын таләп итәргә хакы да бардыр... Кыскасы, аркама суык бәргәч тә уйландым мин: «Туган төягең, Татарстаның юкмы синең? Ашык, Хәлиуллин!» Гариза тапшырдым, сессиядә кычкырып укыдылар, мактап озаттылар».

«Ала-ай,— дип сузды Сабит,— котлыйм!» «Тукта, кәбәм, кабаланма.— Хәлиуллин маңгай дымын корыткан чы сөртте.— Кайттым Эзигә, кердем хуҗа янына. Тамырым монда, рөхсәт булса, үгә кайтырга исәп, димен. Харис Вәгыйзович карап-карап торды да үлчәү колгасына терәп бастырды мине!» Сабит чак пырхылдамады, Нәҗип тә елмайды. «Мәчегә көлке! — дип кычкырып җибәрде Хәлиуллин.— Нәкъ алты сантиметрга буй кыскарган. Җир тартканмы, ходайның каргышы төшкәнме!» «Нилектән алай булды соң?» — дип сорады Сабит бу юлы көлүен яшермичә. «Бүксә калынаймасын дип тегендә гер чөя идем, торам та штанга күтәрәм. Янәсе, сакланам... Харис Вәгыйзович мине элеватор директоры урынбасары итмә кели... Мине, овсюгны, урынбасар?.. Сыйфат тамгасы сугылган татарны урынбасар итәргәме? Юк, мәтәм, Харис Вәгыйзович! Барсам, рәис булып кына барам, кәбәм. Белгән булсам әгәр, тотынып идемме гергә? Врач киңәшен тотып штанга күтәрәм җитмәсә! Унар, егермешәр мәртәбә! Алты сантиметрга җиргә иңгәнмен!.. Сүләш әле, Сабит Йосыпович, хуҗа белән. Синең сүзең үтәр. Бүксә үссә үссен икән, буй бәләкәйләнмәсен, буй!» «Мин киңәшеп карармын,— диде Сабит эре генә.— Тик, ай-һай! Харис Вәгыйзович председательләрнең, парторгларның буен квартал саен үлчәтә! Квартал саен!

Нигә башка бер районга кагылып карамыйсың, Әхсән Сәхәпович? Теләсәң кайсы районга шалтыратам». «Кәбәм,— диде еламсырап Хәлиуллин.— Бата башлаган кешене күргәч, аркан ишәргә тотыналармы? Әзигә мин ярты гомеремне салган. Син кем җилкәсенә басып күтәрелдең? — Ул йонлач, дәү йодрыгы белән әче тузан очырып җилкәсен төйде.— Мин сиңа учетка кермәгән күпме сыер малы, таналар, симез-симез чучкалар калдырдым. Төз сының, хатын-кызларны шаштыра торган күзең өчен калдырдыммы мин аларны? Юк, кәбәм, дөньяның һәркемгә бер үзгәрәсен белгәнгә, егыласы җиремә салам җәеп куйдым. Хәзер син шул саламга ут җибәрмәк келисең. Әйтимме тагын бер сүз?» «Әйт! Икене әйт!» «Көзгә районда хуҗа булып син каласың. Шул чагында килсәм, колхозыңны миңа бирәсеңме?»

«Юк,— диде Сабит үзе.— Юк, Әхсән Сәхәпович, бирә алмам. Харис Вәгыйзович өлкә комитетына күтәрелә. Ул китүгә мин аның тәртипләрен боза башласам, кем булам! Ул председательләрнең буен кварталга бер үлчәтә! Ә мин ай саен үлчәргә кушачакмын! Ай саен!» Хәлиуллин тузан чәчеп ике тезенә ике йодрыгы белән китереп орды да ялт кына торды: «Бер күрүдә мин сиңа ышандым... Нигә дисеңме? Әйтәм, кәбәм. Син миннән бер көтү мал алып калып, чыраеңны да сытмадың. А-һа, бу бала ерак китәр, дидем. Синең яшьтә андый ук чаялык юк иде миндә. Күтәрелдең, ләкин бер нәрсәне истә тотмыйсың икән... Бүген мин сиңа мал калдыра алмыйм, малым юк, бүген мин сиңа шик калдырам — суын эчкәч, коега төкермә. Бата башлаган кешенең бәхете булса, су төбендә аяк басарлык түмгәк табыла аңа. Бүтән районга барырга җүләрме мин? Анда да үз размерың, үз үлчәвең кирәк».

Сабит энесенә сүз катмады, чыгарып та җибәрмәде, димәк, ул бу спектакльне Нәҗип өчен дә уйнап күрсәтте. Ни кисәтергә теләгәндер, нинди акыл бирергә җыенгандыр, ә Нәҗип исә Хәлиуллинны бик нык кызганды, шап-шоп тезен төеп, гасабиланып утырганнан соң, саубуллашмыйча да чыгып барганда аны туктатасы килде. Холкы волейбол тубы сыман бер яктан икенче якка күчеп торган Сабит телендә «ярдәм», «квартира» дигән сүзләр тирбәлгәч, Нәҗип, абыйсы әллә әз-мәз ипләндеме, дип җылынган иде, хәзер алданган, ымсынган үксез бала сыман нәүмизләнеп калды. «Каты күңелле син!»— диде ул абыйсына, җылы сүзләрнең әллә кайдагы Иван Иванович белән әңгәмәдә генә кулланылышын уйлап. «Катымы, түгелме икәнен иртәгә унда белерсең»,— диде Сабит. «Унда ходайдан фәрман иңәме?»— дип чеметеп алды Нәҗип. «Синең хәстәреңне кайгыртып нәкъ унда Иван Иванович шалтыратачак. Ишеттең бит, мин аннан сиңа эш эзләшүен үтендем!»

Иртән алар торып чыкканда Сабит эшенә китеп барган, Сөмбелә дә, утка баскандай кабаланып, кузгалырга җыенган иде. «Больницага пычкыга киселгән баланы китергәннәр, үз җаегыз белән чәйләгез инде»,— диде ул гафу үтенеп. Нәҗип белән Наилә иртәгә китәселәрен белдергәннәр иде, иртәгә Сабит та Казанга барасы булгач, шәт, безне үзеннән калдырмас, дип, хуҗалар белән юл, билетлар хакында сүз кузгатмадылар. Балалар уянды, чәйләделәр, журналлар актардылар, күзләре гел сәгатьтә булды. Тугыз тулды, ун, әбәд якынлашты, Сабит та, Сөмбелә дә кайтмадылар. Бәдәр аш җиткерде, ашны, итле бәрәңгене аннан-моннан капкаладылар. Нәҗип Наиләне юатырга тырышты. «Абыйның коры куык, бушбугаз икәнен сиңа аңлатырга теләгән идем, хәзер аңлатып торуның кирәге дә калмады!»— диде. Урамнан уйнап, Әхмәтзыя малайлары белән сугышып кергән малайлар: «Әйдәгез урманга, төтенле ит ашарга! Тегеләрне ияртмибез!»— дип тыкырдаттылар. Ачу килгәндә аяк астында уралган бала кәефне боза, малайларны пыркытып чыгар-

дылар. «Икесенең берсе булмасмы дип тә уйлыйм!» — дип юрады Нәҗип. «Булмас,— дип кырт кисте Наилә.— Безнең заводта гына ике мең кеше фатир чиратында торганда каян тапсыннар ди безгә?» «Әт оясы хәтле генә куыш булса да, яшәп торыр идек торуын. Үзебезнеке булсын иде!» — дип һаман өметләнде Нәҗип. Инде чыдарлыгы калмаганда, өметләре өзелгәндә Сабит кайтып керде, урта бармагын изәп Нәҗипне кабинетка чакырды. Наилә коелып төште. Сабит ашыкмады, зур эш кыргандай стакан арты стакан «Шифалы су» эчте, кереш сүзсез-нисез энесенең тетмәсен тетәргәябышты. «Син,— диде ул нәфрәтенә җирәнү дә өстәп,— гомер эчендә бер кайтып авылда юк-бар лыгырдап йөргәнсең. Ихлас әйткәннәргә ышанмаган идем. Баксаң, диссидент икәнсең син, тилемиле Сахаровлар сыңары! Хыянәтче! Сатлык Синявский, Даниэльләр белән бер җырны җырлыйсың икән. Җәбрәйләргә сатылдыңмы? Бик теләсәң, мин сине Щаранский янына Чистай төрмәсенә илтеп тыгам! Эш тә табылыр, квартирлы да булырсың! Менә нигә алмыйлар икән сине эшкә! Телең авызыңа сыймаганга куганнар ич сине заводтан! Татарда диссидент юк, без басынкы халык дип йөрсәм, бар икән ул юньсезләр, бар! Кем диген әле? Юньләп тормыш кора белмә, властьны сүгәргә тотын! Вәт тинтәк!»

«Ялган!» — дип кычкырасы килде Нәҗипнең, теле көрмәлде. Каян бер төн эчендә Иван Иванович дигәннәре Нәҗипнең кара тамгасын белеп өлгергән диген! Хәер, Изил Латыйповка гына шалтыратсын, бииби сатып җибәрер... Чит илләрдә бөтен гражданнарга әзер досьелар бар, дип шашына газеталар, үз башыңа таяк төшкәч беләсең икән. Нәҗипкә дә хөкем әллә кайчаннан әзерләп куелган инде! Ул май ае яшене кебек көтмәгәндә чәчрәп яшьнәде: «Әллә мин ялган сөйләдемме? Яла яктыммы? Безнең илдә хаксызлык, гаделсезлек бер дә юкмы?! Кодакодагыйлык, коррупция, ришвәтчелек чәчәк атмыймы? Ил башында түшен калай белән тутырган ахмак утырмыймы?! Ике сүзне кушып әйтә алмаган бәндә дөнья белән идарә итәргә ашкынмыймы? Теге чакта гаризамны кире алуыма үкенәм. Өлкә комитетына язасы иде аны! Мәскәүгә, хөкүмәткә!.. Хәер, Брежневка язып ни файда?! Синең ишеләр бар чакта аңа җил-яңгыр тимәс! Берләшкән милләтләр оешмасына язсаң гына инде. Барыбер файдасы булмас! Кырым татарлары әнә омтылып карыйлар, шул сәгатьтә авызлыклыйлар тегеләрне! Тышаулыйлар! Щаранскийлар сыман үткәреп бер сүз әйтәсе иде әле, тел җитми! Көч юк!»

Сабит төкерекләрен чәчеп, Наилә дә, балалар да ишетерлек итеп акырынды: «Җитәр сиңа, селәгәй! Телеңне кисеп, дурдомга, Арча кырына ябуларын телисеңме? Минем өемдә тының чыкмасын! Мин коммунист! Тагын бер сүз ычкындырсаң, этап белән озаттырырмын! Телефонны күрәсеңме, зәңгәрен, мин аннан хөрмәтле Иван Ивановичка гына түгел, генерал Бичуринга да шалтырата алам. Ул да мине бик яхшы белә. Сине дә беләләр икән, рәхмәт, танытып өлгергәнсең!»

Сөмбелә дә кайткан икән, тавыштан куркышып, балаларны җитәкләп кабинетка алар килеп керүгә, Сабит тынычланырга тырышты, өстәл башына утырды, аякларын йомшак кына биетә башлады. Сөмбелә тез арасына Искәндәрне кыстырып, иркәләп иренә дәште: «Йә, хәлләр ничегрәк анда, Сабит?» Сабит Наилә ягына борылды: «Наилә ханым, ичмасам сез акыллырак булыгыз. Мин биргән вәгъдәмдә торам. Кайтуыгызга шәһәр советына барыгыз, шушы номер белән астан шалтыратыгыз. Нишләргә кирәклеген әйтерләр анда. Сезгә яңа салынган йорттан ике бүлмәле квартир бирәләр. Өченче кат, кояшлы як. Әгәр бу тиле тәүкәл егет Шомбай сыман бүреген кыңгыр салып йөрмәсә, эш тә табарлар. Зинһарлап сорыйм, катышмасын сәясәткә! Төрмәләрнең ишеге ябылганы юк... Кирәк икән, дурдомга илтеп тыгарлар. Шундый мөмкинлекләр ачылганда!.. Яшә дә яшә генә!..»

Наилә кычкырып елап җибәрде һәм хәле бетеп кайнагасының муенына ташланды. Аннан Сөмбеләне кочып-үбеп кат-кат рәхмәт укыды.

Хуҗа иртәнге рейска билетлар да алып кайткан икән, тагын бер тынгысыз төнне үткәреп, Сөмбелә белән аерыла алмыйча сөйләшеп, чөкердәшеп иртәне җиткерделәр. Бераз таушалган «Уазик»та Әхмәтзыя аларны аэродромга илтеп тә куйды.

Сәфәрчеләрнең сөйләшеп сүзләре бетмәде. «Күчешегезгә бездән бүләк!»— дип Сөмбеләнең мең сум акча, балаларга ару кием-салымнар, күчтәнәчләр җибәрүе аларны аерата дулкынландырган иде.

«Туганнар белән аралашу кайчагында бер дә начар түгел икән!»— дип йомгак ясады Нәҗип самолетка кереп утыргач. Кайткач та этиләренә бирәр посылка салырга Нәилә белән сүз берләшеп куйдылар.

Эзи районыннан сессиягә депутатлардан тыш колхоз рәисләре, совхоз директорлары, авыл хуҗалыгы белгечләре бара дигәч, самолетта тыгыз булыр дип пошынганнар иде, нибарысы алты җан очып киттеләр. Күтәрелеп, мотор тавышы тигезләнгәч, тәрәзәгә ябырылдылар. Май кояшы кумгән якты кырлар, күпереп килгән яшькелт болыннар өстеннән очканда олы юлдагы гаҗәеп хәрәкәт-манзараны күреп хәйран калдылар. Эзидән Казанга таба сансыз-исәпсез машиналар чылбыры чыгып килә иде. Шактый баш тинтерәткәч, Нәҗип бу җанланышның да серенә төшенде. Әйе,һәр җәһәттә нык лы тәртип яраткан Харис Вәгыйзович эзиленәрне әнә шулай, тантаналы демонстрация ясап, сессиягә алып бара иде. Энесен, киленен, бала-чагаларын төяп Казанга кайтара алыр иде Сабит, мәгәр райком секретаре урнаштырган тәртип буенча машиналарга чит кеше утыртырга ярамый иде. Һәр депутат, һәр рәис, һәр директор үз машинасында ялгызы Эзигә килә дә, алар башкаларга тоташ кортеж булып, кумәк көч булып кузгалалар. Алдагы сөт төсле ап-ак машинада Харис Вәгыйзович бара. Капотында нәни генә кызыл әләм кадалган. Үзе бара! Үзе! Хуҗа! Аның артыннан, дәрәҗәсен белеп кенә, бүтәннәр тезелә. Сабитның машинасы әлегә бишенче! Көзге конференциядән соң, Харис Вәгыйзович өлкә комитетына авыл хуҗалыгы бүлеген житәкләргә киткәч, бәйраклы беренче машинада Сабит Йосыф улы Нургалиев барачак. Ихлас әле унөченче генә!.. «Коммунизм юлы» дип аталган, исеме җисеменә тап килә торган күргәзмә колхозның рәисе булырга бик теләсә дә, Әхсән Сәхәпович Хәлиуллин килә алмаячак. Буе бәләкәй. Уставка җавап бирә алмый торган буй. Ә бу — җанлы чылбыр булып шатлыклы тәгәрәгән машиналарда нәкъ бер буйдагы — йөз дә сиксән җиде сантиметрлы егетләр, ил тоткалары, пешеп өлгергән социализмның һәм Брежневның төп таянычлары бара. Буйлары шуңа җитә алмаган байтак егетләр витаминлы ризыклар ашап, биеклеккә, югарыга сикереп, турникта озак асылынып торып, болында мәтәлчек атып, гәүдәләрен шул хыялый сызыкка җиткерергә тырышалар. Дөрес, бу иркен дөньяда үз буеның озынлыгын бәяләмәгән ахмаклар да бар. Сирәк булса да очрыйлар андыйлар! Әнә, берсе — Нәҗип Йосыф улы Нургалиев хикмәтле һәм хөрмәтле Иван Иванович кулыннан яшәргә хокук-урын һәм эш дауларга кайта... Кермәсә, утыз өчтә дә акыл керми икән!

Аклы-каралы кортеж Чаллыга барып җитеп, аннан чыккан тагын да шәбрәк, тагын да озынрак колоннага кушылды. Нәҗипләр самолеты тирбәлә-тирбәлә авыл хуҗалыгы батырларын, данлыклы эшче сыйныф вәкилләрен сәламләп узды. Мамадыш, Балык Бистәсе, Питрәч, Биектау кәрваннарын да күреп үтте безнең сәфәрчеләр. Машиналар чылбыры, сигезаяк кармавычлары сыман кыймылдап, шәһәргә кереп сеңә бара иде.

## 27

Сары йортка алар беренче тапкыр таксида утырып кайттылар, кесәгә мең таңкә кергәндә, яңа квартир хуҗалары буласыз дигәндә, өч тиенлек трамвайда кысылырга теләмәделәр. Машинага кереп утыргач, Искәндәр: «Эх, тетенле ит ашарга бара алмадык!» — дип эти-әнисен көлдерде. Выжт иттерең, сары йортның ишек катын сарган карчык-корчыкның күзенә тузан сиптереп кайтып керергә ниятләгәннәр иде, машинаны читтәрәк туктатырга туры килде, ишеккә якын барырлык түгел, анда кара болыт булып халык сарылган иде. Ни хикмәт бу? Әллә йортны сүтәләрме? Бу галәмәтне күреп кызыксынган такси шоферы да аларга ияреп чыкты һәм аяк очларына басып, халык арасына кысылырга маташкан хатыннан: «Ни булды монда, бабуся?» — дип сорады. Карчыкның җавабын ишетергә теләп, Нәҗипләр дә туктадылар. «Ой, касатик! — дип сузып җибәрде карчык.— Лизабыз бар иде. Байтактан монда яши иде. Бәбәй тапкач: «Бала миннән түгел!» — дип ире кугач, күченеп килгән иде бичара. Баласы сәламәтлеккә туймады, астма иде кызында. Интекте сабый, буыла-буыла тилмерде. Шундый тере кыз иде үзе тагын, шундый чая, үткен. Тик бер дә төс кунмады, бите тимгел-тимгел алланып торды. Туктаусыз елады Лизабыз, күзенең коры чагы булмагандыр. Өч көн элек биш яшьлек сабыен буып үтергән дә үзе бер шешә куе серкә эчкән. Ике көн янып-көеп интеккәч, вафат булды мескенкәй. Гәүдәләрен безгә бирмәскә маташалар, әллә каян ире табылган. «Үзем күмәм!» — ди. Кая ул! Бөтенебез бер булып күтәрелдек, прокурорга барып җиттек. Бүген менә Лизаның теләген үтәп, икесен бер кабергә куябыз, хода кулына тапшырабыз». Карчык белешмәләрне биреп бетереп, озын күлмәгенең киң итәгенә абына-абына читкәрәк чыкты. Тыгыз төркем урталай ярылды, корсагы өстендә ике куллап тәре тоткан юантык хатын алга чыкты. Ирләр иңендә буялмаган ике табут тирбәлде. Берсе олы, берсе кеп-кечкенә генә. Халык арасында наразыйлык авазлары яңгырады: «Безгә каһәрләнгән язмыш, ә алар... балдамайда йөзәләр!» «Без күселәр белән чүплектә, ә алар пулатларда!» «Оятлары калмады инде, туймас тамаклар...» «Һаман талыйлар».

«Мондый сүзләрне соң чиккә барып җиткән сары йорт кешеләре генә әйтә аладыр»,— дип уйлады Нәҗип. Нәфрәтнең кая төбәлгәнен ул бик яхшы аңлады. Аңа кагылып диярлек Ионыч үтте, ул аларны күрмәде, кызарган күзләрен уа-уа ташкынга йотылды.

Өйгә керсәләр — харап! Ишек бикле, тәрәзә тыгызлап ябылган булса да, идәндә, тәрәзә төпләрендә, киштәдәге китапларга бармак калынлыгы соры тузан яткан. Ишек янагына элгән халатын танымады Наилә, ятсынып кулына алган иде, аннан болыт бөркелеп, борын тишегенә тулып төчкертә, йөткертә башлады. «Астмалы бала түгел, монда сәламәте дә чихут алыр!» — дип сукранды Наилә һәм зарлана-зарлана идән сайгакларын юарга әзерләнде. Нәҗип җәһәт кенә бер чиләк су алып керде. Икесенә дә нидер эшләргә, ничек булса да мавыгып онытылырга, туган якка ясалган сәфәрнең авыр хатирәләрен онытып торырга кирәк иде. Нәҗип, Наиләгә комачауламас өчен, малайларны кибеткә алып чыгып китте, сөт, катык ише нәрсәләр алып кайтты. Наилә идәнне юып чыгаргач пычрактан, шакшыдан, тузаннан озак кына зарланып утырды. Бүген хатыны җаеннан гына торырга тырышкан Нәҗип: «Күпкә түзгәнгә әзгә түзәрбез»,— дип ычкындырды. Хатынын тынычландырырга теләгән иде, киресе килеп чыкты: «Ышанмыйм мин аның вәгъдәсенә! — диде Наилә.— Үрдәк биреп каз алырга яраткан Сабит абый ниемә дип безнең өчен тырышсын! Бездән ни көтә ул? Нәрсә алырмын дип өметләнә!» Нәҗип хатынын куәтләде: «Бүген Казанга киләсе булгач, Иван Ивановичка шалтыратып маташуы да мәзәк инде. Спектакль уйный, кылана!.. Бер табышмак ачыкланды: якын араларда миңа эш буласы юк икән!»

Тузан басылса да, өйдә зәһәр, әче ис калды. Җил кирпеч заводы ягыннан исә иде. Сөмбелә күчтәнәчләре белән ашыкмыйча чәйләделәр, иртә уянган малайлар башны-башка куеп караватка тәгәрәделәр. «Әллә бармыйммы шул Иван Иванович катына?»— дип, шиген уртаклашты Нәҗип. Наилә авыр сулады, дәшмәде, кулы белән балаларга төртеп күрсәтте. «Ә алар?» «Мин бүгеннән эш эзли башлыйм»,— диде Нәҗип. «И, Нәҗип, Нәҗип... Тинтәк инде син, беркатлы. Эше барга бирәләрме квартир? Чәнчелеп китсен дөньясы, син генә ак калырга димәгән. Дөньясы шул ич аның. Гөлнара исемле танышымны әйткәнем бар бугай. Мин белгәндә генә бишенче квартирларын алыштыралар инде, бишенчесен!»

Татарда сөенеч тә, кайгы-хәсрәт белән авыр шик-шөбһәләр дә өйгә сыймыйлар, борынгы болгар бабайлар кара кайгы иңгәндә яки салават күпередәй балкып куаныч килгәндә, дөньяга яңа җан иясе бәбәй тугандa, тирмәдән чыкканнар да иярсез атка сикереп менеп җайдак җилдергәннәр, киң Идел ярына басып җырлаганнар, җир селкетеп тыпыр-тыпыр биегәннәр, һич югында, кайгыдан бал эчкәннәр...

Нәҗип бахырның менәр аргамагы юк, бабаларыбыздан калган җирне сасы төтенле заводлар биләгән, җырлап җибәрергә моңы юк: чыкты да китте бер башы! Әйе, ул әлегә анык кына берни белми: кем ул Иван Иванович? Шиге бар: Сабит абыйсының сүзен үтәргә атлыгып тора икән, алар ике чабата бер киемдер! Чукынып китсен Иван Иванович, Сабит эшне нигә шулай тизләтте соң?.. Бусы бик шикле иде. Нәҗип, гади булса да, абыйсының комсыз күзләрен күрде, Наиләгә чөләеп карап утыруларын сизде... Әгәр хатынга бер-бер оятсыз ишарә ясаса, Наилә дәшми калыр идемени?! Изил Латыйповның күз елтыратуларын, икеле-микеле оятсыз тәкъдимнәрен һич яшермичә кайтып сөйли алган хатын ич ул!

Наиләнең тычкан исе белән тынчыган салам эскерте төбендә укыган зәһәр хөкеме кылт итеп исенә төште. Аяусыз хөкем чыгарды хатын, ләгънәт укыды, каргады... Бер уйласаң, ул хаклы түгелмени? Авылга кайтып ул үзенең көчсезлеген раслап килде бит! Ярый әле чирләмәде, хисләргә тулышып, мие томаланып җирдә тәгәрәмәде... Кайчагында көчсезлек чирне җиңә дә ала икән...

Нәҗип бүгеннән булмаса да, иртәгәдән, берсекөннән яңача яши башларга тиеш, бүтәнчә, замана законнарына буйсынып, заман кешеләренә яраклашып. Әгәр Иван Иванович дигәннәрендә әз генә шәфкать, мәрхәмәт сыйфатлары бар икән, ачы язмышын нигә аңа ачып салмаска? Бәлки, ул Нәҗип язмышының кылдый-былдый юлларын яхшы якка үзгәртергә туган фәрештәдер?

Тукта, кая килеп җиткән ул? Шәһәрнең бу ягына нигә килгән. Әйләнеп-әйләнеп карагач кына ул үзенең Фәридун Фазлыев яшәгән йорт каршысына килеп җиткәнен, шуның тәрәзәсе турында туктап торуын абайлады. Троллейбуска утырган, трамвайга күчкән, шәһәрне бер яктан икенче читенә үткән, үзе шуны сизми дә калган. Әллә тагын чире яңардымы, инде бүтәнчә яши башлыйм дип ант беркеткәндә, искәрмәс яктан бәреп кереп аяк чаламы?!. Уйлар упкынына батып шушы кадәр җир килгән Нәҗип, уянып, Фәридун Фазлыев яшәгән йортны күзәтте. Язын, әле дөньяның ертык-пыртыклары кар астыннан чыгып бетмәгәндә, Фәридун яшәгән йорт ярыйсы ук нык тоелган иде, хәзер сылавы купкан нигезе, рамнары череп чалшайган кыйшык тәрәзәләре, тоташ күгелҗем мүк сарган шифер түбәсе, дүрткелдән трапециягә әйләнгән ишек авызы, хуҗасызлыкка корылган һәйкәл булып, аның каршысында сураеп баскан иде. Иван Иванович турында уйлап нигә ул Фәридун Фазлыев катына килгән әле? Аны кем китергән? Кем мәҗбүр иткән? Хәзер керергә дә шик-шөбһәләрне сөйләп бирергәме?.. Бәлки, шәфкать-мәрхәмәт Иван Иванович ягыннан түгел, Фәридун Фазлыев ягыннан көтеләдер? Соңгы көннәрдә, авыл сәяхәте вакытында, Нәҗип-

нең үтә нык сизгерләнгән күңеле кайсы якка борылып баш орырга кирәклеген ачыграк беләдер? Кайчагында сукыр күңелгә дә ышанырга кирәк. Әйе, кирәргә дә сөйләп бирергә! Ул күңелен бүген ачса ача ала, иртәгә ул я ң а ч а яши башлый, я ң а кеше булып... Нинди кеше булыр, ахыр чиктә анысы кирәк түгел. Сөенеченме, көенеченме уртаклашырга дип күңеле бүген Фәридүн Фазлыевны сайлаган икән, ул бүген генә аның белән күзгә-күз очраша ала, иртәгә Нәҗип аның янына килә алмас инде. Фәридун Фазлыев белән ике арадагы тигезлек билгесе моннан соң бетәчәк. Моңарчы Нәҗип күз алдында тамыр җәйгән гаделсезлекне сүгеп, каргап авыз тутырып сүз кыстыра ала иде. Хаксызлык, бер төркем югары сыйныфның — партия-хуҗалык аппараты бюрократларының илне имеп, халыкны изеп яшәве, тоташ караңгылыкта тотуы аны рәнҗетә иде... Бәхете идеме бу, бәхетсезлегеме? Ул бу авыр сорауга җавапны иртәгәдән соң гына таба алачак. Чөнки ул я ң а ч а яши башлый, Иван Ивановичка кул бирә, астан өскә аңа ялагайланып карый, ул ни кушса, шуны үтәргә әзер тора. Ул Сабит абыйсының хаксыз өстенлеген таный, аның колына әверелә. Әгәр ачкүз Сабит: «Миңа беразга Наиләңне биреп торчы!» — дисә, Нәҗип Наиләсен кочып машинага утырта, ике бүлмәле кояшлы як квартирының балконыннан кул болгап кала. Моңарчы тарыгып яшәгән малайлар, гамьсез җаннар, пыр тузып идәндә, йомшак келәмдә мәтәлчек атып уйныйлар. Туп тибәләр!

Абыйсы аны «диссидент» дип атады, ямьсез кешеләр. Сахаровлар белән тиңләде. Юк шул, юк! Булсын иде Нәҗип шундый көр тавышлы кеше, дөньяның аклыгын яклап сүз әйтә алсын иде! Бер сүз! Гадел сүзләрне белә ич ул, әйтми, дәшми, дәшә алмый. Менә күрерсез, барачак ул Иван Иванович катына, тезләнеп ялварачак, эш тә сораячак. «Кичерегез, теге чакта ялгышканмын!» — дип инәлячәк. Чөнки аның иртәгәсе киртәгә терәлгән, аның иртәгесеннән хатыны, ике улы карап яхшылык көтеп тора. Әгәр ул бүгеннән Наиләсе белән арасын көйләмәсә, яшәү газапка әйләнәчәк. Кеме бар аның хатынынннан башка? Хакыйкать шул: ул балалары, Наиләсе хакына җанын сатарга да, заман белән вәгъдәләшергә дә әзер. Чукынып китсен!

Ул үзе дә аңлап бетермәде, бу — аның үткән гомер белән, үткән гомерендәге хак сүз белән, чынлык аша аны баеткан Фәридун Фазлыев белән мәңгегә хушлашуы иде. Дәҗҗал мәлгуньгә җанын сатуы иде бу аның. Инде иртәгәдән соң бу төбәккә аяклары адашса да килмәс, чөнки ул моннан ары бөтенләй яңа кеше, замана кешесе булачак. Әй мактар инде аны Фәтхулла абыйсы! И сөенер инде үз авылында рәис булып ятучы Ихлас исемле мөртәт!

Нәҗип алай ук тинтәк түгел. Гаделлекне яклап, авыл агайлары белән махра көйрәтеп, каравыл өе алдындагы бүрәнәдә гәп куерту әле егетлек түгел, гаделлек өчен нидер эшләргә, үзеннән дә өлеш кертергә кирәк. Бу өлеш үз авызыңнан өзеп бирелгән булырга тиеш!

Урнашкач, бәләкәй генә тернәкләнгәч, әти-әниләренә посылка салыр! Беренче нәүбәттә шул! Алдагы җәйдә кайтып өйләрен сипләргә, утын китерергә, сарык-кәҗәгә печән чабарга туры килер. Әтиләр хуҗалыгына кулы кергәч, ул Сабит белән дә икенче төрле сөйләшәчәк! Сабит балаларын, Сөмбеләне кунакка чакырырга... Туганнар белән хат алышырга!.. Ниһаять, аның да тотрыклы адресы була, кешегә күрсәтерлек квартиры! Кояшлы як, өченче кат... Иван Иванович белән якынайсалар, телефон да кертерләр. Утырсын Наилә ахирәтләре белән эпачапа сөйләшеп...

Фәридуннарга барган чакта ул бер иде, сары йортка кайтып кергәндә Нәҗип бүтән иде инде. Буе тәбәнәкләнде, авызы олайды. Бик каты чир кичергәннән соң адәм баласының авызы зураеп кала. Җан чыгарга җиңел булсын өчен иреннәр йомшаралар... Кайтып керсә, дагалы итекләре белән идәнне төеп Ионыч утырган, яланбаш, чалбар төймә-

ләре каптырылмаган, кипкән иреннәре белән төпчеген чәйни. Йокымсырый иде, айныды, карлыккан ямьсез тавыш белән, косык исе чәчеп Нәҗипкә ябырылды. «Нигә поминкада булмадың син? Ник зиратка бармадың?! Урыс үлде дипме? Зиратта аерма булса да, табутта аерма юк, анда һәркем тигез. Без бит ике фәрештәне, гөнаһсыз җаннарны куйдык. Нигә син йортның кайгысын уртаклашмадың?» Нәҗип кыенсынып кына: «Без бүген генә кайтып төштек, Ионыч»,— дип акланырга сүз ачкан иде, Ионыч икенче яктан элдереп алды: «Ник кайттың син, дурак? Нигә? Ник яшисең син бу дөньяда? Нишләп пыскып ятасың бу сары йортта?! Сабыйларыңны ни йөзең белән апкайттың? Болай да сау түгел алар, ютәлләп колакны тондыралар иде. Хәзер аларга астма йогачак. Чехотка! Аллергия дигән нәмәрсәне беләсеңме син, инженер? Яшим, күрәм, бер кыш чыккан балалар да саргаеп күксәүгә әверелә. Олы авыру — фурункул чыга, каннары бозыла. Колаклары ага. ТЭЦ-та гына гаеп түгел, тимер юл гына да зыян салмый, силикат кирпеч заводы черетә адәм балаларын! Заманында бу район шәһәр чите булган, хәзер завод уртада калган... Иван Иванович янына барып сөйләшеп карадым. Кем мин аңа? Тотыныр тоткасы булмаган дүңгәләк... Тамырсыз, көчсез нәрсәкәй. Тигәнәкнең дә ябышыр чаты бар, ә дүңгәләкнең юк... Бер быел ничә мәет озаттык без моннан? Дүрт кеше үзенә кул салды. Ә син... үгез җигәрлек башың белән монда тынчыйсың. Дур-рак! Авылдан балаларны кайтаралармы?! Без яшибез инде, без беткән кеше. Язмыш баш очына козгын утырткан... Син дә беткән кешемени?.. Ионыч кайгысын йомарлап кергәндә утырып эчәргә яртың да булмый бит синең!» Нәҗип сүз кыстырырга тырышмады, сүзе дә юк иде бугай. Ионыч шак-шок басып ишек катына килде, борылып карады: «Июнь аеннан фатир хакы йөз тәңкә! Мин киленгә әйттем». «Нигә алай күп?»— дип сорады Нәҗип. «Сәвит акчасы бер тиенгә дә тормый. Кыйммәте юк, шуңа күрә күп!» «Безнең бик авыр чак иде бит, Ионыч»,— диде Нәҗип җәберсенеп. Ионыч суган исе бөркеп Нәҗипкә йөзен якынайтты: «Үзеңә генә әйтәм! — диде ул.— Лиза үзенә һәм баласына кул салып, безнең йортны телгә кертте. Хәзер кайберәүләрнең авызын томаламасак, квартирлардан колак кагуыбыз да бик ихтимал! Санаша торган чак түгел! Синең барыр җирең бармы?» «Әлегә юк!»— диде Нәҗип. «Минем дә юк! — дип күтәреп алды Ионыч.— Акча гони!»

Нәҗип иртүк шәһәр советына чапты, калтыранган, көчсез тавыш белән Иван Ивановичны сорады. «Ул сессиядә»,— диделәр. Көн тагын сары йортта үтте. Хәзер ул иртә таңнан шәһәр советына чаба торган «даими клиент» булып китте, секретарь ханым аны тавышыннан таный башлады. «Сез миңа йомышыгызны белдерегез, мин Иван Ивановичка җиткерермен. Ул сезгә көн, вакыт билгеләр»,— диде ханым. Нәҗип югалып калды: йомышын бүтәннәргә әйтергә ярыймы аның, юкмы? Байтак интектергәч, ханым аны ачыктан-ачык пешекләргә керешге. Ул кыяр-кыймас: «Сабит Иосыпович Нургалиев рекомендациясе белән шалтырата идем мин»,— диде. Ханым тагын да ныграк орышты: «Нигә башта ук шулай димисез? Иртәгә тугызынчы яртыга килеп җитегез!»

Аны иртәгәсен дә серле Иван Иванович янына кертмәделәр, гәрчә ул аның шәһәр советында иң дәрәҗәле кеше икәнен белеп алган иде инде. Ярдәмче ханым кырыс елмаеп каршылады да: «Фәлән урамда йорт җимерелде. Сез шул йортта яшәүче аварийщиклар исемлегендә. Квартиралар бүлүче отделга төшегез. Анда Фомин дигән иптәш булыр. Формальностьлар эшләнгән. Әзер. Ордер алыгыз да тизрәк күченегез»,— диде. «Шулай тизме?»— диде ни әйтергә белмичә Нәҗип. Ханым дәшмәде, ни уйлагандыр, күз карашы усал, аяусыз иде.

Нәҗипнең үз гомерендә мондый кыйммәтле документ алганы юк иде: туу турында таныклыгы бар — чүп! Паспорт алырга гына ярый ул кәгазь. Паспорт — чепуха! Диплом — адәм көлкесе! Аның белән гадел

яшәсәң, тамак та туйдыра алмыйсың... Ордер! Бу инде орденнардан да кыйммәтрәк, дипломнан да кирәгрәк. Ордер — сине кеше рәтенә кертә, яшәргә хокук бирә. Ордер — квартир. Квартир — крепость. Моннан ары Нәҗипнең тормышына Тимерхан, Җәмиләләр, Ионычлар, Ираидалар, Фәтхуллалар катнаша алмый, аның хатыны белән ничек йоклаганын, ни эчкәнен, ни ашаганын берәү дә тикшерә һәм күзәтә алмый. Яңа квартирга барып кергәч, ул, әлбәттә, ялан тәпи бер биеп җибәрәчәк. Рәхмәт мәрхәмәтле, ягымлы, игътибарлы кулыннан эш килә торган чиновник-бюрократка! Алар арасында да чын кешеләр бар икән!

Беркатлы, тинтәк Нәҗип, әлбәттә, Сабит белән Казан шәһәре башлыгын ни берләштерә алуын уена китерә алмый, тимер юллар министрын каршылауга тотылган байтак чыгымнарны Сабит күтәргәнен, бүтән чакларда да аларның аралашканын, Сабит-хан биләмәләрендә кыр тавыгы, көртлек, Мостафин урманы күлләрендә үрдәк ауларга йөрүчеләрнең иң активы шушы кеше икәнен белми иде.

Ул шәһәр советыннан чыкканда Кремль сәгате нәкъ икене сукты, ул шул якка борылып карады, зәп-зәңгәр күктә манараның алтын йолдызы йөзә кебек тоелды. Аның ике иңенә дә канатлар үсте, чир-чорлар, өметсезлекләр онытылды, моңарчы аякка тагылган богаулар чишелде, күзе ачыграк һәм ераграк күрә башлады, алдагы тормышы Идел аръягында тирбәлгән Ослан таулары сыман гүзәл, серле һәм мәһабәт булып тоелды.

Уңда Җәлил калды, сулда музей. Ул Казан елгасының аръягына, Ленин районына, сары йортка тизрәк кайтып җитәр өчен үрдән аска ташланды, машиналарны узып, троллейбус тукталышына очты. Һәм авыр сулап, кулларын артка куеп, кара кайгыга батып менеп килүче ир затын чак кына таптап үтмәде. Тыелып туктады, килүче таныш булып күренде. Аның кырында, очкан озын гәүдәгә юл сабып, юаш елмаеп, Фәридун Фазлыев басып тора иде.

«И язмыш! Без белмәгән нинди кодрәтләрең бар синең?!» — дип мең кат уфылдады ул соңыннан. Фәридун Фазлыев елмаюын йомып җитдиләнде, ике кулын бирде. «Мин сезне авылда дип торам. Ни эш кыдырып йөрисең?» Нәҗип Фәридунның иңнәрен кочып алды. «Фәридун абый! — дип кычкырды.— Менә квартир алып йөрим!» «Котлыйм! — диде Фәридун табиб, елмаюына көч биреп.— Котлыйм!» «Ә сез, Фәридун абый?» — дип сораса да, Фәридун сүзләренең эчтәлеге әле Нәҗипнең сөенечтән томаланган акылына барып ирешмәде. Шул булды — ул Фәридунга ияреп өскә менә башлады. Халык үтеп-сүтеп йөри, тар баскычта тору уңайсыз иде. Фәридун баскычтан бик акрын һәм шактый ук озак менде. Җәлил һәйкәле кырына, таш эскәмиягә барып утырдылар. Фәридун дымлы маңгаен, битен сөртеп, тынын туплагач, төшендерде: «Ниһаять, миңа да квартир бирергә тиешләр иде. Ике ай төеннәр өстендә утырдык. Йортны тапшырдылар, күченәселәре күченеп бетте, диделәр. Инде ордер алам дигәндә, истә-оста югында, Иван Иванович чакыртты. «Көт көзгә кадәр! — ди.— Мәскәүдән белгеч чакыртып алдык, сиңа багышланган квартирны аңа бирергә туры килде»,— ди... Тагын бер-бер бүтән сүзе юкмы дип аптырап янына менеп барам... Апаң шушы хәбәрдән чирләп егылды. Реанимациядә ята».

Нәҗипнең колак төбендә генә нидер чыртлады, күз алдында ут бөркелде. Менә ни өчен сөенечен уртак итәргә теләп Фәридун абыйсы катына җитәкләп алып барган икән язмышы аны! Мөгаен, шул сәгатьләрдә «белгеч килүен» хәбәр иткәннәрдер аңа? Шул коточкыч шәфкатьсез мизгелдә хатыны чирләп аугандыр?! Тукта! Нигә алай уйлады ул? Бәлки, язмыш аңа карата алай ук аяусыз түгелдер?.. Ул Фәридун абыйсына йотардай булып карады: «Гвардейский урамындамы? Өченче кат. Балконлы, көньякта?!» Ул сораган саен Фәридун баш кагып тора, соңыннан икесе берьюлы әйтеп салдылар: «Утыз беренче йорттан уңдүртенче квартир?»

Нәҗип ордерын чыгарып күрсәтте... Фәридун телсез калды. Нәҗипкә күтәрелеп карады. Бу караш! «Нигә, тәкъдир, уттан алып суга салдың мине? Тәүлек буе куанырга да форсат бирмәдең? Хатын, балаларны сөендерергә дә өлгермәдем!» — дип кыйналды ул соңыннан...

Фәридун сорашмады, аңлады, бер карады Нәҗипкә, батырып карады. Шушы карашы белән ул аны үтерде, бәреп екты, суйды, упкыннан түбәнгә ыргытты, язгы ташкынга төртеп төшерде, яшен булып сукты, тәмугның иң зәһәр, тавышланып, бызырдап кайнаган сумала казанына кул-аякларын бәйләп салды. Нәфрәт белдерергә гел-гел сүз кирәкми, нәфрәт өчен бер караш җитә. Әгәр сиңа намуслы, сатмаган һәм сатылмаган, шәфкатьле, мәрхәмәтле җан иясе нәфрәт утын төби икән — аңа чыдармын димә. Сабит арбасына утырып җырлый башлаган Нәҗип шул мизгелдә үзен үтәли күрде...

Күрде, сикереп торды. Фәридун Фазлыевны шәһәр советының мең хәсрәтле аяклар шомарткан тимер баскычында куып җитте. Иван Иванович кабинетына тарткалаша-тарткалаша алар бергә керделәр.

Шулай теләде Нәҗип, Фәридун ризалашмаса да, кат-кат ялынды. «Әгәр исән калуымны теләсәгез, Фәридун абый, сүземне тыңлагыз. Ордерны алыгыз. Сезне утка ташлап, хәләлегезнең җан кыючысы буласым килми», — диде.

Фәридун Фазлыев яшәгән йортны җимерәләр икән. «Соңгы булып күченәбез, әгәр квартир бирмәсәләр, эш харап иде», — диде ул.

Нәҗип Йосыф улы Нургалиевнең кыюлыгы җитәр, ярдәмче марҗаның ай-ваена карамастан, ул Фәридун Фазлыевны җитәкләп Иван Иванович янына барып керер, үзенә язылган ордердан аның файдасына баш тартып, мәрның «күзгә уйлап карарбыз» дигән сүзенә ышанып, ярык тагарак янында утырып калыр, дип кем уйлаган?! Икенче көнне өченче каттагы, кояшлы яктагы яңа квартирга Фазлыевны күчерешер, әйберләрен сөенә-сөенә ташыр, булышыр дип кем уйлаган?!

«Йортә безне язмышлар», — дип туган ягын сагынганда җырлап җибәргән безнең шахтер бабайлар... Җырлар, мәкальләр, риваятьләр — язмышы конституцияләрдә бер чакта да тиешенчә берегә алмаган татарның яшәү кануннары, безнең уртак тәрәкле уйлар. Татарның язмышы җиңел булмаган, әйдә без дә язмыш җиленә баш биреп, җилкәнсез, ишкәксез көймәләргә утырышып төрле якларга таралган татарларга да, таралачакларына да рәнҗемик... Авыр булса да түзик, «бүлегәнне бүре ашар, аерылганны аю ашар», дип зарлана-зарлана таралышкан кардәшләребез ничәмә ничә гасыр аю-бүреләрне тукландырып торалар икән, нихәл итмәк кирәк? Нужа баткагыннан чыга алмаса да, туган төяген ташлап качмаган Нәҗип ишеләре дә бар ич әле аның үз арабызда!..

Наилә Нәҗипне аңламады, аңларга да теләмәде, иренең дәлилләре вак-төяк, чүп-чар булып күренде. Ничек инде, заман кешеләре бер-берсенең күкрәген изеп үзләренә юл салганда, кулыңа килеп кунган бәхет кошыннан баш тарт?! Бу бит — диваналык, шыр тилелек... Бу, бу... Наиләнең зәһәр тавышы Нәҗипнең колагында чиркәү чаңы гүләгән сыман, «бу, бу, бу!» ишетелеп торды. Черек саламлы эскерт төбендә Наилә әүлия, ак канатлы фәрештә булган икән әле!

Атаның ятарканын белгән хатын-кыз ызгыш-талаш арасында балаларны арага кертә, калкан итеп куя. «Син, тинтәк хайван, сары йорт хакында, монда җан тәслим кылган сабыйлар турында Ионыч әйткән сүзләрне ишетмәдеңмени? Колагыңа мамык тыккан идеңмени, дивана?.. Үз балаларын яратмаган, аларны санламаган ата да булдымы кеше?»

Йөзен ертып, каршысына кереп баскач, кыюланып, Нәҗип Иван Ивановичка эш сорап та мөрәҗәгать иткән иде. Гомер юлында мондый адәми затны беренче тапкыр очраткан Иван Иванович егетне акыл ягыннан зәгыйфь санаса да, кызыксынып китеп, эш белешкәләп торыр-

га кушкан иде. Моны ишеткәч Наилә күтәрелеп бәрелде: төтене дөрес иде бүген хатынның! «Шыр дуракка, күрексез гармунга нинди эш бирсеннәр?! Әнә шул, бакчага карачкы итеп куйсалар инде! Дөнья мәсьәләләрен ач каргалар белән хәл итеп яшә шунда, дөмеккән!»

Кирәк бит, алар шулай тарткалашып, бер як ут кебек дөрләп, икенче як тоташ уттан ничек чыгарга белмичә утырганда сак кына ишек ачылды һәм аннан кем керде дип беләсез?..

Кайда яшәүләрен беркемгә сөйләгәннәре юк, сары йортны адрес бюросында Америка шпионнары да таба торган түгел, ә ишектән, шакымыйча-нитмичә, көяз атлап, утта янмас, суда батмас Мәхмүт-Мудрый басып керде. «Юк-юк! — диде ул Наиләнең бер якка талпынганын күреп.— Чәй кирәкми, тамагым тук, әнкәй янынннан әлерәк кенә гөбәдия ашап чыктым. Гөбәдиясе!.. Кештердәп тора! Бүген Минһаҗевне җирләдек бит, малай. Инфаркт кыра яшьләрне. Егерме тугызы тулган иде егетнең. «Заря» ресторанында дүрт ел директор булды, ә бавырының кылкасы да калмаган. Бавыр белән китмәде тагын, йөрәккә биргән. Ә зиратта яшьләр ята тезелешеп!»— дип такылдады ул, хуҗаларның сырт йоны кабарганын сизенмәскә салышып.

Ачудан талагы кабарган Нәҗипнең бүген «зират», «үлем», «инфаркт» дигән сүзләргә һич исе китмәде, колагы балавызланган идеме, ник чукынып китми дөньясы, Минһаҗевларның ник кырык чөйләре кырылмый, үз кайгысы бүгенгә түгел, иртәгәгә дә җитәрлек әле Нәҗипнең. Наилә аксак чыпчык кебек бер урында сикергәләде, Мудрыйны кая утыртырга белмәде. «Мәхмүт җаным, әҗәт артыннан керүеңдер. Акчабыз бар барын, тик син әзрәккә түзмәссеңме?» Мудрый җылы сүзләрдән эреп, үзенең әзгә түгел, күпкә күтәргә дә чамасы барлыгын белдереп кулларын җәйде. «Керүем аңа түгел, Наилә ханым! Яшәрлек чамам бар. Йомышым юк түгел түгелен».

Гаҗәп, бүгенге хәлгә төшкән хуҗаларда кемнең, нинди йомышы булуы ихтимал? Мудрый таралып яткан балаларның өсләрен рәтләде, каушаган хуҗаларны тагын бераз көттереп: «Сезнең Латыйпов белән аралар ничек? Чама-чамага туры киләме, әллә...»— «Изил Бәдретдиновичны әйтәсеңме? — дип сорады Нәҗип, сытык чыраена караңгылык чыгарып.— Ничек дип...» Наилә, ярдәм көткәндәй, иренә карап алды. «Ни булган Латыйповка? Әллә ул да кәкрәйгәнме?!» Нәҗип сүз өчен генә бирде бу соравын. Мудрыйның кычытмаган җирне кашып йөрүе тулышкан ачуын арттырды.

«Алпавыт булып китте абзагыз! Җир хуҗасы! Кыланмышын күрсәгез... Директор биргән «Волга»да кәпәренеп кенә юрттыра. Кояштыр. Күрсәгез танымыйсыз сез аны!»

Ярата Мудрый куе төтен җибәреп кешеләрнең башын әйләндерергә! Хуҗалар бик белергә теләп сорашсалар да, ул аларны өч нарат янында байтак адаштырып йөртте. Завод кешеләренә дип Идел буеннан ике гектар ярым җир бирүләрен, шул җирдә дачниклар ширкәтен оештыруны Изил Латыйповка тапшыруларын Нәҗип белән Наилә аңларлык сөйләгәнче, үзе дә манма тиргә батты. Ниһаять, аңлашылды, керүе яхшылык артыннан йөрүе икән егетнең! «Идел буенда шәп итеп йорт салып җибәрәсез. Рөхсәт! Яшә шунда, гөлчәчәкләр утырт, бәрәңге, кишер! Станция терәлеп тора, машинаң юк икән, башың ватылмасын, теке-теке поездда теркелдә! Мич чыгарсаң, кышын да анда яшәргә була! Утын хәсрәте юк, урманы өстеңә ишелгән! Латыйповка чабасыз да бүленеп беткәнче җир аласыз!»— дип сөйләп бетерүенә, Наилә пыскып елап җибәрде. «Кем бирсен аннан безгә җир?» Мудрыйның кашлары өскә сикерде: «Әгәр Латыйпов белән вася-вася яшисез икән, ник бирмәсен?! Начальство үз кирәген алып бетергән, партбюро әгъзаларына да шобагага кадәр үк үлчәп биргәннәр, минемчә, читтән-чоттан, ерганак тирәләреннән аның бирер чуты бар».

Наилә ашыгып-кабаланып күз алдыннан сихри күренешләрне үт-

кәрде. Идел. Урман. Саф һава. Түтәлләрдә җәй буе кишер, шалкан үсә. Малайлар түтәлләр арасында тәгәрәп ял итәләр. Нәни генә йорт салып, мич чыгарып куйсаң... Сары йорттан котылырлар иде, ичмасам!

Хатынның Мудрый алдында мышкылдап торуын өнәмәгән Нәҗип кырку гына сорады: «Ни булды сиңа? Балавызыңны ник сыгасың?» «Соң, бәгырь кисәгем, сине заводтан типкәләп чыгардылар. Кем бирсен сиңа җир?» «Ә син? Нигә сиңа бирмәсләр дисең?» Мудрый шулай дип әйтеп өлгерде, Наилә тагын елап җибәрде. «Мин арбаның бишенче тәгәрмәче. Кирәгем шул хәтле генә. Мине куарга да күп сорамаслар. Нәҗип кайтканнан бирле юньләп эшкә чыга алмыйм. Моннан ике транспортка утырып балаларны бакчага илтергә кирәк. Ярты көн үтә. Үз хисабыма ял алып авылга кайттым. «Соңгысы! — дип бирде мөдиребез.— Йә иреңне савыктырасың, йә бездән китәсең!» Кая дип ул бакча». Мудрый алай тиз бирешә торган егет түгел, ул тә-тә-тә хуҗаларны һаман үгетләде. «Ятып калганчы атып калыгыз. Син, Наилә, Латыйпов белән сөйләш!» Ни сөйләшсен ул андый ала күз белән!

Мудрый, үзара талашның җанлануын чамалап, үз вакытында чыгып тайды. Нәҗип белән Наилә парма-пар ызгыштылар, тавышка балалар уянды, ачу китереп, җир селкетеп поездлар үтә торды, аскы катта чыр-чу килеп исерек хатыннар җыр суздылар.

Көндезге гауга төнлә тынып торса да, иртән ир хатынга, хатын иргә борылып карамады. Наилә балаларны дөбердәтеп врачка алып китте, аларны бакчага кайтарыр өчен больницадан белешмәләр кирәк иде. Нәҗип шәһәр советына чапты, «Сабит Йосыпович Нургалиев рекомендациясе белән» тагын Иван Ивановичка шалтыратты, шактый әрсезләнеп, кыюланып үзен кабул итүен үтенде. Өч-дүрт көн йөргәч, ниһаять, алар әзгә генә очраштылар. Дуамал, башсыз кеше белән кызыксына башлаган мәр ахирәт дустының энесенә шәһәрнең иң зур яшелчә базасында директор урынбасары булып урнашырга тәкъдим итте. «Гаҗәпләнмә,— диде ул,— директор урынбасары төшемле, җаваплы урын. Җөмләдән, директор булып анда кәттә бер егет эшли. Әлгәре сәнгать белгече булган диләр, аспирантура тәмамлаган, шагыйрь! Аның кулы астында инженерлар, кибернетиклар, югары мәктәп укытучылары, хәтта бер доцент та барын белеп кит. Оттырмассың».

Әгәр Наилә белән аралары шулай киеренке булмаса, ул, мөгаен, ризалашыр да иде. Бүтәнчә кая бара аласың? Ичмасам, гаиләсенең тамагы тук булыр, эшкә һәм дөнья таләп иткән хәйләгә өйрәнер иде. Тик бүген, Наилә аны секунд саен аска салып изгәндә, «яшелчә базасына урнаштым», дип ничек кайтып әйтәсең?!

Алай да, арты белән күлгә чумган үрдәк кебек, яшелчә базасына кагылып чыгарга булды. База директоры — буйга үзе кебек озын, киңчә ак чырайлы, яхшы аргамак кебек башын югары чөйгән, укымышлы кыяфәтле урта яшьләрдәге кеше. Нәҗипнең киләсен белә икән. Ул Сабит Йосыповичны якыннан белүе белән дә мактанып куйды, эш хакында күп сөйләп тормады. «Төрлечә яшәп карадым мин. Якты дигән юллар ачык иде... Монда килгәч гап-гади хакыйкатьне аңладым: моңарчы мин гел ялварып, бөтен кешегә ялынып яшәгәнмен икән. Ә хәзер бөтен кеше миңа ялынып килә. Шул аерманы аңласаң, кил»,— дип сүзен йомгаклады. Нәҗип: «Рәхмәт; уйлап карармын»,— дип чыгып китте. Киңәшкә Фәридун Фазлыевка барды. Ул сүзне коры тотты: «Пычранма. Кер укытырга. Мәктәптә ир укытучыны ике куллап каршы алачаклар!» «Укытучыларга бирәр заман квартир бирелгәнен ишеткәнегез бармы, Фәридун абый?» Фәридун аптырап калды, Нәҗип аңа да: «Уйлап карармын!»— дип әйтеп, өенә кайтып китте.

Өйдә — өермә, буран! Идән белән түшәм арасында Наилә яшен уйната. Башын иеп чыгып китә Нәҗип, башын иеп кайтып керә, кичергәннәрен тәртип белән хатынына аңлата, ике ара барыбер җылынмый. Наилә, Мудрый сүзләрен куәтләп, Нәҗипне Изил Латыйпов янына куа

башлады. «Әгәр бакча артыннан йөрмисең икән, үзем йөрим! Латыйпов белән үзем сөйләшәм!»— диде ул бер кичне. Ни әйтсен Нәҗип, телен аркылы тешләп, моңсулык гомерлеккә йөгергән күзләре белән аны эшкә озатып, малайларны бакчага алып китте. «Әни нигә көн дә жылый?»— диде Искәндәр, әтисенең кулын ике учы белән кысып. Нәҗип җавап кайтармады.

Наилә ирен кат-кат өркетергә маташса да, әлегә Изил Латыйповны эзләп чапмады, гарьләнде. Түбәнсенәсе килмәде. «Бер-бер бүтән җае килеп чыкмасмы?»— дип нидер өметләнеп көтте. Беркөнне, эшкә барырга җыенып урам як ишек катына чыккач, Ионычны очратты. Алар, берничә ир, борчылган кыяфәттә чыш-пыш нидер сөйләшәләр иде. Колагы торды Наиләнең, якынрак килде, тыңлады. Ионыч күз кыры белән генә аңа карап алды, әңгәмә дәвам итте. Һәм Наилә, коты чыгып, шушы арада бульдозерлар килеп сары йортны җимерәчәкләрен белде.

Эше эш булмады, биш-ун минут саен профкомга чапты, ике көн рәттән сагалады Наилә Латыйповны, шәүләсен күреп калгалады, әмма профсоюз лидеры җир бүлү, су, электр үткәрүләр белән шул кадәр мәшгуль иде, койрыгын тиз генә берәүгә дә тоттырмады. Ә сары йортта мәхшәр башланды! Ионыч квартир саен йөреп чыгып хуҗаларны кисәтте: «Тиз-тиз моннан таясыз! Кайда яшәгәнегезне чәчеп йөрмисез. Алай-болай судка-фәләнгә чакырсалар, җавабын таба белегез!» «Суд» дигәнне ишеткәч, карчык-корчык төенчеген төйнәп, үксеп елашып, кая барырга аптырап, урын эзләргә керешге. «Җир-мазар алсак, палатка куеп булса да җәйне үткәрер идек, көзгә кадәр вакыт бар, ни булса да куыш әтмәләрбез!»— дип сөйләштеләр Нәҗип белән Наилә. Эш җиргә терәлеп калды. Җир — бердәнбер һәм актыккы өмет иде!

Җомга кичендә, хезмәткәрләр кайсы-кая таралышып, тузан исе аңкыган коридорда ул Изил Бәдретдиновичны куып тотты, әрсезләнеп кабинетына ук барып керде. Изил орышмады, кабынмады, йөз сүрәнләгән куеп бер елмайды, кергәч ишекне бикләп, ачкычны өстәл тартмасына ук салып куйды. «Гаҗәпләнмә, Наилә, бу гади саклык чарасы гына. Җир бүлә башлаганнан бирле ничә төн йоклаган юк, тәрәзә астыма килеп күмәкләп кычкыралар. Ришвәт китерәләр, коньяк кыстырып керәләр. Обкомнан шалтыраттыралар. Туй үткәч дөмбергә! Юк бит инде җир, бетте, гөл чүлмәгенә салырлыгы да калмады. Күз ял итәрлек берәр кешегә зарыккан идем, сине күрергә булган икән! Бездә бит шул хәл, халык — сарык көтүе! Кәҗә тәкәсе кая бара, савылып шул якка ябырылалар. Бәлки кәҗә тәкәсе дуракгыр? Аны уйлаган юк. Дача дигән сүз таралуга, завод шашты. Адәм балаларын шул тиклем комсыз, күремсез һәм көнче дип белми идем. Китте берсе өстеннән икенчесенең әләкләре, дәгъвалары! Доноелар! Ярый, утыр син, термоста сөтле чәем бар. Рәхәт, сиңа җир кирәк түгел, болай хәл белергә кергәнсеңдер?»

Изил шкафтан термос чыгарып, куе зәңгәр чынаякларга чәй агызды, Наилә, түзем генә күзәтеп утырды да, йомышын әйтеп салды. «Түгел әле, Изил Бәдретдинович. Мин дә җир сорарга дип көтә идем сезне. Безгә дә өлеш чыгарырсыз дип ышанам». Ышанычын дәлилләргә көче юк иде хатынның, көчсезлектән ике бите яна башлады, тавышы калтырады. Латыйпов күтәрелеп бәрелмәде, бераз уен үлчәп торды, чынаякларны Наилә алдына куеп, үгет бирергә тотынды. «Дача — байлык. Йорт-җире, җиһазы бар, һич югында, машиналы кеше дача артыннан чаба. Дача — кешенең тормышы көйләнгәнлеккә бер дәлил. Белүемчә, сезнең торыр җирегез юк, Нәҗибең дә эшләми шикелле, аны урнаштырырга да ашыкмыйлар? Шулаймы? Нәрсәгә сезгә дача?! Артык акчагыз кесә тырныймы?» Наилә Изил Бәдретдиновичка озак казынырга ирек бирмәде, юкса дилбегә аның кулына күчәчәк иде! «Дачаны сез тормыш йомгагы дисез... Ә без кешечә кыланмаска булдык! Без азактан, муллык дәлиле дачадан башларга телибез!» «Синеке кеше төсле генә булмас инде!»— дип авыз ерды Латыйпов, эчә башлаган чәен читкәрәк

эшереп. «Синеке» дигәндә аерым тыныш ясады. «Дөнья басты, Изил Бәдретдинович, теләгәнчә яшәү мөмкин түгел икән!»

Изил, өстәл артыннан кубып, Наилә янына күн диванга килеп утырды. «Син, Наилә ханым, ирен сатып йөрүче ачык авыз түгел. Сүзеңә кушылмассың да... Ә ирең — шыр тиле! Ничек сине кулына төшергәндер, акылыма сыймый. Яши белми Нәҗип! Асылда сине яратмый ул. Яратса, шул тиклем җәфалар идеме?»

Латыйпов, Нәҗипнең гаеп-кыекларын, ялгышларын саный-саный Наиләгә якынлашты, чиркандырып, өшетеп тән-тәнгә тиде, ләкин Наилә тартылмады, ул ике куллап диванга ябышкан, купмаска тотынган иде.

Җир кирәк аңа бүген! Җир!

Комсомолда тәрбияләнгән, профсоюзда азау теше ярган, меңнәрнең күңеленә рөхсәтсез кереп гадәтләнгән Латыйпов ни өчен йөргәнен ишек бавына тотынгач та белгән иде. Биленә кул салуга сыгылып төште хатын, күз яшенә буылып, Латыйповның тезенә капланды. «Ярый,— диде Изил кипкән иреннәрен ялап.— Өч-дүрт сутый җир табармын. Монда бер четерекле нәрсә бар. Җирне без Зеленодольск райбашкармасы белән килешенеп алдык, рәсмиләштердек. Көтмәгәндә шул участок белән шәһәр советы кызыксынырга тотынды. Хәзер ике арада тартыш бара. Дөрес, безнең завод җирле советларга буйсынмый, төкермибез дә без аларга! Шулай да аларның бер-бер этлек кылырга җайлары бар. Бер мичкә балны бер кашык дегет боза! Шәһәр советы белән чыккан низаг-гауга халыкка мәгълүм. Шуңа күрә җир алып өлгергән кешеләр эшкә тотынырга базмыйчарак торалар. Көтәләр. Эшкә керешеп, агач утыртырсың, йорт сала башларсың, ә җирне горсовет тартып алыр! Инде биш-алты хуҗа, тәвәккәлләп, йорт җиткерә башласа, тиз-тиз тезеп агач утыртса, җирне бездән тартып алу читенләшә! Кыскасы, шарт мондый: мин сезгә җир бүлеп бирәм икән, сез икенче көнне үк йорт салырга тотынасыз. Һәм эшне бик коры тотасыз! Шул очракта гына мин җәмәгатьчелеккә, халык контроленә нилектән сезнең гаиләгә участок бирелүен аңлата алам. Югыйсә гариза биргән дүрт йөз кеше җирдән күзен алмый! Җир синең исемдә булыр, җаныкаем».

Изил Брежнев, Суслов, Романов, Рәшидов, Черненко томнары тыгызлап тутырылган ялтыр-елтыр шкаф янына килде дә, әллә каян, арттан, йомшак поролон сырма тартып чыгарды, аны пөхтәләп, таслап идәнгә җәйде һәм күзләрен зур ачып, куркынган өрәктәй калтырап торган Наиләгә: «Син ни көтәсең тагын?» — дип, чалбар төймәләрен ычкындырды.

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Латыйпов Наиләнең тән ләззәтенә шаккатып, Наилә җирәнеп, хурланып икесе ике якка тәгәрәделәр. Наилә как идәнгә үк төште, аның җан ачысы белән кычкырасы, Изилнең ямьсез елтыраган бәбәкләренә төкерәсе килде. Ә теле бөтенләй бүтәнне, зарын сөйләде: «Кирәктер дә, кая инде безгә алай ашыгыч йорт җиткереп керүләр? Син андый авыр шарт куйма безгә, зинһар. Җәллә безне». Профсоюзның карашы, тавышы үзгәләнде: «Анысы инде, Наилә кояшым, ирең мазасы булсын. Ир исемен йөртә икән, шундаен дан хатынга өйләнергә җөрьәт иткән икән, Нәҗибең кайгыртсын! Кем сораса да, җавабың бер булсын: байтак еллардан син завод китапханәсендә эшлисең, җир сиңа мин әйткән шартларда бирелде. Бетте-китте».

Наилә өенә туры кайтмады. Тормышының бүгеннән нык үзгәрәсен ул бөтен тулылыгы белән аңлый иде. Тормыш, мәхәббәт, балаларга мөнәсәбәт кайсы якка борылып керер, ул бу хакта уйларга әлегә курка иде. Моңарчы табынган әдәп-әхлак кануннарын ул бүген таптап үтте. Ул җинаятьне авыру ире һәм чир алдында торган балалары хакына эш-

ләде, бүтәнчә булдыра алмады. Үзгә юлны тапмады. Хәзер аның саф күңеленә хуҗа булып мәңге онытылмаслык, тәүбәгә килсәң дә, юылмаслык авыр гөнаһ калды. Ул шул хәлендә, яшәгән җире сары йорт кына булса да, кайтып күренергә гарьләнде, юл уңаенда мунчага керде. Бик озаклап тәне күгәргәнче, сызлаганчы салкын су астында торды, аннан шау кайнар су җибәрде. Салкынны да, эссене дә сизмәде, тәне дә җаны кебек үк үзгәргән иде. Ул үз-үзеннән гафу үтенеп, ләүкәнең биегенә менеп, дулкын-дулкын чәчләрен күгелҗем юшкын ямьсезләгән түшәмгә тидереп торды...

Аның: «Изил Латыйповны әзәрлекләп вакыт үткәрдем, гариза язып, ялынып кергән идем, безгә җир бирделәр. Кайтышлый кызлар белән мунча кереп чыктык... Җирен бик мактыйлар».— дигән кәтелмәгән хәбәрләрен тыңлагач, Нәҗип хатыны сөйләгәннәрнең төбен дөп-дөрес аңлады. Йомышы төшкән хатын-кызларны кулы аша үткәрергә яраткан бәндәнең хикмәтләре хакында күптәннән чыш-пышлар йөри иде. Баш инженерның кайнише булган ач күзгә кулы җитә алган кеше генә юк иде әлегә.

Төпченмәде, вакланмады, Наиләсен тукмап ташламады, куырылып, бәләкәйләнеп, җаны бер учка сыярлык булып калды. Йә, белде ди, сорашты ди, Наиләсе бәйнә-бәйнә сөйләп бирде ди. Ни үзгәрә? Бу заманда Нәҗип белән Наилә ни үзгәртә алалар?

* * *

Яши-яши һәр кеше власть белән очрашмыйча калмый, очраша, властьның көчен, аның кодрәтле хокукларга ия икәнен аңлау дәрәҗәсенә ирешә. Военкоматка чакыртып алып дурдомга ябарга әзерләгәндә Нәҗип бу тыелгысыз куркыныч көчтән бер тапкыр качып котылган иде инде. Котылса да, власть көченнән курку калды анда. Власть тудырган гаделсезлекне, хаксызлыкны ачыграк күрде, әмма көчкә каршы бара алмады, ярым качып-посып, ярым битараф калып яши бирде. Власть көче гайрәтле кешеләрне дә чәнчелдереп төшерә, җаннарны вагайта, холыкларны бер калыпка салып, куркакка әйләндерә. Чөнки власть башына һәрчак куркыныч, кансыз, дәһшәтле кешеләр омтыла. Алар, көчлеләр, балтаны Изил Латыйпов кебек кан сөюче кигәвеннәргә, чебен-черкиләргә бирәләр. Власть башлыкларының мөгезенә кунган чебен дә кайчакта арысланга әйләнә, шулай яши. Моңарчы бу көч аннан ничектер еракта кебек тоела иде, хәзер, — үндүртенче гыйнвардан соң — язмыш аның арт сабагын укыта, ул бары тик Наиләсенең сафлыгын биреп кенә үзе өчен иртәгәге көнне яулап ала. Бүтәнчә аңа юл юк. Балта Изил Латыйпов кулында булса, Изил үзе — Нәҗип белмәгән әллә кемнәр кулында.

Нишләмәк кирәк, шулай зур корбан биреп алынган бер кишәрлек җирне буш калдырырга ярамас. Чит-чите йөз атлам да булмаган җир өчен Наилә кешелеген ерткыч Изил алдына ташлады. Ә Идел-Чулман елгалары ярларының меңнәрчә гектар бәрәкәтле җирләре бер файдасызга сасып, корт үрчетеп ята. Бөек ахмаклыклар эшләнгән дәвердә кешенең туган җирен һәм үзен яклап бер сүз әйтергә дә хакы юк!

«Йорт! — диде Наилә. — Йорт салмасак, җирне бездән тартып алачаклар!» Квартирлары, машиналары, шкаф тулы бәллүрләре, калын-калын кисәләре булган күпләрне, буш чыгымнардан коткарып калып, завод белән шәһәр советы тартышында алга чыгарга тиешле кеше булып Нәҗип калды. Йорт өчен Нәҗип үз-үзен сатарга тиеш. Артың белән киртә җимерә алмыйсың. Тик кемгә барып егылырга? Кемгә җанны кыйбатрак сатып булыр? Ул, йокы белән уяулык арасына чумып, үзе белгән бөтен кешеләрне үе аша үткәрә башлады. Ул

белгәннәрдән иң көчлесе Иван Иванович иде. Әгәр абыйсы исеменнән йөрсә, мәр ярдәм итеп тә куяр. Ярдәменең әҗерен Сабит Йосыповичтан таләп итә башлагач, Сабит ни дияр? Иван Иванович — властьның иң куркынычлы вәкилләреннән берсе, каефенә ярамасаң, аңышмастан чәкәләштерсәң, Сабит белән аны юлдан тибеп кенә очырыр. Ярамый. Аңа якынаю куркыныч. Абыйсына да башны биру ярап бетмәс. Аңламас. Гомерлек колы итәр. Фәридун Фазлыевта булса икән көч! Юк шул, ул да Нәҗип шикелле үк көчсез, гаделләргә власть бирелмәгән, власть бүтәннәр кулында. Фәтхулла абзасына барып караргамы? Бу юлы, элек тыңламаганнары өчен, йомшак сөйләп катыга утыртыр. Ул да баш беткеч шарт куяр...

Кемгә сатылырга? Нинди бәягә? Уе шадра Вафага барып җиткәч, тукталды. Вафа әрсез, карак, бур! Бүген аңа нәкъ шундый кеше кирәк.

Тартылган җәя бавы кебек гел киеренкелектә торгангамы, Нәҗип бәйләнчек чир хакында онытыбрак торды, күптән «йөрәк!» дип, дерт итеп уянганы юк иде, бүген төн уртасында, сары йортны җимерергә теләгәндәй арлы-бирле поездлар үткәндә, ул хатынын төрткәләп уятты: «Үләм!» Наиләне караваттан давыл кубардымыни, очып идәнгә төште, ут кабызды. Нәҗип янына килеп баскач, дулкын-дулкын озын чәчен өскә чөйде һәм коры, җансыз тавыш белән сүзгә керешге: «Юк инде, аппагым, үлмисең. Үләргә рөхсәт юк. Җир алып эшкә керешергә дигәндә башыңны җүләргә салып, ат тизәге тибеп йөрергәме?! Үлмисең, үтермим, рөхсәт тә бирмим. Мә, эч даруларыңны!»

Бүлмәгә валокардин исе таралды. Наилә шадра сөлге белән Нәҗипнең тирләгән муенын сөртте, беләзегеннән тотып тамыр тибешен санады, ничә икәнен әйтмәде. Нәҗип кинәт күзен ачып җибәрде һәм хатынының сыгылмалы нәзек билен, тулы, йомыры балтырларын һәм нәфрәт тулган сихерле күзләрен күрмәс өчен борылып ятты...

## 28

Аны Вафа янына тиз генә үткәрмәделәр, биш бармагына биш алтын балдак кигән, мыймылдап торган мут татар апасы, чатнатып, күзен дә йоммыйча: «Вафа Сафич в обкоме!» — дип кабатлады. Хәлбуки, Вафа Сафич беркая да чыгып китмәгән, ул кабинетына кушып салынган аулак бүлмәдә башын юеш сөлге белән урап, үткән кичне онытырга тырышып, ахылдап утыра иде.

Гадәттә мондый хәлдә Вафа эшендә күренми торган иде. Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, кичәге кунаклар арасында мөһим бер трестның бухгалтеры, күрер күзгә ипле, тотышы белән дә бик тыйнак бер ханым бар иде. Ханымның тол икәнлеге ачыклануга, Вафа ул якка карамаска, күз төшермәскә тырышты. Ханымны кыстамады, бокалын чәкештермәде, барыбер хәләле Шәмсия тол хатыннан көнләште. Шәмсия ханым Вафа гап-гади «шадра тәре, көнлекче» чакта көнләшүнең ни икәнен белми торган бәхетле хатын иде, директор хатыны дигән дәрәҗәгә күтәрелгәч, күзе шарайды, шәһәрнең бөтен хатын-кызлары аның директор ире кочагына керергә чират торалар кебек тоела башлады. Кәттә хатыннарның шәп мебель артыннан йөргәлаганнарын ул белергә дә теләмәде. Иртән, Шәмсиясе йокыдан торып, сыртын игәүли, чыра пычагы белән җилкәсен кыра башлаганчы дип Вафа чыгып ычкынды, иртәләрен ярата башлаган кофесын да эчеп тормады. Макмырдан газапланган ирне сүгеп игә китерергә азапланган хатын, андый иртәләрдә ир күзенә аҗдаһа, җиде башлы дию булып күренгәнен беләме икән? Шәмсиясен аҗдаһа итеп күрәсе килми иде шадра Вафаның.

Күз-каш җимерелгән, танау — чөгендер, муен — тимгел-тимгел,

авыздан җен тәме килә, укшыта. Нибуч, аулак бүлмәгә качып, «обкомга барырсың!»

Кичә килсә, Нәҗип мыймылдык хатынның сүзенә ышанып, кара сарык сыман башын иеп, гафу үтенеп чыгып китәр иде: обкомда тек обкомда! Бүген инде «юк!», көтмәсеннәр, ул төшеп калган чакүшкә түгел, ул — җир хуҗасы Нәҗип, шул уч төбе хәтле кечтеки җирдән торып булса да үз хакын дауларга, дөньяда барлыгын расларга дип ният кылып чыккан кеше! Хәзер ул Наилә мыскыллаган, черек эскерт төбенә салып таптаган арыш чумарасы түгел, ул — киек каулап чапкан арыслан, ташбаш балыкларын буа төбендә йотучы чуртан, юлында очраган киртәләрне тибеп-тибеп аударачак баһадир! Шул җир бәрабәренә газиз хатыны Наилә сыткылы танау, камыт аяк Изил Латыйпов белән йоклап кайткан икән, җир шарын үкчәләре белән тибә-тибә «Мебель» кибетенә килеп кергән Нәҗипне бүгеннән тозакка төшерә алмассыз! Ул үткән төннән — замана кешесе, эшкә ашмас хыяллар тоткынлыгыннан ычкынган, әкияти мәгарәдән көнгә чыккан эшкуар! Вафалар төркеменә кушылырга ният кылган икән, бетте, аны юк-бар сүз белән шомарта алмыйсың бүген. Юлда килгәндә бер плитка шоколадны куен кесәсенә тыккан иде, шалт шуны бөрмә авыз, мыймылдык түш кулына! Елмайды, алтынланган йодрык язылды, вак-вак энҗе тешләр арасыннан тел очы күренеп калды. «Вафа Сафич мине үзе чакырды, ул минем яшьлек дустым!» — диде чатнатып Нәҗип. Моңарчы яшьлек дуслары юк иде аның, бүгеннән алары да булачак, беренчесе, әйдә, Вафа Сафич булсын! Кирәкле кеше, директор!

«Алай икән?» — дисә дә, алтын тешле камыр беләк Нәҗипкә сынап, шикләнеп карады. Егетнең үз-үзен тотышында каушау сизелә, әле алган сабаклары җитәрлек түгел, авыллык чыгып бетмәгән иде. Шушы гадилектә меңнәрне күреп, кешене бер карауда танырга гадәтләнгән ханым алданды, Нәҗипкә үзе артыннан барырга кушып: «Рәхим итегез!» — дип елмайды.

Башы ярылырдай булып чатнаган Вафа, затлы чалбарына ак тастымал салып, өстәлдәге кара икрага һәм мәрсин балыгы телемнәренә карар-карамас утыра иде. Бер-ике чәркә коньяк җибәргәндә үтә шәп буласы иде дә, гомергә әртилдә уралып күнеккән Вафаның ялгыз тамагына иң татлы ризык та бармый иде. «О, Нәҗип! Профессор!» Махмырдан тилмергән хуҗа өчен көтмәгәндә килеп кергән, сер сыярлык кунак — хәзинә! Хәзер ямьсез баш төзәтү гадәти кунак сыйлауга әверелә, санламыйча һич ярамый, бердән, Вафа кунакчыл хуҗа, икенчедән, заманында хуҗаны төрмәдән аралап калган кеше килгән! Коньяк — тартмасы белән, ризык мул — сандугач теле генә юк, урын аулак, мыймылдык хатын ышанычлы, Газраил белән Җәбраил парлашып килсә дә, «обкомда, обкомда!» — дип пичәт сугып утырачак. Обкомда кабинетлар йөз, Ариадна йомгагы кулыңда булса, эзләп тап Вафа Сафичны лабиринттан!

Егерменче гасырның җитмеш фәләненче елында замананың йолкышы, бәхетсезе, МВД тәкъдиме белән психик яктан тотрыксызлар исемлегендә теркәлгән Нәҗип Йосыф улы Нургалиев һәм кыюлыгы, тәвәккәллеге, елгырлыгы белән Казан хуҗалары арасында бердәйдан казанган Вафа Сафич очраштылар. Затлы коньяк сыйнфый тигезлекне оныттырды, баш ачылып, чигәләрдәге вак-вак чүкечләр тукылдавы бетүгә, Вафа Нәҗипне кочаклап ук алды: «Брат!» Кичә булса Нәҗип үшән ат кебек башын иеп, тәҗел йомыш белән район начальствосы катына килгән бичара крестьян кебек, ялган чокырын кашып, учына йөткеренеп, картузын учлап-йомарлап кыймыйчарак торыр иде, бүген, шалиш, ул Вафаның бүлтәйгән бүксәсен дә, шадралары тигезләнгән шома битен дә, кысылып эчкә чумган ясмак күзләрен дә күрмәде, салса эчте, мәрсин балыгының калын телемнәрен

майлы иреннәре арасына шудыра торды. Бүген алар тигез. Нәҗип Вафа белән бер сафка басарга ниятләп юлга чыккан егет!.. Һиһаять, карыннар тулды, сулыш алу читенләште, изүләр чишелде, табынга сүз килде.

«Нинди нужа йөртә сине? — дип сорады хуҗа. — Ничек яшисең? Кайда эшлисең? Ни хәлләрең бар?» «Эшләмим. Яшәр җирем юк. Идел буеннан дүрт сутый җир бирәләр. Шунда эт оясы хәтле генә булса да куыш әтмәлләргә иде исәп». «Йорт салырга ниятләгән акыллы баш әүвәл савым сыер сайлап ала». «Сыер белән нишлим мин?»

Вафа шаркылдап көлеп җибәрде: «Сабый бала икәнсең әле һаман? Сыер — мал табарлык эш дигән сүз, имәрлек төшемле эш табасың да савасың гына! Кем үз акчасына ярда йорт сала?.. Хәзерге заманда эшсез йөргәнең өчен ыштаныңны салдырып сыек чыбык белән кыйнарга кирәк! Җүләр! Хәзер бит... акча агып килә торган чак!» «Суктыр, кыйна, чабакла, өй корырлык такта-токтаңны гына бир!»

Вафа ясмык күзләрен йомып беравык уйлап торды да кинәт: «Миңа эшкә киләсеңме!» — дип сорады. «Кем итеп аласың?» «Грузчик итеп алам. Гарьләнмә, холкыңны хәтерлим, эш сорап миңа һәркөн биш-алты кеше килә. Грузчик булып урнашыр өчен хәзерендә җиде-сигез меңне чыгарып салалар!» «Ә директор булып урнашыр өчен күпме сәмән чыгарып салырга кирәк?» «Минем урынга үрләмә. Аңа синең баш җитми. Ә болай... егерме меңнән дә ким түләнми андый урын... Шикләнмә, мине бушлай, югарыдагылар чакыртып алды. Андый хәлләр дә була. Менә мин сине бушка яллыйм лабаса!» «Кайчан да булса бер костырырсың!» — диде кунак айнып. «Костырмам. — Шадра кеткелдәп көлеп җибәрде. — Вакыты җиткәч, эш сорармын. Болай гына куеныма алырга, син минем үгәй малаем түгел! Ике уйлама, кил, урнаш. Яшә, бүтәннәргә дә ирек бир». Нәҗип Вафаның тирләгән беләгенә ике куллап ябышты: «Ни кушсаң да, үтим! Соңгы чиккә килеп җиттем, бетәм. Ярдәмеңне кызганма, якты көндә адәм арасына чыгарга оялам. Хатын янына ир булып ятарга хурланам».

Кадрларны сайлый белә Вафа Сафич: хәзер аның кибетендә йөкче булып ике доцент, рестораннан куылган югары категорияле бер пешекче һәм баш механик янына физик Нәҗип Нургалиев тә килеп кысылды. «Һәй, кайда сез анда доцентлар, повар белән механик кая олаккан? Менә бу чибәр физикка җиһаз сүткәндә калган такталардан бер машина сыртлап төягез дә... әй, бакчаң кайда идең әле? Әллә йоклаган инде?.. Әчкәч йокласа да ярый, бүтән чакта аек һәм хезмәткә әзер булсын!»

Механик белән пешекче сары йортны белмиләр икән, доцентларның булып чыкканнары бар, ахрысы, Нәҗипнең кайда яшәгәнен белгәч, бер-берсенә карашып көлеп куйдылар.

Нәҗип кичкә кадәр караватта аунады, коса-коса җаны чыкты. Вафа Сафич кебек, баш төзәтеп рәхәтләнә алмый. Наилә кайтасы, балаларны бакчадан аласы бар. Грузчик булып ялланганын әйтергәме хатынга, юкмы?..

Наилә көндәгедән соңрак кайтты, балаларга бирәр саплы калач тоттырды, көмеш тәңкәләр бизәгән өр-яңа сумкасыннан йөз кырык ике сум акча чыгарып, бераз кыланып өстәлгә ташлады. «Профсоюздан, ярдәм фондыннан бирделәр». Нәҗипнең башы урталайга ярыла иде, моңарчы бер дә тәтемәгән «фондтан» нигә бүген баллы яңгыр яуганын тикшеренеп тормады. «Яхшы булган», — дип мыгырдады. «Балаларны Аккош күленә пионер лагерена озаталар, безнең малайларны да җәйгә шунда урнаштырырга урын бирәләр. Син ризамы?!»

Наилә, чит бусаганы атлап кергән сәер кунак сыман чишенмичә,

өс-башын алыштырмыйча, тузан баскан идәнгә карап утыра иде. Кинәт урыныннан купты да тәрәзә каршысына килеп тавышсыз гына еларга керешге...

Иртән беренче сүзе шул булды Наиләнең: «Латыйповның сине күрәсе бар, соңарма, кагыл! — диде. — Бакча хакында киңәшәсе бар бугай».

Балаларны Наилә алып китте, Нәҗип аптырашта калды. Вафа белән очрашуның азагы бөтенләй онытылган иде. Ничек дип килешүләрен һич хәтеренә төшерә алмады.

Ахыр чиктә, әүвәл Латыйпов янына кагылырга булды, троллейбуска утырды. Уң кулының урта бармагына эт тырнагы чыккан икән, шул җанга тиеп, тынычсызлап бара иде, тырыша торгач эт тырнагын канатып, тамыры белән йолкып чыгарды. Башы әз-мәз рәтләнгән кебек булса да, җанын һаман нидер тынычсызлады, караса, сул кулының урта бармагына да эт тырнагы чыккан! Тешләп тарта торгач анысы да тамыры белән йолкынып чыкты. Ага гына кан! Тырнак төпләрен баш бармаклары белән кысып тора, җанга һаман тынычлык килми! Аяк киемнәре кыса, аркасы кычыта, тамагы яна. Иелеп караса, ике аягына да сул туфлялар кигән икән!.. Борылып кайтып, туфляларны алмаштырып кияргә кирәк иде, кайтмады Нәҗип. «Йә, эшем уңмас!» — дип шигәйде. Әле болай да, Латыйповның аны бик күрәсе килеп тормыйдыр...

Ул, уйларын учына җыеп, үзенең кая һәм кем янына баруын исенә төшерде. Изил Бәдретдинович Латыйпов янына бара Нәҗип. Ике ир күзгә-күз очрашачаклар. Көндәшләр. Икесе дә Наиләнең упкынга баштүбән ташлануын беләләр. Әгәр хәзер Нәҗип, дуылдап барып кереп, профсоюз эшлеклесен кара яндырып тукмап ташласа?! Бәлки әле соң түгелдер? Наиләне упкын читеннән тартып алып булыр? Нигә аларга шулкадәр югары бәһагә сатып алынган җир? Дачасыз яши алмаслар идеме? Вафа аны дача хуҗасы булган өчен ялламады лабаса?!

Карый Нәҗип: эт тырнагы атсыз бармакларына да чыккан... Ул аяусыз кыланып үткер тешләре белән эт тырнакларын чүпләргә тотынды... Троллейбустан чыкканда Латыйпов исенә төшеп, йодрыгын йомарламакчы була, юк инде, йодрык йомарланмый... Вафа белән килешенүе, яллануы исенә төшкәч, Нәҗипнең гайрәте шиңде. Латыйповны тукмап ташлау уеннан кире кайтты. Әгәр кичә иртән Вафа катына барып егылганчы очраса икән Латыйпов!.. Әле ул чагында, тукмап ташларга йөрәге җитмәсә дә, үзенең моңарчы сыенып яшәгән тыныч тормышыннан торып Латыйповның чыраен бозарлык тозлы-тозлы сүзләр әйтә алган булыр иде. Бүген хәленнән килми, чөнки бүген ул элеккеге Нәҗип Йосыф улы Нургалиев түгел, ул ике доцент, бер пешекче һәм баш механик белән ике тәртә арасына кереп баскан кол. Вафа Сафич дигән шадраның колы. Мыймылдык түшле секретарь колы. Нәҗип аша эш йөртүче югары сыйныф вәкилләре булган бик күпләрнең колы. Бүгеннән ул Наиләсенең дә колы...

Казна йортларына мәңге бетмәскә сеңгән исле коридорга барып кергәч, ул үзенең шушы йорттан ничек-ничек куылуын, мыскыл ителүен уйлап, күңеле суык тешләгән камыр кебек җебеде. Профком ишеген ачуга, өстәл янында иелеп кәгазь караштырып маташкан Латыйпов, кулына беренче килеп кергән көмеш акча сыман ялтырап килеп җитте, иңеннән кочып, аны шомарган кәнәфигә илтеп тә утыртты. Утыруга Нәҗип кычкырып җибәрде, кәнәфинең кадагы чыгып тора икән, йомшак җиренә кадалды...

Изил Латыйпов Нәҗипне камап, элэктереп алды, сүз әйтергә ара калдырмады. «Килдеңме? Шәп! Тиз сал йортыңны, җәһәт кылан! Сезгә илле тугызынчы кишәрлек. Юл якын дип зарланма! Тимер юл белән ике арада иманлек! Иманлек түгел — оҗмах бакчасы! Йөз, мең

ел торачак ул имәннәр! Стена! Крепость! Балаларың, оныкларың аннан рәхәт күрәчәк!.. Идел буенда юк хәзер андый имәнлекләр!.. Поезд тавышы үтеп керү түгел, американнар атом бомбасы шартлатса да, имәннәр сезне саклап калачак. Участок түгел — хәзинә!»

Нәҗип ни дияргә аптырады, канлы, көчсез бармакларын яшерергә тырышып: «Кая барсам да тимер юл сагалады мине! Җык күрдем мин аның тавышыннан!» — дип зарлангандай итте.

Сүзгә йөгерек Изил әңгәмәдә сүзне чуалтырга гаҗәеп оста иде, бу юлы да ул, капылт борылыш ясап, Нәҗипне бөтенләй бүтән тыкрыкка алып керде: «Әгәр дача йортыңны күз ачып йомганчы өлгертеп, төтенеңне чыгарсаң, валлаһи дип әйтәм, директорга керәм, лабораториягә кайтаруларын сорыйм». «Булмас,— диде Нәҗип баш чайкап.— Психушкада учетта торучыны почтовый ящикка алалармы соң? Арттыр, Изил, тик чаманы онытма!»

Латыйпов бу фикерне ишетмәде, Нәҗипнең бер алдына, бер артына төшеп, сикергәләде. «Сүз бар! — диде ул чыраен сытып.— Шуңа чакырттым!» «Әйт», — диде Нәҗип юаш кына. «Без монда уйлаштык... Сине саксызрак кыланып чыгардык, ахрысы...» Нәҗипнең җайсыз тырпылдаган йөрәге кысылып алды. «Җирдә беренче булып йорт сала башлавыгызны баш инженерга җиткердем. Ул, үз чиратында, директорга әйткән. Сезне алда байтак чыгымнар көткәнен искә алып, без Наиләне китапханәдән баш инженерның секретаре итеп күчерергә ниятлибез. Мин, барыннан да элек, синең белән киңәшергә уйладым. Без — дуслар, син — Наиләнең ире, каршы килмәсәң, Наилә иртәгәдән Израил Моисеевичта эшли башлый».

Ниһаять, Изил бертуган апасының ирен — Израил Моисеевичны исеме белән атады. «Хезмәт хакы китапханәгә караганда ике мәртәбә артык. Квартал саен айлык зарплата күләмендә премия. Без монда профсоюз хисабыннан да әзрәк булышырбыз. Йә, сүзең ни?»

Изилнең соравы үтенеч булып түгел, боерык булып яңгырады.

«Наилә ризамы соң?» — диде Нәҗип, иреннәренең калтыравын җиңәргә тырышып. «Риза. Гомере буе китап тузаны йотып утырмас ич?! Эш җиңел булмас, утырышлар, киңәшмәләр булганда соңга калып та кайтыр. Үпкәләштән түгел, мыегыңа чорнап тор». Нәҗип йомшак кәнәфигә тагын да ныграк чумды, баягы кадак әллә бөгелде, әллә читтә калды, күмелде Нәҗип, башы гына күренеп калды. Изил шукланып аның чыгынкы арт чүмеченә чиртте. «Тәмам! Минем ашыгыч эшләрем бар». Нәҗип каударланып сикереп торды, үз теле белән явыз дошманына, көндәшенә рәхмәт укыды. «Ул... профсоюз хисабыннан дигән ярдәмне... озаклатма инде, Изил дус». «Йә, йә, белмимме әллә? — диде Изил, үзенә сузылган юаш кулны ике бармак очы белән кысып.— Вакланмыйк! Без — кешеләр!»

Ишеккә кадәр озатып, ул дымлы учын Нәҗипнең түбәнгә салынган иңбашларына куйды да әллә шат, әллә явыз тавыш белән соңгы хәбәрен җиткерде: «Ә! Ни... Әйтергә онытып торам икән! Казна эше артыннан чабып ми тубал булган! Ни иде... Наиләңне квартир чиратына беркеттек. Шактый сүзләшергә, тирләргә туры килде. Әмма ләкин мин сезне ел ярымда, һич югында ике елда фатирлы итәм!»

Нәҗип телсез калды...

## 29

Үзгәрешләр икесенә берьюлы килде: Нәҗип алак-шалакланды. Элек аяк киеме чисталыгына аерым игътибар биргән кеше хәзер үкчәләре ашалып ямьшәйгән, баулары өзелеп-төенләнеп беткән, кара лайга манчылып каткан туфляларын кия дә рәхәтләнеп йөри. Таң туса, бите алланганчы кырына торган ир, хәзер йоны иләнгән щетка

сыман иягеп кашый-кашый ашый, җиту сакалына ябышкан бәрәңге кисәкләрен сөртергә онытып, фуражкасын алдын артка киеп чыгып китә. Кием-салым, өс-баш иясенең кәефенә тиз яраша, иясенең кемлеген әллә каян кычкырып килә. Биек буй, өстә әллә кайчаннан искеләр арасында аунаган аксыл плащ, тезе сидерәгән лавсан чалбар, урамда очраган сукбайлар, алкашлар, йолкышлар, болай гына исерекләр, ямьсез ис аңкыткан хатын-кызлар, бүтәннәрдән аерып, аңа күз кысалар, сүз каталар, үз итеп санауларын белдерәләр иде. «Син юньлерәк киенеп йөри аласыңмы-юкмы?» — диде беркөн Вафа йөзен чытып. «Миңа ярый!» — дип куйды Нәҗип исе китмичә генә.

Наиләгә тәмле тел кайтты. Малайларын җырлый-җырлый сөя, бии-бии ашата, иренә «Нәҗибем» дип кенә дәшә, үзенә «Наиләм!» дип мөрәҗәгать итүне сорый. Көне буе саллы-саллы тартмалар күтәреп астан өскә, дүртенче, бишенче катларга чабып йөреп кайткач, тез буыннары йомшый, иң өсләре чиләнә, култык аслары тирдән әчи. Мондый чакта «Наиләм» дип юхаланасы килми Нәҗипнең, дөнья аклыгы күзгә күренми, усалланып малайларны да читкә тибәрә. Ә Наилә! Кайткан саен сумкасында малайларга күчтәнәч була, Искәндәр белән Рөстәм хәзер шоколадны бүселгәнче ашыйлар, кәнфиттән тамак төпләре сызлый, прәннекләрне идәндә алка итеп тибеп йөртәләр.

Бер юанычы бар Нәҗипнең, Наилә эшендә озак юана, әле утырыш була, әле җыелыш, әле җыелыш беркетмәләрен яңадан күз йөртеп төзәтеп чыкканнар. «Кырыкмаса кырык эшем көтеп тора, миннән башка нишләрләр икән алар, бичаралар, Израил Моисеевич мине гел мактый, «син минем уң кулым!» — дип атый» — хатынының бу сүзләренә ул ияләнеп тә килә... Хәтта эштән кайткан мәлләрдә Наиләнең өйдә булмавын, эшендә озаккарак тоткарлануын тели, кайта, ашый «якаң ник керләнгән?», «нигә кырынмадың тагын?», «ник мунчага бармыйсың?» дип быткычланучы юк. Иң авыры: авыр сүзләрне дә Наилә тәмле теле белән, көлеп-елмаеп, ире тирәсендә күбәләк булып очып тәкрарлый, шул сәбәпле сүзләрнең тәэсире тагын да авырлаша, Нәҗипне рәнҗетә иде.

Алар байтактан бер караватта йокламыйлар. Нәҗип кайта да, аннан-моннан чишенеп ташлап, идәнгә тәгәри, Наилә озаклап көзге каршысында бөтерелә, тәненең төрле җирләренә ислемайлар, кремнар, лосьоннар сөртә. Беркөн, балалар тирән йокыга талгач, поезд тавышлары тынгач: «Нәҗип, иснәп карачы, миннән җофар исе килә!» — дип дәшкән иде, Нәҗибе ухылдап борылып кына ятты.

Җофар исен белми иде Нәҗип, белергә дә теләми иде. Наилә Гөлнаралар белән бергә көнен саунада үткәреп, аның тәне дә массаж, бал кебек нәрсәләрне татыган иде...

«Ир — баш, хатын — муен», — дигәннәр. Тату чакта бу гадел хөкем эшкә ярап тора, гаиләнең асылына шайтан хуҗа булып алганда, «ир — баш» кәбестә күчәненә әйләнә. Дошман ирдән дошман хатын утын түмрәне ясый. Үзгәрешен, аның сәбәпләрен яшереп тормады Наилә, яшерүне кирәк дип тә санамады, өйләнеп хатынына лаек тормыш кора алмагансың икән — үзеңә үпкәлә, аппагым!

Соңыннан, байтак вакыт үтеп, көннәр-айларның гына түгел, гомернең дә кадере калмаганда, Нәҗип идән мунчаласына, Наиләнең карышусыз колына әйләнгәч, уллары «әти!» дип түгел, «әй!» дип кенә кычкыра башлаганда, «Әллә бу зинданнан ләхеткә күчергәме?!» — дип әйле-шәйле йөргән бер мәлдә ул адашып кына Фәридун Фазлыев янына барып чыкты. Хуҗа өйдә бер ялгызы иде. Көн шактый җылы булса да, җилкәсенә иске буй-буй халатын салып ачык тәрәзә каршысына басып нидер уйлана иде. Ишек бикләнмәгән иде. Нәҗип тә звонок шылтыратып тормады, барды да керде. Аягын салганда туфляларының җимерек борынын абайлап, күз күрмәс тәшкәрәк

әчкә яшерде. Сүзсез генә кул бирештеләр. Сүзсез генә диванга барып утырдылар. Озак кына берни сөйләшмәделәр. Фәридун Фазлыев: «Апаңны больницага салып кайттым менә... Йөрәге менә сүнәм, дип көчкә-көчкә тырпылдый. Йөрәкнең чын сызлануы әнә шулай була ул, Нәҗип туган!.. Мине төрмәгә илтеп тыкканда апаң уникенче больницада хирургия бүлегендә шәфкать туташы булып эшли иде. Яраталар иде аны!.. Мин төрмәдә, җитмәсә шул көннәрдә баш врач итеп бер исерекбашны китереп утырткан нар. Операцияләре ташкүлчим, туный бу тере җаннарны... Берсендә, операциядән соң, авыруның эчендә нәни генә кайчы калдырып тегә. Эчеп килгән икән юньсез!.. Гаепне апаңа сылтыйлар, берчакта да шифаханәләргә кермәслек закон белән эшеннән куалар. Апаң тасма туку фабрикасына барып яллана. Үткән-сүткәндә игътибар иткәнең бармы, Кремль астында гына ул фабрика! Тавыш, тузан, хәрәкәт. Кышын суык, җәен эссе. Мин кайтканчы шунда эшләгән Фәридәм. Шуннан йөрәк авырулы хаста булып чыкты, гомере буе мантымады».

Фәридун Фазлыев иң тирән кайгыларын уртаклашып, әз-мәз теләктәшлек, юаныч эзләп сөйләп торса да, аның сөйләгәннәрен Нәҗип колагына да элмәде, ишеттеме, ишетмәдеме — билгесез, аның ми тартмасы авыр уйлар белән болай да шыплап тутырылган иде. «Әле янымда Наиләнең җылы кулы бар дип яшәгәндә бирешми идем. Тәне янымда калса да, җаны еракка очып китте хатынымның. Шул екты мине. Шул харап итте. Яшәү тәмен югалттым. Каты авырганда, «авыздан тәм китте», диләр бит, шуның кебек менә... Җаным зарыгып уңга-сулга каранам — юк Наиләм! Бергә торабыз анысы, балаларны карый, ярата да кебек. Ләкин аның тормышында мин әллә кайчаннан юк, күрми мине. Шуны сизеп яшим. Чит күләгә белән гомер кичерәм. Нишләргә? Ни кылырга?»

Фәридун Фазлыев, үз кайгысына баткан булса да, Нәҗипнең һәр сүзен ишетте, сүзләрен уйга әйләндереп күңеленә тезә барды. Түзем тыңлады, иң актыктан, егетнең шик-шөбһәләрен ачыклагач, йомгак ясап куйды. «Син, егет, күрәм, дөньяга баш бирдең. Авырлыкларны җиңәргә омтылмадың, алардан качарга тырыштың. «Мин алай, мин болай!» — дип адәм баласы күпме гайрәтләнмәсен, бу дөньяда ул ком бөртеге генә! Сахра җилләре ком бөртеген ары-бире куып йөрткән кебек, хәзерге заман кешесен власть ихтыяры, законнар чүп урынына очырта, тоталитар илләрдә, ягъни бездә, беркем дә үз язмышына тулаем хуҗа була алмый! Ил башына берәү менеп утыра да, без шуның кәефен саклап яши башлыйбыз! Россия берчакта да демократияне татыган ил түгел. Коллар иле ул! Рус философларыннан берәү — Николай Бердяев исемле акыл иясе болай дигән: «Ирекле булу авыр, җиңел булганы өчен адәмнәр кол булырга телиләр дә!» Язмышында коллыкны сайлагансың икән, үпкәләмә хәзер! Чакырдым мин сине, мәктәпкә урнаш, укыт, дидем. Эш табарга булыша идем. Ә син...»

Фәридун Фазлыев аңа акыл бирмәде, «аны эшлә, болай ит!» дип өйрәтмәде, мәгәр аның яныннан Нәҗип тынычланып, сабырланып кайтты. Ул теше-тырнагы белән эшкә ябышты. Ал-ялны онытты егет, көн сәгатьләре җитми башлады, төннәрен урлап-юллап бакча җиренә такта, бүрәнә, кадак ташыды. Вафа Сафичның боерыгын үтәп, аңа буйсынып, төрле шикле йомышлар үтәде. Үзенең ни эшләгәнен белеп бетермәде, иң гаҗәбе — белергә теләмәде; ачыкларга омтылмады, йокларга ятып, арган керфекләре керфеккә ялганганда, элеккедәй татлы күк капусы ачылмады, кайгы хәбәрләрен тыңлаганда йөрәгә какмады, тәне ныгыды, тупасланды, элек дөньяга сөенеп тартылган күзләрен сыек томан каплады.

Әгәр күзен ачыбрак, зиһенен туплап караса, ул үзе яшәгән бәләкәй дөньяда да әллә нилэр туып алмашынуын, үзе катнашкан вак-

вак эшләрнең дә баш китәрлек олы вакыйгаларга барып тоташуын аңлар иде. Сахра киң, офыклар ерак, ерак, ә Нәҗип Йосыф улы Нургалиев һаман ком бөртеге иде.

Ул тырышып-тырмашып, җан тирләрен чыгарып дача салып яткан тын уйсулык асылда шәһәрдәге бик күп көчләрнең, бик күп югары дәрәҗәле кешеләрнең тартыш ноктасы иде! Тимер юл белән Идел арасында җәйрәп яткан, моңарчы кеше күзеннән читтәрәк булган уйсулыкка, уйсулыктан ерак түгел аулак йортка, кешесез болыннарда көрәйгән ала казларга мәхәббәте төшкән Иван Иванович хакында без бәйнә-бәйнә сөйләп үткән идек инде, шәт иншалла, онытмагансыздыр? Әлегә бу җиргә профсоюз күркәсе Изил Латыйповның, баш инженер зирәк Израил Моисеевичның, бигрәк тә генераль директор Валериан Козецкийның бернинди мөнәсәбәте юк тыныч заманнар иде. Буш җирләрнең ял итәр өчен бик кулай булу ихтималы, ул тирәдәге коры, нарат исле һаваның сәламәтлек өчен уңайлыгы Израил Моисеевичның үтә сак колагына килеп ирешкәннән соң, ул бу җирне кулдан ычкындырмаска, ашыгыч эш йөртеп, уйсулыкны берләшмәгә беркетергә ниятләде. Бу эшне ул кайнише Изил Латыйповка тапшырды. Козецкий белән киңәшмичә, аннан хәер-фатыйха алмыйча эшкә керешергә ярамый иде, әлбәттә. Баш инженеры белән һәйбәт яшәгән, киңәшле эш йөрткән Валериан Леопольдович тәкъдимне бик теләп кабул итте, ул да яңалыкларга үтә сизгер җитәкче иде. «Кирәк булу ихтималы бар, халык, оешмалар дача җире алырга ябырылды, миңа атап ике участок тәгаенләп куегыз, алда күз күрер...».— дип, тиешле үтенеч кәгазьләренә имзасын салды. Шәһәр советының, тимер юлчылар һәм Зеленодольск райбашкармасы аша шушы җирне алырга йөрүләрен генераль директор ул чакта белми иде әле. Елгыр Израил Моисеевич, алда тартыш чыгасын искәреп, эшне тиз йөртергә боерды, һәм моңарчы җизнәсенең һәр сүзен тормышка ашырып гадәтләнгән тугры бурзай Изил Латыйпов, күрганегезчә, эшне башлап та җибәрде. Нинди зур оешмалар, нинди кәттә кешеләр арасындагы көрәшкә тарыганын гамьсез, ваемсыз Нәҗип белми дә калды. Ул ярма ташлары арасына адашып килеп кергән бодай бөртеге иде...

Иван Ивановичның берләшмә директоры Валериан Леопольдовичка моңарчы да сырт йоны тырпайганы бар иде. Һич көтмәгәндә, уйламаганда арттан килеп пычак кадады Козецкий! Шәһәр активы Казан хуҗалыгының торышын тикшергәндә Валериан Леопольдович сүз алып, шәһәр транспортын, шуңа ялгап шәһәр башлыкларын тетеп ташлады. РСФСР коммуналь хуҗалык министрлыгыннан вәкилләр бар иде. Алар «Казан шәһәренең үрнәк чисталыгы өчен» Күчмә кызыл байрак тапшырырга килгәннәр иде. Байрак алган хуҗалар исеменә яңгыраган тәнкыйть сүзләрен күз алдына китереп карагыз! ЧП, гадәттән тыш хәл иде бу!!

Бу «сыйнфый каршылык», бу талаш искиткеч нәни бер вакыйгадан башланды. Аңлашылсын өчен безгә бераз үткән көннәргә кайтырга туры килер...

Дүрт-биш ел элек, әллә алты ук үтте микән, алар бер язда Матюшино ягындагы хөкүмәт дачаларына күршеләр булып урнаштылар. Иван Иванович балаларын иртә тараткан, аулак һәм тынлык ярата торган җан, атна эчендә күршеләрен дошман күрә башлады. Чөнки Валериан Козецкий, поляклар токымыннан булып, бала-чаганы үлеп ярата торган кешеләрнең берсе иде. Җәйнең иң матур көннәрендә улы-килене, ике балаларын ияртеп дачага чыгалар да, җәй буе өлкәннәр белән мәж киләләр. Алты җан, арадан икесе шук малай, иртәдән-кичкә кадәр бакча гөжләп тора, турникта атыналар, шаулап балыкка баралар, гөрләп кайтып керәләр. Кая ул тынлык! Сандугач тавышын ишетә алганы юк Иван Ивановичның! Хатынының көн-төн «убырлардан» сукранганын тыңлап яшәргә генә кала!

Житмәсә, ул җәйдә Козецкийларга Ригадан өч балаларын ияртеп кунаклар кайтып төште. Ярамаганмы Балтыйк култыгында бу өч хулиганны асрарга, юк, алып кайтканнар җәфаларны, бакыр бугазлары белән таңнан тотыналар шауларга, җәһәннәмнең җиденче катына төшеп олагырсың...

Чуер таш атып Иван Иванович дачасының тәрәзәсен ваттылар — түзде; койма тактасын куптардылар — чыдады; капкага элгән йозакны алып китеп югалттылар — гауга чыгармады. Ә беркөнне түземе калмады, шартлады Иван Иванович!..

Аның иң яратканы — әнис алмасы. Ал әнис. Исен, төсен, ярата әнисне Иван Иванович, тәме дигәндә бөтенләй үлеп китә. Бакчада аңа иң затлы, иң кадерле, иң татлы сый — алланып, балланып пешкән әнис алмалары. Ул язда кыш суык килде, инде яз җылында дигәндә, алмагачлар ал чәчәкләргә күмелгәндә, кичтән суытып, төнлә кар яуды да алма чәчәкләрен суык алды. Иван Ивановичның кадерлесе булган әнис алмагачында нибарысы егерме җиде яшел төймә ералды. Бер ботагы сау калган алмагачның. Әлеге ботагы Иван Ивановичның коймасы аша сузылып, күрше Козецкийлар ихатасында асылынып тора.

Ризыкка язмаган икән быелгы алмалар, күңелне җирсетеп, авызга су китереп аллана башлаганда гына Козецкий йортындагы балачагалар җыйнаулашып килгәннәр дә әнисләрнең сыңарын да калдырмыйча ашап бетергәннәр. Ботак очын сындырганнар әле житмәсә!.. Җиде яфрак чыгарган япь-яшь ботакны аямаганнар! Әй тузынды Иван Иванович! Әй җилкенде! Әйтмәгән сүз калмады! «Наданнар сез! — дип атады ул Козецкийларны, — ач бүреләр!» — дип тамга салды... Кунаклары алдында читенсенгән Валериан Леопольдович дәшмәде, түзде, күршесенең җикеренүләрен күңеленең кара сандыгына салып куйды. Мәңге онытмаска... һәм моннан ары, җае чыксачыкмаса да, Иван Ивановичны тешләп уза торган булды. Казан урамнары пычрак икән, кадалып китсен, бер гаме юк Козецкийның шәһре Казанда... Әмма урам пычракларын ул җаваплы сессиядә мәрнең чыраена атты!.. Алар дус-ишләре арасында, кулуарларда берсе хакында икенчесе әче мәзәкләр, тозсыз гайбәтләр тараттылар. Инде менә маңгайга-маңгай бәрелешәләр, дача җирләре даулап, икесе ике яктан комарланып мәшһүр уйсулыкка килеп кергәч, берсенең дә баш бирәсе, юл сабасы килмәде. Канга кан! Ике арада астыртын, әмма кискен тартыш башланды.

Дөнья тәгәрмәче Козецкийлар, Иван Ивановичлар хакын хаклап туктаусыз әйләнә, көн вә төн туктамый, кара язмыш шушы туктамас иләмсез тәгәрмәчкә ике яктан Нәҗип белән Наиләне дә беркетеп куйды. Иван Иванович: «Халык, шәһәр мәнфәгате өчен!» — дигән утлы өндәмәләр чәчеп, җирне берләшмәдән тартып алырга омтылды. Валериан Леопольдович: «Эшче сыйныф безнең илдә иң өстен сыйныф!» — дип, авызыннан социалистик очкыннар таратып, даны көннән-көн артучы җирне үзендә калдырырга теләде. Кыскасы, шәһәребезнең абруйлы башлыклары бер кишәрлек җир өчен бер-берсен бугазлап ыргытырга әзер иделәр. Үтерергә ярамаганны белгәнгә, көрәштә заман һәм закон рөхсәт иткән алымнарны гына кулландылар. Һәр ике як төп корал итеп «эшчеләр сыйныфын, халык мәнфәгатен» сайлады.

Сүз арасында, Иван Иванович белән Басыйр Бариевичны аерата ярсыткан аерым фактларга күз ташларга да вакыт җиткәндер, мөгаен!

Тын уйсулыкка шәһәрдән дачниклар явы төшкәннең икенче җәендә Әнисә абыстайның уңган казлары ике ояга ундүрт бәбкә чыгардылар. Бүрекле бер ата, ике әнкә каз, ундүрт бәбкә. Саны ягыннан күп түгел түгелен. Мәгәр шуларны йөртергә дә урын калмады бу якта! Урам чирәменә куар идең, Әнисә абыстайлардан ерак түгел ике

малай буй җиткереп, ундүртләре тулган көндә эткәләре тегеләрнең икесенә ике мотоцикл бүләк итте. Май башыннан июнь аена кадәр ике ташбаш, ике матай өч кәҗә бәрәнен таптадылар, ике песине үтерделәр, алар изгән бәбкә, чебешләрнең санына чыгарлык булмады.

Бәбкәләр саны сигезгә калды, арадан берсе — иң исәйгәне, аксады. Алпан-тилпән йөрде дә югалды. Энисә абыстай баш хастасы белән өч көн тилмерде, казларын барларга күзе җитмәде, алар тимер юл аша үтеп, урман авызына җим эзләп барып кергәннәр. Бер төн кайтмады абыстайның казлары, иртәгәсен өч бәбкәнең өем-өем мамыкларын яшен суккан имән астыннан табып алдылар. Әллә эт буган, әллә төлке ботарлаган, әллә усалларның усалы — ике аяклы ерткыч — кеше кул салган. Бәбкәләрнең азаккысын көзгә кергәч, бакчачылар урлап суйды. Күрүен күрмәде Энисә абыстай, авылдашлары беравыздан дачниклары каргап, бөтен бәла-казаларны шуларга сыларга күнектеләр. Ул да: «Шулар гына харап итте казларымны, шулар гына!» — дип сөйләнеп йөрде, җае килгәндә хәбәрне улы — хөрмәтле Басыйр Бариевичка да җиткерде. Җир өчен талаш кызып килә иде, казларының һәлакәте Иван Ивановичка да барып ирешге! «Җирдән куарга!» — дип боерды ул Басыйр Бариевичка шелтә белән карап. «Ни кылыйк соң?» — дип аның күзенә бакты Басыйр Бариевич, ялгыш утка төшкән яфрак кебек куырылып.

Дачниклар вак шакмакларга бүлгәләнгән җирне түтәлләр, сукмаклар, парниклар белән каплап, ашык-пошык алмагач, чия, кара миләшләр утыртып; карлыган, кура җиләге тамырлары төртеп, җирне үз исемнәренә ныгытканда, Иван Иванович белән Басыйр Бариевич, иң алдынгы илдә яшәүче совет халкының ихтыяҗларын күздә тотып, гаделлек байрагы астында көрәшкә ташландылар.

Иван Ивановичта куәт бар, сүзе үтә — уйсулык кергән җирләрне, тирә-яктагы урман-кырлар белән берләштереп, Зеленодольск районынан аерып, шәһәрнең Киров районына куштылар да куйдылар. Указ чыкты, гел уңайга кул күтәрергә өйрәтелгән ташкурчак депутатлар карарга закон көче иңдерделәр, хәзер Энисә абыстай яшәгән авыл, абыстайның җир биләмәләре, мәгърур имәнлек, аулак култыклар белән бергә, хөрмәтле һәм гайрәтле Иван Иванович карамагына күчтеләр. Форсат бар, законнар гадел, җай чыкты, күрсеннәр казанлылар рәиснең шәһәр хезмәт иягәре өчен янып-көйгәнен! Халыкка кирәк икән — Иван Ивановичның җаны фида! Шәһәр советы сессиясе, чираттагы эшлекле утырышларының берсендә, Энисә абыстай налог түләмичә генә биләгән җирләрдә ял базасы, юллар, кемпинглар, көймә причаллары кору турында тантаналы карар кабул итте һәм бу чаралар шәһәрнең генераль үсеш планына да кертелде. Бетте Валериан Леопольдович Козецкий! Совет власте хөрмәтле Иван Ивановичлар кулында чакта борыныңны бик чөя алмассың! Инде салына башлаган дача йортларын сүтәргә (арада иң беренче нәүбәттә төзелеп бетеп килгән Нәҗип Нургалиевнең йорты тар-мар килергә тиеш), агачларны йолкып ыргытырга, түтәлләрне эз калмаслык итеп сөрергә дигән боерык язылды, бульдозерчы нәрәтен куен кесәсенә тыгып, машинасын кабыза ук башлады. Нәкъ шул иртәдә Мәскәүдән кунакка оборона министры килеп төште. Берләшмәнең хәрби аэродромында аны иярченнәре белән бергә Козецкий каршылады. О-о, Казан татарлары Мәскәү әһелләре дигәндә җитезләнәләр! Министрны Лаеш ягындагы аулак урманга кабан дуңгызы атарга алып бардылар. Ау гаять уңышлы булды, министр җәнаплары өч кабан дуңгызын, шул җөмләдән, азау теше кер бәләге булып як-якка сузылган ата чучканы мәтәлдерде. Китте тантана, китте бәйрәм, дуңгыз каны белән куллырын юып, аяк асты майларын дерелдәтә-дерелдәтә, учак тирәсендә «Эпипә»гә биеделәр. Учак тирәсендә бердәмлек, интернационализм

рухы өстенлек итте. Хуш ис аңкыткан калҗалар шау күмердә куырылганда телләр тик торамы? Сүз арасында Козецкий үзенең кайгыртучан хуҗа булуын, завод эшчеләре өчен көне-төне тир түгеп яшәвен искәртте дә сүз дача җирләре, ял итүгә барып тоташты. Министр җәнапларына хуҗаларны мактарга җай чыкты, ул бу башлангычны кайнар котлады, һәм хуплау сүзләрен шул төндә үк Иван Ивановичка җиткерделәр. Шәһәр башлыгы мәҗлеснең уртасында булырга тиеш иде, Козецкий үчегеп аны чакырмады. Ачудан Иван Ивановичның теше сызлап ята иде, Мәскәү кунагының бакча җире белән кызыксынуын белгәч, аның тәмам һушы китте. Ул... юк, теш врачына түгел, сердәше, көрәштәше, ышанычлы көрәштәше хөрмәтле Басыйр Бариевичка шалтыратты. «Тиз үк минем янга килеп җит!»

Нишләсен Басыйр Бариевич, хәләле җылыткан ятактан торып, Иван Ивановичны эчтән сүгә-сүгә киенеп, кабаланып, төче елмаеп, мәр янына барып җитте. «Вәт син әй! — диде ул, Иван Ивановичның шеш кунып ямьсезләнгән төксе чыраена карамаска тырышып. — Шәһәр башлыгы үз кул астындагы җиргә хуҗа була алмасын инде! Нинди заманага килеп җиттек. Өтек кенә директор кисәге бөтен дөньяны учында тотсын инде». Иван Иванович аны туктатты: «Зар кирәкми миңа, анысы үземдә дә җитәрлек! Акыл бир миңа, фикер әйт! Юл күрсәт!»

Ахирәтләр, кара таңгача киңәшсәләр дә, җайлы карарга килә алмадылар. «Арага министр кадәр министр килеп кысылгач, монда ис чыгарып, төтен таратып кына хәл итә алмассың!»

Басыйр Бариевичның карлыгач оясы хәтле ачылган авызыннан министр дигән сүз чыгуга, Иван Ивановичның уйлардан авырайган зиһене яктырып китте. «Министр?.. Ә Шидловский Илья Ефимович?! Синең министрың юкмы? Хәзер ике министрны чәкештерергә кала!.. Ничек элегрәк уйламаган без моны!.. Сине үзәк матбугатта нәрсә дип теттеләр? «Вагоннар станцада озак тоткарлана... Юллар житешми... Чаралар күрелми... Тимер юлчылар акрын кыймылдый», — дип пешерделәрме?» Әле берни дә аңламаган Басыйр Бариевич Иван Ивановичка акаеп карап катты. «Шидловскийны сыйладыкмы? Сыйладык. Дуслаштыкмы? Дуслаштык! Мине өч тапкыр, сине ике мәртәбә үптеме саубуллашканда? Үпте!» «Мине дә өч мәртәбә үпте! Мине дә!!» — диде Басыйр Бариевич еламсырап. Министрның килүе исенә төшкән саен, аның күңеле тула, йомшара иде. «Министр янына барасың. Акча табасың. Бишьеллык планнарны үтәү максатыннан чыгып, тимер юлларны киңәйтәсең. Һәм синең яңа юлларың нәкъ уйсулык аша үтә. Безгә булмаган икән, аларга да эләкмәсен! Бүген үк Мәскәүгә! Хәзер үк!.. Госпланны кузгатасың, проектны ашыктырасың... Үзең белән берәр дистә норка бүрек ал. Бикле капкаларны ач!»

Теш сызлаганда Иван Иванович чак кына җылы биреп затлы коньяк йоткалый иде, хәзер сызлауны да, кулындагы коньякны да онытты, өстәл янына сикергәләп барып җитеп, каләм-кәгазь алып, төзү, җимерү планнарын сызгалый башлады. Шәһәр башлыгының фикерен башта куанып эләп алган Басыйр Бариевич акылына да бер уй төште: «Ә имәнлек?!»— дип кычкырып җибәрде ул әрнеп. — «Юлларны ишәйтәм дисәң, имәнлекне кисәргә туры килә?!» — дип күк күкрәтте Иван Иванович. — Шушы бәрелештә җиңелеп калсам, Козецкий нинди гайбәтләр таратмас! Имәнлек түгел, арты күкне кыеп төшерергә кирәк дисәләр, мин анысына да кул куям! Чәнчелсен имәнлек! Әнә америка өрәңгесе утыртырбыз. Биш елда дөньяңны баса!»

Иван Ивановичка кушылып, аның дәртен купайтып: «Шулай итәбез! Җиңәбез дошманны! Козецкийны кәҗәгә атландырабыз!» — дип Басыйр Бариевич нәгърә орса да, иртәгәсен, Шидловскийның холыксызлыгын, арты белән киртә җимерергә яратуын белгәнгә, Мәс-

кәүгә барырга аягы тартмады. Ул заявкалар, үтенечләр, планнар белән беренче урынбасарын җибәрергә ниятләп, үзе «әллә нигә сырхаулап торам», дип, Иван Ивановичны шомартырга маташканда, шәһәр башлыгы мәсьәләне кабыргасы белән куйды: «Үзең барасың! Үзең җаен табасың! Җиңгән кешенең чире тиз үтә!» — диде.

«Ел уртасында миллионнарны каян тапсыннар!» — дип дөньяны, дөньяның гаугасына сәбәп булган нәни генә кисәкчәсен, шул уйсулыкка мөгезсез сыер кебек барып кергән берләшмә әрсезләрен каргыйкаргый эссе көннәрдә Мәскәү кабинетларын таптап ялынып йөрергә туры киләсен күз алдына китереп, Басыйр Бариевич министрлыкка сәфәр чыкты. Йокы вагонында бер купеда Валериан Леопольдович белән янәшә туры килделәр. Юл буе сөйләшмәделәр, төшкәч, берберсенә күтәрелеп карамыйча, эшләпә читләрен калкытып алдылар...

Һәрберсе алты йөз тәңкәлек норка бүрекләр маяк булдымы, юлда ашаган-эчкәнен Мәскәүгә кайту белән оныта торган Шидловскийның кәефе әйбәт чак туры килдеме, Мәскәү Басыйр Бариевичны елмаеп диярлек каршылады. Әллә министрны озата барганда янып көлгә әйләнгән салон-вагон файдага чыктымы? Илья Ефимович татарларның юмарт кунакчыллыгын, чатакларны гаепкә алмауларын, хатынын бик сөендергән норка тунны да онытмаган иде, песи булып килеп кергән кунакны кочаклап алды. Басыйр Бариевич кыюланып, кергән шәпкә планнарын сөйләп бирде, тотлыкмады, бүленмәде, кәгазьләрен өстәлгә чыгарып салды. Тын гына тыңлаган министр, кәгазьләрне күргәч, чыраен сытты. «Кирәкми... Принципта мин каршы түгел... Бүлекләрдә йөреп чык, минем фикерне җиткер... Казан тимер юлчыларына, әлбәттә, ярдәм кирәк! Акча табарбыз!» — дип сүзне кыскартты.

Бер кешенең фикер ризалыгы меңнәрнең тормышына тәэсир итмә кертә, норка бүрекләрен кыңгыр салган мәскәүлеләр исәпләп-хисаплап, кысыр бюджетны ипләп-сипләп акча юнәткәндә казанлылар бил буып тантана итәргә әзерләнделәр. Казанның иң зур, иң абруйлы Козецкий берләшмәсе яулаган җирләрне тартып алу хәзер чүп кебек кенә булып күренде!..

## 30

Вафа Сафич Нәҗипне яратты. Шундый күндәм ишәкләрне яратыр дәрәҗәгә ирешкән иде ул. Карышусыз иде Нәҗип Йосыф улы Нургалиев, ни кушсаң — шуны эшли, кая җибәрсәң — шунда бара, сорашмый, төпченми, кызыксынмый. Телен озайтмый, яман сүз таралса, аңа катышмый, акчага хирысланмый, чыгарган өлешкә һәрвакыт канәгать, аз бирсәң дә, күп тамызсаң да, рәхмәт әйтеп ала.

Әгәр берәр кеше Югары Авылда соңгы көннәрен үткәреп ятучы Йосыф карт белән аның Казанда гомер итүче улын якыннан белсә, алар арасында бик күп охшашлыклар, уртаклыклар табар иде. Аерма шунда иде: Йосыф карт шушы хәлгә килеп җитсен өчен Сталин тәртипләре, колхоз шартлары кырык-кырык биш ел тырышсалар, Нәҗипне бөгеп салырга шактый кыска вакыт та җитте.

Мыймылдык ханым директор Вафа Сафич юк чакларда күзен уйнатып Нәҗип тирәсендә уралгалады, ара-тирә: «Син бит дипломлы егет, укыган, буең-сының бар, кыяфәтең килгән, тырышып кара, аудар шул шадра пәрине! Үзең директор булып кал!» — дип пышылдады. Кызыкмады Нәҗип, мыймылдык ханым белән кыҗыр-быҗырга кермәде, моңсу күзле авылдашы Гөлгенәне дә, «хат язармын!» дигән вәгъдәсен дә онытты, басынкы гына яшәде. Уй-фикерләре кыска, хыяллары бер көнлек иде аның. Наилә аны эш, мәшәкать белән күмеп ташлады. Дача йортын өлгертеп кергәннәр иде. Наилә: «Мун-

ча!» — диде. Чолан кирәк булды аңа, кухняның да йорттан читтәрәк булуын теләде. «Ит кызган истән башыма ут каба, май исе затлы киемгә сеңә», — диде ул.

Һәммәсен табарга, юнәтергә, җайларга, майларга, бөтенләй күз күрмәгән бәндәләр белән кул сугышырга, арка кага-кага аракы чөмерергә, вәгъдәләр бирешергә, алдашырга, күз буярга, ялган гуаһлык итәргә туры килә иде. Акча кирәк, акча!

Бер вакыйга Вафа Сафич белән алар арасын тагын да якынайтты.

Көннәрнең берсендә ерак Африкадан — Мисырдан Казанның үзәк сәүдә базасына өч комплект җиһаз кайтып төште. Җиһаз тутырылган тартмаларны директорның да ачып карарга йөрәге җитмәде, һәр комплекты ундүртәр мең сум тора иде! Икесе кая китеп, кемнәрнең лаеклы түрен бизәгәндер — анысын шәһре Казанда беркем дә белмәде, мәгәр комплектның берсе Вафа Сафичка эләкте. Ул үз чиратында: «Сораганыгыз кайтты!» — дип хөрмәтле Иван Ивановичны сөендерде. Кибет директоры итеп эшкә урнашканнан бирле, ул, үзен бурычлы санап, Иван Иванович каршысында кыенсынып йөри иде.

Эшнең четерекле бер ягын хәл итәсе калды. Эш шунда иде ки, җиһаз гарнитуры төп-төгәл ундүрт мең сум тора иде. Үзен хөрмәт иткән шәһәр хуҗасы шул бәһагә җиһаз аламы? Үзен кешегә санаган кибет директоры шәһәр хуҗасына шул кадәр акчага гарнитур тәкъдим итәме? Яхшылыкка яхшылык эшләү чираты, ниһаять, Нәҗипкә килеп җитте. Өй җиткердеңме? Җиткердең. Чолан салдыңмы? Салдың! Мунчаң бар, кухняң балкып тора — яле кайтар әҗерен, гражданин Нәҗип Нургалиев!

Директор тугры колын елмаеп, тәмле сүзләр коендырып үз катына чакырып кертте. «Менә,— диде ул, егеткә кәгазь-каләм сузып.— Дуслыкны ныгыта торган сәгать сукты. Шушы актка кул куеп, дәреслеген имзаң белән беркетәсең дә, актта телгә алынган гарнитурны базадан алып, мин кушкан адреска илтеп тапшырасың».

Бер укыды актны Нәҗип, ике укыды, берни аңламады. Актта ике аягы сынган, пыяласы ватылган, бер ягын өчлы кадак тирән ермачлаган нигидер шкаф турында сүз бара иде. «Юлда килгәндә ясалган шул казаларны истә тотып, фәлән-фәлән иптәшләр катнашындагы комиссия гарнитурның бәясен өч мең дә җиде йөз илле сумга калдырырга дигән карар чыгарды»,— диелгән иде азакта. «Йә, сал имзаңны!» — диде Вафа Сафич ашыктырып. «Минем ул гарнитурны күргәнем юк лабаса»,— диде авыллыгы һаман очып бетмәгән Нәҗип. «Әллә минем күргәнем бармы? Имзам ярылып ята. Ахмак! Синең кесәңә төп-төгәл өч йөз сум керә. Кул куйган саен өч йөз сумны тамызсалар, мин имзамны беләсеңме кайларга куяр идем!» — диде Вафа ямьсез генә хихылдап.

Башың кергән җиргә гәүдә сыя, китте Нәҗипнең җүләр башы язган ташкыннарда агып! Нәҗип, ике иптәшен ияртеп, базага юнәлде. Анда көтәләр иде инде.

Алтынга сатып алынган, шәһре Казанга уравыч юллар үтеп, диңгезләр кичеп, тау-чокырлар гизеп, төргән кәгазьләренә тап та төшмәгән, кадерле шкаф-өстәл-урындыкларны йөкчеләр кул очында гына йөрттеләр. «Әгәр черки кунган эз калдырсагыз да бәясен үзегездән түләтәм!» — дип кисәтеп калды Вафа Сафич. Дәү-дәү саллы тартмаларны, тулы чиләкләрне йөрткән кебек сак йөртеп, тоташ бакча эчендә күмелеп утырган кызыл кирпеч йортның өченче катына, Иван Иванович квартирына кертеп урнаштырдылар. Йөкчеләрнең миссиясе шуның белән тәмамланды. Тартмаларны бүтәннәр ачачак, тагын да ышанычлырак коллар җыячак. Аларны күрү Нәҗип өше күргән калайга түгел. Вафа Сафич кебек ышанычлы затка да насыйп булмаячак.

Наилә белән Сөмбелә сирәк-мирәк хат алышалар иде. Райкомның беренчесе итеп сайлангач, Сабит энекәшен эзләп тапты. Нәҗипнең әзер квартирадан баш тартуын белгәннән соң, шартлар дәрәҗәгә җитеп очрашуны көткән Сабит, ярты сәгать тоташтан русча, татарча, чувашча, марича сүгенде. Төрле телләрдә сүгенергә ул Саратовтан өйрәнеп кайткан иде. Нәҗип карулашмады, уңына да, сулына да ияк кагып, баш игәләп, тик басып торды. Сабит Наиләне көтеп җиткермәде. «Ханнарга тиң булырлык хатын шушы чи тәбикмәк кулында череп ята бит!» — дип каргый-каргый кунакханәгә кайтып китте.

Ялгышты бу юлы хатыннар белгече Сабит Йосыпович, аһ, каты ялгышты! Нәҗибеннән күңеле кайтканнан бирле Наиләнең итәген җил кайтарды, чибәр, сылу ханым баш инженер Израил Моисеевичтан шома гына директоры кулына күчте, Валериан Леопольдович аны үзенең референты итеп алды. Айлык хезмәт хакы, абруе артты Наиләнең, хәзер инде Гөлнаралар аңа баш орып керәләр, ялагайланалар, вак-төяк бүләк ташыйлар. Квартира чираты да күзгә күренеп алга сикерде, болай барса, алдагы елда каһәрләнгән сары йорттан котылачаклар. Саубуллашканда Сабит абыйсы үткәндәге вәгъдәсен бераз яңарткан иде. «Шәһәр советында кирәк кешеләрне күреп сөйләштем. Достоевский урамында бик престижный йорт өлгереп килә. Шуннан син диванага ике бүлмә тәгаенләнгән. Белешеп тор, җүләр булма. Һәм безнең карабодай басуында көртлек ишле булсын дип телә!» «Нигә?» — дип сорамады Нәҗип, ул хәзер шактый нык дагаланып килә торган ир иде.

• • •

Нәҗип яз саен каны алышынып, күзәнәкләре яңара торган хисле зат иде. Быел да шул хәл кабатланды, әмма яз аны гадәттәгедән ныграк яңартты. Каны ургылып-ургылып акты, элгәрге күзәнәкләре җир тетрәгәндәге тау кыялары кебек дөбер-шатыр килеп җимерелделәр, алар урынына яңа, яшь таулар калка торды. Уйлана торгач, соңгы ел ярымда, башыннан кичергәннәрне бер дисбегә тезгәч, Нәҗип Йосыф улы Нургалиев анык бер йомгак ясады. Хыяллары җимерелеп, аста, иске салам эскерте төбендә җебеп калган көннән бирле ул Наиләсе белән туктаусыз көрәшеп килә икән. Кая карап атласа да, эреле-ваклы нинди эш майтарса да, аның эш-гамәлләре Наиләгә каршы юнәлтелгән була иде. Ах, дача йорты кирәкме сиңа?! Мә, ал! Күр! Яшә! Алмагачлар быел яңармадымы? Чукынсын, аларын йолкып ыргытабыз да яренгә яңаларын утыртабыз! Әһә! Күрәсеңме?! Бөтенесе яңарды! Бакчада әлегә андый тук, нык яшь агачлар юк! Мунча сорыйсыңмы? Дөрес! Мөселман хатыны пакь булырга тиеш! Була! Әзер! Ал! Ләүкәсе сап-сары тактадан. Мунча алды сандык кебек. Чапчаклар юкәдән. Ап-ак. Көмеш сулы төпләре ялтырап утыра. Кер, чабын, тәнеңне дә, җаныңны да арула. Дачага җиһаз дисеңме? Боер гына! Камыш урындыклар, тирбәнчек көрси. Ишек өстендә Наиләнең зурайтылган фотосы. Нәҗип акча кызганмады, Ленин урамындагы антиквариат кибетеннән тумпак борынлы, йомшак иренле негрларның кара агачтан кырып ясалган сыннарын алып кайтып дача киштәсенә тезде. Зәвыксызлыкдиләрме? Төкер! Наиләсенә ошый! Аңа ошый икән, башкасы чукынып китсен!

Нәҗипнең рухын төшергән, ирлеген изгән бер нәрсә калды: квартир. Сабит абыйсы вәгъдә иткән йортның да җиденче катын өлгертеп киләләр. Ерак командировкадан әйләнеп кайтуга, Наиләнең чираты да бер-ике санга алга күчә... Сабит абыйсыннан котылып, квартирны Наилә алсын, дип теләп, шушы хәлне ризалашып көткән Нәҗип бер көнне тәвәккәлләп Вафа янына керде. «Вафа Сафич, син миңа бер

заман «фәлән кадәр акчаң булса, квартирлы итәм!» — дигән идең... Акча табам, квартир алып бирерлек чамаң бармы?» — дип сорады. Шадралары шомаланып югалган, күзләре шешенке кабаклары арасыннан күренмәс булган Вафа генералны күргән ефрейтор сыман турайды. «Акчаң гына булсын! Акча — терекөмеш ул, бетоннан койган бапарны да ера...»

Нәҗип акча җыя башлады һәм шул гадәте белән Наиләне шиккә төшерде. «Әллә берәр хатын янына ияләштеме бу йонкытыйк?!» Нәҗип исә соңгы һөҗүмгә күчәргә әзерләнә, истә-оста югында ордер тотып кайтып, Наиләнең чыраена атып бәрергә җыена иде. «Мә, ал!» Бу хәлне ул мең тапкыр күз алдыннан үткәрде, йокысыз аунаган мәлләрдә — булачак шушы тантана белән юанып җанын тынычландырды. Акчаны тизрәк җыярга, мая тупларга кирәк иде, ул Вафаның иң пычрак, иң әшәке йомышларын үтәде. Көн димәде, төн димәде, шимбәякшәмбедә складта уралды, базага булышырга барды, бәйрәм-сәйрәмнәрдә бүтәннәр өчен кизүлек итте. Күбрәк түләсеннәр генә! Саранланды, балаларына кәнфит, прәннек кебек әйберләр алып кайтмый башлады. Шимбә-якшәмбеләрдә таңнан чыгып югала, кара төн уртасында кайтып егыла...

«Инде була, бәхет кошы безнең кулга куна!» — дип йөргәндә, Вафа Сафичка учы-учы белән акча тапшыргач, көтмәгәндә, һич уйламаганда җиһазлар кибетенең өлгер директорын кулга алдылар. Казан шау-гөр килде! Югары даирәләрдәге әшнәләренә, үзе күп яхшылык кылган түрәләргә аркаланып, аларның йолып алачакларына йөз тотып үз эшен алып баручы тикшерүче майор белән дорфа кылана Вафа Сафич, сүгенә, яный, каргана. Майорның теңкәсенә тиеп бетә. Ә ул Вафа Сафичны яклаучылар табылу ихтималын чамалап, эшне мөмкин кадәр кыска тота, өч ай дигәндә әйләндереп чыгара, директорны җиде елга ябып та куялар.

Нәҗипне дә шаһит сыйфатында дәшеп алдылар. Аңа кадәр мыймылдык хатын аңа таушалып, пычранып беткән кәгазь кисәге сузган иде. «Май кап. Акчаң югалмас. Күпмегә япсалар да, мин озак тормам. Телеңне урынында тот!» — дип язылган иде анда. Нәҗип беркемне сатмады, белгәннәрен ачмады, ни сорасалар да: «Белмим, күргәнем юк, ишеткәнем булмады, катнашмадым»,— дип башын тилегә салып утырды. Аны судка чакырмадылар...

Ниһаять, сары йортның соңгы көне килеп җитте. Ионыч кичтән бөтен бүлмәләрне әйләнеп чыкты, шешәләр кузгалды, тустаганнар чыңлады, елаштылар, көлештеләр, сукрандылар, вәгъдәләр бирештеләр, «мәңге онытмам!» — дип кочаклаштылар. Нәҗип белән Наиләнең артык якын кешеләре юк иде, алар бүтәннәргә ияреп коридорга чыгып былагайланып йөрмәделәр, Ионычка ике шешә сыра эчертеп озаттылар да, эчтән бикләп, кара кайгыда калдылар. Ир белән хатын арасындагы кискенлек бераз йомшарды, Наилә дә ире, балалары белән кешечә сөйләшә башлады, кыланмады, Нәҗип, эчтән үртәлсә дә, тышка аны-моны чыгармады. Уйлаша, эзли торгач, Фәридун Фазлыев исеменә барып җиттеләр. Наилә: «Фатхулла абыйларга кагылыйк»,— диде, Нәҗип Фазлыевларга барып кайтуны яклады. Кат-кат йөргәнче дип, ике чемоданга сыйган әйбер-караларын тимер юл вокзалына саклык камерасына илттеләр, мендәр-юрганнарны Наилә китапханәдә бергә эшләгән иптәше Нина Морозоваларга илтеп куйды. Дүртәүләшеп Фәридун Фазлыевларга киттеләр. «Ул квартираның яртысы безнеке әле уйласаң!» — диде Наилә юлда барганда. «Әгәр алай сөйләшә торган булсаң, аларга эз дә басмыйбыз!» — диде Нәҗип кырт кисеп.

Алар Фәридун Фазлыевны йорттан ерак та түгел нәни генә бакчада аккаен төбендәге эскәмия янында очраттылар. Утырмаган иде Фәридун Фазлыев, җете кызыл өч бөртек канәфер чәчәге тотып, хәсрәтенә буылып аяк өсте басып тора иде. Ул үзен урап алган кешеләр-

не шактый озак торгач кына абайлады. Күрешеп, бер-ике сүз алышкач, ул кулындагы чәчәкләрне эскәмия башына таратты. «Шушында үлде Фәридә апагыз, шунда утырып җан бирде», диде ул коп-коры күзләре белән Нәҗипкә карап. «Кайчан?!» — диделәр Нәҗип белән Наилә бер-авыздан. «Ай ярым була инде»,— диде Фәридун Фазлыев. «Нигә безгә хәбәр итмәдегез?» — диде Нәҗип чын күңеленнән хафаланып. «Кирәк чакта сине табып буламыни? — диде Фазлыев.— Яшәгән урыныңны белмәдем. Эшеңә кергән идем, «судта» диделәр... Хәерлегә булсын!»

Алар эскәмиягә утырышып кыска гына сөйләшеп алдылар. Нәҗипләрнең йортсыз-нисез урамда калуларын ишеткәч, ул ашыктыра ук башлады. «Күченәсез дә киләсез. Бербашыма ямансу иде, ичмасам күңеллерәк булыр»,— диде. Нәҗип белән Наилә, рәхмәт әйтеп, әйберләрен ташып та куйдылар.

Фәридун Фазлыевның һәр иртәдә сөеклесе Фәридә җан биргән эскәмия янына барып, йә кыр чәчәкләре, йә кан кызыл канәферләр таратуына Наилә күнегә алмады. Ярым бөкрәеп, юаш кына басып торган ап-ак чәчле ирне күргәч, ул сүз әйтмичә, сүзен әйтә дә алмыйча үрсәләнеп елый иде... Былтыр лагерьдан малайларны: «Сезнең әтиегез псих! Сезнең әтиегез дурак!» — дип үртәп кайтарганнан бирле алар балаларны яннарыннан читкә җибәрмәскә булдылар. Хатыны вафатыннан соң эшкә чыга алмаган, саулыкка туймаган Фәридун Фазлыев балаларга тиз ияләште, аларны ияртеп зоопаркка барды, кинога алып керде. Алар зиратка да бергә барып кайттылар... Наиләне — тәҗрибәле, хәтерле һәм булдыклы референтны — генераль директор Урал ягы шәһәрләренең берсенә алып китәргә җыенгач, Наилә кырыс һәм йомылган иренең иңенә кулын салды. «Командировкага соңгы кабат чыгам, моннан болай балаларны ташлап китеп йөрмим»,— диде. Нәҗип дәшмәде, чынлап уйлаганда ул Наилә сәфәрләренә тәмам битараф иде инде...

Ниһаять, Нәҗипнең бүген беркая барасы юк. Хатыны «соңгы командировкасына» китте. Нәҗип Искәндәр белән Рөстәмен төрткәләп уятты да алар иртәнге поезд белән дачаларына, Идел буена барырга җыендылар. Нәҗип Фәридун Фазлыевны да чакырган иде, ул бармаска булды, «Апаң көтәдер, көн бик матур, зиратка кагылып чыгармын»,— диде ул кыр чәчәкләре бәйләмен эскәмия янына илтергә әзерләнеп.

Бакчада озак юанмады Нәҗипләр, калкына башлаган түтәлдән бер-ике кыяк суган өзеп каптылар да яланаяк, чап-чап басып, куышып, дачалар янәшәсендәге аулак култыкка су керергә төшеп киттеләр. Менә кайда икән ул дөнья рәхәте! Һава саф, тар булса да тирән сулы култык ярларында мең төрле чәчкә-үләннәр кабарып, талгын җилдә сизелер-сизелмәс кенә тирбәләләр. Күбәләкләр — җәйнең фәрештәләре — ал, зәңгәр, чуар канатларын селкеп һава дулкынында иркәләнәләр. Култыкның теге ягында, бу якка элегрәк килеп урнашкан дача хуҗалары утырткан нәзек, яшь каеннарда сандугачлар тавыш биреп куя. Кыш, яз буе ярым караңгы складларда сөремле-корымлы урамнардан, түшәменнән су тамып торган базалардан баш чыкмаган Нәҗип тиз исерде. Җәй һавасы, тансык хуш исләр, күбәләк куып ары-бире йөгергән балаларының гамьсез чыр-чуы аны тәмам мәс итте. Күптәннән наз, иркәләү күрмәгән тәнен таратып чирәмгә сузылды, нык ук күтәрелеп килгән кояш аның куе керфек араларына сыеп бетте. Ул йокымсырады һәм «күк капусы ачылды». Ул дөньяны иңләп басып торган Наиләсен аермачык күрде...

Кинәт сискәнеп китте, колагына балта чапкан, дәү агач ауган тавышлар ишетелгәндәй булды. Тукта әле, нигә болай ачык ишетелә бүген поезд тавышлары? Монда, култык янындагы үзәндә тимер юл ыжгырганы ишетелми иде ләбаса!

Калкынды, этиләренең йокылы-уяулы сөйләшкәнен балалар абайлаган, ахрысы, икесе дә аның янына килеп басканнар, әсәренеп, тыңланып көтеп торалар. «Әти! — диде Искәндәр, учын ачып.— Мин бер нәрсә таптым!» «Нәрсә, улым?!» Нәҗип күзен ачыбрак караса, улының нәни учында ялтырап, нурланып алтын балдак ята «Каян алдың моны?» «Мин аны әниемә бирәм,— диде үз уйларына чумган малай.— Ул балдакны ярата!» «Каян беләсең? — дип сорады кинәт шигәеп Нәҗип.— Аның балдаклары юк ич!» «Булмас! Бар! Ике кулында ике балдак. Икесе дә алтын. Сөенгән әни!» Нәҗип торып басты, балдакны тартып алып, күзенә якын китерде. Алтын! Билгесе бар... Наиләнең ике балдагы бар диген! Ник күрсәтмәгән ул аны Нәҗипкә? Нәҗип ничек күрмәгән? «Юк, улым,— диде ул пошынган тавыш белән.— Югалган балдакны әниеңә бирмә, без аны иясенә кире кайтарырбыз». «Ә иясен каян табабыз?» «Балдагы табылгач, иясе табылмый калмас».

Көннең чите кителде, Нәҗип интегеп, җәфаланып Наиләнең алтын балдаклары хакында уйлады. Ничек күрми калган ул аларны, ничек абайламаган?.. Малайлар балдакны тиз оныттылар, якыннан очып үткән дәү, чуар канатлы күбәләк артыннан йомылдылар. Нәҗип тезен чәнчеп, учындагы балдакны вакыт-вакыт караштырып, ямьсез, өметсез уйлар чоңгылына чумды, янына ук килеп үлән чемченә башлаган кәҗәне дә күрмәде. Ак яулыгын татарча җилкәсенә җәеп салган, нык ук таушалган, бөкресе чыккан карчыкны кәҗә үлән кештердәткән тавышны ишетеп борылгач кына күрде. Карчык, кәҗә муенына салган сүс бауны арык бармакларыннан ычкындырмыйча гына, аның янына килеп чүгәләде, балалар ягына башы белән ишарәләп: «Улларыңмы?» — дип сорады. Нәҗип баш какты, эндәшмәде.

«Исәйгәнче балалар зур байлык, юаныч... Картлык һәркемгә килә... Әмма баладан уңмаган картлык — иң күңелсез картлык... Әйе, картлыктан алама нәрсә юк...» Карчык юл буе үзен урап килгән сөмсез, караңгы уйларыннан арына алмый иде булса кирәк, ул Нәҗип белән түгел, үз-үзе белән сөйләшә, бәхәсләшә, көрәшә иде, ахрысы.

«Әле ярый, ходаның кодрәте киң,— ул адәм баласын картлыкка иртә әзерләргә тотына. Озак әзерли ул аны картлыкка, кинәт килеп җитә торган Газраил белән көрешергә әзерли. Адәм баласы картлыгын абайлап, сискәнеп, йөрәге ярылмасын өчен, аллаһе тәгалә әүвәл башлап аның нурлы йөзенә сызыклар сыза... Аннан иплән кенә күзнең нуры коела. Ниемә кирәк карт кешегә якты күз? Артка караса — үкенечләр, алда — кара пәрдә... Яшьлек тавышларын ишеттермәс өчен, иплән кенә колакны балавызлый... Юынган саен үзеңнең әҗәл көткәнеңне искәрер өчен аяк тырнакларына сары тут төшә... Кул тырнаклары сына, ярыла башлый. «Ай-һай, дөнья!» — дип әйтеп баш чайкаган саен чәч коела... Ашыгудан, җитезлектән коры каласың — буыннарның егәре бетә... Мин элгәре бүрекле ата казымның тавышын чакырым ярымнан аера идем!.. Март башларында болдыр янына килеп бер кычкырсамы?.. Җилгә каршы килеп җитә иде тавышы!.. Хәер, каз асрау да бик читенләшкән иде. Мәшәкате күп аның, кош-кортның. Колагы катыланган, күзе күрмәс булган адәмгә кош-корт артыннан йөрү читен... Син шушы урыннан җир алган кешеме?.. Таныйм, таныйм. Сине танырлык егәре калган икән күземнең. Беренче булып йорт җиткездең... Чая егет дип йөрдем мин сине. Авыл халкы сине каргый, йортларга ут салабыз, дип яныйлар... Идел буе халкы бурлыкка күнеккән. Бурлык өчен аулак булган яхшырак. Ә миңа ни, карт пәригә, булса ни дә, булмаса ни... Моннан ун көн элек кәҗәмне йөрткәндә балдагым шуып төшеп калды, югалды. Бармакларның егәре калмаган. Арыкланган алар, төс җуйган... Нигә булыр икән, дип юрап йокы күргәнем юк. Баксаң, тимер юл буе агачларын кисәргә булган икән. Улым Басыйр... бәлки, ишеткәнсездер дә, Басыйр Бариевич дигән кәттә нәчәлник ми-

нем улым була! Шул әйтә: «Тимер юлларны киңәйтәбез, ишәйтәбез. Бакчаларны бетерәбез»,— ди... Күчергәндә сезгә бүтән урыннан җир кисеп бирәчәкләр икән... Нәрсә сөйли идем соң әле? Ә-ә, иманнарне искә алган идем. Шул, балдакны миңа бүләк иткән кеше утыз җиденче елны язда утырткан иде аларны... И куанып та йөргән иде. Күзен үзен өтерманга илтеп тыгып, эзен югалттылар. Хәзер менә, кырык ел үткәч, урманын кисәләр...»

Нәҗип әсәренеп, калтырап диярлек тыңлады карчыкны. Аның баягы халәте, төш белән өн арасындагы сизгерлек мизгеле китеп, таралып бетмәгән иде, карчыкның һәр сүзенә ияргән моңын, сагышын тирәнтен кичереп тыңлады. «Аллаһе тәгалә адәм баласын картлыкка әзерләп, тәүбәгә килергә вакыт калдыра. Бераүнең дә жанын кинәт кенә алмый!»

Нәҗип учын ачып карчыкка күрсәтте. Әнисә абыстай (бу ул иде, әлбәттә) башта балдакны күрмәде, күргәч искәрмәде. Ул, җанын авырайткан уйларын көч-хәл белән күтәреп, бу тирәдән еракта йөри иде булса кирәк. «Утыз җидедә агачларны утырткан кеше бүләк иткән иде балдагымны. Һи-и, җылы җанлы кеше дә иде мәрхүм!.. Каз багып кына йөри идеммени мин, юк, иманнәр белән серләшә идем. Ни әйтсәм дә, аңлый иде алар мине». «Алыгыз балдагыгызны!» — диде Нәҗип, учын аңа таба якынайтып. Карчык баш чайкады: «Минеке түгел, түгел. Бу минеке түгел. Иманнәрне кырып, төпләрен ком белән каплаталар икән, балдак нигә инде?» «Мин аны әниемә бүләк итәм. Мин таптым аны»,— дип сүз арасына кысылды быткычланып Искәндәр. Нәҗип улының Наиләне телгә алуын, аңа тагын бер балдак бирергә ашкынуын өнәмәде. Искәндәрнең җилкә чокырына төртеп, аны читкәрәк какты. «Алыгыз, ал, апа». «Юк,— диде Әнисә абыстай, учта нурланып яткан түгәрәк алтынга күз төшермичә.— Минеке түгел!» Ул, кәҗәсен ияртеп, култыкның Иделгә тоташкан башына китте. Нәҗип ике улын ике кулы белән җитәкләп, җилтерәтеп, култыктан бакчаларга үтә торган тар тыкрыкка сөйрәде. Тимер юл якынлашкан саен балта-пычкы тавышлары, ишле кеше авазлары ачыграк һәм усалрак яңгырады. Нәҗип адымнарын шәбәйтте, малайлар аның адымнарына өлгермәделәр, ул кулларын ычкындырып тавыш килгән шөбһәле якка бер үзе ашыкты.

Ничек моңарчы күрмәгән ул? Ничек бу хакта беркем аңа хәбәр ирештермәгән? Баскыннар Обсерватория ягыннан урманны кисеп, агачлардан тазартып ук киләләр икән. Тиз тотка용 бер дә социализм эшчеләренә охшамаганнар болар. Әллә монда да акчага хирыс, ял итүне оныткан адәмнәрне яллаганнармы? Берләшмә бакчалары читенә җитәрәк, сулышы кабып, Нәҗип туктап калды. Йөрәге иске насос кебек калтырана, күкрәгенә сыеша алмыйча бәргәләнә иде. Унбиш-егерме метр киңлектәге агачлык хәвефле, ят тавышларга күмелгән: электр пычкылары күндәм генә агач кәүсәләрен тешләре белән умырып керәләр, көн яктысында ботак-сатап тураучы үткер балталар елык-ялык килә, күлмәкләрен салып ыргыткан ир-егетләрнең юеш җилкәләреннән куе пар күтәрелә. «Сагай, сагай!» — дип кычкырган тавышлар тынып өлгерми, яшьтәш иманнәр әле анда, әле монда чайкалып торалар да фырылдап, колачларын җәеп, үләннәрне изеп, вак куакларны сытып, җиргә барып яталар. Бөтен җиргә пычкы чүбе, йомычка, суелган кабык, аракы катнаш тир исе таралган. Анда-санда чи ботакларны чыжылдатып учаклар яна. Арырак, иман аударучылар үткән урыннарда, озын арба таккан тракторлар, машиналар тукталган, шундый ук таза, шәрәтән ирләр бер буйга туралган иман кискәләрен ашыгып-кабаланып төйиләр, һау-һаулап бер-берсен ашыктыралар, дәртләндерәләр. Русча, татарча сүгенү сүзләре язгы рәхәткә күнегә башлаган сак колакларны рәхимсез кисә.

Нәҗип әүвәл бер-бер артлы, аркылы-торкылы ауган агачларны

әрнеп күзәтте. Аннан соң гына, күз аллары бераз ачылгач, кешеләрне аерым-аерым итеп, берәмтекләп күрә башлады. Үз күзләренә ышанмады, ышанырлык та түгел иде...

Беренче итеп Нәҗип сары йортның «элекке коменданты» Ионычны күрде. Аның янында туктаусыз балта уйнаткан өч ир-ат таныш иде аңа. Алары да Нәҗип белән бергә сары йортта сәрсеп ятып, шуннан сөрелгән ирләр. Кушсаң, иманнарне генә түгел, имән-имән ирләрне дә турап чыгачак байгышлар. Гаделлеге өчен Митя Шороховны да шулар үтереп ташлаган, дип сөйләделәр. Алар өчәү укмашып, авыр карашлары белән үткән-сүткәнне капшап торсалар, яннарына якынаерга курка иде Нәҗип. Ионыч мәзәк кенә каш сикертте, «Баш бирмибез, балта безнең кулда!» — дигән сыман күзен челт-челт йомгалады.

Күз Ионычтан читкәрәк күчте, бер төркемнән икенчесенә барып ялганды. Имәнлек, имәнлек!.. Әле узган килгәндә генә Нәҗип улларын имәнлек кырына бастырып: «Сез шушы имәннәр белән янәшә үсәрсез, балалар. Алар сезне, сез аларны саклап яшәрсез»,— дигән иде түгелме? Гаҗәп! Каян килеп эләккән монда Сабит абыйсына шашлык кыздырып яткан Самвел белән Гурген? Әллә алар түгелме? Күзе алмаштымы Нәҗипнең? Башы авырта, колагы чыңлый, аякларында көч калмаган... Юк, шулар! Нәҗипне танып алар да балталарын күтәреп сәламләделәр. Вафа Сафичка хезмәт итүчеләр дә монда! Доцентлар! Пешекче! Баш механик! Алар Нәҗипкә карамаска, күренмәскә тырышалар.

Юк, юк, Нәҗипнең күзенә нидер булган! Ялгыш күрә! Тимер юлчыларның профсоюз лидеры Исламнур да монда! Җир өчен тарткалашып йөргәндә Исламнур белән Нәҗипне Изил Латыйпов таныштырган иде. Тукта, тукта! Мөнир ич бу! Авылын каргап чыгып киткән егет! Трактор янына баскан да ашыгып-ашыгып төпчек суыра. Ә арырак Гөлгенә белән аның ахирәте кара хатын ботак-сатак яндыралар шикелле! Алармы, түгелме? Хатыннарның битләре корымланган, тез турындагы оеклары тишелгән. Бөтен дөнья бәхетсезен җыйганмы әллә шушы урман?

Һа, бусы инде акылга сыймый! Мөмкин түгел! Нәҗип чирләгәндер, күзе Идел буенда калгандыр... Әллә төш күрәме? Саташамы?! Нәҗипнең әлҗе-мөлҗе күзе урман тунаучыларның иң кайнашкан ноктасына җитте дә туктады. Уртада УЛ басып тора иде. Аның кулында пычкы да, балта да юк, киемнәре дә таза. Ул, күп санлы музыкантларны берләштергән көчле оркестрның дирижеры сымак, үкчәләренә басып бер урында зыр-зыр әйләнгәли, кулларын бутап кемгәдер кычкыра, өр-яңа зәңгәрсу чалбарының җиз-патрон төймәләре елтырый. Юк, юк, бу кеше Изил Латыйпов түгел! Булмас! Була алмый! Чире борылып кайткандыр Нәҗипнең, шуның кәсафәтедер! Чир шаукымы гына ла бу! Изил Латыйпов — тимер юлчыларга каршы көрәштә катнашкан, җир өчен канга-кан сугышкан кеше, хәзер шуларның мәнфәгатен яклап урманны кистереп ятсынмы? Аның монда җитәкче, иң кәттә кеше икәнлеге күзгә бәрелеп тора! Ул түгел. Бүген үк, хәзер үк шәһәргә кайтырга да врачка күренергә кирәк. Фәридун Фазлыев: «Торымнан торымга каралырга кирәк сиңа, Нәҗип туган, психик чарпалышлар эзсез үтми алар»,— дигән иде түгелме?

Ул исәнгерәп басып торганда бакыр бугазлар, корыч күкрәкләр: «Әй, сагай, сагай!» — дип тоташ акырдылар, иң биек булып күкрәп утырган имән авыр уфылдап, УЛ дирижерлык кылган тирәгә авып төште. УЛ бер якка сикерде, һәм сабан туе чабышкысы кебек, артын сикертеп Нәҗип янына килеп басты. Ялкын, төтен, ут исе килә иде аннан. «Син дә безнең беләнме? Молодец! — диде ул күзләрен нурландырып.— Ишеттек, ишеттек... Шактый акчаң янган икән! Ә монда!.. Тиз арада акча күрәргә була!»

Изил Латыйпов! Үзе! Шул!

Күзенә дә, колакларына да ышанмады Нәҗип, шаккатты. Аның Вафага акча биреп куюы турында, шадраның төрмәгә эләгүен беркемгә, хатынына да сөйләгәне юк лабаса! Димәк, Наилә аның тормышын, һәр адымын капшап, тикшереп йөри дигән сүз! Тикшерү өстенә шушы азгын каргага сөйләп тә бара икән! Күзләренә ышангач, колакларына да ышанырга туры килде. «Бу ни хәл? — дип сорады ул, тыныч булырга тырышып.— Агачларны кисәләр, җирне тартып алалар, син үзең утырган ботакны кисәсең түгелме? Хыянәт ич бу!» «Ерунда! — дип авызын ерды Изил.— Рощаның хуҗасы юк, утырткан кешеләр беткән, агачлык беркем балансында да тормый. Кисәргә алынган кешеләр шушы кадәр байлыкка үзләре хуҗа! Хуҗа! Аңлыйсыңмы, тинтәк? Мин җиһаз фабрикалары белән элемтәгә кердем. Мала-а-ай! Агач бөтенесенә кирәк! Яртыдан артыгын Украинага, далалы төбәкләргә алтын бәһасенә аткарабыз! Калганын Каспий ягына, урмансыз өлкәләргә саттык! Бер бүрәнә, бер ботак әрәм булмас! Монда акча эшләп алырга була! Сал өстеңне, тот кулыңа балта! Мондый фарт гомердә бер килә!» «Ә җир?» — дип ыңгырашты Нәҗип. «Җир? Татарстанда җир беткәнме!? Тотын балтага, тотын дим мин сиңа!» «Соң үз җирендә татарга яшәр урын калмый лабаса! Күпме уңдырышлы җирләрне су астында калдырып, сулыкларда зарарлы корт үрчетәбез! Нефтьчеләр күпме җиребезне талады! Кара туфраклы басуларга гел кирәкмәгән заводлар китереп утырттык!.. Инде, шушы күз карасы кебек кадерле имәннәрне дә тунап бетерсәк!» «Әй, син! — диде Изил каралып.— Тый телеңне! Телеңнең авызыңа сыймаганлыгын анда бик яхшы беләләр! Чамалап! Йә балтага тотынасың, йә моннан таясың! Җир кирәк булган икән аңа, әтрәк әләмгә! Табырмын мин сиңа җир. Тай моннан, мәхлук!»

Нәҗипнең баш очында яшен чартлады, уйлары ми тартмасына сыя алмыйча кисештеләр, ул каршысында авыз ерып торган Изил Бәдретдинович Латыйповның яңагына китереп бәрде. Профсоюз куштанының күзеннән утлар чәчелде...

Нәҗип көч-хәл белән дачасына кайтып житте, бикле ишек тирәсендә уйнап йөргән улларын күкрәгенә кысты һәм елап җибәрде. Кулъяулыгына дип кесәсенә тыгылса, кулы ят бер әйбергә кагылды. Ул алтын балдакны тартып чыгарды, аңа бер карап алды, булдыра алган кадәр еракка, киселүне көтеп, җилдә калтырап утырган имәннәр арасына ыргытты. Поездлар шавы тынган арада аның колагына пычкы, балта, имәннәрне егып килгән ирләрнең мактанчык-исерек тавышлары килеп җитә торды.

## 31

Буйдан-буйга сузылган урман да, уйсулык читендәге бакча участоклары да әллә кайчан калын ком астында калып югалдылар. Идел төбеннән кудырылган ком катлавы өстендәге шпаллар әлегәчә күгәреп, эшсез ята. Отчет бирелгән, орденнар алынган... Әнисә абыстайның вафатына да байтак вакыт үтте. Бу якларда хәзер казлар күренми!..

Ниһаять, Наиләнең чираты җитеп, Нәҗипләр яңа квартирга күченделәр. «Соңгысы, соңгысы!» — дия-дия Наилә командировкаларына әле дә булса йөри. «Йортка кердем!» — диде әрнеп Нәҗип Ионычны бер очратканда. Квартир Наилә исемендә иде. Валериан Леопольдович Наиләне янадан Израил Моисеевич катына кайтарды. Үзе референт итеп Мәскәүдән Казанга кайтарткан чибәр гөрҗи хатынын алды. Наилә күчешне авыр кичерде. Әгәр Нәҗибе бер-бер кыек сүз ычкындырса: «Квартир минеке! Синең ише чабата олтырагын куам да чы-

гарам мин!» — дип акырырга ярата. Күчеп әз генә яшәп калдылар, Искәндәрне милиционер җитәкләп китерде: «Гараж йозагына ачкыч яратып, велосипед урлап чыкканнар!»

Фәридун Фазлыев киңәше белән Нәҗип кибеттән бөтенләйгә китте, шәһәр читендәге яңа мәктәпләрнең берсендә физика укыта башлады. Искәндәрне үзе укыткан мәктәпкә күчереп, иярттеп йөртергә гадәтләнде. Коллектив әйбәт иде болай, ир педагогны хуплап, хәтта бераз үзсендереп тә каршыладылар. Көзен, ноябрь бәйрәмендә, бәйрәм тантанасында тәртип сакларга, унынчы класс дружинниклары белән Нәҗипне дә җибәрделәр. Бәйрәмнәрдә Ирек мәйданын үтеп кенә киткәне бар иде аның! Хәйран кеше җыйнала икән анда! Нәҗип алып килгән егетләрне Ленин һәйкәленә якын гына урынга бастырдылар. «Җаваплы пост!» — дип кисәттеләр.

Вак рашкы кар сибәләгән көн иде. Мәйданга суворовчылар, гаскәриләр килеп кергәч, Нәҗип бик хафаланып уйлап торды: «Боларның берсе дә иген икми инде, чуен коймый. Һәммәсенә май кирәк, ит!... Нигә шулкадәр күп алар? Ә Мәскәү парадларында! Ел саен күпме офицер әзерлиләр! Илгә сугыш куркынычы янамаганда нигә шулкадәр акча, ресурслар түгеп, чамасыз гаскәр тотарга? Германиядә, чехларда, венгрларда... Нинди акылсызлык бу! Трибунадан яңгыраган лозунгларга бер дә туры килми ич болар! «Тынычлык, тынычлык!» — дибез, үзебез дөньяны атом бомбаларына күмдек. Океаннарда безнең су асты көймәләре, һаваларда хәтәр самолетлар!..»

Аның башы әйләнеп китте, ул тотыныр нәрсә булмагач, якягына каранды да күзен йомды. Күзен ачканда мәйданга байракчылар кереп килә иде. Тукта! Байракчылар таныш түгелме соң аңа? Әйе, әйе!.. Аның маңгае дымланды, аркасына салкын тир бәреп чыкты. Күз аллары караңгыланып, арт чүмеченә яшен китереп бәрде. Егылмаска, егылмаска, дип ныгытты ул үз-үзен. Партия, хөкүмәт җитәкчеләренең дәү-дәү рәсемнәрен күтәреп беренче сафта Ионыч, аның өч ахирәте, Гурген белән Самвел, Исламнур белән янәшә Изил Латыйпов, Гөлгенә белән кара чутыр якут кызы киләләр иде. Самвел — Мжаванадзе, Гурген исә Алиев портретларын тотканнар. Ә Ионычның нык кулларында Брежнев үзе! Аның көрәштәшләре Черненко, Романов, Андропов, Громыко, Суслов, Рәшидовлар аннан әз генә түбәндәрәк тирбәләләр. Нәҗипнең кинәт көләсе, мәйданны яңгыратып: «Балта тоткан куллар кызыл әләмнәрне тотарга да мәҗбүр шул!» — дип кычкырасы килде. Башы әйләнде, тамагы янды, бугазын нидер кытыклады. Көләргә ярамаганын белсә дә, һич чыдар әмәле юк егетнең. Ярылаярыла, бүксәсе шартлаганчы көләр иде мөмкин булса... Бер түзде, ике, аскы иренен чәйнәп бетерде, ниһаять, чыдамады, колонналар өстендә чайкалган зур-зур портретларны янәшә баскан укучыларына күрсәтеп, шаркылдап көләргә тотынды. Трибунада гайрәтле кулы белән казанлыларны котлап торган иң зур җитәкченең чырае сытылды, ул Иван Ивановичка ым какты, Иван Иванович үз чиратында офицерларның берсенә Нәҗипне төртеп күрсәтте. Нәҗип, ике ягыннан ике таза егет килеп култыклаганда да тыела алмыйча, мәйданда яңгыраган сыек кына «ур-ра!» тавышларын басып, һаман, көлә, хихылдый иде.

Арча кырындагы сары йортка илтеп япканда да аның ирен читләреннән канәгать, бәхетле елмаю китмәгән иде әле. Бер үкенеч калды: янәшәсенә баскан укучылары аның нилектән көлгәнен аңышып өлгермәделәр!

Иртәгесен аны чакырып алдылар. Врач белән күрешеп, мәсьәләне ачыклыйбыз дип барса, ярым караңгы кабинетта аны хәрби кыяфәтле, гражданнар киеме кигән, кырыс танышы каршылады. Изил бүлмәсендә очрашканнары бар иде аларның. «Ни өчен бәйрәм вакытында тәртип бозып, ил тантанасын көлкегә алдыгыз?» — диде теге явызланып.

«Кызык ич! — диде Нәҗип елмая-елмая.— Кемнәрнең рәсемнәрен кемнәр күтәреп бара бит!» Һәм ул кысан бүлмәне киңәйтеп тагын шаркылдады. «Түшен калай белән тутырганның портретын кем күтәреп бара диген!»

Таныш артыгын җентекләп тормады. Нәҗипне әллә ничә тимер ишек аша үткәреп, бер ялгызын карцерга илтеп яптылар. Бәйрәм арасында аны чакырган кеше булмады, ашарына кертмәделәр, эчәренә бирмәделәр. Ул, үз хакын таләп итеп, ике йодырыгы белән тимер ишекне озак кына төйде. Бераздан ишек тавышсыз гына ачылды, сүзсез-өнсез кергән тап-таза ирләр Нәҗипне идәнгә егып салдылар да сул беләгенә бер-бер артлы ике укол кададылар. Ике атна үтеп, Нәҗип телгә килгәч, аны өч кеше янына илтеп яптылар. Камерадашларының сүзсезлеген күреп ул: «Нигә безне монда тоталар?! Ни гаебебез бар безнең?!» — дип ишекне төя башлаган иде, тап-таза ирләр кереп, аны эләктереп алдылар. Яңа уколлардан соң ул дүрт ай телгә килә алмады.

Дүрт айдан соң, Нәҗип Йосыф улы Нургалиев, чак-чак исен җыеп, үзе белән ниләр булганын сөйләр чамага кайтканда аны этап белән Томск ягына озаттылар. Һәм шунда аның эзе югалды. Бу юлы балтаның кем кулында булуын беркем дә белми калды.

*1988-1989 еллар*

## *Бер сорауга — бер җавап*

*— Хөрмәтле Гомәр ага! Сез, 90 яшенә якынлашып килүче әдип һәм гражданин буларак, илебез тарихындагы бик күп вакыйгаларның, борылыш һәм тетрәнүләрнең шаһиты булган кеше. Илдә барган бүгенге революцион үзгәрешләрне дә, шаять, актив күзәтеп барасыздыр. Үзгәрешләр җиле татар халкы язмышына да турыдан-туры кагыла. Халыкны, киң катлам җәмәгатьчелекне иң нык борчыганы — Татарстан җөмһүриятенең политик статусын, мөстәкыйльлеген, димәк ки, бәйсез киләчәген кичекмәстән хәл итү. Бу хакта Сезнең фикерне ишетү кызыклы булыр иде.*

— Әйе, бик урынлы сөаль бу. Мин моны хәзерге иң төп мәсьәләләрнең берсе дип карыйм. Чөнки татар халкын автономия белән чикләп калдыру һәр җәһәттән караганда да гаделсезлек иде. Татар халкына Союздаш республика статусын бирү менә шул гаделсезлекне төзәтү булачак.

Өлкән буын кешеләренең һәркайсына мәгълүм булса кирәк, Октябрь революциясендә һәм аны чит ил интервентларыннан саклап калуда безнең татар халкы бик күп көч салучы, биниһая корбаннар бирүче халыкларның берсе булды. Мин бик яхшы хәтерлим әле, революция елларында «хөррият», «милли азатлык», «милли мөхтәрият» дигән ялкынлы сүзләр халык теленнән озак вакытлар төшмәде, газета-журнал битләрендә өзлексез кабатланып торды. Халыкның бик тырышып күптән көтелгән азатлыкны, милли мөстәкыйльлекне таләп итүе иде бу. Чөнки электән мөстәкыйль дәүләт булып яшәү җәһәтеннән булсын (Иван Грозный Казан ханлыгын басып алганчы татар халкының алты гасырдан артык мөстәкыйль дәүләт булып яшәвен онытмыйк!), икътисади, мәдәни җитлеккәнлек булсын — татар халкы мөстәкыйль яшәргә, союздаш республика статусы алырга ул елларда ук хаклы иде. Шул сәбәпле, Сталинның Татарстанга карата куелган «чик буенда түгел» дигән ясалма уйдырмасы ул вакытта ук берәүне дә ышандырмады, аның күз буяу гына икәнлеге көн кебек ачык иде.

Шул рәвешчә без, Сталинның мөселман халыкларга, бигрәк тә татарларга карата духовная семинариядә укыган вакытыннан бирле үк шовинистик карашта булуы нәтиҗәсендә, халык буларак үз хокукыбыздан мәхрүм ителдек.

Ләкин һәрнәрсәнең чиге бар, хокук бозуның бигрәк тә! 7 миллионлы халыкны моннан соң да автономия кысаларында кысрыклап тоту һичбер закон рамкаларына сыймас, Хельсинки килешүенә, гомумән, кеше хокукы турындагы халыкара кануннарга хилаф килер, бөтен бер мәдәни халыкны көчләүгә тиң булыр иде. Татарстанга союздаш республика статусы кичекмәстән бирелергә, ниһаять, бу республика үзәктәге төрле министрлыклар, ведомстволар, аерым шәхесләр колы булып яшәүдән азат булырга, үз җир-суына, үз табигать байлыгына, үз мәдәниятына һәм теленә үзе хуҗа булып яшәргә тиешле. Ул моңа, әйткәнемчә, күптән үк хаклы.

# Салисә Гәрәева

## Авылым

Авыллар бар Россиядә эреле-ваклы.
Якыны юк ләкин җанга Тулбай чаклы! —
Исемендә Татарстан һәм Туган ил...
Иң җылы җир миңа монда, иң җылы җил!

Бу туфракта минем тормыш тамырлары.
Чәчләремдә — туган ягым яңгырлары.
Шул як суы, балы, каны — җисемемдә.
Минзәләнең бер мизгеле — исемемдә!

Урман-сулар аһәңе бар тавышымда,
Уйнап үскән яшел Сөрмәт тавы — шунда!
Арышларым язын һаман серкәдәдер,
Ай нурында басу-кырлар иркәләнер...

— Исәнме! — ди һәр очраган таныш-белеш:
Гадәт шулай — очраганга сәлам биреш!
Бар күзләрдә елмаю һәм җылы күрәм...
Авылымны хәтеремә ныграк үрәм.

## Сандунга

*(Шул исемдәге майя халык җырын тыңлагач)*

Гасырларны, вәхшәтләрне үтеп
Исән калган бер җыр ишеттем.
Ишеттем дә, моңлы йөрәгемә
Шул борынгы җырны иш иттем.

Искиткеч моң, йөрәгемне телеп,
Тетрәндерде мине — еладым.
Тарих серен, Җирне, Кешелекнең
Садә бала чагын уйладым...

Сандунга!
Ул бит сандугачның
Таңгы җыры булып тоелды.
Ирексездән ирен читләремә
Сафландыргыч яшем җыелды...

Сандунга!
Тарих иртәсенең
Безгә килеп җиткән сагышы,
Ул — рәнҗүе җирдән киткән илнең,
Һәлак булган халык тавышы...

---

Салисә ГӘРӘЕВА — *шагыйрә, «Уралым» һ. б. шигырь китаплары авторы. Чиләбедә яши.*

## Европа-Азия читендә

Урал-тауда
Кыйтгаларны ялгар
Сукмак-юллар ята, өзелми:
Тик бер адым атла — Азиябез
Кочагына ала үзеңне!..

Ике чикнең сакчы кыясында
Бөркет йолка канлы корбанын:
Сизми дә ул — аңа Европадан
Салисәнең карап торганын!..

Европаның кырчын ташларыннан
Азиягә атлап үтәм мин;
Тамырларда ике континентка
Хуҗа халык канын йөртәм мин!

*

Кәгъбәләрнең юкка чыккан чагы —
Кыйблаларны ничек табарга?
Гадәтләрен, телен оныта халкым —
Яшәү юлын табыйк аңарга!

Үз телеңнән, үз-үзеңнән качып,
Куркып бөек татар исменнән,
Үсеп килгән буын мәхрүм калган
Милли горурлыгы хисеннән...

Тарихларның эзе — җир астында:
Анда көл дә, сөяк, таш... ватык.
Яшьләребез чит кавемгә күчә,
Милләтем, дип тормый баш ватып.

Бабаларның нәсел тамырын өзеп,
Кем ул аның йортын таркаткан?
Бар халыкның канын катнаштырып,
Ватансызлык юлына атлаткан?..

Кәгъбәләрнең юкка чыккан чоры,
Җаннарыбыз җуйса кәгъбәсен?!
Башны кысып, уйланам да кайчак,
Яшәвемнең тапмыйм мәгънәсен...

## Бер тустаган кымыз

Бер тустаган кымыз тоттырдылар —
(Сары авылында кебек ул)
Болыт кебек өскә күтәрелеп,
Тышка бәреп чыкты күбеге...

Тын тутырып, туктап-туктап эчтем,
Чын ләззәтен татып кымызның.
Тик җитмәде тальян сайраулары,
Чыңгылдавы тансык кубызның.

Янәшәмдә ак каенсар иде,
Бал кортлары очты безелдәп.
Янәшәмдә торган якташларның
Яратуын тойдым күзеннән...

Зәңгәр күктән кояш көлә иде,
Җилфердәде җилдә кылганнар...
Табигать тә, безнең күңелләр дә
Изге уйлар белән тулганнар.

Кымыз эчтем, бер йотымын җиргә,
Үләннәргә ихлас тамызып;
Бер тустаган кымыз иләсләтте,
Якты дәртләр җанда кабызып!

## Мин — Җир кызы

Мин — Җир кызы. Җирдә туганмын да,
Чишмәләрдә битем юганмын.
Миллиард йолдыз күктә. Күзләремдә
Очкыннары чагыла шуларның...

Газиз миңа җирем, анда үскән
Һәрбер үлән, арыш башагы...

Моңын сөйли миңа һәрбер кошчык,
Серен сөйли миләш яфрагы...

Газиз миңа жирем. Һәр кешесе,
Һәр сабые — гүя туганым.
Мин аларга мәңге бәхет телим —
Мин җир кызы. Җирдә туганмын!..

## Татар җыры

Татар җыры... Ерак тарихлардан
Алып килә халык хәтерен.
Оялчан ул, инсаф, ягымлы ул —
Үзе салмак, үзе әкерен...

Шул җыр белән бергә сәфәр чыгып,
Тарих түрләреннән килгәнбез;
Татар җырын җырлап таралганбыз,
Татар җырын җырлап җыңгәнбез...

Мин хәзер дә, үзәк өзелгәндә,
Җырлар канатында тирбәләм;
Кайгы килеп, башым иелсә дә,
Сөенсәм дә — җырлап җибәрәм...

Яшәсәк тә шатлык, бәхет көтеп,
Татар җыры һаман моң тулы:
Мең ел буе җанга сеңгән моңны
Мөмкинме соң инде онытуы!..

## Ноктюрн

Тау битләрен кояш үбә монда,
Нурлар сыйпый кыя яңагын.
Сандугачтан отып алган моңнар
Сулкылдата чишмә тамагын...

Томаннарның күк шәленә төренеп,
Ерак Урал ята күгәреп.
Куллар ауган таулар күкрәгенә, —
Үкенечле яшен түгәдер...

Монда Вакыт кыллы оркестрын
Җир-күк арасында уйната.
Монда Тарих — Бүгенге һәм Үткән,
Киләчәкләр — үзен уйлата...

# Басыйр Рәфыйков

## Нишләттең син, замана...

Әнкәемә эндәшергә телим,
Онытканмын... туган телемне.
Сөйләп кенә аңлатырлыкмы соң —
Төшемме бу, әллә өнемме?

Кайнашалар урыс, инглиз сүзе,
Фәләнчәсе анда бутала.

Чит телдәге фикерләрем ләкин
Туган телдә барыбер юл яра!

«Әнкәй, рәхмәт!» — дип тә
әйталмагач,
Ачы язмыш, инде шуны бел:
Хыянәттер, иң зур җинаятьтер —
Онытылса әгәр туган тел!

❁

Кайчан безнең тарих алга басар
Ак тапларсыз, ертык битләрсез?..
Тере мәет кебек кеше җирдә
Хакыйкатьсез — рухи икмәксез.

❁

Чебен җыйган чүп әрҗәсе сыман
Ларек тарта алкаш ир-атны.
Ә зур тормыш бара — урап узып
Аракыга баскан чиратны...

❁

Урак алды. Черем иткән вакыт...
Чыңлап торган чагы тынлыкның.
Җирнең, горурланып, башакларын
Күккә чөйгән чагына юлыктым.

Кырда вак борчулар юкка чыга
Җәен ялгыш яуган кар төсле.
Тик фасыллар монда алмашына,
Монда хуҗа — икмәк һәм кеше.

❁

Тетрәтмәде аны күз яшьләре —
Инсафлык та кимеп калды шул...
Каен кәүсәсенең ак тәненә
Кызганмыйча балта чапты ул.

Сыкрап торган ачык җәрәхәткә
Уйламый да сузды иренен:
Кәүсә аша эчте... һәм сизмәде
Кан тибешен туган җиренең.

---

Басыйр РӘФЫЙКОВ *(1921) — шагыйрь, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән «Җырым сиңа минем», «Кадерле минутлар» һ. б. шигырь китаплары авторы. Троицк шәһәрендә яши.*

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Нияз Акмал**

# КҮГӘРЧЕН СӨТЕ

ПОВЕСТЬ

## Кыйсса башы



ыз бала туса — шатлык, ир бала туса — горурлык...
Язның шактый борынлап килгән бер көнендә Балтамак авылындагы ике йортка әнә шундый горурлык иңде.

Малайларның берсенә Хәбир дип, икенчесенә Таһир дип исем куштылар. Ләкин әле аңынчы, исем кушканчыга кадәр, Әхмәтгали Сабирҗанов сигез чакрым ераклыктагы район үзәгеннән ат менеп, язгы пычракка бата-чума кайтып керде. Аның йөзе агарынган, өс-башы пычранып, буялып беткән, чәчләре тузган, сулышы кабынган иде.

Әхмәтгалине тәрәзә аша күреп калган хатын-кыз, күрше-күлән урамга йөгереп чыкты. Алар — сөенче алырга ашыгучылар — Әхмәтгалинең әйткән сүзен дә, биргән вәгъдәсен дә яхшы беләләр иде. «Сугыштан исән-сау кайтсам, өй тулы бала үстерер идем»,— дип нәзер әйтүен Әхмәтгали үзе сөйләп йөрде. «Монысы да малай булса, бөтен авылны җыеп кунак итәм»,— диде. Кендек әбисенә дә, сөенче алган күршеләргә дә аерым-аерым бүләк вәгъдә итте.

Әхмәтгали кара тиргә баткан атыннан сикереп төште.

— Сөенче синнән, күрше! Гөлчирәң исән-сау котылды! Малай тапты, малай!..— дип шаулашкан хатыннарны әллә күрде, әллә күрмәде — шул ук шашынган кыяфәт белән алга атлады. Бер-ике адым баргач, кинәт борылып, туктады. Йөзендә елмаю да, шатлык әсәре дә юк иде. Үзен уратып алган күрше-күләнгә озак итеп, гаҗәпләнеп карап торды. Аннан соң каяндыр эчтән, тамак төбеннән чыккан тавыш белән ярым пышылдап әйтте:

— Кайгы, җәмәгать... Сталин үлгән...

Бу — 1953 елның март башы иде. Иртә килгән язның былчырагы күзгә күренеп артты. Авыл советының кыйшайган кыегына, идарәгә, манарасы киселгән элекке мәчет бинасына — клубка, мәктәпкә, салам түбәле йортларга кара белән каймаланган кызыл әләмнәр эленде.

Авыл матәмгә батты...

Иртәгесен Әхмәтгали янына икенче бер малайның әтисе Шәкүр Корбанов килде. Өйгә керде, утырды, сүзен башлап китәлми азапланды. Ниһаять, ирләр өйдә икесе генә калгач, өзеп әйтте:

— Нишлибез, Әхмәт? Бәби туе уздырабызмы? Әллә?..

Әхмәтгали аны ярты сүздән аңлады, шундук кистереп салды:

---

Нияз АКМАЛ *(1954) — шагыйрь һәм прозаик. «Учак», «Үз урамым», «Килер бер көн» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

— Син нәрсә, Шәкүр! Ил — кара кайгыда. Мондый чакта туй уздырып бәйрәм итеп ятудан да яманрак эш булырмы?

— Анысы шулай шулаен да... Ну бит, малай туды, Әхмәт, малай! Аңлыйсыңмы?! Син үзең дә бит, авылны бер гөрләтербез әле, диган иең!..— Шәкүр әллә ничек, буылып, озак итеп юталләде.— Минем бит, үзең беләсең, беренче малай, бердәнбер малай...

Шәкүр Корбанов сугыш чыгар алдыннан гына өйләнгән иде. Яраланып, дүрт ай буе госпитальдә аунаганнан соң, буш нигезенә кайтып егылды. Аның хатыны, районнан килеп йөргән бер вәкил белән чуалып, халык алдында тәмам даны чыгып, соңыннан каядыр китеп югалган иде. Шәкүр моңа бик нык рәнҗеде, яше барса да, өйләнми йөрде, хатын-кызга ышаныч күрсәтмәде.

Ниһаять, читтән килгән укытучы кыз Хәлимә аның күңелендәге кара уйлары — хатын-кызга булган нәфрәтне куып таратты, үзенә каратты. Зурлап, туй ясап өйләнештеләр. Әйе, яңа туган малай Шәкүрнең беренче баласы һәм бердәнбере иде. Әхмәтгали аны аңлады, тик барыбер үз сүзендә калды:

— Юк, яшьти... Сиңа да киңәш итмим, үзем дә андый яман эшкә бармыйм. Ил-көн алдында да, намус алдында да оят булыр. Шундый олы кайгы килгән чакта, бөтен халык зар елаганда без генә бәйрәм ясап ятalмабыз.

— Юлбашчы үлде дип, бала тумый тормый ла инде, Әхмәт. Исем булса да куштырыйк. Бала бит ул! Аңа юлбашчы үлде ни...

Әхмәтгали Шәкүргә шундый итеп карап куйды, тегесе ярты сүздә тукталып калды, аннан соң аклангандай итеп әйтте:

— Шәп исем тапкан идек Хәлимә белән. Таһир дип кушарга исәп...

Шәкүр тагын нидер әйтмәкче булды, әмма ютәле тотып алды. Ютәлдән арынгач, Шәкүр урыныннан авыр гына кузгалды, борылып эндәшмәкче булды, әмма дәшмәде, ишеккә таба атлады.

— Бу кайгылы көннәр узсын, Шәкүр,— диде Әхмәтгали. Аның тавышы йомшарган, йөзендәге ачу галәмәте юкка чыккан иде.— Узсын... Малайлар гына исән-сау булсын, бәби туен да үткәрербез, исем куштыру йоласын да үтәрбез.

Беренче сыйныфка кергән улы Әхсән, сабактан кайткач, әйтте:

— Әти! Мәктәптә җыен булды, бөтен кеше елады, укытучылар да.

— Син еладыңмы соң, улым?

— Бик елыйсым килде, күздән яшь чыкмады шул,— диде малай, үкенеп.— Тырыштым, тырыштым — чыкмады.

Кичке якта Әхмәтгалигә укытучы Әхмәтнәҗип сугылды.

— Малаең туганын ишеттем, килеп чыгып булмады, мәшәкать күп иде, Әхмәт абый,— диде. Өч кенә яшь аерма булса да, Әхмәтнәҗип аңа «абый» дип дәшә иде. Кесәсеннән үзе белән алып килгән «чәкүшкә»сен чыгарды.— Малайның тәпиен «юып алыйк», абый...

Кече якта икесе генә калып, озак кына сөйләшеп утырдылар. Яңа туган малайдан башланган сүз шуңа — ил өстенә килгән кайгыга барып тоташты.

— Син — безгә якын туган тиешле, Нәҗип,— диде Әхмәтгали.— Монда сөйләшкән монда калсын, син анысын гына аңлыйсың. Әйт миңа, нәрсә булыр хәзер илдә? Ничек яшәрбез? Аннан башка...

Укытучы протез аягын исән аягы өстенә җайлап куйды, кесәсеннән «Север» папиросы алып, ашыкмыйча гына кабызды, табынга таралган куе зәңгәр төтенне кулы белән куды:

— Ничек яшәрбез, димә син, абый... Без инде яшәдек. Яхшымы, начармы — яшәдек! Менә, малаең туды, Айсылуың, Әхсәнең бар. Балалар... Алар ничек яшәр, диген син.

— Син инде бигрәк, Нәҗип... Безнең гомер дә башлана гына әле. Яшьлекне сугыш алды алуын, әмма гомер бар әле, яңадан башланып килә, шуңа әйтәм мин.

— Юк, Әхмәт абый. Гомер яңадан башлана алмый. Гомер бер генә: туган көнеңнән алып соңгы сулышыңа кадәр... Бары тик шулай гына. Урта бер җирдән башлана алмый ул, берничек тә башлана алмый! — Әхмәтнәҗип авыр йодрыгын өстәлгә китереп куйды.— Әткәйне алып киткән көнне минем балачагым тукталып калган. Комсомолга кергәндә мин аннан баш тарттым. Мин бит әткәйдән баш тарткан кеше, Әхмәт абый! Сугыш-

та ул минем төшкә кереп интектерде... Каядыр чакыра, баш чайкый. Менә шул... Әй безнең балалар бездән бәхетлерәк булырга тиеш. Алар инде бездән баш тарта алмас! Без алар тусын дип утка барып кердек. Без алар өчен, мең мәхшәр үтеп, исән кайттык. Безнең балалар — яңа буын, Әхмәт абый! Алар үсәр, алар турында: «Бу — Әхмәтгали малае! Бу — Шәкүр малае, бу — Әхмәтнәҗип кызы!» — дип кычкырып әйтергә тиешләр. Аларның кадере үзләреннән алда йөрергә тиеш.

— Анысын син дөрес әйтәсең, Нәҗип энем. Дөрес... Ничек яшәрбез дигән сүзем шул балаларны да уйлап инде. Сугыш-мазар яңадан чыкмасын дип борчылуым. Сталинны кем алыштырыр? Ул исән булганда дөньясы да тыныч булыр иде. Сталинсыз нишләрбез? Ил хуҗасыз тормас анысы...

Алар ярты төнгә тикле сөйләшеп утырдылар. Әхмәтгалинең Гөлчирәдән юллап алган тагын бер шешәсе яртылаш бушады. Сүзләре гел бер тирәдә әйләнде, бер тирәдә йөрде: сөйләшкәннәре яңадан балаларга, үзләре саклап калган яңа буынга, авылда бер үк көнне туып аваз салган малайларга әйләнеп кайтты. Әхмәтгали дә, Әхмәтнәҗип тә бераз иркенәйгән, күңелләре ачылган, аларның хәрәкәтенә олпатлык, кодрәтлек иңгән иде. Алар әле бу вакытта үз балалары турында, киләчәк турында зурдан кубып сөйләшәләр, фикерләренең чисталыгына, олылыгына куаналар, бер-берсен тыйнак кына мактап алалар, рәнҗетми һәм рәнҗеми генә бәхәсләшәләр иде. Алар үз балалары турында сөйләшәләр, яңа буын турында сүз йөртәләр һәм шушы буынның коммунизм төзергә, коммунизмда яшәргә хыялланачагы, үзләре өчен изге булган Сталин исеменә тап төшәчәге, шәхес культы дигән яңа сүз калкып чыгачагы, үзләре өмет баглаган буынның әзсез һәм төссез кешеләрдән торачагы турында уйламыйлар да, белмиләр дә һәм белә дә алмыйлар иде.

Берничә көннән соң авыл ишетте: Шәкүр Корбанов, күрше-күләнне, туган-тумачаны җыеп, бәби туе уздырган, Хафиз картны чакырып, улына исем куштырган.

Хафиз карт балта остасы иде. Аның әтисе дә кулыннан балтаны төшермәде, һөнәрен улына биреп калдырды. Указлы мулла булмаса да, яшен һәм дини китапларны укый белүен чамалап, картлар аны мулла санап йөртә иде. Хафиз карт авылдашларына бура бурый, мунча сала, йорт җиткезеп бирә, кирәк икән, йола хезмәтләрен дә үти. Корбановларга ул ялындырмый килде. Шәкүр белән Хәлимәнең сабый баласына, йоланың бөтен шартын туры китереп, Таһирҗан дигән исем кушты. Әмма аның алдан сөйләгән нотыгы бу юлы башкачарак иде:

— Олы атабыз, юлбашчыбыз Сталин вафат булган бу кайгылы көннәрдә, җәмәгать, авылыбызда ир балалар туды. Алар даһи Сталинның бөек эшен дәвам итүчеләр булсын. Амин, шулай булсын!..

Тиешле догаларын укып, йоланы башкаргач, Хафиз карт бөтенләй үзгәрде. Әйтерсең, ул хәзер авыл мулласы түгел, ә бәлки балта остасы булып йөргән гап-гади бер карт иде. Хәлимәнең кулыннан сабыйны алып, күкрәгенә кысты:

— Әй, бала!.. Бу фани дөньяга килү — үзе бер олы бәхет. Кешенең кадере булмаса, бәхетнең китеге генә кала. Ата-ананың кадерен белеп, үзеңә дә кадер-хөрмәт күреп яшәргә язсын... Амин, шулай булсын!..

Малайлар үсте, тәпи басты...

Зур булмаган авылларда кайсы йортта нинди бала үсүен белеп торалар. Шәкүрнең хатыны Хәлимәгә дә:

— Таһирыңны әйтәм, ахирәт. Тфү-тфү, күз тимәсен, бигрәк тә сөйкемле инде, бигрәкләр дә акыллы, валлаһи, галим булыр бу! — дигән сүзләрне күп ишетергә туры килде.

Шулай да, авылда Таһирны иң якын иткән кешеләрнең берсе балта остасы Хафиз карт иде. Кайчак шулай балта остасының бура бурап яткан җиренә килеп чыга малай. Озак кына, дәшми-тынмый гына, аның эшләгәнен карап тора. Хафиз карт малайның янәшәдә икәнен сизә, күрмәмешкә салыша. Малай түзми, монда булуын белдереп, борын тартып куя. Балта остасы, эшеннән бүленмичә генә, сәламен юллый:

— Ә-ә, килдеңмени, таз баш?! Ата казыгыз күкәй саламы соң?

— Салмый шул...

— Алайса, начар икән.

— Начар шул...— малайның тавышында үкенү сизелә. Әйтерсең, ата казларының күкәй салмавына ул үзе гаепле. Балта остасы аның беркат-

лылыгыннан рәхәтләнеп көлә, балтасын бүрәнәгә чабып, кесәсеннән махра янчыгы чыгара. Бу инде аның бераз хәл алырга тукталуы. Малайга шул гына кирәк:

— Ә син нәрсә саласың? — ди.

— Торырга йорт салам, таз баш. Шәп йорт булачак!

— Ә нигә агачтан саласың?

— Һы, менә кәмит! Бүрәнәдән салмый, тагын нәрсәдән саласың йортны?

— Ә шәһәрдә таштан салалар. Укытучы Нәҗип абый әйтте.

— Шәһәрдәме? — балта остасының кашлары җыерылып куя, бүрәнәгә чапкан балтасын кире тартып ала.— Шәһәрдә анда — башка чут. Йортның аның нигезе булырга тиеш. Һәр нәселнең, һәр гаиләнең үз нигезе. Ә шәһәрдә анда... Бер нигездә яшиләр, үзләре бер-берен дә белеп бетермиләр. Анда бит бер йортка бер авыл сыеп бетә! Ничек итеп ашатып бетермәк кирәк ул тиклем халыкны?..

— Ә сыерларын кая куялар?

— Нинди сыерларын тагы? Кемнәр?

— Теге... Бер авыл сыеп беткән йортта торучылар?

Хафиз картның әле генә ачудан җимерелгән кашлары дерелдәп китә, башын артка ташлап, рәхәтләнеп көлә:

— Сыерларын кая куялар, дисең инде?! Сыерларын! Ну, таз баш, әйтеп тә куясың инде үзең, ә?! Баш та бар икән үзеңдә! Әйтте диярсең, зур кеше булырсың, галим булырсың син! Мә, тотып кара балтаны. Аягыңа чапма түлке! Бу балтаны әле беркемгә дә тоттырган юк минем.

Кулына балта эләккән көнне малай өенә кош тоткандай очынып кайта.

...Хафиз картның сүзләре акланды. Таһир Корбанов белән Хәбир Сабирҗанов, авылдан беренче булып, бөтен күрше-тирәне шаккатырып, югары уку йортына барып керделәр. Таһирны — университетка, Хәбирне төзүче инженерлар әзерләү институтына авыл горурланып озатты.

Ләкин бу шатлыкны Шәкүр Корбанов үзе күрә алмады. Аның турында: «Сугыштан калган ядрәсе кузгалган икән»,— дип сөйләделәр. «Теге вакытта районда сорау алганда бик нык тунаганнар икән, шуннан мантымады»,— дип тә әйткәләделәр. Шәкүрнең баш очында Хафиз мулла ясин чыкты. Этисенең кабере өстендә үксегән Таһирны да ул үзе култыклап алып кайтты:

— Елама, улым...— диде.— Корбановлар нәселе елак булмады...

Таһир университетка этисен җирләгән җәйдә барып керде.

* * *

...Кыш килә дип кенә торганда кинәт яңадан җылытып җибәрде. Мәскәү урамнары тайганакка әверелде. Көннәр әллә ничек шыксыз, килбәтсез һәм эчпошыргыч иде.

— Һава бозылды... Көн бозылды. Табигать бозылды...— дип сөйләнде Мәскәү халкы. Троллейбустан төшкән ир әлеге сүзләрне гамьсез генә тыңлап барды.

Аның янәшәсеннән дүрт-биш яшьлек кызчык атлый. Шулай дәшмичә генә шактый ара баргач, ир әйтте:

— Менә, кызым, тагын бер генә җиргә кереп чыгабыз да, аннан соң инде безнең мәсьәлә хәл ителә,— диде.

Алар «СССР Тышкы эшләр министрлыгы» дигән язулы йорт каршына килеп туктадылар.

Керергә рөхсәт кәгазе тутырып алганнан соң, кызын җитәкләп, әлеге ир икенче катка илтүче баскычка таба китте. Ләкин аны сакта торучы туктатты:

— Пропуск!

Ир кулындагы кәгазьне күрсәтте. Сакчы әле язуга, әле иргә карап торганнан соң кызга күз төшерде:

— Баланы монда калдырыгыз. Аңа пропуск бирелмәгән.

— Ул ялгызы иялэшмәгән, елар, борчылыр,— диде ир.— Рөхсәт итегез, зинһар?..

— Аңа пропуск бирелмәгән,— дип кистереп кабатлады сакчы.— Бу — балалар иләртеп йөри торган урын түгел, өйдә калдырырга иде!

— Минем калдырыр урыным да, таныш кешем дә юк әле. Без читилдән генә кайтып төштек.

— Баланы монда калдырып торыгыз,— дип кабатлады сакчы.

Ир кызына таба иелде:

— Көтеп тор, кызым, яме? Мин тиз чыгармын. Инде барысы да әйбәт, кызым. Без инде туган илгә кайтып җиттек...

Ярты сәгатьтән әлеге ир кире әйләнеп чыкты. Почмактагы урындыкка сыенып утырган кызы янына атылып килде.

— Булды, кызым... Безгә ял итәргә кирәк икән әле. Хәзер инде авылга, әби-бабай янына кайтырбыз, кызым...

Алар урам буйлап җәяүләп киттеләр. Ир, урам чатында «Почта — телеграф» дигән язу күреп, шунда таба борылды:

— Телеграмма сугыйк, кызым. Кайтуыбызны белеп торсыннар, шулай бит!

Ир телеграмма кәгазенә тиешле адресны язды. Бераз уйланып торды. Аннан соң кыска гына итеп язып куйды: «Тиздән кайтып җитәбез. Юлга чыктык. Хәбир».

Әйе, бу — Хәбир Сабирҗанов иде. Әйе, бу вакытта инде Хәбирнең — кызы, Таһирның малае бар иде.

Кыз бала туса — шатлык, ир бала туса...

Хәбир Сабирҗанов, телеграмма сукты да, өстеннән ниндидер бер авыр йөк төшкәнен сизеп, җиңеләеп калды. Хәзер инде «Татарстан» поездына билет аласы гына калган иде.

## I

Янгын көпә-көндез, барча халык аяк өстендә чакта калыкты. Аның очынып-очынып үрләгән ялкынын, каралып-корымланып күтәрелгән куе төтенен ындыр табагында, фермада, басу-кырда эшләүчеләр дә күрде. Кем ничек булдыра алса, шулай ашыкты: ат менеп тә, машина-тракторга төялеп тә, җәяүләп тә ут чыккан якка — авыл үзәгенә таба чапты.

Әле генә тып-тын калып, сентябрьнең соңгы чилләсендә изрәп яткан авыл шау-шуга күмелде, кычкырышкан авазлар белән тулды:

— Кемнәр яна? Кем йортына капкан?!

— Әхсәннәр яна бугай! Валлаһи, шулар!..

— Бүтән йортларга каба күрмәсен, ходаем!

— Ялкынын күр син, ялкынын! Бөтен авылны урый бу болай булса!..

— Әхсәннең үзен районга китте, дигәннәр иде бит...

Янгын сүндерергә ашыккан халык бер-ике генә чиләк су сибеп өлгерде: Әхсән Сабирҗановларның йорты, каралты-курасы күз алдында шартлап-шатырдап янып та бетте. Янган өй урынында пыскып-корымланып торган кисәүләр генә ятып калды.

Бәхеткә, ут башка йортларга үрләмәде. Чиләк-көрәк күтәреп чабышкан, бу көтелмәгән хәлдән каударланган халык, ниһаять, бераз исенә килде, төркем-төркем булып җыелышты, бу афәткә бәя бирде.

Урамның каршы ягындагы капка төбендә утырган Әхмәтгали картны шунда гына шәйләп алдылар. Карт, ниндидер төенчекне кулына кысып, утыргычта тыныч кына йокымсырый кебек иде. Йорт хуҗаларының хәленә керергә тырышкан халык, бигрәк тә хатын-кыз, Әхмәтгали картны сырып алды.

— Әйберләрегезне дә алып чыгалмый калдыгыз бит, мулла абзый! Йортыгыз нык иде, таза иде, яңасын ничекләр җиткерерсез?!

— Әле ярый көндез булды, диген!

— Әй, ходаем, олы бәла килде гаиләгезгә, Әхмәтгали абзый!..

Әхмәтгали карт, кулындагы төенчеген кысып, урыныннан күтәрелде:

— Күрәсе каза булгандыр, җәмәгать. Баш исән булсын...

Ул арада каяндыр Гөлчирәтти пәйда булды. Килене Сәҗидә аның каршысына атылды:

— Әй, әнкәй, кайларда йөрисең син?! Тәмам югалттык сине, борчылып беттек!..

— Югалмадым, килен,— Гөлчирәтти картыннан да тынычрак күренде.— Нишләп югалыйм ди мин? Тавыкларны караштырып йөрдем. Уттан куркып, кайсы кая таралышып беткәннәр, мескенкәйләрем!

Хатыннар дәррәү сүзгә кушылды:

— Әй, Гөлчирәтти! Тавык кайгысымыни хәзер?! Йортыгыз янды, аб-

зар-курагыз кара күмергә калды. Ә син тавык кайгыртып йөрисең!

— Нишләп тавык кына кайгыртыйм ди мин?! Күршеләрнең дә ындыр артын карап чыктым: ут-мазар төшмәгәнме, минәйтәм... Күрәсе каза булгандыр инде бу, җәмагать, күрәсене күрми, гүргә кереп булмый, ди китап.

Мотоциклын яман каты чаптырып, Әхсән Сабирҗанов үзе дә кайтып җитте. Ул инде хәвефле хәбәрне юлда ук ишетеп өлгергән иде. Җыелган халыкны ерып, туп-туры этисе каршына килде:

— Барыгыз да исән-саумы, эткәй?!

Карты өчен Гөлчирәтти җавап кайтарды:

— Аллага шөкер, улым, исән-саулар. Балалар — мәктәптә, килен эштә, фермада иде. Без дә, атаң белән, бакчада булып калдык, умарта карый идек. Ут сүндерергә килгән авылдашларга да, аллага шөкер, андый-мондый зыян булмады. Эштән генә аерылдылар менә...

Әхсән Сабирҗанов көеп-каралып яткан нигезгә карап торды. Аннары кулын селтәгәндәй итте:

— Ярар, мунчасы бик искергән иде инде...

Моны ишеткән халык «аһ» итте: бәла килгәндә күтәрелеп бәрелмәгән, башны ташка ормаган холыкка гаҗәпләнү дә, аптырау да, соклану да бар иде бу авазда.

Урамның аргы башында әче итеп сызгырткан, улаган тавышлар ишетелде. Район үзәгеннән җибәрелгән янгын сүндерү машиналары, гүләп, авылга кереп килә иде.

Ул кичне халык капка төбеннән кермәде. Көтү кайтты, савылмаган сыерлар хатыннарның, киленнәрнең йомшак кулын көтеп зарыкты, сабырсызланып, тынгысызланып мөгрәде. Капка төпләрендә төркем-төркем булып җыелышкан халык телендә һаман шул бер вакыйга — Әхсән Сабирҗановлар гаиләсенә килгән афәт булды.

— Сарыкларын кемгә керттеләр икән соң? Сыерларын күрше Әсмаларга япканнар бугай.

— И, сыер-сарык кайгысымыни аларда хәзер?! Үзләренә түбә кирәк.

— Кайда тукталдылар икән соң?

— Кайда булсын, киленнең әнисендәдер. Ул берүзе, өе дә, күңеле дә киң, дигәндәй. Кодагыйларына бармый, кая барсыннар?

Мондый сүзләр дә булды:

— Мулла абзыйның кулында төенчек иде. Шуның эче тулы кәгазь акча булган, ди. Шуңа күрә бер дә исе китмәгән йортлары янганга. «Берсе янса, икенчесен, тагын да шәбрәген салабыз аның, боерган булса»,— дип әйтеп әйтә, ди.

— Булыр шул, мулла кешедә акча бетәмени?!

— Юкны сөйләмәгез лә инде! Нинди мулла булсын ул Әхмәтгали абзый? Картлар кушканга гына йөри. Ә акчасы бардыр: үзләре пенсия ала, умарта асрый. Әхсән дә, киленнәре дә эшләп тора. Тагын ни кирәк?

Сабирҗановлар, чыннан да, Саҗидәнең әтисе йортында тукталдылар. Ләкин әле аңынчы, бөтен гаилә бергә җыелганчы, шактый вакытлар үтте, бихисап мәшәкатьләр баш калкытты. Көтүдән кайткан малларны җыеп ябу, абзарларга урнаштыру үзе бер бәла булды. Янган-көйгән исне сизеп көйсезләнгән сыер, үз ихатасын таба алмыйча интегеп, чит капкага якын барырга теләмәде. Сарык бәрәннәренең яртысы урамда калды, качып, таралышып бетте. Әниләреннән адашып калган яшь бәрәннәрнең ялварулы тавышы ярты төнгә кадәр ишетелеп торды.

Ниһаять, барысы да җыелышты. Бәла килде дип эш ташламаган, фермага кичке савымга барып кайтырга өлгергән Саҗидә монда да алны-ялны белмәде: килен кайда да килен булып кала дигән сүзне холык-фигыле белән җөпләп, табын әзерләде, урын-җирне карады. Әллә инде нәкъ менә үз өендә — кыз чагындагы йортта булганга, үзен аеруча бер җаваплылык белән тотты, кабаланды, ашыкты, әрле-бирле йөрде — ирен, балаларын, каенанасы белән каенатасын җайлырак, уңайлырак урнаштырырга, тәмлерәк ашатырга, татлырак сүзләр белән юатырга тырышты. Үзе һаман берөзлексез сөйләнде:

— Урын барчабызга да җитә. Әнкәй, эткәй, сезгә түр якка җәйдем. Түшәкләр йомшак, рәхәтләнеп йокларсыз. Без, балалар белән, идәндә урнашырбыз. Урын җитә, борчылмагыз. Кышны рәхәтләнеп чыгалабыз. Иртә яздан башласак, киләсе көзгә тикле өйне ничек тә җиткерербез, шулай бит, Әхсән?

Сажидә, балаларын кул-канат астына алып, иренә төбәлде. Әллә инде аны шул куркынып, тынып калган балаларның тән җылысын тою йомшартты, әллә бу мәхшәрле көннең бар авырлыгы менә хәзер, тынып-тукталып калгач кына бәреп чыкты — Сажидә, тыела алмыйча, әкрен генә сулкылдый башлады.

— Килен! — Моңарчы дәшми-тынмый утырган Әхмәтгали картның тавышы шактый кырыс чыкты.— Сабыр ит, килен. Киңәшләшеп алыйк.

Сажидә күз яшен тыйды, сулкылдавыннан туктады. Гаиләдә беләләр иде: киңәшү сүзен карт бик сирәк әйтә, бик четерекле мәсьәләләрне хәл итәсе булганда гына телгә ала. Мондый чакта ул сүзне үзе башлый, үзе алып бара, әмма аның һәр җөмләсе, һәр хәрәкәте бу гаиләдә төп кеше Әхсән икәнлекне белдереп тора.

Өйдә тынлык урнашты. Кан тамырлары чуарлаган кулларын өстәл өстенә куйган Әхмәтгали карт, фикерләрен тупларга теләп, бер ноктага төбәлеп торды.

— Шулай итеп, балалар, йортыбыз янды. Җиһазларны, кием-салымны, кирәк-яракны чыгарып өлгермәдек. Әйе... Абзар-кура, мунча янды, алты баш умарта янды. Башка умарталарның, белмим, ояляры исән-сау микән... Үзебез, шөкер, исән. Бәла килде дип, балавыз сыгып утырып булмый. Яшәү турында уйларга кирәк...— Карт, «дөрес сөйлимме?» дигәндәй, тыңлаучыларга карап алды.— Иң беренче эш итеп, малларны ныклап урнаштырырга кирәк. Аннан соң, балаларның сабагын өзмәү шарт. Кодагыйның күңеле дә, өе дә иркен, барыбызны да сыйдырыр. Әмма дә ләкин тормыш әле ул яту-тору, ашау-эчүдән генә тормый. Балаларның мәктәпкә йөрисе, сабак аласы, дәрес карыйсы бар...

— Бабай! Син минем китапларны алып чыкмадыңмы соң?

— Китаплар? — Әхмәтгали карт, бу көтелмәгән сорауга гаҗәпләнеп, оныгына карады. Үзе, ирексездән, каршысында — өстәлдә яткан төенчегенә кагылып куйды.— Нинди китаплар?

— Соң, китаплар инде! Дәрес әзерләргә кирәк бит!

Әхмәтгали карт башын чайкады:

— Юк, кызым, сезнең китапларны алып өлгермәдем. Мөгаен, өлгермәс тә идем...— Һәм ул, ни өчен өлгерә алмавын аңлатырдай сүзләр эзләп, як-ягына каранды, янә әлеге төенчегенә кагылды. Әмма ут-төтен эченә ничек кереп китүен, өйнең түр почмагындагы олы сандыкны көч-хәл белән ачып, шушы төенчекне табып алуын, сулышы-тыны бетеп, урамга атылып чыгуын аңлатырдай сүзләр таба алмады. Аптырагач, төенчеген чиште.— Менә, шушыларны гына алып өлгердем, кызым...

— Бу нинди китаплар соң, бабай?

Сажидә, башкаларга сиздерми генә, кызының җилкәсенә төртте:

— Тик кенә тор! Бабаң китаплары алар...

Әхмәтгали карт килененең сүзләренә игътибар итмәде, оныгын үз янынарак тартты:

— Менә, бер вакыты чыгып, икегезгә дә күрсәтермен, сөйләрмен әле,— диде.

Бу төенчектә искечә язулы китаплар саклануын Әхсән белә иде. Шулай, кызыксынып китеп, малай чакта үзләренең шәҗәрә язуын өйрәнгән, ә әтисе барысын күрсәтеп, сөйләп-аңлатып барган иде.

Нәкъ менә шуны искә төшерү аның үзен дә, күрәсең, баласытып җибәрде, әйтеп ычкындыруын сизми калды:

— Их, техникум китапханәсеннән алган китаплар да янды инде!.. Имтихан вакытында биреп торганнар иде...

Монысы инде артыккарак китте. Әмхәтгали карт кырысланды, төенчеген ябып куйды:

— Ачуланма, улым, башка нәрсәләрне алып өлгермәдем,— диде. Бераз сүзсез торгач, йомшаграк эндәште:

— Шулай итеп, балаларның сабагын өзмәскә кирәк. Аларны укытучы Әхмәтнәҗипкә чыгарып торырбыз. Ул безгә чыбык очы туган тиешле, карендәш. Каршы килмәс. Үзе дә, җәмәгате дә пенсиядә, балалары читтә, вакытлары да, урын-җирләре дә иркен, мәктәпкә якын торалар...

Инде килеп, улым, килен эштә иде — эш киемнәре белән генә торып калды. Йорт янды дип, кеше алдында ким-хур булып йөрмәс, кешелеккә киярдәй кием алып, аның өс-башын карарга кирәк.

— Әй, әткәй, нәрсәгә әле миңа кием? Кая барасым бар ул кадәр?! —

картның беренче булып үзе турында кайгыртуына күңеле тулган Сәҗидә күз яшен яулык очы белән басты.— Эш киемем бар, бик җиткән...

— Син, улым, районда идең,— дип дәвам итте Әхмәтгали карт.— Киенеп-ясанып киттең. Сиңа инде фермага кияргә генә эш киеме юнәтү әллә ни авыр булмас.

— Миңа, әткәй, ферма киеменең кирәк булмавы да бар әле...

Карт улының бу сүзләренә игътибар итмәде:

— Инде йорт мәсьәләсенә килгәндә, улым, анысын озакка сузмаска кирәк. Син эшләп торасың, киленнең дә хезмәт хакы мул. Анаң белән миндә дә касса акчасы юк түгел. Бүген-иртәгә дөнья куярга дип тормыйбыз, җыйганын чыгарырбыз. Кирәк булса, сыерны да сатарбыз. Әмма дә ләкин кышка йортсыз керү ярамас. Барыбыз да ныклап керешсәк, боерган булса, кышны үз нигезебездә каршыларбыз. Сиңа, улым, эшеңнән ял сорап торырга туры килер. Бөтен ышаныч синдә, улым.

— Ялны, мөгаен, бирмәсләр аны, әткәй.

— Нишләп икән? Фермада сине алыштырып торыр кеше табылмас микәнни?

— Эш анда түгел, әткәй. Үзең беләсең, мине бүген районга чакырдылар, райкомга. Сүз булды анда. Колхозның партия оешмасы секретаре итеп тәкъдим итмәкчеләр мине. Ашыктыралар. Партия кушуы буенча, диләр. Каршы килеп булмады, ризалык биреп кайттым...

Әхмәтгали карт улына сынаулы караш ташлады, Әхсәннең бая әйткән сүзләренә шунда гына ныклап игътибар итте. «Кара син аны,— дип уйлап куйды.— Фермага йөри торган киемнең кирәге булмас, имеш. Һы, ә үзеңнең абзарыңдагы малны кем карар? Авыл җирендә эш киеменең кайчан әле кирәксез булганы бар?..» Әмма бу уйларын сиздермәде Әхмәтгали карт. Бераз тын калып, уйланып торгач, әйтте:

— Алайса, улым, чынлап та, ял бирмәсләр шул. Бирмәсләр... Әмма йортны кышка кадәр ничек тә җиткерергә кирәк. Бөтен ышаныч синдә, улым...

## II

Вокзалда «Ашыгыч ярдәм» машинасы көтеп торырга тиеш иде. Хәбир, бөтенләй сабырсызланып, тәрәзәгә капланды. Поезд Казан елгасы күперенә кереп бара иде.

— Вагон номерын беләләрдер инде?

Хәбир белән бер купеда кайтучы Ахо аның үзалдына гына әйткән бу сүзен эләктереп алды:

— Белерләр, белми кая барсыннар! Алар, туганкаем, утырган урыныңа кадәр белеп тора.

Моңарчы күңелле генә кайткан Ахо нигәдер сабырсызлана, борчыла сыман иде. Ахо Хәбирнең кызы Розалия белән бик тиз дуслашып алды. Тәрәзәдән күренеп калган авылларны, станцияләрне күрсәтә-күрсәтә, аны юл буе таныштырып кайтты. Әллә тәрәзәдән җил бәрде, әллә вокзалда чакта салкын тиде — таң алдыннан сабый шабыр тиргә батып, ут кебек янып уянды.

— Шул кара мөртәтләрнең генә күзе тиде балага,— диде Ахо, Хәбирнең уйларын сизгәндәй.— Яратмыйм, күзләре яман шул эттән туганнарның!..

— Алар монда озак тормады ич,— диде Хәбир, Ахоның чегәннәр турында әйтүен аңлап. Поезд Мәскәүнең Казан вокзалында торган чакта купега бер төркем чегән хатыннары кереп тулды. «Казангамы? Әй, алланың рәхмәте! Үзебезнең якташлар икән!» — дип, аркаларындагы йөкләрен, юл капчыкларын бушата башладылар. Бу көтелмәгән кунакларны чыгарып җибәрү мөмкин булмас кебек иде. Әмма Ахо тырышты, тавыш куптарды, проводницаны чакырды, тегеләрне эткәләп тә, төрткәләп тә куып чыгарды. Чегәннәр каргый-каргый чыгып киттеләр.

— Барыбер,— диде Ахо ачу белән.— Яратмыйм шуларны. Кинода гына күрсәтәләр ул: имеш, атлар, учак, мәхәббәт, чегән романтикасы! Бетте инде ул чын чегәннәр. Болары — дөньяга яраклашып барган спекулянт калдыклары, адәм хурлыгы!

Хәбир көлемсерәп куйды. Кайчандыр чегәннәр үзен дә төп башына

утырткан булсалар да, ул күңелендә бу халыкка үч-үпкә сакламый иде. Әлеге алдану аның язмышында ниндидер бер серле мәгънәгә ия сыман булып калды.

Ул чакта Хәбир, Минзиләне каршы алырга дип, аэропортка барган иде. Самолет килде, Минзилә килмәде. Хәбир икенче рейсны көтеп калды. Көнен, самолет рейсын, очу вакытын әйтеп хат язган иде Минзилә. Бәлки билет булмагандыр? Бәлки?.. Менә шушы «бәлки»ләр белән тәмам пошаманда йөргәндә, аны чегән хатыннары урап алды.

— Сабый бала хакына ун тиен бирче, егеткәй? — Бер кулына баласын кысып, икенче кулын алга сузган яшь кенә хатынның күзләре мөлдерәмә тулган иде. Хәбир кесәсендәге көмеш акчаларның барысын да хатынның учына салды. Ләкин кузгалып китәргә өлгермәде, янәшәдәге хатыннарның иң өлкәне аның йөрәгенә уклы сүз кадады:

— Юкка көтәсең, егетем... Килмәс синең кызың, килмәс! Һәм син аны бүтән беркайчан да күрмәссең. Арагызга ятлар керер!..

Хәбир, гаҗәпләнеп, хатынның күзләренә карады. Аның Минзиләне көтеп йөргәнен бу чегән хатыны каян белгән? Ничек инде ул, килмәскә тиеш? Ничек инде, арага ятлар керер?

— Ышанмыйм...— дип пышылдады Хәбир.

— Сал, егетем, учыңа кәгазь берлек. Мин сиңа бөтен язмышыңны әйтеп бирәм. Син юлга бәхет эзләп чыккансың. Шуңа күрә дә казна йортын ташлап киткәнсең... Сал, егетем, учыңа тагын бер кәгазь акча!..

«Каян белгән бу хатын минем институттан киткәнне?» — дип уйлады Хәбир, кесәсеннән тагын акча чыгарып. Ә хатын дәвам итте:

— Сиңа, егетем, зур хыянәтне күтәрергә туры килер. Бер көн килеп, бәхетле булдым, диярсең. Әмма ул синең кайгы-хәсрәтең булып чыгар. Сине гомер буе җан әрнүе эзәрлекләр. Бәхет сиңа, күгәрчен сөте сыман, аз-азлап кына тамар...

Ул көнне чегән хатыннары Хәбирнең кесәсендәге соңгы акчаны алып калдылар. Алардан арынып бераз баргач, зиһене ачылып, шундый уй килде Хәбиргә: «Тукта! Алдаганнар ич алар сине! Кызың килмәс, имеш... Нәрсәсе бар соң әле моның?! Синең аэропортта әрле-бирле йөргәнеңне күреп-күзәтеп торганнар. Ә аэропортта шулай йөргән кеше кемнедер көтә. Синең кебек яшь егет, әлбәттә, кызын көтәргә мөмкин! Их, ташбаш! Моны гына белү өчен чегән булып торасы да юк ич!..» Хәбир ашыгып кире борылды, әлеге хатынның каршысына килеп басты:

— Кайтарыгыз минем акчаны! Сез барысын да алдап кына әйткәнсез! — диде.

Чегән хатынының күзләре көлемсерәп куйды:

— Нәрсәгә сиңа ул акча, егеткәем?! Хәзер сиңа акча кирәкми. Солдатта сине хөкүмәт ашатыр...

Хәбир яңадан авызын ачып калды. Чегән хатыны аның институттан китүен дә, армиягә чакырылуын да белгән! Димәк, Минзилә хакында да дөресен әйтә... Ул, яшен суккандай миңгерәүләнеп, артка чигенде. Китәр алдыннан кинәт борылды:

— Ә нигә сез мине гомер буена бәхетсез булыр дисез? Ни өчен?

Чегән хатыны якынрак килде:

— Мә, бер тәңкә акчаңны кире ал, әбәт ашарсың.

Хәбир үзенә таба акча сузган кулны кире этте дә аэропорттан чыгып чапты.

Тулай торакка кайткач, уйланып ята торгач, әлеге хатынның сүзенә ышанмаслык тагын бер шик тапты табуын: аның кесәсеннән, акча белән бергә, хәрби хезмәткә чакыру кәгазе дә юкка чыккан иде. Кем белә, бәлки ул кәгазьне дә, сиздермичә генә, кесәдән алганнардыр? Монысы инде Хәбир өчен сер булып калды. Әмма шунысы дөрескә чыкты: берничә көнгә дип авылга кайтып киткән Минзилә Хәбирне солдатка озатырга килеп җитә алмады. Һәм алар шуннан соң беркайчан да очрашмадылар...

Поезд тизлеген киметә башлады.

— Вакыттыр, мөгаен. Ахо, сез минем әйберләрне алып чыгарсыз, булышырсыз инде, ә?

— Иа хода! Бу хакта сүз булырга мөмкинме соң?! Син, туган, сабыйны гына кара, башкасы өчен бер дә борчылма.

Ахо, купе ишеген ачып, үзенең көр тавышы белән бөтен тамбурны яңгыратты:

— Әй, гражданнар! Юл бирегез! Авыру баланы «Скорый» машинасы көтә!

Әллә Ахоның тавышыннан өркеп, әллә чыннан да хәвеф барлыгын аңлап, чыгу юлына өелешкән пассажирлар як-якка тайпылды.

— Розалия... Кайтып җиттек, кызым. Казанга кайтып җиттек!

Сабый керфекләрен хәлсез генә күтәрде, иреннәрен кыймылдатты:

— Әтием...

«Ашыгыч ярдәм», чыннан да, аларны вагон төбендә үк каршы алды.

— Авыру сабый шушымы? Сабирҗанов сез буласызмы? Машинага!— врач арттан авыр-авыр чемоданнар сөйрәп килгән Ахога сораулы караш ташлады.— Сез бергәме?

— Әйе, бергә.

— Машинага!

Җыелып өлгергән халыкны як-якка аерып, машина шәһәр үзәгенә таба ыргылды.

## III

Көз айлары мәшәкатьләр белән үтте. Соңлап тәмамланган урак, өзмәс-куймас сибәләп торган яңгыр астында барган басу-кыр эше, колхоз һәм авыл тормышы Әхсәнне яңа вазифасы белән бергә бөтереп алды. «Бөтен ышаныч синдә, улым»,— дип өметләнгән Әхмәтгали карт йорт салуның барлык мәшәкатьләренә үзе җигелергә мәҗбүр булды. Юк, улына үпкәләмәде, рәнҗемәде ул: шыгырдап торган нарат бура табып кайтаруына мең рәхмәтләр укып, калганына инде үзе кереште. Осталар яллау, аларны ашатып, көйләп эшләтү, кирәк-яракның эресен-вагын дигәндәй табып тору кебек эшләрнең һәммәсе дә карт белән карчык һәм килен җилкәсенә төште. Кайда гына, кем булып кына эшләсә дә үзен аямаска күнеккән Әхсән Сабирҗанов бу көннәрдә, әйтерсең, үзенең гаиләсен, салынып-күтәрелеп яткан бурасын, хатынын һәм балаларын онытты. Әлбәттә, йорт салучылар янында сирәк булуын, төп авырлыкны картлар һәм хатыны җилкәсенә калдыруын ул үзе дә аңлап-белеп тора, шуңа үртәлә иде. Әмма аның өчен иң кыены башка нәрсә иде; яңа эштә көч-куәт белән генә алдырып булмаганын, тәҗрибәнең дә, белемнең дә, тагын әле бик күп нәрсәләрнең дә җитеп бетмәгәнен сизеп-тоеп йөрде ул.

Әнә шулай үзенең кем икәнен, нәрсә эшләргә тиешлеген анык кына белми, белә алмый йөргән көннәрнең берсендә, балаларны күрергә дип, Әхмәтнәҗип абыйсына барып чыкты. Капка төбенә килеп җиткәч, кинәт кылт итеп исенә төште: Әхсән Сабирҗанов партиянең башлангыч оешма секретаре итеп сайланган җыелышта өлкән коммунист Әхмәтнәҗип Сәлимов катнашмаган иде. «Анысының да сәбәбен сорармын»,— дип уйлап куйды Әхсән. Ләкин сорарга базмады: кайчандыр үзен укыткан бу кешенең алдына килеп баскач, ниндидер зур гаебе бар кешегә әйләнде дә куйды. Әйе, еллар буе нәрсәдер эшләнгән, эш артыннан куылган, шушы йортка хәл белергә дә керелмәгән, читтән генә исәнләшеп узылган. Хәер, кергәне булган аның бу йортка, булган... Техникумнан имтихан алдыннан бирелгән курс эшләрен үзе генә башкарып чыга алмаган чакларында килә иде монда Әхсән. Һәм менә ул тагын шушы йортка аяк басты. Укытучының протез аякларын авыр шыгырдатып урыныннан кузгалуын, ябык, сөякчел кулларын сузып күрешүен, йомылып, кечерәеп калган гәүдәсен, нурлары сүрәнләнә төшкән күзләрен, битараф-гамьсез булып тоелган йөзен күрде. Ул көнне алар аз сөйләштеләр. Әмма Әхсән тойды: Әхмәтнәҗип абыйсының уй-сөреше, бик катлаулы булып тоелган нәрсәләрне гади генә итеп аңлата белүе, тәҗрибәсе, белеме аңа бүген сулар һава кебек үк кирәк икән бит. Шуны сиздә Әхсән, уйлап-уйлап йөри торгач, янә шушы йортка килеп керде. Килеп керде дә, туп-туры әйтте:

— Абый, син — мине мәктәптә укыткан кеше. Менә, ачуланмасаң, тагын синнән өйрәнергә килдем,— диде.

— Ничәмә-ничә еллардан соң шулай дип килгәнсең икән — йә мин сине бик начар укытканмын, йә бик яхшы,— диде укытучы.— Ничек икәнен нәрсә өйрәнергә килүең күрсәтер анысы... Техникум тәмамлап йөрисең дип ишеткән идем?

— Килүемнең хикмәте башкачарак иде, абый...

Әхсән, дәрескә кергән бала сыман каушап, гозерен аңлатты. Үзе, бу ни әйтер дип, укытучыга төбәлде.

— Син, Әхсән энем, бик үк дөрес килмәгәнсең бугай. Мин бит сине математикадан укыттым. Партия эшләрендә нәрсәгә өйрәтә алырмын икән мин?

Әхсән нәкъ шуннан — укытучының кире кагуыннан курыккан иде. Аптырап калды. Аннан соң кинәт исенә төшкәндәй, сорап куйды:

— Мине сайлаган җыелышта син булмадың, Әхмәтнәҗип абый...

— Мин, энем, җыелышларга күптәннән йөрмим инде.

— Ничек?

— Картлар алар үзләренчә, дигәндәй. Карт кеше беркемгә дә кирәк түгел инде ул...

Әхсән нидер әйтмәкче иде, тукталып калды, күз алдыннан мәктәп еллары, дәресләр, шау-шулы тәнәфесләр үтеп киткәндәй булды. Укытучы, аның уйларын сизгән кебек, әйтеп куйды:

— Дәресләрне хәтерлисеңме син?

— Хәтерләмәскә инде, Әхмәтнәҗип абый!— Әхсән балаларча кычкырып җибәргәнен сизми калды.— Ну интектерә идең син безне!

— Интектерә идемме?

— Соң инде! Дәрескә керәсең дә: «Иә, ташбашлар, ике икең ничә була?»— дисең. Без билгеле: «Дүрт!»— дип кычкырабыз. «Әйе, кичә дүрт иде, ә бүген ничә?»— дисең, күз дә йоммыйсың бит! Шуннан соң инде алдынгы укучылар да аптырашта кала. Уйларга кирәк бит: үзгәрмәгәнме кичәге сан?

Икесе дә елмаешып куйдылар. Ялганмас кебек тоелган сүз дә үз җаена кереп китте. Мәктәп, дәрес сүзләрен ишетү, күрәсең, укытучының күңелен кузгатты: йөзенә ниндидер бер матурлык кунды, ихласлык йөгерде. Әхсәннең классташларын, сабакташларын санап чыкты, кемнең кайсы партада утыруын хәтерләргә тырышты.

— Ә бервакыт, абый, син безгә ике икең биш икәнен исбатлап күрсәттең, хәтерлисеңме? Аннан соң, сигез сигезең алтмыш биш икәнен. Монысы — геометрия дәресендә. Хәтерлисеңме?!

Укытучы елмаеп тыңлады. Күзләрен хәйләкәр кысып, Әхсәнгә төбәлде.

— Без аптыраган идек ул чакта. Син безгә шул исбатлауда нинди ялгыш барын белеп килергә куштың. Өйгә эш итеп бирдең. Ә аны беребез дә чишә алмаган идек. Алдынгылар да, баш иеп, кызарып утырды ул дәрестә. Аннан соң, ялгышның нидә булуын үзең аңлатып күрсәттең. Юк кына нәрсәдән булган, югыйсә...— Әхсән, үзе сөйләгәннәрдән дулкынланып, сулышын җыеп торды.— Син, Әхмәтнәҗип абый, математиканың төгәл фән булуы белән бик горурлана идең. Ә тормыш, менә, «ике икең — дүрт»тән генә тормый шул. Әллә нинди сораулар китереп куя, мең төрле чишелеш тага. Исбатлап кара шуннан соң үзең тапканны!

Укытучы, әйтерсең, аның бу соңгы сүзләрен ишетмәде:

— Сине, Әхсән энем, кешеләр белән эшләргә өйрәтәсе юк,— дип, үзалдына сөйләнгәндәй башлап китте.— Атаңны, Әхмәтгали абзыйны, яхшы беләм. Сугышка бергә алындык. Киткәндә телендә бер сүз булды: «Балам кала, кызым кала»,— дип уфтанды. «Ичмасам, нәсел өчен бер малай да булмады бит»,— ди торган иде. Шөкер, ватылып кайтсак та, сугыштан исән кайттык. Әхмәтгали абзый һаман малай көтте. Син тугач, атаң бик шатланды. Төпчеге Хәбир тугач, әле тагын канатланып йөрде. Гаиләдә малайлар, ир балалар булу әйбәт ул. Син үзең дә менә кызлар белән генә куандырасың әле. Хәбирнең дә кызы бар дип ишеттем. Малай алып кайтырга кирәк сезгә дә.

— Әле малай кайгысы түгел, Әхмәтнәҗип абый. Үзең күреп торасың бит...

— Йорты аның, бер башлагач, салынып, очланып чыгар. Ир балаларсыз ярамый бу дөньяда. Нәсел шәҗәрәсен шулар дәвам итә. Малайлардан ирләр үсә. Монысын сүз уңаеннан, атаң турындагы сүздән әйтәм. Ул сезнең барыгызга да әйбәт тәрбия бирде. Олыны олы итеп, кечене кече итеп яратырга өйрәтте. Апаң бик акыллы булды, кеше бәхетенә үсте, үзе дә шуңа күрә бәхетле. Кайтып төшсәләр, бөтен авыл соклана. Син үзең дә безнең күз алдында үстең. Ике ат җигеп, кырдан киндер ташыганыңны хәтерлим әле. Ничәнче сыйныфта булдың икән син ул чакта? Җидедәме, әллә сигездәме?

— Сигезгә күчкән идем, абый. Шул сигезенчене тәмамлый алмый калдым бит инде мин.

— Ә, әйе шул, атаң авырып киткән чак иде. Укырга хирес идең үзең. Колхозда эшләп, кичкене тәмамладың. Ферма мөдире булгач та сынатмадың. Синең атаң ир бала турында юкка гына уйламаган: ил-көн алдында абруе булган, нәселне дәвам итәчәк уллар турында уйлаган ул. Син аның ышанычын авылдашлар алдында, ил-көн алдында акларга тырыш.

— Авылдашлар белән уртак тел табармын мин табуын, Әхмәтнәҗип абый. Тик минә алар белән парторг булып сөйләшүе кыен, аңлыйсыңмы? Алар бит миннән төгәл эш, төгәл сүз көтә... Кыен миңа, абый...

— Кыен...— укытучы сузып торды. Аннан соң, Әхсәнгә туры карады.— Математиканың төгәл фән булуы белән горурлана идең, дип әйттеңме әле? Әйе, горурлана идем. Төгәллек бик кирәк иде безгә. Кирәк иде!

Укытучы, алга талпынып, протез аягын җайлабрак куйды. Әхсән аның бу гадәтен белә: бәхәсләшергә уйласа, гел шулай итә Әхмәтнәҗип абыйсы. Чыннан да, укытучының тавышында, сөйләүдән бигрәк, бәхәсләшү төсмере пәйда булды:

— Ә бит, беләсең килсә, тормыш та төгәллек һәм төгәлсезлекләрдән тора. Төгәллек — дөреслек, төгәлсезлек — ялгыш яки ялган. Нәкъ математикадагыча. Килешәсеңме?

Әхсән, әле сүзнең кая таба агасын аңлап бетермәсә дә, баш какты:

— Төгәлсезлек — ялгыш яки ялган.

— Соң!— укытучы куәтләп алды.— Мине бит башта пехотага алдылар. Мине, математика укытучысын, беренче бәрелешкә агач мылтык тоттырып керттеләр. Бер мин генә түгел, башкалар да шулай: өч кешегә бер чын мылтык. «Коралны иптәшең үлгәч алырсың».— диделәр. Мин, солдат, дошманга атар өчен, башта иптәшемнең үлгәнен көтеп йөрергә, йә булмаса, бер тапкыр да атмаган килеш үләргә тиеш. Төгәллек идеме бу?

Укытучы Әхсәнгә сынаулы, сораулы караш белән төбәлде. Әмма җавап көтеп тормады:

— Ярый, соңрак кемнең кем булуын ачыклый башладылар. Минем дә белемем кирәк булып чыкты. Окоптан, кыр өстеннән чакырып алдылар. Укып, кече лейтенант булып, миномет батареясына кайттым. Ә син беләсеңме минометның нәрсә икәнен?— укытучының күзләре очкынланып китте.— Ориентир — номер один! Ближе — сто, левее — пятнадцать! Огонь!.. Төгәл ата идек без. Немец якынлашкан саен, көпшәне өскәрәк күтәрә барасың, утны күчерәсең. Мина биегрәк дуга ясаган саен, якынгарак төшә. Берчак көпшәне шундый күтәреп җибәргәнбез — баш очындагы наратка тондырдык минаны. Одинцов дигән егет утыра иде шунда. Күзәтче булып. Бәреп төшердек егетебезне, күз алдында чәрдәкләдек. Үз кулыбыз белән. Дошман бик якын иде. Шулай... Төгәл ата идек...

Әхсән инде бу йортка ник килгәнен дә онытты кебек. Боларны малай чакта, мәктәптә укыганда ук сөйләтмәүләренә гаҗәпләнеп, укытучысының маҗараларын тыңлады.

— Төгәллек кирәк,— диде укытучы, тагын бер кат кабатлап.— Һәркайда — тормышта да, эштә дә, политикада да төгәллек кирәк. Ә төгәлсезлекне күп күрдек. Халык туйды андый төгәлсезлектән. Әйе, син дөрес әйтәсең: тормыш математика гына түгел, анда төрле чишелешләрне исәпләп, тактага бер язып, язганны сызып ташлап, яңадан язып, яңадан сызып яшәве кыйбатка төшә. Класстагы кара тактада ярый ул: яздың, ялгышын таптың — сөртеп ташладың юеш чүпрәк белән. Тагын исәп-хисапка керештең... Ә тормышта? Ил язмышында? Халык төгәллекне ярата, төгәллекне сорый, дисеңме? Шулай. Ә бит һәр төгәлсезлек үз корбанын сорый. Мин — коммунист, математик. Төгәллекне мин дә сорыйм. Ә син мине җыелышларга йөрми башлауда гаеплисең. Мин — математик! Икене икегә тапкырлагач чыккан нәтиҗәнең бер көнне — унбиш, икенче көнне биш булуын тыңлап утырасым килми минем!

Әхсән уйга калды. Аннан соң, укытучыга карады:

— Әйе, Әхмәтнәҗип абый... «Нәрсә өйрәтермен соң сиңа?»— дип башлаган идең, шактый дәрес биреп ташладың әле үзең. Инде шуны әйт: менә мин — Әхсән Сабирҗанов — үз эшемдә төгәл булу өчен нишләргә тиеш? Нәрсәләр турында әйткәнеңне аңлап, тоеп утырдым. Математик буларак түгел, кеше буларак сөйлисең син. Менә мине дә кешеләр сайлап куйды. «Әхсән үзебезнеке, ышанабыз аңа», диделәр. Димәк, мин һәрнәрсәдә төгәл җавап табарга тиеш. Әгәр дә ул җавап, хаклыкны һәм халыкны канәгатьләндереп тә, югарыдагыларны канәгатьләндермәсә? Яки бүтәнчә: мин тапкан чишелеш дөрес җавап булмаса? Минем төгәллек хаклыкка, дөрес чишелешкә җавап бирмәсә, туры килмәсә? Ул чакта ничек?

Укытучы, «аңлыйм» дигәнне белдереп, баш какты:

— Син инде, Әхсән энем, хаклыкны табасың килсә, әдәм баласының күзенә карый торган бул. Дөрес чишелеш табасың килсә, дип әйтүем...

Саубуллашканда, ниндидер сер әйтәсе кешедәй, Әхсән укытучының колагына таба иелә төште:

— Ә теге вакытта... Дәрестә безне ни өчен интектергәнеңне әйтимме, абый? Теге, «ике икең — биш» тәге ялгышны ни өчен эзләткәнеңне? — Әхсән көлемсерәп, көттереп карап торды.— Уйларга өйрәткәнсең икән безне. Кат-кат исбатланган нәрсәне дә тикшереп карарга, булган ялгышны тотып алып, дөрес чишелеш эзләргә өйрәткәнсең, шулаймы? Өйрәтергә тырышкансың...

Укытучы елмайды:

— Син инде мондый сорау биргәнсең икең, димәк, мин сезне ул кадәр үк начар укытмаганмын.

Шул көннән башлап Әхсән бу йортка ешлады.

Ә көннәр үтә торды. Әхсән Сабирҗановның яңа йорты, аның үзен юньләп күрмичә дә, күтәрелә, калка бирде. Ниһаять, ноябрь башларында, Әхсән үз йортына — нарат сагызының хуш исләрен аңкытып торган яңа йортына кайтып керде. Бу яңа бина элеккесеннән дә иркенрәк, элеккесеннән дә матуррак, элеккесеннән дә күркәмрәк иде. Һәм бу йорт аларның иске нигезенә — ата-бабадан калган нигезенә урнашкан, алар гаиләсендәге һәркемнең уртак көче, уртак хезмәте, уртак ихтыяры белән салынган иде.

Балта осталары тырышты: ихатада, каралты-кура тирәсендә, яңа мунча да калкып чыкты.

Элекке корымлы хәрабәнең, кисәүле урыннарның эзе дә калмады. Әйтерсең бу урында коточкыч янгын булмаган да, бу ихата кара күмергә калып ятмаган. Тора-бара бу янгын турында бөтенләй дә оныттылар кебек. Әмма Сабирҗановлар гаиләсен чолгап алачак ялкын әле алда булган икән...

## IV

Көнне һәм төнне үткәрергә кирәк иде.

Кешенең шундый хәлдә калган чагы була: ул бер максаттан икенче максатка бару вакытында яшәми, ә бәлки тереклек кенә итә. Максатына ирешкәч, яшәп ала, аннан соң яңадан тереклек итә башлый — яңа максатына таба китә. Хәбир үзен андый халәттә дип уйламый иде. Әмма ул бүгенге көнне һәм төнне тизрәк үткәреп җибәрү өчен күп нәрсәләр бирергә риза иде.

Кызын больницада алып калдылар. Һәм менә Хәбир таныш та, ят та булып тоелган урамнар буйлап атлый. Аларның ят булуы аны каушатмый, таныш булуы шатландырмый иде. Ул, әйтерсең, бүген бернәрсә дә тоймый, бары тик вакытның үтүен генә көтә.

Ниһаять, бер фикергә килеп, кунакханәгә таба юл тотты.

— Урын юк,— аны шушы сүз белән каршыладылар. Чемоданнарын күтәреп, шактый йөрде. Кунакханә ишекләре аңа ачылмады: «Урыннар юк» дигән язу аның күзенә күренә сыман иде инде. Шулай, урын эзләп йөри торгач, «Казан» кунакханәсенә килде. Үзенең юлдан гына булуын, авыррак хәлдә калуын аңлата торгач, кечкә унбергә кадәр көтәргә куштылар. Хәбир, шул өметләндерүгә ышанып, залда көтеп утыра иде. Кинәт таныш тавыш ишетте:

— Иә, туган! Менә очраштык та! Нихәл? Кызың ничек? Алып калдылармы? — Ахо, чын күңелдән куанып, аның кулын кысты. Хәбир үзенең хәлен сөйләп аңлатуга, туп-туры администратор тәрәзәсенә таба атлады. Озак та үтми, әйләнеп тә килде.

— Әйде, туган. Кемнең кем икәнен аңламый башлаган болар. Аңлатырга туры килде,— диде. Хәбирнең алдына кәгазьләр куйды.— Тутыр документларыңны.

Ахо алып биргән бүлмә ярымлюкс булып чыкты.

— Урын юк дигән булалар тагын. Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга икән...

— Кемгә-чыга, кемгә-юк,— дип елмайды Ахо,күрәсең, ул Хәбиргә ярдәм итә алуына бик шат иде.— Син әле әбәт тә ашамагансыңдыр. Бу мәшәкатьләр белән йөри торгач дип әйтүем. Әйдә, кичке ашка үзем чакырам.

— Юк, рәхмәт, Ахо,— диде Хәбир. Аның берьялгызы каласы, ничектер урнашасы, фикер туплыйсы килә иде.— Мин, мөгаен, ашап тормам инде бүген.

— Ихтыярың,— дип елмайды Ахо.— Мин анда, ресторан залында булам. Мине эзләсәң, «Лимон» дип сорарсың. Аңладыңмы: «Лимон»! Ярый, күрешкәнгә кадәр!

Ялгызы калгач, чишенеп юынды да, урынга ауды Хәбир. Шунда гына үзенең тәмам арганлыгын сизде. «Ашыгыч ярдәм» машинасында да шактый озак йөрергә туры килде. Больницаларның берсендә кабул итмәделәр, урын юк,

диделәр. Икенчесендә кизү врач булмады. Ниһаять, авыруны бүтән бер шифаханә кабул итте. Анда да үзара әйткәләш булып алды.

— Күрмисезмени, сабый бала авыр хәлдә?! Олы кеше булса, бер хәл иде әле! — дип тузынды аларны поездлан ук алып килгән врач. Үзенең кунакханәгә урнаша алмый йөрүендә әнә шул вакыйга белән бер охшашлык тапты Хәбир. Исеме генә — кунакханә, ә инде кунак каршылау, кунак итә белүнең әсәре дә юк, кунак кадере юк. Әле ярый, Ахо килеп чыкты. «Лимон...» — дип уйлады Хәбир, аның соңгы сүзләрен искә төшереп. Кызык кеше булып чыкты бу «Лимон».

— Дүрт класс белемем бар минем, беләсең килсә! — поездда кайтканда Ахо шулай дип сөйләнде. — Дүрт класс бетердем, алга таба укый алмадым, шайтан алгыры. Минем анам, артын корт чаккыры, эти белән безне ташлап китеп барган. Мин бәләкәй чакта ук. Эти укуымны таләп итмәде, мин укымадым. Ә шулай да, туганкаем, мин үземне бик күпләрдән акыллырак саныйм. Ни өчен дисеңме? Чөнки мин бу тормышны аларга караганда күбрәк беләм.

Ахо һәрбер сүзенә басым ясап, үзе дә ышанып, кешене дә ышандырылык итеп сөйли белә:

— Кайбер шундый бәндәләр бар. Егермешәр ел укып белем алалар, башлары пеләшләнеп бетә — үзләреннән бер тиен файда юк. Әчмуха хезмәт хакы алып, шуңа риза-бәхил булып яшиләр. Ит тә юк, сөт тә юк андый мәхлуклардан. Соң ул акчаны, туганкаем, мин аны укымыйча да алам бит! Валлаһи шулай!

Хәбир аның сөйләвен рәхәтләнеп, елмаеп тыңлап кайтты. Ахоның ачуы да, шатлыгы да эчтә калмый — эчендәге тышында, йөзендә — сабыйларча беркатлылык.

— Ә минем үземә дүрт класс белем бик җиткән. Нәрсә? Тормыш катлаулы, дисеңме? Төкер! Мәсәлән, мин әйтәм ул тормышка: «Бутама! Гадирәк бул!» — дим. Һәм ул гап-гади була да кала. Ә менә сиңа инде, туганкаем, мин зур хөрмәт белән карыйм.

— Нигә миңа гына шундый аерым хөрмәт? — дип елмайды Хәбир. — Мин дә бит шул егерме ел буена укып, ыштан туздырып белем алган бер фәкыйрьмен.

— Ә, юк инде!.. — Ахо, мине алдый алмассың дигәндәй, бармак янады. — Син бу сүзеңне миңа түгел, әнә, әрекмән колакларга сөйлә. Синең юк-бар кеше генә түгел икәнең маңгаеңа язылган. Сез татарларда «маңгайга язган» дигән сүз юкка гына чыкмаган ул, туганкаем. Мин татарларны беләм, хатын татар иде минем, шайтан алгыры!

— Минем маңгайга нәрсә язылган соң?

— Намуслы кеше булуың язылган. Эшкә осталыгың. Дус-ишне сатмавың. Хыянәтне кичермәвең. Кыскасы, көчле шәхес булуың.

— Рәхмәт, нык зурладың син мине. Көтмәгән идем.

— Чит илгә, туганкаем, чүпрәк башлар чыкмый. Ә син менә чит илдән кайтып киләсең. Шуңа хөрмәт итәм мин сине. Әйтәм бит, дүрт кенә класс белемем булса да, кешеләрне биш бармагым кебек беләм мин.

Хәбир Ахога чит илдән алган бер талисман кебегрәк әйбер бүләк иткән иде. Ахо моңа шулкадәр шатланды, мөгаен, сабый Розалия иң матур курчакка да болай шатлана алмас иде.

Ахо «Ашыгыч ярдәм» машинасыннан шәһәр үзәгендә төшеп калды. «Күрешербез әле!» — дип әйткән иде, күрешү бик тә тиз булды. Рәхмәт Ахога, ярдәме тиде...

Шуларны уйлап ята торгач, Хәбир больницага шалтыратып алырга булды. Кызын андагы шәфкать туташларына тапшыргач, ул шактый озак көтеп утырды. Нишләргә, кемнән сорашырга белмичә, әрле-бирле йөрде. Аннан соң, Розалияне алып калган туташларның берсен күреп алып, сораша башлады:

— Миңа нишләргә икән соң инде, сеңлем?

Туташ бу сорауга бик гаҗәпләнде. Йөзенә «Моннан да ахмаграк сорау булырга мөмкинме?» — дигән сүзләр язылган сыман иде:

— Ничек инде «нишләргә»? Кызыгызны кабул итеп алдык. Аны доктор карый.

— Соңыннан докторны күреп булмас микән? Бер генә минутка?..

— Сезгә әйтелде бит инде! Докторның вакыты юк!

Хәбир, ник эндәшкәненә үкенеп, кире борылды.

Шулай да икенче бер туташны очратып, больницаның телефон номерын, Розалияне караучы докторның исем-фамилиясен язып алды. Телефоннан ул

нәкъ менә шул докторны — Фәридә Рәшитовнаны сорады.

— Көтегез, чакырырбыз,— диде телефондагы тавыш. Хәбир ераклашкан аяк тавышларын тыңлап торды. Шактый озак көтте. Ниһаять, тавышлар кабат якынайды, ашыгып атлаудан ешайган сулыш ишетелде.

Хәбир бер-ике сүз генә әйтеп өлгерде, доктор аны орышып ташлады:

— Ә-ә, әле сез Сабирҗанов буласызмыни? Сабыйны карамагансыз, әти кеше! Юк-юк, минемчә ул поезда гына авырып китмәгән. Сез аның хәленә игътибар итмәдегезмени? Авыру бала белән юлга чыгарга ярыймы? Әгәр авыру көчәеп, кызыгыз гомерлек чир алып калган булса? Каян килә ата-аналарга бу кадәр игътибарсызлык?!

Бераздан докторның тавышы йомшара төште. Хәбир, шуннан файдаланып, кызының хәлен сорады.

— Температурасы төшә. Һәрхәлдә, хәле җиңелрәк. Тик, беләсезме, эш монда катлаулырак булса кирәк. Сез иртәгә киләсезме? Мине күрергә тырышыгыз.

Доктор белән сөйләшүдән соң, Хәбир яңадан ике ут арасында калды. Әйе, кызының температурасы төшә, хәле җиңеләя — монысы сөенечле хәл. Әмма доктор ни өчен: «Эш монда катлаулырак булса кирәк»,— диде? Нәрсә әйтергә теләде ул бу сүзе белән? Бәлки?.. Бәлки ул нәкъ менә шул турыда — Хәбир уйлап интеккән нәрсәләр турында әйтергә теләгәндер? Юк-юк!.. Хәбир кинәт башын чайкады, ямьсез уйларын куарга тырышты.

Син үзеңнең ни өчен шулай борчылганыңны беләсеңме?

Хәбир сискәнеп китте. Ул сизде: бу сорауны аңа үз тавышы, күңелдәге тавыш бирә иде.

— Беләм,— дип кистереп әйтте Хәбир.— Без авылга кайтып җитәргә тиеш идек. Телеграмма суктык, анда да борчылып көтәләрдер. Юл буенда, кызым авырып китте. Ул — минем бердәнберем.

— Синдәге борчулар бары тик шуннан гынамы?

Күрәсең, әлеге тавыш бәхәсләшергә маташа иде. Тик Хәбир бу сорауга җавап бирмәде. Бүтән бернәрсә дә ишетмәс өчен, башын мендәр белән каплады да, ашыгып-ашыгып санарга кереште.

Юк, күзгә йокы кермәячәк иде. Хәбир моны сизде. «Мондый чакта кеше матуррак уйлар уйларга тиеш,— дип ышандырырга тырышты ул үзен.— Мәсьәлән, бүгенге көндә хәл шактый әйбәт, иртәгә тагын да яхшырак булачак. Кызым да терелер, авылга да исән-сау кайтып җитәрбез, әбисе белән бабасын шатландырырбыз...»

Хәбир авылдагы йортны, әтисен һәм әнисен күзалдына китерде. Әхсән абыйсы инде район үзәгенә кат-кат килеп киткәндер, Казаннан самолет көткәндер. Ашыгыбрак җибәрде шул телеграмманы, болай килеп чыгасын белмәде...

Хәбирнең кинәт исенә төште: бала чакта, кышның салкын бер көнендә, әтисе аны район больницасына алып барган иде. Салкын тигергән вакыты булды микән? Хәбирне, толыпка төреп, чанага салганнар иде. Ат экрен генә теркелди, чана чыжылдый. Хәбир күзләрен йома. Һәм, ни гаҗәп, чана артка таба шуган сыман. Хәбир моңа аптырый, күзләрен ачып, толыпның бер читен күтәрә: юк, чана алга таба бара. Күзләрен йома, толыпны яба — чана тагын артка шуа. Хәзер дә Хәбир үзен нәкъ менә шундый хәлдә хис итте. Күзләрен ачса — күзалдында бүгенге көн, күзләрен йомса — уйлары каядыр артка — узганнарга шуыша.

...Чегән хатынының сүзләре дөрескә чыкты. Хәбирнең беренче хисләре авыр хыянәткә тап булды. Аңа берьюлы ике якын кешесе — сөйгән яры һәм балачактан бергә уйнап үскән якын дусты хыянәт итте.

Алар Таһир белән укырга кергәннән соң, Балтамак авылының тагын бер кызы — Минзилә студент булды. Ничектер шулай килеп чыкты: Минзиләнең әтисе Хәмәт Мортазин кызын Казанга озата килә алмады, Хәбиргә ияртеп җибәрде. Хәбир кызны педогогия институтының тулай торагына китереп урнаштырды. Казан белән ныклап таныштырырга вәгъдә итеп, китеп барды. Ә кайчан башланды?.. Әйе, аларның аңлашуы әнә шул кар-буранлы бер кичтән башланып китте. Ул көнне алар Әлфия Афзалова концертына барганнар иде.

— Нигә мин дә артистка булмадым икән?!— дип хыялланып кайтты Минзилә.— Күзалдыңа китерәсеңме, Хәбир абый: бөтен зал сиңа тәбәлгән. Меңләгән кешеләрнең йөрәге синең моңнан, синең сагыштан өзгәләнә. Шәп бит, ә?!.

— Әйе, син дә матур җырлыйсың,— диде Хәбир.— Авылда чакта тыңлаганым бар, сәхнәдә җырладың...

— Юк, мин — башка... Мин үзем өчен генә җырлыйм. Ә чын җырчыларны меңләгән кешеләр тыңлый!

— Авылда сине дә яратып тыңлыйлар иде. Беләсеңме, кулны иң нык чапкан кеше кем иде?

— Беләм!

— Кем?

— Әлбәттә, син!..— Минзилә кычкырып көлеп җибәрде, башын Хәбирнең иңбашына сала-сала, рәхәтләнеп көлде. Минзиләнең кайнар иреннәренә кагылганын сизми дә калды Хәбир. Шул иреннәрнең калтыранып китүен тойды, йөрәгенең дөп-дөп килеп тибүен ишетте.

Кар ява, кар ишелә иде. Дөньяның шушы кары аларның икесен дә берьюлы күмеп китәр, тоташ итәр сыман иде. Бу кар аларны чит-ят күзләрдән яшерергә, аларның серен башкаларга белгертмәскә тели кебек иде.

Чегән хатынының сүзләре дөрескә чыкты...

Хәбирне озатырга килеп җитә алмавына үкенеп, хат язды Минзилә. Энисенең авырып киткәнен, үзенең ике ут эчендә янганлыгын, газапланып интеккәнлеген аңлатты. «Мин сине көтәрмен, Хәбир! Син миңа көн саен хат язып тор, көн саен, яме?!» — дип ялварып язды. Укуын ташлап китеп барган Хәбиргә үпкә-рәнҗү сүзләрен әйтеп, «Син киткәч, урамнар моңаеп калды. Нигә дип киттең син, нигә мине ялгыз иттең? Ник ташладың институтны?» — дип язды. Институттан ничек һәм ни өчен китүен Хәбир беркемгә дә, хәтта Минзиләгә дә белдермәгән иде.

Хәбирнең язмышын ул чакта Раздуваев дигән бер укытучы хәл итте. Хәбир аның лекцияләрен, ни өчендер, башта ук яратмады. Бәлки, нәкъ менә кечкенә авылларның киләчәксез булуы, бетәргә тиешлеге турында сүз барганлыктан яратмагандыр аны Хәбир. Раздуваевның лекцияләрен тыңлаганда, кечкенә авылларның кичекмәстән бетерелергә тиешлеген ишеткәндә ул үзенең туган авылы Балтамакны күз алдына китерә, күңеленнән генә үртәлеп, сыкрап утыра иде. Хәбирнең лекцияләрдә игътибарсыз утыруын, өнәмәвен, еш кына кире сүзләр әйтеп куюын Раздуваев сизми калмады, билгеле.

— Сез минем лекцияләрдән юкка читләшәсез, Сабирҗанов,— диде ул бервакыт.— Минем лекцияләрем — зур кибет. Аннан теләсә нәрсә алырга мөмкин.

Әнә шул чакта Хәбир түзмәде, бәхәскә керде:

— «Кибете зур да, товары начар»,— диде. Хәбир үз авылын — Балтамакны яклады. Кайнарланып, үзенең туган җирен, туган ягын — чишмәләрен, тал-тирәкләрен, авылның кешеләрен яклады. Һәрхәлдә, Хәбир үзе шулай уйлады. Ләкин үзенең шул кайнарлыгы белән ул, әлбәттә, Раздуваевның еллар буена эшләгән хезмәтенә каршы килүен, аның хезмәтенә кул күтәрүен аңламый иде. Раздуваев кызды. Ул лекция тыңлаучыларның күбесе авыл җиреннән — шул ук кечкенә авыллардан булуын һәм әчтән генә шушы Сабирҗановны яклап утыруын белә иде. Юк, тәүчеләрнең мондый булуын теләми иде Раздуваев. Аңа киң колач белән эш итүче, киләчәккә йөз тоткан төзелешләр турында уйлаучы сәләтле төзүчеләр кирәк. Әлбәттә, ул бүген студентларны сүз белән генә ышандыра алмаячагын сизде. Шуңа күрә, Хәбирнең русча шактый хата белән сөйләшүенә ишарә ясап, хәлиткеч җавап кайтарды:

— Кечкенә авыллар материаль яктан гына түгел, культура ягыннан да үзләрен акламый, Сабирҗанов. Менә сез үзегез дә шундый авылдан. Шуңа да русча ике сүзне бергә кушып әйтә алмыйсыз...

Бу инде Хәбир өчен кичереп булмаслык көлү иде. Һәм ул, шушы көннән башлап, Раздуваевны күрәлмас булды.

Үз чиратында Раздуваев та нәкъ шуның белән җавап кайтарды. Ул Хәбиргә «Авыл җирендәге перспектив төзелешне социаль яктан бәяләү юллары» дигән курс эше тапшырды. Бу курс эшен Хәбир яклый алмады. Раздуваев аны шактый озак йөртте, курс эше тапшырылмый торып, чираттагы имтиханнарга керү мөмкин түгел иде. Иптәшләре имтихан тапшырганда Хәбир әле һаман курс эше буенча чапты. Раздуваев курс эшен кабул итсен өчен ул, һичшиксез, үз фикереннән баш тартырга, кечкенә авылларның юк ителүен якларга, үзе әйткәннәрне инкарь итеп, Раздуваев фикерләренә таянырга тиеш иде. Хәбир курс эшен үзгәртмәде, башкача язмады. Ә бер көнне, институттан китәргә теләвен белдереп, гариза язды. Деканатта моңа бик гаҗәпләнделәр. Китәргә теләвенең сәбәпләрен кат-кат сорадылар.

— Укырга теләмим,— диде Хәбир. Декан, тәмам аптырашта калып, тирләгән маңгаен сөртте. Аннан соң гаризага имзасын салды:

— Юкка, юкка китәсез, яшь дустым, бездән. Беләсегез килсә, безнең институт иң перспективалы уку йорты.

Институттан киткәнен башта авылга да, әти-әнисенә дә хәбәр итмәде Хә-

бир. Заводка эшкә урнашты, кая булса да кечкенә укуга керергә уйлап йөри, һаман да әле элекке тулай торакта иптәшләре янында яшәп ята иде. Хәрби комиссариатка чакыру кәгазе дә шул элекке адресы буенча килде.

Армиягә китүчеләр автобуска төялгәндә ул берьялгызы иде. Башкаларны кемдер озата, кочаклаша-үбешә, күтәреп өскә чөя. Хәбир боларны күзәтеп торды, ялгызлыгын сизеп, эчтән сызды. Монда яңгыраган җырлар, гитара һәм гармун тавышлары аны бер генә нәрсәгә дәшә — кайдадыр бер аулак табып, туйганчы бер үксеп еларга чакыра иде.

Инде машинага кереп утыргач, күңеле тәмам иләсләнде. Әле һаман да «Минзилә килеп чыкмасмы?» дип өметләнгән күзләренә яшь тыгылды. Үзенең кычкырып җырлап җибәргәнен сизми калды:

Их, алмагачлары!
Сайрый, сайрый, сайрый, сайрый,
Сайрый сандугачлары!..

Аның бу җырына беркем дә игътибар итмәде: әчкәндер булачак яшь солдат...

Вакыты булган саен, Минзиләгә хат язды Хәбир. Ул сагышка бирелмәсен дип, хатларын шаян сүз, уен-көлке белән тутырды. Үзе чыгарган такмакларын язды:

Командирлар әниләр кебек:
Торалар гел елмаеп-көлеп.
Сөйләшәләр гел назлап кына,
Иөгертәләр аз-азлап кына...

Юк, командирлар елмаеп кына тормыйлар иде. Әмма солдат хезмәтенең гел күңелле якларын гына белеп барды Минзилә аның хатларыннан. Боларны укып, Минзиләнең ничек шатланасын, елмаясын күз алдына китергән Хәбир үзе дә балаларча куана иде.

Яман хәбәрне аңа иң элек әнисенең хаты алып килде. Үз хәбәренең улы йөрәгенә таш булып ятачагын сизгән Гөлчирәтти, бик җайлап кына, юатыпкөйләп кенә язган иде: «Синең дустың Таһир да башлы-күзле булды, улым. Җәмәгате үзебезнең авыл кызы, югары оч Мортаза Хәмәтенең Минзиләсе. Чәчләрен чәчкә бәйләргә уйлаганнар икән, инде бәхет-шатлыкларын насыйп итсен. Хезмәтеңне исән-сау тутырып кайтсаң, син дә үз тиңеңне табарсың, улым. Исәнлек кирәк...»

Зур хыянәт иде бу Хәбир өчен. Атна-ун көн буе иләс-миләс йөрде. Иптәшләре аның хәленә керделәр: ул-бу булмасын дип, артыннан саклап йөрделәр.

Таһир белән дә, Минзилә белән дә бүтән һичкайчан күрешмәскә, сөйләшмәскә ант эчте Хәбир. Зур иде, мәңге бетмәс кебек иде аларга булган рәнҗүе... Армиядән ул әнә шул рәнҗүен кочаклаган хәлдә кайтты. Авылда бер-ике көн торды да, берни әйтмичә, Мәскәүгә китеп барды. Мәскәү архитектура институтына укырга кергәнлеген өйгә соңыннан гына хәбәр итте. Таһир белән Минзилә турында берни дә ишетергә теләмәде, кызыксынмады. Бу — мәхәббәтте кимсетелгән җанның горурлыгы гына түгел, ә бәлки югалтуның зурлыгын, югалтканны инде берничек тә кайтарып булмаячагын аңлаудан иде.

Укуны тәмамлап, рәссам-реставратор дипломын алырга әзерләнеп йөргәндә, аңа көтелмәгән бер нәрсә — Әфганстанга эшкә барырга тәкъдим иттеләр. Әйтүләренчә, алар анда зур эш башкарырга — үзләренең интернациональ бурычларын үтәргә тиеш. Мәсьәлә бик җитди. Рәссам-реставраторлар анда дошманнар тарафыннан шартлатылган мәчетләрне торгызу эшен башкарачак. Унбиш миллион халкы булган бу илдә ике йөз илле мең мулла бар. Халык дини. Дошманнарның максаты ачык: мәчетләрне шартлатып, халыкны үзгәрешләргә каршы котыртмакчы да, куркытмакчы да булалар. Күптән түгел бик зур мәчет — уналтынчы гасырда ук салынган тарихи мәчет шартлатылган. Әлеге мәчетнең мулласы илдәге үзгәрешләрне яклап чыккан булган икән. СССРдан барган рәссам-реставраторларның әнә шундый мәчетләрне торгызуда катнашуы — кешелеклелек һәм дуслык-туганлык бурычы икән.

Хәбир Әфганстанга барырга берсүзсез риза булды. Әмма әле аңынчы, чит илгә китәргә ризалык биргәнчегә кадәр, ул Лиза исемле бер латыш кызы белән язылышып өлгергән иде. Лиза — чит телләр факультетын тәмамлаган, гарәпфарсы телләрен белгән кыз — комиссия тарафыннан шатланып кабул ителде: Әфганстанда тәрҗемәчеләр дә бик кирәк икән.

Лиза балалар йортында тәрбияләнгән, кече яшьтән үк ятим калган. Язылышып кайткан көннәрендә Хәбиргә әйтте:

— Син, Хәбир, минем ирем дә, әтием дә, абыем да булдың,— диде.

Лизаның балаларча беркатлылыгы, онытылып, җаны-тәне белән ярата белүе Хәбиргә яңа хис — яңа мәхәббәт алып килде. Хатынының һәрнәрсәгә гаҗәпләнеп караган зәңгәр күзләре, сабыйлыктан арынып бетмәгән әчкерсез карашы, гөнаһсыз үпкәләүләре һәм шаярулары Хәбирнең үзен бөтенләе белән яулап алды. Минзиләгә бәйле хатирәләрне акрынлап кысырыклап чыгарды. Күңелдә еллар буена сакланган рәнҗү дә, җепшек кар кебек, эреп юкка чыкты. Ә инде Минзилә белән Таһирга үч һәм үпкә саклап йөрү бөтенләй башка сыймас хәл, көлке бер нәрсә, яшьлек җүләрлеге булып тоела башлады.

Чит илгә китәр алдыннан Хәбир белән Лиза авылга, ата-ана йортына кайтып килделәр. Ул көнне Балтамак урамнарында шундый сүз йөрде:

— Әхмәтгали абзыйның төпчек малае марҗа алып кайткан!..

— Әй, күрә инде Гөлчирәтти килен рәхәтен!..

Ләкин, Әхмәтгали карт белән Гөлчирәттинең шомланып-каушап калуын йомып, озын телләрнең сүзен юкка чыгарып, Хәбир алып кайткан «марҗа» күрше-күлән белән «исәнмесез»ен әйтеп күреште. Булдыра алганча татарча сөйләште. Авыл малайларын койма башларына үрмәләтеп, җилкенчәк кызларның күзен ут яндырып, көянтә-чиләк белән чишмә юлында йөрде. Киленне бер күрүдә бәяләргә өйрәнгән авыл халкы «марҗа кызын» кинәт кенә яратып куйды. Хәбирләр кайтып төшкән көнне коеп-коеп яңгыр яуды: җәйнең корылыгыннан интеккән халык монысын да киленнең җиңел аягына юрады. Ә Лизаның татарчасы авылда бер мәзәк булып калды.

Коеп яуган яңгырдан соң чишмәгә барган Лиза хатыннардан яман хәбәр ишетеп кайткан. Ишеткәнен түкми-чәчми Гөлчирәттигә сөйләп бирде:

— Әни! Син, знаешь, вчерашний яңгырда бер «Жигули» аккан, бер ат аккан!..

— Әй, ходаем! Кемнәр акты икән? Каян ишеттең, балам? Кешеләре исән микән? Машиналары белән төпкә киттеләр микән? Машинасы бер хәл, кешеләре генә исән булсын, раббым! — дип хафаланды Гөлчирәтти. Әлеге хәбәр, күрше-күләнгә ияреп, бөтен авылга таралган, фермага ук барып җиткән. Бераздан ул, Саҗидә белән бергә, мәзәк булып кайтып керде: чишмә янындагы хатыннарның: «Кичәге яңгырда бер җигүле ат агып китә язган»,— дигән сүзен Лиза «Жигули» белән атка әйләндергән икән!

Гөлчирәтти киленен яратты. Лиза үзе ишетмәгәндә күршеләргә:

— Әй, ходаем, билләре бигрәк нәзек шул, балакаемның. Бәбиләрен ничек кенә табар инде?! — дип сөйләнде. Табын янына утырсалар:

— Авылда чакта ашап кал, балам,— дип, каймагын-маен һаман килене алдына куйды. Саубуллашканда да:

— Никләргә дип китәсез шул чит-ят җирләргә, үз илебездә генә дә эш бетмәгәндер лә инде? — дип өзгәләнде.— Оныкларымның бишектә чагын күрми калырмын дип куркам, тизрәк исән-имин әйләнеп кайтыгыз!..

Саҗидә дә килендәшен үз итте. Инде китәр алдыннан Лизаны җәйләүгә — үзенең эш урынына алып барган иде. Басу юлларын, әрәмәлекләрне, инеш буйларын күрсәтеп йөрде. Җәйләүдә Лиза белән тагын бер мәзәк хәл килеп чыкты.

— Минә шушы сыерымны бик яратам, чиләкләп-чиләкләп бирә сөтне, җаныкаем. Мөгезләрен генә күр син аның, җиленнәрен генә күр! — дип сөйләнгән Саҗидәне туктатып, Лиза бер читкә күрсәтте:

— Ә әнә теге сыер сөтне әз бирәдер, әйеме? Мөгезе шундый зур үзенең, җилене бер дә юк...— диде.

Саҗидә ул күрсәткән якка карады: анда ферманың нәселле үгезе утлап йөри иде. Саҗидә шуны аңлаткач, икесе дә тәгәри-тәгәри көлделәр, тыела алмый җәфаландылар. Бу мәзәк читкә таралмады, гаилә эчендә генә калды.

Улы килен алып кайткан көнне каушап-югалып калган Әхмәтгали карт Лизадан канәгать иде. Саубуллашкан чакта әйтте:

— Безнең рөхсәтсез, фатихасыз гына өйләнеп куюың белән дә, килеңнең чит халыктан булуы белән дә куркыткан идең, улым. Инде күрдек: килен үзебезнең кеше икән, бездән фатиха,— диде.

Чит илгә алар, әнә шулай, ата-ана фатихасын алып киттеләр.

Кабулда аларны иркен, якты йортка урнаштырдылар. Лиза Хәбирдән озак аерылып торудан бик курка, ул командировкага җыена башласа, аерыла алмый интегә иде.

Беркөнне Хәбирне төн уртасында уятты. Хәбир, йокылы күзләрен уып, урыныннан күтәрелде. Лиза түшәмгә карап ята иде.

— Нәрсә булды, Лиза?

Хатыны дәшмәде. Кулы белән Хәбирнең кулын эзләп тапты, үзенең кендек турысына куйды:

— Сизәсеңме?!.

Хәбир тойды: уч төбендәге тибеш таныш та, ят та кебек иде.

— Лиза?!. Син нәрсә? Әллә елыйсың инде?..

— Шатлыктан бу...— диде Лиза. Бераз тынып торгач, әйтте: — Мин куркам, Хәбир, куркам!.. Син безне сакла, яме?!

— Юләрем, юләркәем минем!.. Барысы да яхшы булачак, менә күрерсең,— хатынын иркәли-иркәли юатты Хәбир.— Беләсеңме, әгәр син миңа бер малай алып кайтсаң...

— Кыз,— дип бүлдерде Лиза.

— Юк инде, малай! — Хәбир юри үчекләште.— Син миңа бер малай алып кайтсаңмы!..

— Шуннан?

— Шуннан соң без өчәү булабыз!

— Кызык.

— Нәрсәсе кызык?

— Өчәү булуы. Мин бит берьялгызым идем, Хәбир. Берьялгызым... Сине таптым. Хәзер менә өчәү булабыз. Без бит барыбыз да170 бербөтен булабыз, шулаймы, Хәбир?

— Шулай, Лиза. Бербөтен, бер гаилә.

— Ә син чынлап та малай булуын телисеңме?

— Әйе,— диде Хәбир һәм тавышына ясалма кырыслык чыгарды.— Үз-үзен хөрмәт иткән ир һәрчак малай булуын теләргә тиеш!

Лиза бу сүздән көлде:

— Ә балага узган хатын-кыз тәм-томга бик таләпчән була икән...

— Булса соң! Беләсең килсә, мин синең өчен барысын да табам. Ни телисең — шуны!

Лиза урыныннан ук күтәрелде:

— Барысын да, барысын дамы?

— Әйе. Телисең икән — хәтта күгәрчен сөтен дә!

Лиза елмайды:

— Күгәрчен сөте булмый ла ул...

— Булырга тиеш. Миңа бер чегән хатыны әйтте: «Бәхет синда, күгәрчен сөте кебек, аз-азлап кына тамар»,— диде. Алдады, дөресрәге, ялгышты чегән хатыны! Килде ул бәхет миңа, Лиза! Минем бәхетем — син ул, туачак балабыз ул, ышанасыңмы?!

— Әгәр кеше гел бәхетле генә булып торса, бәхетнең ни икәнен аңламас иде, шулай бит? Бәхетнең ни икәнен белү өчен, башта бәхетсез булып карау кирәктер.

Хәбир нидер әйтмәкче булган иде, Лиза урыныннан күтәрелде:

— Хәбир!.. Ә бит ул чегән хатыны дөрес әйткән! Бар бит ул күгәрчен сөте, бар! Күгәрчен сөтен табу, мөгаен, үзеңнең кемгәдер кирәк булуыңны, кадереңбулуны тоеп яшәүдер ул. Син мине ташлама, яме? Син мине гомерең буена ярат, кадерлә! Синең минем өчен табасы күгәрчен сөтең шул булыр, миңа шул җитә, бик җитә!..

Хәбир Лизаны кочагына алды, иреннәреннән, күзләреннән үпте, төбәлеп карап торды: мондый гөнаһсыз затны яратмый мөмкин түгел иде...

«Син безне сакла, Хәбир!..» — хатынының шул сүзләре аның колагында яңгырап калды. Лизаның соңгы минутларын күрә алмады, янында була алмады Хәбир. Хәтта менә шул янында була алмау да мәңгелек үкенеч булып калды.

Розалиягә инде өч яшь тулып килә, ул инде бакчага йөри, күп нәрсәне аңлый, шаяра-көлә иде. Кызының туган көнен билгеләп үтәргә әзерләнеп йөргән бер вакытта Хәбирне ашыгыч рәвештә чакырып алдылар: тиз арада белгечләр төркеме туплап, юлга җыенырга куштылар. Хәбир өчен бу гадәти командировкаларның берсе иде. Эш урынына барып, ныклап урнашырга да өлгермәделәр, Хәбирне яңадан Кабулга чакырттылар. Ул моңа бик гаҗәпләнде, хәтта каушап калды: күңеле нидер сизенә иде. Розалия авырып киткәнме? Лиза белән бер-бер хәлме? Нәрсә булуы мөмкин? Ник чакыралар? Әле бит эш башланып кына китте!

Кайтты. Өнсез калды: аны Лизаның җансыз, телгәләнгән гәүдәсе каршы алды.

— Урамдагы шартлаудан...— дип аңлаттылар Хәбиргә.— Шактый кеше кырылды...

Очраклы һәм мәгънәсез бу үлемне Хәбир берничек тә аңлый алмады, кабул итә алмады. Аны сыгылып төшүдән бер нәрсә коткарды: янында ятим калган Розалия бар, кызы бар иде. Хәбир аны сакларга, ятимлеген белдермәскә, аңа таяныч булырга тиеш иде.

— Теләсәгез, илгә кайта аласыз,— диделәр Хәбиргә.— Хатыныгызның гәүдәсен дә озатырбыз.

Илгә кайтырга? Кая? Хәзер барысы да бер түгелмени?! Шулай уйлады Хәбир. Кайтып китүдән баш тартты. Лизаны да шунда, күп кайгылар күргән Әфган җирендә җирләделәр.

Хәбир хатыны каберенә үзе генә йөрде. Әнисен сагынып ялварган кызын алдады: «Әниең еракка, кунакка китте»,— диде. Башта бик юксынган кыз әкренләп оныта барды. Әмма, кичләрен уянып, кинәт кенә әнисен дәште, чакырды, ялварды. Андый төннәрдә Хәбирнең йөрәге парә-парә килде. Кызын кочаклап, аның үзенә сиздермичә генә, сулкылдый-сулкылдый елады. Әнә шундый төннәрдә — кызы ачыргаланып әнисен чакырган, әнисен эзләгән төннәрдә — Хәбир бу илнең үзен дә, бу илдәге дошманнарны да, үзләрен бу хәвефле илгә җибәрүчеләрне дә берьюлы ләгънәтләде, каргады, җаны-тәне белән рәнҗеп сыкранды.

Розалия балалар бакчасында үсте. Ул анда онытыла, уйный, әкренләп үсә бара иде. Әнисен сирәк сорый, әмма таләпчәнрәк сорый башлады.

Инде илгә кайтыр вакыт җитте. Әнә шул чакта Хәбир зур икеләнү, зур бүленеш алдында калды. Розалияне һаман-һаман алдап йөртергә тиеш идеме ул, әллә дөресен әйтергәме? Шушы уй аның миен бораулады, күңелен актарды. Башта үсә төшсен, аңлый башласын. Ул чакта инде аңа авырга туры килмәс, дип уйлады. Ләкин икенче бер фикер, көтмәгәндә калкып, өстенлек ала башлады: Розалиянең әнисе белән, аның кабере белән саубуллашырга, әнисенең йөзен хәтерләргә, аның күмелгән урынын күңелендә калдырырга хакы бар түгелме?! Кеше хакы дигән олы хак шуннан башланмыймы? Ә бәлки... Бәлки, әнисенең каберен күрсәтү аның нәни йөрәген җәрәхәтләү генәдер? Шулай икеләнеп, борчылып, газапланып, шактый көннәр үтте.

Ниһаять, көткән көн килеп җитте. Кабул аэропортыннан күтәреләчәк самолет аларны туган илгә алып кайтырга тиеш иде. Әйберләрен җыеп, тынып калгач, уйларын-фикерләрен соңгы тапкыр барларга дип, урынга утырды. Утырды да, үзенә төбәлгән карашны тоеп, кинәт кызына күтәрелеп карады. Чак кына кычкырып җибәрмәде. Розалия, күзләрен зур ачып, туптуры аңа карап тора һәм аның карашында бер генә сорау — таләпчән сорау чагыла иде: «Ә әни? Ул кайтамы?..» Хәбир аның бу соравын йөрәге белән тойды. Кызын кочаклап, күтәреп алды. Әйе, әнисе кабере белән саубуллашырга, аның каберен хәтерендә калдырырга Розалиянең хакы барлыгын, олы хакы барлыгын тоеп алды ул бу минутта.

Үзләрен аэропортка илтергә килгән машинаны Лизаның каберенә таба борды. Алар икәү — ата белән кыз — кабер янында озак басып тордылар...

Юк, Розалия еламады. Әнә шул чактан, шул көннән башлап ул еламый да, көлми дә торган булып калды.

Юк, йоклап китеп булмаячак иде. Хәбир, ниһаять, моны аңлады. Урыныннан торып, караңгы бүлмә буйлап әрле-бирле йөрде. Аннан соң тәрәзә каршына килеп басты. Җемелдәп янган утлары, төн дип тә тормыйча каядыр ашыккан кешеләре, әрле-бирле чабышкан машиналары белән шәһәр шау-гөр килеп тора, шәһәр яши иде. Һәм менә шушы шәһәрнең кайсыдыр бер ноктасында Хәбир басып тора. Шушы шәһәрнең кайсыдыр почмагында аның кызы Розалия авырып ята. Кайдадыр, шушы шәһәрдәге йортларның берсендә, аның беренче мәхәббәте Минзилә һәм балачак дусты Таһир яши...

Шәһәр шаулап, гөрләп тора. Тоныкутлары белән җемелдәп, күңелне кузгата. Кешеләр һаман ашыга, машиналар чабыша. Һәм шушы ыгы-зыгы белән тулган шәһәрнең бу минутта Хәбирдә дә, аның язмышында да, Лизаның кайдадыр чит җирдә калган каберендә дә, Розалиянең әнисез үсүендә дә бернинди катышы, бернинди эше, бернинди кайгысы юк кебек иде.

## V

Карлар явып, көн салкыны бераз тернәкләнә төшкәч, авылда сугымнар башланды. Әлбәттә, халык әле олы малга тотынырга ашыкмады: үрдәген-казын, сарыгын-бәрәнен чалып, табынына ризык өстәде. Кешеләр кунакка йөрешге. Шәһәр ягыннан туган-тумачалар кайтты.

Сабирҗановлар гаиләсе дә кунак-төшемсез калмады. Башта Әхмәтгалинең олы кызы Айсылу ире Мәҗит белән кайтып төште. Нәкъ шул көнне төпчек малайлары Хәбирдән «Кайтабыз...» дигән хәбәр-телеграмма килде.

Айсылуның ата йортында юньләп күренмәвенә инде өч-дүрт ел тула иде. Туганлык һәм сагыну хисләрен хат һәм бәйрәм котлаулары, почта аша җибәрелгән күчтәнәчләр белән генә белдереп яшәгән Айсылуның кайтып төшүе көтелмәгән зур шатлык булды.

Айсылу башта яңа йортка бик шатланды, нарат исе аңкып торган бүрәнәләрне кат-кат иснәп карады — иснәп туймады. Аннан соң, эшнең нәрсәдә икәнен белгәч, шактый тузынды, өйдәгеләрнең һәммәсен — этисен дә, әнисен дә, Әхсәнне дә орышып ташлады:

— Ниткән эш инде бу, ә?! Шундый бәла килеп тә, безгә хәбәр итү юк. Туганнарга белдерү юк! Кешеләр, әнә, тавыгы аксап йөрсә дә — туганнарына барып егылалар, каз алып кайталар. Ә болар, имеш, йорт хәтле йортны үзләре генә җиткерә! Әхсәннең уенда булмаса, әткәй-әнкәй, ичмасам, сез уйлар идегез! Дөрес бит, Мәҗит?

Авыр гәүдәле, басынкы табигатьле Мәҗит хатынын куәтләде:

— Соң, шулай кәнишне! Айсылу дөрес әйтә, алай ярамый бит инде, бабай... Без ярдәм итә алмас идекме әллә?

Боларның шулай тузынуы, күрәсең, Әхмәтгалигә рәхәтлек кенә бирә иде. Күңеле күтәрелеп, кызын үчекләп, шаяртып җавап кайтарды:

— Ярар, балалар, бу йорт искергәч, иң беренче эш итеп, сезгә тилиграм сугам. Анысының инде бер почмагы сезнең өлештән булыр...

— Әстагъфирулла! — Гөлчирәтти битен яулык очы белән каплап көлде.— Әле син, оялмыйча, шушы йорт искергәнчегә тиклем яшәмәкче буласыңмыни?! Картая торгач, тәмам сабыйлар акылы кергән моңа!..

Айсылу күчтәнәчләрен чыгарды. Өйдәгеләрнең берсе дә өлешсез калмады. Әтисенә дигән күчтәнәчен-бүләген соңгарак калдырган икән:

— Менә, әткәй, картлар арасында йөрим дип язган идең, бөтенесен көнләштереп киеп йөр әле! — дип, чигүле түбәтәй чыгарды.

Табын артына утыргач, Айсылу кинәт кенә тынып калды, күзләренә сәер бер моңсулык чыкты. Юкка гына булмаган икән, кинәт кенә әйтеп куйды:

— Шулай гел көтмәгәндә, хәбәрсез-нисез кайтып төшүебезгә аптырагансыздыр инде, әйеме? — үзе, җавап та көтеп тормастан, тезеп китте: — Сагындым мин, әнкәй, үлеп-үлеп сагындым. Каз өмәләрен... Кешегә сөйләсәң — кеше ышанмас, билләһи. Төшләремә керә башлады. И, матур да була иде бит ул бездә каз өмәләре! Әллә үзем дә картаеп барам инде: исәр кеше сыман, үзалдыма сөйләнеп, җырлап йөрим. Нигә шулай сагынамдыр?!.

Айсылуның сүзләре барысына да тәэсир итте, уйчанланып, тынып калдылар. Гөлчирәтти күз яшьләрен сөртеп алды, торып килеп, кызының аркасыннан какты:

— Әй, балам, җан да тарта, кан да тарта инде ул туган якка. Туган җирең, туып-үскән нигезең каз өмәсе булып төшләреңә кергән синең...

— Уйлаштык-уйлаштык та, быел юлга җыендык шулай. Ялыбыз бары бер әрәмгә кала иде. Мәҗиткә рәхмәт, ул да каршы килмәде: «Бабайның бер сыерын ашап бетереп киләм әле, болай булгач!» — дип көлә. Ә сез монда, малларны сата-сата, үзегез генә йорт җиткергәнсез...— Айсылу, әллә күңеле тулып, әллә инде үзенең артыграк сөйләп ташлавын сизеп, туктalып калды.

— И кызым, авыл җирендә ит бетә димени?! Берүк юкны сөйләмә! Бик әйбәт булган, кайтуыгызга рәхмәт,— Гөлчирәтти чак кына туып алган бушлыкны шул сүзе белән тутырды. Әхсән дәшмәде. Әхмәтгали карт тамак кырды. Ирләрнең дә күңеле йомшарган, алар үзара сүзсез генә аңлашалар иде.

Нәкъ шул чакта Әхсәнне идарәгә дәшеп киттеләр. Яңа гына кайтып төшкән кунакларны ташлап чыгып китү кыен иде. Шуңа күрә:

— Нәрсәгә икән? — дип кабатлап сорады. Хәбәр китергән малай, ничек керсә, шулай чыгып чапты. Ярым ачык калган ишектән:

— Белмим, персидәтел кушты! — дигән тавыш кына ишетелеп калды. Әхсән киенде. «Озакламаска тырышырмын»,— дип, чыгып китте.

Урам буйлап атлаганда апасы Айсылуның сүзләре турында уйлады ул. «Каз өмәләрен сагындым, кешегә сөйләсәң — кеше ышанмас», диме? Ышанган кеше ышанып, апа, ышанып... Читтәгеләр генә түгел, авыл кешесе үзе дә ышанып моңа. Кайчан булганы бар хәзер авылда элекке төсле өмәләрнең? Үзгәрде авыл, апа, нык үзгәрде. Элек, бәрәңге утыртасы булса, ярты авыл бер-беренә өмәгә җыела торган иде. Ә хәзер? Күмәк хуҗалык дип аталган җирдә күмәклек бетте, кирегә китте...

— Әй, абый, ал ишәгеңне — ат килә!

Әхсән, сискәнеп, артына борылып карады. Иңенә көянтә-чиләк аскан кыз, елмаеп, җиңел генә атлап, аны куып җитеп килә иде. Әхсән, сукмактан чыгып, көрт эченә кереп басты, кызга юл бирде. Кыз аңа таныш түгел иде, мөгаен, берәрсенә кунакка кайткандыр.

Әхсән аның килешле, матур буй-сынына, көянтә-чиләкләренә игътибар итте.

— Нәрсә, әллә колонкаларда су юкмы? — дип кычкырды ул, кызның чишмә юлыннан күтәрелгәнен аңлап. Кыз чак кына борылды:

— Бар. Тик безгә чишмә суы кирәк! Бәйрәм бүген бездә, абый.

— Нинди бәйрәм?

— Каз өмәсе бүген бездә! Кунакка килегез, абый, белен ашарга! — кыз челтерәп көлде.

— Каз өмәсе?! — монысын инде Әхсән, үзе дә сизмәстән, гаҗәпләнеп әйтте.— Син кемнәргә килдең соң, кемнәрдә каз өмәсе?

Кыз тукталды. Борылып, Әхсәнгә туры карады:

— Әй, Әхсән абый, күзегез күрми икән сезнең. Бу авылда ике ай торам бит инде мин, мәктәптә укытам...— кыз, янә бер челтерәп көлде дә, үз юлы белән китеп барды. Ә Әхсән баскан урынында торып калды. Каз өмәсе турындагы сүзне бүген инде менә икенче тапкыр ишетүе әллә нинди могҗизаны хәтерләтә кебек иде. «Әсматтиләргә фатирга урнашкан укытучы кыз инде бу, алайса»,— дип уйлады ул һәм үзенең мәктәпкә бик күптәннән аяк басмаганын сизде. Мәктәп... Үзең укыган мәктәп. Анда синең малай чагыңны кабатлаган, нәкъ синең кебек үк хыялланып йөргән малайлар-кызлар укый. Анда — синең үз балаларың. Сорашканың бармы, күргәнең бармы мәктәп хәлләрен, парторг? Шул сорауны үз-үзенә бирүгә үк, акланырдай җавап тапты Әхсән: анда аңа тикле партия оешмасы секретаре булып эшләгән Мортазин Хәмәт директор булып килгән иде. Үзен парторглыктан төшерүләренә әллә ни исе китмәгән кебек күренсә дә, үз урынына Әхсәнне сайлауларын белгәч, сүз әйтми калмаган икән Мортазин. Әхсән, әлбәттә, моны кеше аркылы гына ишетте. Ишетте дә онытты: ферма мөдире булып эшләгәндәге чәкәләшүләр — эш өчен барган бәхәс, ә инде кеше телендә йөргән сүз — бүген бар, иртәгә юк, дип кенә кабул итте. «Кая ул Сабирҗановка партия эшендә эшләргә, башта дөрес язарга өйрәнсен әле. Минзәлә техникумы белеме белән аңа шул дуңгыз карап кына йөрергә...» — Мортазинның имеш-мимешләр буенча ишетелгән бу сүзен дә дөрес дип тапты: белеме, тәҗрибәсе юклыгын үзе дә бик сизеп, белеп тора иде.

Сизү генә түгел, бу хакта райкомда, әле үзен парторглыкка димләгән чакларында ук әйтте. «Безгә бүген саф белеме булган кешеләр түгел, халык алдында абруй казанган, эш өчен янып-көеп йөрүче коммунистлар кирәк. Без сезне, иптәш Сабирҗанов, нәкъ менә шундый кеше итеп беләбез,— диделәр аңа.— Ә уку мәсьәләсенә килгәндә — укырсыз, өйрәтербез...» Әхсән инде Мортазинның сүзләре турында онытКан, күптән оныткан иде. Шуңа күрә, мәктәпкә кермәвен, кызыксынмавын шул бер сылтауга гына калдырып, акланып баруын үзе дә аңлап алды. Оят булып китте, үзеннән мәктәп турындагы уйларны куарга тырышты.

«Каз өмәсе...— дип уйлады ул, яңадан теге кызның сүзләрен искә төшереп.— Чишмә суы кирәк...» Әнә шулай, аяк астындагы карны шыгырдатып атлаганда, Әхсән үзе өчен бер ачыш ясады: юк, каз өмәләрен генә сагынмаган аның Айсылу апасы. Ул үзенең яшьлеген, авылның яшь чагын сагынган. Элегрәк кайткан елларны да кичке уеннарны, басудагы күмәк эшләрне, печән чабу вакытларын искә ала иде. Юк шул, үтте авылның андый көннәре. Яшьләрне якындагы һәм ерактагы шәһәрләр, төзелешләр тар-

тып алды. Кичен берәрсе гармун күтәреп чыкса, аны — йә исерек, йә исәр, диләр. Клубта лекция-мазар булса — халыкны җыеп булмый. Концерт куелса — залның яртысы буш. Нилектән?

Нилектән шулай? Бервакыт Әхмәтнәҗип абыйсы белән бу хакта бәхәсләшкәннәр иде. Укытучы аңа өздереп җавап бирде:

— Кадер юктан,— диде. Әхсән моны аңламый калды, кабатлап сорады:

— Ничек инде кадер юктан? Кемгә кадер юктан?

— Кешеләргә кадер булмаудан,— диде укытучы.

— Син инде, абый, юкны сөйләмә,— дип кызды Әхсән ул чакта.— Эш кешесенә кадер юкмы бездә? Көчеңне кызганмыйча, ялкаулыкка бирелмичә генә эшлә — барысы да була. Акчасын кызганмый түлиләр кешегә, бүләген-мактавын яудырып торалар. Йорт-җире җитешле. Тагын нәрсә кирәк?

— Кадер кирәк, энем,— диде укытучы.— Кадер кирәк...

— Килешмим бу сүзең белән, абый! Дөресрәге, килешеп бетмим. Үзең үк күреп торасың: хәзер эшләгән кешегә акчасын да бирәләр, орденын да тагалар.

Укытучы көлемсерәде:

— Сөтле сыер белән нәселле сарыкның да үзенә күрә кадере була, энем. Кем әйтмешли — хезмәтенә күрә хөрмәте. Ә кешегә кадернең башкасы кирәк. Безнең бөтен ялгышлар, бөтен югалтулар әнә шул кадер булмаудан. Без халыктан аның үз бәйрәмнәрен, үз йолаларын тартып алдык, көчләп оныттырдык. Без халыкка ясалма йолалар тактык, ясалма тарих, ясалма киләчәк белән алдадык. Туйганчы кадерсезләдек, халык фикерен санга сукмадык, аны сукбайлыкка чыгардык. Әйе-әйе, кешегә кадер кимегән җирдә сукбайлык арта. Ә сукбайлары күбәйгән ил үзе дә сукбайлыкта кала. Кызганыч, әмма менә шулай, энем... Ә син әйтәсең: халык клубка йөрми, кызыксынмый, китап укымый, битараф, дисең. Ә кем гаепле?..

«Кем гаепле? Кем?..» — бу сүзләр Әхсәннең колагында яңгырап йөрде.

Әхсән, үзенең артык ашыгып атлавын сизеп, кинәт адымын акрынайтты. Болай дуамалланып баруын кеше-кара күрмәде микән дип, артына ук борылып карады. Һәм гаҗәпләнде: колхоз идарәсен дә, авыл советы бинасын да шактый узып киткән иде...

— Чакырган идеңме, Әмирхан абый? — дип, ишектән үк исәнләште.— Бер-бер, ашыгыч эш бармы әллә?

Әмирхан Шакиров ике куллап күреште:

— Бар иде шул, ашыгыч эш бар иде. Син, Әхсән энекәш, бөтен авылны оятка калдырырга уйлыйсыңмы?

— Аңламадым мин сине, Әмирхан абый?!

— Аңладың, бик яхшы аңладың. Аңламаганга гына сабышасың.

— Чынлап әйтәм, Әмирхан абый!

— Ярар, аңламасаң, аңлатырбыз. Айсылу апаларың кайттымы кунакка?

— Әйе... Әле генә. Ире белән кайтып төштеләр.

— Соң?..— Әмирхан сораулы карашы белән төбәлде.— Ничегрәк кунак итмәкче буласың инде син аларны? Өстәлгә каймакны, майны, сөт-катыкны ничегрәк куясың, йә? Күршеләрдән алыпмы?

Әхсәннең ни әйтергә белми аптырап торуын күргән Әмирхан кулын гына селтәде:

— Акланып маташма, беләм мин сине. Авызыңа китереп каптырмасалар, үзең сорап ала белмисең. Элегрәк минем дә, ничектер, башка килмәгән. Соң, синең бит балаларың бар! Әллә аларга сөт кирәк түгелме? Менә кәмит, ә! Сыерларын саттылар да, рәхәтләнеп типтереп яшиләр хәзер. Мал карыйсы юк, абзар чистартасы юк. Әле ярый Сәҗидәң фермада эшли. Югыйсә, сыер җилененең нинди булганын да онытыр иде. Сезгә рәхәт, ә менә сезнең аркада бөтен авыл оятлы булырга тиеш!

— Шаяртасыңмы син, Әмирхан абый? Нинди оят? Нишләп авылны оятка калдырыйм ди мин?!

— Шаяртам?! — Әмирхан урыныннан ук сикереп торды.— Нишләп шаяртыйм, ди мин? Мин дөресен сөйлим! Безнең авылга кайткан һәр кунак авылның матурлыгын, тазалыгын, көчен, байлыгын, сый-хөрмәткә муллыгын күреп китәргә тиеш. Читкә киткәннәр ишетеп көнләшерлек булсын! Көнләшүдән эчләре сызласын! Кунак булып киткәннәрнең телендә авыл булсын, мондагы катык-каймакның тәме иреннәрендә торсын! Онытылмыйча сөйләп йөрсеннәр. Авыл җире өчен көрәш әнә шулай да барырга тиеш, ми-

немчә. Юк-юк, син көлмә! Зур политика бу. Без хәзер үзебезнең авылны әнә шулай итеп тә сакларга тиеш. Шунсыз булмый. Ә син нишлисең? Апаларың кайткан, аларны сыерсыз абзар, майсыз-катыксыз табын белән, ярык тагарак белән каршылыйсың. Озын сүзнең кыскасы шул: иртәгә үк колхоздан сыер аласың. Бәясен әкренләп түләрсең. Ит тә яздырып ал. Кара аны, минем йөзгә, авылдашлар йөзенә кызыллык китерәсе булма! Менә шул, әйтәсе сүз дә, йомыш та шул иде сиңа.

Әхсәннең күңеле тулды. Башта аның уена бер шик төшкән иде. Әмирханның яшьлегендә Айсылу апасын яратып йөргәнлеген, үзе армиядә чакта Айсылуның читкә китеп, башка берәүгә кияүгә чыгып калуын бик авыр кичергәнлеген белә иде Әхсән. Монысы малай чактан ук хәтерендә калган. «Әллә соң шуның берәр шаукымы микән бу, үзенчә бер үч алуы яки минминлеген күрсәтүеме?»,— дип уйлап куйды ул һәм бу уеннан үзе үк оялды. Юк-юк, Әмирхан абыйсы андый кеше түгел. Авыл турында уйлый, киләчәк турында уйлый — шуңа күрә кузгата бу сүзне. Әхсәннең күңеле тулды, үзе дә сизмәстән, әйтеп ташлады:

— Карале, Әмирхан абый!.. Авылда берәр бәйрәм ясыйсы иде бит. Күптән узганы юк... Кыр эшләрендә тырышты халык. Алны-ялны белми эшләде. Чөгендерне кар астыннан диярлек алдык. Аннан соң да ял булмады. Берәр бәйрәм, халыкның үзенә якынрак бәйрәм уздырасы иде, каз өмәсе кебегрәген, ә?

— Каз өмәсе?! — Әмирхан аңа гаҗәпләнеп карап торды.— Син, энекәш, моны үзең уйлап чыгардыңмы, әллә берәрсе өйрәттеме? Ничегрәк үткәрергә уйлыйсың син аны?

— Ничегрәк икәнен үзем дә белмим. Бәлки, белдерү язып эләргә кирәктер... Картларны, өлкәннәрне дә чакырып. Яшьләрне дәшеп. Авыл турында сөйләшергә, авылның үз йолалары турында, үткәне турында сөйләшергә. Чәй куеп, беленнәр пешереп, концерт куеп... Югыйсә, көтүчегә әйләндек бугай инде.

Әмирхан гаҗәпләнеп карады:

— Ничек инде? Нинди көтүче?

— Әхмәтнәҗип абыйның сүзен әйтәм. Үз халкын көтү итеп куып йөрткән кеше берзаман үзе дә көтүчегә әверелә икән, ди. Тәкъдире шундый, ди. Чөнки янәшәсендә бер генә киңәшер кешесе дә калмый. Шул — кулындагы чыбыркысы да, башындагы тишек эшләпәсе генә кала. Шуннан соң инде үзе дә гел көтүче булып кала икән. Эшләпәсе белән генә киңәшеп яши торган көтүче, ди.

— Менә-менә! Әйбәт әйткән Әхмәтнәҗип карт! Әйе, кулда — озын таяк, башта — ертык эшләпә! Ә үзебез халыктан активлык сорыйбыз... Юк, Әхсән, ертык эшләпә андый киңәш бирә алмый, көтүче демократия тудыра алмый. Аны менә без, авылдашлар, үзебез тудырырга тиеш.

«Озакламам»,— дип чыгып киткән Әхсән йоклар вакыт җиткәч кенә кайтып керде. Аны өйдә яңалык көтә иде. Әхмәтгали карт Әхсәннең каршысына килде, үзенә хас булмаган бер дулкынлану белән, кулындагы кәгазен сузды. Бу — Хәбирдән килгән телеграмма иде. Әхсән шунда гына өйдәге сәер халәтнең, шатлыклы хәрәкәтнең сәбәбен аңлап алды.

— Кайталар бит, исән-имин кайталар бит, ходаем!..— Гөлчирәтти, үзен кая куярга белмичә, әрле-бирле йөренде. Әхмәтгали карт бер урынына — өстәл башына барып утырды, бер кире торды. Сәҗидә, килендәшен кат-кат телгә алып, истәлекләрен сөйләргә керешге. Хәбирнең хатынын Айсылуның да, Мәҗитнең дә әлегәчә күргәннәре юк иде. Ләкин алар бүтәнчә дулкынлана: аларның олы уллары шунда, Хәбирләр булган җирдә — Әфганстанда хезмәт итә иде.

— Кайниш маладис,— дип кулларын уды Мәҗит.— Вакытын белеп кайта. Күптән күрешкән юк үзе белән. Кайткач сорыйм әле, безнең малайны күрмәде микән?

Шатлык хәбәре килү уңаеннан күздән ычкынган һәм әле һаман да йокларга ятмаган балаларның үз шатлыгы бар иде:

— Хәбир абый кайта! Күчтәнәч алып кайта!..

Бу көнне Сабирҗановлар йортындагы тәрәзәләрдә ярты төнгә кадәр ут сүнмәде.

## VI

Бәйрәм кичәсе көтелгәннән дә күңеллерәк килеп чыкты. Аның буласын игълан язып та, җирле радиодан да хәбәр иткәннәр иде. Клубта инде күптәннән аяк басмаган картлар-карчыклар, алдан ук килеп, түрдән урын алып калдылар. Механизаторлар, савымчылар ул көнне эшне иртәрәк төгәлләргә ашыкты. Шәһәрдән ялга кайткан яшь-җилкенчәк, башка чаклардагы кебек, клуб болдыры төбендә таптанмады, халыкның бу кадәр җыелуына гаҗәпләнеп, «Тагын ни булыр?» дигән кызыксынуны яшермичә, алгарак узарга тырышты.

Әхсән, кичәне башлап җибәрү өчен, үзе берничә генә сүз әйтеп китмәкче булды. Озакка сузмады, күңелендәгесен әйтте. Авылның элекке чакларын, күмәк вакытын, матур йолаларын искә алды. Шушы авылдан чыккан кешеләрнең исемен атады. Ничектер, тел очына килеп, беренче класска укырга кергән балаларның саны дүрт-биштән узмаганын әйтеп алды. Бүгенге кичәнең авыл турында зур сөйләшү, чын күңелдән гәпләшү, уртага салып фикер алышу икәнен әйтте. Шуннан соң китте: әйтерсең, кемдер буылып торган суны ерып җибәрде. Могтәбәр картлар кузгалып сүз башлады. Карчыклар чәчрәп-чәчрәп чыгып сөйләде. Зиратның ватылган коймасы, ферма көтүе кергән әрәмәлек, кибеп-корып барган чишмәләр, авыл көтүен йөртергә болын калмау, яшьләрне — картлар, картларны яшьләр белмәү, олыламау — барысы да сүз артыннан ялганып-ялганып китте. Инде кичәнең концерт өлешен башларга, биючеләрне, җырчыларны чыгарырга вакыт иде. Әмма халык туктамады, күңелендәгесен бушатып бетерергә тырышты. Колхоз рәисе Әмирханга нык эләкте: тегермәннең эшләгәне юк, ипине район үзәгеннән ташыйсы — юньле җитәкче шундый эшне сузып торамы? Әхсән үзен әле бер читтәрәк калыр дип уйлаган иде. Әмма алай язмаган икән:

— Менә сез, җитәкче кешеләр, халык та халык, авыл да авыл, дисез. Имеш, авылны сакларга кирәк, якларга кирәк, яшьләрне монда калдырырга кирәк. Ә нигә алдыйсыз? Нигә сүздә тормыйсыз? Әхсән абыйның миңа әҗәте бар, әле һаман биргәне юк! — клубтагы халык артка, иң арттагы рәттә басып торган Ильяска борылып карады.

— Нинди әҗәт тагын?

— Күпме аласың бар? Әйтеп сөйләш!..

— Әллә ни күп түгел түгелен, әмма бар.— Ильяс бүреген кырын салып, хәйләкәр елмайды.— Бар бит, Әхсән абый, әйеме?

Әхсән аптырап калды. Нинди әҗәт? Каян килгән әҗәт? Хәтерләми иде Әхсән андый нәрсәне. Шуңа күрә:

— Син, Ильяс, аңлатып сөйләш,— диде.

— Һы! Онытты да мыни, Әхсән абый?! Теге чакта, басуда... Үзең әйттең бит, урак беткәч, дидең. Онытуы килешми, Әхсән абый, ярамый... Онытсаң, исеңә төшерәм, сөйләп бирәм!

Келт итеп хәтеренә төште Әхсәннең: әйе шул, әйткән сүзе, әҗәте бар иде аның бу егеткә.

Урак тәмамланып килгән көннәр, кылны кырыкка ярырлык вакытлар иде. Район үзәгеннән мотоциклда кайтып килгән Әхсән басу уртасында туктап калган комбайнга, машиналарга игътибар итте. Ватылып тукталганнармы? Бер-бер хәл килеп чыкканмы? Шулай уйлап, юлдан борылды. Барып җиткәнче үк ишетте: комбайн да, машиналар да эшләп тора иде. Димәк, ватылып туктамаганнар. Эш нәрсәдә? Комбайн янында сузылып яткан кешеләр аның мотоцикл тавышын ишетмәде. Әхсән күрде: уртага табын җәйгәннәр, суган, кыяр, помидор ише нәрсә тураганнар. Башланган бер «ярты» янәшәсендә бушаганы тора. Әхсән якынрак килде, исәнләште. Егетләр, аны күрүгә, сикерешеп тордылар:

— Тамак ялгап алмакчы идек әле, Әхсән абый,— дигән булдылар.

— Их, егетләр!..— диде Әхсән,— Сөйләштек бит, урып-җыю беткәнче — коры закон, дидек. Нишләп инде алай итәсез?

— Ә кайчан бетә ул урып-җыю? Аның беткәнен көтсәң, эчең кортлый башлар! — нәкъ менә шул сүз, читтән ярдәмгә «Уборочная» машинасы белән килгән шоферның урынсыз шаяртуы чыгырыннан чыгарды Әхсәнне. Башланган аракыны җиргә түкте:

— Болай эчеп йөрсәк, бетмәс тә ул урак!

Егетләр кызмача иде. Түгелгән аракыны күргәч, бөтенләй үзгәреп киттеләр, Әхсәнгә бәйләнделәр:

— Ә ник түгәсең әле син аны? Әллә үз акчаңа алынганмы?!

— Минекенәме, сезнекенәме — барыбер! — диде Әхсән.— Эш вакытында кем эчә?!

— Ярар, эш вакытында эчкәнбез икән — безнең гаеп. Штраф сал, премияне кис! Ә кеше акчасына алынганны, кеше әйберен ник түгәсең?! Кем сиңа андый права бирде?! Бәлки мин монысын хатынның аркасын сыларга калдырырга уйлаганмындыр? Ник түгәсең?!

— Сезнең шул булыр ул, начальствоның! Кеше әйберенә хуҗа буласыз!

Әхсәннең ачуы килде, кесәсеннән акча чыгарды:

— Алай икән — түлим. Кайсыгызга акча?

— Юк инде, Әхсән абый! — диде шулчак Ильяс. — Син безгә натурала та түлә!

— Әйе! Ни пычагыма безгә синең акчаң?! Син безгә үзебезнекен бир!

— Авыз итәргә дә өлгермәдек бит, ичмасам, шайтан!

Әхсән егетләргә карап торды. Аннан соң машиналарга борылды: моторлары эшләп тора.

— Ярар, егетләр... Сүзне озынга сузмыйк. Эш көтә. Ә түләвен түләрмен. Урак беткән көннең икенчесендә үзем бер литр бирермен.

Урак бетте. Ул чактагы күп кенә йокысыз төннәр, мәшәкатьләр һәм бәхәсле минутлар артта калды.Ильяска бирелгән вәгъдә дә, әлеге әҗәт тә оныт тылды. Ә менә Ильяс онытмаган икән. Күңелендә йөрткән, җаен көткән. Кара син аны, нинди вакытта чыгара бит, бөтен халык алдында... Уңайсыз, бик уңайсыз хәлдә калды Әхсән. Ни дип җавап бирергә Ильяска? Гомумән, Әхсән аны эш вакытында эчүдән йолып калган икән, әле тагын әҗәт түләргә тиешме ул? Һәм мондый нәрсә әҗәт булып санала аламы? Ә вәгъдә? Ә әйтелгән сүз?

— Ярар, Ильяс энем, — диде Әхсән, ниһаять. — Мин онытмадым. Мин синнән бер ярты аракы алып торган идем. Мин аны сиңа түләрмен.

— Юк, Әхсән абый! Син аны миннән алып тормадың. Син аны, без уракта чакта эчкән өчен, җиргә түктең. Һәм дөрес эшләдең. Синең урыныңда булсам, мин дә шулай итәр идем. Анысына рәхмәт кенә әйтәм мин. Безнең ул эш турында кешегә сөйләп йөрмәдең, тавыш кузгатмадың, штраф салмадың, премияләрне кисмәдең — анысына да рәхмәт. Тик син хәзер миңа әҗәтеңне бүтәнчә түләргә тиеш. Чөнки вакыт күп үтте, әҗәт өстәп түләүне сорый. Ә өстәп түләүнең шарты шул, — Ильяс, сүземне ничегрәк кабул итәрләр икән дигән сыман, сузып торды... — Мин Әхсән абый өйләнергә йөрим. Ә туй үткәрергә кибеттә аракы юк. Үзем көне-төне эштә, шәһәргә барып йөрергә вакыт калмый. Син, Әхсән абый, әҗәтеңне шулай түлә: йә — кибеткә аракы кайтарт, йә шәһәрдән үзең алып кайтып бир. Акчасы — миннән!

Халык гөж килде, бераүләр Ильясны тиргәде, икенчеләре хуплады. Ыгы-зыгы купты:

— Өйләнәм дип сөйләнә генә ул!..

— Тапкан өйләнер вакыт! Аракы гына кирәк аңа!

— Ә нигә?! — дип тавышын күтәрде Ильяс, үзенә игътибар итүләреннән дәртләнеп. — Үзебез авыл турында сөйләшәбез, үзебез һаман мескен булып яшибез. Шәһәрдә саталармы хәмерне — саталар! Ә авылда нишләп юк? Нәрсә, әллә шәһәр кешесенең ашказаны алтыннан ясалганмы?! Ашау-эчү мәсьәләсендә һәр кеше тигез булырга тиеш. Шунсыз тигезлек турында сөйләшеп торасы да юк!..

Әхсән шаулашкан халыкны туктатты:

— Ильяс энем, син әле өйләнүең турында беренче тапкыр әйтәсең. Туй үткәрү турында иркенләп сөйләшербез, әйдә, бүген кичәне дәвам итик, концерт карыйк, — дип, сүзне бүтәнгә борды. Җыелган халык та бер гөләп алды, шундый матур кичәне бүтән якка борган өчен Ильясны шелтәләде. Ләкин, ни генә булмасын, бу вакыйга Әхсәннең күңелендә берегеп калды.

Концерттан соң да халык таралмады. Картлар кат-кат килеп рәхмәт укыды. Авыл урамында гармун тавышы ярты төнгә кадәр тынмады.

Шул кичәдән соң авылда каз өмәләре ешаеп китте. Кешеләр, үзара сөйләшеп куйгандай, бер-берсен кунакка алдырдылар. Авылда Айсылуның ахирәтләре күп иде. Алар аш-судан кайтып та кермәде диярлек. Алар белән бергә, Әхмәтгали картны да, Гөлчирәттине дә еш дәштеләр. Сабирҗановлар үзләре дә аш үткәрмәкче булып йөриләр. Хәбирләрнең генә кайтуын көтәләр иде.

Инде Айсылуның күңеле басылды. Инде Мәҗит тә «Кунак гомере — өч көн» дигән сүзләрне кабатлый башлады. Әмма аларны җибәрергә ашыкмадылар, кат-кат кыстап, китү турындагы уйларыннан кире кайтардылар. Айсылу белән Мәҗитне тотып торган тагын бер сәбәп бар иде: Хәбирдән хәбәр килеп тә, аның һаман кайтып төшмәве аларның да күңелен борчып тора иде. Хәбирне күрмичә, андагы хәлләрне сорашмыйча, уллары турында белешмичә китү мәгънәсезлек тә, гөнаһ та булыр сыман иде.

Нәкъ менә шундый көннәрнең берсендә колхоз рәисе Әмирхан Әхсәннең күңеленә шик-шөбһә салган бер хәбәр әйтте:

— Безнең өстән кемдер югарыга шикаять язган, Әхсән. Партия оешмасы эшен тикшерергә мөмкиннәр, итәк-җиңеңне җыебрак, кәгазь-мазарларыңны караштырыбрак йөр, — диде. Нинди шикаять? Нәрсә хакында? Кем язган? Монысын Әмирхан әйтмәде. Үзе шаяртты:

— «Беләм, ләкин әйтәлмыйм!» — дип, урамда кычкырып йөргән бер кеше турында укыганың бармы? Бер дусты моны кызганган: «Ябыгып беттең, сереңне миңа гына әйт, мин беркемгә дә чыгармам», — дигән.

Тегесе ант алган, серен ачкан. Шуннан соң, бу дусты үзе үк: «Беләм, әмма әйтәлмыйм!» — дип кычкырып йөри башлаган. Юләрләр йортына ябып куйганнар, ди, шуннан соң үзен...

Хәер, шикаятьнең төп эчтәлеген Әмирхан үзе дә ахырынача белми иде. Анда сүз Әхсән Сабирҗановның парторг булып эшләргә хакы юклыгы, ниндидер ялгышлары, гаепләре турында булса кирәк — райком секретаре Бикташевның сүзеннән шуны гына аңлады Әмирхан. Әлбәттә, шикаятьнең кем тарафыннан язылган булуы белән дә кызыксынды. Бикташев авыр сулады:

— Имзасын куймаган,— диде.

— Соң, алайса бу гап-гади анонимка бит инде! — дип кызды Әмирхан. Бикташев көрсенде:

— Иптәш Шакиров! Партия, әгәр үзенә кирәк дип тапса, анонимканы түгел, шайтаныңны да тикшерә!

— Ничек инде ул алай? Кем ул партия?! Без үзебез партия түгелмени?! Без, мәсәлән, Сабирҗанов Әхсәннең кем булуын, ничек эшләвен, ничек яшәвен белмибезмени! Без, шул имзасыз хатка ышанып, партия оешмасы секретареның исемен шик астына куябызмыни?!

— Бу очракта мин, партия дип, югары оешмаларны әйттем, иптәш Шакиров. Хатта әйтелгән: язманың бер нөсхәсе партиянең өлкә комитетына җибәрелде, диелгән.

— Соң шуннан? Җибәрелсә ни?! Анда, партиянең өлкә комитетында, Әхсән Сабирҗановны безгә караганда яхшырак беләләрмени?

— Эш анда түгел...

— Ә нәрсәдә соң? Эш нәрсәдә?

— Мәсьәлә сез уйлаганга караганда шактый катлаулырак, иптәш Шакиров. Һәрхәлдә, бюро җыеп, Сабирҗановның эшен карарга, бу хатны тикшерергә тиеш без. Югыйсә, обком алдында януыбыз бар. Шалтыратып Сабирҗанов белән кызыксындылар инде. Күңелем сизә, комиссия килми калмас...

Монысы инде Әмирханны тагын да ныграк гаҗәпләндерде. Аның күз алдында эшләп, тырышып йөргән Әхсәннең шулай обком кызыксынырлык нинди гөнаһы бар?

Шулай уйлап, Әхсәнне кисәтеп куярга теләде ул. Әмма, вакытыннан алда борчымас өчен, турысын әйтергә ашыкмады: безнең башлангыч оешма эшен тикшерәләр, диде.

## VII

Алар урам чатында капма-каршы килеп бәрелештеләр.

Хәбир, иртән иртүк кузгалып, базарга ашыга иде. Кызына алмалар, яшелчә-җимеш алып барырга иде аның исәбе. Бауман урамыннан колхоз базарына илтә торган чатка борылуга, каты бәрелүдән күз аллары караңгыланып китте. Үзе, баскан урынында чайкалып, ашыгып кабатлады:

— Гафу итегез... Ялгышлык белән... Гафу итегез...

— Карап йөрергә кирәк! — кар өстенә чәчелгән кәгазьләрен «дипломат»ына тутырып маташкан ирнең тавышы кырыс чыкты. Хәбир инде китеп бармакчы иде, кинәт бу тавыш аңа артык таныш булып тоелды. Әлеге ир аның

карашын сизде, күтәрелеп карады, гаҗәпләнеп аптырап калды:
— Хәбир?.. Синме бу, Хәбир?!
— Таһир!..
Бу очрашу икесе өчен дә көтелмәгән хәл, гадәттән тыш бер хәл иде. Кинәт кочаклаштылар. «Нигәдер бик йончыган, таушалган»,— дип уйлап алды Хәбир һәм шунда ук уйның ишетелми торган нәрсә булуына шатланып куйды. Кочаклаштылар, әмма сүз ялганып китә алмый торды. «Нихәл, дускай?!», «Исәнме-саумы?!» кебек сүзләрдән узмады. Әйтерсең, аларның һәр икесен ниндидер тимер кыршау чолгап алган, шул кыршаудан аз гына чыксалар да, нидер булыр, нидер җимерелер кебек. Ниһаять, әлеге кыршауны беренче булып Таһир атлап чыкты:
— Менә бит, кире беткән кәҗә тәкәләре кебек, урам чатында килеп сөзештек! Кара, син ничек үзгәргәнсең!.. Урамда тукмап китсә дә танымас идем, дигән сүз шушыдыр инде ул?!
Бу шаяру урынлы булды. Югыйсә, икесе дә бик кыен хәлдә иде.
— Шул буладыр, — дип җавап бирде Хәбир.— Син дә үзгәргәнсең. Ир булгансың.
— Дөнья үзгәртә. Ә нишләп монда басып торабыз соң әле без? Әйдә соң, кереп утырыйк берәр җиргә! — Таһир сәгатенә карап куйды.— Түлке, әле бер җир дә ачык түгел икән. Бездә шулай инде, иртәнге якта базардан башка бүтән җир эшләми.
— Менә мин дә базарга ашыга идем әле. Аласы әйберләр бар.
— Син соң, ни... Узып барышың дип әйтимме?
— Авылга кайтып барыш иде. Телеграмма да җибәреп өлгергән идем. Тукталырга туры килде.
— Нәрсә, самолетка билетлар юкмы?
— Билет турында бөтенләй уйламаган да әле. Кызым авырып китте минем. Больницада ята. Алма алып барыйм дигән идем...
— Ә-ә... Ә ул анда әнисе беләнме?
— Юк, үзе генә.
— Ә ул?..— Таһир сүзнең кем турында барганлыгын ым белән генә аңлатты.— Ул кайда?
— Ул анда калды, чит илдә.
— Ә-ә... — Таһир, аңлыйм дигәнне белдереп, баш какты. Әмма ул бу минутта бары тик бер генә нәрсәне — үзенең Хәбир турында, аның язмышы турында берни дә, бернәрсә дә белмәвен, бөтенләй хәбәрдар булмавын гына аңлап алган иде.
Моны Хәбир, ничектер, күңеле белән сизде һәм, киеренке кыенлыкның артасын уйлап, китәргә ашыкты:
— Мин бик ашыга идем, Таһир, гафу ит...
Таһир кесәсеннән каләм белән кәгазь чыгарды.
— Тукта-тукта, Хәбир, болай булмый бит инде. Очрашмаганга, күрешмәгәнгә күпме...— ашыга-ашыга үзенең өй адресын язды.— Син бер килеп чык әле, яме?! Вакыт тапсаң, бүген үк кил. Чөнки мин тиздән командировкага китәм. Иркенләп бер сөйләшеп утырырбыз. Күптән бит күрешмәгәнгә... Иә, киләсеңме?
Хәбир адресны алды:
— Алдашу булмасын өчен, вәгъдә итмим, Таһир. Әгәр мөмкинлек булса, килеп чыгармын,— аннан соң, әйтергәме-юкмы дип, икеләнеп торды.— Бәлки, килеп тә чыгармын. Минзиләне дә күптән күргән юк бит.
Саубуллашып, икесе ике якка китеп бардылар. Бераз баргач, Таһир артына борылып карады. Хәбир тиз-тиз атлап еракლаша иде. Кинәт Таһир үзендә ниндидер шомлану хисе тойды. Әнә шул еракლаша барган гәүдәдән курку идеме ул, әллә аның еракლашуыннан курку идеме — монысын ул үзе аңламады. Бары тик «Ник чакырдым?!» дигән көйдергеч уй гына күңеленнән сызылып үтте. Әлеге уйны шунда ук янә бер үҗәт, үзсүзле фикер алыштырды: «Ә нигә? Килсен, күрсен — беткән эш беткән!» Үзен шулай дип тынычландырса да, күңелендәге шом югалмады, киресенчә, артканнан-арта гына барды. Әйтерсең, Хәбир аңа бүген урам чатында бәрелеп кенә калмаган, ә бәлки бөтен дөньясын әйләндереп ташлаган, инде ияләшенгән, күнегелгән, шулай булырга тиеш дип кабул ителгән нәрсәләрне кузгатып ташлаган иде.
Әйе, Минзилә белән ике арада барган нәрсәләргә Таһир инде тәмам ияләшеп, тормышының шулай агышына буйсынып, күнегеп бара иде. Әкренләп кенә, көн саен, минут саен еракლаша бару кешене үзенә һәрчак күнекте-

рә, иялаштерә ала. Таһир да моны үзенчә аңлаган, шулай булырга тиеш дип кабул иткән, үз-үзен шуңа ышандырган иде. Үзенең горурлыгы уянган, үз гаиләсенең язмышы турында уйланган, баш күтәрәсе, кычкырасы, ярсыйсы йә булмаса кемнәндер ярдәм сорап ялварасы килгән чакларын ул инде акылы белән басарга күнекте.

Күптән түгел Минзилә аңа үзенең бөтенләй китеп барачагын әйтте. Таһир бу көннең кайчан да бер киләчәген, туачагын сизеп, белеп йөри, әмма күңеле белән моңа ышанып бетә алмый иде.

Минзилә белән мөнәсәбәтләр кискенләшкән бер чагында Хәбирнең Казанга кайтып төшүе, бүгенге көтелмәгән очрашу, аны кунакка чакыру башка сыймаслык бер акылсызлык та, шул ук вакытта ниндидер бер өмет тә иде Таһир өчен. Һәм ул тагын шуны сизде: ни өчендер үз тормышын, үз язмышын бу минутта Хәбиргә бәйләп күзалдына китерә түгелме ул? Әйтерсең, моңарчы ул үз тормышын каяндыр читтән, еректан гына күзәтеп килгән дә, бүген инде шул тормышның уртасына Хәбир белән янәшә кереп баскан.

Таһир университетны тәмамлар алдыннан өйләнде. Аңа ул чакта төп-төгәл егерме ике яшь иде. Таһирга аспирантурада калырга тәкъдим иттеләр. Һәм моңа аның сабакташлары да, ул үзе дә гаҗәпләнмәде. Таһирның фән юлына басачагы, фән юлыннан китәчәге ничектер үзеннән-үзе аңлашылып торган бер нәрсә кебек иде. Хәер, кем өчендер аның бу юлга кереп китүе бик җиңел яуланган үр булып тоелгандыр. Әмма бу үрне Таһир үз көче, үз тырышлыгы белән алды. Башка студентлар күңел ачканда, кичәләрдә, концертларда йөргәндә, кинотеатрларга чапканда Таһир китапханәләрдә басылып утырды. Курс эшләрен дә ул башкалар кебек атна-ун көн эчендә генә язмады. Ныклап әзерләнеп, архивларда актарынып, чын күңеленнән эшләп яклады. Соңгы курсларда укыганда аның инде тарих, философия һәм социаль психология буенча кызыклы гына күзәтүләре, материаллары бар иде. Аларның кайберләре гыйльми советның кулъязма һәм басма җыентыкларында урын алды. Һәр яңа ачышка Таһир үзенең йокысыз төннәре, өзмәс-куймас эзләнүләре аша барды. Үзенең сабакташлары, яшьтәшләре белән аз аралашты. Бердәнбер якын дусты Хәбир дә армиягә алынгач, бөтенләй ялгыз калды. Үзе өчен яңалык булган ачышларны хәзер инде ул Минзиләгә сөйли, аның фикерен ишетергә тели иде. Ул сөйләгәннәр Минзиләне һич тә кызыксындырмый, әмма кызый тыңлап утыра белә һәм кайчакта:

— Молодец, булдыргансың! — дип әйткәли иде.

Әмма көннәрдән бер көнне Таһир үзе өчен көтелмәгән, бөтенләй яңа тарафтан калыккан ачыш ясады: бу — Минзиләнең, аңа карата үзгәргәнлеген сизүе иде.

Ул чакта Таһир Идел буе югары уку йортлары студентларының фәнни-практик конференциясендә катнашты. Анда, очраклы рәвештә генә, Минзилә дә ияреп барган иде.

Университетның актлар залы шыгрым тулы. Таһир иң соңгы кешеләрнең берсе булып чыгыш ясады. Зал инде арган, конференциянең тәмамлануын көтеп йокымсырый. Таһир трибунага чыкты. Беренче җөмләсе белән үк залны уятты, кузгатты.

— Борынгы елъязмачылар безгә караганда күп тапкырлар акыллырак һәм гаделрәк булган, — дип сүзен башлады Таһир.— Алар — үз чорларының алдынгы һәм намуслы кешеләре — тарих алдында да, кешелек дөньясы алдында да зур җаваплылык хисе тоеп яшәгәннәр. Алар кешелекнең тормыш тәҗрибәсе бары тик дөрес һәм объектив язылган вакыйгалар, хакыйкатьне чагылдырган тарих аша гына туачагын аңлый белгәннәр...

«Иҗтимагый фәннәр үсешен тарихчанлык күзлегеннән чыгып бәяләү принциплары» дигән шушы чыгышы белән Таһир бу конференциягә ниндидер яңа бер сулыш өреп җибәрде. Аның бу чыгышы тулысынча төгәл документларга, архив материалларына нигезләнгән, әлеге материаллар айлар буе уйланулар, күңел талпынуы, күңел эзләнүе, чагыштырулар аша туган иде. Архивларда казынган чакта, әле ґел бүтән бер тема өстендә эшләгәндә дә, Таһир кызыклы тоелган мәгълүматларны җыя, туплый барды. Кайчакта ул үзе өчен гадәттән тыш ачышлар ясап ташлады. Еш кына шулай була иде: ул тапкан мәгълүматлар бүгенге тарих фәненең кайсыдыр бер өлеше белән тәңгәл килми, хәтта аны кире кага, аңа карата шик уята иде. Башта ул моңа әллә ни әһәмият бирмәде, очраклы бер төгәлсезлек, ялгыш — күренмичә калган бер нәрсә итеп карады. Әмма архивларда озаграк утырган саен, тора-бара аның бу мәгълүматлары ниндидер бер юнәлеш, система ала башлады. Һәм

Таһир инанды: тарихны дөрес өйрәнмичә торып, иҗтимагый фәннәрне дөрес юнәлештә үстерү мөмкин түгел. Табигатьнең, дөньяның кануннары шундый. Син тарихны чагылдыруда кайчан да булса бер ялгыш җибәрәсең, махсус рәвештәме яки ялгышлык беләнме хата кыласың икән — әлеге ялгышлар барыбер сиңа китереп сугачак. Бүгенме, иртәгәме, әллә гасырлар үткәчме — барыбер сугачак. Тарихны ялгыш күзаллап өйрәнү — киләчәк буыннар алдында җинаять, аларны дөрес булмаган юнәлешкә этәрү, карурман арасында адаштырып калдыру. Бер ялганчы яки намуссыз тарихчының эше иҗтимагый фәннәр үсешен дистәләрчә елларга тоткарларга йә булмаса аларны да ялган һәм уйдырма фән итәргә мөмкин. Әнә шуңа инанды Таһир.

— Тарих фәне үзе дә, аңа бәйле булган башка иҗтимагый фәннәр дә бары тик тарихчанлык таләпләренә — чынбарлыкка буйсынып үсәргә тиеш, — диде ул. — Шушы таләпкә җавап бирмәгән фәннәр — философияме ул, социаль психологиямe яки башка бер фәнме — кайчан да булса банкротлыкка чыга, яңа буыннарның ышанычын яулый алмый...

Зал аның чыгышын йотылып, кызыксынып сагаеп тыңлады. Югары уку йортларында, нәкъ менә үзе укыган вузда да иҗтимагый фәннәрнең ни дәрәҗәдә объектив булуын шик астына алган фәнни докладны белән ул дүртенче курс студенты өчен артык зур батырлык, артык зур тәвәккәллек ясады. Бу, һәрхәлдә, конференциядә катнашучы студентлар өчен дә, гыйльми җитәкчеләр өчен дә шулай иде. Ә Таһир исә бөтенләе белән үзе кузгаткан, үзе күтәргән проблемалар арасында күмелеп калды. Әйтерсең, зал аның өчен ниндидер тораташ бер җирлек; әйтерсең, ул залның гомуми карашын, гомуми сулышын гына тоя. Әгәр дә Таһир, үзе сөйләгән нәрсәләрдән аз гына арынып, арттагы рәтләрнең берсенә, анда утырган Минзиләгә күз төшергән булса, аның гаҗәпләнүдән һәм соклanудан зур булып ачылган күзләрен, куанып, сөенеп, теләктәшлек белдереп балкыган карашын күргән булыр иде.

Докладлар бетеп, инде кайтырга җыенгач, аны профессор Кукушкин туктатты:

— Котлыйм сезне, яшь дустым! Котлыйм... Кыю күтәрдегез мәсьәләне. Әгәр шулай дәвам итсәгез, алда сезне зур эшләр, зур уңышлар көтә. Килер көн менә шундый кыю яшьләр кулында булырга тиеш. Без картларда хәзер тәвәккәллек тә, бунтарьлык та юк инде. Ышаныч сезнең кебек егетләрдә, зур эшкә алынгансыз, котлыйм, яшь дустым!..

Профессорның мондый бәясеннән югалып калган Таһир ни әйтергә дә белми торды, каяндыр эчтән, көчел түреннән генә мыгырданып, рәхмәт сүзләрен кабатлады, янәшәдә басып торган Минзилә артына сыенды. Нәкъ менә шул чакта Кукушкин Минзиләне дә шәйләп алды:

— О, гафу үтенәм... — диде ул, елмаеп. — Янибызда гүзәл туташ барлыгын күрми дә торам икән. Әйе, сезне дә котлыйм, кадерлем. Мондый кыю егетләргә дәрт һәм дәрман бирүче гүзәл затлар яшәсен! Фән дигән авыр, сикәлтәле юлдан атлаганда янында сине аңлый белүче, көчел җылысы биреп торучы булу — үзе бер бәхет ул. Уңышлар телим...

Әнә шул көннән соң барысы да үзгәрде. Таһир үзе дә тоеп йөри башлаган бу үзгәреш аны каушата, куркыта, икеләндерә, газаплый иде.

Ә беркөнне Минзилә Таһир яшәгән тулай торакка, аның бүлмәсенә килеп керде. Килеп керде дә, туп-туры әйтеп салды:

— Син минем алда үзеңнең зур гаебең барлыгын аңлыйсыңмы?

— Гаебем? Нинди гаебем? — дип югалып калды Таһир. Минзилә бер мәл тынып торды, турыдан ярып әйткән батырлыгы җуела төште, кыяфәтенә наздылык чыкты:

— Кайчан гына килсәм дә, һаман шул китапларың белән утырасың. Кайчан гына килсәм дә... Ичмасам, егет булсаң, бер киного алып барыр идең мине!..

Минзилә, иреннәрен сабыйларча бүлтәйтеп, үпкәләгәндәй итте. Таһир нәрсәдер әйтеп акланмакчы булган иде, кинәт тукталып калды: Минзиләнең әнә шул шаярып үпкәләвендә, бер үк вакытта үрсәләнеп тә, елмаеп та торуында, күз карашларында әйтеп аңлата алмаслык, әмма көчел белән генә тоярлык сәер бер мөнәсәбәт күреп алды ул. Күреп алды да, гаҗәпләнеп, аптырап карап торды. Аннан соң, кинәт кузгалып, өстәлдә аунап яткан китапларын, дәфтәр-кәгазьләрен җыйды, Минзиләгә таба борылып:

— Киттек! — диде.

Шулай башланды. Таһир укуын, эшләрен онытты. Китапларына кагыла алмас булды. Моңарчы ул шөгыльләнгән, ул эзләнгән, ул кызыксынган

нәрсәләр барысы да Минзилә белән чагыштырганда артык вак, артык әһәмиятсез, артык кечкенә бер нәрсә булып тоелды. Һәм бу хак иде: Таһирга зур ярату, моңарчы һич тә таныш булмаган, кайчан киләсе дә билгесез, көтелмәгән, әмма аның барлыгын йөрәк белән тоеп зарыгылган мәхәббәт иңде.

Яз иде. Ул кичне яңгыр явып үтте. Казан урамнарындагы юкәләрдән таралган хуш ис башны әйләндерә, күңелне җилкендерә иде. Минзиләне култыклап атлаган Таһир бәхеттән исерде. Ә Минзилә әкрен генә җыр башлады:

Яшьлек диган яшел аланда
Ләйсән яңгырлары яуганда, —
Әллә ничек кенә очраштык,
Көтмәгәндә-уйламаганда...

Минзилә җырлады. Ә Таһир аның беләгенә ныграк ябышты. Шулай итмәсә, егылып китәр, башы әйләнүдән чалкан барып төшәр сыман иде.

Безнең бу яз ашыкмаган да,
Безнең бу яз соңармаган да.
Үз вакыты белән килгән ул, —
Көтмәгәндә-уйламаганда...

Таһир бу минутта ихтыярсыз иде. Яз яңгыры, урам юкәләре, Минзиләнең чәчләреннән аңкып торган хушбуй исе, җыр авазы аны исәрләтә, исертә, күккә чөеп, бушлыкка ыргыта иде. Аның, шушы кечкә караңгылыкны ярып, ялгыз калып, үкереп-үксеп елыйсы йә булмаса шаркылдап көләсе, яки Минзиләнең алдына тезләнеп: «Яратам! Яратам! Яратам бит мин сине!..» — дип, башын юеш асфальтка бәрә-бәрә кычкырасы килә иде.

Үз вакыты белән килгән ул, —
Көтмәгәндә-уйламаганда.
Безнең очрашасын белгән ул, —
Көтмәгәндә-уйламаганда...

Җыр өзелде. Ул җырны Минзиләнең иреннәреннән Таһир тартып алды; тартып алды да, мәхәббәт хисе белән төреп, күңеленең иң түренә урнаштырып куйды.

Үзе яшәгән тулай торакка кадәр ул җәяү кайтты. Казан аңа дөньяда иң матур шәһәр, Минзилә яшәгән йорт иң матур йорт булып тоелды. Яңгыр да, җил дә, еракта җемелдәп күренгән утлар да — барысы да аныкы, аның үзенеке генә кебек иде. Кулдәвекләрне ерып, тездән суга батып, онытылып, талпынып атлады. Шулай шактый баргач, аны төннең ялгыз трамвае куып җитте. Трамвай йөртүче кыз тизлекне әкренәйтте, «Әйдә, утыр!» — дигән сыман кул изәп, ишекләрне ачты. Таһир елмайды, башын чайкап:

— Юк! — дип кычкырды. Трамвайны кул болгап озатып калды. Озатып калды да, кинәт сискәнеп, атлап барган җиреннән тукталды: кызулап, ераклашып барган трамвайның тәгәрмәчләре: «Ә Хәбир?.. Ә Хәбир?! Ә Хәбир?!!» — дип кабатлый сыман иде.

Шул төннән соң ул Минзиләдән качып йөри башлады. Газаплы, әрнүле, икеләнүле ялгыз төннәр үткәрде. Әмма тора-бара аңлады: күңелендә бөреләнгән хисләр аны күптән инде ихтыярсыз иткән, үз кочагына алган иде. Әнә шул хисләр, Таһирны кол итеп, яңадан Минзилә янына җитәкләп алып килде.

Ул көнне Минзилә аны җибәрмәде.

— Мин бүген бүлмәдә ялгызым. Иптәш кызлар авылга кайтып китте, — диде.

Шул җәйдә аларның туйлары булды.

Ә менә бүген, салкын бер иртәдә, Таһир урам чатында маңгайга-маңгай бәрелешеп очрашты Хәбир белән. Нәрсә бу? Язмыш көлүеме? Әллә очраклылык кынамы? Ә ни өчен соң Таһир үзенең дустын җимерек гаилә белән каршы ала? Ни өчен? Очраклылыкмы?.. «Язмышның үч алуы бу... — дип уйлады Таһир эчтән генә. Аннан соң үз-үзен ничек тә юатырга тырышты. — Хәбир инде үз тормышын тапкан, гаилә корган. Димәк, миңа рәнҗү сакларга тиеш түгел...» Тик шулай да, ник чакырды, ник чакырды соң ул Хәбирне өйгә? Җимерек тормышын, бозылган гаиләсен күрсәтер өченме?

Юк, гаиләсен сакларга тырышмады түгел, тырышты Таһир. Ләкин, текә

тау башыннан тәгәрәп киткән кечкенә бер таш та зур афәтләр алып килергә мөмкин булган кебек, гаиләдә башланган җимерелү торган саен арта гына барды. Тауларда шулай: түбәдә яткан кечкенә бер таш, юк-бар сәбәптән генә, урыныннан кузгала. Таш аска таба тәгәри, аның әле тавышы-тыны да чыкмый, җимерелүләр, гарасатлар да көтелми. Әмма әлеге таш, аска төшкән саен, тизлеген арттыра бара, көч җыя, үзеннән зуррак ташларга бәрелеп, аларны кузгата. Ә инде алары исә, үз чиратында, башка ташларны аска тәгәрәтә, җимерелү, гарасат туа.

Таһирның гаилә тормышында җимерелү тудырган әнә шул беренче, җиңел сил ташы аның кандидатлык диссертациясен яклый алмавы иде. Еллар буе эзләнеп, әзерләнеп, йокысыз төннәр үткәреп эшләнгән диссертацияне гыйльми совет кабул итмәде, яклауга лаек дип тапмады. Аның студент чактан ук өйрәнеп, туплап килгән эзләнүләрен тарихка, җәмгыять белемнәренә, барлык иҗтимагый фәннәргә яла ягу, дип бәяләделәр. Тарих фәне, партияле фән буларак, берниндди шикләнүләргә, икеләнүләргә урын калдырмаска тиеш, дип чыктылар. Бу Таһир өчен зур югалту булды. Ул үз диссертациясен яклаячагына ышана, шушы яклаудан соң тормышы да үзгәрер, нинди дер бер җиңеллек килер, гаиләдә дә, өйдә дә, эштә дә үзгәрешләр булыр дип өметләнә иде. Әлеге үзгәрешкә бигрәк тә Минзиләнең мохтаҗ булуын аңлый иде Таһир. Әмма...

Гыйльми совет утырышыннан соң ул барлык әрнүен, җан ачысын профессор Кукушкинга ачып салды:

— Ник? — диде ул, тышка бәреп чыккан күз яшьләрен чак-чак йотып.— Әйтегез, профессор, ни өчен аңларга теләмиләр?! Минем бу эшемдә бер генә ялган да юк. Монда барысы да төгәл мәгълүматларга, архивтан алынган материалларга таянып язылган. Мин аларны еллар буе тупладым. Әле бит элек, студент чакта, сез үзегез үк бу теманы хуплаган идегез!

Профессор авыр сулап көрсенде:

— Их, яшь дустым... Студент чакта ни әйтсәң дә, нәрсә язсаң да ярый ул. Әмма бу... икенчерәк дөнья шул, — диде.

Бу хәлне Таһир эчтән янып, эчтән көеп кичерде. Үзенә ни дәрәҗәдә авыр икәнлеген, барысын да яңадан, яңабаштан башларга кирәк булачагын Минзиләгә белгертмәскә тырышты, аның сораулы карашларыннан качарга, нинди дә булса сылтау-сәбәпләр табарга күнекте. Ә гаиләне ашатырга, туендырырга, киендерергә кирәк иде. Минзиләнең өйдә бала белән утыруы аларның хәлен соң чиккә җиткерде. Квартира булмагач, шәһәрдә теркәлү язуы юк, ә аннан башка Рөстәмне яслегә, бакчага урнаштыру мөмкин түгел иде. Кайчакларда, инде тәмам өметсез калган вакытларында, барысын да ташлап, Минзилә белән улын алып, авылга, район үзәгенә кайтып китү турында уйланды Таһир. Әмма андый чакларда аны ниндидер бер көч, кайдадыр тирәндә яткан инану, үзенең, эшенең кирәклегенә ышану саклап кала, өметләндерә иде. Яңа диссертация темасын ул башкачарак, җиңелчәрәк итеп үзгәртте. Профессор Кукушкин да аңа артык каршылыкларга кермәскә, тарих фәнендә булган төгәлсезлекләргә игътибар итмәскә, табылган материалларны бүгенге көнгә яраклаштырып, буйсындырып чыгарга киңәш итте...

Әнә шундый авыр бер вакытларда аңа республика газетасыннан үтенеч белдерделәр: ул газета өчен ырымнарга, дини йолаларга каршы, үткен генә бер материал әзерләргә тиеш иде. Таһир дини йолалар, аларның килеп чыгу тарихы, кеше психологиясендә тоткан урыны белән яхшы хәбәрдар иде. Мәкаләне зур итеп, үзенең төпле уйланулары аша, ныклап әзерләнеп язды. Һәрхәлдә, икеләнүле уйлар эчендә яшәгән, яңа диссертацияне ничегрәк итеп күзалларга белми йөргән бер вакытта мондый тәгаен эшкә алыну аңа бер юаныч иде. Редакциядән шалтыраттылар: «Мәкаләгез безгә бик ошады, тик кайбер урыннарын газета таләпләренә туры китереп үзгәртергә туры киләчәк»,— диделәр. Газета чыккач, Таһир үз мәкаләсен танымый торды: аның бу зур эшеннән, эзләнеп, әзерләнеп язган мәкаләсеннән бары тик берничә генә мисал калган һәм әлеге мисаллар барысы да бер генә фикергә: ырымнар, дини йолалар — агу, алар — халыкның аяусыз дошманнары, дигән фикергә буйсындырылган иде. Таһир редакциягә ризасызлык белдереп шалтыратты. Ә аңа яңа мәкалә язарга тәкъдим иттеләр.

Бераздан Таһир әлеге мәкаләсе өчен гонорар алды. Гаиләдә очны-очка ялгый алмый яшәгән бер көндә килеп төшкән бу акча Таһир өчен зур шатлык булды. Ул инде редакциягә яңа мәкалә илткән иде.

Газетада язмалары күренүгә, аңа бүтән редакцияләрдән дә мөрәҗәгать

итә башладылар. «Беләсезме, иптәш Корбанов, бездә атеистик темага яза алучылар юк, ярдәмне сездән көтәбез»,— диделәр. Редакциядә бу өлкәдә махсус белгечләр булмавын Таһир аңлый иде. Әмма ул бер генә нәрсәне аңлый алмый интекте: атеистик темага яза белмәгән әнә шул кешеләрдән кемдер аның мәкаләләрен бик оста итеп төзәтә, җиренә җиткерә һәм шуның белән Таһирның ачуын кабарта иде. Соңыннан күнекте, ияләште. Мәкаләләр өчен гонорар вакытында килеп бара иде. Аның бу язганнарын күреп алучылар булган. Бервакыт Таһирга партия өлкә комитетыннан шалтыраттылар: Алма-Атада Ислам дине белән шөгыльләнүче атеистларның Бөтенсоюз семинары булачак икән. Таһир Татарстаннан баручы делегациягә кертелгән...

Ни генә булмасын, Таһир бик тиз арада әнә шул юнәлештә танылып өлгерде, газета-журналларның даими хәбәрчесенә әйләнде. Ул инде үз мәкаләләрен сызылмый-кыскартылмый торган итеп, ягъни газета таләпләренә җавап бирерлек итеп язарга күнекте. Редакцияләр аның һәр мәкаләсен хуплап каршы ала һәм бу хәл Таһирга үзенчә бер рәхәтлек бирә иде. Әмма ул еш кына күңелне рәнҗеткән сүзләр дә ишеткәләде.

— Сезгә рәхмәт инде, иптәш атеист, — диде аңа бер карт язучы. — Мин үзем корбан бәйрәмнәрен, ураза аен сезнең язмалар аша гына белеп барам. Укыйм да, ә изге ай җиткән икән бит, берәр әби-бабайга хәер-сәдака бирергә кирәк, дим. Рәхмәт инде сезгә, югыйсә, каян белер идем...

Таһир бу сүзләрнең зәһәр төрттерү икәнен аңлый, әмма берни эшли алмый иде. Әлбәттә, мәкаләләр язудан берара тукталып та торган чаклары булды. Әмма, әз генә тукталып тордымы, редакцияләр аңа яңадан шалтырата, яңадан аны яхшы бәя белән кызыктыралар иде.

Таһир, яшерен бер өмет белән, үзенең яңа диссертациясен әзерләде. Профессор Кукушкин аңа ныклап, эчкерсез рәвештә ярдәм итә, кайсы өлкәләргә кагылмасаң, нинди темаларга сугылмасаң гына эшнең каршылыксыз үтә алуына төшендерә иде.

Минзиләнең әрнүле күз яшьләрен дә, фатирдан фатирга күченеп, сөрелеп йөрүләрне дә, улы Рөстәмне бакчага урнаштыра алмый интегүләрне дә Таһир үз йөрәге аша үткәреп күтәрде, түзде, тырышты, максатына таба атлады.

Ниһаять, ул үзенең диссертациясен яклады, философия фәннәре кандидаты дигән гыйльми исем алды. Тормышлары кинәт кенә яңармаса да, киләчәк өметле иде. Ләкин... Әлеге дә баягы текә тау түбәсеннән кузгалган таш зур тизлек алып өлгергән иде инде!

Минзилә белән соңгы тапкыр ачыктан-ачык сөйләшкән көнне, дөресрәге төнне, Таһир саташып, кычкырып уянды. Ә аңынчы, йокысызлыктан интегеп, шактый азапланып яткан иде. Кинәт капкадан Хафиз карт килеп кергәнен күргәч, аптырап калды.

— Менә сиңа кирәк булса! Син, Хафиз абый, үлгән идең түгелме соң инде?! — дип сорады ул, чиктән тыш гаҗәпләнеп, һәм шунда ук моның саташулы бер төш кенә икәнен аңлап алды. «Әй, төш күрәм икән, ләбаса...» — дип уйлады ул йокылы-уяулы хәлдә, ә үзе шул ук төшне күрүен дәвам итте.

— Син үлгән идең бит инде, Хафиз абый?..

Хафиз карт капка баганасына сөялде. Таһирның колагына таба иелә төшеп пышылдады:

— Мин сиңа бүтән тоттырмыйм балтаны, бел! — диде.

— Ник?

— Өметне акламадың син.

— Ничек инде!? Мин тырыштым, Хафиз абый! Син әйткән идең, галим булырсың, дигән идең. Мин галим булдым, Хафиз абый!..

— Өметне акламадың... — дип дәвам итте карт. — Атаңның каберенә чардуган куярга да оныттың, имансыз...

— Чардуган? Хәзер, хәзер ясап куям мин аны! Балтаңны бир, Хафиз абый!

— Бирмим. Аягыңа чабарсың. Балта тота белмисең син, тәҗрибәң юк.

— Кит инде, авыл малае бит мин! Хәзер, әнидән сорыйм мин ул балтаны! Әни кайда соң әле? Әни! Әни!!!

— Йөрмә. Барыбер табалмыйсың син аны.

— Кайда соң ул?

— Атаңны эзләп китте.

Таһир елмайды:

— Зиратка киттемени?! Хәзер куып җитәм мин аны! Әни!..

Менә шул чакта Минзилә җилтерәтеп уятты Таһирны:

— Тор әле, уян, саташасың бугай, — диде. Таһир, аптырап, гаҗәпләнеп, хатынына карап торды.

— Саташасың, белая горячка башландымы әллә? Менә шулай ул, эчеп йөрсәң...— Минзилә бүтән сүз эндәшмәде, борылып, үз урынына барып ятты.

Таһир дәшмәде. Бераздан соң, тыныч кына сорап куйды:

— Син чынлап китәргә уйладыңмы?

— Без бу турыда сөйләштек бит инде, Таһир.

Икесе дә сүзсез калдылар. Бераздан Таһир яңадан сүз катты:

— Кем соң ул, синең күңелне шулай яулый белгән кеше? Ичмасам, кем икәнен белеп калыйм...

— Кем булсын... Гап-гади бер кеше. Юк! Гади түгел. Көчле кеше. Ул үз дигәненә ирешә, үзе теләгәнне эшли белә торган кеше!

Айлар буена сузылган киеренке халәттән соң, беренче тапкыр тыныч кына, гаугасыз гына сөйләшүләре, аңлашулары иде бу.

— Үз дигәненә ирешә алуы хактыр, — дип төрттерде Таһир. — Кеше хатынының башын әйләндерерлек булгач... Чибәрдер, матурдыр.

— Их аллам! Андамыни эш! — Минзилә, урыныннан сикереп торып, Таһирның каршысына ук килеп басты. — Син менә миңа кара әле, кара! Нинди мин?!

Таһир хатынының төнге ут яктысында мәрмәрләнеп күренгән иңбашларына, күпереп торган чәчләренә, тыгыз күкрәкләренә, буй-сынына юри, махсус төбәлеп күз йөртеп чыкты:

— Карыйм. Син бик матур, Минзилә.

— Ә, шулаймыни?! Матурмы? Юк, дускаем, әлек матур идем мин! Матурларның матуры идем! — Минзиләнең сулышы кысылды, күзләре очкынланып китте. — Мин сиңа яшьлегемне, иң матур чакларымны бирдем. Ә син миңа шуның өчен нәрсә бирдең? Иә, әйт, нәрсә бирдең?!

— Мин дә сиңа үз яшьлегемне бирдем, Минзилә. Һәм моның өчен беркайчан да үкенмәдем.

Минзилә әче итеп, үртәлеп, әрнеп елмайды:

— Синме?.. Миңа үз яшьлегеңне бирдеңме? Юк, җаныкаем, миңа бирмәдең син ул яшьлегеңне. Беләсең килсә...— Минзилә, йөгереп барып, өстәлдә яткан кәгазьләрне тузгытып ташлады.— Беләсең килсә, менә шушыларга бирдең син яшьлегеңне! Бер кирәксезгә, бер мәгънәсезгә әрәм иттең, мине дә бәхетсез иттең!..— Минзилә ярсыган, кызган, тынычланудан узган иде. Йөзе җыерылып, күзләренә яшь бәреп чыкты, гәүдәсе аска сыгылды, түбәнгә иңде. — Аһ, күпме түздем мин, күпме түздем!.. Барысы да узар, барысы да үзгәрер дип көттем. Күпме гомер әрәмгә узды. Әгәр хәзерге акылым булсамы?! Дөньядан аерылган шушы ир белән берәр көн яшәр идеммени мин!? Юк, бер генә сәгать тә, бер генә минут та тормас идем! Юк, бирмәдең син миңа яшьлегеңне. Әгәр син үзеңне гаиләгә багышлаган булсаң, без болай яшәмәгән булыр идек! — Минзилә инде кычкырудан туктады, сулкылдап кына сөйли башлады. — Иә хода! Яшьлек җүләрлеге... Күпме түздем бит мин, күпме түздем... Иң әлек кеше өстендә тордык. Әдәм мәсхәрәсе. Балагыз елый, йокы бирми дип, ничәмә-ничә тапкыр җанымны әрнеттеләр минем анда. Ничәмә-ничә фатир алыштырдык?! Берәр үзем теләгән күлмәк кия алдыммы мин үз гомеремдә? Юләр мин, юләр... Әлек миннән «Ирең кем?» — дип сорасалар, «Укый, аспирант», — дип, горурланып җавап бирә идем. Кеше көлгәндер инде миннән ул чакта! Хәзер менә оялып йөрим. Әгәр хәзер сорасалар, мин синең фәннәр кандидаты икәнеңне әйтергә дә оялам! Нәрсәбез бар соң безнең кеше алдында күрсәтерлек? Ә, беләсең килсә, теге вакытта, кеше фатирында торган чакта, мин бер тапкыр ашханәдән тоз савыты урлап алып кайттым. Тоз савыты сатып алырлык та акчабыз юк иде бит безнең! Тоз савытын да... Күпме түздем бит мин, түздем, барысы да узар дидем...

— Аңламассың сине, — дип бүлдерде, ниһаять, Таһир. — Күпме түздем, имеш, узар, дидем... Ә узмадымы? Шөкер, инде кеше өстендә яшәмибез. Рөстәм үз квартирабызда үсә. Барысы да җитешле хәзергә... Киләчәктә дә булыр.

— Ах, һаман үзенекен сөйли бу!.. Бернәрсә дә аңламыйсыңмыни соң син, җаныкаем?! Минем яшьлегем әнә шул киләчәккә бәхетне көтеп үтте. Әрәм үтте. Ә хәзер мин нәрсәгә өметләнеп, нәрсәгә алданып яшәргә тиеш? Шушы тычкан куышы хәтле фатирыңамы? Кешеләрнең нинди рәк кварти-

раларда торганын беләсеңме соң син, күргәнең бармы әзрәк?! Без с частичными удобствами яшәгәндә, башкалар бит с полными удовольствиями яши! Бер без генә шундый хәлдә бит!

— Бер без генә түгел, ярты Казан шулай... Кетә дә белергә кирәк.

— Ярты Казан, имеш! Син Казанның бүтәнчәрәк яшәгән ягына кара! Әнә, Рөстәм үсеп килә. Безнең бит, беләсең килсә, аңа калдырырлык та җыйган нәрсәбез юк. Без бит, башкалар белән чагыштырганда, шыр ялангач! Хәерчеләр бит без! Аңлыйсыңмы шуны?!

— Аңлыйм,— дип кырт кисте Таһир.— Алайса, синең ул танышыңның кесәсе бик калындыр инде...

— Калын шул! Ул, беләсең килсә, үзенең түш кесәсендә генә дә синең еллык зарплатаң хәтле акча йөртә! Кирәк-яракка тотар өчен!

Таһир, борылып, башын юрганы белән каплап ятты. Минзиләнең бу соңгы сүзләренә каршы аның бердәнбер җавабы шул гына була ала иде.

— Эш өчен яшим, кешеләр өчен яшим, дигән буласың...— Минзилә кызып өлгергән иде инде.— Үзе өчен дә яши белмәгән кеше башкалар өчен нинди юньле эш кыралсын?! Ә үзеңнең башкаларга кирәгең бармы соң синең? Әгәр кирәгең булса, шушы хәлләрдә яшәгән булыр идекме без? Юк, җаныкаем, эшеңнең дә үзеңнең дә, кирәгең юк синең кешеләргә...

— Җитте!..— Таһир, юрганын ачып бер кычкырды да, кире бөркәнеп ятты. Минзиләнең бу сүзләре аны тәмам чыгырдан чыгарды. Әлеге сүзләрне ул кайдадыр, кайчандыр бер ишеткән кебек иде инде. Әллә үзе генә уйлады микән?..

Кинәт исенә килеп төште. Узган кыш үзенең сабакташ дусты Назарны очраткан иде. Күптән күрешелмәгән, тукталып, хәл сорашып, сөйләшеп тордылар. Назар аның диссертация яклаганын ишеткән икән, котлап шатлыгын уртаклашты да авыр гына көрсенеп куйды:

— Шулай, Таһир дускай, дөнья мине әллә кай тарафка бөтереп җибәрмәгән булса, мин дә сезнең брат арасында, халыкка хезмәт итеп, фән юлыннан барыр идем, яраткан эшем белән шөгыльләнер идем бит,— диде.

Назар университетта чакта ук әдәбият тарихы белән ныклап кызыксынып киткән, университетны кызыл диплом белән тәгәлләп, Мәскәүдә аспирантура тәмамлаган иде. Таһир аның белеменә, логик фикерләвенә, искиткеч хәтерле булуына һәрчак сокланып карый иде. Мәскәүдән кайткач, Назар фәннәр академиясенең филиалында эшләп йөрде дә каядыр китеп юкка чыкты. Шул чаклардан соң беренче очрашулары, беренче күрешүләре иде. Назарның күңелендә йөргән, күрәсең, сораганны көтеп тормыйча әйтте:

— Киттем мин фәннән, туган, киттем. Күптән инде...— диде.— Кайбер әйберләрне кичләрен караштырып утырам. Шактый кызыклы нәрсәләр җыелган... Тарих бай. Кызыклы шәхесләргә бай. Шуларны уйлыйм да, әрнеп куям. Аннан соң уза, онытыла... Киттем мин фәннән, булмады...

— Их, Назар, син бит безнең арада иң сәләтле егет идең,— диде Таһир, аның ачылып сөйләшүеннән тәэсирләнеп.— Фән өчен туган кеше идең. Ышанасы килми хәтта...

— Сәләтле егет...— дип көрсенде Назар.— Эш сәләттә түгел... Эш синең ни дәрәҗәдә кирәкле булуыңда.

— Ничек инде?

— Шулай, Таһир. Кирәксез кеше булып яшисем килмәде минем. Дөрес әйтәсең син: фәнне ярата идем, аспирантурада дәртләнә-дәртләнә укыдым. Иөрәктә — дәрт, иңнәрдә — канат. Шулай кайттым мин Мәскәүдән. Эш күрсәтергә, дөньяларны актарырга исәп. Юк, чын фән кешеләре түгел, булмаган фәннилекне бар итеп күрсәтүче курчаклар кирәк икән бу дөньяга. Аннан соң... гаилә бар бит әле. Торыр урын юк, күченеп-күченеп йөрибез. Шунда миңа әйтсәләр: «Назар, син бит безгә кирәкле кеше, булачак галим, Мәскәүдә аспирантура бетердең, менә сиңа тар гына, кысан гына бер куыш, шунда яшәп тор, киләчәктә бирәр нәрсә уйлашырбыз», — дисәләр, китәр идеммени мин фәннән? Юк, кусалар да китмәс идем. Фатирсыз, акчасыз яшәүгә дә түзәр идем мин. Әмма кадер юклыкка түзәлмәдым.

Назар көлемсерәп куйды:

— Акыл керде миңа. Анысына кызым ярдәм итте. Олы кызым, беренчесе, ул чакта әле бер генә бала иде безнең. Хәзер өчәү инде... Шулай бервакыт эштән кайтып керәм, кеше өстендә фатирда торган чак безнең, хатын елап утыра. Хуҗалар, нindидер сәбәп табып, тавыш кубар-

ган. Чыгып китегез, диләр икән. Фатирны ремонтлап кына бетергән идем әле. Фатир хуҗалары шулай бит алар: бүлмәне ремонтлаганыңны гына көтеп торалар да, чыгарып җибәрәләр. Ремонтланган фатирга яңа кеше кертәләр: кыйбатрак хакка инде, ремонтланган бүлмә булгач. Күп фатир ремонтладым мин шулай... Хатын елап утыра, кызым әле бернәрсә дә аңламый, теле дә ачылмаган. Аңламый, үзе миңа мөлдерәп карап тора. «Әти, нишләп безнең үз өебез юк?! Нигә әни елый? Нигә безне моннан куалар? Без шулай беркемгә дә кирәксез кешеләрмени?!» — дип әйтә кебек сабый... Менә шуннан соң акылга килдем мин. Фән турында түгел, бала хакы, балаларның киләчәге турында уйлый башладым.

— Юк, син бит фәнгә, халыкка кирәк кеше, Назар...

— Аңлыйм, Таһир... Синең нәрсә әйтергә теләгәнеңне аңлыйм мин. Синең кебекләргә көнләшеп карыйм. Әмма үзем алай булдыра алмыйм. Балалар бар бит... Дүрт бүлмәле фатир алдым. Кооперативныкын. Түләп. Хәзер яшелчә базасында мин. Директор. Суганга кытлык быел. Килеп чык бер. Мин ул суганны сиңа җибәрдем ни, кибеткә ни... Син килеп чык, машинада ук озатып куярмын, тик син башта үзең кил, күреп кит минем эш урынын...

— Килермен,— диде Таһир. Минзиләнең: «Суган бетте, суган юк...» — дип тинтерәткәне исенә төшкән иде. Вәгъдәләшеп, көнен-сәгатен билгеләшеп, очрашырга сүз куешып аерылыштылар. Нәкъ аның янына барасы көнне Таһирга бер гыйльми утырышта катнашырга кирәк булып чыкты. Һәрхәлдә, ул аннан китә ала иде. Кайсысын сайларга, барыргамы, утырышта калыргамы дигән икеләнү бер генә мәлгә булды: Таһир Назар янына бармый калды, шуннан соң элемтә ялганмады, күрешкәннәре булмады.

Минзилә үзенең танышын кайдадыр сәүдә өлкәсендә эшли дип ычкындырган иде. Таһир ирексездән Назарны база директоры буларак күз аллап куйды. Юк, Минзиләнең ул танышы Назарга һич тә охшый алмас кебек иде.

— Рөстәмне үзең белән аласыңмы, миңа калдырасыңмы? — диде ул хатынына. Минзилә яткан иде инде, яңадан баш калкытты:

— Әйе, сиңа калдырып, аны да бәхетсез итәргәме? Юк инде, җаныкаем! Син тагын, судлашып-нитеп йөреп, безне дә, үзеңне дә оятка калдырма! Рөстәмне суд барыбер сиңа бирмәячәк. Анадан баланы беркем дә аермый!

— Судлашсаң ярар иде анысы, — диде Таһир, үзалдына гына уйлангандай.— Тик мин безнең судларның гаилә мәсьәләсендә ни дәрәҗәдә компетентлы булуын яхшы беләм шул. Ишеткән, укыган бар...

Шушы ачыктан-ачык сөйләшүдән соң ике ай вакыт узды. Минзилә дә, Таһир да, өйдә сирәк очрашып, аерылышу көнен көтәләр, тереклек итәләр иде. Минзилә, сәбәбен әйтмичә, күчеп китүне һаман-һаман сузып килә, шуның белән Таһирны өметләндереп тә, газаплап-җәзалап та яши бирә иде. Ләкин, инде күнегелгәнчә, алар аерым яши, аерым көн итә, уллары Рөстәмнең янәшәдә булуы да бу күнегелгән читләшүне киметә алмый иде.

Һәм менә Таһир бүген шушы өйгә Хәбирне кунакка чакырды, адресын бирде. Оят, тагын бер кат оят иде аңа бу мәлдә. Ул көне буена бары тик шушы хакта гына уйлап йөрде. Әшендә дә җанына тынгылык таба алмый йөдәде.

Төшке аштан соң аңа гыйльми секретарь шалтыратты. Аны партия өлкә комитетының кадрлар белән эшләү бүлегеннән сорауларын, шалтыратырга кушуларын әйтте.

Таһир шалтыратты. Белеште. Башы буталган иде. Мәсьәләне тиз генә аңлый алмый торды. Кайсыдыр бер районнан шикаять килгән. Ниндидер бер парторг үзенең мулла этисе белән бер йортта тора, парторг белән мулла, икесе берләшеп, халыкны дингә өнди, обком комиссиясе шуны тикшерергә барачак икән. Атеистик тема белән шөгыльләнүче буларак, комиссия составына Таһир Корбанов та кертелгән. Аның өчен дә, комиссиянең башка әгъзалары өчен дә билетлар алдан алып куелачак. Юлга чыгу көне әлегә билгесез. Алга таба хәбәр итәләр. Бу хәбәр Таһирны шатландырды гына: «Их, әгәр бүген үк чыгып китәсе булса...» — дип уйлады ул, балаларча түземсезләнеп. Бүген өйгә кайтасы барлыгы, Хәбирнең өйгә килү мөмкинлеге аңа һаман да тынгылык бирми, әрнетеп, үкендереп, тора иде.

Хәбир кызы янына, больницага ашыкты. «Үзен сәер тотты, — дип уйлады ул Таһир турында. — Читенсенә, ятсына булса кирәк... Хәер, алай дисәң, ачылып китәргә дә әзер кебек иде».

Хәбир, Таһирның каушап калган йөзен күзалдына китереп, ирексездән көрсенеп куйды. Юк, Таһир дус, үтте инде ул, үтте сезгә рәнҗегән чаклар! Үпкә дә, ачу да, рәнҗү дә юк инде сиңа! Бушлык кына бар... күңелдә. Хәбир үзенең Минзилә белән Таһирга үч саклап йөргән чакларын уйлап, янә елмаеп куйды. Һәм шунда ук, үзенең бер сәбәпсез елмаеп баруын тоеп, ачуы килде. «Авыз ерырлык ни шатлыгың бар?» — дип кычкырды аңа ниндидер тавыш. Хәбир таныды: бу әлеге дә баягы — кичә аңа тынгылык бирмичә интектергән, бәхәсләшергә җыенган эчке тавыш иде.

Ак халат бөркәнеп, кызы янына палатага килеп кергәч, Розалияне күргәч, йөрәге кысылып, сулкылдап куйды Хәбирнең. Розалия башта елмайгандай итте, алга атларгамы, урынында калыргамы белми торды.

— Кызым...

Шул сүздән соң Розалия аның каршысына атылып килде, үзен күтәреп алган әтисенең муеныннан кысып кочаклады, башын аның иңенә салып, әкрен генә, тавышсыз гына сулкылдый башлады. Аның бу сулкылдавында әчкерсез бер үпкә, шелтә һәм сагыну бар иде. «Аңлый бит, ялгызын калдырып китүем өчен үпкәли бит»,— дип уйлап алды Хәбир, үзенең дә күзләре яшьләнде. Аның кинәт кенә кызын шушы бүлмәдән алып чыгып китәсе, кызы алдында тезләнеп, елый-елый, үкси-үкси гафу үтенәсе, аны бөтән беркайчан да, бер генә минутка да ялгыз калдырмаячагы турында ант итәсе килде. Һәм ул шушы минутта үзенең дә, кызының да никадәр ятим, никадәр ялгыз булуларын, бер-берсеннән башка аларга бу дөньяда берниндн ямь булмаячагын тоеп алды. Бу ялгызлык — Лизаның булмавыннан, Лизаның юклыгыннан, аның инде дөньяга беркайчан да кире кайтмавыннан иде.

Ә Розалия сулкылдады да сулкылдады. Ата белән кыз шулай бер-беренә сарылып күпме торырлар, кызның шулай тавышсыз гына сулкылдавы күпмегә сузылыр иде — билгесез. Әмма шулвакыт янәшәдә ниндидер моңлы, ягымлы тавыш ишетелде:

— Бу ни хәл бу, ә, Розалия?! Әтиләрне шулай елап каршылыйлармыни? Ярамый. Карале, ул сиңа нинди тәмле, матур алмалар алып килгән!..

Хәбир гаҗәпләнде. Юк, Розалиянең шулай кинәт кенә елаудан тукталуына түгел, ә бәлки үзе әле генә ишеткән шушы шелтәле сүзләрнең дә әллә ничек ятышлы, ягымлы, көйле яңгырый алуына гаҗәпләнде ул. Кичә бит ул бу таныш тавышны — үзен балага карата игътибарсызлыкта гаепләгән тавышны ишеткән һәм бу врачны бөтенләй бүтәнчә итеп, артык кырыс, артык гөрбиян итеп күз алдына китергән иде. «Әле бит ул япь-яшь кеше икән», —дип уйлап алды Хәбир, аннан соң гына баш какты:

— Исәнмесез, доктор...

— Розалия бик акыллы, тыңлаучан кыз,— диде врач һәм Хәбир бу сүзләрнең иң беренче чиратта Розалия өчен әйтелгәнен аңлады.— Розалия хәзер уколдан да курыкмый. Шулай бит, Розалия?

Кыз, «әйе» дигәнне белдереп, баш какты, мышкылдап, борынын тартып куйды.

Ниһаять, Хәбир үз-үзен кулга алды. Врач тәкъдим иткән сөйләшү алымына кушылып, кызы исеменнән сорады:

— Әйтегезче, зинһар, доктор апа, безнең хәлләр ничегрәк? Монда, больницада, озак ятачакбызмы?

— Без әле, әти кеше, бу турыда бергәләп сөйләшербез,— диде врач. Аннан соң, үзенең кабинетын атады. Бүлмәдәге балалар белән сөйләшеп, аларны карап, күз йөртеп чыккач, яңадан борылып килде.— Розалиягә әле ятып торырга кирәк. Аңа өзлегергә һич тә ярамый. Ә аннан соң, терелгәч, без әле гел йөгереп кенә йөри башларбыз, шулай бит, Розалия?

Кыз янә баш какты.

Врач чыгып киткәч тә әле кызы янында шактый озак утырды Хәбир. Ата белән бала сүзсез генә аңлаштылар, бер-беренә сыенып, бер-беренә никадәр кадерле булуларын тоеп, шушы очрашу минутларын озаккарак сузарга тырыштылар. Розалия башын әтисенең кулына салды, зур алсу алманы күкрәгенә кысып, тын гына ятты.

Саубуллашканда да көйсезләнмәде.

— Кызым, мин тагын килермен... Көн саен килермен. Син тыныч бул... Терел, яме? Аннан соң авылга, әби белән бабай янына кайтырбыз,— диде Хәбир.— Безне авылда көтәләр, кызым. Син терелүгә үк, кайтып китәр без, кызым.

Кыз баш какты, кулындагы алманы ныграк кысып, мөлдерәгән карашы белән әтисен озатып калды.

Врач аны көтеп тора иде.

— Кичә мин сезгә катырак бәрелдем бугай...— диде ул, Хәбиргә урын күрсәтеп.— Гафу итәсез... Мин белмәдем.

— Нәрсәне? — нидер сизенеп, ирексездән кабаланып сорады Хәбир.

— Бүген иртән үк шул палатага кердем мин. Кызыгыз янына килдем. Хәлен белергә теләп. Ә аның беренче сүзе шул булды: «А маму мою в яму закопали». Бала... Мин кичә үк сизенгән идем. Салкын тигерү — анысы узар. Вакытында дәвалауның ярдәме тими калмас. Тик менә... Миңа калса... Розалиянең күңел төшенкелеге, артык моңсулыгы борчый мине. Йоклаганда саташа, кинәт куркып калтырана, ул бик авыр кичерә, аңлыйсызмы? — Врач карашын Хәбиргә төбәде.— Күптән җирләдегезме әнисен?

— Күптән,— дип авыр сулады Хәбир.— Без чит илдән кайтып барабыз бит. Әфган ягыннан. Әнисенең каберен шунда калдырдык.

Врач, «аңладым» дигәнне белдереп, баш какты:

— Бу турыда сүз кузгатуым өчен миңа рәнҗемәгез. Мин бит врач, дәвалау барышында миңа барысын да белеп торырга кирәк.

Хәбир нидер әйтергә теләде, әмма әйтә алмады: тамак төбенә төер утырды. Шушы чит-ят кешенең артык якыннан кызыксынуы, игътибарлы булуы күңелен йомшатып җибәрде. Тупаслыкка, рәхимсезлеккә, катылыкка түзә алган кеше дә күңел җылылыгыннан, мәрхәмәтлелектән йомшара, диләр. Хәбир дә нәкъ менә шундый хәлдә иде. Һәм ул, сүзне икенчегә борырга ашыгып, сорап куйды:

— Күрәм, сезнең эш тә бик катлаулы, четерекле.

— Әйе, һәрбер эш кебек үк, безнең эш тә авыр. Әмма иң авыры шул: дәвалау өчен кирәкле дарулар юк бездә, юк. Кайчак рецепт язасың. Алдан ук белеп торасың: таба алмаячаклар бу даруны аптекалардан. Юк даруга рецепт язу тыелган булса да язасың. Эзләп-эзләп интегәчәкләр — табалмаячаклар. Белеп торган килеш язарга туры килә. Даруы булмагач инде, үзеңчә дәваларга тырышасың: күңелен күтәрәсең, өметләндерәсең... Бары тик шул гына. Сез инде, зинһар, кызыгыз янына ешрак килегез. Мин сезгә даими пропуск язам. Сезне юксыначак, борчылачак ул, югыйсә...

Больницадагы әлеге сөйләшү кунакханәгә кайткач та тынгылык бирмәде Хәбиргә. Ни өчен врач Розалиянең боеклыгына кат-кат басым ясап әйтте? Әллә, чынлап та, кызда бер-бер психик авыру бар дип шикләнәме? Әллә?.. Шул хакта уйлау Хәбирне инде күп тапкырлар борчыган газапларга кире кайтарды. Хакы бар идеме аның кызын Лизаның каберенә алып барырга, әллә юкмы? Әллә ялгыштымы ул моның белән?..

Хәбир вакытны ничек үткәрергә белми йөдәде. «Бәлки,— дип уйлады Хәбир тәмам пошынып,— Таһирларга барып кайтыргадыр?» Үзенең бу уен шунда ук кире какты. Таһирның һәм Минзиләнең бәхетле елмаеп, кунакчыл хуҗалар булып, табын артында утыруларын күз алдына китерде.

— Син аларның шул бәхетенә сокланып кайтыр өчен барасыңмы? — дип, мәсхәрәләп көлде эчке тавыш. «Ә ни өчен көләргә әле? — дип каршы килде Хәбир.— Бәхетле икән — бәхетле. Аларның моңа икесенең дә тулы хакы бар. Аннан соң, Таһир бит Хәбирне күрүе турында Минзиләгә әйтми калмаячак. Кунакка, өйләренә чакыруын да әйтәчәк. Бармасаң, алар нәрсә уйлый инде? Минзилә нәрсә уйлый? Һаман шул, балаларча үпкәләп, үч саклап йөри икән диярме? Барырга, берни булмагандай сөйләшергә, күрешеп кайтырга кирәк...»

— Ә нәрсә турында сөйләшмәкче буласың соң син алар белән? Үзеңнең кайгы-хәсрәтең турында сөйләрсеңме, әллә күбрәк аларның бәхетле тормышы турында сүз тыңларсыңмы? — диде үҗәт эчке тавыш. Һәм аның соңгы сүзләре дәлиллерәк тә, көчлерәк тә яңгырады.

— Чыннан да,— дип килеште Хәбир.— Кызым авырып ята, ә мин кунакта йөрим булып чыга. Ярар, бармыйм булгач — бармыйм.

Ә вакытны ничек тә үткәрергә кирәк иде. Капкалап алырга да, ятып йокларга кирәк, дигән фикергә килде Хәбир. Ләкин шул ук вакытта Хәбир

сизде: йокы сүзе аны куркыта, газаплый иде; чөнки ул үзенең йоклый алмаячагын, тиз генә йоклап китә алмаячагын, сәгатьләр буена интегәчәген белә. Чыннан да, нишләргә?..

Аның шушы үҗәт соравына җавап бирергә теләгәндәй, кинәт ишек шакыдылар.

— Әйе! — дип кычкырды Хәбир, үзе ишекне ачарга ашыкты. Ахо икән бит! Кулларын як-якка җәеп, кычкырып җибәрде:

— Иа хода! Әллә инде тәмам монахка әверелгәнсең син, туган! — Ахоның кочаклашып күрешүеннән генә абайлады Хәбир: бераз төшереп алган бу. Йөзенә, кыяфәтенә, гәүдәсенә тамчы да чыкмый икән үзенең. — Мин инде сине кичә дә көттем аста, ресторанда. Бүген дә көттем, беләсең килсә... Синең белән, туганкай, сөйләшүе күңелле ичмасам. Ә болар...— Ахо каядыр читкә, аска таба кул селтәде.— Юньле әдәм түгел болар!..

Ахо, тунын ачып, түшеннән «Шампанское» тартып чыгарды:

— Кайгырма! Яхшылык эшлә дә суга сал — халык белмәсә, балык белер, ди сезнең татар. Син үзең яхшы кеше.— Ахо, тунын салып, караватка ыргытты.— Ә яхшы кешеләр аз калды хәзер, аз калды. Әйдә, китер тустаганнар, синең өчен эчәбез, туган! Моны эчәбез дә, аска төшәбез. Син — бүген минем кунагым, шуны бел. Юмарт көнем бүген минем, шәп, изге эшләр башкарган көнем, шайтан алгыры!

Бераздан Хәбиргә дә җиңел булып китте. Ахо белән рәхәт, аның белән онытылырга була иде.

— Ахо, гафу ит, — диде ул җанланып китеп.— Син үзең татарларны яхшы беләм дидең, хатының татар кызы. Безнеңчә әйбәт беләсең, мәкаль кушып кына сөйлисең. Ә үзең син... Милләтең кем дип әйтимме?

— Һа!.. Менә монысын шәп тоттың син, шайтан алгыры! Әйтәм бит, акыллы кеше син. Мине бит күпләр бутый. Татарлар арасында — татар, башкалар арасында — башка була алам мин. Ә милләтем ассириец минем. Ассирия! Бөек милләт, илен җуйган милләт! Казанда шактый безнекеләр, игътибар иткәнсеңдер. Бездә бит, туган, чит халыкка кияүгә чыгу, өйләнү юк. Ә миңа рөхсәт иттеләр. Аңлаттым мин үзебезнең аксакалларга, эш өчен кирәк, дидем. Аңладылар. Хатын татар кызы иде минем. Шәп иде, шайтан! Аерылыштык. Малай калды. Әтисе әйбәт кеше иде хатынның. Танылган аш-су остасы иде. Бай иде, каһәр! Кунак итә белә иде үзенең киявен! Татарчага шуларда ныклап өйрәндем...

Ахо шешәдәге соңгы шәрабны тутырып салды. Хәбирнең аркасыннан кагып куйды, яратып, үз итеп, якын итеп какты:

— Тел — минем коралым. Үзең яшәгән якның телен яхшы белергә кирәк. Гореф-гадәтләрен бел син аның. Татар авылларына барып чыгам мин. Ишекне шакып кына керәм, «Әссәламәгаләйкем!» — дип сәлам бирәм. Мине апак яулыклы матур бер татар карчыгы каршы ала. Ах, яратам мин, шайтан алгыры, татар карчыкларын! Ә алар чәй ярата. Һинд чәен. Мин әйтәм аларга: «Апа җаным, һинд чәе кирәкмиме?» — дим. «Әй, улым, кирәк, бик кирәк ие шул!» — диләр. Назланалар, «Күпмегә сатасың соң, улым?» — диләр. Хакын әйткәч, тагын бер иркәләнеп алалар: «Кыйбатрак икән шул, балакаем, кыйбатрак икән», — диләр. Ә мин иркәләнмим дә, назланмыйм да: «Ярар инде, алайса, апа җаным, киттем мин ул чакта», — дим. Юк, җибәрмиләр, кулымнан тотып туктаталар, йөзәр кап алып калалар. Малайлары комбайнда эшли тегеләрнең, акча җәл түгел, чәй генә булсын! Алып калалар. «Тагын кил, улым», — дип ялыналар. Иә, әйт, начар кешеме мин шуннан соң? Әгәр начар кеше булсам, ни өчен ул апалар миңа рәхмәт укып кала? Ә? Ни өчен аларга ул һинд чәен совет кибетләре кайтармый?

Хәбир елмайды. Ахо, гадәттәгечә, кызып-кызып сөйләгәндә сабый балага әверелеп кала сыман иде.

— Мин сине аңлап җиткермәдем,— диде Хәбир.— Син бит үзеңне итек остасы дигән идең?

— Ха! Минме??! Сапожникмы мин?! — Ахо чын күңелдән шаркылдап көлеп җибәрде.— Әйе, дөрес, сапожник мин! Мәхлукләр күз алдында — сапожник! Әйе, урамда, будка эчендә итек чистартып утырам мин, ямыйм, ялтыратам, иренмим! Үзем генә сыярлык алачыгым бар минем анда. Әйе, киләләр миңа кешеләр — хәтәрләр. Аякларын алдыма куялар: «Чистарт!» — дип боералар. Мин чистартам. Ә алар, мәхлуклар, эткә сөяк ташлаган сыман итеп, миңа көмеш акча ыргытып китәләр. Валлаһи! Кимсетәләр. Ә үзләренең, әгәр аякларыннан тотып селкесәң, кесәләреннән өч тәңкәлек тә

акча төшми! — Ахо, кемнедер аягыннан тотып селкегәндәй, куллары белән селтәнеп торды.— Төшми тек төшми! Ә шул мәхлуклар аңламый: мин аларның ай буена ыштан туздырып тапкан акчасын кайчак бер көн эчендә эшлим! Дүрт класс белемем булган башым белән. Ә алар шуны белми, аңламый, шайтан алгыры! Менә бүген мин, таң белән торып, Биектау районын урап кайттым. Татар авылларын. Урысларга кермәдем, кермим дә. Ә менә татар авыллары әйбәт, юмарт, андагы карчыклар ак яулыклы, чәй яраталар...

— Алайса, син спекулянт буласың түгелме соң, агай-эне?

— Спекулянт?! — Ахоның күзләре ялтырап китте, йөзенә үпкәләү билгесе чыкты.— Син нәрсә, туганкаем, нигә дип рәнҗетәсең син мине? Әйтмә шундый сүзне миңа, үртәмә җанымны. Андый сүзне, спекуляция сүзен наданнар гына әйтә. Син — акыллы кеше, син әйтмә. Беләсең килсә, мине башка илдә «коммерсант» дип әйтерләр иде. Ә бит минем бабам сәүдәгәр булган. Эти дә сәүдәгәр иде. Сәүдә минем каныма сеңгән, җаныма, җелегемә сеңгән. Мин бу эшне биш бармагым кебек беләм. Ә син мине рәнҗетәсең.— Ахо, чын-чынлап үпкәләп, башын түбән иде.— Чит илдә мине иң акыллы сәүдәгәр дип йөртерләр иде.

— Син, Ахо, чит ил дә, чит ил, дисең.— Хәбир елмаеп җибәрде.— Ә үзең менә яшәр өчен бер дә чит илне сайламагансың, шушы илдә тукталгансың. Мин бит беләм, ассириецлар чит илләрдә дә шактый...

— Иа алла!..— Ахо да, Хәбиргә кушылып, шаркылдап көлде.— Әйтәм бит, акыллы кеше син, туган. Миңа әле беркемнең дә болай дип әйткәне юк иде, усал тоттың син мине. Әә, ярый, киттек әйдә! Бүген минем гаҗәеп шәп бер эш майтарган көн! Сыйлыйм әле үзеңне.

Ахо Хәбирне көчләп диярлек урыныннан кузгатты, әйдәп-әйдәп, үгетләп, ресторан залына алып төшеп китте.

Залда халык күп, утырырга урыннар юк иде. Ахоның бер хәрәкәтеым кагуы җитте: официант кыз, стена кырындагы «Не обслуживается» дип язылган өстәлне тиз арада җыештырып, аларны шунда чакырды.

— Зур кунагым бар, ачысын да төчесен дә китер,— диде Ахо кызга. Кыз елмайды, хәйләкәр генә итеп каш сикертте:

— Кунакларың күбәйде бу арада, Лимон!

«Лимон»,— дип уйлады Хәбир, Ахоның әле кичә генә шушы сүзне әйткәнен искә төшереп, Лимон... Кызык кушамат бу...»

— Сине монда да «Лимон» дип йөртәләр икән? — диде ул, елмаеп.— Үзең болай әллә ни ачы да күренмисең...

— Йөртәләр,— дип кул селтәде Ахо.— Кара сакалың кая барсаң да артыңнан калмый, диләрме әле? Берзаман шулай, күптән инде — лимонга кытлык елларда — аз-маз шөгыльләнеп алган идем. Татар карчыкларының чәендә минем лимоннар йөзә иде ул чакта. Шуннан калган кушамат. Хәзер инде, ташлап калдырып булмый үзен, шайтан алгыры!

Официант кыз тиз килде. Табынны бик мулдан ясады. Башта сүзсез генә эчеп куйдылар. Бер хәл алгач, Ахо чын-чынлап борчулы кыяфәткә керде:

— Бая сорамадым, туганкай, кызың ни хәлдә? Бардыңмы, күрдеңме, дигәндәй...

— Күрдем. Юксына бала... Авыр булды аны калдырып китүе. Врачын да күрдем. Әйбәт врач, кешелекле күренә. Тик бер нәрсә генә әйтеп куркытты ул мине: салкын тию әле ул кадәр үк куркыныч булмаска мөмкин, ди.

— Нәрсәсе куркыныч инде тагын?!

— Беләсеңме, Ахо, мин инде бу турыда бик күп тапкырлар уйландым, җавап кына таба алмадым. Кабулдан киткән чакта, түзмәдем, энисенең каберен күрсәттем мин Розалиягә. Уйладым-уйладым да, сабыйның моңа хакы бардыр, дигән фикергә килдем. Ялгыштым бугай. Кызым, күрәсең, моны бик авыр кичерә. Бер-бер психик авыруга дучар булмасын тагы дип куркам. Врач та шуңа ишарә ясады бугай.

— Шулай...— дип сузды Ахо, аннан соң кулындагы рюмкасын чәкештереп, башын артка ташлап, эчеп җибәрде.— Шулай, Хәбир туган... Ананы югалту зур фаҗига, олы кайгы бала өчен...— Ахо, күзләрен кысып, бер ноктага төбәлеп, уйланып торды, аннан соң Хәбиргә туры карады.— Ә менә атаны югалту? Анысы җиңелме балага, ә? Минем менә малай иде. Түп-түгәрәк, тап-таза малай, ике кан кушылудан ясалган беренче сорт малай! Аерылыштык хатын белән, ә малай аңарда калды. Дөреслекме бу?

Юк, пычагым да дөреслек юк монда! Малай бит минеке иде! «Әттә!» — дип үлеп тора иде. Мин хыяллана идем: бөтен җыйган малымны шушы малайга калдырам, ул минем нәселемне дәвам итәчәк! Барып чыкмады, югалттым малайны. Ул да мине югалтты. Юк, мин аны, әлбәттә, ташламыйм. Күздән җуймам мин аны. Ныклап аңлый башлагач, мин аның әтисе икәнен әйтеп хат яза башлыйм. Аралашып яшим. Аннан соң инде, нәкъ үсеп җиткән бер вакытында, чит бер шәһәрдән телеграмма сугам үзенә: «Бик нык авырыйм, түшәктә ятам, кил. Әтиең» дип. Әгәр ул шунда, кырык эшен кырыкка ташлап, җан-фәрманга ашыгып минем янга килеп җитә икән, мин аны, елмаеп, сау-сәламәт килеш каршы алам, бөтен мөлкәтемне, җыйган байлыгымны аңа калдырам. Ә инде ул шул чакта килмичә, «Вакытым юк иде, гафу ит»,— дип кенә хат язса, мин аңа бер тиен дә калдырмыйм! Чөнки белəм: унсигез яшькә җитеп тә үзенең кем каныннан булуы турында уйланмаган, үзенә тормыш бүләк иткән әтисенә рәхмәтле була белмәгән, ата канын кадерли алмаган кешедә өмет юк.— Ахо эчеп куйды да, син ничек уйлыйсың дигәндәй, Хәбиргә төбәлде. Шунда гына ул гәптәшенең читкә карап утыруын шәйләде.

— Ә-ә...— дип көрсенде ул, Хәбир караган якка ымлап.— Синең дә күзең төште мәллә? Чибәр нәрсә... Типтерә белә сәүдәгәрләр...— Ахо, ачуы килеп, төкереп үк куйды, янә рюмкасын тутырып, капыл гына эчеп җибәрде.— Ә син мине спекулянт дип рәнҗетәсең. Минем нәрсәм бар ул кадәр? Мин, ичмасам, тапканымны — эшләп табам, кешеләргә дә файда китерәм. Ә бу, шайтан алгыры, үз корсагына гына тутыра. Кара ничек ябышкан сөяркәсенә, корсагын ничек итеп җайлап терәгән?!

Ахо дөрес сизгән иде: Хәбир күптән инде залның аргы почмагындагы бер парны күзәтеп килде. Таза гәүдәле, кызыл чырайлы, сирәк чәчле бер ир белән күзгә-күз карашып серләшеп утырган яшь кенә ханым артык таныш булып тоелды аңа. Дөресрәге, башта ул аны Минзиләгә охшатып куйды. Аннан соң: «Чынлап та Минзилә түгелме соң бу?» — дип уйлады. «Юктыр, булмастыр, Минзилә нишләп әле монда йөрсен?» — дип икеләнде. Әлеге таза ир хатынны биергә чакыргач кына ышанды: әйе, бу хатын Минзилә иде. Хәбир аны буй-сыныннан, кыяфәтеннән, аяк атлауларыннан, хәрәкәтләреннән таныды. Ахо нәкъ менә шул чакта эндәште, аның читкә карап утырганын шул чакта сизеп алды.

— Ярар, төкер, тапкансың кызыгырлык нәрсә,— диде Ахо, Хәбирнең әледән-әле шул парга карап алуын күреп.— Андый кәттәләр безнең ишегә сирәк эләгә эләгүен, әмма дә акча булганда, мондыйны гына алыштырырлыкларны табабыз аны! Әйт кенә син миңа!

Хәбир Ахоның сөйләгәнен әллә ишетте, әллә ишетмәде. Ул берьюлы мең төрле уй эчендә калган иде. Яшьлегендәге Минзилә дә, үзенең армиягә китеп барулары да, Таһир да, Лиза да — барысы да берьюлы күз алдыннан үтте аның. Һәм уе, соңгы чиктә, Таһирга кайтып терәлде. Таһир? Аның белән бүген генә очрашкан иде бит әле Хәбир? Ул бит Хәбирне кунакка чакырган, адресын калдырган иде. Минзилә ни өчен монда? Таһир аңа Хәбирнең киләсен әйтмәгәнме әллә?..

Минзилә белән карашы очрашудан курыкты Хәбир. Бу очрашу, һичшиксез, ямьсез очрашу булачак иде. Шуңа күрә урыныннан кузгалырга ашыкты:

— Ахо, син мине гафу ит,— диде ул, әкрен генә.— Миңа бит иртәгә иртүк торырга кирәк. Китим мин, ачуланма...

— Иа хода! — дип кулларын җәйде Ахо.— Син нәрсә, туган? Мине монда бер ялгызымны ташлап калдырмакчы буласыңмы? Юк-юк, уйлама да! Бүген минем сине сыйлыйсым килә, сыйлыйсым!..

Ахоны көч хәл белән үгетләп, залдан чыгып китте, бүлмәсенә күтәрелде Хәбир. Ресторанда эчкән хәмер үзен шактый сиздерә, уйны бутый, ныклап, эзлекле итеп уйларга ирек бирми иде. Хәбир ваннага кереп, юынып чыкты. Тәне, башы бераз сафланып киткәндәй булды.

Хәбир кинәт Лизаны исенә төшерде. Кайдадыр эчтә, тирәндә калыккан әрнүле бер сулкылдау күкрәгеннән бәреп чыкты:

— Язмыш! — дип кычкырып эндәште Хәбир һәм тәрәзәгә килеп капланды. Әйтерсең, ул сөйләшкән, аңа җавап кайтарырга тиеш булган язмыш нә шул караңгы тәрәзә артында гына иде. — Нигә дип шулай каныктың син миңа, язмыш! Синең алда минем нинди гөнаһларым бар соң?

*Ахыры киләсе санда.*

# ӘДИПНЕҢ АЗ БИЛГЕЛЕ ШИГЫРЬЛӘРЕ

*Татар һәм башкорт әдәбиятчы-текстологлары көче белән классик язучыбыз Мәҗит Гафури иҗат мирасының зур өлеше халыкка кайтарылды инде. Соңгы елларда бу юнәлештә башкарылган эшләрдән күзгә күренеп торганнары — Казанда һәм Уфада әдипнең дүртәр томлы «Әсәрләр»е басылып чыгу. Алар М. Гафури тууга йөз ел тулуга багышлап әзерләнгәннәр һәм аны, башлыча, күренекле шагыйрь, хикәяче һәм балалар язучысы сыйфатында күз алдына китереп бастыралар.*

*Әйтергә кирәк, әлеге дүрттомлыкларны төзү эше торгынлык чорында алып барылды һәм бу нәрсә аларның эчтәлегендә дә, текстларның бирелешендә дә шактый дәрәҗәдә чагылыш тапты. Аерым алганда, берише әсәрләр басмадан читләштерелделәр, икенчеләре исә кыскартып урнаштырылды. Мисалга татарча басмасының I томын китерергә мөмкин. М. Гафуриның кыраклап шигыре, «Адәм вә Иблис», «Рисаләт» һәм «Йосыф вә Зөләйха» дигән өч поэма-легендасы юк анда. 3 томында утыз урында эчләренә күп нокталар сибелгән сынык җәяләрне очратабыз — болар исә текстларның «ярамаган» төшләре кыскартылып бирелүен аңлата. Ни өчен болай эшләнде соң? Чөнки без күп еллар әдәбият сөючеләрне, укучыларны әдипнең «чит карашлар»ыннан сакларга тырышып яшәдек. Барыннан да бигрәк Гафури иҗатын «милләтчелек»тән, ислам диненә бәйле моментлардан аралап алырга, аны иҗатында сыйнфый тигезсезлек күренешләрен чагылдырган революцион-демократ язучы итеп күрсәтергә омтылдык. Шөкер, хәзер безгә дә бу хатабыздан арынырга, Гафури иҗатын, әдәби һәм иҗтимагый әшчәнлеген хакыйкатьтә барынча чагылдырырга мөмкинлекләр ачылды.*

*Быелгы август аенда Гафуриның тууна 110 ел тула. Бу уңай белән, классик әдипнең мирасын фәнни тикшерү, яңабаштан карап чыгу җәһәтеннән нинди дә булса җитди чаралар күрелмәвен дә истә тотып, Гафури томнарына кертелми киленгән шигъри әсәрләре хакында берничә сүз әйтү, кайберләренең текстларын укучыларга тәкъдим итү урынлы булыр кебек.*

*Әйткәнебезчә, Гафуриның революциягә кадәрге иҗатыннан кырыклап шигъри әсәре татарча басмаларыннан читтә кала килә. Язылу вакытлары белән алар 1903—1917 елларга карыйлар. Аерым китап булып чыкканнары да бар аларның («Мөнла Һибәтулла бин әш-шаех Зәйнулла әл-Нәкышбәнди хәзрәтләренең мәрсиясе», 1903; «Адәм вә Иблис», 1910; «Замана шигырьләре», 1909 һ. б.), вакытлы матбугат битләрендә басылганнары да, җыентыклары эчендә дөнья күргәннәре дә аз түгел. Кайберләре исә кулъязма хәлендә генә сакланган. Боларның һәммәсенә тукталмастан, биредә «Милләт мәхәббәте» исемле җыентыгындагы шигырьләр язмышына гына күз салыйк.*

*Китап 1907 һәм 1911 елларда Казанның Шәрәфләр матбагасында басылып чыккан. Цензура әһелләре игътибарын да җәлеп иткән ул, аерым шигырьләрен русчага тәрҗемә итүгә исә Казан университеты профессоры, көнчыгыш телләре белгече мәшһүр Н. Ф. Катанов та тартылган булган. Бу юкка гына түгел. Ни дисәң дә, автор (китабының исеме үк ишарәли) татар милләтенә мәхәббәте хакында сөйли бит, аның бүгенгесенә борчыла, ерак үткәне белән горурлана, киләчәген кайгырта. Хөкемдарларга, руслаштыру сәясәтен тоткан, башка милләтләргә юл бирми яшәгән шовинистларга бу соң ничек ошасын икән?...*

*Китаптагы 38 шигырьнең 28 е дүрттомлыкта урнаштырылган. Ә калган унысы хакында анда бер сүз дә әйтелми. Чынында — алары да бүгенге укучыга тәкъдим ителерлек әсәрләр. Әдип, татар милләтенең язмышына сызланса да, һич тә милләтчелек чире белән авырмый, ягъни татарларны башка милләтләрдән өстен куймый, киресенчә, бүтән халыклардан үрнәк алып, уянырга, җаһиллектән, гайрәтсезлектән чыгарга чакыра. Егерменче гасыр башы татар шигъриятендә мондый рухтагы әсәрләрнең дә, һичшиксез, үз урыны бар. Алай гына да түгел, Мәҗит Гафурины борчыган күп кенә уй-кичерешләр, хис-тойгылар бүгенге буын татар кешесенең дә күңеленә бик якын, заманыбызга авазлаш.*

**Зөфәр РӘМИЕВ.**

# «МИЛЛӘТ МӘХӘББӘТЕ» КИТАБЫНДАГЫ ШИГЫРЬЛӘРДӘН

## Лисане хәлебез

Эчем кайгы, идәр аh-ваh лисаным —
Бу хәсрәтне каләмдер тәрҗеманым;
«Кеше хәлен кеше белми» дигәннәр,
Ничөн хәсрәт чигә минем бу җаным?..

Гафил ятмый урыннан кузгалырга
Мине мәҗбүр итәр инде заманым;
Бу көннәрдә кулымда калмагандыр
Нә Әстерхан, нә Болгар, нә Казаным.

Җиhанда миннән әхкарь hич кеше юк,
Мине кызган!.. Мине кызган, туганым!..
Зәваль юк, дип фикер иттем мин ахмак,
Кая китте гүзәл хан илә ханым?..

Озын чәчкә мөсәххәр булды бунлар —
Моны күреп тәгайер итте каным.
Гаҗиз булдым аякка баса алмый,
Ята-ята агырган ике саным.

Динем, дөнья пәракәндә улыптыр,
Кулымда калды ялгыз бу иманым;
У мөлкәт берлә китмеш бергә гайрәт,
Кулымда калмаган гайрәт нишаным.

Бу көннәрдә миңа махсус ватан юк,
Мәкам улмыш шу дошманга мәканым;
Качан бетәр татарның аh-зары?!..
Кулымда файда юк, күптер зыяным.

---

Лисане хәлебез — ап-ачык күренеп торган хәлебез.
Тәрҗеманым — аңлатучым, күчерүчем.
Гафил — ваемсыз, гамьсез.
Әхкарь — түбән; хур ителгән.
Зәваль — бетү, юкка чыгу; үлем.
Мөсәххәр булды — буйсындырылды.
Пәракәндә улыптыр — таркалыптыр.
Нишаным — эзем, галәмәтем.
Мәкам — тору урыны.
Тәгайер итте — алмашынды, үзгәрде.

*

Үзенең гаклына татбикъ итеп диннәрне hәр милләт,
Буңа чаклы бу дөньяда ничә диннәр бозылгандыр.

Җидаль hәм ихтилаль берлән бетерделәр китапларны,
Явыз куллар кереннән сакланып калганы — Коръәндер.

hабил кател итеп Кабил кабул итмәде тәүбәне,
Шу көннән бу көнгә чаклы бу дөнья кып-кызыл кандыр.

Бәни адәмдә hәр заман гөнаh кыйлмак — гадәт бер эш,
«Кулың сузма!» дигән йиргә адәм кулы сузылгандыр.

hаваи нәфсинә алданды инсан hәм хатыннарга,
Хатыннарның сүзи берлән аталары хур булгандыр.

Безем тәгъбирчә бу көндә тәмәдденле дигән йирләр
Бөтен инсаннари мөhлик зарарлар берлә тулгандыр.

---

Татбикъ итеп — яраклаштырып. Җидаль — гауга, низагь. Ихтилаль — фетнә. Кател итеп — үтереп. hаваи — буш. Тәмәдденле — культуралашкан, мәдәниятле. Мөhлик — hәлак итүче.

Сән күрендең күзләрә дош-
манлыгың бетмәс кеби,
Безләри агыр эшә куш-
канлыгың бетмәс кеби.
Алдадың бик күп заман,
Гафил иде милләтләрем;
Бездә гафләт бетсә дә куш-
танлыгың бетмәс кеби.
Башкалар күзен ачарсә,
Ни өчен эчең пошар?
Юкса кылмадыңмы фарыз —
Солтанлыгың бетмәс кеби?
Хак зоһур итте бу көндә —
Аттылар сән шәйтани;
Атса да хак йолдызы,
Шәйтанлыгың бетмәс кеби.
Йә татар! Тиз сән дә уян —
Мөнкариз булмас борын;
Зан идеп булдың һәлак сән —
Ханлыгың бетмәс кеби.

---

Күзләрә — күзләргә. Эшә — эшкә. Гафил — ваемсыз, гамьсез. Гафләт — ваемсызлык, гамьсезлек. Ачарсә — ачар исә, ачса. Хак зоһур итте — алла күрсәтте. Мөнкариз булмас — юкка чыкмас. Зан идеп булдың һәлак сән Ханлыгың бетмәс кеби — ханлыгың бетмәс кебек уй йөртеп һәлак булдың син.

Алар бездән оялганнан
Тәрек кыйлмадылар горфен;
Алардан бән оялганнан
Тәрек итмәм татарлыкны.

Әгәр белсә иде милләт:
Хәвефләдер киләчәк көн;
Ганимәт дип белер иде
Татарлык бездә барлыкны.

Аларга улма, дус, хәйран
Һәр эшләре гаҗәеп дип;
Алар алмадылар күктән
Бу без күргән кибарлыкны.

Әгәр син иҗтиһад итсәң,
Алардан артта булмазсән;
Шигем юк, бер вакытларда
Алырсән игътибарлыкны.

Кешенең фазлына кызма!
Фәзаилне үзең эстә!
Алырга иҗтиһад иткел
Алар безгә кызарлыкны.

---

Тәрек кыйлмадылар горфен — гадәтләрен ташламадылар. Кибарлыкны — горурлыкны, тәкәбберлекне. Фазлына — өстенлегенә, яхшы ягына (дәрәҗәсенә). Фәзаил — өстенлек, дәрәҗә.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ТУКАЙЛАР РУХЫ

**Бу айда күренекле әдип, сугыш һәм хезмәт ветераны Салих ага Батталга 85 яшь тула. Шул уңайдан аның белән үткәрелгән әңгәмә тәкъдим итәбез.**



*— Салих ага, Сез бай һәм гыйбрәтле тормыш юлы узган могтәбәр язучыларыбызның берсе. Кем әйтмешли, Сезне аяклы тарих дияргә дә була. Әйтик, безнең буын совет чорының әүвәлгерәк тарихын башлыча китаплардан, газит-журналлардан гына укып белсә, Сез исә ул тарихның тере шаһиты. Димәк, безнең әңгәмәбез дә гел әдәбият турында гына бармас дип уйлыйм...*

— Әдәбиятның чор, тарих белән үзара мөнәсәбәтенә караган мәсьәләләр, нигездә, тәнкыйтьчеләргә кагыла. Сүз дә юк, без тарихыбызны әдәбияттан аерып карый алмыйбыз. Процент ягыннан алганда, илебездә сугышта катнашкан әдипләрнең зур күпчелеге — татарлар. Ул чордагы татар шигърияттен Мәскәүдәге татар әдәбияты декадасында да «солдат шигърияте» дип атадылар. Мәрхүм Шәрәф Мөдәррис бу хакта образлы итеп болай диган иде: «Әгәр сугыш вакытында Татарстан язучылары съездын үткәрергә кирәк булса, моны фронтта гына үткәреп булыр иде...»

Инде килеп, Ватан сугышында корбан булучылар арасында да азчылык милләт кешеләре бик күптер дип уйлыйм. Чөнки алар — күбесенчә гади солдатлар. Командир булыр өчен хәрби белем кирәк, ә азчылык милләтләрнең андый уку йортларына керү мөмкинлекләре чикләнгән... Хәзер бит Искәндәр патша (Александр Македонский) заманындагы кебек, командующий дип әйтмим, батальон, яисә полк командиры да һөҗүмгә үзе башлап керми — солдатларга әмер бирә. Ә кинофильмнарны карасаң, Ватан сугышында бары тик урыслар гына катнашкан дип уйларсың! Күңел өчен сирәк кенә бер грузинны яки казакъны күрсәтеп куялар... Һәлак булган 20 миллионның ничәсе кайсы милләттән икәнен белү бик мөһим. СССР Оборона министрлыгы, ниһаять, моны әшкәрә итәргә тиеш.

*— Сез сталинизм һәм неосталинизм мәхшәрләрен үз җилкәсендә кичергән буын вәкиле: яшьлегегез дә, иң актив иҗат итү елларыгыз да шул дәвергә туры килгән. Белмим, Сез үзегезне сталинизм корбаны дип исәплисездерме, юктырмы — шулай да әйтегез әле, үткән дәвернең «тимер пәрдәсе» артында яшәлгән гомерегез өчен берәр вакыт үкенү хисе кичерергә туры килгәне булмадымы?*

— Юк, гомумән, үкенү хисе миңа ят нәрсә. Ялгышам икән, моның өчен үкенеп ни файда? Мондый ялгышны кабатламас өчен уйлабрак эшләргә кирәк!

Сталин алла булып күктән иңмәде, халык күтәрде аны, без күтәрдек! Ялгышканбыз икән, нигә аңардан соңгыларны да шулай күтәрәбез?!

Безнең авылда Таз Мәгыйзь бар иде. Мәрхүм сөйли-сөйли иде дә: «Валлаһи, бусы дөрес!» — дип куя, шулай итеп, башта әйткәннәрен юкка чыгара бара иде... Сталиннан культ ясап авыз пешкәч тә, бу хәлдән сабак алмыйча, нигә без аңардан соң килгән берсен «Валлаһи, бусы дөрес эшли!» дип, тәнкыйть итми генә, ленинизмны һәм конституцияне санга сукмыйча яшәдек?

Сталин калкып чыкканчы дистә еллар элек мин 1901 елда туган абыемны гражданнар сугышына озатып, 1921 елгы ачлыкны баштан үткәргән малай. Аннары эшсезлек.

Очраклы эшләрдә тирләп, туңып
Мәскәү тирәләрен урадым.
Карыйм, тагын кайсы завод терелә,
Төтенен болгап, чакыра морҗасы, —
Чабам! — килә хезмәт бәхетен татып,
Кочагына арып егыласым...

Аннары ике еллык татар-башкорт эшче яшьләр курсларында МОНО хисабына ачлы-туклы уку (МОНО — Московский Отдел Народного Образования).

Егерме тиен МОНО бирә ашар өчен;
Аз ашатып интеллигент ясар өчен;
Ипи алсаң, акча калмый шәкәр өчен; —
Моннан артык тагы гаҗәп булыр әле...

— дип яздык без ул чакта дивар гәзитенә. Күмәк язган бу шигырьнең бер авторы мишәр иде, шул шикәрне «шәкәр» дип рифмалаштырды. Шуннан соң ул мишәрнең үзен дә без «мәшәр» дип йөртә башладык.

Хуҗалык башлыгыбыз Зольков, татарча — Зөлкәбир,
Шунда бик яхшы укырбыз, өч талон бер көнгә бир!

Әнә шулай без егерменче еллар уртасында ук талонның ни икәнен белдек. МОНО биргән 20 тиеннең 10 тиенлек талонына вокзал ашханәсендә төшке аш ашап кайта идек. Калган 10 тиенен иртәнге һәм кичке ашка тоттык. Бу чор — НЭП — яңа икътисади сәясәт дип атала иде. Партия тарихын укытучы дәрестә болай диде: «Зиновьев әйтмешли, без Кронштадт вакыйгалары тәрәзәгә шакыгач кына бу сәясәткә күчтек!». Берочтан бу сәясәт турында Ленин сүзләрен дә искә төшерде: «НЭП — ул артка чигенү. Аның каравы, без бөтен халык белән бергә алга барачакбыз».

Сталинның ул чорда ук генераль секретарь булуына карамастан, без аның турында берни дә ишетми һәм белми идек. Ленинның авторитеты никадәр зур булмасын, ул Сталин дәрәҗәсендәге культ булмады. Укытучыларыбыз да аны ул кадәр өскә чөймәделәр. Беркөнне тарих дәресендә бер курсант: «...шуннан соң Ленин революция ясады», — дигән иде, укытучыбыз аны туктатып:

— Ленин бер ялгызы революция ясап йөрдеме?! Тибәрләр дә егарлар! — дип куйды.

Икенче көнне укытучыбыз безгә бер түгәрәк пыяла күрсәтеп:

— Бу нәрсә? — диде. Без дәррәү: «Пыяла», — дип җавап кайтардык.

— Дөрес, ләкин гади пыяла түгел, — дип укытучыбыз язгы кояш балкыган тәрәзәгә таба атлады. Кояш нурын шул пыяла аша икенче кулындагы кәгазьгә юнәлткән иде, кәгазьнең бер ноктасы көеп, төтен күтәрелә башлады...

— Менә, — диде укытучы, — юлбашчылар да шулай: партиянең, ә партия аша сыйныфларның энергиясен, аңын бер максатка туплап, революция утын кабызалар. Ләкин революция болай тиз булмый. Моның өчен еллар буенча, төрле шартларда төрлечә тактика кулланып көрәшергә кирәк... Ялгышларны кабатламаска. Менә шулай җиңде Октябрь революциясе...

Ә инде сталинизм, неосталинизм миңа, ачлык һәм эшсезлек нужаларын баштан үткәргәнгәдер, мәхшәр булып күренмәде. Күмәкләшү чорында, илнең бер чигеннән икенче чигендәге аэродромнарга туктаусыз күченеп эшләгәндә исә һәрвакыт очу маршрутын өйрәнеп, үземнең экипаж әгъзаларын хәрби заданиене үтәрлек итеп «күмәкләштерү» белән мәшгуль идем. Игенчеләрнең күмәкләшүе, кулакларның сыйныф буларак бетерелүе турында вакыт тигәндә бары гәзитләрдән генә укып белә идем.

Дөрес, очкан чакта һавадан карап та чагыштырмача үзгәрешне күреп була иде: утызынчы еллар башында аерым хуҗалыкларның солы, тары, карабодай һ. б. иген басулары рәткә тезеп салынган төрле төстәге тасмалар кебек күренсә, бераздан ул «тасмалар» гаип булды, һәр культура чакрымнарга сузылган мәйданда җәйрәп ята башлады.

Белмим, сез «тимер пәрдә» дигәндә нәрсәне күз алдында тотасыздыр, мин исә моны 1922—1923 елларда Сталинның «автономлаштыру» дип, партияне баткаклыкка төшерүен, авыру Ленинның аны җитәкчелектән читләштерергә тәкъдим итүен бездән яшергән пәрдә, дип аңлыйм.

Ә баткаклык калды һәм без аңа ныграк бата бардык...

Тагын шул искә төште: мин үкенү хисен кичергәнмен икән бит! Һәм бер генә дә түгел — ике мәртәбә!

«Казан утлары»ның үтенече белән мин сугыш вакытындагы бер очышым турында

язган идем. Һәм ул басылып та чыкты. Тик шуны язарга онытканмын: әгәр бу очыш вакытында снаряд тиеп, самолет яраланса, мин аны капитан Гастелло үрнәгендә дошман объектына юнәлтеп, аның көлен күккә очырачакмын, ә укчы-радист белән штурман парашюттан сикереп, исән калырга тиешләр...

Шулвакыт өчебез дә телсез калдык. Әйтерсең, беренче мәртәбә күрешкәнбез. Штурман белән радистны танырлык түгел. Шундук аңлап алдым: мин аларга парашюттан сикерергә кушып, үземне генә шундый батырлыкка сәләтле дип уйлаганмын икән. Әгәр үзләрен эт итеп сүккән булсам да, алар болай ук гарьләнмәсләр, бәлки тәгәрәп көләрләр иде, гомердә булмаган хәлне күреп, хәтта үз ана телемдә сүгенүемне дә кичерерләр иде... Ә хәзер! Тере кешедән бозга әверелделәр.

— Ярар, ахыргача бергә очарбыз, — дидем мин, аркаларыннан кагып, ләкин күзләренә карамаска тырыштым.

85 ел гомер кичереп, икенче кат үкенүем үткән ел «Советская Татария» газитендә «Требую реабилитации» исемле мәкалә бастырып, Гомәр ага Бәширне ялганларга мәҗбүр иткәнем өчен булды. Юк, мин Гомәр аганы үземнең бертуган Галимҗан абыемдай якын күрәм. Ул да аның яшендә иде, гражданнар сугышында катнашты. Ватан сугышында һәлак булды. 7—8 яшемдә үк мин абыем белән сабан сөреп, җир тырмалап йөри идем. Гомәр ага да үз биографиясендә әтисенең тырмаланган җирнең баш-башын каеган тун якасына охшатып мактаганын яза. Хәзер моны аңлап, күз алдына китереп укучы, бәлки, мин генәдер? Без дә абый белән җирнең баш-башын шулай эшкәртә идек...

Кем уйлаган балалык, яшьлек хисләремә туганнарча эстетик юл ачучыны әлеге мәкаләм белән ялганларга мәҗбүр итәрмен дип: мине партиядән чыгарган бюрода катнашучылардан бәлки бердәнбер ул гына исәп калгандыр? Гогольнең «Ревизор»ында бугай, бер хатын, үзенең күгәргән тәнен күрсәтеп, кыйнаучы өстеннән шикаять итмәкче булгач, «Она сама себя засекла», — дигәннәр. Мине дә беркем дә түгел, үз-үземне партиядән чыгарганмындыр, ахры...

*— Егерменче еллардан соң бик күп язучылар, шул җөмләдән татар язучылары да, партаппарат идеологиясенә хезмәткә ялланырга мәҗбүр ителде. Бу шаукымга хәтта зур-зур язучылар да иярәләде. Ә Сез, Салих ага, шул чорларда язылган берәр әсәрегездән баш тартыр идегезме?*

— Шул елларда «Кешелек һәм күселек» исемле поэмам чыкты, ул «Мөсәлләм» исеме белән һаман да басыла әле. Дзержинский үлеменә багышланган һәм башка патриотик шигырьләрем дөнья күрделәр. «Язулы яулык» һәм «Сынау» исемле пьесаларым Академия театрында уйналды. Ләкин мин аларның берсеннән дә баш тартмас идем.

*— Сер түгел, торгынлык елларында мәгълүм даирәләр тарафыннан Сезгә диссидент ярлыгы тагылган иде. Хәтта Сезне партиядән чыгаруга кадәр барып җиттеләр. Бу эш ничек булды? Партократларны мондый чара күрергә нәрсә мәҗбүр итте?*

— Диссидент ярлыгын миңа дөрес такканнардыр. Чөнки бу сүз «башкача уйлау» дигәнне аңлата. Мин, чыннан да, башкача уйлый идем.

Мин — 1927 елдан бирле партия члены. Булды вакыт: партиядән чыгарылгач, хәтта үз-үземә кул салмакчы да булган идем...

Тик аңарчы республикада хәл ителгән бу мәсьәләнең ҮКта каралуын көтәргә булдым.

Мәскәүгә баргач, утырыш алдыннан ҮК инструкторы Иванова дигән бер ханым минем белән махсус әңгәмә үткәрде. Шул чакта ул мине бүлдереп:

— Как, как вы сказали? — дип сорады. Әйткәнемне кабатладым.

— Так не говорят, — диде ул, мин әйткәнне төзәтеп. Мин аңарга рәхмәт әйтеп, урысча ычкындырган ялгышым өчен гафу үтендем. Инструктор ханым исә шул мәлдә:

— Видимо, Иван Грозный мало работал над вами!.. — дип куймасынмы?!

Шунда мин куркыныч төштән уянган кебек, күземне ачып, төштән дә хәтәррәк чынбарлыкны күрдем: ҮК инструкторы Иванова аңлатканча, безнең партиябез Грозный кылган гамәлне азсына, бу юнәлештә тагын да күбрәк эшләргә тырыша икән!

Шул партиядән чыгарылган өчен үз-үземә кул салыргамы? Юк! Ләкин диссидент булып кына яшәргә ярамый, көрәшергә дә кирәк!

Берәүнең җинаять эшләвен белеп тә, аны фаш итмәү — ул җинаятьне бергәләп эшләү дип карала. Шуңа күрә мин Ивановaның ул сүзләрен генә түгел, Хрущевның урыс телен СССРдагы барлык азчылык милләтләрнең икенче туган теле дип игълан итүен дә, соңрак Брежнев җитәкчелегендәге ҮКның азчылык милләт балалары мәктәптә үз туган телләрен урыс балаларыннан соң калып өйрәнергә тиешлеге турындагы карарын да җинаятьчел эш санап, көрәшергә ант иттем.

Иванова белән әңгәмәдән соң, ҮКның контроль комиссиясе утырышында минем «эш» каралды. Рәис минем партиядән чыгарылуыма сәбәпче булган «Ватыйга мөрә-

җагать»нең кульязмасы дип, алдындагы кәгазьдән нидер укый башлаган иде, мин «Бу минеке түгел!» — дип кычкыргач, шып туктады.

— Ничек сезнеке түгел?

— Карагыз, мин анда кул куйганмы?

Ул кәгазьләренең аскы ягын әйләндереп карады да, шул ук минем «эш» буенча килгән А. Гомәргә (ул чакта Язучылар союзының партоешма секретаре) карап: «Кемнеке?» — дип сорады. А. Гомәр торып басты да, тынсыз калды.

«Батый» өчен Казанда ничек итеп партиядән чыгарылуым турында мин «Советская Татария» газитендә язган идем инде: ул чакта идарә бүлмәсендә «Батый»ның бер каралама вариантын укып, соңыннан чүп кәрзиненә ташлап киткән идем.

Димәк, шуны табып алганнар да, шул күләмдә урысча бер пародия кебек нәрсә язып, идеясен бозып, минем әсәрнең «юлга-юл тәрҗемәсе» дип, ҮКка ирештергәннәр...

Шунда мин тордым да әйттем:

— Мәсьәлә ачыкланды: монда башка автор әсәре тикшерелә. Аңа минем катнашым юк. Китәргә рөхсәт итегез. Пропускка кул куегыз, юкса чыгармаслар, — дидем.

— Әйтермен, чыгарырлар, — диде рәис, телефонга ишарә ясап. Һәм мин чыгып киттем.

Кунакханәгә кайткач, әллә Виноградов, әллә Смородин дигән берәү миңа шалтыратып: «ҮК сезнең лаеклы әсәрләрегезне тоткарлыксыз басып чыгарырга күрсәтмә бирде», — диде.

Һәм мин Казанга кайтып, күптән яза башлаган «Чирмешән ярларында» исемле шигъри романыма тотындым.

Ә инде дөресен әйткәндә, минем партиядән чыгарылуыма «Батый» бер сылтау гына булды. Төп сәбәп башкада иде. Язучыларның бер гомуми җыелышында мин ул вакыттагы беренче секретарь Тәбиевне тәнкыйть иткән идем...

*— Салих ага, инде берочтан партиягә ничек итеп кабат торгызылуыгыз турында да сөйләсәгез иде. Сезнеңчә ничек, язучы ниндидер бер партиядә торырга тиеш дип исәплисезме? Партияле әдәбият дигәнне ни рәвешле аңлыйсыз?*

— Партиягә кабат торгызылганчы 23 ел вакыт узды. Гәрчә, ҮК безнең өлкә комитеты карарын расламыйча, минем «эшне» борып, яңадан карарга кайтарса да, әсәрнең татар телендәге оригиналын зарарлы дип санадылар. Хәтта ул әсәрне эшкәртеп, басар дәрәҗәгә китерергә тырышуымны «политик ялгышын танымый, аны тагын да тирәнәйтә», дип гаепләделәр.

Мин аның юлга-юл тәрҗемәсен «Литературная Россия»гә юллап, уңай бәя алдым. Кайбер җитешсезлекләрен күрсәтеп, шуларны төзәткәч, басарга да булдылар. Редакция портфелендә күп материалларның чират көтеп ятуын да әйттеләр.

Хәер, минем үз эшләрем дә чират белән эшләнә иде. «Сигезенчесе кем?» повестен тәмамладым. Аны шул ук җитәкчелек: «Повестьтагы төп персонажның улы урыс гаиләсендә хыянәтче булып тәрбияләнә, бу бөек урыс халкына яла ягу, милләтчелек рухы белән сугарылган әсәр», — дип кире какты. Болар минем партиягә кабат торгызылуны тоткарладылар, билгеле.

Ә бит югыйсә 1956 елда ук XX съезд «тимер пәрдә»нең бер читен ачты. 1959 елда исә Ленинның «Милли политика һәм пролетар интернационализм мәсьәләләре» дигән китабы яңадан чыкты. Анда Ленин «бөек» дип аталган милләтнең көчләүче, «держиморда» буларак кына «бөеклеген» күрсәткән, шул җөмләдән типик урыс бюрократының хәтәрлеге турында кисәткән иде.

«Бөек»ләргә, «кәрлә»ләргә бүленеп,
Таркалмасын безнең тиң рәтләр;
Тик көчләүче булып, бер-берсеннән
«Бөек» була ала милләтләр.

Ә инде шагыйрьнең партиялелегенә килгәндә, Некрасовның:

Поэтом можешь ты и не быть,
а гражданином быть обязан,

— дигән юлларын искә төшерү кирәктер.

Утызынчы еллар башында ленинчыл партия бар иде әле, партия «актив»ка да, «пассив»ка бүленмәгән иде. «Партиясез актив белән бергә партиянең ачык җыелышы уздырыла» дигән игъланнар да эленә иде ул чакта.

Без хәзер бюрократизм белән көрәш кирәклеге турында күп сөйлибез. Экономистлар шуны ачыклаганнар: илебездә файдалы эш белән шөгыльләнүче хезмәт ияседәнең һәрберсенә ун ярымтамак туры килә икән. Берәү тиргә батып эшләп, унау

ашап ята дигән сүз. Алары инде бюрократия, сезнеңчә әйткәндә, партократия була. Аның белән көрәшү мөмкин түгел, чөнки бүген дә бөтен идарә итү рычаглары партократия кулында.

Ә инде партияле әдәбият дигәнне, сорауларыгыздан күренгәнчә, мин нәкъ сезнеңчә аңлыйм шикелле...

*— Сезнең кайбер әсәрләрегез беренче мәртәбә үзәк матбугатта урыс телендә басылып чыкты. Нигә алай? Мондый парадоксны ничек аңларга?*

— Бу парадоксны аңлатыр өчен мәрхүм урыс шагыйре С. Щипачевның СССР язучыларының II съездындагы чыгышыннан өзек китерү урынлы булыр: «Без татар шагыйре Салих Батталга үз вакытында ярдәм күрсәтмәдек. Һәм аңарга, үзенең талантлы, кискен конфликтлы «Олы юл буйлап» поэмасын яклап, аны урындагы «конфликтсызлык теориясен» урнаштыручылардан юк иттермәс өчен бернichә ел ялгыз сугышырга туры килде».

Мин әлеге поэманың урысча юлга-юл тәрҗемәсен эшләп, «Новый мир» журналына тапшырдым һәм ул басылып та чыкты.

«Сигезенчесе кем?», «Батыйга мөрәҗәгать» исемле әсәрләрем дә шундый ук язмышка дучар булды.

*— Татар әдәбиятының хәзерге торышыннан Сез канәгатьме? Бүген әдәбиятыбызга нәрсә җитми? Сез аның иртәгәсен ничек күзаллыйсыз?*

— Әдәбиятның яшәве, киләчәге телгә бәйләнгән. Бүген Ленинның «һичбер милләткә, һичбер телгә бертөрле дә өстенлек куймаска» дигән күрсәтмәсе дә, СССР Конституциясенең 36 нчы статьясы да үтәлми.

Шулай ук быелның 24 апрелендә урыс телен бөтен СССР территориясендә рәсми тел итеп законлаштыру да СССР Конституциясенең 36 нчы статьясына туры килми.

Республикаларның балалар бакчаларында да урыс теленә өстенлек биреп, шул телне генә белгән тәрбиячеләр тоту практикасыннан баш тартырга, ягъни шул республика телен дә белүче тәрбиячеләр булдырырга кирәк.

Ә без антиконституцион карарга хурлыклы рәвештә буйсынып, балаларыбыздан үз ана теленнән йөз чөергән урыслашкан буын үстердек! Һәм үстерәбез...

Миңа калса, хәтта Гитлер да СССРда нацизм сәясәтен болай кыю үткәрмәде, фашистик легаль булмаган киңәшмәсендә ул курка-курка гына болай дип белдерә:

«Кавказдагы кебек, Уралда да төрле халыклар һәм милләтләр бар. Уралда татар яки мордва телен, ә Кавказда, әйтик, грузин телен төп тел итү мөмкин дә булмас, бу политик яктан да дөрес түгелдер. Шуның өчен ул телләрнең барын да бәйләгеч итеп, бәлки, немец телен кертү турында уйлау кирәктер? «Исән калган славяннар» югары белем алмаска тиеш» (Совершенно секретно, только для командования» исеме белән Мәскәүдә чыккан китаптан).

«Кырымны барлык чит-ятлардан бушатырга...» (шул ук чыгыштан). Гитлер өчен чит-ятлар, әлбәттә, кырым татарлары. Гитлер хыялы тормышка ашты — татарлар үз җиреннән куылды.

Ватан сугышы башланганчы, Муса Җәлил башка каләмдәшләре кебек үк гади бер шагыйрь иде. Сугышта һәм әсирлектә — фашизмның өнендә ул, аның белән көрәшеп, «Моабит дәфтәрләре»н иҗат итте. Гадәттә, мондый күренеш турында: «Бу хәл аның эчендә йоклаган арысланны уятты», — диләр. Муса Җәлил үрнәге әдәбияттагы партиялелек, гражданлык мәсьәләсен дә, әдәбиятыбызның хәзергесе, киләчәге мәсьәләсен дә яктырта: әсирлек шартларында фашизмга каршы көрәш 35 яшьлек Муса эчендә йоклаган арысланны уяткан икән, хәзер шул яшьтәге әдипләребезгә нигә Муса традицияләрен дәвам иттермәскә?

Ленинчыл программа болай куелган иде бит: «Национальная программа рабочей демократии: никаких безусловно привилегий, ни одной нации, ни одному языку».

*— Салих ага, Сезнең торгынлык елларында язылып та, басылмый калган әсәрләрегез булу турында ничектер ишеткәнем бар иде. Ләкин аларның әле дә булса дөньяга чыкканы юк шикелле. Хикмәт нидә? Мөхәррирләр сагаймы, әллә үзегезнең матбугатка тәкъдим иткәнегез булмадымы?*

— Дөрес, сез искә алган нәрсә бар, ул — «Я отрекаюсь» исемле урысча язылган памфлет. ҮК инструкторы Иванованың миңа Иван Грозный исеме белән җинаятьчел янавыннан соң язылып та, ул ниндидер юллар белән Черек күлгә барып эләккән иде. Шунда эшләүчеләрнең берсе заманында мине чакыртып, тәүбә дә иттерде. Ул «тәүбә» язу машинасында басылып, әзерләнеп куелган. «Тәүбә»дә «Я отрекаюсь» дигән әсәрем Ленинга һәм юлбашчыларыбызга яла ягу дип бәяләнгән, аны төрле матбугат органнарына җибәреп бастырырга теләвем нык гаепләнгән иде...

Билгеле булганча, памфлет сатира жанрына керә, анда яманлауны мактау дип

тә, мактауны яманлау дип тә аңларга була. Иван Иванович Иванов исеменнән үзем булып, үземнең шовинистик эшләрем белән горурланып, Хрущев, Брежнев идеяләрен тормышка ашыручы булып яздым. Аларны кыюлыклары өчен мактадым, бабасы ягыннан калмык булган берәүне милли мәсьәләдәге кайбер кыюсызлыгы өчен «трус, паникер» дип атадым... Бусы Ленинга биргән характеристика икәнен, әлбәттә, аңлаганнар. Ләкин сатира жанрының үзенчәлеген генә аңламаганнар.

«Безне урынсыз яманлыйлар» шигырендә «Садакать бездә юкмыш, булмаса ялганымыз бардыр,— Нифак выставкасында күп медаль алганымыз бардыр»,— дигән юлларны язган Тукайны да хәзерге власть «Син ник ялганны мактап шигырь яздың?» — дип, җавапка тартыр иде микән?

«Я отрекаюсь» дигән памфлетның кайчан да булса басылып чыгасына мин ихлас-тан ышанам, чөнки үзгәртеп кору һәм хәбәрдарлыкның таләбе шундый.

*— Әйе, Сез гомерегез буе СССРда милли принципларның тупас бозылуы турында катгый сүзегезне әйтә килдегез. Ә бит бүген дә милләтләрнең үзбилгеләнү һәм суверенлыгы турында принципны гамәлгә ашырырга бик атлыгып тормыйлар. Ирексездән, «Ни өчен?» дигән сорау туа. Ә Сез, Салих ага, әлеге сорауга ни дип җавап бирер идегез?*

— Бу сорауга Энгельстан да төплерәк итеп җавап биреп булмастыр. Аның бу сүзләрен «Милли политика һәм пролетар интернационализм мәсьәләләре» дигән әсәрендә Ленин да кабатлаган. Мәгънәгә хилафлык китермәс өчен мин дә Энгельсның әлеге сүзләрен Ленин язган һәм сөйләшкән телдә китерәм: «Россия, — говорит Энгельс, — есть владелец громадного количества краденой собственности (т. е. угнетенных наций), которую ей придется отдать в день расчета».

*— Журнал укучыларга нинди теләкләрегез бар?*

— Пушкин әйтмешли, укучыларыбыз журналны нинди теләк белән укыйлар бит — эштән ял итепме, әллә имля ялгышларын эзләпме... Ә мин укучыларга кадерле журналыбызны күңел күзе белән укуларын теләп калам.

Әңгәмәне **Газинур МОРАТ** уздырды.

# ӘДИП ТУРЫНДА КАЛӘМДӘШЛӘРЕ

## Салих Баттал

Бөек Ватан сугышы еллары. Мин Казан госпиталеннән сәламәтләнеп чыккач, «Совет әдәбияты» журналы редакциясенә эшкә кердем. Анда матур әдәбият бүлегендә танылган язучы Фатих Хөсни эшли икән. Исәнлек-саулык сорашкач, ул күптән түгел фронттан, шагыйрь Салих Батталдан хат алуы турында әйтте һәм хатны миңа сузды. Ул хатта кайбер сугыш хәлләре, әдәбият мәсьәләләре турында язылган иде. Салих Баттал ул вакытта әле минем шигырьләр язуымны да, үземне дә белми: Казанга сирәк килә, әдәби кичәләрдә бик сирәк була, чөнки Мәскәүдә очучы булып хезмәт итә. Өстәвенә, мин дә ул вакытта әле матбугатта күренгән кеше түгел, үзем өчен генә мәхәббәт шигырьләре яза идем.

Салих Баттал журналның бер санында басылып чыккан «Авылда» дигән шигыремне укыган икән. Хатында ул шул хакта искә алган. Минем бу әсәрем турында бик җылы фикерләр әйткән. Аның башкалар иҗатына игътибар һәм ихтирам белән каравы инде бу.

Мин, әлбәттә, танылган шагыйрьнең яхшы бәясенә эчтән генә шатландым. Шулай итеп, безнең беренче танышуыбыз шигърият аша башланды.

Хәтеремдә, без кичергән авыр елларда мин «Нәләт төшкән уйлар» дигән бер шигырь укыган идем. Анда заман турында сак һәм оста итеп, тирән ризасызлык белдерелгән иде. Ләкин бара-тора шагыйрь сабырын һәм саклыгын югалтып:

*...Җыр язам дип тезгән сүзләрең дә*
*Елап өргән эттән тәрҗемә...*

— дип әйтергә, үзенең шәхси фикерләрен ачып салырга мәҗбүр булган. Минем моңа исләрем китте! Бу көчле сурәтләүле шигъри җөмләне еллар буена авыз әченнән генә кабатлап йөрдем һәм ул, дөнья күрә алмаган хакыйкать шикелле, күңел түренә йолдыз булып гел яктырып, ялтырап торды. Күп гомерләр әсәр яңадан дөньяга чыкмагач, тора-бара аның авторы да онытылды. Бу юлларны мин эпиграф итеп берәр шигыремә куярга уйлап, күпләрдән сорашсам да, аларның кем сүзләре икәнен белә алмадым.

Ләкин, «без капчыкта ятмый», дигәндәй, сораша торгач, бервакыт авторның үзенә тап булдым. Баксаң, ул — шагыйрь Салих Баттал икән. Мин моңа хәзинә тапкандай шатландым.

Әйе, Салих Батталның тылсымлы шигырь тартмасында андый хәзинәләрне күп табарга мөмкин. Әле шагыйрьнең ул тартмасында төрле асылташлар өстәлә генә тора.

Үзенең күңеле керсез, фикере ачык булганга, ул тормышта да шулай ачык фикерләргә ярый торгандыр дип күпме «ялгышты» — күпме «таяк ашады»! Ләкин һәрвакытта да Баттал — Баттал булып калды.

Бер шигырендә шагыйрь:

*...Баттал икәнемне онытсам да,*
*Сакта икәнемне онытмам!*

— дип әйткән иде. Мин аның бу юлларын беркадәр чәчмәгә әйләндереп:

*Кемнәр булуыңны онытсаң да,*
*Баттал булуыңны онытма!*

Син безгә, барыннан да элек, шуның белән кадерле, дим. Һәм, дусларча елмаеп, озын гомере, керсез-саф хезмәте белән котлап, кулларын кысам.

**Нури АРСЛАН**
апрель, 1990 ел.

# Үкенечләрнең берсе, актыккысы түгел...

Ниһаять, татар җаны да сталинчыл социализм кысасына сыймый башлады. Әле моннан берничә ел элек кекә үткәннәргә — куркып, киләчәккә тулы өметсезлек белән карасак, бүген иреннәребез язылa төште, мәңгегә йомылган дип уйланган авызлардан онытылган, төсләре уңып, кадере калмаган дип саналган сүзләрнең яңача яңгырар көне килде: «шәфкать» дибез, «мәрхәтле булырга» өндибез, иманыбызга кире кайтырга чакырабыз. Күзләр ян-якка түгел, бер-беребезгә туры карый. Телебезнең гаять зур әчтәлекле, тирән мәгънәгә ия сүзләре кабат күңелебезгә иңә һәм шул сүзләр бүген үзара мөнәсәбәтләрне билгелиләр. «Игелек», «татулык», «туган телебез», «газиз җиребез» дип әйткән саен күңелләребезгә яктылык сеңә бара, барыр юлыбызны киртәгә илтеп терәгән тар сукмактан котылып чыгып, Олы юлга чыгарга омтылабыз! Уйлап карасаң, чәчең үрә торырлык иде бит, валлаһи! Җитмеш ел дәвамында халкыбыз аңында мең еллар эчендә тупланган иманны — гаделлекне, ихласлыкны, өлкәннәргә ихтирамны, туган телгә рыясыз мәхәббәтне тәмам җуя яздык. Үзара мөнәсәбәтне, арадашлыкны, яшәеш чикләрен чиннар, дәрәҗәләр, биләгән урыннар билгеләде... Сүзләр җил очырта алырлык кибәккә әйләнде, тел бары тик ялган вә ялагайлануга, шапырыну коралына әверелде. Куабыз да куабыз, узабыз да узабыз! Баксаң, аксак атка атланган безләр әллә кайда артта, караңгыда, лыгырдык сүзләр сазлыгында батып калганбыз икән. Башлар иелде, билләр бөгелде, буйлар сынды!

Язмышыбызга һәр тарафтан зыян салынды! Ничәмә-ничә еллар әдәбиятыбызда безгә көчләп өстән тагылган ялган җаннарга буйсынып яшәдек. Ялган язучыларга тыңләп безнең буй-сыннарыбызны үлчәделәр, шуларга таянып безнең чынлыкка омтылган әсәрләргә каһәр укыдылар... Ул елларда күккә чөеп макталган байтак әсәрләрне бүген укып карасаң, шаккатасың: алар очына-очына «ныгыган социализм»ны мактаган дәвердә ил, халыклар, шул җөмләдән үзебезнең сөекле татар халкы да, нинди җәбер-җәфалар күргән икән дә, без күзле сукырларны алга чыгарып, язмышыбызны бетүгә, инкыйразга илткәнбез икән! Иреннәр йомык, күңелләр томанлы, җаныбыз байрак күтәреп йөргән бушбугазлар әсканҗәсендә булган икән. Хәтердә, татар әдәбияты үсеше юлында караташ

булып яткан бәндәләр бүген дә арада әле! Алар сагаеп нидер көтәләр, матбугатта Нина Андреева кебек мөртәтләр күренгәндә җанланалар, җай барында күләгәдән чыгып безне һаман искегә, җитмеш ел безне газаплаган, кискен аскан, кешелектән чыгарган, табигатебезне корткан буш идеяләргә кайтырга өндиләр.

Берәүләр илне имеп, халыкны күзгә-күз талап, һич читенсенмичә казна байлыгын үз кәефенә исраф итеп, күз буяп яшәде. Партия-бюрократик аппарат аларны мактады, күккә чөйде, аларның сатлык йөрәкләренә орден-медаль такты. Халык исеменнән сөйләнгән булып, халык мәнфәгатен үз рәхәтләренә алыштырган бәндәләр, еллар, ун еллар дәвамында өстен катлау вәкилләренә тәлинкә тотып, халыкны юк-бар белән алдап, капитализмны сүгеп, «Безнең ил иң бәхетле, иң рәхәт, иң иркен ил!» — дип дөнья сасытып яшәмәделәрмени?! Алар хәзер дә исән, күбесе безнең арада, хәзерге шартларга ярарга, яраклашырга тырышалар, булмаганны бар итеп, үз үткәннәрен бүгенчә сипләргә дәлилләр эзлиләр. Имеш, без барыбыз да илнең үзгәрүен теләгәнбез... Ялган! Күпчелекнең җаны усак яфрагы кебек калтырап торды, ялган белән өртелгән күзен түрәләр йорты тирәсеннән алмады, югарыдагыларның табанын ялады. Китабы әз генә тоткарланса да шунда чапты, иҗаты турында кискен, хак фикер ишетсә дә, койрык болгап, шунда үрмәләде.

Үткәннәрне хәтерләү авыр, ләкин «тормыш — хәтер ул!» дигән хак сүзне дә онытырга ярамый.

Соңгы елларда без күп нәрсәләрне хәтерләргә тырышабыз, утызынчы елларда бер гаепсезгә һәлак ителгән әдипләребезнең канлы язмыш төеннәрен чишә барабыз. «Бер гаепсезгә, нахакка җаннарын кыйганнар» дип кызганабыз, язмыш тәртипләрен халыкка җиткерәбез. Мине һәр очракта бер уй борчый: нигә аларның һәммәсе дә гаепсез булган икән? Нигә?! Нигә ичмасам арадан берәү: «Әйе, хәзерге социализм халыкларның үсеш юлын чикли, хөрлекне томалый... Әйе, колхозлашу мең вә миллионнарга һәлакәт китерде, җирне хуҗасыз калдырды... Әйе, кулакларны сөрәбез дигән булып, без җирне хуҗасыз, авылларны уңганнаарсыз калдырдык!» — дип әйтмәгән икән?! Утызынчы елларда илдә башланган хаксызлыкны, колхозлашуның җимергеч ударын, миллионлаган тырыш җир хуҗаларының эт җиккән якларга сөрелүен язучылар белмәгән, ишетмәгәнмени?! Моның өчен сукыр вә чукрак, телсез вә дөнсез булырга кирәк ләбаса! Русның атаклы шагыйре Николай Клюев утыз дүртенче елда, җәзалау органы вәкиле каршысында «Колхозлашу рус крестьянына ни бирәчәк?» — дигән сорауга болай дип җавап биргән: «Колхозлар җиргә хуҗасызлык, рус крестьянына һәлакәт китерәчәк!» Кемнәрдер аңлаган ич, хаксызга түгел, аңлаулары өчен гаепләнгән, алар Сталин системасының дәүләткә нинди бәла-казалар китерәсен чамалаганнар... Татар әдипләре дә бу юнәлешнең кая кадәр илтәсен белмәгәннәрме? Белгәннәр, сизенгәннәр, ләкин дәшмәгәннәр. Нигә шул кадәр юаш без?! Ничек шулкадәр рухсыз, көрәшсез яшәгәнбез?!.. Татар әдәбияты үрнәкләре егерменче гасырда чынлап торып дөнья әдәбияты агымына катнашып китә алмады диярлек. Бүтән халыклар безне аз беләләр.

Сүзләр тереләләр, халкыбыз әллә кайчан биргән мәгънәләрен алалар, сүзләр хаклы рәвештә безнең белән яңи башлыйлар. «Шәфкать», «мәрхәмәт», «иман» дибез... Тик бер олы сүз һаман онытылып кала бирә, байтак сүзләр күңелдә яралганда әлегәчә беребезнең дә «тәүбә-тәүбә!», «тәүбәгә килдем!» дигән авазы заманча яңарыш тапмады... Ә ул сүзне дә хаклы рәвештә яңгыратасы иде! Без яшәдек ич каһәрле елларда, без дә сүз сөйләдек, яздык, күңел серләребезне халкыбыз белән уртак итәргә тырыштык. Әгәр бүген миллионнан артык татар туган телен оныткан икән... Әгәр бүген татар кызларының байтагы чит милләтләр арасыннан кияү табалар икән... Шулай ук бик күп татар егетләре чит милләт вәкилләрен яр итәләр икән... Әгәр бүген шәһәр-авылларыбызда милли төсмерләр бетеп, кием-салымнарыбызда гореф-гадәтләребез чагылмый икән... Бу инкыйразда, бу һәлакәттә татар әдипләренең өлеше юкмыни?! Нигә без бүген үзебезнең беркатлы булуыбызны, йокымсырап яшәп, ялган сүз чәчеп, ялагайланып партократларга, бюрократларга, чиновникларга — тулы бер өстен сыйныфка ялланып яшәвебезне танымыйбыз? Нигә тәүбәгә килмибез?!

Заманында, иң кара елларда, атаклы шагыйребез Салих ага Батталны партиядән чыгарып ыргыттылар. Күптән түгел генә үзен партиядән чыгарышкан чордашына хат язып, ул аңа үзенең рәнҗешен, җан ачысын белдергән иде. Чордашы мәсьәләне бик гади хәл итте: «Мин ул чакта җыелышта юк идем, тавыш бирүдә катнашмадым», — дип акланды да куйды. Ансат котылу! Суга керен тә, коры чыга алу! Әгәр Салих аганың чордашы, ничәмә-ничә еллар дәвамында безнең халыкның гадел әдибе дип тәкъдим ителгән иптәш, Салих агага җавап хатында: «Җыелышта, чыннан да, юк идем, Салих кордаш, гафу ит мине, кичер, җыелышта булсам да мин сине яклап чыгыш ясамас идем, «чыгармагыз!» дип тавыш бирергә йөрәгем җитмәс иде», — дисә, нинди гүзәл һәм акыллы адым булыр иде бу!

Ә Салих аганы, шул заман әһелләре күзлегеннән карaганда, гаепсез дип әйтеп булмый. Салих ага дөньяны, җирне-күкне, елга-күлләрне, җир йөзендәге һәрбер нәрсәләрне үзенеке генә итеп игълан итәргә тартышкан шовинистларның бөген ертып коңга чы-

гарганы өчен дә гаепләнде ул чагында. Бүгенге көн күзлегеннән караганда Салих ага батыр йөрәкле, кыю, намуслы, гадел һәм гүзәл рухлы кеше булган! Коридорларда, аулак кулуарларда аңа теләктәшлек белдергән, аңа рәхмәт әйткән кешеләр очраштыргалады, мәгәр аны яклап дау күтәреп чыккан шәхесләр бар идеме икән? Хәтерләмим. Без, күп еллар дәвамында, үзебез кыеп сүз әйтү түгел, әйтә алганнарны да яклап чыга алмадык. Яшьләребезнең дә әдәбиятка шактый имгәнеп, икеле-микеле уйлар белән килүендә дә шушы йомшаклыгыбыз сәбәпчедер дип уйлыйм...

Съездларның берсендә, үз фикеремне уртак итәргә теләп, трибунадан мин: «Партия группасы нәрсә карагандыр, мин аларның фикере белән асла килешмим»,— дип белдерү ясаган идем... Шушы гади генә шик өчен язучылар съездларын үз учында йомарлап тота торган Мөдәррис Мусин мине ярты сәгать эт итеп сүкте... Аның сүзләренә исем китмәде, тәнәфескә чыгып, яныма беренче булып йөгереп килгән якын бер иптәшемнең шушы вакыйгага мөнәсәбәте исә таң калдырды. «Партия шундый ул... аңа кагылырга да, сүз әйтергә дә ярамый... Син моны бүгеннән колагыңа киртләргә тиеш!» — дип, дустым миңа акыл биреп китте.

Без олы әдибебез, кыю чордашыбыз Салих ага Батталга бер чакта да акыллы, җитди күз белән карамагандыз. Чордашлары белән якынлыгын белмим мин аның, кызганычка каршы, ул безнең белән дә, артларыннан бастырып килүче буын вәкилләре белән дә якынаерга тырышмады. Алай да Салих аганы партиядән сөргәндә без аның җанын, рухын, иманының яктылыгын аңлый идек шикелле. Бу рух аның яшәешендә дә, иҗатында да нык чагылган икән... Аның «Олы юл буйлап» поэмасы заманның иң алдынгы фикерләү сызыгында торган «Новый мир» журналында басылды... «Сигезенчесе кем?» повесте безне нык уйландырырга тиеш булса да, әлеге дә баягы, кыйналганны тәпәләргә тиеш заманнарда, без аның исемен байрак итеп күтәреп йөртә алмадык... Тарихи гаделсезлекләрне ачарга тырышкан өлкән агабызны заманында, хәҗәт мизгелләрдә яклаган берәр кеше булдымы икән? Булмый калмагандыр, ләкин аның исеме дә халык арасында ныгымады... Алай гынамы, шул чорда, мин драматурглар секциясе башында торганда, кыйналган көннәрендә ул безнең игътибарга пьесалар җыентыгын тәкъдим итте. Хәтердә, язмын йөген тибеп төшереп калдырып булмый, без аның әсәрләренә тиешле бәяне бирмәдек, без нидәндер куркыктык. «Әһә, Баттал бит ул ни... партиядән куылган иптәш!» Безнең шул ялгыш карашыбызны ул чагында язучыларның партия оешмасын җитәкләгән иптәш тә хуплады, аның сикерә-сикерә безне мактавы әле дә хәтердә...

Кичерә алсаң, кичер, Салих ага! Без, синең арттан килүче, әз-мәз кыен ашаган кешеләр дә сиңа терәк була алмадык! Безгә сабак, бездән соң килүчеләргә акыл бу!

Булды, минем дә кыйналган чаклар булды. Академия театры сәхнәсендә, яз һәм көз, ике пьесам «Җиз кыңгырау» һәм «Киек каз юлы» куелгач, кемнәр генә мине типкәләп чыгыш ясамады! Җирле газеталарда гына егермедән артык мәкалә чыкты. Мине ни өчен кактылар дисезме? «Киек каз юлы» өлкә комитеты әһелләренә бер дә ошамады. Өлкә комитет вәкиле спектакльне икенче тапкыр карарга килгәч, пьесаның текстын тезе өстенә куеп, тамашачыларның һәр реакциясен билгеләп тамга салып һәм хөкем чыгарып утырды. Кай урында көлә халык, кайда теләктәшлек белдереп кул чаба, икенче көнне мине югары йортка, почмакка бастырып арт сабагымны укыттылар. «Нигә монда гел «халык та халык» дисең, нигә «партия» дигән сүз юк!» — дип гаепләделәр... Төп гаеп шул булды. Бер атнадан тагын чакырдылар. «Төзәттеңме?» — диләр. «Төзәттем, димен, элек әсәр герое Хәллә Бадамшин «трестка барам, тресттан кайтам» дип белдерә иде, хәзер ике урында «горкомга барам» дип чыгып китә, «горкомнан кайттым» дип килеп керә», — дигән идем, җаваплы иптәш пьеса текстын минем чыраема атты. Спектакльне бөтенләйгә тыйдылар. Ул чактагы ыгы-зыгыны режиссерыбыз Ширьяздан ага Сарымсаков хәтерли булыр?!

Бераз соңрак Әхсән Баяновның ифрат уңышлы «Яшьлегемне эзлим» повесте тирәсендә сүз купты. Бәхәскә мин дә катнаштым һәм «Ә син үзең кем, укучы?» исемле мәкаләм «Совет әдәбияты» журналында басылып та чыкты. Шул уңай белән миңа байтак вакыт «төерле коймак» ашаттылар... Булды, ярдәмгә мохтаҗ чаклар күп булды. Теләктәшлек белдергән әдипләр дә булмады түгел, мәрхүм Гази ага Кашшафның мине аңларга тырышып язылган мәкаләсе әле дә исемдә...

Шул шомлы елларны «Әңгер-меңгер» дип игълан иткән өчен күпме кыен ашамадым мин!

Моннан ике ел элек Салих ага Батталдан көтелмәгән хат алдым. Хат букчасыннан аның байтак еллар элек «Социалистик Татарстан» редакциясенә юллаган мәкаләсенең копиясе килеп чыкты. Минем омтылышларымны дөрес аңлап, чатакларым белән килешмичә, уй-фикерләремнең юнәлешен тулаем аңлап, газетада чыгыш ясарга теләгән Салих ага. Әлбәттә, басмаганнар аның мәкаләсен! Сәбәбе һаман шул булгандыр дип уйлыйм: «Сак булыгыз, Салих Баттал мәкаләсе ул!» — дигәннәрдер... Хат бит исеме-чабы обком агайларының мыегын чуалтучы Аяз Гыйләҗевкә багышланган! Иншалла сак булу файдалы!

Хат күп елларга соңарып килсә дә, күңелле булды. Рәхмәт сиңа, Салих ага! Хат үз вакытында килеп ирешсә, тагын да күңеллерәк булыр иде... Бәлки, миңа яшәү дә, иҗат итү дә бәхетне тулырак итәр иде. Хәер, «татарныкы төштән соң» диган ачык хакыйкатьне безгә башка халыклар көчләп такмаган, аны күп еллык тәҗрибәбездән чыгып бабаларыбыз чыгарган. Минем эндәшем дә бик соң, үтә соң барып ирешер. Ләкин бу эндәшем — тәүбәгә килүем минем. Кичерә алсаң, кичер, Салих ага! Эчке фикердәшең булып та, үз вакытында, сине тәртеп екканда, иңемне куя алмаганмын. Менә нәрсә ҮКЕНЕЧ!

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ,
13 - 14 май, 1990 ел.

## Татарча радиограмма

Очучы Салих Баттал сугыш вакытында хәрби йөкләмә үтәргә очып барганда, аста — диңгездә совет корабларының да һөҗүмгә йөзгәнен күреп, татарча радиограмма юллый:

— Батыр татар диңгезчеләре! Дошманны катырак кыйнагыз! Татар язучысы Салих абзагыз Баттал!

Корабтагы радист хәрефләп тапшырылган радиограмманы аңламый, командиры янына йөгерә.

— Менә, — ди радист. — Безнең кораб өстеннән очып баручы берәү әллә нинди сәер радиограмма тапшырды.

Капитан моның татарча икәнен чамалап, бөтен диңгезчеләрне сафка тезеп, радиограмманы татар егетенә биреп, бөтен состав алдында радиограмма укыттыра.

Шуннан соң корабтан очкычка татарча радиограмма менеп китә:

— Сынатмабыз, Салих абый! Татар халкының йөзенә кызыллык китермәбез! Татар диңгезчеләре.

## Тиз үзгәрүчеләр

Коточкыч цензура, кысу заманасында да Салих Баттал үз фикерен әйткән һәм язган кечле шәхес. Шундый әсәрләренең берсендә ул мондый күренешне сурәтли. Колхоз рәисе, районнан килгән түрәгә ялагайланып, колхозның Демократия исемле бозавын суя һәм вәкилнең тарантасына салып җибәрә.

Элек тә кыен күргән Баттал бу әсәрдән соң тагын да катырак кыйнала башлый. Өстә өстенә нахак гаеп өеп, аны партиядән чыгаралар. Еллар узгач, замана үзгәрә башлагач, шул ук кешеләр аны партиягә кайтару белән дә шөгыльләнә. Шундыйлар Батталдан алда:

— Яшәсен демократия! Без демократияне яклаучылар! — дип янә лаф ора.

Язучы Батулла шул турыда Батталның үзенә әйтә. Салих ага бераз дәшми торгач, болай ди:

— Үзгәртеп кору заманында тиз үзгәрүчәннәр үз файдасына кененә кырык үзгәрергә дә риза! Син, энем, тиз үзгәрүчәннәрдән саклан! Җае чыкса, алар мине тагын партиядән чыгарачак!

## Һыбылар

Әсәрләрен бастырмый башлагач, Батталга әйткәннәр, имеш:

— Салих ага, нишләп синең исемең бу арада матбугатта күренми? — дигәннәр.

Җавап итеп Баттал әйткән, имеш:

— Нигә күренмәсен? Көн саен минем турыда язалар ич! — дигән.

— Кая? Кайда? — дип гаҗәпкә калган сораучылар.

— Һәр гәҗит минем турыда мәгълүмат бирә, — дигән Баттал. — «Бу җыелышта Мирсәй Әмир, Сибгат Хәким, Гариф Гобәй һ. б. лар катнашты» диләр. «Һыбылар»ны — «һәм Батталлар катнашты» дип укырга кирәк.

Роберт БАТУЛЛА

**Лирон Хәмидуллин**

# КИҢӘШЛЕ ЭШ ТАРКАЛМАС

Әйе, барлык халыклар телендә дә шундый әйтем яши. Бергәләп, киңәшләшеп эшләнгән эш эзсез калмас, таркалмас... Бу язма да — әнә шундый бер фикер алышу, киңәшләшү турында.

Берничә ай элек Алма-Ата шәһәрендә әдәби бәйләнешләр һәм тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган халыкара конференция булып узган иде. Бу олы киңәшмәне Казагыстан Язучылар союзы каршында бер ел элек кенә барлыкка килгән «Тәрҗемә һәм әдәби бәйләнешләр Баш редакциясе» дип исемләнгән берләшмә оештырган иде. Әлеге берләшмәгә исә шушындый катлаулы һәм шактый ук мәшәкатьле бу эшне башкарып чыгарга СССР Язучылар союзы карамагындагы Тәрҗемә Советы җитәкчелеге дә, җирле Язучылар союзы идарәсе дә зур булышлык иткәннәр иде.

Конференциянең төп темасы «Үзгәрүчән дөнья хәлләре шартларында әдәби тәрҗемә мәсьәләләре» дип билгеләнсә, төп максаты исә илебез халыкларының үзара киеренке мөнәсәбәтләре яктылыгында бердәм фикер туплау һәм бердәмлеккә ирешү юлларын барлау булды дип әйтер идем мин.

Киңәшмә эшендә әдәби тәрҗемә һәм арадашлык проблемалары белән даими шөгыльләнгән байтак кына язучы галимнәр һәм тәрҗемәчеләр катнашты. Шул җәһәттән чит мәмләкәтләрдән унике кеше, күпчелек союздаш республикалардан икешәр-өчәр вәкил һәм өч автономияле республикадан дүрт язучы-тәрҗемәче килгәннәр иде. Тагын Таулы Алтай автономияле өлкәсеннән бер әдип — Торшын Торбоков та булды. Алда аерым тукталып тормас өчен, автономиядәш делегатларны атап үтим. Татарстаннан анда мин, Башкортстаннан Хөрмәт Биккол, Якутиядән шагыйрь Семен Руфов белән прозаик Иван Федоров катнашты. Руфовтан башкаларыбыз күңелләребездәге уй-фикерләрне әйтергә тырыштык. Мин, мәсәлән, конференциянең беренче көнендә чыгыш ясадым, автономиядәш башка иптәшләр киңәшмәнең соңгы көнендә, Язучылар союзында уздырылган утырышта сөйләделәр.

Автономияле республикалардан тагын Каракалпакстан вәкиле дә чакырылган иде, ләкин, ни сәбәпледер, аннан килүче булмады. Союздаш республикалардан Әрмәнстан делегациясе киңәшмәдә катнашучылар күңелендә беркадәр ризасызлык төсмере калдырды. Алар, берничә язучы, Әрмәнстан башкаласыннан Алма-Атага турыдан-туры очучы самолет юк, мәгълүм сәбәпләр аркасында Бакуда тукталыш ясап очасыбыз килми, дип, сәяси дәгъва белдергәнрәк телеграмма гына җибәрделәр. Конференция делегатларының күпчелеге мондый сылтауны хупламады, билгеле. Ник дисәң, шул ук төбәктән килүче Грузия язучыларына да бит турыдан-туры рейс булмаган, алар да бирегә, бик җайсыз шартларда Ташкент аэропортында тукталыш ясап, икенче рейс белән очып килгәннәр иде. Шулай ук башка делегацияләрне дә өф-өф итеп, өйдән-өйгәчә озатып куюлар каралмаган иде.

Алма-Атада булачак шушы олы сөйләшүгә дип махсус әзерләнеп, Венгрия, Кытай һәм Чехословакиядән икешәр кеше, Болгария, Монголия, Израил, Сүрия, Төркия һәм Франция илләреннән берәр язучы килгәннәр иде. Конференциянең рәсми телләре итеп казакъ һәм рус телләре билгеләнде, баштагы ике көндә — утырышлар Казагыстан Фәннәр академиясенең зур залында барганда — чыгышлар шушы ике телгә тотрыклы рәвештә тәрҗемә ителделәр. Безгә, Россиянең төрле төбәкләреннән җыелган кешеләргә, бигрәк тә шунысы гыйбрәтле һәм кызык тоелды: чит ил кунакларының бер өлеше рәсми чыгышларын саф төрки-казакъ телендә башкардылар. Үзара безнең белән гәпләшкәндә дә алар, «гой-бай» кушымчаларын өстәп, һич тә тотлыкмыйча һәм ят сүзләр кыстырмыйча, казакъча бик иркен сөйләштеләр.

Мәсәлән, тумышы белән маньчжур кабиләләренең берсеннән булган кытай галиме һәм язучысы Ха Ба Хуанҗан, һәр җөмләсен дип әйтерлек бик күтәренке тавыш белән: «Җолдастар!» — дип башлый-башлый:

— Мин монда Абай илен аңсып килдем... Жолдастар! Мин төрки әдәбиятларны өйрәнү өчен, эзләнү өчен килдем, — дип, бик ялкынланып сөйләде.

Шулай ук Венгриядән килгән тәрҗемәчеләр шагыйрь Ференц Буда белән әдәбият галиме Иштван Мандоки, Монголиянең Баянөлгәй аймагыннан (өлкәсеннән) кунак Жәмлиха Шалулы, Кытайдан әдәбият галиме һәм тәрҗемәче Бай Цыхун да залдагыларга үз фикерләрен бик аңлаешлы итеп казакъ телендә ирештерә алдылар. Төрек галиме һәм язучысы Ирфан Насретдин улы, авыру сәбәпле, беренче көн утырышларында була алмады, ә инде соңгы көндәге үзара аралашу барышында шулай ук барлык төрки телле делегатлар аңларлык дәрәҗәдә әңгәмәләште.

Бу хәлгә без, төрле автономиялардән килгән язучылар, сокланып та, көнләшеп тә утырдык, билгеле. Әйе, Союздаш мәмләкәт халыкларының телен чит илләрдә дә өйрәнәләр икән, ул республикаларның мөмкинлекләре зур, бик зур, ә арадашлык-дуслык мөнәсәбәтләре бик тә колачлы икән! Бу хәл, әлбәттә, бер казакъ әдәбиятына гына карамый. Украина, Белоруссия, Үзбәкстан, Грузия яисә Балтик буе республикалары кебек дөнья үзәгендә кайнаганнары гына түгел, алардан гадирәкләренең дә чит мәмләкәтләрдә яшәүче каләмдәшләре белән аралашу мөмкинлекләре безгә караганда бермә-бер артык: алар әледән-әле бергә очрашып сөйләшә һәм киңәшәләр, бер-берсенең (милләтләр күздә тотыла) әдәби мираслары, мәдәни казанышлары белән даими рәвештә уртаклашып торалар.

Алма-Атадагы конференция барышында да без мондый үрнәкләрне күп ишеттек. Әнә бит Кытай әдәбиятчысы Ха Хуаҗан бүгенге казакъ язма әдәбиятының нигезен салган Абай Конанбаев иҗатын аның туган җиренә килеп өйрәнгән, кытай телендә аңа багышлап күләмле гыйльми хезмәт язган, Абай шигырьләренең тулы җыентыгын кытай телендә бастырып чыгарган. Хәзер исә ул Абайның шәкертләре — егерменче гасыр башында иҗат иткән күренекле Казакъ шагыйрьләренең иҗатлары белән дә кызыксына икән. (Казакъ мәдәниятында якты эз калдырган ул акын-шагыйрьләрдән Мәгъҗан Җомабаев, Шәкәрим, Йосыфбәк Аймаутов иҗатлары соңгы елларда халыкка яңадан кайтарылды).

Монголиядә дә казакъ әдипләренең иҗатына булган ихтыяҗ арткannан-арта бара икән. Җәмлиха Шалулы башлыча шул турыда һәм киләчәктә ни-нәрсәләр тәрҗемә итәргә кирәклеге турында сөйләде.

Европадагы барлык илләрдә дә казакъ әдәбияты һәм казакъ халкының борынгы авыз иҗаты күпләп бастырып чыгарыла һәм шул халыклар телендә яратып укыла икән. Киңәшмә-конференциядә бу хакта Болгария, Венгрия, Чехословакия язучылары тәфсилләп сөйләделәр. Билгеле, башта конференцияне ачу тантанасы булды. Анда тәрҗемәче язучылар алдында торган мөһим бурычлар хакында кыскача докладны Тәрҗемә һәм әдәби бәйләнешләр Баш редакциясе рәисе, күренекле этнограф һәм әдәбият галиме Морад Әүэзов ясады. Киңәшмәне исә кыскача кереш сүз белән рәиснең урынбасары, күренекле прозаик һәм тәрҗемәче Сатимҗан Санбаев ачып җибәрде. Алардан соң башлап сүз алган Франция вәкиле Жан Малори да иң элек казакъ әдәбияты белән арадашлык мәсьәләләренә тукталды. Якын киләчәктә Париждагы үз нәшрияты «Плон»да казакъ фольклорын, Абай Конанбаевның тулы басмасын чыгарачакларын әйтте. Үзе дә Казагыстанга багышлап бер китап яза башлаган, шул китап та тиз арада «Плон» басмасында дөнья күрәчәк икән.

Жан Малори нәшир һәм язучы-тәрҗемәче генә түгел, ул халыкара ЮНЕСКО оешмасының әдәби арадашлыкка багышланган бер комиссиясендә эшләүче әдәбиятчы галим дә икән әле, дөньякүләм әдәби тәрҗемә хәлләрен дә яхшы ук күзаллый. Һәр халык язучысы үз ана телендә иҗат итәргә тиеш, аны башка телдә сөйләргә, язарга көчләү ярамый. Ә тәрҗемәче исә, ике телдә дә иҗат иткән кайбер язучылар шикелле үк, ике халыкның да гореф-гадәтләрен белеп эш иткәндә генә уңышка ирешә ала. «Шунлыктан безнең бурыч — бер-беребезнең гореф-гадәтләрен, телләрен өйрәнүдән башланырга тиеш», — диде Жан Малори. Шөбһәсез, бүгенге бу уртак киңәшмәбез шул юлда бер зур эш булыр, халыкара бәйләнешләрне, танып-белешүләребезне ныгытыр, димәк, халыкларыбыз дуслыгын ныгытыр, дип белдерде ул. Аннары француз әдибе кабат Казагыстан вәкилләренә мөрәҗәгать итте:

— Бу ил белән танышуымны киләчәктә дә дәвам иттерәчәкмен. Ә казакъ әдәбиятын турыдан-туры француз теленә тәрҗемә кылырдай белгечләр бездә бар, — диде.

Чехословакиядән шагыйрь Войцех Кондрат, Казагыстанның олы әдибе Морис Симашко, СССР Язучылар союзы каршындагы Тәрҗемә Совет җитәкчеләреннән берсе Элизбар Анониашвили, Белоруссиядән әдәбият галиме һәм тәрҗемәче Вячеслав Рагойша, Болгариядән тәрҗемәче Николай Аретов һәм башкалар да тәрҗемәче язучылар алдында торган зур бурычлар хакында сүз алып бардылар. Тәрҗемә офыкларын киңәйтү, арадашлыкны ныгыту юлларын бергәләп эзләргә тиешбез, дип белдерделәр. Сүриядән шагыйрь Айман Абушаар, Израилдә рус әдәбиятын еврейчага күчерүче язучы Давид Маркиш әлегә үз илләрендә совет язучылары әсәрләрен бастырып чыгару аз икәнен белдерделәр, киләчәктә бу тәҗрибәнең киңәйтеләсен әйттеләр. Шунлыктан әле ул илләрдә башлыча рус классик һәм рус совет әдәбияты гына күпләп кулланышта икән. Мәсәлән, Д. Маркиш Из-

раилдә бүген бигрәк тә Бөек Ватан сугышына багышланган әсәрләр яратып укыла, совет язучысы Александр Бекның «Волокалам шоссе»сы иврит телендә инде егерме тапкыр басылып таратылды, диде.

А. Абушаар Сүриядә СССР халыклары әдәбиятына багышлап берничә антология чыгармакчы. Икенче томга Кавказ әдәбият үрнәкләре керәчәк. Беренче, Рус әдәбияты томы инде чыккан.

Әмма, минем карашка, бу зур халыкара киңәшмәнең киң бер тармагы төрки әдәбиятларның бүгенге торышы һәм бәйләнешләре мәсьәләләрен тикшерүе белән әһәмиятле булды. Төрки әдәбиятларның бүгенге хәленә һәм үзара мөнәсәбәтләренә кагылышлы төпле фикерләрен әйтүчеләр арасында казакъ язучы һәм галимнәре өстенлек итте дисәк тә ялгыш булмас. Жумагали Смагулов, Акселеү Сәйдимбәков, Әскар Токманов, Җаппар Үмәрбәков, Фатих Фәткуллин (тумышы белән безнең якташ), Хәмзә Абдуллин һ. б. казакъ язучыларының тәрҗемә өлкәсенә караган бурычлары хакында борчылып сөйләделәр. Европа классик әдәбиятын тәгаен барлап бастырып чыгарган булсалар да, кардәш әдәбиятларның күренекле вәкилләрен тотрыклы рәвештә тәрҗемә итү, барлау булмады әле, дип пошынып сөйләделәр. Җаппар ага Үмәрбәков: «унбиш еллар элек «Жазушы» нәшрияты «Дуслык китапханәсе» һәм «Шәрек йолдызлары» серияләрен башлап җибәргән иде, әмма соңгы вакытта «Шәрек йолдызлары» сериясе тоткарланып чыга»,— диде. (Җәя эчендә шуны да искәреп китик, «Дуслык китапханәсе»ндә беренчеләрдән булып «Татар повестьлары» җыентыгы дөнья күрде, аны хуплаучыларның берсе, китапка юл ачучы да язучы һәм тәрҗемәче Җаппар ага иде). Азербайҗан шагыйре Акиф-Әхмәтов та киләчәктә төрки телле әдәбиятларны берләштерү кирәклеге, очраклы әсәрләрне түгел, гыйльми яктан уйланылган тәртиптә бер-беребезне тәрҗемә итешү юнәлешен алу кирәклеге хакында сөйләде.

— Югыйсә аяныч хәлләр туа. Казакъ әдәбиятын даими рәвештә азәрбайҗанчага тәрҗемә итеп чыгара килсәк тә, үкенечкә каршы, бездә әле Абайның юка гына җыентыгы да дөнья күрмәгән, — диде ул.

Аннары Акиф иптәш киләчәктә барлык төрки әдәбиятларның күренекле әсәрләрен туплаган уникe томлык серия чыгарылачагын белдерде.

Үзбәк язучысы Фазыл Насыйров төрки әдәбиятларның бүгенге торышын һәм проблемаларын яктыртучы уртак бер журнал кирәклеге турында, аңа «Төрекстан» дип исем бирү турында әйтте. Үз чыгышымда мин дә аның бу тәкъдимен хупладым, ул уртак журналда тәрҗемә проблемалары гына түгел, төрки телләрнең уртак һәм үзгәлекләрен чагылдырган мәкаләләр урнаштырып, гомумтөрки мәсьәләләрне дә тикшерергә мөмкин булыр иде, дип әйттем. Мин шулай ук, фәкать төрки телле әдәби тәрҗемә мәсьәләләрен тикшерү өчен якын бер арада шушы телдә нәҗат итүчеләр киңәшмәсен уздырасы иде, дип тә белдердем. Минем бу фикерне азәрбайҗанлы иптәшләр дә, үзбәк язучылары Фазыл Насыйров белән шагыйрь Мирбулат Мирзаев та хуплап чыктылар.

Казагыстанда исә бу юнәлештә дә кайбер эшләр башкарыла икән инде. Бу хакта Тәрҗемә һәм әдәби бәйләнешләр Баш редакциясенең альманах редакторы Акселеү Сәйдимбәков белән Морад Әүэзовлар сөйләделәр. Казагыстан тәрҗемәче-язучыларының бу берләшмәсе 1989 елның апрель аенда «Казакъчага тәрҗемә ихтыяҗ-проблемалары» темалары темасына багышлап бер зур киңәшмә уздырган. Шул ук елда бу киңәшмә материаллары тупланган җыентык дөнья күргән. 1989 елда шулай ук шушы Баш редакция тарафыннан оештырылган «Галәм» (казакъча язылышта «Алем») альманахы ың беренче саны басылып чыга. Киләчәктә бу альманах рус һәм казакъ телләрендә елына берничә сан булып чыгачак икән. Бу альманахны киләчәктә, әлбәттә, гомумтөрки әдәбиятлар бәгланышы матбугатына да әверелдерү мөмкиндер. Ә әлегә, минемчә, һәр республикада чыгып килүче журнал, альманахлардан тулырак файдаланырга кирәк, ул журнал битләрендә тәрҗемә ихтыяҗларын да онытмау, аларны даими барлап, күзәтеп торуны оештыру кирәк.

Алма-Атада узган халыкара конференциядән алган иң зур тойгым, төп фикерем — безгә, татар язучыларына һәм тәрҗемәчеләренә, ешрак чит дөньяларга чыгу, башка халык әдәбиятлары белән ешрак танышу һәм аралашуның бик-бик зарури икәнлеген тагын бер кат тану булды. Бүгенге дөньяда без шулай аралаша-аралаша гына үз юлыбызны, үз урыныбызны таба алачакбыз. Югыйсә бүгенге көндә Урта Идел регионында гына чикләнеп калу куркынычы, әдәбият дип йөртелгән Идел-суыбызның башка су-дәрьялар белән аралашмаган һәм кушылмаган очракта тәмам саегып калу куркынычы бар бит. Моны без онытмаска тиешбез.

Китап күзәтү

# ХӘЗИНӘЛӘР АЧКЫЧЫ

Гарәп язуы меңнән артык еллар буе безнең халкыбызга аң-белем, мәгърифәт ачкычы булып торган, мәдәниятны үстерүгә булышкан. Әнә шул әлифба нигезендә күп буыннар укырга-язарга өйрәнгән. Нәтиҗәдә милләтнең башка халыклар белән аралашуы өчен дә киң юл ачылган. Ул халкыбызның рухи үсешенә дә зур өлеш керткән, әлифба белән бергә, унынчы гасыр башында ук рәсми рәвештә ислам дине дә кабул ителгән. Бу исә халыкның борын-борыннан килгән гореф-гадәтләре, әхлакый-тәрбияви сыйфатлары тагын да үсүгә, болгар-татар һәм гарәп-иран мәдәниятләренең үзара керешеп үсүенә китергән.

Бүгенге чынбарлык, илдәге үзгәртеп корулар элекке язма мирасыбызны белүне һәм үзләштерүне дә таләп итә. Мәгълүм сәбәпләр буенча, берничә буын аны өйрәнү хокукыннан мәхрүм ителгән иде. Хәзер инде олыбыз да, кечебез дә иске әлифбаны бик кызыксынып өйрәнә башлады. Соңгы берничә ел эчендә гарәп язуындагы татарча әлифбаны үзләштерү юнәлешендә киң эш җәелеп китте. Журналларыбызда һәм телевидение аша махсус дәресләр бирелә, Татарстанда, башка өлкәләрдә аерым курслар оештырыла, үзлегеннән өйрәнүчеләр өчен кулланмалар чыга. Җ. Зәйнуллин тарафыннан киң халык даирәсенә исәп тотып, күпләп чыгарылган «Гарәп язуы нигезендә татарча әлифба» да шуның бер ачык чагылышы. (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1989).

Үзлегеннән өйрәнүчеләр өчен кулланманың кереш бүлегендә гарәп язуы, аның тарихы турында мәгълүмат бирелә, бүгенге көндә гарәп әлифбасының, милли әлифба буларак, рәсми рәвештә 22 илдә кулланылуы һәм 250 миллионнан артык кешегә хезмәт итүе турында әйтелә. Безнең тарихыбызда гарәп язуы нигезендә иске имла һәм яңа имла язып килгән. Китапта ул әлифбаларны аерып, график рәвештә күрсәтү дөрес эшләнгән. Элекке язма мирасыбызның төп өлеше иске имлада бирелгән. Октябрь революциясеннән соң яңа имла кабул ителә, кайбер үзгәрешләр керә һәм хәрефләр арттырыла. Ул озак дәвам итми, 1927 елда инде яңалифка — латинга күчү башлана.

Кулланмада хәрефләрнең төрле урыннарда: ялгыз хәлдә, сүзнең башында, уртасында, ахырында кулланылуларына карап, ни рәвешле, нинди шәкелдә язылуларына аеруча игътибар ителә. Бу тәртип һәр хәрефнең язылышын аңлатканда искә алына. Билгеле, болай кабатлап баруны кайбер иптәшләр кимчелек итеп тә кабул итәргә мөмкин.

Гарәп әлифбасында кыска сузыкларның күрсәтелмәвенә, аларны белдерүче билгеләр — хәрәкәләрне (фәтхә, дамма, кәсрә), ярдәмчел билгеләр — һәмзә, тәшдид, сәкенне аңлатуга да аерым бүлекчә багышлана. Моңа игътибарлы булу бик мөһим. Бу уңай белән шуны да искәртеп үтәсе килә: тегe яки бу әлифбаны өйрәнү андагы хәрефләрне уку-язу гына түгел, бәлки тегe яки бу күләмдә ул телне дә үзләштерү дигән сүз. Элекке татар мәдрәсәләрендә укытучылар моны бик нык искә алганнар. Анда уку-язуга өйрәнү шактый катлаулы методикага — комплекслы укытуга (берничә алымның кушылуына) корылган булган. Шәкертләр шәкли (тышкы) як, ягъни хәрефне укый-яза белү белән генә чикләнмичә, шул хәрефләр кергән гарәп сүзләрен, җөмләләрен ятлау белән дә шөгыльләнгәннәр. Бу шәкертләрнең акыл-аң үсешен, әйләнә-тирәгә карашын киңәйтүгә ярдәм иткән. Телләрне чагыштырма өйрәнү балаларда зиһенне үстерүгә һәм ихтыяр көче, тырышлык тәрбияләүгә юл ачкан. Монда, әлбәттә, таяк белән көчләп укыту турында сүз бармый. Ә без, гадәттә, элекке мәдрәсәләрне шундый итеп кенә күз алдына китерергә күнеккәнбез.

Гарәп язуында кыска сузыкларны ас һәм өс билгеләре белән күрсәтү укуда зур читенлек тә тудыра. Сүзнең мәгънәсен аңлаганда гына хәрәкәләр куелмаган текстларны дөрес укып була. Тегe яки бу күләмдә телне дә үзләштерергә кирәк, дигән фикер дә нәкъ шушы шарт белән бәйләнгән. Моның хәзер дә әһәмияте юк түгел. Китапта бу принципны сакларга тырышу уңай күренеш булып бәяләнергә хаклы.

Кояш һәм ай хәрефләрен аерып күрсәтү дә дөрес уку өчен бик зарур. Кулланмада гарәп саннарының укылышын һәм язылышын үзләштерү, саннар урынына хәрефләр куллану, гарәпчә һәм фарсыча саннарны аерып күрсәтүгә дә игътибар ителгән. Бу да мөһим мәсьәләләрдән санала. Мәсәлән, хәзерге татар әдәби телендә көн исемнәренең (шимбә, якшәмбе, дүшәмбе...) фарсыдан алынган бу-

луы, иске татар телендә ай исемнәренең (мөхәррәм, сәфәр, рәбигъ әл-әүвәл...) гарәпчә кулланылышы һ. б... Гарәп һәм иран мәдәнияты белән бәйләнешле математик-астрономик исәпләүләрне дә, ай әйләнешенә нигезләнгән һиҗри елны да ачык белергә кирәк.

Китапның кушымта өлешендә гарәпчә язуның төрләре (куфи, сөлс, нәсх, рокъгә, дивван, тәгълыйкъ) бирелә, уку һәм язу күнегүләре өчен төрле вакытларда язылган әсәрләрдән өзекләр китерелә. Ул «Кәлилә һәм Димнә» әсәреннән алынган язма һәм басма текстлардан башлана. Аннары аерым сүзләр, Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасы, Г. Кариевның «Тукай Мәкәрҗәдә» истәлеге, әкиятләр, риваятьләр, Дәрдемәнд шигырьләре, Г. Фәезханов, Ш. Камал, К. Насыйри әсәрләреннән өзекләр, публицистик мәкаләләр тәкъдим ителә. Күренә ки, әле монда хронологик яктан да, жанр ягыннан да билгеле бер эзлеклелек чагылмый. Һичшиксез, гадидән катлаулыга бару алымы яхшырак. Бу — беренче шарт. Башта аерым сүзләрне, халык авыз иҗаты әсәрләрен, аннары әдәби, публицистик әсәрләрдән алынган өзекләрне, соңыннан укырга авыррак булган борынгырак текстларны бирергә мөмкин булыр иде.

Шул рәвешчә, гарәп язуына өйрәнгәндә, хәрефләрнең тышкы ягына гына түгел, бернигадәр аларның эчке мәгънәсенә дә төшенергә, ягъни сүзләрнең мәгънәсен, эчтәлеген дә аңларга тырышырга кирәк. Татар телендә гасырлар буенча туплана килгән киң күләмдәге гарәп, фарсы катламы бар. Бу — XIX гасырга һәм XX гасырның башына кадәр үзгәрешсез килә. Ләкин Октябрь революциясеннән соң, егерменче елларда, иҗтимагый-сәяси җирлектә гарәп сүзләренә, гарәп әлифбасына каршы кискен көрәш башлана, бу үсешнең тамырына балта чабыла. Әнә шулай зур катлам тәшкил иткән гарәп сүзләрен куып, кысрыклап чыгару нәтиҗәсендә бик ерактан килгән әдәби тел традицияләре җимерелә. Хәзер төшереп калдырылган гарәп сүзләренең кайберләре инде яңадан кайта һәм телдә үзләренә кулланылыш таба башлады. Мондый сүзләргә хәзер без аеруча игътибарлы булырга, аларны арттырырга тиешбез.

Кулланма, күләме ягыннан зур булмаса да, гарәп язулы татар әлифбасын үзләштерү өчен иң зарури мәгълүматларны эченә ала. Аның миллионлаган татар халкының ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндереп бетерә алмавы турында да әйтеп үтү урынлы булыр. Киләчәктә, һичшиксез, мондый уку ярдәмлекләрен тулырак һәм зуррак итеп чыгарырга кирәк.

Хәзер югары уку йортларында гарәп, фарсы һ. б. көнчыгыш телләрен укытуны киңәйтү, ул телләрдән белгечләр әзерләү буенча махсус группалар оештыру өчен киң мөмкинлекләр ачылды. Димәк, безнең мәктәпләрдә дә көнчыгыш телләрен укытуны тормышка ашырга башларга вакыт җитте.

**Вахит ХАКОВ,**
филология фәннәре докторы.

## *Безнең календарь*

# Халикъ Садриның тууына 100 ел

Халикъ Садри (Габделхаликъ улы Садретдинов) 1890 елның 4 августында Самара губернасының Богырыслан өязе (хәзерге Куйбышев өлкәсе) Иске Ярмәк авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Бик яшьли ятим калып, чит кешеләр кулында тәрбияләнә һәм үз көнен үзе күрә башлый. Ул башта авылда, аннары Уфа, Баку, Самара, Оренбург шәһәрләрендәге предприятиеләрдә эшли, оста механик булып җитешә.

Февраль революциясе вакытында Халикъ Садри көрәш хәрәкәтенә кушыла. 1917 елның мартында аны партиягә кабул итәләр. Октябрь көннәрендә ул Самарада Совет властен урнаштыру һәм Идел буен акгвардиячеләрдән азат итү өчен көрәшә. Аннан соң партиянең Самара губерна комитетында татар-башкорт секциясе рәисе булып эшли. 1925 елда Халикъ Садри Казанга килә һәм татар коммунистлары университетында укый, аннары «Спартак» фабрикасында җитәкче урыннар били. Уйлап табу һәм рационализаторлык буенча да нәтиҗәле эшли.

Бөек Ватан сугышы елларында Халикъ Садри полк комиссары буларак фронтның алгы сызыгында сугыша, яралана. Шәхси батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз һәм башка сугышчан орденнар белән бүләкләнә.

Әдәби иҗат эшен Халикъ Садри Октябрь революциясенә кадәр үк башлый. 1913 елда Уфада аның «Тегермәндә» исемле беренче хикәясе басылып чыга. Утызынчы елларда исә ул үзенең төп әсәрләрен: «Ил батырлары», «Тимерче малае» һәм «Безнең таң» повестьларын яза. Сугыштан соң «Йөзмә госпитальдә» һәм «Юллар» дигән әсәрләр иҗат итә.

Г. Халикъ Садри 1955 елның 8 мартында Казанда вафат булды.

**Гомәр Саттаров,**

филология фәннәре докторы, профессор

# ИСЕМНӘР ЙОЛДЫЗЛЫГЫ

Көнчыгыш халыкларының күпчелегендә, шул исәптән татарларда да, әдәбият, мәдәният һәм фән эшлеклеләре үзләренең тәхәллүс-фамилияләре итеп, фарсы изафәсе формасы -И-, -ЫЙ- кушымчасын ялгап, туган авыллары һәм шәһәрләренең исемнәрен алганнар: Ә. Рудәки (IX йөз), М. Кашгари (XI йөз), Сәиф Сараи (XIV йөз), М. Болгари (XIV йөз), Юныс Оруви (XVII йөз), Г. Утыз-Имәни (XVIII йөз), Г. Курсави (XIX йөз), Ш. Мәрҗани (XIX йөз), Г. Кандалый (XIX йөз), Г. Чокрый (XIX йөз) һ. б. Байтак кына әдип һәм галимнәребезнең нисби фамилияләре әтисе яки бабасы исеменә нигезләнеп ясалган: (XVI йөз), Каюм Насыйри (1825—1902), Габдрахман Ильяси (1856—1896), Фатих Халиди (1850—1923), Мәҗит Гафури (1880—1934) һ. б.

Урта гасырларда кайбер укымышлылар һәм әдипләрнең үз исеме белән янәшә әтисе яки бабасы исемен, бернинди кушымча алмаган килеш, фамилия-патроним итеп кулланулары да очрый: Мәхмүт Мөхәммәдьяр (XVI йөз), Хаҗимөхетдин Мөхәммәт (XVI йөзнең беренче яртысы), Кадыйр Галибәк (XVI йөзнең икенче яртысы), Таҗетдин Ялчыгол (1768—1838) һ. б.

Ә инде соңга таба мәдәният эшлеклеләре татар телендәге **-лы**, **-ле** һәм рус теленнән алынган **-ский**, **-ская** аффиксларының топонимнарга кушу юлы белән туган җирләрен, күрсәтә торган тәхәллусфамилияләр ясау дәвам иттерелде: М. Сөндекле, Ф. Сәйфи-Уфалы, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Иделле, Р. Җамаваклы, С. Урайский, Г. Толымбайский, И. Кудашев-Ашказарский, Г. Кайбицкая, Г. Болгарская, Г. Камская һ. б.

XIX йөз башларыннан алып татар әдипләре арасында фамилия функциясендә үз исеменнән соң әтисе яки бабасы исемен куллану шактый киң урын ала: Ш. Зәки (1825—1865), З. Һади (1863—1933), Г. Тукай (1886—1913), Ф. Әмирхан (1886—1926), Г. Камал (1879—1933), Ш. Камал (1884—1942) һ. б.

Патронимик фамилияләр куллану Көнбатыш һәм Көнчыгыш язучылары арасында шулай ук киң таралышка ия: Андре Стиль, Ромен Роллан, Вильям Шекспир, Гафур Голям, Фәез Әхмәт Фәез, Сөләйман Рөстәм, Әхмәт Габбас һ. б. Татар әдипләреннән Муса Акъегетзадә үзенең патронимик фамилиясен таҗик-фарсы телләрендә «улы» төшенчәсендә йөрүче **задә** сүзен куллану юлы белән ясаган.

Татар телендәге исем-фамилияләрне дөрес әйтү, язу һәм транскрипцияләү мәсьәләләре кичектергесез рәвештә махсус фәнни тикшеренүләр алып баруны сорый. Билгеле, болар язучыларыбызның исем-фамилияләренә дә кагылалар. «Борынгы татар әдәбияты» (Казан, 1963) китабында (74 б.) «Йосыф вә Зөләйха» поэмасы авторының үзен бер урында Гали, икенче җирдә Кол Гали дип атавы әйтелә. Әдәбиятыбызда һәм матбугатта аның исемен Кол Гали дип язу кабул ителгән. Татарстан китап нәшрияты 1983 елда чыгарган «Кыйссаи Йосыф» китабында да автор Кол Гали рәвешле бирелгән. Болай язганда Кол шагыйрьнең исеме, ә Гали фамилиясе булып аңлашыла һәм укучы аны шулай кабул итә дә. Безнеңчә, шагыйрьнең исемен Колгали дип кушып әйтү һәм язу, ягъни аны кушма төзелешле кеше исеме итеп кабул итү һәм куллану дөресрәк булачак.

Инде танылган берничә әдибебезнең исем-фамилиясе һәм туган авылы атамасының этимологиясен ачыклауга күчик. Иң элек татар поэзиясе күгенең иң якты йолдызлары, фамилияләре «Т» авазына (хәрефенә) башлана торган атаклы өч шагыйрьгә — Г. Тукай, Һ. Такташ һәм Х. Туфанга тукталыйк.

Х. Зәбиров (Г. Тукайның анасы Газизә Зәбирова улы — Г. С.) «Тукай — шагыйрьнең фамилиясеме, псевдонимымы?» дигән мәкаләсендә («Казан утлары», 12 сан, 1981, 177 б.) Г. Тукайның нәсел шәҗәрәсен китерә: «Габдулла Мөхәммәттариф Мөхәммәтгалим Шәмсетдин Мортаза Тутулы». Шуннан килеп чыккан «Тукай»,— дип яза.

Борынгы заманнарда төрки халыкларда тәңредән бала сорау-үтенү йоласына (бала

келәве) нисбәтле рәвештә турыдан-туры теләк-боерыкны белдерә торган **ту (ту) сүзләренә** (теләк һәм боерык фигыльләренә) нигезләнеп байтак кына кеше **исемнәре ясалган**. **Ту (ту)** теләү-боеру фигыле катнашып: Тубай, Байту-Байту (**Байтуков фамилиясендә** сакланган), Тубәк, Тубикә, Тухан-Тукан, Туиш (татар-мишәрләрдә **Туишев фамилиясендә** сакланган. Туиш — соңгы елларда Кукмара эшчеләр **поселогы составына кушылган** татар авылы атамасы), Тугаш, Тугуш (татар-мишәрләрдә **Тугашев, Тугишев, Тугушев** фамилияләрендә сакланган), Исәнту-Исәнту, Тубота (**ту + бота — «дөя баласы»**), Тутулы һ. б. исемнәр барлыкка килгән.

Тутулы, ягъни «тулы булып ту; бөтен әгъзалары исән-сау, бар булган **килеш ту»** дигән теләк-йолага нисбәтле кеше исеме электә татарларда да кулланылышта **йөргән**. Татарстанның Зеленодольск районы Мулла иле авылындагы «Туту» **дигән нәсел-ыру** кушаматы шул Тутулы исеменең кыскартылган (соңгы **лы** иҗеге **кулланылыштан төшкән**) варианты булса кирәк.

Х. Зәбиров Тутулы исеменнән «Тукай» килеп чыккан, ягъни бу исем Тукайга әверелгән дип саный. Тутулы исеме Тукайга ничек әверелгән? Автор бу хакта сүз алып бармый.

Язучы Йосыф Гәрәй Тукай исеменең килеп чыгышын **туганкай** сүзенә бәйләп, «бик якын, үтә газиз» мәгънәсенә ия дип аңлата[1].

Таҗик антропонимисты Алим Гафуров, күпчелек төрки телләрдәге **Тогай, Тугай**, Токай, татарлардагы Тукай исеме «әрәмәлек, елганың язын су баса торган **дуга сыман** бормалы урынында (чаг.: монгол телендә **тукай** — «җәя», «салават күпере», **«ягъни дугасыман** бөгелгән әйбер) үсүче урман» төшенчәсен белдерә торган **тогай-тугай** (рус теленә күплек санында **туган** рәвешле кабул ителгән географик терминына **нисбәтле рәвештә** ясалган булса **кирәк** дип фараз итә[2].

Себер татарлары Туктасын, Туктаргали исемнәрен кыскартып, **җанлы сөйләм телендә** Тукай рәвешле кулланалар. «Риваятьләргә караганда, Габдулла **Тукайның ерак** бабаларыннан берсе Туктаргали исемле булган, аны, тулы исемен кыскартып, **Тукай** дип йөрткәннәр»[3],— дип яза профессор И. Нуруллин.

Безнең карашыбызча, Тукай исеме **ту**: а) «Дөньяга кил, пәйда бул, ту»; б) «**байрак**, әләм, яшәү, тереклек билгесе, символы» сүзенә **-кай** иркәләү-кечертәйтү кушымчасы кушылып яки **тук**: а) «ризык-нигъмәткә, аш-суга тук булу, бай-мөлкәтле, **тук тормышлы** булу»; б) «тулы, таза, төгәл-камил, исән-сау» сүзенә **-ай антропонимик атау-эндәшүбоеру** кушымчасы ялганып ясалган исем (чаг.: **тук** сүзенә, **-ан** антропонимик атау-эндәшү кушымчасы ялганып Тукан; **-ач** кушымчасы кушылып, Тукач; **-аш** кушымчасы ялганып, Тукаш исемнәре барлыкка килгән.

Баланың туганда физик (физиологик) яктан ничек тууы, бөтен әгъзалары **төгәл-төзек**, тулы-ким яки артык хәлдә, үзенең таза яки ябык, зур яки кечкенә **булып тууы** төрки халыкларының антропонимик системасында балага исем кушуда **мөһим бер мотив** булып саналган.

Татарларда баланың туганда барлык әгъзасының да төгәл-төзек, **тулы-камил булуы** антропонимик синонимик рәт барлыкка китерүче **төгәл, төз** (төзек), **тулы, тук сүзләре** (антрополексемалары) катнашып ясалган исемнәр белән белдерелгән: **Төгәлбай** — «төгәл бай», ягъни «барлык әгъзасы исән-имин ир бала» (Татарстанның **Әлки** районында Татар Төгәлбае һәм Рус Төгәлбае дигән авыллар бар), Төгәлбота — **төгәл + + бота** «дөя баласы», Төгәлбуга — **төгәл + буга** «үгез» Төзбай — «төз, тулы, **барлык әгъзасы** да бар бай, ягъни ир бала», Төзбәк (бу исемнәр татар-мишәрләрдә **Төзбаев, Тузбаев**, Төзбәков, Тузбеков фамилияләрендә сакланганнар). Тукбай (тук, тулы **бөтенесе җитеш** бай (ир бала), **Тукчура**, Тукшаһ, Тукшәех (диалекталь вариантлары **Тукшәй, Тукшай**, Тукши), Тукхан, Тугай-Тогай-Тукай — «тук, таза, тулы-камил» яки «**тук, таза, тулы-камил** бул!» һ. б. — ир-ат исемнәре; Төгәлбикә, Төзбикә, **Тукбикә, Туксылу** һ. б.— хатын-кыз исемнәре.

А. Гафуров та Мәскәүдә 1987 елда чыккан «Имя и история» **дигән китабында**: «Тукай яки Токай исеме **тукай** «канәгать, мохтаҗ түгел» сүзеннән килеп **чыкса кирәк**. Гомумән, **тук-ток** тамыры «туенган, көр; юан, калын», «ләззәт, рәхәт, хозур, **юаныч**» мәгънәләрен белдерә, ә **тукай** шушы нигездән ясалган хәл фигыль»[4],— дип яза. Без бу фикерне моннан ун ел элек үк дөнья күргән «Татар исемнәре сүзлеге» (Казан, 1981) **дигән** китабыбызда әйткән идек инде.

Урта гасырларда (Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында) То ай, **Тугай, Тукай** исемнәренең кулланылышта актив булуы тарихи чыганаклар **буенча мәгълүм**.

---

[1] Гәрәй Й. Бик һүзләр кайдан килә?— Өфө, 1971, 113 б.

[2] Гафуров А. Имя и история.— М., 1987, 27 б.

[3] Нуруллин И. Тукай.— М., 1977, 8 б.

[4] Гафуров А. Күрсәтелгән хезмәт, 29 б.

Югарыда сөйләгәннәр яктылыгында, әдәбият галиме һәм язучы М. Мәһдиевнең «Тукай» сүзенең мәгънәсен, бәлки гарәп-фарсы сүзләреннән чыгып эзләргә кирәктер»,— дип язуының чынбарлыкка туры килмәве ачыклана. (Казан утлары.— 1973.— 12 сан.—181 б).

Габдулла Тукай республикабызның Арча районы Кушлавыч авылында туган. Кушлавыч авылының Красна елгасы бассейнындагы Кушлавыч елгасы исеменнән (гидронимнан) алынган. Бу елгага исә, үзе кушыла, агып төшә торган елганы кушлаучы, куш-пар итүче елга булганга, әлеге исем кушылган. Чаг.: Куштармак елгасы — Шушма елгасы бассейны (Арча районы). Куш елга — Мәтәскә суы бассейны (Түбән Мәтәскә авылы, Саба районы), Кушчишмә, Кушкүл һ. б.

Казан артының Алат юлындагы Кушлавыч авылының Казан ханлыгы чорында булуы мәгълүм. Бу вакытта Тау ягында да Кушлаучы һәм Чуртанлы елгалары арасындагы җиргә утырган Зур Кушлавыч һәм Кече Кушлавыч исемен йөртүче авыллар булган[5].

Биредә шунсын әйтеп китү дә урынсыз булмас. Борынгы һәм иске татар телендә **иш** сүзенең синонимы **куш** сүзе (бу сүз «пар, ике; икесе бергә булган», күчерелмә мәгънәдә «әтисен кушлаучы, куш, пар, иш итүче өлкән (беренче) ир бала» төшенчәсен белдерә) катнашып байтак кына кеше исемнәре барлыкка килгән. Кушай, Кушбай, Кушбакты, Кушбәк, Кушкара, Кушбарс, Куштимер, Кушбирде, Кушбатыр, Кушбүләк, Куштирәк, Куштамак («**куш тамак**», ягъни «ике тамаклы (иякле)». Бик таза (ике иякле) булып туган ир балаларга кушылган. Е. Пугачев җитәкчелегендәге крестьян сугышы белән бәйләнешле документларда Куштамак Кушбакты углы исеме бар.

Габдулла Тукайның Сәгъди абзыйларда ваемсыз балалык еллары узган хозур табигатьле Яңа Кырлай авылы (хәзерге Тукай-Кырлай авылы) атамасының килеп чыгышы да игътибарга лаек.

Казан артында Алат юлы өстендә Иске Кырлый һәм Яңа Кырлай авылларының Казан ханлыгы чорында булулары тарихи чыганаклар буенча мәгълүм[6]. Бу авылларның атамасы борынгы төрки-татар чыгышлы Кырлачай Кырлай исеменә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән. Кырлачай, Кырлай, Кырлач исемнәре исә **кырлач ай** кырлай «салкын ай» дигән мәгънәгә ия. **Кырлач** — кышның иң салкын вакыты, **олы кырлач** — январь аена, **кече кырлач** — февраль аена туры килә. **Кырлач** сүзенең борынгы «календарь» мәгънәсе кайбер төрки халыклар телендә хәзергәчә сакланып калган. Чулым татарларында **кырлач ай** — «буранлы ай», караимнарда **улу кырлаш** — «каты салкын», ә **кичи кырлаш** — «көчсез салкын». Идел-Кама болгарларында һәм аларның варислары казан татарларында кышның иң салкын аенда туган ир балаларга Кырлачай Кырлай дип исем кушу гадәте (чаг.: руслар салкыннарда туган ир балага Мороз исемен биргәннәр) булган.

Атаклы татар совет шагыйре Һади Такташ фамилиясенең асылында Такташ дигән борынгы төрки-татар исеме ята. Борынгы төрки телдә **такташ** сүзе «кыя ташы, гранит» төшенчәсен белдергән.

Борынгы заманнарда дөньяга яңа туган балага ни өчен «ташлы» исемнәр кушканнар соң? Моның асылында нинди йола-мотив ята?

Ерак мәҗүси заманнарда төрки халыклар, шул исәптән болгар-татарлар, төрле минерал (**таш, чакматаш, чуерташ, такташ** — «гранит», **агат** һ. б.) һәм металларны (тимер, корыч, булат, бакыр, җиз һ. б.) илаһи көчкә ия дип санаганнар, аларны изгеләштергәннәр. Металл, минераллар, алардан ясалган тормыш-көнкүреш әйберләре һәм сугыш кораллары (мәсәлән, **балта, ат дагасы, кылыч, сөнге, ук, урак, кусар, чүкеш, хәнҗәр** һ. б.) усал көчләрне куркыта, аларны кешегә якын җибәрми, дип ышанганнар. Шушы җирлектә усал көчләр бала янына килмәсен, бала авыруларга бирешмәсен, сәламәт, таза-нык булып үссен дигән теләктән чыгып, каты, нык минерал һәм металл исемнәре, алардан ясалган әйбер атамаларын балага исем итеп кую йоласы барлыкка килгән.

Шушы йола белән бәйләнешле рәвештә, каты, нык минерал таш һәм аның төрләре (**чакматаш, такташ, акташ** һ. б.) атамасын кеше исеме итеп бирү һәм составларында әлеге минерал (**таш**) атамасы булган кушма төзелешле исемнәр кушу татарларда һәм башка төрки халыкларда киң таралышка һәм кулланылышка ия булган. «Ташлы» исемнәребезгә Таш (шуннан Ташев фамилиясе), Ташбай, Ташбулат, Ташбакты, Асылташ, Гәүһәрташ, Ташбикә (соңгы өчесе хатын-кыз исеме), Ташбәк, Ташкай, Ташморза, Ташмөхәммәт, Ташхуҗа, Таштимер, Тимерташ, Такташ («гранит»), Акташ, Бикташ,

---

[5] Чернышев Е. И. Селения Казанского ханства /по писцовым книгам // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья.— Казань, 1971. 286, 290 бб.

[6] Чернышев Е. И. Күрсәтелгән хезмәт. 286 б.

Күкташ, Ташкисәр, Ташкал («таш миң»; тәнендә таш кебек каты миңе (калы) булган ир балага кушылган; себер татарларында Ташкалов фамилиясендә сакланган), Ташкол, Таңташ (татар-мишәрләрдә Таңташев, Танташев фамилияләрендә сакланган), Чуерташ, Чынташ һ. б. мисал итеп китерә алабыз.

Идел-Кама болгарлары телендә «таш» төшенчәсенең белдерү өчен **чал** сүзе йөргән. Төрки телләрнең кыпчак группасында әлеге төшенчәне белдерү өчен **таш** сүзе кулланыла. Үзара синонимдаш **чал** һәм **таш** сүзләренең (антрополексемаларының) төрки телләрдә кушма төзелешле кеше исемнәрен ясауда актив кулланыла торган **бай, бәй, булат, бакты, мөхәммәт** һ. б. исем компонентлары белән кушылуы нигезендә болгар-татарларда Чалбай-Ташбай, Чалбәк-Ташбәк, Чалбулат-Ташбулат, Чаллы-Ташлы, Чалкай-Ташкай, Чалмөхәммәт-Ташмөхәммәт, Чалбакты-Ташбакты һ. б. кебек мәгънәдәш исемнәр барлыкка килгән. «Таштугай» мәгънәсенә ия булган Чалтугай исемен исә болгар бабаларыбыз күчмә яки ярымкүчмә тормыш белән яшәгәндә, ташлы (ягъни болгарча **чаллы**) тугайда туган ир балаларга кушканнар.

Һади Такташ, белгәнебезчә, 1901 елның 1 январенда элекке Тамбов губернасы Спас өязе (хәзерге Мордва АССРның Торбеево районы) Сыркыды авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Шагыйрьнең туган авылы Сыркыды атамасының килеп чыгышы иске татар телендәге **сарку-сырку** (диал. сыркыды) гидрографик терминына нисбәтле. **Сарку-сырку** гидрографик термины белән җир астыннан аз-азлап кына саркып чыгып торган чишмә күзе, аз сулы кечкенә чишмә-инеш, су чыганагы белдерелгән. Төрдәшләре **саркыды-сыркыды**, ягъни җир астыннан саркып кына чыгып агучы аз сулы чишмә. Шушы гидрографик терминнарга нигезләнеп, Казан ханлыгы чорында булуы тарихи чыганаклар буенча билгеле Сарку-Кадыш дигән татар авылы (бу авыл Нугай юлындагы Чырпы елгачыгы буенда булган)[7] һәм Һ. Такташның туган авылы Сыркыды дигән татар авылы исеме ясалган.

Татар совет поэзиясенең классик шагыйре Хәсән Туфанның әдәби фамилиясе (псевдонимы) бөтен дөньяны су басу риваятендә «көчле ташкын, көчле яңгыр, давыл, ураган» төшенчәсен белдерә торган мифологик термин **туфан** сүзеннән алынган. Хәсән Туфанның чын фамилиясе Гөлзизин була. Чөнки патша хөкүмәтенең карары нигезендә чукындырылган регионнарда өйләнүче татарларның никахы чиркәүдә үткәрелмәсә, аларның балалары законсыз туган булып исәпләнгән һәм фамилияләре ана исеме белән кушылган.

Проф. Хатип Госман болай дип яза: «Туфан... Казан губернасының (хәзерге Октябрь районы) Кармәт авылында әнкәсенең соңгы унынчы баласы буларак, 1900 елның 9 декабрендә дөньяга килә[8]...

1905 ел революциясенә кадәр Хәсән һәм аның туганнары әнкәләре Гөлзизә исеме буенча бирелгән Гөлзизин фамилиясе белән яшәргә мәҗбүр ителгән булганнар. Ә инде шагыйрь булып, әсәрләрен бастыра башлагач, Хәсән әдәби имзасын бабасы Фәхретдиннең кушаматы «Дуфан»нан «Туфан» дип ала»[9]. Туфан әдәби фамилиясе тәэсирендә Туфан исеме утызынчы еллардан башлап ир балаларга кушыла башлады (мәс., Туфан Миңнуллин — күренекле татар совет драматургы исеме һ. б.)

Егерменче-утызынчы еллар совет татар әдәбияты үсешенә зур өлеш керткән күренекле драматург, шагыйрь, публицист, әдәбият тәнкыйтьчесе һәм тәрҗемәче Фәтхи Бурнашның әдәби фамилиясе Бурнаш (тулы фамилиясе Бурнашев) борынгы төрки-татар чыгышлы Бурнаш (Борнаш) исеменә нигезләнеп барлыкка килгән.

Бурнаш (Борнаш) исеменең килеп чыгышын берничә төрле карап була: 1) татар теленең көнбатыш диалектында **борнаш** — борнау, борынлау, шытып, тишелеп чыгу (татар әдәби телендә **борнау-борынлау**: а) шытым җибәрү, үренте чыгару; б) томшыгы белән күкәй кабыгын тишү; в) күч. барлыкка килү, туу). 1841—1845 елларда Саратов духовный семинариясендә укыганда Н. Г. Чернышевский татар телен һәм топонимиясен өйрәнү белән шөгыльләнгән. Ул Саратов губернасындагы татар авыллары исемнәренең килеп чыгышы турындагы кулъязма хезмәтендә (СССР Үзәк Дәүләт Әдәбият Архивы, 1 ф., 2 эш) Бурнашевка авылы атамасын **борнаш** — борынлау «пускающий ростки» сүзенә бәйләп аңлата; 2) бу исем **борыны аш**, ягъни «борыны аш-сулы булсын, ризыгы киң, мул булсын» дигән сүз тезмәсенә нисбәтле теләк-йола исеме буларак барлыкка килүе дә бик мөмкин; 3) **борыны ач,** ягъни «ач (юка) борынлы»[10]; 4) **бурнаш** —

---

[7] Чернышев Е. И. Күрсәтелгән хезмәт. 288 б.

[8] «Совет Татарстаны язучылары» биобиблиографик белешмәсендә (Казан, 1986, 454 б.): «...Элекке Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волосте (хәзерге Татарстан АССРның Аксубай районы) Иске Кәрмәт авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә сигезенче бала булып дөньяга килә»— диелә.

[9] Хәсән Туфан. Сайланма әсәрләр — Казан, 1964, 5—6 бб.

[10] Баскаков Н. А. Русские фамилии тюркского происхождения.— М., 1979, 166 б.

«кәпрәйгән, масайган; типтереп яшәүче тол ир»[11]; 5) ашыгучы: куып узучы[12]; 5) татар теле һәм рус теле сөйләшләрендә **борнаш** һәм **борнай** сүзләре «борынын күтәргән, масайган, кәперәйгән; сөйләшмәүчән, төмсә» мәгънәләрен белдерә; 6) болгар-татар чыгышлы Борындык исеменең фонетик-морфологик үзгәреш кичергән тәрдәше булып та Борнаш әйтелеше ясала ала.

Урта гасырларда Бурнаш (Борнаш) исеменең татарларда кулланылышта актив йөрүче тарихи чыганаклар буенча мәгълүм[13]. Татарстанның Апас районында Борнаш дигән татар, Чистай районында рус авылы бар. Казан ханлыгы чорында Арча һәм Нугай юлларында Борнаш исемле татар авыллары булган.[14] Татар-мишәрләрдә һәм русларда Бурнашев фамилиясе шактый киң таралышка ия.

Күренекле татар совет язучысы Гадел Кутуйның әдәби фамилиясенең (тулы исем-фамилиясе Гаделша Кутуев) асылында Котай (татар-мишәрләрдә Кутуй) дигән борынгы төрки-татар кеше исеме ята.

Беренче мәгънәсе борынгы төрки телдә «җан» төшенчәсен белдергән **кот** сүзенә нигезләнеп татар телендә байтак кына сүзләр, тәгъбирләр һәм кеше исемнәре барлыкка килгән. Күренекле эпиграфист Һ. В. Юсупов татарларның исламга кадәр җан турындагы карашлары патриархатлык чоры мифологиясе тудырган илаһи тереклек көче «кот»та гәүдәләнеш тапкан, дип карый.[15] Кот кешене ташласа, аның тәненнән аерылса, кеше үлә, ә тәннән очып чыккан «кот» үлемсез, мәңге яши, дип ышанган борынгылар.

Борынгы төрки телдә үк **кот** сүзе, «җан» төшенчәсе белән бергә, «бәхет», «шатлык» төшенчәләрен дә белдергән. **Кот** («җан») бәхет, шатлык, байлык итеп танылган, шулар белән тиңләштерелгән. Төрки каганатта Улуг кот — «Зур бәхет», «Зур шатлык» дигән титул булган.[16] «Кутаду белиг» («Бәхетле булу турындагы фән») исемле борынгы төрки китап барлыгын беләбез. Татар телендә **кот** сүзенә **-лы** кушымчасы ялганып, **котлы** («бәхетле») дигән сыйфат сүз ясалган. Котлы («бәхетле») сүзенең дә «җанлы» төшенчәсенә якынлыгы яхшы сиземләнә. Котлының антонимнары **котсыз** да ул аерата калку төсмер ала. **Котсыз** — җансыз, ямьсез, матур түгел (мәсәлән, **котсыз кеше, котсызга кот кунмас, умартасында корт тормас — мәкаль һ. б.**). Җансыз, үле кешенең матур, ямьле булмавы бик табигый. Котсыз сүзенең беренчел мәгънәсе үлгән кеше, җансыз кеше төшенчәсе белән бәйләнешле булса кирәк.

Җан-тереклек, исән-иминлек, яхшылык, бәхет-шатлык, байлык теләү белән бәйләнешле рәвештә, **кот** «җан» һәм **котлы** «бәхетле» сүзләре катнашып, борынгы төрки һәм иске татар телендә Кутлуг, Кутлуг тимер, Котби (**кот** — «җан» һәм **би** — «князь» сүзләре кушылып ясалган исем. Котби 1342 елда атаклы «Хөсрәү вә Ширин» поэмасын иҗат иткән төрки шагыйрь), Котлыбәк, Котлыбикә, Котлыбарс, Котлыюл, Юлкотлы, Котлыкач, Котлычура, Котлызаман, Котлыбай, Котлыгъяр, Котлыбура, Котлыбөкәш, Котлыәхмәт, Котчы (казан татарларында Кутчин, Кутсин фамилияләрендә сакланган), Котлы (Котлин, Кутлин фамилияләре шушы исемнән ясалган), Котлыказан (баланың бәхетле һәм мул ризыклы, аш-сулы булуын теләп кушылган исем), Котлыиш, Ишкотлы, Коттумак, Котаймас («җан таймас, качмас», ягъни «озак яшәр ир бала»), Котлынйса, Котлыбикәч, Котлыҗан, Котык (Котыков, Кутуков фамилияләрендә сакланган. Кутуков фамилиясе русларда да бар), Котый (**кот** — «җан» + -ый — атау-эндәшү кушымчасы. Казан татарларында Котыев, Кутыев, Котаев, Кутаев, татар-мишәрләрдә Кутуев фамилияләрендә сакланган. Кутыев фамилиясе русларда да бар) һ. б.

Күренекле шагыйребез Шәехзадә Бабич фамилиясенең асылында «ир бала», угыл» мәгънәсенә ия булган туганлык терминыннан ясалган борынгы төрки Бәбәч исеме ята. Башкорт теле сөйләшләрендә **бәпәс** — «ир бала, угыл», татар теленең минзәлә сөйләшендә **бәбәч** — «кечкенә бала». Казан татарларында Бабичев фамилиясе сирәк булса да очрый. Мәсәлән, Казан шәһәренең 1915 елда чыгарылган адрес-календарендә әлеге фамилия бар. Татарстанның Тәтеш районы Олы Тархан авылында берничә гаилә шушы фамилияне йөртә. Бабич, Бабичев фамилиясе русларда да бар.[17]

Күренекле әдип-прозаик Әмирхан Еники (Еникиев) фамилиясенең асылында татар теленең төмән (БАССРда яшәүче татар-мишәрләр) сөйләшендәге **йәни** (фарсыча «җани» сүзеннән) сүзенә **-кәй** иркәләү-кечерәйтү кушымчасы кушылып ясалган Йәни-

---

[11] Селищев А. М. Происхождение русских фамилий, личных имен и прозвищ // Ученые записки МГУ «Труды кафедры русского языка», вып. 128. М., 1948. 137-141 бб.

[12] Радлов В. В. Опыт словаря тюркских наречий, т. IV, ч. 2. — СПб. 1911. 1830 б.

[13] Писцовая книга Казанского уезда 1602-1603 годов. — Казань, 1978. 208 б.

[14] Чернышев Е. И. Күрсәтелгән хезмәт. 285 б.

[15] Татары Среднего Поволжья и Приуралья. — М., 1967. 344 б.

[16] Малов С. Е. Памятники древнетюркской письменности. — М. — Л., 418 б.

[17] Веселовский С. Б. Ономастикон. — М., 1974. 18 б.

кәй-Еникәй-Еники исеме ята. Бу исем XVI-XVIII йөзләрдә шактый актив кулланылышка ия булган. XVII йөз башында Казан арты җирлегендә дә Еникей исеменең кулланылышта йөрүе тарихи чыганаклар буенча мәгълүм.[18] Шул исемнән ясалган Еникеев, Енакиев фамилиясе татарларда шактый киң таралышка ия. Еникеев фамилиясе русларда да бар.

Әмирхан Еники үзенең нәсел-нәсәбе, Еникеев фамилиясенең каян чыкканлыгы һәм борынгылыгы турында «Соңгы китап. Истәлекләр» (Казан, 1987, 9-10 бб.), дигән әсәрендә түбәндәгечә яза:

«Инде минем үз нәселемә күчик булмаса, ягъни Еникеевлар каян чыккан, кемнән башланган алар?

Кайчандыр, ерак заманда бу җирләрдә Бихан исемле бер князь (бәк) яшәгән. Шушы Биханның тора-бара Кугушев, Акчурин, Кутуев, Муратов фамилияләре үрчеп, тармакланып чыккан. Ә Кугушевлардан берсенең исеме Күлдәш булган. Күлдәштән исә Еникей туган. Димәк, болай була: Бихан, берничә буын аша Күлдәш, аңардан Еникей... Бу Еникейдән тагын биш ир бала туган: Алакай, Идей, Терегол, Усангали, Иртуган. Башкортстандагы күчеп килгән безнең бабайлар менә шул Идей белән Тереголның дәвамы икән. Фамилияләре исә Күлдәш улы Еникейдән башланып китә. Шуннан соң инде ул үзгәрмичә буыннан-буынга күчеп килә. Тора-бара Еникеевләрдән Терегулов фамилиясе аерылып чыга. (Югарыда Идей белән Тереголның бертуган икәнен күрдек). Каргалы халкының да күпчелеге Еникеевләр белән Терегуловлар, һәм алар чынлап та үзара туганлык җепләре белән бик нык бәйләнеп, чуалып беткәннәр. Күрәсез, бу ике фамилия бик борыннан килә, шуңа күрә аларның күп таралуы гаҗәп тә түгел».

Шагыйрь Әхмәт Ерикәй (Ерикиев) фамилиясенең килеп чыгышы фарсы-таҗик теленнән кергән **ери (яри** — «дус, дуси, дустанә») сүзенә **-кәй** иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган Ерикәй исеменә нисбәтле.

Татар совет драматургиясенең классигы күренекле артист һәм режиссер Кәрим Тинчурин фамилиясенең асылында борынгы төрки-татар Тиңчура исеме ята. Бу исем **тиң** һәм **чура** компонентларыннан гыйбарәт кушма тезелеш тәшкил итә. **Тиң** сүзе — «тиң, иш, бәрабәр, шундый ук; күңелгә хуш килгән» мәгънәләренә ия булган исем компоненты. Иске татар телендә **чура** сүзе дә «ир бала; хезмәтче, игенче, крестьян, крепостной; батыр; батыр сугышчы; дружина члены; дус» мәгънәләренә ия булган хәлдә, ир-ат исемнәре ясауда актив кулланылган антрополексема. Мәсәлән, Тиңбай, Тиңбак, Тиңбакты, Тиңбәк (төрдәше Тимбик, шуннан язучы Кояш Тимбикова фамилиясе ясалган), Тиңкилде, Тиңбулат, Тиңкәй, Тиңморза, Тиңтуган, Тиңкуәт, Тиңхан (диалекталь вариантлары Тимкан, Тимган, Тимхан), Тиңчура; Байчура, Чурабай, Акчура, Аичура, Карачура, Ханчура, Колчура, Ишчура, Илчура, Чынчура, Чурабтыр, Чураман, Чурачык, Чураморза, Чурахан, Чурагол һ. б.

Тиңчура исеме «тиң, иш ир бала, игенче, хезмәтче» яки «тиң, иш батыр сугышчы» дигән мәгънә белдерә. Шушы исемнән ясалган Тинчурин, Тинчуров, Тинчеров фамилияләре татар-мишәрләрдә байтак.

Бертуганнар шагыйрь һәм драматург Илдар Юзеев, тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме Нил Юзеевләр фамилиясенең асылында Йөзәй (Йүзәй-Йүзи) дигән борынгы төрки-татар кеше исеме ята. Бу исем «йөзгә җит, озак яшә; ишәй, күбәй» яки «йөзе ай; бик чибәр, ай йөзле» дигән мәгънә белдерә. Шушы исемнән казан татарларында һәм татар-типтәрләрдә Юзаев, Юзиев, Юзеев фамилияләре барлыкка килгән.

Танылган татар совет язучысы Афзал Шамов һәм күренекле сәхнә остасы, СССР халык артисты, язучы һәм тәрҗемәче Габдулла Шамуков фамилияләренең чыгышы татарларга гарәпләрдән кергән Шәмсетдин («диннең кояшы») исеменә мөнәсәбәтле.

Татар теле сөйләшләрендә Шәмсетдин исеменең күп кенә фамильяр һәм диалекталь вариантлары барлыкка килгән: Шәм, Шәми, Шәмси, Шәмсүк, Шәмәй, Шәмкәй, Шәмүк, Шәмәки һ. б. Болардан Шамов, Шамуков, Шамин, Шәмсиев, Шәмсин, Шамсуков, Шәмиев, Шамиев, Шәмкәев, Шамкаев, Шамкин, Шәмәков, Шамаков, Шәмәкиев-Шамакиев фамилияләре ясалган.

Байтак кына әдипләребезнең фамилияләре әтисе яки бабасы исеменең фонетик тартылыш кичереп, кыскарып барлыкка килгән беренче өлешенә **-ый, -и, -әй** яки **-ау, -әү**, атау-эндәшү кушымчасы кушылып ясалган: К. Нәҗми, Д. Фәтхи, Г. Шәрәфи, С. Сүнчәләй (Сөенечгалидән), Ф. Хөсни, Х. Ярми, Н. Дәүли, Г. Гобәй, Х. Мөҗәй, Ф. Гыйльми, Г. Насрый, Т. Әйди, М. Гатау, М. Галәү һ. б.

Күреп үткәнебезчә, татар әдипләренең фамилияләре татар теле һәм антропонимиясенә хас закончалыклар тәэсирендә барлыкка килгәннәр һәм үзлекле тарихи үсеш-кулланылыш алганнар.

---

[18] Писцовая книга Казанского уезда 1602-1603 годов.— Казань, 1978. 211 б.

# ӘДИПНЕ ХУПЛЫЙМ

Хөрмәтле редакция!

Мин, кызганычка каршы, туган телебезне яхшы белмим, шунлыктан русча язарга мәҗбүрмен. «Казан утлары» журналын да күптән түгел генә алдыра башладым. Әдәбиятыбызны, мәдәниятебезне, бигрәк тә тарихыбызны тирәннән өйрәнәсе килә.

Сезгә хат язарга исә Миргазыян Юнысның «Телсезләнү: тамыры һәм җимешләре» (быелгы 3 сан) исемле мәкаләсе этәргеч булды. Минемчә, бу мәкалә бер генә укучыны да битараф калдырмас, чөнки анда язылганнар без татарларның һәммәсенә кагыла. Монда туган тел, милләтнең үзаңы мәсьәләләре бик төгәл һәм дөрес ачылган. Чыннан да, без хәзер тарихыбызны бозып күрсәтүләрнең, телгә һәм әхлак-гадәтләребезгә битарафлыкның ачы җимешләрен җыябыз.

Моңа мисаллар эзләп ерак китәсе түгел. Миңа, мәсәлән, үз язмышым ук бик күп нәрсә хакында сөйли. Туган телдә сөйләшә дә, яза да белмим. Ярый, шөкер, башкалар әйткәнне бераз аңлыйм да язганны укый алам. Әти-әниләрем татарча сөйләшә, хатын белән мин аларны аңлыйбыз әле, тик үзара — урысча инде. Җиде яшьлек кызыбыз татарчаны бөтенләй белми. Менә шундый хәлләр...

Тел, аның белән бергә туган мәдәният, гореф-гадәтләр онытыла, югала барган. Урыслашканбыз. Үзебезнең татар милләтеннән икәнне дә сизмәмешкә салышканбыз. Без — урыс, дип тә әйтә алмыйбыз, чөнки, арада моны теләүчеләр булса да, ул зат мәңге чын урыс була алмаячак. Бәс шулай икән, кем соң без?! Космополитмы? Юк. Дөресен әйткәндә, без — милләтеннән, диненнән язган затлар. 1979 елгы исәпкә алуларның нәтиҗәсен карaганда, 6 млн. 313 мең татарның 889 меңе туган телен җуйган, ә соңгысында — 6 млн. 654 мең татарның теленнән язганнары — 1 млн. 130 меңгә якын. Ни булган соң? Хикмәт нәрсәдә? Кем гаепле?

Соңгы сорауга, әлбәттә, иң гаеплесе — һәркем үзе, дип кенә дә җавап бирергә мөмкин. Мин беләм: шундый халыклар бар, аларның һәр кешесе милли хисен, милли горурлыгын иң алга куеп яши. (Балтик буе, Кавказ, Урта Азия һ. б. якларда яшәүчеләрне күздә тотуым.)

Әммә татарның татарлыгыннан качуын аерым шәхесләрнең гайре табигый гадәтенә генә кайтарып калдыру да дөрес булмас, минемчә. «Мин — татармын!» — дип горурлана алмау, уйлавымча, тарихыбызның элек-электән бозып күрсәтелүенә барып тоташа. Балалар, бакча-яслегә йөрергә тотынуга: «Татарлар — кыргый халык», — дигән вәхши фикер ишетә башлый. Урысча язучы әдипләрнең тарихи әсәрләрен укысалар, балаларыбыз кая кереп качарга белми аптырый кебек. Рәсем сәнгате дә, кинофильмнар да, кирәксә-кирәкмәсә, татарны хурлау белән мавыга. Хәтта безнең кыяфәт тә бозып тасвирлана: кәкре аяк, кап корсак, кысык күз, сары йөз...

Дөрес, кешенең тышкы кыяфәте төрлечә булырга мөмкин, әмма татарны болай сурәтләү хакыйкатькә туры килми бит. Гарәп, фарсы, рус, алман елъязмачыларының, хәтта бүгенге объектив тарихчыларның әсәрләре дә безнең борынгы бабайларның бөтенләй башка төсле икәнен ачыклый. Бүген «татар» исеме белән атап йөртелгән кешеләр берничә төрле нәселдән кушылып барлыкка килгән. Аларның кыяфәте, чын галимнәр раславынча, элек-электән зур гәүдә, зур күзле якты йөз белән әллә кайдан аерылып торган. Алар туры сүзле, мәгъруР, кыю, хөр күңелле булган. Безнең халык урта гасыр башында гомумкешелек тарихына нык тәэсир ясаган.

Византия, Русь, Грузия, Персия ирләре үзләренә хатын итеп болгар-кыпчак кызын алуны мәртәбә санаган. Бу хакыйкать тә — безнең борынгы әби-бабаларыбызның халыкара күләмдә абруйлы булуына бер дәлил. Димәк, безнең топ нәсел Европа һәм Азия культурасы формалашуга да шактый өлеш керткән.

Кызганыч, шундый халыкны кимсетергә тырышу, аның тарихын мыскыл итү әле дә дәвам итә. Мәсәлән, СССР тарихы дәреслегендә язылганча, XVI гасырда Казан ханлыгының үсеш дәрәҗәсе, культурасы урысларныкыннан түбән булган, янәсе,

шунлыктан Явыз Иванның Казан ханлыгын яулап алуы — прогрессив күренеш. Әле 1988 елда гына чыккан «История Казани» китабы авторлары да (1 китап, 76 бит) Казанның урыслар тарафыннан басып алынуын уңай күренеш итеп бәяли. Казанны вәхшиләрчә җимерү, халыкны, бигрәк тә ир-атларны тоташтан сую, калганнарны көчләп чукындыру, туган Иделе буеннан куу — ничек уңай күренеш була алсын икән?! Мәчетләр, мәдрәсәләр, китапханәләр яндырылган. Туган тел, ислам дине тыелган...

Без бит, башка илләр тарихын өйрәнгәндә, мондый күренешне үз исеме белән, «басып алу» дип атыйбыз. Әйтик, Госманлы империясенең Греция, Әрмәнстан, Дунай Болгарстаны, Мисыр кебек илләрне буйсындыруын «бөек берләшү» дип бәяләсәк, ә?! Тик ул илләр һәммәсе үзенә мөстәкыйльлек дәгъвалады һәм шуңа иреште. Минемчә, Явыз Иванның Казан ханлыгын басып алуы да һичничек алдынгы күренеш була алмый. Тарихчы галимнәр кичекмәстән бу хакта чын дөресен язып чыгарга тиешләр.

Шундый ук бозулар Алтын Урда чорына да карый. Белүемчә, бу чорда тормыш шактый матур, шактый мөстәкыйль булган. Телгә, дингә, халыкның эчке тәртипләренә, борыннан килгән гадәтләренә-һөнәрләренә сүз әйтүче булмаган. Шул ук вакытта анда Казан, Әстерхан, Себер, Кырым ханлыгы татарларының һәм башкаларның бердәмлеге дә сакланып килгән. Хаклыклар берәм-берәм таркала башлагач кына, хәлләр начарланган. Кырым ханлыгы исә мөстәкыйльлеген шактый озак саклаган.

Бу уңайдан кырым татарларының безгә, ягъни Казан татарларына, һичнинди мөнәсәбәте дә юк, дигән ялгыш карашны да фаш итәсем килә. Телдәге, музыкадагы аерым төсмерләргә таянып кына без бу канкардәшләребездән читләштерелергә тиеш түгел. Андый гына аерымлыклар урыс халкының торле төбәктәге төркемнәре арасында — буа буарлык. Әмма без аларга бер милләт итеп карыйбыз.

Дөрес, татарларның тарихы башка. Гасырлар агышында татарларның төрле төркемнәре формалашкан, милләтне милләт итүче сыйфатлар аерымлашкан. Шунлыктан мин һич тә кырым татарларын безнең кебек үк милләт дияргә җыенмыйм. Әмма туганлык җепләрен өзеп ташларга да һич кирәкмәс. Бигрәк тә кырым татарларының язмышы кыл өстендә торган бу елларда аларны һәрьяклап хупларга, аларга кулдан килгәнчә ярдәм итәргә кирәк.

Сүзем язучы М. Юныс мәкаләсеннән башланган иде бит. Мин бу авторның фикерен ачык иттереп әйткәне өчен бик яраттым. Рәхмәт аңа. Дөрес яза ул: без, тарихыбызны гадел нигезгә бастыргьнда гына, уңышка ирешербез. Татарстанга союздаш республика статусы бирергә, татар телен Татарстанда дәүләт теле итеп законлаштырырга кирәк, дигән фикерләрен дә бик хуплыйм. Болар барысы да — халкыбызның тарихи урынын билгеләргә иң кирәкле чаралар дип саныйм.

**Фоат ГАНИЕВ,**
эшче.
Сарапул шәһәре.

# ӨМЕТЛӘР ӨЗЕЛМӘГӘН

Егерме биш ел милли мәктәпләр институтында эшләгәнлектән, Россиянең төрле төбәкләрендә — Куйбышев, Пермь, Ульяновск, Төмән, Оренбург һ. б. якларында булып, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, укучылар, ата-аналар, мәктәп һәм район җитәкчеләре белән очрашканым бар. Соңгы елларда илебезнең барлык урыннарында милли телләр укыту мәсьәләсе кузгалгач, мондый сәфәрләр тагын да ешайды. Кулга каләм алырга этәргеч биргәне — Кемерово өлкәсенең Ижмор районындагы Җылы Елга авылында үткәрелгән укытучылар семинары. Авылга барып керүгә игътибарны үзенә җәлеп иткән нәрсә — аның төзеклеге. Өйләр сурәттәге сыман зур, биек, төзек. Авыл урамнары тигез, киң, чиста, ник бер чүп булсын! Терлек-туар күп, йорт саен, иң кимендә, өч баш мөгезле эре терлек, хәтта җидегә җиткерүчеләр дә бар икән (рөхсәтителә), егерміләп сарык (артыгы да бар), тавык-казлар йөзләп исәпләнә. Бусы — халык тормышының матди ягы. Өс-баш заманча, шәһәрчә, сөйләшү саф татарча, хәтта диалекталь сүзләр дә ишетелми. Уку урысча. Авылда да, мәктәптә дә татарча бер генә язу кисәге дә юк — һәммәсе урысча.

Безне, мәктәп директоры Гөлшат Биккулова җитәкчелегендә, укучылар һәм укытучылар татарча сәламләп, каршы алдылар. Кулларында — чәчәк бәйләме. Октябрьдә, кырыс Себер чынбарлыгында бу кадәр нәфис чәчәкләр кайдан?! Мәктәпнең ике теплицасында искиткеч розалар чәчәк аткан, кып-кызыл булып помидорлар пешеп утыра.

Кемерово өлкәсендә халык саны буенча татарлар, урыслардан кала, икенче урында. Шуңлыктан, җитәкчеләр, мәктәпләрдә татар телен укыту буенча семинар үткәрүне максат итеп, Мәскәү һәм Казан белән бәйләнешкә кергән. Чуаш, шор, телеут телләрен укыту мәсьәләсе дә көн тәртибенә куелган. Татар телен укытырга хәзерлек уңаеннан өлкәнең төрле төбәкләреннән әлеге семинарга укытучылар җыйналды. Җылы Елга авылында әлеге семинарга охшаган чаралар еш үткәрелә икән. Бу очракта аның татарча булуы авылның бөтен халкын уятып җибәрде кебек. Җитәкчеләр авыл халкының Казан белән, татар теле, әдәбияты, мәдәнияте белән кызыксынганлыгын әйттеләр.

Авылда игъланнар эленде. Ә мин элемтә бүлегенә юл алдым: кем күпме укый, нәрсә укый — шуларны ачыклыйсым килде.

«Азат Себер» колхозы ике авылны — Җылы Елга һәм Яңа Авыл хуҗалыкларын берләштерә. Газета-журнал алдыручылар исемлеген карагач, менә мондый күренеш ачыкланды.

| Татарча матбугат | Җылы Елга (167 хуҗ.) | Яңа Авыл (149 хуҗ.) |
|---|---|---|
| Азат хатын | 31 | 27 |
| Казан утлары | 1 | 1 |
| Чаян | 57 (русча) | 2 (12 русча) |

Чагыштыру өчен Саратов өлкәсенең Дергачев районында урнашкан авыллардан мисал китерәсем килә.

| Татарча матбугат | Алтата (250 хуҗ.) | Вергазовск (400 хуҗ.) | Сафаровка (300 хуҗ.) |
|---|---|---|---|
| Казан утлары | 5 | 23 | 10 |
| Азат хатын | 75 | 112 | 90 |
| Совет мәктәбе | 9 | 11 | 7 |
| Ялкын | 17 | 58 | 40 |
| Чаян (татарча) | — | 18 | 5 |
| Социалистик Татарстан | — | 12 | — |
| Татарстан яшьләре | — | 27 | — |
| Яшь ленинчы | 4 | 49 | — |

Саратов өлкәсенең Казахстан белән чиктәш булган әлеге өч авылында башлангыч класста татарча укытуны торгынлык елларында да саклап кала алганнар. Укучылар русча яхшы сөйләшү өстенә, татарча да укый, яза беләләр. Шуңлыктан хәтта яшьләр дә татарча матбугат белән араларын өзми.

Себер киңлекләренең урманлы-күлле, чишмәле гүзәл табигать кочагына сыенып утырган Җылы Елгада һәм Яңа Авылда бер генә татарча газета да булмауны ничек аңлаталар соң? Элемтә бүлегендә эшләүче ачык чырайлы, чибәр кыз — Зәйтүнә белән сөйләшәм. «Газеталар алмыйсыз, «Казан утлары» бер генә», — дим. Яшьләр журналы «Идел» турында хәбәр итәм. Зәйтүнә исә мәсьәләнең тагын бер ягын ача:

— «Казан утлары»н да, «Азат хатын»ны да пенсионерлар гына укый бездә, — ди. — Яшьләр журналын алдыручы булмас.

— Сез үзегез дә укымыйсызмы?

— Юк, без, яшьләр, укый белмибез.

— Ничек инде? Бик матур сөйләшәсез бит.

— Без сөйләшәбез генә, укый белмибез, без урысча гына укыдык, журналларны да, газеталарны да урысча гына укыйбыз...

Шул чакта элемтә бүлегенә йомыш белән килгән олырак яшьтәге бер апа эндәште:

— Казаннан кешеләр килгән дигәннәр иде, сез шуларның берсеме әллә?

— Әйе, апа, нәкъ шулай.

— Татарча календарь кирәк иде, ничек итеп алдырырга икән шуны?..

Мин хәтердәге беренче китап кибетенең адресын язып бирәм, шуннан сорап карарга киңәш итәм...

Зәйтүнә яза, апа ялварып сорый:

— Миңа бишне сора, күршемә тагы да күбрәк кирәк, сора, бик тилмерәбез бит...

Элемтә бүлегеннән кайтканда гүзәл табигать кочагындагы төзек авыл, анда әдәпле генә татарча сөйләшүче, затлы киемле кешеләр белән очрашудан туган шатлыклы тәэсирләр сүрелә төшкән иде инде.

Кич Мәдәният сараенда халкыбызның тарихы, тел, әдәбият, мәгърифәт турында сөйлибез. Үзгәртеп кору чорында Мәскәү, Ленинград, Киев, Рига, Свердловск һ. б. һ. б. шундый зур шәһәрләрдә яшәүче халкыбызның да туган телгә карата кызыксынуы,

игътибары артуы. Татар иҗтимагый үзәге турында һәм аның күп шәһәрләрдә бүлекләре барлыгын хәбәр итәбез.

Залдагылар да безгә сораулар бирә. Башка төбәкләрдә яшәүче татарлар ни хәлдә? Яңа җырлар, композиторлар күпме, хәзерге әдәбиятны әйдәп баручылар кемнәр? Казанда ничә татар мәктәбе бар? Татарстанда нинди китаплар чыга? Казанда муллалар күпме, безгә килүчесе булмасмы икән? Казанда дин әһелләре әзерләүче уку йортлары бармы?..

Татар теле семинарына килгән укытучылар «Туган тел» җырын башкарды. Аерым концерт та әзерләнгән иде. Халыкның күңеле тәмам кузгалды, тиз генә таралырга ашыкмый. Күрәсең, авыл үзенең җырын-моңын, талантларын әлегәчә саклап кала алган. Җыр, музыка, уеннар озак дәвам итте. Яшьләр җыр-бию, күңел ачу белән мәшгуль. Өлкәннәр, үзләрен кызыксындырган сораулар бирә-бирә безне урап алды. Өлкән яшьтәге бер агай миннән бүгенге прозаикларның исемнәрен язып бирүемне үтенә: Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев, Мөсагыйть Хәбибуллин, Әхсән Баянов, Гариф Ахунов, Әхәт Гаффар... Кәгазьне кулына алгач агай йөзенә нур сибелгәндәй булды. «Бар икән, күбәүләр икән!» — ди.

Каршыма мөлаем йөзле апа килеп басты. «Казан утлары» журналын алучы мин ул, — ди. — Бөтен урамыбыз аны укырга чират тора, без аны бергәләп тә, аерым-аерым да укыйбыз»... Аның янындагы апалар исә:

— Моннан соң үзебезгә дә яздырабыз әле, газета да яздырабыз, бөерган булса, — диделәр.

Без бер-беребезгә рәхмәтләр әйтеп таралыштык. Урамда кырыс һәм аяз Себер көзе. Күктә янган йолдызлар арасында күз алдымда Фатих Әмирханның гасыр башында язган сүзләре балкый кебек: «...мең еллык тарихы булган, башкаларныкыннан бер дә калышмаслык кабилияте булган, тырышып, сакланып килгән дине вә гадәтләре булган, үзенең язуы, әдәбияты, җыры, көе булган, гасырлар буенча мәктәп вә мәдрәсәләре булган бер милләтнең берәрсәсе дә бервакытта да чүпкә чыкмый, чыга алмый!..»

**Гөлчәчәк ӘДҺӘМОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

# МОҢА БЕЗ ХУҖА

Журналыгызның 3 санында М. Юнысның «Телсезләнү: тамыры һәм җимешләре» мәкаләсе һәм 4 санында ТИҮ рәисе М. Мөлеков белән әңгәмә өчен рәхмәт. Аларда күтәрелгән мәсьәләләр безнең өчен бик вакытлы һәм әһәмиятле булды.

Хәзер инде милли матбугатыбызда Татарстаннан читтә, әмма үз тарихи ватанында, ата-бабалары җирендә гомер итүче милләттәшләребез хәлен төрле яктан һәм тәфсилле яктыртуны көтәбез. Чөнки Әстерхан, Оренбург, Төмән өлкәләрендә һәм алар белән Татарстан арасындагы киңлекләрдә яшәүче татарлар туган телен, туган мәдәниятын үстерүдән, милли ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән нигездә мәхрүм ителгән. Бу гаделсезлекне бетерүнең, минемчә, ике юлы бар:

Халкыбыз яши торган тарихи татар төбәкләрен тулаем Татарстан республикасы эченә кертү.

Әстерхан, Оренбург, Төмән өлкәләре һәм алар белән Татарстан арасындагы җирләрдә, рус теле белән бергә, татар теленә дә Дәүләт теле хокукын бирү. Бу җирләрдәге экономика рус милләте һәм культурасына гына түгел, татар милләте һәм мәдәниятына да хезмәт итәргә тиешлеген канунн нигездә гарантияләү. Казанның Татарстаннан читтәге татар халкы мәнфәгатьләрен якларга хокуклы булуын тану.

Киләчәктә җирне шәхси милек рәвешендә сату да күздә тотыла. Татар халкының тарихи ватанына мирас хокукы уңай хәл ителгәнче, мондый сату-алу эшләренә юл куелмаска тиеш.

**Р. СӨЛӘЙМАНОВ,**
Ташкент шәһәре.

# ӘХМӘД БАЙ ГАЛИ УГЛЫ ХӨСӘЕНЕВ

Әхмәд бай 1837 нче елда Оренбург Каргалысында дөньяга килеп, 1906 нчы елның декабрендә Казанда вафат булды. Каргалыда бераз мал тапканнан соң туганнары Габделгани вә Мәхмүд байлар белән Оренбургка күчеп килделәр. Соңгы ун ел эчендә туганнары белән Казанга күчеп килде. Әхмәд бай бала вакытында мәктәпкә укырга бирелсә дә уку тәртипләренең начарлыгыннан һәм гаиләсенең хәле начарлыгыннан күп вакыт укый алмады. Язуы бары татарча, русча кул куя белүдән гыйбарәт иде. Яшь вакытында ук сәүдәгә тотынып бәхетенең ярдәме вә үзенең иҗтиһады аркасында зур бер байлыкка малик булды.

Әхмәд бай малны бик сөя иде, ләкин малга хирыс булмый, бәлки малның кадерен бик белүче һәм ярдәм кылуны бик ярата иде. Шуның өчен милләтнең кирәк урыннарына малын һич кызганмый ярдәм итә иде. Әмма кирәк булып булмаган урыннарын бик тикшерә иде. Шуның өчен кирәк җирләргә мәктәп, мәдрәсә вә мәсҗедләр салдыра иде. Идел буендагы төрле авылларга ике йөзгә якын мәктәп салдыргандыр. Һәр ел 40-50 кадәр авылдагы мөгаллимнәргә вазифалар бирә иде. 30лап таш мәсҗед салдырды. Мәктәпләргә биргән китапларының, төрле җирләрдә казыткан коеларының вә салдырган күперләренең саны бик күптер. Оренбургта үз акчасыннан салдырган «Мәдрәсәи Хөсәения» Русиядәге мөселман мәдрәсәләренең иң зур вә яхшысыдыр. Бунның җирен алып бинасын салдырыр өчен 99 мең сум акча тотты. Ахыр гомерендә кылган васыятенең барсы ярты миллион сум булып, шуннан килгән фаиз — «процент»ны милләтнең иң мохтаҗ урыннарына тотыла чакдыр.

Әхмәд байның сәүдәсе тире-яры, җон-җобага кеби маллар белән булып боларны Яурупага озата иде, ләкин үзе укый-яза белмәгәнлектән файдасының күбрәк өлешен немец вә яһүдиләргә бирүгә мәҗбүр була иде.

Бу эш Әхмәд байның җанын бик әрнетә иде. Шул сәбәптән эше бераз зурайгач Берлин вә Лондон шәһәрләрендә конторлар ачты. Шулай булса да галим инглизләр белән немецләргә каршы тора алмады. Андагы сәүдәсеннән зарар иткәч, ул конторларын бетерергә мәҗбүр булды.

Ләкин чит мәмләкәтләр белән сәүдә итәргә Русия татарларына бер үрнәк булды.

Корбангалиев М. Татарча уку. Дүртенче җөзьә. — Казан, 1917. 36—37 бб.

احمد بای علی اوغلی حسینف

احمد بای ۱۸۳۷ نچی یلدا اورینبورغ قارغالیسندا دنیاغا کیلب، ۱۹۰٦ نچی یلنک دیکه‌بر نده قازانده وفات بولدی. قارغالیدا برآز مال تابقاندان سوڭ توغانلاری عبدالغنی و محمود بایلار بلەن اورینبورغا کوچب کیلدیلەر. سوڭغی اون یل ایچنده توغانلاری بلەن قازانغا کوچب کیلدی. احمد بای بالا وقتندا مکتبکه اوقورغا بیرلسه ده اوقو ترتیبلەرینک ناچارلغندان هم عائله سینک حالی ناچارلغندان کوب وقت اوقی آلمادی. یازووی یاری تاتارچا، روسچا قول قویا بلودەن عبارت ایدی. یەش وقتندان اوق سوداگه توتونوب تحتینک یارده‌می و اوزینک اجتهادی آرقاسندا زور بر بایلقغا مالك بولدی.

احمد بای مالنی بیك سویه ایدی، لکن مالغا حریص بولمی، بلکه مالنک قدرین بیك بلوچی هم یارده‌م قیلونی بیك یاراتا ایدی. شونک اوچون ملتنک کیره‌ك اورنلارینا مالن هیچ قزغانمی یارده‌م ایته ایدی. اما کیره‌ك بولب بولماغان اورنلارین بیك تیکشره ایدی. شونک اوچون کیره‌ك جیرله‌رگه مکتب، مدرسه و مسجدله‌ر سالدرا ایدی. ایدل بوینداغی تورلی آوللارغا ایکی یوزگه یاقن مکتب سالدرغاندر. هر یل ٤٠ - ٥٠ قدر آولداغی معلم‌له‌رگه وظیفه‌لار بیره ایدی. ۳۰ لاب تاش مسجد سالدردی. مکتبلرگه بیرگەن کتابلارینک، تورلی جیرله‌رده قازیتقان قویولارینک و سالدرغان کوپرله‌رینک سانی بیك کوبدر. اورینبورغدا اوز آقچاسندان سالدرغان «مدرسهٔ حسینیه» روسیه ده‌گی مسلمان مدرسه‌له‌رینک ایڭ زور و یاخشیسیدر. بونک جیرین آلب بناسن سالدرور اوچون ۹۹ مڭ سوم آقچا توتدی. آخر عمرنده قیلغان وصیتینک یارسی یاری میلیون سوم بولب، شوندان کیلگه‌ن فایض -- «پروسینت»نی ملتنک ایڭ محتاج اورونلارینا توتولاچاقدر.

احمد باینک سوداسی تیری - یاری، جون - جاساغاکی ماللار بلەن بولب بولاری یاوروپاغا اوزاتا ایدی، لکن اوزی اوقو- یازو بلمه‌گه‌نلکدن فائداسینک کوبره‌ك اولوشی نیمس و یهودیله‌رگه بیروگه مجبور بولا ایدی.

بو ایش احمد باینک جانن بیك ئه‌رنته ایدی. شول سبب‌دەن آشی برآز توراینجاچ بیرلین و لوندون شهرلرنده کانتورلار آچدی. شولای بولسا دا عالم اینگلیزله‌ر بلەن نیمسله‌رگه قارشی تورا آلمادی. آنداغی سودا- سنده‌ن ضرر ایتکه‌چ، اول کانتورلارین بتررگه مجبور بولدی.

لکن چیت مملکتله‌ر بلەن سودا ایته‌رگه روسیه تاتارلارینا بر اورنه‌ك بولدی.

## Хәниф Хөснуллин

### «Саратти агентлыгы»

Хәбәрдар соң безнең авыл:
Төрле нәрсәне сора —
Мәскәү көнләшерлек итеп,
Барысын белеп тора.
Газеталар, радиолар
Җитешү кая аңа!
Авыл бу төр хезмәтендә
Сараттигә таяна...
Бөтен илдә төн йокламый
Үзгәреш барган чакта,
Оялмыйча, үзе генә
Ул ничек калсын артта?
Башта ул бер күзен сөртте,
Имеш, якын-тирәне
Барлык тулылыгы белән
Заманча ул күрәме?
Икенче күзен уды ул,
Имеш, гадәткә керсен:
Кайсы җирдә нәрсә барын
Бер карау белән күрсен.
Теле үтә җитезләнде,
Сизгерләнде колагы.
Кыскасы, ул һава түгел —
Гайбәт белән сулады...
Сүзләр — диңгез, сүзләр — чиксез,
Кыя булып басты ул:
Сүз җыеп тарата торган
Кооператив ачты ул.
Шулай яши башлады ул,
Юк, рәсми теркәлмәде;
Кеше, «гайбәт әртиле», дип
Әйтсә дә, үртәлмәде.
Эшкә җикте күршеләрен,
Җикте ирен, баласын...
Берәүләрне чит итте ул,
Кабул итте яңасын.
Хәбәрләрме? Чыганак күп,
Ул шулардан туена:
Сараттинең агентлыгы
Эшли тәүлек буена.
Җыелышта кем турында
Кемнәр нәрсә кузгаткан;
Кемнең кызын кайсы егет
Кая кадәр озаткан;
Алдагы ел ничек килер;
Илне ни язмыш көтә;
Кемгә гомер озын кирәк,
Кемгә кыска да җитә...
Йолдыздан алып коңгызга
Кадәре сөйли бит ул,
Усал сүзләр яманлыгын
Теленә төйни бит ул.
Шикләнмәгез, гайбәтләрдән
Без дә читтә калмадык —
Җиде буыныбыз белән
Сүз сазында аунадык...
Кояш нуры да, мөгаен,
Ул йортка куркып керә.
Сараттиләрнең эте дә
Дөньяны сүгеп өрә.

### «Банкрот»

Яшь чагында карадык без
Һәм хәзер дә карыйбыз:
Бер сүздән Г. Камалның «шәп»
Сиражиен таныйбыз...
Бигрәк тә Сабир ошатты,
Әнә бит күптән, диде,
Мәскәүнең кара байларын
Сиражи «өткән», диде.
...Директор булды Сабир да —
Зур бер совхоз башлыгы.
Уңышы күренмәсә дә,
Ташып чыкты шатлыгы.
Анысын төзи башлады,
Монысын сүтеп атты...
Җитмеш җирдә җитмеш төрле
Әҗәткә кереп батты.
Совхозымы? Тора-бара
Бөтенләй бөлгән, диләр,
Юкка гына Сиражидан
Өйрәнеп йөргән, диләр.
...Яшь чагында карадык без
Һәм хәзер дә карыйбыз:
«Банкрот»ның геройларын
Арабыздан таныйбыз.

## Низами

### Тәүбә

Урамнарда пәйда булды озын чират,
Арка-арка тезелешеп басты ир-ат.
Этеш-төртеш! Монда исән калуларың
Икеледер, булсаң әгәр салам сыйрак.

Ялваралар: «Алчы, туган, берне генә!»
Кундыралар хәтта ипи шүрлегенә.
Пеләш башлар, күзлекләләр... — бу аракы
Үз катына чакырмаган кемне генә!

Агай-эне мыек бора, тамак кыра,
Кибетчеләр акча ягын санап тора.
Койрык — тышта, үзе әнә «яшел елан»
Киштәләрдән мөлдер-мөлдер карап тора.

Узып бара аракылы заман, дидек,
Эчүсез дә бу тормышлар таман, дидек.
Ах, тиз генә китми бездән иске гадәт:
Эчемлеккә килеп тагын башлар идек...

## Кәшфелзадә

### Һаман «күтәрелүче» бер дуска

Әйт, сине кайсы түбәгә чакырыр «зурлык» тагын?
Болай да биек ояда син — алтын орлык, җаным!

Күр әнә, аста калган бит, түбәндә күпме тиңең!
Син исә һаман менәсең, сиңа киртә юк, җаным!

Йөз чыт та безгә аркаң бор, яшәгез, сарыклар, дип;
Мин, диген, хәтта бүгеннән һәйкәлгә лаек, җаным!

Шунсы сәер, бер тавыш юк: ни хуплау, ни каршы өн,
Син чыннан да көчлесеңме, дәлилеңме нык, җаным?!

Ә ник сөенү, сөюләр, табыну, ышану юк?!
Әллә чынлыкта бүтән син,— бер агач мылтык, җаным?!

Әй менәсең өскә һаман — кем бара икән этеп?!
Каһармандай бит кыяфәт, юк, түгел «куык» җаным!

Әмма арган ахры халкым, күп «бөек»тән алданып,
«Шылт»та итми... каян бездә бу битарафлык, җаным?!

...Юк, син әйдә шикләнмә, үс, имансыз чорга таян;
Кем белә бүген: ни ялган, ни анда чынлык, җаным?!

# ЖУРНАЛЫБЫЗНЫ КАЙДА КҮПМЕ АЛДЫРАЛАР

1990 ел «Казан утлары» өчен сынау елы булды. Әлегә кадәр ул татар телендә бердәнбер калын әдәби журнал булып чыкса, хәзер аның янәшәсенә яшьләрнең «Идел»е килеп басты. Кыю, дәртле, күпне колачларга омтылучы басма. Җитмәсә, сурәтле журнал. Без аның ышанычлы рәвештә атлап китүенә сөендек, шул ук вакытта «Казан утлары»на күпмедер дәрәҗәдә көндәш буласын да белеп тордык. Чөнки байтак укучыларның кесәсе ике журналга берьюлы язылырлык калын булмаска да мөмкин иде.

Әмма язылу нәтиҗәләре калын әдәби журналларның икесенә дә шатлык китерде — «Идел» гомеренең икенче елында ук татарчасына 96 мең тираж җыйды һәм СССРдагы шундый милли басмалар арасында мәртәбәле урын алды. Шул ук вакытта «Казан утлары» да быел былтыргыдан алты меңгә күбрәк тарала башлады. Димәк, аны яратып укучы тотрыклы бер катлам бар һәм ул соңгы елларда өзлексез рәвештә арта бара. Тулаем алганда исә халкыбызның туган телендәге яңа журналларга күңел кытлыгы, чыннан да, зур булганлыгын, димәк, киләчәктә борын төртәчәк бүтән басмаларыбызның да ышанычлы җирлеге барлыгын искәртә бу тиражлар.

Журналыбызга быел гына язылган кешеләрнең өчтән икесе Татарстанда яши. Шунысы күңелле, соңгы ике-өч елда республикабыз шәһәрләрендә татар матбугатына игътибар туктаусыз арта бара — халкыбыз туган теленә, мәдәниятенә йөз белән борыла башлады. Мисалга, узган ел белән чагыштырганда, быел «Казан утлары»на язылу Казанда 121, Әлмәттә 134, Чаллыда 136, Түбән Камада (районы белән) 156 процентка күбәйде. Башкалабызда аны 1988 елда 3797, былтыр 4960, быел исә 5890 гаилә алдыра. Ярты миллион татарга бу, әлбәттә, күп түгел, ләкин егерме биш ел элек, «телләрне, милләтләрне кушу» омтылышы ажгырып торган шомлы дәвердә төп әдәби журналыбызны Казанда нибары 400 гаилә генә алдыруын да онытмыйк.

Татарстаннан читтәге кайбер шәһәрләрдә быел журналыбызга язылучылар түбәндәгечә булды (җәя эчендә — былтыргы сан): Магнитогорск — 206 (143), Октябрьск — 295 (241), Оренбург — 295 (199), Пермь — 306 (253), Куйбышев — 306 (180), Ульяновск — 172 (343), Ижевск — 567 (512), Ташкент — 782 (571), Уфа — 1153 (974). Соңгы күрсәткечләр Уфадагы милләттәшләребезнең дә башкортлаштыру шаукымына бирешмәвен раслый.

Журналыбызның төрле республикаларда һәм өлкәләрдә быелгы таралышын былтыргы белән чагыштырып күзәтү дә кызыклы. Куйбышев, Чиләбе, Саратов, Волгоград, Әстерхан, Пенза, Ульяновск, Горький өлкәләрендә һәм Удмурт, Мордва республикаларында — халкыбызның тарихи ватаны булган Идел-Урал буйларында «Казан утлары» таралышының кискенрәк артуы мәктәпләрдә туган тел-әдәбият укытуның киңәюенә, татар иҗтимагый хәрәкәтенең җанлануына, иман ирегә җәелүенә дә бәйләнгән.

Быел журналыбызның халыкара абруе тагын да күтәрелүе күз алдында. Хәзер ул унике илдә (былтыр — ун) 60 данә (былтыр — 47) тарала. Шуның 18 данәсе төрле илләрнең зур китапханәләренә барып керә. АКШ конгрессы китапханәсе, АКШның Иллинойс, Индиана, Колумбия, Англиянең Оксфорд, Глазгов университетлары, Лондон һәм Көнбатыш Берлин шәһәр китапханәләре, Франция, Финляндия, Нидерланд, ГФРның Шәрыкне өйрәнү институтлары, Болгария дәүләт китапханәләре, тагын башка гыйльми үзәкләр алдыра «Казан утлары»н.

«Казан утлары» журналын мин әүвәл Хельсинкида, Совет китаплары һәм матбугатын сатучы мәркәз каталогында күрдем,— ди ГФРда яшәүче Фәридә Хәмит.— Финляндия татарларыннан беренче булып язылдым, шуннан бирле даими алдырып торам. Бик бай эчтәлекле журнал. Татарчаны да шуннан өйрәндем, халкымның әдәбияты, сәнгате, тарихы белән дә шуның аша таныштым. Гаҗәп ки, Төркия — мөстәкыйль ил, мәдәнияте борынгы, халкы 60 миллионга җитеп килә, әмма анда «Казан утлары»на тиң төпле әдәби журнал юк. Горурланып кулыма алам «Казан утлары»н, аның хезмәткәрләренә, авторларына рәхмәт укыйм!»

Анкара шәһәрендә яшәүче Әсфәндияр Чынбай әфәнде: «Безнең илгә Совет басмалары кертелми, югыйсә «Казан утлары»н алдыручылар Төркиядә күп булыр иде,— дип яза.— Журнал соңгы елларда әйруча кызыклы, бай чыга башлады. Тормыш, дөнья турында дөреслек канат җәйде анда. Без «Казан утлары»н мең бәла белән кулга төшерәбез, кулдан-кулга йөртеп укыйбыз. Тарихи ватаныбызда барган яңарыш, тәрәккый сулышын алып килә ул безгә, күңелләребезгә юаныч өсти».

«Казан утлары» хәзер әнә шулай ерак илләргә дә барып җитә, яңадан-яңа укучыларыбызның рухын күтәрә, җанын җылыта. Быел 83 мең гаилә бертуктаусыз алып укый аны. Редакция хезмәткәрләре һәм авторларыбыз «Казан утлары» тагын да матуррак булсын өчен киләчәктә дә бар көчләрен һәм сәләтләрен бирергә әзер!

## «Казан утлары» 1990 елда

| Республика, әлкә | Саны | Былтыргыга карата процент |
|---|---|---|
| РСФСР | 76 734 | 107,9 |
| Татарстан | 40 699 | 111,3 |
| Башкортстан | 18 348 | 100,5 |
| Үзбәкстан | 2 471 | 104,8 |
| Казахстан | 2 320 | 102,2 |
| Оренбург | 2 168 | 105,0 |
| Пермь | 1 811 | 120,8 |
| Төмән | 1 694 | 100,5 |
| Свердловск | 1 528 | 96,5 |
| Ульяновск | 1 290 | 139,5 |
| Чиләбе | 1 167 | 116,6 |
| Куйбышев | 1 068 | 114,5 |
| Удмуртия | 892 | 110,1 |
| Мәскәү | 805 | 97,6 |
| Горький | 629 | 144,3 |
| Киров | 430 | 109,7 |
| Кемерово | 417 | 98,1 |
| Таҗикстан | 399 | 117,7 |
| Мари | 367 | 101,1 |
| Кыргызстан | 367 | 107,0 |
| Чувашстан | 348 | 93,5 |
| Украина | 337 | 110,5 |
| Коми | 298 | 87,4 |
| Пенза | 285 | 135,7 |
| Әстерхан | 227 | 129,0 |
| Красноярск | 224 | 96,6 |
| Омск | 218 | 113,0 |
| Төрекмәнстан | 182 | 87,1 |
| Саратов | 162 | 120,9 |
| Курган | 161 | 101,3 |
| Ленинград | 124 | 121,6 |
| Иркутск | 115 | 95,0 |
| Якутия | 111 | 84,7 |
| Новосибирск | 97 | 132,9 |
| Мордовия | 95 | 131,9 |
| Томск | 85 | 86,7 |
| Ростов | 62 | 121,6 |
| Магадан | 57 | 89,1 |
| Ставрополь | 56 | 121,7 |
| Сахалин | 54 | 79,4 |
| Әзербайҗан | 50 | 135,1 |
| Волгоград | 43 | 122,9 |
| Краснодар | 42 | 150,0 |
| Хабаровск | 41 | 87,2 |
| Чита | 41 | 95,3 |
| Приморье | 39 | 97,5 |
| Камчатка | 37 | 92,5 |
| Мурманск | 35 | 77,7 |
| Иваново | 34 | 170,0 |
| Бурятия | 29 | 80,5 |
| Владимир | 28 | 121,7 |
| Тула | 25 | 119,0 |
| Алтай | 24 | 82,8 |
| Архангельск | 21 | 70,0 |
| Ярославль | 20 | 95,2 |
| Амур | 18 | 90,0 |
| Бүтән якларда | 241 | 121,7 |
| Мәҗбүри данә | 44 | 81,5 |
| СССРда | 82 984 | 107,7 |
| Чит илләрдә | 60 | 127,7 |
| Барысы | 83 044 | 107,8 |

Мәгълүматлар 1990 елның 4 саны нигезендә бирелә.

1991 ел өчен газета һәм журналларга язылу башланды. Укучыларыбызның үтенечен искә алып, татар телендә чыга торган вакытлы матбугат турында кыскача мәгълүмат урнаштырабыз.

### КАЗАНДА

*Журналлар:*

**«Казан утлары»**. Индексы 73210. Бәясе 10 сум 80 тиен.

**«Идел»**. Индексы 73951. Бәясе 4 сум 80 тиен.

**«Азат хатын»**. Индексы 73002. Бәясе 3 сум.

**«Чаян»**. Индексы 73488. Бәясе 6 сум.

**«Мәгариф»**. Индексы 73363. Бәясе 3 сум.

**«Ялкын»**. Индексы 73582. Бәясе 2 сум 40 тиен.

**«Татарстан коммунисты»**. Индексы 73377. Бәясе 3 сум.

**«Офык»**. Индексы 73946. Бәясе 1 сум 44 тиен.

**«Салават күпере»** нәниләр өчен төсле рәсемле журнал. Бер санының бәясе 50 тиен. «Союзпечать» киоскларында сатыла.

*Газеталар:*

**«Социалистик Татарстан»**. Индексы 54123. Бәясе 7 сум 80 тиен.

**«Шәһре Казан»**. Индексы 54126. Бәясе 7 сум 80 тиен.

**«Татарстан яшьләре»**. Индексы 54121. Бәясе 3 сум 12 тиен.

**«Яшь ленинчы»**. Индексы 54124. Бәясе 1 сум 8 тиен.

**«Аваз»**. Индексы 54194. Бәясе 3 сум 12 тиен.

### УФАДА

**«Кызыл таң»** газетасы. Индексы 50602. Бәясе 7 сум 80 тиен.

**«Агитатор блокноты»** журналы. Индексы 73864. Бәясе 1 сум 92 тиен.

### КУЙБЫШЕВТА (ӨЛКӘ)

**«Бердәмлек»** атналык газета. Индексы 52382. Бәясе 1 сум 56 тиен.

### КИРОВ ӨЛКӘСЕНДӘ

**«Дуслык»** атналык газета. Бер елга язылу бәясе 3 сум 12 тиен.

### УЛЬЯНОВСКИДА

**«Өмет»** атналык газета. Индексы 54473. Бәясе 1 сум 56 тиен.

## ЯЗУЧЫЛАР ҖЫЕЛЫШЫ

28 июньдә Татарстан Язучылар берлеге башлангыч партия оешмасының ачык җыелышы үткәрелде.

Көн тәртибендә — балалар өчен әле быел гына чыга башлаган «Салават күпере» журналы турында сөйләшү иде. Күзәтүне М. Галиев һәм Х. Гайнетдинов ясады. Чыгыш ясаган әдипләр яшь журналның эчтәлегенә һәм бизәлешенә бәя бирделәр, үзләренең теләкләрен әйттеләр. Журналның баш мөхәррире З. Хөснияр редакциянең алдагы максатлары һәм бурычлары турында сөйләде, сорауларга җавап бирде.

Язучылар берлеге идарәсе рәисе, РСФСР Югары Советы әгъзасы Р. Мөхәммәдиев РСФСР халык депутатлары съездында алган уй-фикерләрен уртаклашты.

Җыелышның икенче өлешендә әдипләр, Татарстанга союздашлык статусын бирүне кичекмәстән көн тәртибенә кую һәм аны уңай якка хәл итүне сорап, ТАССР халык депутатларына мөрәҗәгать кабул иттеләр.

## ТАТАРСТАНДА ЭСТОН ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

22—28 июньдә Татарстанда эстон әдәбияты көннәре булып үтте. Бу истәлекле бәйрәмгә Эстониядән Язучылар берлеге рәисе урынбасары А. Валтон, «Лооминг» әдәби журналының җаваплы сәркатибе шагыйрә В. Вилланди, Язучылар берлегенең әдәби консультанты, балалар язучысы Х. Йыгисалу, Тарту университеты укытучысы тәнкыйтьче, филология фәннәре кандидаты Ү. Тонтс, прозаик О.Ремсу, «Ээсти раамат» нәшриятының эстон әдәбияты редакциясе мөдире М. Оямаа, Финляндиядән прозаиклар Е. Каннила, А. Конкка һәм «СССР-Финляндия» дуслык җәмгыятенең мәдәният бүлеге мөдире П. Маннинен килделәр.

Кунаклар, Татарстан Язучылар берлегендә каләмдәшләре белән очрашып, ике республика арасындагы иҗади бәйләнешләрны ныгыту турында фикер алыштылар. Аннары алар халкыбызның үткәне белән танышыр өчен Болгарга бардылар, Тукай-Кырлайда Г. Тукайның музеен карадылар. Эстон һәм фин дуслар Арча районындагы авылларда сәяхәт итеп, халкыбызның тормыш-көнкүреше белән якыннан таныштылар. «Аккош күле»ндә Сабан туенда катнашу, татар җырларын тыңлау, биюләрен, уеннарын тамаша итү кунакларга аеруча ошады.

Болгар җирендәге тарихи архитектура һәйкәлләре, Казан Кремле белән танышу, КДУ гыйльми китапханәсендә саклана торган кулъязма һәм китапларны күрү, Ш. Мәрҗани исемендәге мәчеткә, башкалабыздагы Г. Тукай музеена аяк басу кунакларга Татарстанның матди һәм рухи мәдәниятен киңрәк күзалларга мөмкинлек бирде. Балтыйк буе язучылары Казандагы каләмдәшләренең өйләрендә булып, шәхси бәйләнешләр дә урнаштырдылар.

Татарстанда узган эстон һәм фин әдәбияты көннәре вакытлы матбугатта, радиотелевидениедә киң яктыртылды, кунакларның байтак әсәрләре татар укучысына тәкъдим ителде.

Уңышлы узган бу атналык соңгы дәвердә Татарстанның тиң дәрәҗәдә һәм рәсми рәвештә союздаш республика,бәйсезлеккә йөз тоткан ил белән беренче мәртәбә әдәби бәйрәм алмашуы булып тора.

## МИТИНГ-КОНЦЕРТ

Татар иҗтимагый үзәге, Гражданлык комитеты һәм Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры чакыруы буенча 14 июнь көнне Казанның Ирек мәйданындагы Г. Тукай һәйкәле янында ТАССРның 70 еллыгына багышланган митинг-концерт булды.

Соңыннан митинг-концертта катнашучылар РСФСР халык депутатлары съездының барышына канәгатьсезлек белдереп һәм республикабыз статусын үзгәртүдә ярдәм итүне сорап, СССР Президенты М. С. Горбачевка һәм РСФСР Югары Советы рәисе Б. Н. Ельцинга мөрәҗәгать кабул иттеләр.

## ЧИКЛӘРНЕ УЗЫП...

Шагыйрь Р. Бохараев февраль аенда ГФРның Франкфурт шәһәрендә уздырылган Төрек-ислам җәмгыяте симпозиумында катнашты һәм меңләгән кеше алдында халкыбызның тарихы, иҗтимагый йөзе, әдәбиятыбыз үсеше турында төрек телендә чыгыш ясады. Март аенда Франкфурт, Кельн шәһәрләрендә яшәүче төрекләргә әдәбиятыбыз турында биш лекция укыды. Мюнхенның Людвиг университетында һәм Тюбинген шәһәре гимназиясендә немец яшьләренә, Мюнхенның Украин университетында олкәннәргә Татарстан тормышы хакында сөйләде.

Хәзерге вакытта ул — Англия һәм Австралиядә сәфәрдә.

## ЧИТ ИЛЛӘРДӘ ЯШӘҮЧЕ МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ — БЕЗДӘ КУНАКТА

«Ватан» җәмгыяте чакыруы буенча июнь аенда чит илләрдә яшәүче милләт-

тәшләребез Казанда кунакта булдылар. Алар арасында Төркиядән Бәһия Алтан, Америкадан Равил Сәлихмәт, Япониядән Гаяз Агиш, Финляндиядән ирле-хатынлы Фатих һәм Фәридә Низаметдиннар, Көнбатыш Алманиядән «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе мөдире Фәрит Иделле, Гали Акыш, Австралиядән Ләйлә ханым һәм Сәгыйть әфәнделәр гаиләсе һәм башка кунаклар бар иде.

Алар Казан белән таныштылар, Сабан туе бәйрәмнәрендә булдылар, бик күп очрашуларда катнаштылар, изге Болгар җиренә зиярәт кылдылар.

Фәрит Иделле һәм Гали Акыш исә Пресса йортында да булдылар, «Казан утлары» редакциясе коллективы белән очраштылар.

## БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ КӨННӘРЕ

17—28 июнь көннәрендә республикабызның халыкара «Идел» ял лагеренда Бөтендөнья татар яшьләре көннәре булып үтте. Бирегә Төркиядән (Истанбул), Башкортстаннан, Баку, Ташкент, Тубыл, Магнитогорск, Мәскәү шәһәрләреннән, Төмән, Ульяновск, Әстерхан, Саратов, Куйбышев өлкәләреннән, Татарстанның шәһәр һәм авылларыннан яшьләребез җыелды.

«Идел»дә ял итүче татар яшьләре галимнәр, артистлар, дин хезмәткәрләре, язучылар, шагыйрьләр белән фәһемле очрашуларда булдылар, республикабызның һәм Казанның тарихи истәлекле урыннарын карадылар. Болардан тыш алар лагерьда үзләре дә кызыклы кичәләр, төрле мавыктыргыч чаралар үткәрделәр.

Бөтендөнья татар яшьләре көннәре Татар иҗтимагый үзәге һәм республиканың комсомолы тарафыннан оештырылды.

## ТУГАН ТЕЛ БӘЙРӘМЕ

Республика «Ватан» җәмгыяте 28 июнь җомга кичендә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасы каршындагы мәйданда «Туган тел» бәйрәме үткәрде. Бу бәйрәмдә Төркия, Австралия, Америка, Япония, Көнбатыш Алмания, Финляндия мәмләкәтләреннән килгән милләттәшләребез һәм илебезнең төрле төбәкләреннән җыелган яшьләр катнашты һәм чыгыш ясады. Шулай ук биредә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры артистлары үзләренең сәнгать осталыкларын күрсәттеләр. Соңыннан «Туган тел» бәйрәмендә катнашучылар, республикада татар телен дәүләт теле итеп игълан итүне якларга чакырып, Татарстан АССР халык депутатларына мөрәҗәгать кабул иттеләр.

## ТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ҮЗӘГЕНЕҢ IV ПЛЕНУМЫ

16—17 июньдә Казанның Актерлар йортында һәм Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының Кече залында Татар иҗтимагый үзәгенең IV Пленумы булды. Биредә илебезнең төрле төбәкләрендә яшәүче милләттәшләребез вәкилләре катнашты һәм чыгыш ясады. Пленумда бүгенге көн милләтебез хәятенә кагылышлы мөһим мәсьәләләр каралды. Татар җәмәгатьчелегенең бу форумында республика җитәкчелегенең булмавы аның үз халкын хөрмәт итмәве һәм мәнфәгатьләренә битараф каравы дип билгеләнде.

Пленум Татарсан җитәкчелегеннән түбәндәгеләрне таләп итә:

1) ТИҮне бөтен татар халкының мәнфәгатен чагылдыручы Бөтенсоюз иҗтимагый-сәяси оешма икәнлеген танырга;

2) Республикадагы хакимият органнарының ТИҮгә булган мөнәсәбәтләрен уңай якка үзгәртергә, бу оешманың эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле булган барлык шартларны да булдырырга (бина бирергә; республикадан читтә яшәүче татарларның мәдәни-тел үсеше буенча эш алып баруны оештыру өчен кирәкле ярдәм күрсәтергә);

3) «Үз милли-дәүләт берләшмәләреннән читтә яшәүче яки ул СССР җирендә андый берләшмәләре булмаган СССР гражданнарының ирекле милли үсеше турында» дигән СССР Законын тормышка ашыру юнәлешендә ТАССР министрлар Советы каршында татар халкының мәдәни-тел үсеше буенча Дәүләт комитеты төзергә;

4) Мөрәҗәгатьне «Социалистик Татарстан», «Советская Татария», «Вечерняя Казань» газеталарында, «Идел», «Казан утлары» һәм «Азат хатын» журналларында бастырып чыгарырга.

## МӨСЕЛМАННАРНЫҢ БИШЕНЧЕ НӘДҮӘСЕ

Июнь аеның беренче ункөнлегендә Уфада мөселманнарның бишенче нәдүәсе үткәрелде. Ниһаять, 42 елдан соң чираттагы бу мәҗлескә катнашу өчен илебезнең төрле өлкәләреннән, шулай ук Литва, Эстония мөселманнары, АКШ, Япония, Төркия, Австралия, Финляндия, Согуд Гарәбстаны, Азия һәм Африканың башка илләреннән вәкилләр килде.

Нәдүәдә мөфти хәзрәтләренең хисап чыгышы тыңланды, яңа мәчетләр төзү, мәхәлләләр булдыру, дини матбугат басмалары, балалар өчен җәйге ял лагерьлары оештыру, башка күп төрле эшләр башкару мәсьәләләре каралды.

Мөселманнарның бишенче нәдүәсендә катнашучылар бертавыштан мөфти итеп янә Шәйхелислам Тәлгать Таҗетдин хаҗи хәзрәтләрен сайладылар.

## ИСТАНБУЛ ГАЛИМЕ КАЗАНДА

20—25 июньдә Истанбул университеты доценты Осман Фикри Серткая башкалабыз Казанда булды. Ул бирегә СССР Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәге Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты чакыруы буенча килгән иде.

Кунак институт галимнәре белән очрашып фикер алышты, кулъязмалар бүлегендә һәм КДУның гыйльми китапханәсендә хәзерге вакытта саклана торган төрле борынгы язмалар, китаплар белән танышты.

Галим шулай ук шәһәребезнең истәлекле урыннарын да тамаша кылды.

## ЯҢА МӘЧЕТКӘ НИГЕЗ САЛЫНДЫ

21 июнь көнне республикабызның Әлмәт шәһәрендә төзеләчәк яңа мәчеткә нигез ташлары салу тантанасы булды. Биеклеге 70 метр, гөмбәзле, 5 манарадан гыйбарәт булган гыйбадәт йорты шәрык архитектурасы бизәлешендә эшләнгән мәһабәт композицияне тәшкил итәчәк.

Яңа мәчетне төзү 1992 елда тәгалләнәчәк.

## ЛАУРЕАТЛАРГА БҮЛӘК ТАПШЫРУ

Мәгълүм булганча, Татарстанның Г. Тукай исемендәге 1990 елгы дәүләт бүләкләре язучы М. Мәһдиевкә «Кеше китә — җыры кала», «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү» повестьлары өчен, язучы И. Салаховка «Колыма хикәяләре» романы һәм композитор С. Садыйковага (вафатыннан соң) җырлары өчен бирелде.

23 июнь көнне ТАССР Министрлар Советында лауреатларга дипломнар һәм медальләр, шулай ук С. Садыйкованың кызы — Ә. Айдарскаяга әнисенең дипломы һәм медале тапшырылды.

## ТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ҮЗӘГЕ: ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРДӘ

Шушы елның 10 май көнендә Башкортстандагы Эстәрлетамак шәһәре «Химик» мәдәният сараенда киң җәмәгатьчелек катнашлыгында җыелыш булды. Анда катнашучылар «Мирас» дип исемләнгән Татар иҗтимагый үзәген оештырдылар. Үзәк төбәктә яшәүче күпсанлы татар халкының рухи, мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүне күздә тотып төзелде. Бу җыелышта устав, программа, резолюция кабул ителде.

Татар иҗтимагый үзәге «Мирас»ның рәисе итеп Эстәрлетамак педагогия институты укытучысы И. Насипов, рәис урынбасары итеп табигатьне саклау комитеты тикшерүчесе Ф. Туктаров сайланды.

«Мирас» Эстәрлетамак шәһәр Советының 12 июнь карары белән расланды һәм рәсмиләштерелде.

## ТАТАР ГИМНАЗИЯЛӘРЕ

Быелгы яңа уку елында республикабыз күләмендә 4 татар гимназиясе ачыла. Аларның өчесе Казанда, берсе Чаллы шәһәрендә булачак.

Гимназияләрдә укыту-тәрбия эшләре татар телендә алып барылачак. Укыту дәверендә халык педагогикасы, халкыбызның гореф-гадәтләрен киң куллану күздә тотыла. Шулай ук татар милләтенең тарихы һәм мәдәнияте, гарәп теле, логика, эстетика, экология, дин тарихы, этика һәм гигиена кебек фәннәр дә өйрәтеләчәк.

## АЛМАН ИЛЕНДӘ

Татар иҗтимагый үзәге рәисе, Татарстан халык депутаты Марат Мөлеков, Татарстан халык депутаты, Татар иҗтимагый үзәге идарәсе әгъзасы, язучы Фәүзия Бәйрәмова һәм профессор Риф Хәйретдинов май аеның 9ыннан 25енә кадәр Көнбатыш Германиядә булдылар һәм «Төрек-Ислам берлеге» җәмгыятенең III Бөек Корылтаенда катнаштылар.

Моннан тыш язучы Ф. Бәйрәмова Көнбатыш Германиянең Франкфурт-Майн, Кельн, Майнц, Мюнхен, Дармштад, Хайдельберг, Аугсбург, Денслакен, Опелхайм, Мельхайм, Ремшей шәһәрләрендә «Төрек-Ислам берлеге» җәмгыяте бүлекчәләрендә татарлар турында лекцияләр укыды. Шулай ук Хайдельберг университетында алман укытучылары һәм студентлары белән очрашты, университет китапханәсендә эшләп, аннан татарлар турында бай мәгълүмат тапты, Аугсбург шәһәрендә Кырым татарларының Хәтер көнендә катнашып, бүгенге Кырым турында сөйләде, Кельн шәһәрендә казакъ җәмгыятендә булды. Ф. Бәйрәмова «Азатлык» радиостанциясендә татар халкының тарихы һәм бүгенге хәле турында радиотасмага дистәләгән чыгыш яздырып калдырды, радиостанциядә эшләүче башка милләт вәкилләре белән матбугат конференциясе уздырды, төркмән, таҗик, казакъ, үзбәк, азәрбайҗан, грузин радиоларына аерым чыгышлар яздырды.

Ф. Бәйрәмова Алман җирендә Төркиядән килгән танылган сәясәткәрләр, галим, язучы һәм сәнгать эшлеклеләре белән дә очрашты, Татарстан һәм Төркия арасында булачак сәяси, икътисади, мәдәни бәйләнышлар турында эшлекле сөйләшүләр булды. Төркиянең «Заман», «Төркия», «Хөррият», «Тәрҗеман», «Азатлык» һәм башка күп кенә газеталарында Ф. Бәйрәмова белән әңгәмәләр басылып чыкты.

Язучы туган илгә бай материал — татарлар турында китаплар да алып кайтты. Алар арасында Абдулла Баттал-Таймасның «Казан төрекләре», Йосыф Акчура, Зәки Вәлиди турында истәлекләр китабы, Гаяз Исхакый, Җамал Вәлиди хезмәтләре, урыс телендә чыккан тарихи хезмәтләр бар.

# КАЗАН КРЕМЛЕ

Заманында феодаль дәүләтләргә хас булганча, дошман һөҗүмнәреннән саклану өчен урта гасырларда Казан шәһәрендә дә ныгытма-кальга төзелә. Аның диварлары юан, нык имән бүрәнәләрдән буралап 6-7 метр киңлектә, 8 метр биеклектә эшләнеп, эченә ком, балчык тутырылган. Калкулык өстендәге бу ныгытмада керел-чыгып йөрергә биек каравыл манаралары урнаштырылган капкалар ясалган. Көньякка каратып эшләнгәне Хан капкасы, яки Зур капка, Болак буе ягындагысы Түбән капкасы, төньяк-көнбатыш тарафындагысы Нурга-ли капкасы, төньяк-көнчыгышка чыга торганы Алабуга капкасы дип аталган. Вакытлар үтү белән кальга тагын да киңәйтелә, анда янә Аталык, Кырым, Ногай, Арча һәм башка капкалар куела.

Өстәмә саклану чарасы итеп дивар әйләнәсендә кирәк урыннарга су тутыру өчен махсус чокырлар, канаулар казылган. Тарихи чыганаклардагы кайбер мәгълүматларга караганда, аларның киңлеге 6, тирәнлеге 14 метр булган. Ә инде Болак елгасы һәм төньяктагы күлләр ныгытма корырга урын сайлаганда ук аларның стратегик әһәмияте искә алынганлыгын күрсәтә.

Казан Кремле турында XVI йөздә аны үз күзләре белән күрүчеләр, соңга таба тарихчы-тикшеренүчеләр бик сокланып язып калдырганнар. Мәсәлән, 1552 елда Казанны яулап алуда катнашкан кенәз А. Курбский язмаларында түбәндәгеләрне укырга мөмкин: «...Казан елгасыннан тау шундый биек ки, хәтта карау өчен дә бик югары. Аның өстендә исә кальгада таштан эшләнгән хан сарайлары һәм мәчетләр бар, шунда ук Казанның үлгән патшаларын күмгәннәр, ялгышмасам, алар бишәү икән...». Ныгытманың төзелешенә, андагы корылмаларның матурлыгына Явыз Иван үзе дә бик сокланып караган. «...Бөек кенәз башта шәһәрне тирәли карап йөргәч, диварларның биеклеген һәм һөҗүм итәрлек урыннарны күзәткәч, кальганың матурлыгыннан гаҗәпкә калды...» — дип билгеләп үтә бу турыда «Казан тарихы»н язучы.

1977 елда үткәрелгән археологик казынулар А. Курбскийның язганнарын тагын бер тапкыр раслады. Ул әйткән биш патшаның каберләре ачылды. Янә аның язмаларында телгә алынган биек манара да Сөембикә манарасы булырга тиеш.

Урта гасыр шәһәр ныгытмаларын махсус өйрәнүчеләр бу кальганың корылышын югары бәялиләр. «Казан беренче класслы, һөҗүм белән алып булмый торган ныгытма»,— дип билгеләп, аны Смоленск һәм Тула шәһәрләрендәге ныгытмалар белән тиңлиләр.

1552 елның 2 октябрендә урыс баскынчылары, кальганы һөҗүм белән генә алып булмаячагына төшенгәч, аның диварларын ике урыннан шартлаталар. Шартлатылган урыннарның берсе хәзерге Университет һәм Бауман урамнары чатындагы аптека, икенчесе хәзерге Бауман урамы башындагы Кремль астындагы элекке Аталык капкасы төбәкләрендә булган. Җир астыннан казып кереп, әйтеп үтелгән җирләргә 24 зур мичкәдә 480 пот (7680 килограмм) микъдарда дары куелган. Көчле шартлау нәтиҗәсендә ныгытма стеналары һавага күтәрелгән һәм шул урыннардан урыс гаскәрләре кальга эченә ташланганнар.

1556 елда Кремль диварларын ак таштан сала башлаганнар һәм аның озынлыгы 1565 елда 900 метр гына булган. 1590 елларда ул кызыл кирпечтән төзелә башлый. Элеккеге агачтан буралап эшләнгәне 1730 елда сүтеп алынган.

**Сәлам АЛИШЕВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган драматург, СССРның халык депутаты Туфан Миңнуллин.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотолары.

*«Казан утлары» 1991 елда*

**Гурий Тавлин**

# АФӘТ

РОМАН. II КИСӘК

Артымда авыр тимер ишек хәвефле шыгырдап ябылгач, мин дегеттәй куе караңгыда нишләргә белми озак басып тордым. Аннары, әйләнә-тирәмне кулларым белән капшап, утырыр урын эзләргә керештем. Әмма яңа торагымда формасы белән авыл хатыннарының капкачлы калай күмер чүлмәкләрен хәтерләткән сасы парашадан бүтән берни дә юлыкмадым. Дөм караңгы салкын бүлмәдә, бер йә ике кешелек камералардагы шикелле, стенага беркетелгән кечкенә өстәл дә, бәләкәй утыргыч та, көндез диварга күтәреп бикләнә торган примитив карават корамасы да юк иде.

Стеналарга тотына-тотына сәер куышымны берничә тапкыр әйләнгәч, ишек буендагы парашасыз почмакка чүгәләдем.

Менә нинди икән ул карцер дигәннәре! Ул, тәрәзәсез кысан тартма булуын һәм утсыз икәнен исәпләмәгәндә, әллә ни канәгатьсезлек тудырырлык түгел кебек. Кызык, мине ничә тәүлеккә керттеләр икән аңа? Карцерда кеше тәүлекләр буена гел аяк өсте торырга яки боз күк салкын таш идәнгә утырырга тиеш микәнни? Өс киемнәрен кертсеннәр иде хет, монда болай, салкын тидереп, аяктан егылуың да озак түгел. Тукта, мин нигә берничә тәүлек буе суык шәрә идәндә аунарга тиеш әле? Чү, нәрсәдер кагылды түгелме аякка? Ниндидер җан иясе бар бугай янымда... Бәлки, мәчедер? Әнә чыелдады. Мәче чыелдамый, мияулый. Камерада күсеәр бар, ахры, шулар чыелдаша. Надзирательләр мине бирегә күселәрдән талатырга утырткannar, димәк... Талатмый торсыннар!..

Мин, аякларыма калкып, тимер ишекне тибә-тибә дөбердәтергә тотындым. Коридордан кемдер ачу белән:

— Сиңа коры карцер ошамый, юешенә утырасың киләме? — диде.

— Монда күселәр бар, яктыртыгыз камераны!..

— Күселәр бүре түгел, кабып йотмас. Аң бул, әгәр тагын тавыш чыгарсаң, бездә синең ише җәнҗал куптаручыларны тыярга юашландыру күлмәге дә бар. Аны үлчәтеп карарга да күп сорамабыз...

Юеш карцеры ниндирәк албасты куены икән тагын? Гүр кебек салкын бу баздан да койтырак җир бар микәнни әле бу төрмәдә?.. Юашландыру күлмәге, ди тагын. Патша самодержавиесе золымын юк иткәнгә инде утыз өченче ел бара, илебездә мондый җәза урыннары нигә бетерелми, нигә дип һаман саклана икән? Меңләгән коралдаш иптәшләрем илебез бәйсезлеге өчен аяусыз көрәштә баш салып яу кырында ятып калганда мин, гаепсездән гаепле булып, шушы түбәнсетүләрне, кимсетүләрне татырга исән калганмыни сугышта? Бездә гаделлек, мәрхәмәт, кешелеклелек тик сүздә генә микәнни соң?

Өстемә кинәт күсе сикерде...

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)